Мәхмүтова А.Х.

Бәзәкәм – туган бишегем



Мәхмүтова Альта Хажи кызы

1937 елның 9 июнендә Бәзәкә авылында туган. Башлангыч мәктәпне авылда тәмамлап, 1948–1951 елларда район үзәге Бондюгта 5–7 классларда укыган. 1951–1955 елларда Алабуга педучилищесында белем алган. Шуннан соңгы гомере Казанда үтте. 1955–1965 елларда Казан мәктәпләрендә укыткан, 1965 елда читтән торып Казан университеты тарих-филология факультетының тарих бүлеген тәмамлаган. Шул ук елны СССР тарихы кафедрасы каршындагы аспирантурага кабул ителгән. 1967 елдан 2010 елга кадәр университетта эшләгән (ассистент, өлкән укытучы, доцент). 1971 елда «Татарларда хатын-кызларны деньяви укыту өчен көрәш (1861–1917 еллар)» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклаган. Берничә фәнни һәм фәнни-популяр китаплары, төрле журнал һәм җыентыкларда күпсанлы мәкаләләре басылды. «Лишь тебе, народ, служенье! (Әйдә халыкка хезмәткә!)» китабы өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге премиясе лауреаты. Хәзер пенсиядә.

АЛЬТА МӘХМҮТОВА

БӘЗӘКӘМ,
ТУГАН БИШЕГЕМ

УДК
ББК

Мәхмүтова Альта Хаҗи кызы. Бәзәкәм - туган бишегем. – Казан:

Мөхәррир Мәхмүтова Әнисә Хаҗи кызы

Татарстан Республикасы Менделеевск районындагы Бәзәкә авылы – тарихы гасырлар төпкеленә барып тоташкан күпләгән авылларның берсе. Китапта күпсанлы чыганаклар нигезендә аның гыйбрәтле күпгасырлык тарихы күрсәтелә, тырыш, намуслы халкының гамәлләре, көнкүреше тасвирлана. Басмада авторның һәм авылдашларның хатирә-истәлекләре дә урын алуы аны укучыларга якынайта.

Туган як тарихы белән кызыксынучыларга, эш сөючән һәм горур бәзәкәлеләр игътибарына тәкъдим ителә.

Кадерле әти-әнием
һәм авылыбызны гасырлар буена
яшәткән әби-бабаларыбыз рухына
бу китап изге дога булып барып ирешсен.

Хөрмәтле авылдашым!

Синең кулыңда авылыбыз тарихы. Нәрсә ул авыл тарихы? Бер яктан караганда, безнең авыл да, меңләгән башка авыллар кебек, салмак кына бер алган юлдан гасырлар аша үзгәрешләрсез генә барган да барган сыман. Аның үткәнендә бернинди кызыклы, истә калырлык вакыйгалар, күренекле шәхесләр дә булмаган кебек. Ләкин болай уйлау урынсыз. Тарих ул аерым кешеләрнең язмышыннан тора. Авыл тарихы – танылган шәхесләр тарихы гына түгел, ә бәлки анда яшәгән һәр кеше тарихы. Бу тарихта һәркем кадерле. Шәҗәрәсеннән аерылган бүгенге буыннар өчен моны аңлау бигрәк тә мөһим. Һәрбер авылның йөзен билгеләүче нәселләр, буыннан-буынга ихтирам белән искә алынучы шәхесләр булса да, авылны бар итүче, аны яшәтүче алар гына түгел, ә авылның хезмәт сөюче барлык халкы икәнлеген онытмасак иде.

Бу язма тарих безнең – синең һәм минем – әби-бабаларыбыз, туганнарыбыз, сөекле Бәзәкәбездә туып-үскән, гасырлар дәвамында авылны яшәткән кешеләр тарихы. Буыннар алмашы дәвамында безнең җирлегебездә меңләгән кешеләрнең тормышы узган. Һәркемнең тормышы кызыклы һәм кыйммәт. Без аңа игътибар гына итмибез түгелме? Чыганакларга таянып, мин авылдашларыбыз тарихын киңрәк тасвирларга, халыкның уй-хыялдагы түгел, ә чынбарлыктагы тормышына күбрәк тукталырга тырыштым. Һичшиксез, бер китап кына барлык шәхесләрнең дә исемнәрен атый алмый. Шулай да бу китапны укучы авылдашларымның һәрберсе үз нәселе хакындагы мәгълүматка да тап булыр дип ышанам.

Бу китап безгә – бүген гомер итүчеләргә дә, бездән соң килүче буыннарга да - кызыклы булыр дип өмет итәм.

А.Х.Мәхмүтова.

Хәтерем эзләреннән

...Шәһәрдәге таш фатирдан мине
Эзләп тапты авылымның җаны.
Хәтергә бер күз салырга кушты,
Бушатты да тынны аз гына ул,
Элек әнкәй хат яздырган төсле,
Васыятен әйтеп яздыра ул...

Харрас Әюп

Хәтер... Кеше хәтере, нәсел-ыру хәтере, халык хәтере, тарихи хәтер... Хәтер үзенә бик күп нәрсәне сыйдыра – дөнья хәлләрен дә, аерым кеше тормышында булган вакыйгаларны да. Хәтер ул – тарихны саклаучы да, аны юкка чыгаручы да була ала. Шулай да... “Тарихи Хәтер дигәнең гаҗәп тотрыклы, нык, хәтта үзенчә “киребеткән” - үҗәт нәрсә икән, - дип язган иде 1994 елда, тарихи үзгәрешләр башланган чорда, академик М.Госманов “Гасырдан – гасырга” исемле җыентыкка кергән бер мәкаләсендә, - Күпме аны кырып, себереп ташларга теләсәң дә, һич тә юкка чыкмый. Бер җирдә бассаң, күмсәң, икенче урыннан тишеп, калкып чыгар ул. Калын асфальтны үтәли тишкән нечкә үлән сабагыдай төрле сәяси, идеологик тыюлар аркылы да киләчәккә таба уза ул Тарихи Хәтер. Йә көчсезләнеп кечерәйгән хәлдә, яисә, киресенчә, әллә нәрсәләр исәбенә үскән, зурайган рәвештә. Легендага, риваятькә әверелгән чынбарлык, тарихи фактлык дәрәҗәсенә дәгъва итә торган легенда, әкиятләр төсле...”.

Хәтерем мине еракларга алып китә: мин балачагыма кайтам. Әле яңа гына Бөек Ватан сугышы тәмамланган еллар... Әби-бабайлардан ишеткән бәет-мөнәҗәтләр, китаплардан укыган әкият-риваятьләр, хикәя-легендалар сабый чагымнан ук мине тарихка алып кергән икән бит! Бу өлкәдә иң беренче сабаклар бирүчем исә “гади авыл карты” – Тәҗимулла абзый (Шакиров Тәҗетдин – үсеп җиткәнче мин аның тулы исеме Тәҗимулла дип уйлый идем) булган икән.

Авыл никадәр зур булса да, аның халкы, гадәттә, бер-берсен ишетеп, күреп, аралашып белә; ләкин бу белемнең чикләре дә бар. Шуңа күрә, күпмедер вакытка кадәр, мин Тәҗимулла абзый белән таныш түгел идем. Аларның өе безнең өйдән шактый ерак, олы урамда урнашкан, Тәҗимулла абзыйның төпчек кызы Сания да миннән олырак. Сигез-тугыз яшемдә, нинди сәбәп булгандыр, хәтерләмим, мин Сания белән аларның өйләренә килдем. Аның әтисе белән танышу минем өчен үзе үк гыйбрәтле булды: ул, зур кешене кабул иткән кебек, эшеннән аерылып, минем белән сөйләште, бер алма да тоттырды (1941-42 елгы суыкларда алмагачлары корыган авыл өчен алма бик тансык нәрсә иде). Ләкин мине иң гаҗәпләндергәне – без килеп кергәндә, Тәҗимулла абзый өстәл артында нәрсәдер укып-язып утыра иде! Саниядән да сораштым, өйгә кайткач та төпченүемне дәвам иттем, ләкин күп нәрсә белә алмадым.

Мин бик үҗәт бала идем: башымда берәр сорау туса, җавабын тапмыйча, башкаларга тынычлык бирми идем. Тәҗимулла абзыйның үзенә сораулар

бирергә баштарак читенсенсәм дә, төрле сәбәпләр табып, аларга баргалый башладым. Һәр килүемдә, хуҗалык эшләре белән мәшгуль булмаган вакытларында, аның кулында кәгазь-каләм күрә идем. Күршедәге бабайларның берсен дә китап-кәгазь белән күрмәгән кызчыкка бу хәл бик гаҗәп, сәер тоелгандыр, күрәсең! Таҗимулла абзый, авылда зур хөрмәткә ия булса да, гади кеше - укытучы да түгел, кантурда (колхоз конторасы һәм авыл советын без шулай атый идек) да эшләми, ә һаман язу эшендә. Шуның белән бергә ул безнең эшләр белән дә кызыксына, мине сөйләштерә, кайчагында безгә авылыбыз турында төрле риваять-хикәяләр дә сөйләп ала. Аңа ияләшә төшкәч, мин дә үземне борчыган сорауны бирергә җөрьәт иттем, нәрсә язуын сорадым. Нәкъ шул вакытта мин аннан үземә таныш булмаган "*шәҗәрә*" сүзен ишеттем.

Шәҗәрәнең нәрсә икәнен Таҗимулла абзый безнең нәсел мисалында буыннар чылбырын әйтә-әйтә аңлатты: "Әтиеңнең исеме *Хаҗи* (Хаҗиәхмәт), аның әтисе *Мәхмүт* исемле булганын син беләсең. Ә әтиеңнең бабасының исемен беләсеңме?". Мин белмәвемне әйткәч, ул: "Мәхмүтнең әтисе *Ибраһим*, Ибраһимның әтисе *Бикташ*, Бикташның әтисе *Хуҗаш* исемле булган, - диде һәм өстәп куйды: - Менә бу сезнең нәсел чылбыры, ягъни шәҗәрә була". Кешеләргә җиде буын бабаларын белергә тиешлеген дә әйтте ул, үзенең авылда яшәүче нәселләрнең шәҗәрәләрен торгызу белән шөгыльләнүен дә аңлатты. Исәннәрнең генә түгел, үлгәннәрнең дә исемнәрен белүнең мөһимлеген шул чагында аңлый башлаганмындыр кебек тоела миңа хәзер.

Таҗимулла абзыйны тыңлаганда миндә туган яңадан-яңа сорауларны мин башкаларга да (әти-әнием, укытучым Әминә апа, туган-тумача һәм күрше әби-бабайларга) бирә идем. Шулай сораша-сораша, мин авылның бик борынгыдан килгән шәҗәрәсе булганлыгын, аның 20-30 еллар азагындагы зур янгын вакытында юкка чыгуын белдем (хәзер уйлыйм – бәлки ул янгын да булмагандыр, ә шул чор репрессияләрен халык шулай атагандыр?). "Ни өчен нәкъ менә Таҗимулла абзый бик күпне белә, авыл шәҗәрәсен дә яза, ул бит гади колхозчы гына?" - дигән сорауга да җавап таптым. Минем бетмәс-төкәнмәс сорауларымнан туйган әтием: "Ул бит Бубыйда укыган, Бубый шәкерте булган кеше", - дип, минем сорауларымны ишәйтте генә. Акрынлап мин Бубыйның безнең авылдан 90 чакрым ераклыктагы авыл булуын, анда революциягә кадәр атаклы мәдрәсә эшләвен белдем. Бу мәдрәсәдә укыган шәкертләрнең зур белемгә һәм ихтирамга ия булуларын да аңладым. Әтидән: "Ә нигә син ул мәдрәсәдә укымадың?" – дип сораганым да хәтеремдә.

Әлбәттә, минем үз әби-бабаларым хакында күбрәк беләсем килде. Һәм мин үземнең сорауларым белән әти-әнине аптыратып бетерә идем. Башта алар: "Син әле кечкенә, әгәр дә кызыксынсаң, үскәч белерсең", - дип, минем "бәйләнүләремне" туктатырга уйладыдлар (ул чор өчен мондый җавап бик гадәти хәл, һәм әни еш кына мине шулай туктата иде). Ләкин бу юлы мин бирешмәдем. "Таҗимулла абзый: "Һәр кеше үзенең нәселен җиде бабасына кадәр исендә тотарга тиеш," - ди, нигә син миңа дүрт кенә бабамның исемен әйтәсең?" - дип, әтине йөдәтеп бетерә идем.

Нигаять, кичләрнең берсендә әти хәтерен яңартырга булды. Ул кечкенә чагында, абыйсы Нуриәхмәт белән әтигә Мәфтуха әбиләре җиде буын бабаларының исемен өйрәткән булган икән. Ләкин ул вакыттан соң бик күп еллар узып киткән, дөньялар үзгәргән, әти башыннан күпме кайгы-хәсрәт узган, күп нәрсәләр онытылган... Бабаларның исемнәре дә хәтерендә буталган. Шулай да, хәтерендә казына торгач, мин Таҗимулла абзыйдан белеп кайткан дүрт исемнән башка, тагын өч исемне әйтте: *Уразмәт, Тәкәш, Сөләйман*. Ләкин аларның нинди тәртип белән бирелгәнлеген, ягъни кайсы ата, кайсы бала, кайсы баба булуын исенә төшерә алмады. Аның хәтерендә тагын бер үзенчәлекле факт табылды: Мәфтуха әби Сөләйман бабайның тагын бер исемен атаган икән – аны авылда, үлеменнән соң озак вакытлар үткән булса да, “*Сөлүк староста-бабай”* дип искә ала торган булганнар...

Хәтерем XX гасыр азагына - “үзгәртеп кору” дигән төшенчә кергән, Советлар Союзы җимерелгән заманга сикерә. Бу чорда җәмгыятьтә башланган үзгәрешләр, аны демократияләштерүгә омтылу, чагыштырмача матбугат иреге урнашу тарихтагы “ак таплар”ны тутырырга, татар халкы тарихына булган карашны киңәйтергә, яңа фикерләр әйтергә мөмкинлек бирде. Бу яңа тарихи чорда кешеләрдә моңа кадәр бик тирән яшерелгән хис - үз халкы, үз төбәге, үз авылы, үз нәсел-ыруы тарихы белән кызыксыну хисе - елгалардагы буаларны җимергән язгы ташкын кебек бәрелеп чыкты.

Бәлки мин тарихчы булгангадыр, 90-елларда, кайда гына барсам да, нинди кешеләр белән аралашсам да, татар тарихы хакында сүз чыга, сораулар ява, бәхәсләр күтәрелә иде. Туган авылым Бәзәкәгә кайтканда да шул ук хәл – тарих, сәясәт хакында сөйләшүләр артканнан-арта барды. Бу сөйләшүләр, урамда очрашканда башланып, минем апам, пенсиядәге укытучы Нажия Мәхмүтова йортында да, башка өйләрдә дә дәвам итте. Әңгәмәдәшләремнең күбесе – Нажия апаның дуслары һәм хезмәттәшләре. Бу чорда иң күп аралашкан авылдашларым Шәргыя апа Ибәтуллина һәм аның ире Фәрахетдин абый Хужиәхмәтов (авылның атаклы рәссамы), укытучылар Гаян апа Әюпова, Фирая апа Салихова, Хәй абый Гыйльфанов һәм Фәйзелхак абый Хөснетдинов булдылар. Бөтенебез берьюлы бергә җыелып түгел, әлбәттә. Очрашулар вакытында, татар халкы тарихына кагылышлы сөйләшүләрдә, сүзебез авылыбыз тарихына күчә, истәлекләр башлана, күптән онытылган дип исәпләнгән вакыйгалар каяндыр калкып чыга башлады.

Менә шул сөйләшүләрнең берсендә, Фәйзелхак абый белән булса кирәк, мине кечкенә чагымда шундый кызыксындырган, ләкин үскәндә “җиңел” генә онытылган авыл шәҗәрәсе тарихына кереп киттек. Таҗимулла абзый төзегән шәҗәрә, аның вафатыннан соң, Фәйзелхак абыйга күчкән һәм анда сакланган булып чыкты. Фәйзелхак абый шәҗәрәне 1976 елда авылга Казаннан килгән Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләүче галимгә биреп җибәргән икән. Ләкин копиясен алып, кайтару шарты белән бирелгән бу кыйммәтле документ, ике дистә елга якын вакыт үтсә дә, кире кайтмаган. Фәйзелхак абыйга мин шәҗәрәнең эзен табуда булышырга вәгъдә бирдем. Ул галим минем яхшы танышым, ләкин ул Чаллыга күчеп киткән иде. Уртак

дуслар аша аны эзләп табып, шәҗәрәне кайтаруын сорадым.

Нигаять, шәҗәрә минем кулда. Ул, тигезле-тигезсез итеп киселгән көрән төстәге каты кәгазьгә язылып, кулдан тегелгән дәфтәр формасында иде. Бондюг химия заводында кулланышта булган зур кәгазь каплардан кисеп ясалган бу дәфтәргә (“фабричный” дәфтәрләр булмау сәбәпле сугыш вакытында мәктәп укучылары да мондый “дәфтәр”ләрне куллана иде), гарәп графикасында, “химический” дип йөртелә торган карандаш белән (ул карандаш, язганда юешләсәң, язма шәмәхә - язу карасы төсен ала, юешләмичә язсаң, язма тонык чыга) нәсел шәҗәрәләре язылган. Азагында бирелгән исемлектә 47 нәсел (һәрберсендә 3-7 төркем) күрсәтелгән. Кулъязма авыр укыла (гарәп графикасындагы кулъязмаларны уку күнекмәгән кешегә гомумән авыр бирелә, моның өстенә кәгазьнең сыйфатын һәм карандаш эзләренең “картаю”ын искә алырга кирәк). Шуңа күрә мин, җыентыкны карап чыгып, үзебезнең нәсел шәҗәрәсен генә күчереп алдым да, Фәйзелхак абыйга кайтарып бирдем... Соңрак, шәҗәрәләр белгече Марсель Әхмәтҗановның 2012 елда чыккан “Татар шәҗәрәләре” исемле китабына Бәзәкә шәҗәрәсе дә кертелгән булып чыкты. Ләкин аны безнең шәҗәрәнең уңышлы басмасы дип әйтеп булмый, чөнки байтак исемнәр дөрес укылмаган яки укылмыйча калдырылган һәм сорау билгесе белән билгеләнгән. Безнең нәсел шәҗәрәсендә, мәсәлән, беренче ике буыннан кала, исемнәр буталган, 27 исемнең 11-е урынына сорау билгеләре куелган...

Соңгы егерме-егерме биш ел эчендә туган халкыбыз, туган җиребез тарихына бәйле бик күп китап дөньяга килде һәм килә тора. Алар арасында төрлеләре бар: үткәндәге фактларны җентекләп сайлап алганнары да, тарихы кызыклырак, күңеллерәк, оптимистик рухта язылганнары да, йомшаграк аңлатмалар белән, юбилейга бәйле рәвештә гел мактап-мактанып язганнары да бар. Ничек кенә булмасын, бу китаплар халкыбызның тамырлары тирәнгә, ерак гасырларга киткән тарихын, рухи-әхлакый байлыкларын, үлмәс традицияләрен, үзенчәлекле гореф-гадәтләрен, көнкүрешен, омтылыш-хыялларын ныклап өйрәнү, кадерләп саклау теләген чагылдыра.

Бу дистәләгән-йөзләгән авыл тарихлары арасында минем туган авылым Бәзәкәгә багышланган китаплар да юк түгел. Беренче карлыгач - “Туган авылыбыз Бәзәкә кайда да безнең йөрәктә” исемле 120 битлек китапчык 2000 елда Алабуга шәһәрендә басылды. Аның авторы – авылдашым Сәлахетдин Фәрдетдин улы Тажиев, Алабуга педагогия институты доценты, педагогик фәннәр кандидаты. Шактый күп һәм төрле характердагы материал туплап, ул тарихи-публицистик очерклар җыентыгын авылдашларына тәкъдим итте. Китап бик вакытлы дөнья күрде. Авторның тәвәккәллеге һәм шундый авыр хезмәтне башкарып чыга алуы, һичшиксез, мактауга лаек (аның авырлыгын тарихка бәйле китап язып караган кеше генә аңлый аладыр).

2010 елда “Укытучым, кадерлем” исемле тагын бер китап белән таныштык. Бәзәкә урта мәктәбенең 80 еллык тарихына багышланган бу хезмәтнең авторы да Бәзәкә кызы – Рәмзия Гәрәй кызы Мөхетдинова-Гыймазетдинова. Бәзәкә мәктәбен тәмамлаган, үзе дә шул мәктәптә 35 ел рус һәм татар телләрен һәм әдәбиятларын укыткан (шул ук вакытта 25 елын

пионервожатый һәм тәрбия эшләрен оештыручы да булган) Рәмзия ханым мәктәп тарихын төрле яктан тасвирлаган. Әсәрдә шушы 80 ел эчендә шунда эшләгән укытучыларның күбесенә аерым очерклар багышланган. Мәктәптә аз вакыт кына эшләгән укытучыларның да, материал җитмәгән очракта, исем-фамилияләре генә булса да күрсәтелгән. Авторның үз мәктәбенә, аның укытучыларына булган тирән ихтирамы китапның һәрбер җөмләсеннән сизелә. Авылда укучы балаларны гына түгел, аларның ата-аналарын да мәгърифәткә тарту юлында армый-талмый эшләгән һәр укытучыга Рәмзия ханым җылы сүзен тапкан, мәктәпнең белем учагы гына түгел, авыл тормышының үзәге, рухи учагы булуын ассызыклаган. Китап Бәзәкә мәктәбенә, аның укытучыларына һәм укучыларына, гомумән авыл халкына гимн, мәдхия булып яңгырый.

Авылдашларым арасында авылыбыз тарихы белән кызыксыну арткан саен, туганнарым, якташларым, танышларым-дусларым да Бәзәкә тарихы белән шөгыльләнү вакытының миңа да җитүе, бу эшкә алынырга кирәклек хакында ярым шаяртып, ярым җитди рәвештә әйтә башладылар. Авыл шәҗәрәсен табып кайтарып биргәннән соң без Фәйзелхак абый Хөснетдинов белән тагын да якынлашып киткән идек. Мин авылга кайткан саен, я Фәйзелхак абый безгә килә, я мин аларга барам. Сүзебез күп, авыл хәлләре, шәҗәрәләр, тарих хакында сөйләшәбез. Ә 2003 елда атаклы Бубыйлар нәселе, Иж-Бубый авылы һәм аның мәдрәсәсе тарихына багышланган “Лишь тебе, народ, служенье!” исемле китабым басылып чыккач, бу сөйләшүләргә минем тарафтан язылган Бәзәкә тарихын күрү теләкләре дә кушылды. Бер көнне Фәйзелхак абый үзенә генә хас итагатьлелек белән: “Альта, ә Бәзәкә тарихын язу хакында уйламыйсызмы?” - дип, сүз башлап җибәрде. Мин бу фикергә үз мөнәсәбәтемне аңлаттым.

Мин һәрвакыт: “Китап язу – бик җаваплы эш, аны минем кебек тарих укытучысы башкарып чыга алмый”, - дигән фикердә тордым. Дөрес, минем бу эштә кечкенә генә тәҗрибәм дә бар: 1976 елда язып бетереп, нәшриятка тапшырган “Становление светского образования у татар” исемле күләме зур булмаган китабым 1982 елда дөнья күргән иде. Ләкин ул яртылаш кыскартылып басылды - бу факт минем фикеремне ныгытты гына. Һәм мин аерым мәкаләләр язу, конференцияләрдә катнашу кебек гамәлләр белән чикләнә килдем. Хәтта үзгәреш еллары башлангач та, гомер буе җыйган материалларым җитәрлек булса да, Бубыйларга багышланган китапны язарга, башкарып чыгуыма ышанып ук җитмичә, XXI гасыр башында гына җөрьәт итүемне дә Фәйзелхак абыйга аңлаттым. “Ә Бәзәкә тарихын язу хакында уйларга да базмыйм, чөнки теманы яхшы белгәндә генә һәм чыганаклар булганда гына мондый эшне башкарып була. Мин исә аңа әзер түгел”, - дидем.

Әлбәттә, моңа кадәр Бәзәкә тарихы белән мин бөтенләй кызыксынмадым дип әйтмәс идем. Кайда гына “казынсам” да – архивларны ул, китапханәләрме, мин, һичшиксез, Бәзәкә эзләрен дә табарга тырыша идем. Ләкин ул эзләр бик аз иде шул. Бәлки шуны белгәнгәдер, мин бу сөйләшүгә кадәр әлеге темадан “кача” килдем. 2007-2008 елларда миңа

конкрет тәкъдим дә булды. Чаллы эшмәкәре, авылдашым Мөнәвир Гыймазетдиновтан иде ул. Бәзәкәгә, авылдашларга, үз нәселенә багышлаган китап чыгарырга ниятләп, рус һәм татар телләрендә кулъязма хәзерләгәнен әйтте, шул кулъязманың редакторы булырга тәкъдим ясады ул миңа. Мин ул вакытта әле университетта укытам, аның өстенә “Милләт аналары” исемле китабымның кулъязмасын хәзерләргә дә керешкән идем. Шуңа күрә Мөнәвир әфәндегә, аның кулъязмалары һәм җыелган материаллары белән танышып чыкканнан соң, булачак эшнең күләменнән чыгып, җавабымны бирергә булдым.

Менә минем алда шактый саллы папка. Эчендә рус телендә язылган текст һәм төрле чыганаклар, язма материал, күп кенә фотографияләр иде. Текстның татарчадан русчага шактый тупас тәрҗемә булуы ачык күренә. Татарча текстын да карап чыгарга кирәк, чөнки русча текст кытыршырак чыккан дигән фикерне Мөнәвир әфәндегә хәбәр иттем. Ни сәбәпледер, ул текст миңа килеп җитмәде. Мин, булган материаллар белән танышканнан соң, үз фикеремне аңа белдердем: кулъязманы китап хәленә җиткерер өчен шактый күп хезмәт һәм зур вакыт сорала. Мин, бер-ике елдан соң гына, башланган эшемне тәмамлагач, бу эшкә керешә алачагымны әйттем. Мөнәвир әфәнде ул кадәр көтәргә вакыт булмавын (эшмәкәр кеше эшне тиз башкарырга өйрәнгән), китапны тизрәк чыгарырга теләвен әйтеп, икенче редактор эзләргә булды.

Ләкин берничә ел узды, китап чыкмады. Мине тагын “кысрыклый” башладылар. Һәм мин, ризалашып, максатчан рәвештә чыганакларны барларга, материал җыярга керештем. Казан, Уфа, Киров, Мәскәү архивларында Бәзәкәгә кагылышлы чыганакларны эзләсәм, китапханәләрдә һәм интернет челтәреннән дә гомуми характердагы материаллар тупладым, чөнки авыл тарихын халык тарихыннан, ил тарихыннан, дөнья тарихыннан аерып алып кына карап булмый. Бәзәкәләләр ул тарихны башкалар белән уртаклашкан. Илдәге, дөньядагы социаль тетрәнешләр Бәзәкә халкын да урап узмаган. Халыкның оешу һәм яшәү тарихларын, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен чагылдыра торган гомуми мәгълүмат авылны, авыл халкының яшәешен тасвирларга да ярдәм итә. Шуңа күрә, эш барышында төрле әдәбияттан файдаланырга, тарих, археология, этнология, тел белеме галимнәренең хезмәтләреннән Бәзәкә тарихын аңлау өчен кирәк булган шактый күп факт һәм аларның аңлатмаларын кулланырга туры килде.

* *
*

Китапның төзелеше хакында**.** Ул хронологик тәртиптә бирелгән аерым очерклардан тора. Һәрбер бүлек шигъри юллар белән башлана. Моның сәбәбе – мин күп сүз белән аңлатырга тырышып та, очына чыгып җитә алмаган фикерләрне шагыйрьләр кыска һәм матур гына итеп ачып салуларында дип уйлыйм. Бөек Габдулла Тукай, Хәсән Туфан, чордашларым Харрас Әюп, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, авылдашым Марсель Гыймазетдинов

һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләреннән алынган өзекләр һәр бүлеккә ачкыч ролен үтәде дисәм, ялгыш булмас.

Алабуга – Бондюг (Менделеевск) төбәгендә Бәзәкә иң борынгы авылларның берсе булуын мин сабый чагымнан ук үзләштергән идем. Ләкин ул борынгылык ничә гасырны тәшкил итә соң? Бу сорауга ачыклык кертеп булырмы? Бәзәкә хакында гына түгел, меңләгән татар авыллары хакында да борынгы чор мәгълүматлары риваять-бәетләрдә генә саклануы сәбәпле бу хакта сүз алып бару кирәкме? Бу һәм моның кебек башка сорауларга җавап эзләүне мин үземә беренче бурыч итеп билгеләдем. Икенче төркем сораулар (икенче бурыч) авыл тарихын кайсы чорга кадәр җиткерү хакында иде. Яза башлаганда ук, мин авыл тарихын Бөек Ватан сугышы чоры белән тәмамларга уйлаган идем, чөнки бүген булган вакыйга инде тарих дип саналырга хаклы булса да, ул әле елъязмага гына керә. Аны аңлау өчен вакыт кирәк. Бөек Ватан сугышы чорындагы авыл хәлен тасвирлауга җиткәч, аны үземнең балачак хатирәләремне дә кулланып язарга булдым. Чөнки алар минем шәхси истәлекләрем генә түгел, алар чорны, авылны тасвирлый. Шулай итеп, хатирәләрем мин шаһиты булган сугыштан соңгы чорны һәм XX гасырның икенче яртысына туры килгән илдәге һәм Бәзәкәдәге үзгәрешләрне сурәтләүгә дә китерде.

Әгәр дә китапны язган дәвердә ышанычлы таянычларым, киңәшче-ярдәмчеләрем һәм тәнкыйтьчеләрем булмаса, мин бу авыр хезмәтне төгәлли алыр идем микән? Беренче чиратта, ул минем “алтын баганаларым” – өлкән дустым, XX гасыр авыл хәлләре буенча төп консультантым Шәргыя Ибәтулла кызы Ибәтуллина һәм баш тәнкыйтьчем, сеңлем Әнисә Хаҗи кызы Мәхмүтова. Күрсәткән ярдәмнәре, ышаныч-сабырлыклары өчен мин аларга чиксез рәхмәтлемен. Шулай ук үзендә булган Бәзәкә хакындагы мәгълүматны минем белән эчкерсез бүлешкән Әгерҗе районы Тәбәрле егете Раиф Мәрданов һәм Кичкутан егете Илдар Нәфыйков алдында мин зур бурычлымын. Аларга олы рәхмәтләремне җиткерәм. Бәзәкәгә бәйле материалларны миңа даими рәвештә җиткереп торучы авылдашларым, интернетта “бизяки.рф” сайтын тотучы Рәшит Хаҗинур улы Кәлимуллинга, Фәрит Рәшит улы Бәшаровка, Гүзәл Габделхак кызы Габдуллинага, Рәис Фәрахетдин улы һәм Гөлшат Фәрахетдин кызы Хуҗахмәтовларга, шулай ук фотографияләр табарга ярдәм иткән башка күп кенә бәзәкәлеләргә бик зур рәхмәт. Үзләренең киңәшләре белән миңа һәрвакыт ярдәмгә әзер коллегаларым, тарихчылар Динә Мостафина, Эльмира Сәлахова, Илдус Заһидуллин, Дамир Исхаков, Айдар Ногманов, Радик Салиховка да рәхмәтләремне җиткерәм.

Риваятьләр ни сөйли?

Күпме генә озак яшәмәсен -
Юк, бер гомер бик аз кешегә,
Шуңадыр ул, бәлки, чордан чорга
Әкиятләр булып күченә.
Харрас Әюп

Минем туган җирем – Татарстан Республикасының төньяк-көнчыгышындагы Менделеевск районына кергән Бәзәкә авылы. Борын заманнарда бу төбәк Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Мәскәү кенәзлеге җирләренең бер өлеше булган. Казан ханлыгы җимерелеп, Рус дәүләте (Мәскәү патшалыгы) составына кереп киткән бу җирләр Казан Сарае идарәханәсе (Приказы) карамагында булып, Казан өязе (провинциясе) Җөри даругасы (Җөри юлы) төбәгендә исәпкә алынган. Аңлатып китим. *Даруга* – XIII-XVI гасырларда Монгол дәүләтендә, Җүчи олысында (Алтын Урдада), Казан һәм Себер ханлыкларында административ берәмлекне (өлкә, провинция) билгеләгән атама. Казан, Себер һәм башка җирләрне яулаганнан соң да XVI-XVIII гасырларда Рус дәүләте бу атаманы кулланган. Ләкин тора-бара “даруга” сүзе “дорога” формасын алган, ә берәмлек “Зюрейская дорога” дип йөртелә башлаган һәм шуңа нисбәтле татар теленә дә “Җөри юлы” буларак тәрҗемә ителә башлаган. XVIII гасыр ахырларында да Казан өязендә биш берәмлек – Алат, Арча, Гәреч, Җөри, Ногай даругалары, Уфа (Оренбург) өязендә дүрт шундый берәмлек (Казан, Ногай, Себер, Уса) булган. Бу берәмлекләрнең төгәл чикләре булмавын, алар юнәлешләрне генә билгеләгәнен дә, авылларның да төрле берәмлекләрдә күрсәтелү мөмкинлеген дә әйтергә кирәк. Мәсәлән, Бәзәкә авылы күп очракта Җөри даругасында, ә кайбер документларда Арча даругасында дип тә, Уфа өязе Казан даругасында дип тә күрсәтелгән.

Бәзәкә авылының кайчан, кайсы гасырда барлыкка килүе хакында төгәл мәгълүмат юк. Хәер, мондый төгәлсезлек күп кенә татар авылларына хас. Һәм бу факт үзе генә дә авылның берничә гасырлык тарихы булуы хакында сөйли. Төгәл мәгълүмати чыганаклар булмаганда, алар урынын төрле легенда-риваятьләр ала. Башка борынгы авыллардагы кебек, Бәзәкәдә дә авылның исеме һәм килеп чыгышы хакында күп кенә легенда-риваятьләр саклана. Авыздан-авызга, буыннан-буынга күчеп, бу риваять-хикәятләр безнең көннәргә дә килеп җиткән. Күп кенә хикәят-легендаларны С.Таҗиев үз хезмәтендә китергән. Мин дә сүземне үзем кечкенә чагында әби-бабайлардан ишеткән һәм гомергә күңелемә кереп калган берничә риваятьтән башлыйм.

Аның беренчесе авылның бу урында барлыкка килүе һәм исеме хакында. Кайчандыр, бик күптән, борын-борын заманда, безнең авыл урнашкан якларга бер төркем кеше килеп чыккан. Төркемнең башлыклары – Бәзәк, Сәйтәк һәм Тәкәш исемле батырлар булган. Аларны өч дус дип тә, өч бертуган дип тә сөйлиләр иде. Бик ерактан килгән, арган-талчыккан кешеләр урман-әрәмәлекләре, елга-күлләре һәм хәтфә үләнле киң болыннары булган

җирдә ял итәргә туктаганнар. Тирә-юнь белән танышкач, алар урман-әрәмәлекләрдә төрле җиләк-җимеш-чикләвек, җәнлекләр күп булуын, елга-күлләрнең кош-кортка һәм балыкка бай булуын күргәннәр. Чәчүлекләргә яраклы аланнар да булган монда. Һәм өч батыр, шушы җирдә туктап, яңа авылга нигез салырга булганнар. Тау астыннан бәреп чыккан искитмәле чиста, тешне сындырырлык салкын сулы чишмә янында төпләнеп калган алар. Бер ел үткәнме, ун елмы, батырлар яңа авылларга да урын сайлаганнар. Бәзәк үз исеме белән йөртелә башлаган авылда калган, Сәйтәк өч-дүрт чакрым көнбатышта булган, искиткеч тәмле сулы чишмә янында үз авылын, Тәкәш ике авылдан да бертигез ераклыкта төньяккарак таба булган шундый ук чишмә янында үз утарын булдырган. Шулай итеп Кама буе урманнары уртасында Кама елгасыннан җиде-ун чакрымдагы калкулыкта урнашкан өч авыл барлыкка килгән.

Икенче легенда, алдагысына кайбер өстәмәләр кертеп, яңа мәгълүмат җиткерә. Безнең бабаларыбыз бу җирләрдән бик ераклта, Идел (Волга) дип атала торган елга буенда, Болгар дәүләтендә, Бәзәкә исемле авылда тормыш көткәннәр икән. Ләкин дошман Бөек Болгар каласын да, аның тирәсендәге авылларны да җимергән-яндырган, малларын талап алган. Күп кеше һәлак булган, әсирлеккә төшкән. Бу якларда шушы фаҗигага ачлык, төрле афәтләр дә өстәлгән. Исән калганнары качып котылган, төрле якка таралышкан. Шундый бер төркем, безнең якларга килеп чыгып, иске исем белән яңа авылга нигез салган. Бу риваятьнең икенче вариантында Болгардагы Бәзәкә авылының Болгар бәкләренең биләмәсе булганлыгы һәм качып котылган төркем башында шул бәкләрнең берсе булуы хакында да сөйләнә иде.

Патша Иван IV исеме белән бәйле хикәятләр дә бар. Мәсәлән, шуларның берсендә сүз рус хөкүмәтенең татарларны христианлаштыруы хакында иде. Явыз Иванның отрядлары якынлашуын ишетеп, бәзәкәлеләр яз башында ук хатын-кыз, бала-чага, карт-корыларны, шулай ук мал-туарны да, авылдан төньякка, өч-дүрт чакрым ераклыкта кара урман эчендә булган күптармаклы чокыр-ерынтылар эченә яшергәннәр. Авылны сакларга, төрле хуҗалык эшләрен башкарырга калган ирләр дә, чукындыручылар Сәйтәккә килеп җитәр алдыннан, урманга качканнар. Шулай бәзәкәлеләр ислам динендә калган, ә сәйтәклеләр керәшен булып киткән дип сөйлиләр иде әбиләр. Бәзәкәлеләр качып калган җирләр бүген дә шушы вакыйгага бәйле рәвештә “Кызлар чокыры” дип атала (бары тик аның тирәсендәге урманнар гына юкка чыккан). Бу хакта бәет-мөнәҗәтләр дә әйтә иде әбиләр. Минем исемдә калган бәет-мөнәҗәтләрнең берсе “Алабуга бәете” иде. Безнең күрше Гайшә әби (Әхмәтҗанова) бик нечкә тавыш белән көйли торган бу бәетнең берничә юлын мин, Казан университеты профессоры М.Х.Бакировның “Татар фольклоры” исемле дәреслегеннән алып, монда укучыларга тәкъдим итәргә булдым:

“Алабуга ак шәһәр, тарихы озак яшәр,
Дошманга, яуга бирелмәс, юлына каршы төшәр.
Алабуга урыс кулына Сәүгән ханнан калгандыр,
Сәүгән ханның мажарасы тарихта язылгандыр.

Атлар җиктем яратып, Саралыга каратып,
Саралы, Сәйтәк чукынган, көфер утын таратып.
Туйгужа белән Аккужа сөрелделәр иленнән,
Сарай белән Сәйтәкбәк чыкты ислам диненнән”.

Әкиятләрдән дә кызыгырак тоелган бу бәет-риваятьләрне мин әбиләрдән кат-кат сөйләтә һәм һәрвакыт төрле сораулар бирә идем. Ләкин әбиләрнең җавабы бер – “мин сиңа үз әбиемнән ишеткәнне сөйләдем, шуннан артыгын белмим”. Әнинең җавабы: “Үскәч, сорауларыңа җавапны үзең эзләп табарсың”. Ниндирәк сораулар иде соң ул? Мине ул вакытта борчыган сорауларның исемдә калганнары: Бу хикәят-легендаларның кайсысы чынбарлыкка туры килә? Яки ул әбиләр уйлап чыгарган әкият кенәме? Кайсы заманда булган бу вакыйгалар? Борынгы әби-бабаларыбыз яшәгән авыл-калаларны нинди дошман җимергән? Һәм башкалар, һәм башкалар.

Чыннан да, бу риваятьләрнең чынбарлыкка туры килү-килмәвен ачыклау мөмкинме икән? Үсеп җиткәч түгел (ул чорның үз сораулары күп, борынгы тарих ераклта калган иде), инде картайгач, Бәзәкә тарихын барлауга тотынып, мин шушы сорауларга җавап эзләп карарга булдым. Эзләнү-уйлануларны бик борынгы чорлардан башлау дөрес булыр.

Борынгы заманнарда Кама буе җирләре катнаш урманнар белән капланган булган. Тирә-юньгә яктылык чәчеп торган каенлык-наратлыклар да, куе имәнлекләр дә, караңгы чыршы урманнары да булган бу якларда. Балан, гөлҗимеш, чикләвек, кыргый алма, карлыган куаклыклары каплаган тау битләре, әрәмәлекләр, хәтфә үләнле киң болыннар, балыкка бай елга-күлләре булган төбәк кешеләргә төпләнеп яшәр өчен уңай булган. Башта бу якларга күчмән кабиләләр килеп чыкканнар. Археологлар тикшерүләре күрсәткәнчә, безнең эрага кадәр икенче гасырда ук бу тирәләрдә Пьяный Бор культурасына, соңрак Ананьино культурасына караган кабиләләр урнашкан була. Исемнәр галимнәр тарафыннан Пьяный Бор (хәзер Әгерҗе районындагы Красный бор) һәм Ананьино (Алабуга районы) авыллары тирәсендә шул чорга караган беренче табылдыкларга бәйле рәвештә бирелгән.

Күчмән кабиләләр безнең төбәктә дүрт гасыр чамасы - безнең эраның икенче гасырына кадәр тормыш көткәннәр. Бу хакта археологларның күпсанлы табылдыклары сөйли. Бу культура табылдыклары Кама буенда Сарапул шәһәреннән Алабугага кадәрге төбәктә шактый еш очрый. Аларның иң билгелесе һәм иң зурысы Бәзәкәдән ерак түгел урнашкан кабилә башлыгы күмелгән Турай корганы. Бәзәкә тирәсе әлегә тикшерелмәгән. Шулай да, С.Тажиев язуынча, 1994 елда археологлар Бәзәкә тирәсендә ачып караган шурфларда шул чор табылдыкларына очраганнар (кеше сөякләре, балчыктан ясалган орнаментлы чүлмәк, савыт-саба ватыклары һ.б.).

Күчмән кабиләләр дигәч тә, күчмә тормышны теләсә ничек, теләсә кайда мәгънәсез күченеп йөрү дип күзалларга ярамый. Риваятьләрдә сакланган, хан ярлыкларында да беркетелгән мәгълүматлар буенча күчмәннәр башлыкларының махсус әмере буенча сулыклар тирәсенә

омтылганнар, шунда күченеп йөргәннәр. Күченү төгәл бер маршрут белән барган. Яңа җирләр дә (көтүлек, сулыклар) эзләп тапканнар, кайберләрендә озак яшәгәннәр, ә кайсы-берсен, бер-ике ел узгач та, ташлап киткәннәр. Күрше ыруг җирләренә керү тыелган, алар үз көтүлекләренә, үз җәйләүләренә ия булганнар.

Көн артыннан көн узган, кышны җәй алмаштырган, гасырлар узган. Шушы вакыт эчендә бер-берсен алыштырып торган күчмә кабиләләр арасында төркиләр дә, фин-угырлар да булган. Утрак тормышка күчү стадиясен кичерүче кайбер кабиләләр бу җирләргә төпләнеп калган, авылларга нигез салган. Авыл халкы исә игенчелекне җәелдереп җибәргән. Бу шөгыль исә ризык төрлелегенә нигез булган. Балыкчылык, аучылык алга киткән. Бу тирәләрдә озак вакытлар күчмә һәм утрак тормыш, бер-берсен тулыландырып, янәшә барган. Төрле сәбәпләр аркасында кайбер авыллар юкка чыккан, алар урынына яңа ыруглар, яңа кешеләр килеп урнашкан, яңа авыллар барлыкка килгән. Кама буйларын үзләштерү шулай барган...

Монсы безнең төбәкнең бик борынгы тарихы. Хәзер Бәзәкә авылының башлангыч чоры, аның иң әүвәл нигез салынып, яшәп киткән дәверенә күчик һәм мин алдарак сөйләп киткән риваятьләрнең тәңгәллеген барлау мәсьәләсенә кайтыйк. Беренче риваятьне, һичшиксез, чынбарлык белән тәңгәлләштерү мөмкин. Тарихта билгеле булганча, бик күп төрки-татар авыллары авылга нигез салучыларның исеме белән аталганнар. Ләкин мин кечкенә чагымда ук сөйләүчеләрне: “Нигә Сәйтәк белән Тәкәш авыллары нигез салучыларының исемнәрен үзгәртмичә саклаганнар, ә безнең авыл Бәзәк булып калмаган?” - дигән сорау белән аптырата идем. Хәер, мин хәзер дә бу сорауга риваятьне чыганак буларак кулланырлык җавап таба алмыйм.

Икенче риваять, минемчә, тыңлаучыны (укучыны) тулысынча ышандыра ала. Һәм татар тарихында моңа охшаш фактлар бик күп. Борынгы заманда Болгар дәүләтендә Бәзәкә исемле авыл булуы мөмкинме? Эзләнеп карыйк. Борынгы Болгар җирендә, бүгенге Татарстанның Алексеевск районында, Иделгә коя торган Актай елгасы буенда Базяково исемле рус авылы бар. Авыл исемен татарчага Бәзәкә дип тәрҗемә итеп буламы? Базяковоның тарихына күз салыйк.

Алтын Урда чорында ук бушап калган бу җирләрне XVI-XVII гасырларда рус патшалары үзенең яраннарына хезмәтләре өчен өләшкән. Рус алпавытлары исә Мәскәү тирәсендәге өязләрдә яшәгән үз крестьяннарын яңа урыннарга, Волга буйларына күчергәннәр. Шундый бер алпавыт үз крестьяннары белән Актай елгасы буенда бушап калган болгар авылы җирләренә урнашкан. Татар энциклопедиясе бу авыл хакында XVII гасыр урталарына нигез салынган дигән мәгълүмат биргән. Авыл ул чорда, күрәсең, Базяково исемен йөрткән. 1761 елда, авылда Тихвин Богородицасы чиркәве төзелгәч, ул Богородицкое исемен алган. Совет заманында, дин-чиркәүләр белән көрәш башланган чорда, авыл борынгы болгар чорыннан ук килгән, рус телендә Базяково дип янгыраган исеменә кайткан. Әлбәттә, Болгар дәүләтендә яшәгән авылның исеме русча түгел, ә төрки-болгар телендә - Бәзәкә - булган.

Бәзәкә-Базяково җирлегендә борынгыдан ук кешеләр яшәгәнлеген археологларның табылдыклары дәлилли. Татарстан Республикасының археологик картасында безнең эрага кадәр үк бу төбәктә яшәгән Имәнкискә кабиләләренә һәм Болгар – Алтын Урда чорына караган археологик истәлекләр - авыл-кальга урыннары, каберлекләр теркәлгән һәм бу карталарда Бәзәкә-Базяково исемендәге авыл булуы да күрсәтелгән. Ә менә Казан ханлыгы чорына караган картада бу җирләр бушап калганлыгы күренә. Бәзәкә авылы да күрсәтелмәгән. Минем фикеремчә, бу карталарга нигезләнеп, без икенче риваятьнең дөреслеккә туры килүен дә, безнең авылга кайчан нигез салынуын да фаразлый алабыз.

Вакыйгаларны болай тасвирларга була.

Идел Болгарстанының йөзләгән авыл-шәһәрләре арасында Бәзәкә исемле авыл да булган. Башка болгар авылларында яшәүчеләр кебек, бәзәкәлеләр дә икмәк үстергән, терлек асраган, киек кошлар, җәнлек аулау, балык тоту белән шөгыльләнгән. Уңдырышлы туфрак, куе һәм сусыл үләнле көтүлекләр, бай урманнар, мул сулы елгалар әлеге эшләр өчен уңай шартлар тудырган. 1236 елгы монгол явыннан исән калган җирләрдә тормыш яңадан тернәкләнеп киткән. Ләкин ундүртенче гасыр азакларында бу җирләргә яңа афәт килгән. 1395 елны Аксак Тимер гаскәрләре Болгар, Сарай, Әстерхан кебек шәһәрләрне һәм алар тирәләрендәге авылларны талаган-җимергән. Күп халык үтерелгән яки коллыкка алып кителгән.

Моның өстенә 1395 елның азагында берничә елга сузылган коточкыч кытлык чоры башланган. Меңләгән кеше гомерен өзгән куркыныч авырулар таралган. 1405 елда гына бераз басыла төшкән чума чире аеруча куркыныч булган. Моннан соң да әле ул берничә тапкыр кабатланган. Котылу чарасын эзләп күпләр илдән киткән. Алар арасында бөтен бер кабиләләр дә, аерым олысларда яшәүчеләр дә булган. Бу вакытта Болгар шәһәре үзенең элеккеге көчен һәм Болгар җирләре үзәге ролен бөтенләй югалткан. Ызгыш-талашлар, Урда һәм рус кенәзләре һөҗүмнәре болгарлар хуҗалыгын тәмам җимергән. Шәһәрләр хәрабә хәленә килгән. Авыллар юкка чыккан. Болгарларның исән калганнары төньякка таба күченергә мәҗбүр булган. Алар Мишә, Казансу, Нократ елгалары буендагы җирләрне үзләштергән. Халыкны Кама-Чулман аръягының тыныч җирләре дә җәлеп иткән. Монда XIV гасыр азагы — XV гасыр башларында дистәләгән авыллар барлыкка килгән.

Туган җирләрен ташлап китүчеләр арасында бәзәкәлеләр булуын да фаразлый алабыз. Аларның бер өлеше, риваятьтә сөйләнгәнчә, тынычрак тормыш эзләп, Кама буйларына килеп чыгарга һәм яңа урында иске исем белән яңа авылга нигез салырга мөмкин. Әгәр бу шулай булса, *Бәзәкә авылына хәзерге урында* ***XV гасырның беренче яртысында*** *нигез салынган* дияргә мөмкинлек бар. Кызганыч, ләкин без бу фаразыбызны бернинди документ белән дә раслый алмыйбыз, чөнки ул чордан бернинди язмалар да, кабер ташлары да калмаган. Бәлки киләчәктә археологик эзләнүләр бу фикерне раслый алыр. Авылның башлап урнашу чорына караган документаль чыганаклар булмаса да, халык хәтерендә сакланган

риваятьләргә нигезләнгән шушы фаразны әлегә кабул итеп алыйк. Чөнки бу риваятьләрнең эчтәлегендә әкияти, башка сыймаслык ниндидер могҗизалар, хакыйкатькә туры килмәстәй вакыйгалар хакында сөйләнми.

Тарих сәхифәләрен ачканда

Чын тарих калкып чыга ул
Чистарып чор көленнән,
Яшермәскә генә кирәк
Тарихны бер-береңнән.
Роберт Миңнуллин

Бәзәкә исеме искә алынган иң борынгы документлар элеккеге Мәскәү дәүләтендә Казан ханлыгы җирләре белән идарә итү өчен барлыкка килгән *Казан сарай Приказы (идарәханәсе*) материаллары арасында саклана. Беренче чиратта бу *Писцовый кенәгәләр.* Рус җирләрендә XV-XVII гасырларда халык санын, йорт-җир биләмәләрен теркәгән бу язмалар, Мәскәү билгеләгән *писец*лар (күчереп яки әйткәнне язучылар) тарафыннан урыннарда башкарылып, төрле салымнар билгеләү өчен кулланылган. Рәсми документларда авылның исеме төрле язылышта - *Безяка, Бозак, Безяково, Безяки, Бизяки* формасында, инеш исеме *Безяка, Бозак, Безяковка, Безякинка* дип бирелгән.

Минем карамакта булган иң борынгы документлар XVII гасырга - 1642, 1650, 1670, 1680, 1692, 1697 h.б. елларга - караган. Бу язмаларда авыл-инеш исеменнән башка авыл тирәсендәге хәзер дә кулланышта булган елга-күлләр, ерынты-чокырлар, юл-болыннар исемнәрен дә очратырга мөмкин. Аларның исемнәре рус язылышында шактый үзгәртеп бирелгән. Моның сәбәбе – татар телен белгән чиновникларның аз булуы, телдән әйтелгән исемнәрнең начар аңлашылуы дип уйлап була. XVI-XVIII гасырга караган документларның азлыгын да искәртим. Беренчедән, бу чорда хөкүмәт идарәчелеге әле яңа кушылган төбәкләрнең барысын колачлап ала алмаган. Икенчедән, алар теркәлгән җыентыкларның төрле сәбәпләр аркасында юкка чыгуын да әйтергә кирәк. Мәсәлән, XVII гасыр башында Мәскәүдә зур пожар булып, күп кенә писцовый кенәгәләрнең көлгә әйләнүе билгеле.

Бу документлардан файдаланып, авыл тарихын барлауга керешкәнче, аларда кулланылган кайбер атамаларга аңлатма биреп үтәм. Казан ханлыгыннан күчеп, Рус дәүләтендә кулланышта булган административ берәмлек атамасы *даруга* хакында аңлатма бирелгән иде инде. Даруга төрле сандагы авыллар тупланган *йөзлек*ләргә бүленгән. *Йөзбашы*на (сотник, сотский) *авыл башлыклары* (староста) hәм *унлык башлыклары* (десятский, десятник) ярдәм иткән. Шул ук чордан рус теленә кереп киткән тагын бер атама - *ясак* — дәүләт файдасына түләнә торган салым. Бу салымны түләүче Идел-Урал буйларында hәм Себердә яшәгән халыклар *ясаклылар* дип аталган. Ясак, гадәттә, әйберләтә – ашлык, затлы балык, бал, затлы тире белән, кайчакта акчалата түләнгән. XVII – гасырда бер ясакны түләүдә 2-4 хуҗалык катнашкан. Ашлыклата түләгәндә бер ясакка уртача тугыз пот

арыш яки солы туры килгән. Аның өстенә ям тотуга (почта йөртүгә), юл йөрүгә, урманнан файдаланган өчен һәм башка төрле акчалата түләүләр дә булган.

Ясаклы татарлардан башка, чыганакларда “*служилые татары*” - *йомышлы татарлар* дигән атама да кулланыла. Бу термин белән XIV-XVIII гасырларда Рус дәүләте хезмәтендә булган катлау аталган. Алар тылмач, илчелек вазыйфаларын башкарганнар, Рус дәүләте алып барган сугышларда, чик буен саклауда катнашканнар. Бу хезмәтләре өчен патшалар аларга җир биләмәләре бүлеп биргән, ашлык белән яки акчалата хезмәт хакы түләгән. Җир биләмәләре өчен ике төрле термин кулланылган - *вотчина* һәм *поместье.* Беренчесе ата-бабалардан бернинди шартсыз варисларга күчүче биләмә булса, икенчесе патша тарафыннан хезмәт өчен һәм шул вакытка гына бирелгән биләмә булган.

Тагын бер искәрмә. 1700 елга кадәр Рус дәүләтендә ел исәбе “дөнья барлыкка килгән” заманнан алып барылган. Шуңа күрә борынгы документларда без *«лета 7151»* яки *«151 год»* кебек даталар очратабыз. Аларны хәзерге ел исәбенә күчерер өчен күрсәтелгән саннан 5508 санын алырга кирәк (христиан тәгълиматы буенча, Иисус Христос дөньяга килгән ел). Мәсәлән, 7158-5508=1650. Рус дәүләтендә яңа ел 1 сентябрьдән башланган. Шуңа күрә, ае күрсәтелмәгәндә, датаны төгәлрәк билгеләр өчен чиктәш ике ел бергә дә бирелергә мөмкин (1649/50 яки 1650/51 формасында). Документларда кеше исемнәренең кечерәйтелеп-кимсетеп бирелүен дә әйтергә кирәк — Федька Федоров, Агилдейко Тямов h.б.. Татар исемнәре еш кына асылын аңламаслык итеп үзгәртелүен дә онытмыйк.

Документларның күбесе XVI-XVIII йөзләрдән үк архив киштәләрендә безнең көннәргә кадәр хәрәкәтсез сакланган чыганаклар гына түгел. Патшалар һәм рәсми оешмалардан алган документларны безнең бабаларыбыз да, буыннан буынга тапшырып, кадерләп, гасырлар буена саклаган. Кирәге чыкканда, хакимият әгъзаларына күрсәтә-күрсәтә, яки күчермәләрен ясатып-тапшырып, бабаларыбыз бу документлардагы бәһасыз мәгълүматның безнең көннәргә килеп җитүенә сәбәпче булганнар. Шуңа күрә бу документлар еш кына очраклы рәвештә табыла. Безнең авылга – Бәзәкәгә караган чыганакларның да язмышы шундый булган. Мондый фактларга мин беренче тапкыр Россия дәүләтенең борынгы актлар архивында (РГАДА - Мәскәү), соңрак Татарстан республикасының милли архивында (ТР МА - Казан) тап булдым.

Авылыбызның тарихын ачыклаучы бу кыйммәтле мәгълүматларны табу маҗараларына да бераз күз салыйк. Маҗара дип билгеләвем бер дә очраклы түгел. РГАДАда саклана торган материаллар минем кулыма бөтенләй көтмәгәндә (хәтта уйламаганда да) килеп керде (Юкка гына әйтмиләр бит - “бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына”).

Ераклта калган 1973 ел. Мин Мәскәү университетында, дүрт айлык квалификацияне күтәрү курсларында укып йөрим. Шул чагында безнең өчен РГАДАда гамәли дәресләр дә уздырдылар. Ул вакытта “үземә борынгы документлар кирәк булыр” дигән кебек уйлар башыма да керми иде әле,

чөнки мине XIX — XX гасырлардагы Россия тарихы һәм татар мәктәпләре тарихы кызыксындыра. Һәм мин ул материалларны бу архивта эзләмим дә. Ә монда – борынгы актлар, аның өстенә борынгы рус кулъязмаларын укуы да бик авыр. Ә гамәли дәрестә ниндидер бирем эшләргә кирәк. Шуңа күрә ялкау гына фондларның исемлекләрен актарып утырам (нәрсәдер сайлап алырга кирәк). Кинәт күзем бер папканың исемен эләктереп алды - *«Спорное дело об отводе земель вокруг города Елабуги»,* ягъни “Алабуга шәһәре тирәсендәге җирләрне бүлеп бирү хакында бәхәсле эш” (РГАДА, ф. 1306, оп. 2, д.127). Әлбәттә, бу исем минем табигый кызыксынуымны уятты – Алабуга – туган яктагы кала, анда минем әби-бабайлар яшәде, мин үзем дә 4 ел педучилищеда укыдым. Папкадагы материаллар белән якыннан танышкач, гаҗәпләнүем тагын да көчәйде – монда безнең Бәзәкәбез хакында да материал бар икән ич! Андагы Бәзәкә җирләренә кагылышлы иң борынгы документлар XVII гасырга караган, ә папка үзе XIX гасырда, җирләрне ызанлау барганда һәм алар өчен бәхәсләшкәндә барлыкка килгән икән.

Шушы материалларны, укуы һәм аңлавы авыр булса да, күчереп алып, “Моя родная деревня в древних документах” исемле контроль эшемдә анализладым. Аның белән авылда әтиләрне, кайбер укытучыларны да таныштырдым. Алар өчен дә бу бик кызыклы булды, чөнки безнең барыбызга да таныш исемнәрне борынгы документларда күрү гаҗәеп күренеш иде. Ул вакыт ниндидер китап язу кайгысы башыма да кермәгән чор. Хәер, ул чагында шәҗәрәләр белән мавыгу да юк, ә инде үз туган ягың, туган авылың тарихын язу мөмкинлеге төшкә дә керми иде. Чөнки хәтта без, тарих белән профессиональ рәвештә шөгыльләнүчеләр дә, тарих фәне кечкенә авылларның, гади кешеләрнең үткәнен түгел, ә дәүләтләр, патшалар, даһи кешеләр тормышын өйрәнә торган фән дип уйларга күнеккән идек.

Шулай да, инде олыгаеп, архивлардан Бәзәкә тарихына караган материаллар җыя башлагач, үземнең шушы онытыла язган язмаларымны архивымнан эзләп таптым. Кызганыч, язып алган материалларым бик күп түгел иде. Төрле сәбәпләр аркасында Мәскәү архивына мин яңадан бара алмадым. Шулай да, булган материалларны кулланып, китапны яза башларга, шул ук вакытта үзебезнең архивны, җае чыкканда, башка архивлардагы фондларны өйрәнергә булдым. Һәм менә яңа табыш! Казанда яшәүче үзешчән тарихчы Руслан Шакиров Бәзәкә җирләре телгә алынган тагын бер папканың Казанда, Милли архивта булуын әйтте. Алабуга өяз суды фондында сакланучы бу папка “Алабуга һәм Сарапул өязе башкорт һәм типтәрләрнең җирбиләүчелек хокуклары хакындагы эш” исемен йөртә иде.

Һәм менә бу папка минем кулымда. 184 биттән гыйбарәт папкада төрле документлар җыелмасының җентекләп эшләнгән тасвирламасы бирелгән. Бу документлар Алабуга һәм Сарапул өязләрендә дәүләт тарафыннан уздырылган җир биләмәләренең чикләрен билгеләгән заманда туган дәгъвалашуга бәйле рәвештә 1804-1865 елларда җыелган булып чыкты. Ягъни бу материаллар алда сөйләнгән Мәскәү архивындагы материалларның күчермәсе яисә тасвирамасы дип әйтергә була. Мөгаен, документларны Мәскәүгә җибәрер алдыннан чиновниклар төгәл күчермәләрен алган яисә

җентекле тасвирламалар ясагандыр. Шулай итеп, “күктән эзләгән җирдә табылды”. Шушы ике чыганаклар җыентыгы авылыбыз тарихының борынгы чорын тасвирларга һәм аңлатырга нигез булды.

Табылган документларда Бәзәкә атамасы белән бәйле иң борынгы еллар патша Петр Беренченең 1697 елның октябрь аенда Уфа воеводасы стольник Василий Федорович Леонтьев һәм подъячий Федор Юрьевка җибәргән грамотасында (хатында) очрый.

Хатның эчтәлеге. Уфа өязе Казан юлы Ирмин волосте башкортлары Агилдейко Тямов белән Еманко Юскеев бөек падишаһка үзләренең зур үтенечләрен җиткергәннәр: аларның Кама елгасының аръягында Бәзәкә инеше буенда урнашкан һәм буыннан-буынга күчеп килгән биләмәләре бар икән. Ул биләмәләр аларга борынгы бабалары Тогайко Беляков заманыннан ук калганлыгы дә әйтелгән. Шулай ук 151 (1643) елда Ахбулатко Ихтеевка бирелгән грамота буенча Бәзәкә инешенең тамагы һәм Шаранбур белән Казанбур исемле күлләрдәге балык тоту урыннары да аларныкы саналган. Ләкин биләмәләрнең аларныкы булуын раслаучы борынгы документ (“старинная крепость”) һәм балык тотарга рөхсәт итүче таныклык та 159 (1651) елда янып көлгә әйләнгән. Шулай булса да, бу борынгы документ заманында “Уфа приказы ызбасы” исеме йөрткән административ оешмада теркәлгән булган икән. Шушы язмага нигезләнеп, 200 (1692) елда бәзәкәлеләргә аларның хокукларын раслаган һәм Уфа шәһәре мөһере сугылган белешмә бирелгән. Ләкин бу хокукларын ныгыту һәм Бәзәкә биләмәләрен үзләренеке итеп рәсми таныту өчен алар бөек падишаһтан грамота (яклагыш яки саклау грамотасы) бирүен үтенгәннәр. Петр I воеводага мәсьәләне үтенүчеләр файдасына чишәргә, аларга биләмәләре белән элеккечә файдаланырга рөхсәт бирә торган саклау грамотасы бирергә боерган. Салымнарның (оброк һәм ясакны) тулысынча Уфада түләнергә тиешлеген дә билгеләгән, башка воеводалар һәм приказ кешеләре (чиновниклар) сораганда күрсәтер өчен бу хатның күчермәсен дә үтенүчеләргә бирергә кушкан (Кушымта № 4).

Документта күрсәтелгән еллар (7151 = 1643; 159 /7159/ = 1651; 200 /7200/ = 1692; 7205 = 1697) барысы да XVII йөзгә караган. Анда Бәзәкә инеше тирәсендәге җирләр хакында гына сүз булып, “авыл” сүзе кулланылмаса да, авылның инде күптән төпләнгәнлеген башка чыганаклар күрсәтә. Аларга без соңрак мөрәҗәгать итәрбез. Патша грамотасы да Бәзәкәнең борынгы авыл булуын ачык аңлата кебек. Мондый мөмкинлекне безгә документтагы «*старинная вотчина*», «*старинная де их крепость на тое их вотчину*» кебек гыйбарәләр бирә. Бу гыйбарәләрдән Тогай Беляковка бирелгән биләмәнең бик борынгы булуы күренеп тора: ул грамотаның кайчан бирелгәнлеге дә онытылган, билгеле түгел. Ә менә Акбулат Ихтеевка балык тоту җирләрен билгеләгән документның елы, ярты гасыр чамасы вакыт үтсә дә, ачык күрсәтелгән – 1643 ел. Димәк, бу грамоталар, иң кимендә, авыл XVI-XVII гасырлар кисешендә яшәгән, ә аның нигезе бәлки аннан да иртәрәк салынгандыр дигән фаразга өстәмә дәлил бирә.

Т.Беляковка бирелгән борынгы грамотаның алынган вакытын төгәлрәк

билгеләп булмасмы? Бәлки башка документлар ачыклык кертер? Мин архивлардан күчереп алган документларны кат-кат укыйм һәм моңа кадәр игътибар итмәгән датага юлыгам: Вятка межалаштыру конторасына Бәзәкә авылы кешеләреннән җыелган документлар тасвирламасында беренче булып Оренбург гражданнар палатасында теркәлгән “7025 елгы грамота» аталган. 7025 ел - ул **1517 ел** дигән сүз. Бу исеме язылмаган грамотадан соң сүз алып бара торган патша Петр Алексеевичның Уфага, воевода Леонтьевка җибәргән грамотасы (ягъни Т.Беляковка бирелгән яклагыш грамотасындагы җирләрне бәзәкәлеләргә ныгыткан документ) кертелгән. Уйлап карасак, без бу елы гына күрсәтелгән грамотаны 1651 елгы янгында юкка чыккан Т.Беляковка бирелгән яклагыш грамотасы булуы мөмкин дигән нәтиҗә ясый алабыз.

Ләкин бу фикер яңа сораулар гына тудыра. 1517 ел Казан тәхетендә Мөхәммәтәмин хан, Мәскәүдә - кенәз Василий III утырган чорга туры килә. Петр I хатында “старинная крепость” дип күрсәтелгән яклагыш грамотасы Тогай Беляковка кем тарафыннан бирелгән булырга мөмкин? Уйлана, тарихи фактлар белән чагыштыра торгач, мин кенәз Василий III варианты чынбарлыкка якынрак торадыр дигән фикергә килдем. Аңлатып китәм. Казан ханлыгының көнчыгыштагы чикләре Нократ (Вятка) һәм Агыйдел елгалары белән билгеләнә. Төбәк тарихчылары фикеренчә, XIII - XV гасырларда Казан ханлыгы белән чиктәш бу җирләр Новгородтан чыккан сәүдәгәрләр нигезләгән Вятка буендагы Хлынов республикасы карамагында булган.

XV гасырның соңгы чирегендә Мәскәү дәүләте бу җирләрдә актив сәясәт алып бара башлаган. 1489 елда кенәз Иван III сәүдә шәһәре Хлыновны (хәзерге Киров шәһәрен) үз дәүләтенә кушкан. Мәскәүгә алып киткән аксөякләр арасында “Ар (Вятка) кенәзләре (яисә ар бәкләре)” исемен йөрткән татарлар да булган (М.Госманов фикеренчә, бу бәкләр, арлар яшәгән җирләргә ия булганга күрә, кайвакытта рәсми кәгазьләрдә ар кенәзләре (бәкләре) дип йөртелгәннәр). Рус аксөякләренә Нократ буйларына кире кайтырга насыйп булмаган. Ә менә татарларны, Мәскәүгә тугрылыклы булырга “ант эчкәннән” соң, “үз җирләренә” җибәргәннәр. Өстәвенә Мәскәү кенәзе Иван III Нократ елгасының уң як кушымтасы Чыпца (Чүпчә) бассейнында урнашкан җирләр алар карамагында булуын раслаган. Фәрман-килешүдә ар бәкләре биләмәләренең чикләренең “киңлеге 150 чакрым, озынлыгы – Кама буйлап” дип билгеләнгән.

Шулай хәзерге Татарстанның төньяк-көнчыгыш җирләре XV гасыр азагында ар бәкләре кул астына кергән һәм Мәскәү Казанны яулап алганга кадәр үк Мәскәү дәүләте йогынтысына эләккән булып чыга. XVI гасырга караган Мәскәү кенәзләре грамоталарында бу җирләр рәсми рәвештә «Каринский стан или волость» дип язылган, ә җирле халык аны «Нократ йире» дип атаган. Төбәкнең үзәге Нократ-Карино ныгытмасы булган. Ар бәкләренең йомышлылары саналган бу төбәктә яшәгән татарлар XVI гасыр башыннан Нократ һәм Иж елгалары аралыгындагы җирләрне үз биләмәләре итеп рәсми рәвештә ныгыта башлаганнар. Нократ татарларының 1505, 1509,

1511 h.б. елларда Мәскәү кенәзләре Иван III һәм Василий III фәрманы белән үз җирләренә яклагыш грамоталары алулары тарихчылар Д.Исхаков һәм башкалар тарафыннан танылган факт. Шулай итеп, Вятка-Иж бассейнындагы җирләрнең күп өлеше XVI гасыр башыннан “вотчина хокукына”, ягъни мирас булып күчү хокукына ия булган. Шушы фактлардан чыгып, 1517 елда шундый грамота Т.Беляковка да бирелгән булгандыр дип фаразларга мөмкин.

Тажимулла абзый Шакиров, авыл шәҗәрәләрен барлаганда, бер биткә “Таһир баба 1545 елда вафат” дип язып куйган. Мин бу язма хакында бик күп уйландым. Фәйзелхак абый, Хәй абыйлар белән дә киңәшләшкән идек. Ни өчен XVIII-XX гасырларда яшәгән халыкның исемнәрен барлаганда, XVI гасырда вафат булган кешенең исеме һәм үлгән елы язылган? XX гасыр урталарында яшәгән картларның да хәтерендә сакланырлык нинди эшләр эшләгән, нинди хезмәтләр башкарган Таһир баба? Бу сорауларга без ул вакытта җавап таба алмаган идек. Менә хәзер бу сорауга җавап табылды кебек. Әгәр дә без русча язмаларда татар-төрки исемнәренең еш кына таный алмаслык дәрәҗәдә үзгәрүен исәпкә алсак, “Таһир”ның “Тогайга” әйләнеп кую мөмкинлеген фаразларга була. Икенче аңлатма – рус телендәге документта “Тогай” дип язылган исемнең бәзәкәлеләргә таныш “Таһир” исеме булып китүе дә бик мөмкин түгелме соң? Шулай булганда, Таһир баба Бәзәкә халкын җирле иткән шәхес булып чыга. Әлбәттә, аның исеме халык хәтерендә гасырлар буена сакланган. Ә Тажимулла абзый аны безгә дә җиткерер өчен шәҗәрә кырыена язып куйган.

Т.Беляковның нинди катламнан булуын да якынча гына билгеләргә мөмкин, чөнки грамота 1651 елда янып юкка чыккан. Әгәр дә без Бәзәкә авылын XIV гасырның беренче яртысында Болгардан күчеп килгән кешеләр нигезләгән дигән фараздан чыгып фикер йөртсәк, ярлыкаш грамотасының иясе Болгардан чыккан бәкләрнең дәвамчысы булуы мөмкин. Тогай (Таһир?) Беляковның нократ татары булуы да мөмкин. Шунысы шиксез: биләмәнең хуҗасы затлы, белемле, абруйлы шәхес булырга тиеш (ул чакта урман эчендә яшәгән гади авыл кешесе ярлыкаш грамотасын сорау түгел, аның нәрсә икәнен дә белмәгәндер әле). Бәзәкә авылына да ул нигез салгандыр дигән фикергә дә килә алабыз. Ләкин, шулай булганда да, Бәзәкә авылы 1517 елга кадәр үк нигезләнгән дип раслап була, чөнки бу җирләргә хуҗа булу һәм биләмәнең чикләрен билгеләү өчен, һич кимендә, аларны белү кирәк. Ничек кенә булмасын, нәкъ менә 1517 елдан Бәзәкә халкы үз җирләренә ия булган. Тарих фәнендә кабул ителгән кануннар буенча, борынгы авыл-шәһәрләрнең барлыкка килгән вакыты төгәл билгеле булмаган очракларда документларда күрсәтелгән иң борынгы датадан аларның тарихын башлау мөмкин (мәсәлән, Мәскәү шәһәре үзенең тарихын нәкъ шулай елъязмаларда бирелгән 1147 елдан билгели). Димәк, без дә Бәзәкә тарихын документларда очраган иң борынгы дата – **1517 елдан** - башлый алабыз.

Петр I-нең 1697 елгы фәрманына әйләнеп кайтыйк, чөнки нәкъ шушы фәрман XVIII гасыр башыннан бәзәкәлеләрнең җир хокукларын билгели торган иң мөһим рәсми документ булып саналган. Ә без аны әле тикшереп

бетермәдек. Биләмәнең чикләре бу рәсми кәгазьдә шактый төгәл күрсәтелгән. Бәзәкә исемен йөрткән инешнең ике ягында да урнашкан җирләрнең көньяк чиге Кама елгасы буйлап билгеләнгән. Аның түбәнге ноктасы “Долгая гора”, югарысы “Был Караул” тавы дип язылган. Көнчыгышта Бәзәкәдән 4-5 чакрым ераклыкта булган калкулык чыннан да каравыл куярлык урын булган. Ул чорда, бигрәк тә, ушкуйниклардан – елга юлбасарларыннан - саклану чарасы буларак, очланып Кама елгасына кереп торган борыннан елгадагы хәлләрне күзәтергә бик уңай булган. Моннан Кама буйлары ике якка да яхшы күренә. Нәкъ шушы урында XVII гасырда Ык Тамагы (Икское Устье) авылына нигез салынган. Ә бу урыннан якынча 20 чакрым ераклыктагы Озын Тауда шул ук чорда Тихие Горы исемле авыл һәм соңрак пристань барлыкка килгән.

Күрүебезчә, Бәзәкә биләмәсенең көньяк чиге Кама буйлап төгәл билгеләнгән. Башка чикләрдә исә мондый төгәллек күренми. Биләмәнең башка чикләре “Бәзәкә инешенең башыннан тамагына кадәр булган ике ягындагы җирләр” дип кенә бирелгән. Ул вакытта бу җирләр катнаш урманнар белән капланган булган, ә Бәзәкә инеше Кама үзәнендәге күпсанлы күлләрнең берсенә койган. Күлләрнең берсенә дип әйтүемнең сәбәбе – мин үскәндә, безнең авыл белән Сәйтәк авылы каршындагы урында Иске Бәзәкә буе, Иске Бәзәкә тамагы дигән җирләр бар иде. Димәк, кайчандыр инеш авылдан уңгарак борылган булган. XVII гасыр документларында исә инешнең Бәзәкә һәм Ык Тамагы авыллары каршындагы әрәмәдәге Зирәкле күлгә коюы әйтелгән. Хәер, бу җирләр барысы да Түбән Кама сусаклагычы астында калды.

Темабызны дәвам итик. Димәк, Т.Беляковка бирелгән җирләрнең үзәгендә Бәзәкә инеше тирәлегендәге җирләр булган. Бәзәкә инешенең төньяктан көньякка 15-20 чакрымга сузылганлыгын исәпкә алыйк. Башка чыганаклардан да файдаланып, Бәзәкә биләмәсе көнчыгыштан Турай авылы биләмәсе (алар да XVII гасырда яклагыш грамотасы алганнар), ә көнбатышта Игра исемле ар авылы җирләре белән чиктәш булган дигән фикергә киләбез. Шулай булганда, биләмәнең күләме якынча 350-400 квадрат чакрым тәшкил итәргә тиеш. Ләкин бу якынча сан. Хәзергә шуны искәртим: Бәзәкә биләмәсе чикләренең төгәл күрсәтелмәгән булуы патша администрациясенә киләчәктә бәзәкәләләрнең җирбиләүчелек хокукларын кысрыкларга мөмкинлек биргән. Шуны да әйтергә була: 1642/43 елда Акбулат Ихтеевка балык тотар өчен бирелгән Бәзәкә тамагы һәм Шаранбур белән Казанбур исемле күлләр, күрәсең, Бәзәкә биләмәсенә кермәгән булгандыр. Шундый ук төр яклагыш грамоталары 1642 елда Исәнгол Сарыбаевка, 1696 елда Аднагол Урусовка да бирелгән булган.

Тагын ике документка мөрәҗәгать итик (Кушымта № 1, 3).

Казан сарае идарәханәсенең икмәк кенәгәсеннән алынган күчермәләрдә сүз Түләкәй иллелегендәге “Азаева пустошь” - ниндидер сәбәпләр аркасында файдаланудан чыккан, бушап калган Азай җирләре хакында бара. 7158 (1650) елда язылган беренче күчермәдә Сәйтәк инешенең ике ягындагы бу бушап калган җирдә яңа күчкән Федька Федоров урнашуы һәм аның ярты

ясак түләргә тиешлеге хакында сөйләнә. Ф.Федоровка бу бушлыктагы сөрүле җирләр бирелмәгән, аңа Казандыш (Кәзәнгеш) исемле инеш буендагы печән чабулыкларыннан файдаланырга, шуның өчен ярты ясак түләргә кушылган. Икенче документ - 200 (1692) елда Җөри юлы Сәйтәк авылында яшәүче Ф.Федоровның оныгы “яңа керәшен” Титико Дементьевның патшадан бабасы биләгән җирләрне сорап үтенүе хакында сөйли. Бу документларда Бәзәкә авылы телгә алынган, алар авыл биләмәсенең чикләрен ачыкларга да ярдәм итә.

Азай бушлыгының чикләрен билгеләгәндә, өске чиге *удмурт авылы* Игранның (хәзер – Иске Игра) сөрүле җирләре белән тоташканы күрсәтелә. Ә көнчыгышта аның чикләре я Сәйтәк чокырына, яки Бәзәкәдән өч чакрымда булган Тарлау чокырына килеп җиткән булырга тиеш. Тарлау – татар телендә урман яки болын уртасындагы сөрүлекнең атамасы; икенче мәгънәсе – басу уртасындагы сөрелми калган сазлык яки вак агачлар белән капланган урын. Тажимулла абзый Шакиров сүзләре буенча, Бәзәкәнең иң борынгы басулары нәкъ шушы җирләрдә булган. Бу документларда очраган атамалар - Ирык Илга (Ерык Елга), Казандыш (Кәзәнгеш), Каинлы Зилень (Каенлы Җилән) — хәзер Түбәнкама сусаклагычы сулары астында калган җирләрнең исемнәре.

Әле мин үскәндә дә, бу атамалар киң кулланышта иде. Әрәмәгә, Идел буйларына гөлҗимеш, балан, җиләк җыярга йөрүчеләр дә, утын-печән хәзерләүчеләр дә аларны еш куллана иде. Хәзер Түбәнкама сусаклагычы сулары каплаган Кама тугайларында “Ар юлы”, “Ар болыны” атамалары булганлыгын да әйтеп үтәргә кирәк. Табылган документларда Бәзәкә болыннары арасындагы ар болыны Бәзәкәдән 20 чакрым ераклыкта урнашкан Игра авылыныкы итеп билгеләнгән. Тотрыклы тормыш алып барган Игра халкы, бәзәкәләләр кебек үк, үзләренә тиешле җирләрдә иген иккән, мал-туар тоткан, утын-печән әзерләгән, балык тоту, аучылык-сунарчылык, чолыкчылык (урман умартачылыгы) белән шөгыльләнгән. Бу юл белән тапкан мал (затлы балык, бал, кыйммәтле җәнлек тиресе h.б.), күбесенчә, ясак түләргә киткән.

“Сәйтәк инеше буендагы Азай бушлыгы”ның документта күрсәтелгән чикләре безгә бу бушлыкның хәзерге керәшен авылы Сәйтәк җирләрендә булганлыгын аңлата. Бу җирләргә Федор Федоров күчереп утыртылганда, анда инде иң кимендә җиде хуҗалык урнашкан була дип әйтә алабыз, чөнки анда яшәүче халык өч ярым ясак түләгән. Тагын ярты ясак яңа килгән Ф.Федоров өстенә йөкләнгән. Икенче документтагы мәгълүматтан без тагын бер фактны дәлилли алабыз.1650 елда Ф.Федоров яшәгән җир Сәйтәк елгасы буенда Азай бушлыгы дип кенә язылган булса, 1692 елгы язмада аның оныгы Тит Дементьев Сәйтәк авылында яшәүче “*новокрещен* (яңа керәшен)” дип әйтелгән. Димәк, күрше керәшен авылы Сәйтәк XVII гасырның икенче яртысында хәзерге исеме белән атала башлаган. Анда христиан динен яңа кабул иткән татарларны күчерә барганнар дип фаразларга була. “*Новокрещен* (яңа керәшен)” hәм *“кряшен* (керәшен)” терминнары XVI гасыр азагыннан, патша Федор Иоанновичның чукындырылмаган hәм чукындырылган татарларның бергә яшәвен тыйган махсус указы чыккач, кулланышка кереп

киткән, һәм аерым керәшен авыллары да барлыкка килә башлаган. Ә XVII гасырда “Новокрещенская контора” дигән оешма барлыкка килгәч, аңа кадәр христиан диненә күчерелгәннәр “иске керәшен” булып калганнар. Димәк, мин кечкенә чагымда ишеткән “Сәйтәк авылы татарлары Явыз Иван тарафыннан көчләп чукындырылган” кебек хикәяләр чынбарлыкка туры килми булып чыга. Ләкин бу мәсьәләне ачыклау өстәмә эзләнүләр таләп итүен дә онытмыйк.

Тагын бер документка мөрәҗәгать итик. Аны башкорт галиме Ә.З.Әсфәндияров “Аулы мензелинских башкир (Минзәлә башкортларының авыллары)” исемле хезмәтендә кулланган. 1856 елда Сәмәкәй (хәзер Тукай районында) авылы башкортлары (типтәрләр) үзләренең кайдан чыгулары хакында күрсәтмә биргәннәр, дип язган ул. Алар сөйләвенчә, типтәрләрнең ерак бабалары, элек Бәзәкә авылы ясаклы чуашлары булып, соңрак типтәр булып киткәннәр. Типтәрләр бу хакта рәсми кәгазь дә (“сберегательная память”) күрсәткәннәр. Бу кәгазьнең эчтәлеге: Бәзәкә авылының ясаклы чуашлары Казан ягыннан килүче хөкүмәт кешеләренең үзләрен төрле кысрыклауларга дучар итүләре хакында Уфа воеводасы Кондыревка һәм патша Алексей Михайловичка шикаять белән мөрәҗәгать иткәннәр. Патша әмере буенча стольник һәм воевода Кондырев дәгъвачыларга сусар тиресе белән түләнүче ясакны Уфага түләү һәм чит кешеләрнең аларга бернинди кысрыклау ясарга хаклары булмавы турында рәсми язу биргән. Бу язмадан күренгәнчә, 1856 елда Уфа губернасында яшәүче типтәрләрнең бабаларына саклагыш язуы 1670-1676 еллар арасында бирелгән (Уфада нәкъ шушы вакытта Кондырев фамилияле ике воевода булган). Ясаклы чуашлар исемен йөрткән бабалары Бәзәкә җирләренә, иң ким дигәндә, XVII гасырның беренче яртысында килеп урнашкан булырга тиеш, чөнки типтәрләр ул вакыйгаларга “220 елдан артык вакыт узган” дип сөйләгәннәр.

Типтәрләр күрсәткән борынгы язманың нык таушалуы аркасында өске өлеше юкка чыккан. Эчтәлегенә караганда, алар кулланган документ - патша Алексей Михайлович заманында воевода Кондырев тарафыннан Уфа өязе Казан юлы Бәзәкә авылы ясаклы чуашлары Уруска Еналеев һәм Юзейка Янгориннарның үтенеч-шикаятьләренә җавап буларак бирелгән 178 (1670) елгы саклагыш грамотасы белән тәңгәл килә. 1670 елда бирелгән грамотада бәзәкәлеләр Ырыс Еналеев, Йөзәй Янгорин үзләренең агай-энеләре, балалары, башка туганнары белән казнага түләп килгән еллык 13 сусар тиресеннән торган “бобыль” ясагына тагын 4 сусар тиресе өстәлүе һәм бу 17 сусар тиресенең Уфага тапшырылырга тиешлеге хакында язылган була. Шулай ук саклагыш грамотасында патша әмере һәм Уфадан бирелгән указ грамоталары булмаган очракта Казан һәм башка шәһәр – өязләрдән килгән ясак җыючыларга бәзәкәлеләрдән өстәмә ясак таләп итмәскә дигән боерык та булган. Күрәсең, ясакның артуын бәзәкәлеләрнең дәрәҗәсе үзгәрүе (элеккеге бобыльләр ясаклы чуаш булып киткән) һәм Уфа кул астына алынулары белән аңлатып буладыр.

Икмәк кенәгәсеннән алынган күчермәләрдә дә Бәзәкә чуаш авылы дип аталганын күргән идек. Ә Әгилдәй Тямов һәм Еман Юскеев үзләрен башкорт

дип атаган иделәр. Соңгырак документларда (РС 1719) Бәзәкә ясаклы татар авылы дип күрсәтелгән. Ничек булып чыга? Бер үк чорда бер авыл башкорт авылы да, чуаш авылы да, татар авылы да була алганмы? Бу сорауга җавап табар өчен безгә ул чорда кулланышта булган этник төшенчәләргә ачыклык кертергә кирәк.

“Ясаклы чуашлар” мәсьәләсеннән башлыйк. Галимнәр фикеренчә, XVI-XVII гасыр чыганакларында еш очрый торган термин “*ясашные чюваша*” этник атама дип түгел, ә социаль категория буларак каралырга тиеш. Бер вакытка караган төрле документларда, дип күрсәтә галимнәр, бер үк авыл чуаш авылы дип тә, татар авылы дип тә аталырга мөмкин. Әлбәттә, ясаклы чуашлар һәм аларның авыллары да булу мөмкинлеген мин икърар итмим, ләкин һәр очрак махсус тикшерүләрне таләп итүен дә онытмаска кирәк. Мәсәлән, Бәзәкә халкы хакында сүз йөрткәндә, бу фактны билгеләп кенә дә үтә алып та булыр иде. Ягъни XVI гасыр азагы — XVIII гасыр башларында Бәзәкә авылында ясаклы чуашлар яшәгән, аларның бер өлеше типтәр булып киткән, калганнары татар (башкорт) тарафыннан “йотылган” дип әйтергә дә мөмкин кебек. Ләкин Бәзәкә урнашкан төбәктә чуаш эзләре сакланмаган – якын-тирәдә бер генә чуаш авылы да юк, җирле атамалар арасында да чуаш теленнән кергән төшенчәләр очрамый. Мисал өчен, борынгыдан бу тирәләрдә яшәгән фин-угырларның (удмурт, мариларның) авыллары да бар, атамалар да җитәрлек. Дөрес, чуаш теленең төрки тел булуын, аларның тамырлары шулай ук болгарларга барып тоташуын исәпкә алсак, бәлки Бәзәкәдән чыккан типтәрләрнең бабалары да чуаш кабиләләреннән булуына нигез бар кебек. Ләкин алда игътибарыбыз үзәгендә булган документ та бу фаразга каршы килә.

Татар-башкорт мәсьәләсенә бераз ачыклык кертергә дә вакыт җитте. “Татарлар һәм башкортлар арасында барган зур масштабтагы этник процессларның характеры һәм нәтиҗәсе турындагы мәсьәлә бәхәсле булып тора. Бу проблема, аны аерым гына алганда да, гади түгел”, - дип ассызыклый Д.М.Исхаков “Татарлар: халык исәбен алу һәм сәясәт” исемле хезмәтендә. Соңгы ике дистә ел – чирек гасыр эчендә Идел-Урал төбәгендә (Татарстанның көньяк-көнчыгышы, Башкортстанның көнбатышы, Пермь крае) яшәүче “төрки телле халык кайсы милләткә карый - алар башкортмы, татармы?” - дигән сорау тирәсендә фикерләр “куера” башлады. Беренче чиратта, башкорт журналистлары, сәясәтчеләр, нигезле дәлилләр эзләмичә, җиңел генә, татар телендә сөйләшә торган бу төбәк халкыннан “асаба” (чиста) башкорт “ясап” куйдылар. Сәяси шаукымга бирелеп, кайбер Башкортстан галимнәре дә тиз генә бу фикерне куәтли торган “саллы” әсәрләрен дөньяга чыгардылар (Мисал өчен А.З.Әсфандияровның “Аулы Мензелинских башкир” исемле хезмәтен әйтергә була). Бу проблема белән күптән шөгыльләнүче Башкортстан һәм Татарстан галимнәре капма-каршы позициядә торган ике төркемгә бүленделәр.

Чыганакларга һәм әдәбияткә мөрәҗәгать итик. Менә 1937 елда Мәскәүдә басылган “История Татарии в материалах и документах” исемле җыентыктагы документлар. 1730 елда Казан губернаторы А.П.Волынский

“Россия империясендә башкорт мәсьәләсенең торышы һәм аны чишү юлындагы алымнар” исемле язма хәзерләгән булган икән. Анда ул башкортлар яши дип саналган җирләрдә халык санының бик тиз үсүенә, бу җирләргә даими арта барган салымнардан һәм күтәрә алмаслык изүдән качкан халык агылуына игътибар иткән. “Моннан 20 ел элек кенә 35-40 меңнән артмаган башкорт саны бертуктаусыз үзгәрә тора, һәм хәзер качкыннар хисабына 100 меңнән артып китте. Казан, Себер, Темников һәм башка өязләрдә яшәүче ясаклы татарларның яртысыннан артыгы башкортка күчте, башка христиан булмаган халыклар да, мордва, чуаш, вотяклар, бөтен авыллары белән, ясактан качып, шунда ук күчтеләр”, - дип ассызыклаган ул язмасында. Оренбург губернаторы И.И.Неплюев та XVIII йөзнең 40-елларына караган документларда башкортлар составында рус булмаган халыкларның күбәюе хакында даими хәбәр итеп торган.

Тарихчы, этнолог Д.М.Исхаков XVI-XVII йөзләргә караган рәсми документларда Урал буеның төньяк-көнбатышында ясак түләп яшәүче халыкның күптөрле атамалар белән аталуына һәм күп очракта алар *«башкурд»* яки *«башкирцы»* исемен йөртүенә игътибар итә. “Әмма чыганакларда очрый торган күптөрле атамалар шушы зонада яшәүче халыкның чын этник составын чагылдырмый, - дип күрсәтә ул. – [...] Урал буеның төньяк-көнбатыш өлешендә XVI-XVII йөзләрдә яшәгән төркемнәрнең ыру-кабилә исемнәрен өйрәнсәң, аларның ике төркемгә бүленгәнлеге күренә”. Аларның берсе нигездә кыпчак-монголларга, икенчесе – төрки-угыр тамырлы кабиләләргә барып тоташканын билгели галим. Моңа өстәп, XVII гасырда «татар» һәм «башкорт» арасындагы этник чикләрнең бик сизелерлек булмавын да ассызыклый ул.

Тел белгече Д.Б.Рамазанова да Уфа өязендә яшәүче халыкларның рәсми чыганакларда еш кына бер исем астында – башкорт исеме белән йөрүен күрсәтә. «XVII гасырда башкорт булу өстенрәк катлауда булу белән тәңгәл булган, башкорт исемен алу күчеп килгән крестьяннарга бик күп авыр йөкләмәләрдән котылырга мөмкинлек биргән, - дип язган тарихчы-галим У.Х. Рәхмәтуллин. - Шуңа күрә Уфа өязенең көнбатыш һәм төньяк өлешендә яшәүче чуаш, татар һәм марилар үзләрен башкорт дип атый башлыйлар”. Нәтиҗәдә, ул вакытларда ук “башкорт” атамасы этноним (халык исеме) буларак кына түгел, социаль-икътисади, территориаль мәгънәгә нисбәтле дә кулланылырга тиешлеген тәкъдим иткән галимнәр.

Барлык әйткәннәрне исәпкә алсак, ни өчен Уфа өязе Казан юлы Ирмин волостендә яшәүче яки анда вакытлыча күчкән Әгилдәй Тямов һәм Еман Юскеевның, Петр I-гә үтенеч белән мөрәҗәгать иткәндә, үзләрен башкорт дип күрсәткәннәре аңлашыла. Аларны татар-башкорт мәсьәләсе түгел, ә үз биләмәләрен саклап калу проблемасы борчыган. Һәм үтенүчеләр шул максатны күздә тотып эш йөрткәннәр. Төрле авыл-волость-аймакларда яшәүче башкорт-татарның телен, динен, гореф-гадәтләрен, көнкүрешен аера торган чикне уздыру ул вакытта мөмкин дә булмагандыр. Сәясәткә артык бирелмәгән халык өчен мондый мәсьәлә бүген дә бик актуаль түгел. Ә милли үзаң формалашырга өлгермәгән чорда, нинди нәсел-кабиләдән

булуны белү белән бергә, дини аермаларга гына игътибар бирелгән.

Шулай итеп, бу бүлектә без Бәзәкә авылына бәйле XVII гасырда барлыкка килгән рәсми документлар белән таныштык. Аларны кайбер легенда-риваятьләр белән тәңгәлләштереп карадык. Берничә мәсьәләнең чишелешен дә таптык шикелле. Хәер, җавапны укучым үзе бирер дип ышанам.

Таш язмалар

Зиратыңда синең күпме буын ята...
Син тарихлы авыл, Бәзәкә!
Тирән серләреңне чишә-чишә,
Тарихыңны алам йөрәккә...

Авыл тарихын барлаганда, таш язмалар да ярдәм итә ала. Беренче чиратта, сүз авыл зиратларында бу көнгә кадәр сакланып калган кабер ташлары хакында булыр. Үлгәннәрнең каберләре өстенә куелган гарәп язулы борынгы кабер ташлары - кыйммәтле мәгълүмат туплаган ышанычлы чыганак булып тора. Юкка гына мондый ташлары булган авыл зиратларын күренекле тарихчы-археограф Миркасыйм Госманов үзенчәлекле таш архивлар дип атамагандыр. Ташларга чукып язылган мәгълүмат кабердә яткан кешенең исеме, яшәгән еллары, нәсел шәҗәрәсе кебек фактлар хакында сөйләп кенә калмый, аларда теге яки бу тарих серләрен ачарга ярдәм итә торган материаллар да очрый. “Борынгы чорлардан башлап, XX гасыр башына кадәр кабер ташларында вафат булган шәхескә бәйле рәвештә милли тарихыбызның аерым бер фактлары, халыкның мәдәни һәм әхлакый үсеш дәрәҗәсе чагылыш тапкан”, - дип яза кабер ташларын өйрәнүче галимнәр Раиф Мәрданов һәм Ирек Һадиев “Гасырлар авазы” журналында 2002 елда дөнья күргән “Таш архив” серләре” дип аталган мәкаләләрендә. Төрле эчтәлекле мәгълүматка бай борынгы кабер ташларын әле бүгенгә кадәр авыл зиратларының күбесендә очратырга мөмкин, шуңа күрә, кичекмичә, аларны барлау-өйрәнү эшен җәелдереп җибәрергә кирәклеген ассызыклый алар.

Филология фәннәре кандидаты Раиф Мәрданов Бәзәкә авыл зиратындагы борынгы ташларны да өйрәнде. Үзенең тамырлары да Бәзәкәдән булган галим, туганнары белән бергә зиратның иске өлешен тикшереп, эзләнү нәтиҗәләрен 2004 елның 23 һәм 30 июлендә «Менделеевск яңалыклары» газетасында бастырып чыгарды. Анда ул гарәп язулы 42 кабер ташын исәпкә алуы, аларны фотога төшереп, текстларын күчерүе хакында яза. Менә шул мәкаләдән берничә өзек. “Бәзәкә авылының зираты бик зур, иске ташлар бик күп. Дөрес, XIX гасырда һәм XX гасыр башында куелган кайбер ташларның кеше исеме һәм елы кебек фактик мәгълүмат язылган өлешләре ватылган, яисә хәрефләре коелып-юылып беткән”, - дип яза автор.

“Зираттагы иң борынгы таш каберстанның уртасында басып тора. Ул таш 1689 елда вафат булган Йөзекәй улы Айман исемле кешегә куелган. Андагы язуга караганда, ташны мәрхүмнең әтисе куйдырган. Ташның биеклеге бер метр, киңлеге 50 см, калынлыгы 22 см, - дип дәвам итә

Р.Мәрданов. - Ул чорда куелган мөселман татар кабер ташлары аерым бер үзенчәлеккә ия. Аларда Болгар һәм Казан ханлыгы дәверендәге ташъязма истәлекләрнең традициясе сакланган. Ташның очлы өске өлешендәге традицион чәчәкле бизәк һәм текстының язылышындагы традицион элементлар шуны раслый. XVII гасырдагы мондый ташларның уючы-язучысының да исеме билгеле. Ул – Килмөхәммәт Ишмән улы”.

Өлкән буын авылдашлар борынгы заманнарда Бәзәкәнең тагын бер зираты булуы хакында да сөйлиләр иде. Ул Бәзәкәдән 1-2 чакрым төньяктарак Көчәнде дип әйтелә торган урында урнашкан, әле 1930-1940 елларда да бу иске каберлекләр өстендә берничә иске язулы таш булган. 1952-1955 елда Казан галимнәре бу ташларны килеп караганнар, бер ташны бик әһәмиятле дип билгеләгәннәр. Ләкин вакыт узу белән бу кабер ташлары уала-югала барган. 1970-елларда колхоз бу җирләрне чәчүлеккә әйләндергән. Монда эшләгән колхозчылар сөйләвенчә, вакланган-җимерелгән таш кисәкләрен алар сөрелә торган җирләрдән инеш буена күчергәннәр. Ә исән калган зур ташны соңрак Менделеевск музеена алып киткәннәр.

Бу таш хакында Р.Мәрданов та язган: “Бәзәкә авылы янындагы «Көчәнде» дип аталган урындагы иске зират урынында борынгы таш булганлыгы турында безгә мәгълүм иде. Фәйзелхак абый сөйләвенә караганда, 1930-1940 нчы елларда анда борынгы ташлар берничә булган. 1955 елда Казан галимнәре Н.Воробьев һәм Г.Хисаметдинев андагы бер ташны килеп караганнар, бик әһәмиятле дип билгеләгәннәр. Гәрчә алар тарафыннан тексты укылмыйча һәм язып алынмыйча калган. 1957 елда басылган бер фәнни җыентыкта алар бу ташны Казан ханлыгы дәверенеке дип язганнар. Шуннан соң борынгы кабер ташлары белгече Һ.Йосыпов 1960 елда дөнья күргән бер китабында бу ташны XVII гасырныкы дип билгеләгән. 1970 нче елларда галим М.Әхмәтҗанов та бу ташны килеп күргән. [...] Менделеев каласындагы төбәк музеена кереп белешкәч, “Көчәнде” ташының шунда китерелгәнлеге ачыкланды. Вакыт тыгызлыктан һәм язуы бик таушалганлыктан хәзергә текстын укырга туры килмәде. Ләкин беренче күз ташлауга шул ачык аңлашылды: ул алдарак тасвирлап үтелгән, XVII гасырга караган үзенчәлекле ташлар кебек үк. Шунлыктан, Бәзәкә тарихы турындагы китапның 113 битендәге таш фоторәсеме астына «Болгар кабер ташы» диелгән язу хакыйкатькә туры килмәвен белдерергә тиешбез”. Соңрак Р.Мәрданов бу таштагы язуны укыганлыгын, анда ташның Чураш (яки Йөзәй) бигә 1689 елда хатыны Зәйнәп куйдыртканлыгы хакында мәгълүмат булуын 2006 елда “Мәйдан” журналында язып чыкты.

Димәк, XVII гасыр азагында Бәзәкә тирәсендә ике урында ике зират булган. Моны ничек аңлатырга мөмкин? Минем фикеремчә, ике зиратта бер-берсенә охшаган ике таш булуы, өстәвенә аларның 1689 елда бер үк оста тарафыннан язылуы безгә бу вакытта Бәзәкә инеше буенда, иң кимендә, ике авыл булуы хакында сөйли. Ә бәлки авыллар берничә дә булгандыр: куе урманнар кочагында дистә ярым - ике дистә чакрымга сузылган елга буенда өч-биш йорттан торган берничә авыл яшеренергә мөмкин. Моңа өстәп, бу тирәдә тагын бер зират – Пан зиратының урыны булуын да әйтергә була.

Бу юлларны язганнан соң бер елдан артык вакыт узгач, әлеге фаразның дөреслеккә туры килүе ачыкланды. Р.Мәрданов Мәскәүдәге борынгы актлар архивыннан үзе күчереп алган 1680 елга караган документның күчермәсен бирде миңа (Кушымта, № 3). Бу документтан Көчәнде зиратының анда күрсәтелгән Бәзәкә һәм Тәкәш инешләре арасындагы пүчинкәнеке булып чыгуы аңлашыла. Бу чыганакка әле без XVIII гасыр документларын тикшергәндә әйләнеп кайтырбыз. Тагын бер фараз. Бәлки бу урынның Көчәнде дип аталуы да күченүләр белән бәйледер: мондагы авыл халкы бу урыннан күченеп китәргә мәҗбүр булгач, әлеге җирләр күченгән урын – Күченде булып калган, ә вакыт узу белән бу исем Көчәнде булып киткәндер. Ничек кенә булмасын, Бәзәкә зиратларындагы кабер ташлары авылның XVII гасырда яшәвен дәлилли. Ләкин бу факт аңа нигез салыну вакытына ачыклык кертә алмый. Шуны гына әйтергә була, кабер ташлары куелган зиратлар булу өчен бу тирә кешеләренең җирдә ныклап “утыруы” – яшәве дә кирәктер.

XVIII йөздә Бәзәкәдә халык санын исәпкә алу

Кемнәр соң әле без? Күпме соң без? –
Мин очына әле чыгалмадым...
Роберт Миңнуллин

Рус дәүләте өчен дә, анда яшәгән халыклар өчен дә бик катлаулы булган XVIII йөздә яңа дәвер башланган. Ул чордан безнең көннәргә кадәр архив-китапханәләрдә сакланып калган документларның күп булмавын исәпкә алсак, Бәзәкә исеме очраган документларга юлыгу үзе зур куаныч. Бу гасырга караган Бәзәкә хакындагы материаллар халык исәбен алуга кайтып кала. Дәүләт өчен халыкның төгәл санын белү, беренче чиратта, салым җыю өчен кирәк булган. Петр I уздырган мөһим реформаларның берсе – салымнарны хуҗалык берәмлегенә бәйләп түгел, ә җан (ир-ат) башыннан чыгып билгеләү булган. Димәк, халык санын алуга да үзгәрешләр кертелгән, һәм Писцовый кенәгәләргә алмашка, дөресрәге, аларның дәвамы яки бер төре булып, “**Ревизская сказка”**лар килгән. Петр I-нең 1718 елның 26 ноябрь указы нигезендә кертелгән махсус язмалар - **“Ревизская сказка”** – ике сүздән ясалган атама (*ревизия* – тикшерү, барлау, *сказка /сказывать/* – телдән сөйләнгәннең язмасы) - XVIII-XIX гасырларда уздырылган халык санын алу документларының исеме. Петр I фәрманында “барлык авылларда җан исәбеннән салым салыр өчен, бер ир-атны да калдырмыйча, бер ел эчендә халык исәбен язып алырга” дигән катгый таләп куелган була. Бу һәрбер авыл һәм шәһәрдә салым түләүче сословиеләр өчен аерым төзелергә тиешле документта йорт хуҗасының үз исеме һәм әтисенең исеме, ничә яшьтә булуы, шулай ук хуҗалыкта яшәгән кешеләрнең исеме, яше, хуҗага мөнәсәбәте күрсәтелергә тиеш булган.

Русиядә барлыгы ун ревизия уздырылган. Аларның рәсми билгеләнгән еллары - 1719, 1742, 1762, 1782, 1795, 1811, 1816, 1834, 1850, 1858 еллар булган (алдагы язмаларда алар, исемнәре кыскартылып, РС 1719, [...] РС 1858 тибында бирелер). Ләкин Русия территориясенең зурлыгы, эшне белгән

чиновникларның җитмәве аркасында ревизияләрнең һәркайсы берничә елга сузылган. Мәсәлән, беренче ревизия 1719-1727 елларда, соңгысы – 1857-1860 елларда башкарылган. Шуны да әйтү мөһим: документлар барысы да бер җирдә тупланмаган. Шуңа күрә бу чыганакны эзләүне төрле архивларда, төрле фондларда алып барырга кирәк булды. Һәм төрле сәбәпләр аркасында аларның шактый өлеше сакланмаган да. Мәсәлән, Татарстан Милли архивында Бәзәкәгә кагылышлы алты ревизия материалы гына саклана. РС 1719 шаблон буенча язылган булса да, әле сан алуның махсус таләпләре эшләнеп җитмәгәнлеге күренә. Аннан соңгы халык санын алуларга хәзерләнгәндә, аерым указлар белән документның эчтәлеге киңәйтелгән, махсус кенәгәләр эшләнгән.

Бәзәкә авылында ничә ир-ат яшәве хакындагы беренче мәгълүмат 1719 елның 8 июнендә алынган (Кушымта № 5). Мәгълүматны Казан өязе Җөри юлы Бәзәкә авылында яшәүче сотник Текешка (Тәкәш) Тинебәков җиткергән. Аның сүзләре буенча, Бәзәкә авылында бу көнгә биредә яшәүче ясаклы татарлардан өч кенә ир-ат булган. Алар 85 яшьлек Тәкәш Тинебәков үзе, аның улы 45 яшьлек Полат (Булат) һәм оныгы, Булатның улы, 15 яшьлек Суханкул (Сөбханкол). РС 1719-ның кереш өлешендә, тулы һәм дөрес мәгълүмат бирелмәгән очракта, гаепленең каты җәзага тартылачагы хакында да әйтелгән (“*жестокое наказание бити кнутом нещадно”)*. Язып алынган хәбәрләрнең дөреслеген сотник Тәкәш үз тамгасы (“/\/\”) белән беркеткән. Тамгалар хакында аңлатма: һәр нәселнең борын-борыннан килгән үз тамгасы булган. Нәселдә берничә тармак һәм хуҗалык булган очракта, аларның һәрберсе нәсел тамгасын, бераз үзгәртеп, үзләренә тәгаенләгәннәр. Үз тамгасын хуҗа иманасының бер почмагына да ныгыткан, рәсми документларда имза урынына да куйган, малын билгеләгәндә дә кулланган.

Сүз уңаеннан, Тәкәш Тинебәковның безнең ерак бабабыз булуын да әйтеп китим. Әтидән ишеткән нәсел чылбырыннан кала, бу фактны Тәкәш бабаның тамгасы да раслый; “/\/\” формасындагы тамга мин кечкенә чагында безнең иске йортның капка баганасына уелып киселгән иде, әти аңлатканчы, мин аны фамилиябезнең беренче хәрефе дип уйлый идем. Бу искәрмәне бирүемнең сәбәбе – РС 1719 да тагын бер бабабыз – Тәкәш улы Уразмәтнең исемлектә булмавы. Күрәсең, җан саны алынганда, Тәкәш баба белән бергә ирләрдән улы Булат һәм оныгы Сөбханкол гына яшәгән. Ә Уразмәт үз гаиләсе белән аерым яшәгән булып чыга (патша указындагы “налицо” сүзен бик тар мәгънәдә аңлап та була). Бу очракта Бәзәкә инеше буенда берничә авыл урнашканлыгы хакындагы фикер дөреслеккә туры килергә мөмкин.

Беренче ревизия чорына караган Бәзәкәгә бәйле икенче исемлек тә бар (Кушымта № 6). 1722 елгы бу исемлекне миңа Чаллыда яшәүче Илдар әфәнде Нәфыйков җибәрде. Үз нәселе һәм Әгерҗе районындагы туган авылы Кичкутанның тарихын өйрәнгәндә, ул Кичкутанны Бәзәкә белән бәйләгән документларга тап булган. Һәм, минем белән бәйләнешкә кереп, Илдар әфәнде үзендә Бәзәкә тарихына бәйле берничә документ барлыгын сөйләде. Тапкан материаллары белән ул мине дә таныштырып барырга булды. Шулай, көтмәгәндә, Чаллыда минем фикердәш-теләктәшем һәм

ярдәмчем табылды. Беренче ревизиягә бәйле ике исемлек булуы Бәзәкә инеше буенда иң кимендә ике авыл булганлыгын күрсәтә. Димәк, бер чордан безнең көннәргә кадәр килеп җиткән ике кабер ташы хакында сөйләгәндә ясалган фараз чынбарлык булып чыга. Бәзәкә инеше буенда берничә авыл яшәгәнлеген башка ревизия документлары да дәлилли.

Бәзәкә буенча 1742 елда узарга тиешле икенче ревизия материаллары хәзергә табылмады. Аның каравы, өченче ревизиягә (РС 1762) караган өч документ табылды. Аларның өчесендә дә Бәзәкә исемле авылларда яшәгән кешеләр теркәлгән. Димәк, 1762 елгы өченче ревизия язмалары да Бәзәкә инеше буенда берничә авыл урнашкан булуы хакындагы фикеремне раслый. 1762 елгы өченче ревизиянең беренче язмасына Бәзәкә авылында яшәүче ясаклы татарлар (Кушымта, № 9), икенчесенә соңрак типтәр булып язылган ясаклы татарлар (Кушымта, № 8), өченчесенә 1680 елгы язмада Тәкәш һәм Бәзәкә инешләре кушылган җирдә пүчинкә дип язылган авылда яшәгән, соңрак Бозак-Тукмаклы исемен йөрткән авылның ясаклы татарлары теркәлгән (Кушымта, № 7).

РС 1762, беренче ревизиядән аермалы буларак, махсус дүрт графалы таблицага кертелгән. Икенче ревизия язмаларына хатын-кызлар теркәлгән булуы да сизелә. Эчтәлегеннән Бәзәкәдә ясаклы татарлар яшәве, аларның ата-бабаларыннан калган биләмәләре булуы күренә. Халык саны алуны уздыру вакытлары да билгеләнгән еллардан соңрак булуы аңлашыла – РС 1742 Бәзәкәдә дә, Бозакта да 1747 елда, ә РС 1762 - 1764 елда уздырылган.

Кырык ел эчендә бу төбәктә өч сотник алмашынган: 1719 елда монда сотник вазифаларын Тәкәш Тинебәков үтәсә, 1747 елда бу хезмәтне Тойка Абдулов (татарча бу исем, бәлки, Туйкә булгандыр – А.М.), ә 1764 елда черемис (мари) Кучим Мучюков башкарган. 1764 елда сотник Тәкәшнең оныгы Сөләйман Уразмәт улы Бәзәкә авылының старостасы, ә Сөләйманның улы Мөхәммәт Алат юлында сотник булуын да күрәбез. Шуңа да игътибар итик: XVIII гасырда да Рус дәүләте Казан ханлыгында яшәгән ясак түләүче җирле халыкны унлык, иллелек, йөзлекләргә бүлүне саклап калган. Сотник карамагына, авыллардагы хуҗалык (җан) башыннан чыгып, берничә авыл да, дистәләгән авыллар да кергән. Бер сотник карамагындагы авыллар төрле төбәкләрдә урнашкан булуы мөмкинлеген дә билгеләп үтик.

Бу күзәтүләрне Ф.Ислаев һәм Р.Галлямов 2004-2006 елларда “Гасырлар авазы” журналында бастырып чыгарган 1742 елда Казан өязендә җимерелгән мәчетләр исемлегеннән файдаланып ясарга мөмкин. Документта Бәзәкә исеме юк, ә күрше татар авылы Тәкәш бар. Анда язылганнардан унбиш хуҗалыклы Тәкәшнең Туйкә Абдулов йөзлегендә булуы һәм 80 ел элек төзелгән авыл мәчетенең махсус команда тарафыннан җимерелгәнлеге күренә. Шул ук йөзлектәге Бәзәкә авылының бу исемлеккә кермәвенә берничә сәбәп булырга мөмкин: 1) Бәзәкәләрдә дә, Бозакта да бу чорда мәчет булмаган; 2) Булса да, ул манарасыз йортта урнашкан, шуңа күрә карательләр аны тапмаганнар; 3) Кара урманнар эчендә урнашкан авыллар Тәкәштән 3-4 чакрымда гына булса да, мәчетләрне җимерүчеләрдә алар хакында мәгълүмат булмаган; 4) Казан өязе Җөри юлында саналган Бәзәкә

халкы үзенең Оренбург (Уфа) өязенә чиктәшлегеннән дә оста кулланган булырга мөмкин (бәзәкәлеләр, үзләрен башкорт дип атап, Анна Иоановнаның башкорт авыллларындагы 1736 елга кадәр салынган татар мәчетләрен җимермәү хакындагы фәрманы нигезендә эш алып бара алганнардыр дип уйларга була). Бу исемлектә, башка йөзлекләрдә дистәләгән авыл булып, Т.Абдулов йөзлегенә кергән бер генә авыл күрсәтелүе дә игътибарны җәлеп итә (бәлки башкалары фин-угыр авыллары булгандыр).

Өченче ревизия материалларына кайтыйк. Таблицадагы беренче графада исемнәр бирелгән, икенчесендә икенче ревизиядә хисапка кергәннәр хакындагы мәгълүмат урын алган. Ул вакытта төп Бәзәкәдә 9 хуҗалыкта 1 яшьтән 78 яшькә кадәрге 19 ир-ат яшәгән икән. 18 ел эчендә 10 кеше вафат булган. Ике кеше (1754 елда 29 яшьлек Агаретдин Мөслим улы һәм 1763 елда 34 яшьлек Азой Сәрмәкәй улы) сөргенгә җибәрелгән, берсе (20 яшьлек Сәгыйть Сәрмәкәй улы) 1757 елда рекрутка озатылган. Шулай 1764 елга авылда 5 хуҗалыкта 7 ир-ат кына калган (68 яшьлек староста Уразмәт улы Сөләйман үзе, 38 яшьлек Теләүмәт Көлмәмәт улы, 81 яшьлек Сәрмәкәй Биктимер улы, 20 яшьлек Мәсәгут Хәмит улы, 8 яшьлек энесе Йөзекәй белән 19 яшьлек Исхак Ибраһим улы һәм 22 яшьлек Сәгыйть Мөслим улы). Соңгы өч егетнең өйләнмәгән булуы да күрсәтелгән.

Икенче ревизиядә хатын-кызларны да исәпкә ала башлаганнары күренә. Ләкин Сөләйман Уразмәт улы үз хатыны 50 яшьлек Әминә һәм 18 яшьлек кызы Мәдинә хакында гына мәгълүмат биргән. РС 1762 дә исә бер хатын-кызның да исемлектә булмавы өченче ревизия барышында аларны исәпкә алмаганнар дип уйларга мөмкинлек бирә. Шуңа игътибар итик: Әминә Әбүшаһман кызы чыгышы белән Арча юлы Матабар (бәлки бу авыл хәзерге Тукай районындагы Малтабар авылыдыр?) исемле ясаклы татарлар авылыннан булган; ә кызлары Мәдинәне Уфа өязе Ахтай авылына кияүгә биргәннәр. Бу фактлар ул чорда ук бәзәкәлеләрнең үз төбәкләрендә генә йомылып ятмаулары, бер-берсеннән шактый ераста урнашкан башка төбәкләр белән тыгыз бәйләнештә булулары хакында сөйли.

Документлар XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башында бу җирлектә шактый мөһим үзгәрешләр булганлыгын күрсәтә. Т.Беляков биләмәсенең варислары XVII гасыр азагында үзләрен башкорт дип язулары хакында сүз булган иде. Ә РС 1719 һәм РС 1762 Казан өязе Җөри юлы Бәзәкә авылында ясаклы татарлар гына яшәгәнлеген күрсәтә. Башкортлар кая киткән? Үз җирләрен рәсми рәвештә ныгытыр өчен Уфа, Мәскәүгә (патшага кадәр) үтенечләр юллаган Т.Беляков дәвамчылары әллә биләмәләреннән ваз кичкәннәрме? Бу фактны ничек аңлатып була? Ул Ирмин волостеннән үтенеч юллаган Әгилдәй Тямов, Еман Юскеев һәм Акбулат Ихтеевларның даими рәвештә Бәзәкәдә яшәмәгәнлеген раслый. Бәзәкәдә көн күрүче сотник Тәкәш Тинебәков аларның чордашлары булуын да исәпкә алсак, бәзәкәлеләрнең бик хәрәкәтчән булуын билгеләп, алар кирәк вакытта башкорт, икенче очракта татар төшенчәләрен кулланганнар дигән нәтиҗә ясарга гына кала.

Ата-бабалардан күчеп килгән җирләрнең хуҗалары Алтын Урда, Казан

ханлыгы заманнарында да дәүләткә ясак түләп килгән. Мәскәү кул астына күчкәч, барлык җирләр дә Мәскәү патшасы (казна) милкенә әверелгән. Биләмәләренең борын-борыннан үзләренеке булуын дәлилли алган авылларга, аерым алпавытларга биргән кебек, “жалованная грамота”, “владеная выпись”, “крепость”, “сберегательная память” һәм башка исемнәрдә булган саклагыш таныклыклары (яклагыш грамоталары) бирелә башлаган. Таныклыкны югалту исә зур мәшәкатьләр тудырган, башкаларга да бу җирләрне дәгъва кылу мөмкинлеген ачкан. Яклагыш грамоталарына ия булган татарлар да казнага ясак түләгән. Шуны да өстәп әйтим: Алтын Урда, Казан ханлыгы заманында ук мондый биләмәләр, гадәттә, бөтен авыл җәмгыятенеке исәпләнгән, авылда яшәгән һәр хуҗалык иясе бу җирләрдән файдаланырга хокуклы булган. Әгилдәй Тямов һәм Еман Юскеев, димәк, үз исемнәреннән генә түгел, ә барлык бәзәкәлеләр исеменнән эш йөрткәннәр.

Биләмә җирләре авылда аерым хуҗалыкларга җирәбә белән бүленеп бирелгән. Ясак түләүче үз теләге белән җирәбә җирен калдырып китә дә, ясак түләүне башка кешегә күчерә дә алмаган. Шуны да әйтергә кирәк: бездә “җирәбә” сүзе урнына еш кына “имана” сүзе дә кулланыла. “Имана” дип җирәбә белән алган җир дә, бу биләмә хуҗасы үзе дә, җир өчен түләнә торган салым да аталырга мөмкин. Бу сүз рус теленнән кергән булырга тиеш: “исем - имя-имена-имана”. Имананың чикләре, күләме, хуҗасының исеменә беркетелеп, махсус кенәгәләргә теркәлгән. Ясаклыларның социаль-икътисади хәле алпавыт крестьяннары хәленнән өстенрәк булган. Шәхси тормышта, яши торган җиреннән икенче җиргә чыгып кайту мәсьәләсендә, төрле һөнәрләр яки сәүдә белән шөгыльләннүдә аларның мөмкинлекләре күбрәк булган. Моның өстенә алар өстәмә салым (оброк) хакына аучылык-сунарчылык, балык тоту һ.б. шундый кәсепләр белән шөгыльләнер өчен яраклы урыннарны хөкүмәттән арендага да ала алганнар. Моны без 1642 елда балык тоту өчен ике күлне арендага алган Акбулат Ихтеев мисалында да күрдек. Бәзәкәнең Кама буенда балык тота торган җирләре оброк түләү шарты белән “мәңгелек һәм сатылмый торган мөлкәт” буларак 1766 елда йомышлы башкорт Муса Мурин һәм аның иптәшләренә бирелүе хакында тагын бер документ сөйли.

Дүртенче һәм бишенче ревизия материаллары табылмаса да, бәзәкәлеләр хакында ул вакытка караган берничә сан китереп була. Мәсәлән, Вятка губернасы составында Алабуга өязе формалашканда 1781 елда төзелгән өяз авыллары исемлеге саклангган. Анда 1781 елда Бәзәкәдә 40 башкорт хуҗалыгы һәм 17 чукындырылмаган ясаклы татар хуҗалыгы булуы күрсәтелгән. Димәк, бу хуҗалыкларда яшәүчеләр РС 1782 дә язылган булырга тиеш. Ә бишенче ревизиягә (РС 1795) бәйле мәгълүмат Бәзәкә җирләренең чикләрен билгеләгән сызымның аңлатмасында урын алган. Аннан без 1795 елга Бәзәкәдә 95 башкорт хуҗалыгы һәм 12 типтәр хуҗалыгы булуын күрәбез. Башкортлар 244 ир-ат һәм 261 хатын-кыз, типтәрләр 22 ир-ат һәм 11 хатын-кыз булган.

Безгә мәгълүм булган бу чор материалының саннардан гына торуын исәпкә алып, без бу очракта да, бәзәкәлеләр татар-башкорт атамаларын бер-

берсенә тәңгәл санап, бер дәрәҗәдә кулланганнар, дип аңлата алабыз. Үз нәселебез тарихы да шуны күрсәтә. Безнең ерак бабаларыбыз Тәкәш, Уразмәт, Сөләйман ясаклы татарлар булганнар. Ә Сөләйман бабаның улы Хуҗаш Сулюковның исеме беренче тапкыр РС 1811 дә очрый. Һәм ул анда башкорт дип язылган. Бу фактның аңлатмасы болай булырга мөмкин: XVIII гасырның илленче елларында рус дәүләте көньяк-көнчыгыш чикләрен саклау өчен башкорт хезмәтеннән файдалана башлаган. Бу хезмәткә язылган башкортлар 1754 елдан ясактан азат ителгәннәр. 1723 елда туган Хуҗаш Сөләйман улы да, бәхетен сынап, башкалар белән бергә башкорт гаскәренә язылган һәм хезмәткә киткән. Җитмешенче елларда кире әйләнеп кайткан бәзәкәлеләрне рәсми документларда башкорт дип язганнар. Бу фактлар нигезендә XVIII гасыр азагында бу төбәктә яшәүче төрки халыклар арасында аерымлашу-бүленү процессы әлегә формалашмаган дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Бер инеш буенда өч Бәзәкә

Тарихыбыз – чытырманлык,
Нинди киртә арада?
Аңлашылмаучанлыклардан,
Тарих, зинһар, арала!

Роберт Миңнуллин

XVII – XVIII гасырлардан безең заманга килеп җиткән чыганаклар безгә хәзерге Бәзәкә җирлегендә ул чорда бер инеш буенда иң кимендә өч авыл яшәгәнлеген дәлилләргә мөмкинлек бирде. Ул авыллар кайчан барлыкка килгән? Шушы сорауга җавап эзләп карыйк. Авылларны бутамас өчен аларның аермаларын яки төп сыйфатларын билгелик. Варислары бүгенгә кадәр Бәзәкәдә яшәүче авыл - ул борынгы Бәзәкә, яки бу җирлекнең хуҗасы булган төп Бәзәкә. Ул чагында икенчесен типтәр Бәзәкәсе дип атыйк, ә өченчесе, документта язылганча, Бозак яки Тукмаклы булсын. Бәзәкә инеше буенда хәзерге урында төпләнеп яши башлаучылар, авылга нигез салучылар, авылны яшәтүчеләр безнең бабаларыбыз булган. Һәм китапта нәкъ менә шушы бабаларыбыз яшәгән борынгы Бәзәкә тасвирлана. Шуңа күрә бу бүлектә аны аерым тасвирлауда хаҗәт юк.

Икенче Бәзәкәгә күчик. Алдагы бүлектә телгә алынган 1722 елгы ревизия исемлегендә бу Бәзәкәдә ясаклы татарлар яшәве теркәлгән. Аларның ике хуҗалыгы булуы, 80 яшьлек Сәпәр Әхмәтев хуҗалыгында 6 ир-атның, 26 яшьлек Минка Әлмәтевнекендә өч бертуган ир-атның исемнәре, яшьләре, туганлык мөнәсәбәтләре күрсәтелгән. Бу ике хуҗалык “бобыль ясагы” исемен йөрткән салым түләгән. Ясакның күләме дә бирелгән – кеше башыннан 26 алтын 4 тәнкә, барлыгы 1 рубль 20 алтын; моның өстенә һәрбер төтенгә (хуҗалыкка) 8 тәнкә, ям тоту (почта йөртү) һәм әсирләр өчен унар тәнкә, барлыгы 6 алтын алынган (1 рубльдә 200 тәнкә, яки 33 алтын 2 тәнкә булган – А.М.). Барлыгы казнага бу хуҗалыклардан елга 1 рубль 26 алтын керем тиеш булган (Кушымта № 6).

Салымның исемен аңлатып китим. Кагыйдә буларак, XVII-XVIII гасыр документларында очрый торган “*бобыль*” сүзе белән үз хуҗалыгы булмаган, яки яңа җирдә рөхсәтсез яшәгән кешеләр билгеләнгән. Алар җирдән файдаланган өчен аренда да, ясак та түләмәгән. 1631-1632 елларда аларга ясаклылар түли торган салымның яртысы күләмендә ясак билгеләнгән. Шулай “бобыль ясагы” исемле төшенчә кулланышка кереп киткән. Икенче Бәзәкәдә 1722 елгы исемлектә ясаклы татар булып теркәлгән кешеләр 1764 елда, өченче ревизия материалларында типтәр дип язылган. Ничек һәм нинди сәбәпләр аркасында 1722 – 1764 еллар аралыгында бер үк нәселгә караган кешеләр икенче исем алганнар? Кемнәр инде алар – типтәрләр?

Галимнәр “типтәр” сүзе XVII гасыр азагыннан кулланышка кергән дип саныйлар. Ә рәсми чыганакларда бу сүз беренче тапкыр 1736 елның 31 маенда типтәр һәм бобыльләргә бирелгән сенат указында кулланылган дип санала. Типтәр һәм бобыльләрнең үтенече нигезендә язылган бу указда аларның, үз теләкләре белән Уфа воеводасы канцеляриясенә килеп, үзләре хакында тулы мәгълүмат бирергә тиеш булулары билгеләнгән. Мәгълүматны даругаларга бүленгән махсус дәфтәрләргә язу каралган. Шулай итеп, Уфа өязендә яшәүче үз җирләре булмаган кешеләр, кем булуларына карамастан, типтәр булып языла алганнар.

Фәнни әдәбиятта типтәрләр хакында төрле карашлар яшәп килә. “Соңгы вакытларга кадәр аларны татарларның вакытлыча аерылып торган өлеше итеп санау төп урынны алып торды, - дип яза галим-этнолог Дамир Исхаков “Татарлар: халык исәбен алу һәм сәясәт” исемле хезмәтендә. - Әмма соңгы елларда Башкортстандагы кайбер галимнәребез хезмәтләрендә яңа бер караш бәян ителде: бу караш буенча типтәрләр башкортлар һәм татарлар арасында торган этникара этнографик төркемне тәшкил итәләр”.

“Типтәр” сүзенең мәгънәсен дә галимнәр төрлечә аңлата. Берәүләр бу атаманы фарсы сүзе “*дәфтәр*”гә бәйләп карасалар (“яшәгән җирләренән качып киткән һәм дәфтәргә язылган кешеләр”), икенчеләре «*тибү (типкәләү)*» сүзеннән ясалган атама диләр. Ләкин ике аңлатма да җәмгыятьтән читкә китәргә мәҗбүр булган хокуксыз кешеләр мәгънәсенә туры килә түгелме соң? Галимнәр, типтәрләрнең үз җирләре булмаган, гадәти буларак, алар җирне татар-башкортлардан арендага алып яшәгәннәр дип саный. Алар фикеренчә, типтәрләрнең тамырлары төрки яки фин-угыр телле халыкларга барып тоташа. Баштарак аларда үз телләре һәм этник-мәдәни үзенчәлекләре сакланган. “Урал буе татарларының иң зур өлеше буларак, типтәрләр XVIII йөздә күчеп килгән казан татарлары хисабына оешалар, - дип күрсәтә Д.Исхаков. - Бу төркем инде XVIII йөздә үк аерым сословие төркеме булып формалашса да (аның “типтәр” дигән үзаңы да булган), типтәрләр татарлардан аерылып бетмиләр”.

1890 елда дөнья күргән “Вятка губернасы статистика материаллары. VI том. Алабуга өязе” исемле китапның кереш өлешендә типтәрләргә багышланган кызыклы фикерләр бар. “Гадәти буларак, типтәрләрне аерым кавем, аерым халык дип саныйлар, - дип язган аның авторы Евгений Филимонов. - Без исә типтәрләрне аерым сословие буларак билгеләдек. Һәм

менә нәрсәгә карап. Теркәлгәндә типтәрләрнең бер өлеше башкорт (татар), икенчеләре чирмеш булып чыкты. Аерым этнографик берәмлек дип күрсәтерлек типтәрләр төркеме бер җирдә дә табылмады. “Типтәр” - татар сүзе. Берәүләрнең фикере буенча бу сүз белән салымнан азат кешеләрне билгелиләр; икенчеләре бу төшенчә малороссларда гы “казак”, борынгы рус телендәге “стрелец” сүзләренә тәңгәл килә дип саный. Элекке елларда рус дәүләте үзенең көнчыгыш чикләрен дошманнардан саклар өчен шушы стрелецлардан яки казаклардан торган гаскәрне булдырган дип сөйлиләр. Төрле “инородец”лардан торган һәм хөкүмәткә тугрылыклы булган бу гаскәр типтәр гаскәре исемен алган. Соңрак бу гаскәрдә хезмәт итүчеләрне дә типтәр дип әйтә башлаганнар. Хезмәттәге (йомышлы) сословие буларак, типтәрләргә кайбер ташламалар да ясалган. Исемнәре белән бергә бу ташламалар да бүгенгәчә сакланып килә. Алабуга өязендә типтәрләрнең ике төре яши: берәүләре – үз биләмәләре булган типтәрләр (вотчинниклар), икенчеләре үз җирләре булмаган, җирне арендага алучылар (припущенниклар). Беренчеләре җирле халык булса, икенчеләре - килмешәк, Кама аръягыннан чыккан булырга тиешләр”.

Күптомлы “Татар тарихы”ның алтынчы томында “Русия империясендә типтәрләр рус булмаган халыкларның йомышлы-хәрбиләштерелгән төркемнәре булган һәм дәүләт (казна) крестьяннары арасында үзенчәлекле урын алып торганнар. Административ яктан караганда, аларны татар-мещеряк гаскәренә тиңләп булса (алар шулай ук үз хисапларына тупланган махсус полкларда хәрби хезмәттә булган), икътисади яктан казна крестьяннарына якынрак торганнар”, - дип билгеләнә. XIX гасыр вакыйгалары хакында сөйләгәндә, бу мәгълүмат, һичшиксез, дөрестер.

1736 елдан типтәрләрне исәпкә алу үткәрелгән, димәк, аларны махсус дәфтәрләргә язганнар (бәлки нәкъ шул вакыйгадан соң “дәфтәр-типтәр” төшенчәсе барлыкка килгәндер). Алар, башка җирле халыклар кебек үк, командаларга бүленеп, староста, сотник, старшиналар тарафыннан идарә ителгән. 1790 елда типтәрләр хәрби-хезмәт сословиеләре разрядына күчерелгән, 500 кешедән торган типтәр полкы формалашкан. 1798 елда ул полк икегә бүленгән. 1835 елдан типтәрләрдән ел саен һәр 720 кешедән 1 рекрут, барлыгы 150 рекрут алыну хакында карар чыккан. Уфа һәм Минзәлә воеводалары карамагында булган старшиналарның төп бурычлары - үз вакытында салымнар җыелуы, төрле йөкләмәләр һәм канун-күрсәтмәләрнең үтәлүе, рекрутлар туплануы, халык санын исәпкә алу булган. Милек-хуҗалык һәм гомуми мәсьәләләр тулысынча старшина һәм аның ярдәмчеләре карамагында булган. XIX гасырның беренче яртысында типтәрләр 13 төрле дәүләти йөкләмә үтәргә тиеш булганнар: рекрутлар бирү, почта һәм чиновникларны ат һәм олаулар белән тәэмин итү, становой пристав һәм лесничийлар өчен фатирлар тоту, почта трактлары һәм күперләрнең төзеклеген, елга аша кичүләрне тәэмин итү, почта һәм арестантларны саклау өчен каравыл бирү, төрле чиннар, арестантлар һәм узып баручы гаскәриләргә куну урыны әзерләү, юл күрсәтүчеләрне бирү, кирәк булганда, полиция десятскийлары һәм сотскийлары эшен башкару h.б.

Бәзәкә типтәрләренә кайтыйк. Димәк, чыннан да, икенче Бәзәкәдә яшәгән ясаклы татарлар 1722-1748 еллар аралыгында типтәрләр исемлегенә язылган булып чыга. 1764 елда төзелгән исемлек тагын нинди үзгәрешләр күрсәтә соң? 1748 елда типтәр Бәзәкәсендә 8 хуҗалыкта 16 ир-ат, 1764 елда 7 хуҗалыкта 17 ир-ат яшәгән. Бу ике ревизия арасында (16 ел эчендә) 6 ир-ат вафат булган, 7 малай туган. 1722 елда өч ир-аттан торган Әлмәтевләр Кальметевлар дип язылган. Нәселләре зурайган – 1764 елда бу нәселнең инде 4 хуҗалыкта яшәүче 12 ир-аттан торуы күренә. 6 ир-аттан торган Исмәгыйль Әхмәтев нәселе юкка чыккан. Ләкин аның хуҗалыгындагы Исмәгыйль улы Сәпәрнең үги малае 10 яшьлек Аббяз Токтаров 48 яшьлек староста Абляз Токтаров дип язылган. Күрсәтелгән тагын ике хуҗалык кешеләренең нинди нәселгә каравын билгеләрлек материал юк. Исемлекне староста Абляз Токтаров, тәрҗемәче Константин Иванов һәм Бәзәкә авылының ышанычлысы Зәет Кальметев раслаганнар.

Бәзәкә типтәрләренә бәйле тагын бер документны Ә.З.Әсфәндияров “Минзәлә башкортларының авыллары” исемле китабында китергәнлеге турында сүз булган иде. Ул документта Минзәлә өязе Сәмәкәй авылы типтәрләре – башкорт припущенниклары биргән мәгълүмат урын алган. 1856 елгы гаризада Сәмәкәй типтәрләре үзләренең бабалары “ясаклы чуашлар”ның Бәзәкә җирләрендә урнашуларына 220 елдан артык вакыт узганлыгын язганнар.

Шулай итеп, минем карамакта булган документлар Бәзәкәдә яшәгән типтәрләрнең борынгы бабалары XVII гасырның урталарында Бәзәкә җирләренә килеп төпләнүләрен раслый. Ул чорның рәсми кәгазьләрендә аларны “ясаклы чуаш” дип тә, “бобыль ясагын түләүче ясаклы татар” дип тә атаганнар. 1736 елгы сенат указы нигезендә типтәрләрне аерым дәфтәрләргә теркәп кую чорында алар типтәр дип язылган. Бу типтәрләрнең бер өлеше (беренче ревизия вакытында исәпкә алынган Смагил Әхмәтев нәселе дип уйларга була) Минзәлә өязе Сәмәкәй авылына (хәзерге Мөслим районы) күчеп киткән, ә икенче өлеше Бәзәкә инеше буенда яшәвен дәвам иткән дип фаразлап була.

Өченче Бәзәкәгә күчик. Аның нигезләнү вакытын галим Раиф Мәрданов Мәскәүдә РГАДАда табып, миңа куллану мөмкинлеген биргән 1680 елгы документ ярдәмендә чамаларга була (Кара: Кушымта № 2). Бу чыганактагы мәгълүмат шактый күп сораулар тудыра. Хәзергә кайбер фактларга гына тукталыйк. Ике инеш – Бәзәкә һәм Тәкәш инешләре аралыгында кайчандыр файдалануда булган, ләкин нинидидер сәбәпләр аркасында бушап калган җирләр барлыкка килгән. Һәм бу җирләргә бер төркем татарлар килеп яши башлаган. Бу хәл XVII гасыр урталарында булуга ошаган, чөнки авылның әлегә исеме юк - “починок (пүчинкә)” яңа төпләнгән авыл дигәнне аңлата. 1680 елда бу исемсез авылда 11 хуҗалыкта барлыгы 40 ир-ат теркәлгән. Ул чор өчен пүчинкәнең зур булуы күзгә ташлана. Ә яңа төпләнгән авыллар 1-3 хуҗалыктан торган. Җир күләменнән чыгып ясак түләүче 13 кеше (алар документларда “люди” дип аталган) – 7 бөтен һәм чирекнең яртысын тәшкил иткән ясак түләгәннәр.

XVIII гасырда бу пүчинкәгә бәйле бер генә чыганак табылды. Ул РС 1762 исемлеге. Анда авыл исеме “Казан өязе Ар юлындагы Бозак, яки Тукмаклы исемле авыл” дип язылган һәм ясаклы татарлар яшәве күрсәтелгән. Мин аны башта кулланмаска булган идем: бердән, авылның исемнәре шикләндерә. Аның Арча юлындагы авыл дип бирелүе дә шөбһә тудыра. Аның өстенә документта Уфа өязе Казан юлындагы Бәзәкә авылы да искә алына. Архив документларының күбесендә исә Бәзәкә (авыл да, инеше дә) Җөри юлында күрсәтелгән. Уйлану-эзләнүләр нәтиҗәсендә бу авылның безнең төбәктә булуына инандым, чөнки Бәзәкә инешенә Тәкәш инеше кушылган җир янында бүген дә Тукмаклы исемен йөртүче урын һәм аның янында иске зират урыны бар. Һәм тагын бер факт – ике Бозак кызының Бәзәкәгә кияүгә бирелүе һәм бер Бәзәкә кызының Бозакка килен булып төшүе хакындагы мәгълүмат та фикеремне ныгытты. Бу язма бер инеш буенда урнашкан ике авыл халкының, бер-берсенә кыз биреп, килен төшереп, дустанә мөнәсәбәттә яшәгәнен дә күрсәткән дип әйтергә мөмкин.

Ләкин XIX гасырга кергәндә бу ике Бәзәкә халкы арасында низаг чыккан. Бу хакта өченче документ сөйли. Бу чорда җир биләмәләренең чикләрен төгәл билгеләү максаты белән Русия дәүләте Генераль межалаштыру (ызанлау) чарасын уздырган. Җир биләүчеләр, шул исәптән бәзәкәлеләр дә, үз җирләрен барлап, аларны читләрдән бушата башлаган. Бәзәкәлеләрнең җирләрендә язма килешүсез генә күптәннән бирле яшәүче Бозак-Тукмак халкы да шушы исәпкә эләккән. Бәзәкәлеләр төрле юллар белән 1804 елда бу җирләрне үзләренә кайтарып алган (“деревни Безяков жители разными усилиями ту землю завладели”), ә бозаклылар Тәкәш авылына күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Бу хакта соңрак, Бәзәкә вотчинасы җирләре хакында дәгъвалашуга багышланган бүлектә иркенрәк сөйләшербез. Хәзергә исә Бозак яки Токмаклы авылының яшәеше шулай тәмамлануын билгелик.

Башкорт-мещеряк гаскәренә керү

Башкорт гаскәре турында
Җыруымны башладым,
Ырымбур чикләрен саклап,
Күпне күрде башларым.
(*Халык җыруы*)

XVIII гасыр азагында Бәзәкә халкы тулысынча бу гаскәр составына кергән. Һәм авылның алдагы тарихын башкорт гаскәре тарихына кагылмыйча аңлавы авыр булачак. Русия империясендә җирле идарә органнары көчәя барган саен гади халыкның изелүе, кысрыклануы да арткан. Салымнарның даими үсүе, рус дворяннарының җирле халыкларның җирләрен тартып алырга тырышулары, чиновникларның чамасыз башбаштаклыклары рус булмаган халыкларның ризасызлыгы үсүгә китергән. Аларның “башкорт” яки “башкорт-татар” исеме астында тарихка кереп калган, XVII-XVIII гасырларда барган милли һәм социаль изүгә каршы юнәлтелгән күпсанлы чыгышлары

рәхимсез рәвештә бастырылып килгән. Ләкин ул баш күтәрүләрнең яңадан кабатлану куркынычы да реаль булып кала биргән. “Һәр елны диярлек эчке тынычсызлыкны кабызып җибәрергә омтылучы очкын туып кына тора”; “тәвәккәл башлык кына килеп чыксын, башкортлар шунда ук бунт, фетнә күтәрергә әзер торалар”, - дип язган Оренбург генерал-губернаторы О.А.Игельстром Екатерина II-гә җибәргән отчетларында. Башкорт һәм татарлар актив катнашкан Е.Пугачев җитәкчелегенләге крестьян сугышы патша хөкүмәтенең борчылуларын тагын да арттырган.

«1773-1775 елгы Крестьян сугышы чорында патша хакимияте җирле органнарының көчсезлеген һәм эш алып бара алмавын ачык күрә, - дип язган Ә.З.Әсфәндияров «Кантонное управление в Башкирии (1798-1865гг.)” исемле китабында. - Пугачев баш күтәрелүенә китергән төп сәбәпләрне бетермәсә дә, патша хөкүмәте, җәза куллану белән генә чикләнмичә, берничә саклану чараларыннан да куллана – үзенең таянычы булган чиновник һәм руханиларның хәлен яхшырта, аерым катламнарны казаклар рәтенә кертә, һәм, ниһаять, пугачевщинаның кабатлануына юл куймау өчен идарәдә кантон системасына күчү эшенә керешә”.

Нәрсә соң ул кантон системасы? Французлардан алынган административ-территориаль идарәне күз алдында тоткан система хакында сүз башлаганчы, ул мәсьәләне көн тәртибенә куйган вакыйгаларга күз салып китик. XVIII гасырның 30-40 елларында Русия, көньяк-көнчыгыш юнәлешендәге тышкы сәясәтен көчәйтү максатыннан чыгып, Оренбург экспедициясен оештырган. Русиянең көньяк-көнчыгыш чикләрен саклауны арттыру өчен экспедиция чиновниклары рус булмаган халыкларны хәрби көч буларак киң планда куллану фикеренә килгән. Чиновниклар уенча, бу адым аларны хөкүмәткә каршы чыгышлар оештыру теләгеннән дә кайтарырга тиеш булган. Һәм губернатор И.Неплюев штатында регуляр булмаган гаскәриләр урын алган. Бу гаскәриләр арасында христиан динендәге казаклар да, ислам динен тотучы башкорт-мишәрләр дә, калмыклар да булган. Башкорт исеме астында аларга ясаклы татарлар да, фин-угорлар да кушыла башлаган.

1754 елдан башкорт һәм мещеряк (мишәр) исемнәре белән йөргән төркиләрнең бер өлешенә ясак урынына хәрби хезмәт эшен башкару мөмкинлеге ачылган. Аерым алганда, алар Русиянең көньяк-көнчыгыш чикләрен саклауда катнашканнар. Шуны истә тотып, хакимият аларны бу эшләргә тартуны киңәйтергә һәм башкорт белән мишәрләрне хәрби казак катлавына күчерергә, аерым башкорт-мещеряк гаскәре оештырырга булган. Башкорт-мишәрләрне хәрбиләр рәтенә күчерүдә Оренбург наместнигы О. А. Игельстром зур хезмәт күрсәткән. 1789 елның 22 апрелендә ул башкортларны “йорт” дип аталган командаларга бүлү хакындагы фәрманга кул куйган. 20908 башкорт хуҗалыгын 103 “йорт”ка бүлеп, алар белән идарә итүне үзе башкортлардан билгеләгән башлыкларга – йорт старшиналарына һәм аларның ярдәмчеләренә йөкләгән. Болардан тыш, 63 походтагы старшина һәм 213 сотник башкортларның хәрби хезмәтен (чик саклау) башкаруларын күзәтергә тиеш булган. Әлеге саннарны китергән

Ә.З.Әсфәндияров бу тәртипне урнаштыруны кантон системасына күчүнең башлангыч этабы дип бәяләгән. Өстәп шуны ассызыклап әйтеп була, кантон системасына күчеш “асаба” башкорт хуҗалыкларыннан тыш Вятка, Пермь, Самара губерналарына караган күп кенә ясаклы татарлар яшәгән җирләрдәге халыкларны да үз эченә алган. Вятка губернасы Алабуга өязенә кергән Бәзәкә авылы моңа мисал була ала.

Күчеш үзе ун елга якын сузылган. Башкорт-мишәрләрне хәрбиләр рәтенә күчерү хакындагы указга 1798 елның 10 апрелендә кул куелган. Бу указ белән Оренбург, Вятка һәм Пермь губерналары җирләрендә, Русиянең көньяк-көнчыгыш чикләрен ныгыту һәм башкорт җирләрен буйсындыру максатыннан чыгып, идарә итүдә кантон системасы кертелгән. 11 башкорт һәм 5 мещеряк кантоныннан торган регуляр булмаган башкорт-мещеряк гаскәре оештырылган. Кантоннар, нигездә, территориаль принциптан чыгып бүленгән һәм Урал-Кама буендагы башкортлар гына түгел, татарлар яшәгән җирләрне дә үз эченә алган. Кагыйдә буларак, бер кантонга, тулысынча яки өлешчә, берничә волость кергән. Бер волостьның берничә кантон арасында бүленү очраклары да булган. Кантон башында наместник (соңрак генерал-губернатор) тарафыннан билгеләнгән кантон башлыгы (начальнигы) торган.

Кантоннар төрле зурлыкта булган, алар составындагы халык һәм авыллар саны да тигез булмаган. Кантоннар “йорт”ларга бүленгән, алардагы йортларның саны да төрле булган (җидедән алып кырык сигезгә кадәр). Бер йортта йөздән меңгә кадәр җан саналган. Йорт башында кантон башлыгы тарафыннан билгеләнгән йорт старшинасы торган. Ул, бер яктан, кантон администрациясе алдында хәрби хезмәттә таләп ителгән йөкләмәләрнең тулы башкарылуы өчен җаваплы булса, икенче яктан, өяз, губерна җирле органнары алдында да төрле салымнарның үтәлүе хакында җавап тоткан. Йорт старшинасының төп вазифасы – елга ике тапкыр үз карамагында булган авыллардан, билгеләнгән чират буенча, казакларны “линия” (чик) хезмәтенә хәзерләп озату булган. Моннан тыш салымнар җыюны күзәтү, дәүләт һәм гаскәри йөкләмәләрне үтәүне оештыру да старшина бурычы саналган. Бу бурыч-вазифаларны үтәүдә старшинага төрле чиндагы ярдәмчеләре булышкан.

Башкорт-мишәр гаскәрендәге чиннар ике төрле – хакыйкый һәм штаттан тыш хезмәттә саналган. Хакыйкый чиннарга - гаскәри һәм казак чиннары (урядник, хорунжий, сотник, есаул һ.б.) кергән. Штаттан тыш чиннар, нигездә, башкортларга бирелгән, һәм аларны “походтагы” яки “зауряд-” сүзе белән билгеләгәннәр (зауряд-хорунжий, зауряд-сотник, зауряд-есаул...). Бу сүз казак гаскәрендәге гамәли чиннар башкарган хезмәтне вакытлыча үтәүче кешеләргә бирелә торган исем-билге булган.

Кантоннар чикләрен билгеләгәндә, Бәзәкә җир биләмәләре 11-башкорт кантоныың Кама аръягындагы Байлар волосте җирлеге составына кертелгән. 1798-1854 елларда күрше Кураз (Әтәс) һәм Турай авыллары белән бергә Бәзәкә 11-кантонның 23 (24)-йорты булып саналган. 11-башкорт кантоныың төп өлеше, шул исәптән, Байлар волостеның күпчелек җирләре дә, Кама аръягында, Ык елгасының түбәнге өлешендә булган. Волость

составындагы җирләрнең барысы да анда яшәүчеләрнең борынгы заманнан ата-бабаларыннан күчеп килгән биләмәләре саналган. Һәм, Бәзәкә мисалында күргән кебек, бу биләмәләр саклагыш грамоталары белән якланган. Шулай булса да, 1796-97 елларда бу грамоталар яңартылган. Мәсәлән, Бәзәкәгә яңа яклагыш грамотасы Петр I-енченең 1697 елдагы грамотасын кабатлап, 1797 елның 8 октябрендә бирелгән.

Бәзәкә җирләрен ызанлау

Исәнме, дип кочагына ала
Тугайларым, басу-кырларым.
Җилдә уйнап дулкынланган басу
Җырлый миңа сагыну җырларын.
Марсель Гыймазетдинов

Кантон системасына күчү белән параллель рәвештә башкорт гаскәре җирләрендә биләмә чикләрен билгеләү – ызанлау (межалаштыру) эшләре дә башкарылган. Бу эшләрне XVIII гасырның 60-елларында ук Русиядә ил күләмендә башланган иң зур аграр чаралардан булган “*Генеральное межевание*” - Генераль ызанлауның бер өлеше дип карарга кирәк. XVIII гасырда авыллар арасында җир низаглары күбәю, бер авыл биләмәсе белән икенче авыл җире арасындагы чикләрнең төгәл билгеләнгән булмавы, салым җыю барышындагы төрле күңелсезлекләр Екатерина II-нчене бу чарага керешергә этәргән. 1765 елның 19 сентябрендәге “Генераль ызанлау хакындагы манифест” һәм 1766 елның 13 февралендә һәм 25 мартында бирелгән указларда чараның максаты, принциплары һәм уздыру формалары билгеләнгән.

Генераль ызанлауның төп принцибын аерып күрсәтү мөһим – ул җир үлчәү, аларның чикләрен билгеләү эшләрен “*дача*”ларга бүлеп алып бару булган. ***Дача*** – бер яки берничә авылның җирләрен үз эченә алган территориаль берәмлек (җирлек). XIX гасырның беренче яртысында Оренбург, Пермь, Саратов, Вятка губерналарында урнашкан башкорт-мишәр гаскәре җирләрендә дачага, гадәттә, бөтен волость кергән. Ләкин монда да чыгармалар булган: кайбер урыннарда дачага берничә волость та, бер генә авыл да керергә мөмкин булган. Бәзәкәне без нәкъ шундый чыгармалар арасында күрәбез: аның башка авыллардан аерым үз дачасы булган.

1794 елдан ызанлау эшләре белән гомуми идарә итү Петербургтагы Сенат межа департаментына, ә оператив җитәкчелек Мәскәүдә урнашкан ызанлау канцеляриясенә тапшырылган. Кыр эшләрен башкаруның төп авырлыгы губерналарда оештырылган межалаштыру конторларына төшкән. Ызанлау эшләрен оештыру, эш барышын күзәтеп тору белән бергә планнарны, дачаларның ызанлау кенәгәләрен әзерләү, тикшерү һәм хуҗаларына тапшыру шушы конторалар кулында булган. Документация эшен башкару өчен дача җирлегендә яшәгән халыктан акчалата пошлина да җыелган. Ызанлау конторларының иң катлаулы эше булып дача чикләренең бәхәсле мәсьәләләрен чишү саналган.

Ызанлау эшен өязләргә җибәрелгән землемер командалары үтәгән. Һәр командага баш землемер, аның ярдәмчесе, өлкән һәм кече землемер өйрәнчеге, кыр эшләрен башкару өчен 1-2 канцелярист һәм 4 солдат кергән. Землемерлык эшләре барганда һәр команда кыр журналы (язмалар), көндәлек журнал, икътисадый журнал, ызанлау кенәгәсе белән махсус геометрик планнар һәм башка документлар тутырырга тиеш булган. Ызанлау командасы эшенең мөһим өлеше булып икътисадый журналны (икътисадый искәрмәләр) тутыру саналган. Бу журналда һәрбер авылның тасвирламасы, 1795 елгы бишенче ревизиядә күрсәтелгән халык саны һәм авыл халкының шөгыль-һөнәрләре, шулай ук җирләрдән файдалану структурасы язылырга тиеш булган. Землемерларның күп вакытын картографик документация төзү алып торган. Һәрбер дача өчен махсус геометрик планнар һәм дачаның географик ориентирлары белән чикләрен билгеләгән ызанлау кенәгәләрен ясау тиеш булган.

Генераль ызанлау 1766 елда империянең үзәк губерналарыннан башланган. Утыз ел эчендә илнең Европа өлешендәге күп кенә җирләрендә ызанлау эшләре башкарылган. 1797 елның 25 июнендә Оренбург һәм аңа чиктәш булган Вятка, Пермь, Саратов губерналарындагы башкорт-мещеряк гаскәренең кайбер волостьләре урнашкан җирләрдә ызанлау эшләрен башлап җибәрү хакында указ чыккан. Бу указда, башкортлар җирләренең үзләренеке булуын исбатлый алган очракта, бу фактны тану тиешлеге дә күрсәтелгән. Борынгы ярлыкаш грамоталарын күрсәтә алганнарга ызанланган дачаның барлык җирен дә хуҗаларына бирү каралган була. Бәхәсле җирләрнең үзләренеке булуын исбатлау өчен дача җирлегендә яшәүчеләр, ярлыкаш грамоталарыннан кала, писцовый кенәгәләрдән алган күчермәләр, ясак түләгәндә бирелгән квитанцияләр, хөкем карарлары, пүнәтәй-шаһитларның күрсәтүләрен дә куллана алганнар.

Бәзәкәдә генераль ызанлау 1805 елда башланган. Архивларда сакланган документлар безгә бу эшнең барышын да, Бәзәкә биләмәсенең күләмен дә күзалларга мөмкинлек бирә. Бәзәкә җирләренең Байлар волостенә яки аның 23-нче йортына кергән авыллар белән бергә түгел, ә аерым дача буларак каралуына игътибар итик. Архивта Бәзәкә дачасының геометрик планы да сакланган (Кушымта № 10). Планның башында бирелгән язмада ызанлауны башкаручылар һәм эш барышы хакында да мәгълүмат бар. Ул безгә җирләрнең күләмен, чикләрен, составы нинди булганлыгын ачык күрсәтә. Кызганыч, план белән бергә дачаның географик ориентирлары белән чикләре язылган ызанлау кенәгәсе табылмады. Шулай да, бу документның безнең көннәргә килеп җитүенә дә рәхмәтле булырга кирәк.

Бәзәкәдә ызанлау эшләре өлкән землемер коллежский асессор Коев җитәкчелегендә 1805 елның 8 августында башланган. Коевның чирләп китүе аркасында эшне коллежский регистратор Петр Малинин дәвам иткән. Вятка ызанлау конторасы карары белән эшне 1807 елның октябрендә кече землемер губернский секретарь Кирила Петров тәмамлаган. Башкала органнарында исә Бәзәкә дачасының чикләрен билгеләгән документларны раслау чирек гасыр кадәр вакытны таләп иткән: Сенатның межалаштыру департаменты

аларны 1829 елның 23 маенда гына раслаган. Ызанлау эшләренең Бәзәкәдә озакка сузылуы, бер яктан, Русиядә бюрократик машина күчәрләренең бик зур авырлык белән генә әйләнүен тасвирласа, икенче яктан, Бәзәкә халкына җирләрнең законлы рәвештә үзләренеке булуын исбатлау өчен дә шактый тырышырга кирәк булуын күрсәтә.

Бәзәкә дачасын тасвирлауга күчәм. Геометрик махсус планда Бәзәкә дачасының сызымнары бирелгән, аңа кергән җирләрнең төрләре һәм күләме дә җентекләп язылган. Бәзәкә дачасында барлыгы ***4358 дисәтинә 433 сажин,*** эшкә ярамаган җирләрдән башка ***4051 дисәтинә 1320 сажин*** җир булган (1 дисәтинә /2400 квадрат сажин/ хәзерге чама белән 1,09 га, 1 сажин – 2,13 м тәшкил иткән) Җирләрнең төрләренә дә күз салыйк:

сөрүлек җирләре — *903 дисәтинә 625 сажин;*

печәнлек җирләре (болын) — *507 дисәтинә 1054 сажин;*

әрәмә арасындагы печәнлекләр — *224 дисәтинә 1109 сажин;*

төзү эшләренә яраклы урман — *1180 дисәтинә 945 сажин;*

сазлыкта утынга яраклы агачлыклар - *1199 дисәтинә 1668 сажин;*

авылда хуҗалыклар урнашкан җирләр (яшелчәлекләр, киндер һәм җитен чәчүлекләре белән) - *36 дисәтинә 718 сажин;*

йөри торган юллар астындагы җирләр - 13 *дисәтинә 418 сажин;*

комлыклар — *54 дисәтинә 1015 сажин;*

Кама елгасы буйлап бурлаклар йөри торган комлы җирләр (бечевник) — *28 дисәтинә 1080* сажин;

Кама елгасының яртысы астындагы җирләр - *139 дисәтинә 1776 сажин;*

елга-күлләр һәм башка сулыклар астындагы җирләр — *58 дисәтинә 1215 сажин;*

сазлыклар астындагы җирләр — *12 дисәтинә 809 сажин.*

Шушы җирләр махсус межа белән билгеләнгән һәм рәсми рәвештә Бәзәкә дачасы дип аталган. Бәзәкә халкының күләме хакында соңгы бишенче ревизиядә алынган мәгълүмат китерелгән. Анда 1795 елда авылда 95 хуҗалыкта башкортлар 244 ир-ат, 261 хатын-кыз, типтәрләр 22 ир-ат, 11 хатын-кыз яшәгәне күрсәтелгән.

Дачага кергән җирләрне күзәтеп алыйк. Кулланышка яраклы җирләрнең күләме ***4051 дисәтинә 1320 сажин,*** яки, җан исәбеннән карасак, бер ир-атка 15 дисәтинә 2298 сажин эшкә яраклы җир туры килгән. Санавыбызны дәвам итик: бер җанга сөрүлек җирләре 3,395 дисәтинә, 1,9 дисәтинә болын, 0,8 дисәтинә әрәмә арасындагы печәнлекләр туры килгән. Авыл эчендә бер хуҗалык якынча 0,38 дисәтинә (913,03 сажин) җирне биләгән. Бәзәкә дачасы җирләренең яртысыннан артыгын урманнар каплаган булган. Планнан күренгәнчә, Кама белән авыл арасындагы үзәнлектә әрәмә (русчадан туры тәрҗемә - сазлыктагы утынлык урманы) һәм болынлыклар булган, ә инешнең сул ягындагы җирләрдә (калкулыкта) кара урман үскән. Дачаның башка бүлемтекләренә игътибар итик. “Кама елгасының яртысы астындагы җирләр” - бу билгеләмә бәзәкәләләрнең балыкчылык белән шөгыльләнергә (яки арендага бирергә) хокуклары булуын күрсәткән. Алар Кама ярындагы җирләргә генә түгел, ә елгага да - уртасына кадәр - хуҗа саналганнар икән.

Бечевник (бечева – аркан) – елга һәм күлләрнең ярлары буйлап сузылган елгада йөк ташу өчен кулланылган юлның исеме. XIX гасыр башында, пароход-буксирлар әле булмаган чорда, йөкләрне баржаларда су юлы белән кешеләр (бурлаклар) яки атлар тартып күчергәннәр; бу гамәл аркан тарту дип аталган. Гомумән, сулыкларның күп булуына игътибар итик – 198 дисәтинә 591 сажин. Монда Кама елгасы да, әрәмәдәге күпсанлы күлләр дә, култык-ермаклар да, инешләр дә, хәтта йөкләрне бер сулыктан икенчесенә, мәсәлән, күлдән-күлгә күчерер өчен табигый яки махсус эшләнгән каналлар (“волошная речка”) да исәпкә алынган. Әгәр дә авыл биләмәсенә кергән җирләрнең сызымын игътибар белән карасак, ул заманда, Кама елгасыннан комлыклар белән генә аерылып, берничә чакрымга сузылган Кәзәнгеш исемле күлләр булган. Аларны бер-берсе белән шул ук исемле инеш-елгалар тоташтырган.

Хәзер авылның план-сызымына күз салыйк. Планнан аның ничек урнашканлыгын аңларга була. XIX гасыр башындагы авыл хәзерге Бәзәкәнең көнъягында якынча өчтән бер өлешен алып торганлыгы күренә. Авылның көнбатышында (Сәйтәк ягында) юл аркылы урнашкан озынча өлешен типтәрләр яшәгән урын дип фаразларга була. Төп өлеше җиде кисәктән торганына да игътибар итик. Мондый бүленеш борынгыдан килгән нәселләрнең аерым-аерым укмашып яшәвен күрсәткән.

Ызанлау командасы махсус план белән бергә икътисадый журнал да (*икътисадый искәрмәләр*) тутырган. Бу искәрмәләр безгә авылыбызның моннан 200 ел элек, XIX гасыр башындагы халәтен ачык күзаллау мөмкинлеген бирә.

Икътисадый искәрмәләрнең эчтәлегенә тукталыйк. “Бәзәкә авылы Бәзәкә инешенең уң ягында урнашкан, ә дачасы Кама елгасына кадәр сузылган. Аңа Козы күле һәм чишмәсе башы, Четкуки (Кече күл?) һәм Пинәрә күлләре, Сәйтәк чокыры, Коры һәм төрле исем белән йөри торган табигый ызанның уң ягы, Исемсез чокырлар, Курбаж (Корбансу?) чокырларының өске өлеше, Кусяш, Безынкина (Бәзәкә?) инешләре, Коры чокыр, Иске Бәзәкә, Лурт (Олы Сырт?) тамаклары, Кече, Олы, Елтык, Казы, Кәзәндеш һәм башка бик күп исемсез күлләр һәм чишмәләр”, - дип күрсәтелгән Бәзәкә җирлегенең чикләре. Берничәсен аңлатып китим. Бу атамалар авыл җирлегенең планында да күрсәтелгән. Мәсәлән, Исемсез чокырлар Кызлар чокыры булырга тиеш, Курбаж - аннан төньяккарак урнашкан, планда Корбансу чокыры дип күрсәтелгән чокыр булса кирәк, Кусяш инеше буена Тәкәш авылы урнашкан булган (планда “деревня на речке Кусяш, Текашево тож” дип язылган), Безынкина – Бәзәкә инеше, Коры һәм төрле исемнәр белән йөри торган чокыр – Тарлау чокыры, Четкуки – Кече күл булырга тиеш.

Географик атамаларның барлыгы да диярлек, русча язылышта үзгәрсәләр дә, бүгенге бәзәкәлеләрнең күбесенә таныш. Бәхтегәрәева (Сәгдиева) Әлфинә язып җибәргән исемнәр белән чагыштырыйк: “Ык Тамагы ягыннан киләм. Күлләр: Урыс күле, Караңгы күл, Якты күл, Кәзәнгеш, Олы күл, Кече күл, Пинәрә (Морат тамагы Олы Пинәрә белән Чат

Пинәрәне тоташтыра иде), Тәңкәле күл. Әрәмә өчкә бүленгән иде. Олы болын юлыннан барганда уң якта яшелчәлек, аннары әрәмә түмгәклек белән, сул якта Биш имән сырты – Олы әрәмәгә керә. Авыл каршында Маймырда (Майморза), аннан Сәйтәк әрәмәсе, күгәнлек. Әүлия каберлегеннән аска төшкәч, Ар юлы. Ул барып чыга Олы күл буена, зиреклеккә. Андагы хозурлык! Чәчәкләр, йодрык хәтле гвоздикаларга кадәр үсә иде. Заповедник иде бит әрәмә. Тау буенда чиялек, умарталык. Умарталыктан соң Сәйдәл сыртында беләк юанлык еланнар түмгәккә уралып ята иде. Киттек югары очка. Асфальттан сул якка китә Мошай чокыры. Аннары Пан зираты, Пан чишмәсе, Кәбеләй бүәсе (хәзер дә бүәләр), Кызлар чокыры, Тукмаклы, Тиҗек басуы, Тиҗек зираты...”.

Безнең әтиебез Мәхмүтов Хаҗиәхмәт (1900-1980) тә Бәзәкә тирәсендәге җирләрнең һәм әрәмәдәге күлләрнең исемнәрен бик яхшы белә иде. Мин аннан бервакыт әрәмәдәге юлларны язып алган идем. Авылдан болын-әрәмә аша Кама буена алып бара торган биш юлны билгеләгән иде ул. Аның берсе, авыл каршындагы Майморза (Майморда) дип аталган баткак-камышлы җирдән чыгып, Шәмәрәй түбәсе аркылы Каенлы җилән тамагына барган юл; икенчесе – Иске Бәзәкә сыртына илтә торган Минәч юлы; өченчесе – Пинәрә күленең югары башына, Барлас тамагына илтүче Сәйдәл юлы; дүртенчесе – Киндер күле, Яман тал дигән урынга алып бара торган Тау буе юлы; бишенчесе - Ар юлы, ул Олы җилән, Кече җиләннәр аша Олы күл, Кече күл буйларына, Ар болынына барган юл. Кызганыч, бу җирләр, Түбәнкама сусаклагычы төзелгәннән соң, барысы да су астында калды. Исемнәре дә халык хәтереннән югалып бара.

Икътисадый искәрмәләрдә күрсәтелгән табигый байлыклар да игътибарны җәлеп итәрлек: “Күрсәтелгән Кама елгасының җәйге эссе вакытта киңлеге 300-350 сажин, тирәнлеге 3 сажиннан башлап. Анда кырлы (белуга), мәрсин (осетр), җәен (сом), укборын (севрюга) балыклары, ак һәм кызыл балык, чөгә (стерлядь), алабуга (окунь), шыртлака (ерш), сагалак (голец), ташбаш (пескарь) һәм башка вак балыклар. Инешләрнең агымы бик кечкенә, аларда балык юк. Каз, Кандыш, Пинәр, Казандыш күлләренең киңлеге 6-10 сажин, тирәнлеге 1-2 сажин тирәсе. Алардагы кәрәкә (карась) һәм карабалыкны (линь) мондагы халык үзе өчен тота. Елга, инешләр һәм күлләрнең суы бик чиста, халык үзе эчәр өчен һәм терлек өчен куллана”. Бу тасвирламада күрсәтелгән балыктан безнең бабайлар күлдәге балыкны гына үзләре өчен тотканнар. Ә затлы Кама балыклары борын-борыннан ясак һәм оброк түләү өчен киткән. Балык тоту җирләре оброк түләү шарты белән арендага да бирелгән.

Искәрмәләрдә бәзәкәләләр кулланышында булган чәчүлекләр һәм болын-урманнарга тасвирлама да бар: “Җир кара туфраклы, кайбер урыннарда соры балчыклы. Ашлаганда анда арыш, арпа, солы, бодай яхшырак үсә, ә башка орлыклар уртача. Печәнлекләрдә үләннәр бик яхшы була. Урманнар коры җирдә үзәнлекләрдә дә, сазлыкларда да үсә; төзү эшенә китә торган һәм утын итеп куллана торган агачлар да бар. Урманнарда куян һәм башка җәнлекләр дә очрый; кошлар күптөрле: миләш чыпчыгы,

сандугач, сары чыпчык, песнәк, купшы чыпчык, суларда кыр үрдәкләре һәм төрле шөлдиләр һәм башкалар”. Шулай итеп, бу искәрмәләрдән без бабаларыбызның моннан 200 ел элек чәчкән ашлыкларын, чапкан печәннәрен, эчкән суларын гына түгел, урманнарда нинди кошлар сайравын да күз алдына китерә алабыз.

Халыкның шөгыльләре хакында да мәгълүмат бирелгән бу документта: “Крестьяннар билгеләнгән казна окладында торалар, игенчелек һәм терлекчелек белән бик тырышып шөгыльләнәләр. Тормышлары уртакул. Хатын-кызлар, кыр эшләреннән тыш, өйләрендә кул эшләре белән мәшгуль, җитен, киндер һәм сарык йонын эрлиләр, үзләре өчен, кайбер вакытта сату өчен дә, киндер, җитен, постау сугалар”. Шулай итеп бабаларыбызның төп шөгыле иген игү һәм терлек үстерү булган. Яхшы уңыш бирә торган арыш, арпа, солы, бодайдан кала, алар, уңышы бик мактанырлык булмаса да, борай, борчак, карабодай кебек ашлыкларны да чәчкәннәр. Өйләре кырында яшелчәлекләре дә булган, алар үстергән яшелчәнең исемнәре генә әйтелмәгән. Безнең әби-бабаларыбыз җитен һәм киндер дә чәчкәннәр. Үзләре үстергән киндер һәм җитен сабагын эшкәртеп, сүс-пәҗе хәзерләгәннәр, җеп эрләгәннәр, төрле тукымалар, келәм, чүпләмле сөлгеләр тукыган-сукканнар, күлмәк-ыштан, чикмән һәм башка өс-баш киемнәрен теккәннәр. Хуҗалыкта кирәк була торган ат сбруе-дирбиясе, аркан, дилбегә, бау кебек башка кирәк-яракка да сүс-пәҗе җитәрлек булган.

Хуҗалыкта терлекчелек зур урын алып торган. Мал-туардан ат, сыер, сарык, кәҗә асраганнар. “Татар ат өстендә туа, ат өстендә үлә” дигән заманда яшәгән безнең бабаларыбыз өчен ат иң кыймметле мал саналган. Атына атланып гаскәри хезмәтен башкарганда, ул иксез-чиксез Оренбург далаларын гизгән, озын-озак айларга (елларга да) сузылган ил чикләрен саклаганда, аның аты сердәше дә, таянычы да булган. Күндәм, чыдам атларга авылда да эш җитәрлек булган. Атын җигеп, бабаларыбыз җирләрен дә сукалаган-тырмалаган, утынын-печәнен дә ташыган.

Бәзәкә халкы элек-электән сарык асрау белән дә шөгыльләнгән. Йорт саен ким дигәндә ике-өч баш, хәллерәк яки ишлерәк гаиләләрдә күбрәк тә сарык асраганнар. “Сарыктан ит тә, май да, йон да, тун да, итек тә, читек тә була”, - дигәннәр безең бабайлар. Сарыкларны кыркып, аның йонынан тула, киез басканнар, җеп эрләп, бияләй, оек-оекбаш, җылы камзул, шәлләр дә бәйләгәннәр. Сарык йоны төрле тукымалар тукырга (постау – сукно сугуга) да кулланылган. Ул тукымалардан кием-салым җитештергәннәр. Сарык тиресеннән тун, толып, бүрек, хәтта юл йөрү өчен җылы чалбарга кадәр теккәннәр. Сарык итенең гаять туклыклы ризык саналганлыгын да искә алыйк. Асылда, безнең әби-бабаларыбыз хуҗалыкта кирәк булган бар нәрсәне үзләре хәстәрләгән, ягъни натураль хуҗалык алып барган.

Тормышларының нигезе булган игенчелек, терлекчелектән кала бабаларыбыз аучылык, балыкчылык, умартачылык (чолыкчылык) кебек шөгыльләрне дә ят итмәгәннәр. Бу юл белән тапкан мал-табышның күп өлеше ясакка китсә дә, үз хуҗалыкларына да ярдәме булган. “Билгеләнгән казна окладында торалар” дигән сүзләргә игътибар итик. Дәүләт (казна)

крестьяннары саналган авыл халкы “оклад”, ягъни үзләренә йөкләнгән салымнарны түләргә тиеш булган. Алар ике төрле – казнага түләнә торган салымнар һәм җирле салымнар. Казна салымнарын бәзәкәләләр башкорт гаскәрендә хезмәт итүгә алмаштырганнар. Җирле салым-йөкләмәләрне алар башкалар белән тигез үтәргә тиеш булганнар. Җирле салымнарны губерна идарәсе авылларга тараткан, ә авылларда алар, яңа туган малай яки соңгы ревизиядән соң үлгән кеше булуына карамастан, җан исәбеннән чыгып бүленгән.

1850 елда, мәсәлән, Вятка губернасында акчалата җирле салым бер җан башына елга 28,5 көмеш тиен туры килгән. Кайбер елларда бу салым 60 тиенгә кадәр күтәрелгән. Хәзерге күзлектән караганда, бу акча тузан бөртеге кебек кенә күренсә дә, ул заманда натураль хуҗалык белән яшәгән кешегә аны табу да бик авырга туры килгән. Җирле йөкләмәләр арасында юл эшләре дә булган. Аның өчен дә еш кына акча җыелган. Мәсәлән, 1817-1818 елларда казнаныкы саналган зур юл-күперләрне төзәтү һәм тоту өчен башкорт гаскәрендәгеләргә җан башыннан 25 тиен акчалата салым билгеләнгән. Аннан соңгы елларда алар бу хезмәтне үзләре башкарган. Акчалата түләүләрне үтәү ашлык уңмаган елларда бигрәк тә авырга туры килгән. Йөкләмәләрнең бар авырлыгы гади кешегә туры килгән, чөнки авыл башлыклары һәм мулла барлык салым-йөкләмәләрдән азат булганнар.

Тагын бер җирле йөкләмә – олаучылык вазифаларын үтәү булган. Халык өстенә җирле (өяз, волость, авыл) чиновникларны һәм аларның йомышчыларын бушлай йөртү йөкләнгән. Олаучылык йөкләмәсен үтәү, акчага күчергәндә, бер хуҗалыкка бер елга уртача 3 сумга төшкән. Төрле түрәләрнең күплеге, аларның губерна эчендәге күпсанлы йөрүләре өстенә “ям чабу (почта йөртү)” йөкләмәсен дә күрсәтергә кирәк. Почта, эстафета һәм курьерларны халык губернатор карары буенча чиратлап йөрткән. Моның өчен бу йөкләмәне үтәргә тиешле кешеләр һәрвакыт почта станцияләрендә әзер торырга тиеш булганнар. Аларны авыл җәмгыяте олаулар белән тәэмин итәргә һәм командировка вакытына җитәрлек ашлык бирергә тиеш булган. Олауга ике ат, таза-нык җигү кирәк-яраклары һәм арба (чана), тиешле корал кергән. Сигез пот ашлык һәм фураж белән тәэмин ителүләрен дә исәпләргә кирәк. Бу хезмәткә билгеләнүчеләр таза-сау урта яшьтәге кешеләр булуы таләп ителгән.

Бу һәм башка йөкләмәләрне үтәүне Вятка губернасының җирле түрәләре дә, хәрби идарә дә таләп иткән, чөнки Бәзәкә халкы башкорт-мишәр гаскәре башлыгы булган Оренбург хәрби губернаторына буйсынган. Ягъни төрле йөкләмәләрне үтәүне, бер яктан, алардан Вятка губернаторы таләп итсә, икенче яктан, башкорт казаклары катламында хезмәттә саналган халык тагын бер төркем хәрби хезмәткә караган йөкләмәләрне үтәргә тиеш булган. Икеләтә басымның алар тормышында зур авырлыклар тудыруын аңлатып торасы да юк.

“Рымбур юллары такыр...”

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Габдулла Тукай

Башкорт гаскәре XVIII гасырның урталарында ук формалаша башлаган. Аның составына кергән халыкның вазифалары акрынлап үзгәрә – өстәлә барган һәм XIX гасыр башында бербөтен йөкләмәләр комплексы булып киткән. Шул йөкләмә-бурычлар хакында сүз алып барыйк. Йөкләмәләр барлык регуляр булмаган гаскәрләр өчен бертөрле булган һәм махсус документларда беркетелгән. Бу гаскәрләр өчен төп йөкләмә, төп хезмәт – чик буен саклау булган. Оренбург чик буе линиясе XVIII гасырның 30-елларында ук салына башлаган була. Ул Тобол елгасыннан Каспий диңгезенә кадәр сузылган һәм биш дистанциягә бүленгән. Шушы линияне (чикләрне) төзү һәм саклауның бар авырлыклары Оренбург казак гаскәре белән бергә Башкорт-мещеряк гаскәре җилкәсенә төшкән.

Бу гаскәрдәге мәҗбүри хезмәт типсә тимер өзәрлек ир-егетләрне дә, аларның атларын да озак вакытларга хуҗалык эшләреннән аерган. Канун буенча, гаскәри хезмәткә 20 яшьтән 50 яшькә кадәр булган ир-атлар чиратлап җибәрелгән. 17-20 яшьлек егетләр гаскәргә хәзерлек төркемен тәшкил иткән. 17 яшен тутырган егетләрне аерым учетка алганнар. Сәламәтлекләрен тикшергәннән соң, хәрби хезмәткә яраклы егетләрне махсус кенәгәләргә теркәгәннәр һәм чик буен саклау хезмәтенә чиратка куйганнар. Тыныч вакытта һәрбер ир-атның ярты еллык чик буен саклау хезмәтенә китү чираты 4-5 елга бер тапкыр булган. Нәрәтнең зурлыгы хуҗалык яки хәрби хезмәткә яраклы кеше санына бәйле булган.

Оренбург линиясендә 1742-43 елларда ук башланган чик саклау хезмәтендә кирәк булган әйберләр башкорт гаскәрендәгеләрнең үз хисабына тәэмин ителгән. Әлбәттә, күп хуҗалыклар нәрәткә җибәрелә торган кешене үзләре генә кирәк-ярак белән тәэмин итә алмаслар иде. Бу очракта авыл җәмгыяте ярдәмгә килгән. Уртача алганда, бер кешене кирәкле әйберләр белән тәэмин итү 4-5 хуҗалыкка туры килгән. Мөмкинлеге булмаган казакларга– корал, ике ат (берсе йөк аты), азык-төлек, хәтта башкорт казагы киемен - формасын да җәмгыять хәзерләп биргән. Линиягә киткәндә һәр казакка авыл җәмгыятеннән 8 пот он һәм 1 пот ярма бирелгән. Моннан тыш авылдашлар китүчеләргә тиешле урынга барып җиткәнче туклану өчен азык-төлек һәм “подможный” дип аталган акча да биргәннәр. Бу акча авылдашлар арасында төрле кантоннарда җан башыннан 27-45 тиеннән алып 40-75 тиенгә кадәр җыела торган булган (XIX гасырның 50-60-елларында бер кешене хезмәткә хәзерләү көмеш акча белән 49-64 сумга кадәр җиткән). Шулай итеп, хәрби хезмәтнең авырлыгы бөтен халык җилкәсенә төшкән. Ерак юлга чыккан командалар җыелу пунктыннан 100 чакрым ерагайгач кына казна хисабына күчкәннәр. 1797 елгы указ буенча җәйге нәрәттә булганнарга аена берәр сум акча бирә башлаганнар, ләкин бу акча казак чыгымының бик кечкенә өлешен капларга гына җиткән.

Линиядәге хезмәт икегә – алтышар айлык җәйге һәм кышкы нәрәткә бүленеп башкарылган. Җәйге хезмәт 16 майдан 15 ноябрьгә, кышкысы 16 ноябрьдән 15 майга кадәр барган. Кышкы нәрәткә кечкенәрәк команда җибәрелгән, чөнки кыш көннәрендә чик буе тынычырак булган. Ләкин нәрәт хезмәтенә киткән вакыт алты ай белән генә чикләнмәгән, чөнки ул даталар чик саклау вакытын гына билгеләгән. Линиядәге ныгытмаларга вакытында килеп җитү өчен алар авылларыннан 1-2 ай алдан чыгып китәргә тиеш булганнар.

Билгеләнгән кагыйдә буенча, линиягә бара яки аннан кайта торган командаларны кабул итү – озату эшен башкортлардан билгеләнгән дистанция (чик буеның аерым бер өлеше) начальнигы башкарган. Аларны (һәр кантонга өчәр кеше) кантон башлыгы билгеләгән һәм губернатор раслаган. Йорт старшиналары, үз авылларыннан җыйган башкорт казаклары командаларын кантон үзәгенә алып килеп, исемлек буеча кантон башлыгына тапшырган. Кантон башлыгы, үз чиратында, шулай ук исемлек буенча, линиягә китәргә тиешле казакларны дистанция башлыкларына тапшырган. Болары исә, кабул итеп алганда, китүченең чираты саклануын һәм яше туры килүен, һәрберсенең ике аты һәм ияр-дирбияләренең нык һәм җитешле булуын бик җентекләп тикшергән. Аларның мундир-амуницияләре, азык-төлек һәм ярдәм акчалары опись буенча кабул ителгән. Шуннан соң гына дистанция башлыклары кабул итеп алынган нәрсәләрнең санын һәм эшкә яраклылыгын күрсәткән квитанция биргән. Шулай кантоннан җыелган командалар линиягә җибәрелгән. Анда казаклар ныгытмаларга (крепость һәм редутларга) таратылган. Линиядә хезмәт итү шартлары шактый авыр һәм кырыс булган.

1745 елдан башлап, Оренбург линиясен саклаудан тыш, башкортлардан торган мең кешелек команда Себер чикләрен сакларга да җибәрелгән. Бу хезмәт тагын да авыррак саналган, чөнки ерак җирләргә бер елга китәргә кирәк булган. Башкорт-казаклар арасында көчле канәгатьсезлек сизелә башлагач, 1800 елда линия хезмәте этап хезмәте белән алмаштырылган, ягъни башкорт нәрәтләренә Себергә сөргенгә җибәрелгәннәрне озату хезмәте йөкләнгән. Бер еллык булган бу хезмәт тә җиңел булмаган. Этап хезмәтен башкорт нәрәтләре XIX гасырның 40-елларына кадәр башкарган. Моннан тыш башкорт полклары илнең көнбатыш чикләрен саклауда да катнашкан. Көнбатыш хезмәте, гадәттә, берничә елга сузылган. Башкорт гаскәре зур шәһәрләрдә һәм ярминкәләрдә тәртип саклау, качкыннарны эзләү һәм тоту, халык чуалышларын бастыру кебек полиция хезмәтен башкаруга да тартылган.

Империянең Урта Азиядә алып барган актив сәясәте Русиягә яңа төбәкләрне кушуга һәм дәүләт чикләрен киңәйтүгә алып барган. Бу сәбәпләр Оренбург линиясендәге хезмәтнең кирәклеген киметкән. Хөкүмәт эзлекле рәвештә башкорт гаскәренең линия хезмәтен эш хезмәтенә алмаштыра башлаган. Моның өчен махсус кертелгән хезмәт йөкләмәсе нигезендә башкорт казакларыннан торган эшче командалар оештырылган. Аларны төрле казна эшләрен башкару өчен кулланганнар. Хөкүмәт, беренче чиратта, Башкорт-мещеряк гаскәрендәге казакларны Оренбург төбәгендәге хәрби

корылмаларны төзү эшенә тарткан. Бу эшләрне бушлай башкаручы командаларга җибәрелгән казаклар саны елдан-ел арткан, тора-бара казна эше Башкорт гаскәренең төп хәрби хезмәте булып киткән. XIX гасырның 40-еллары азагыннан линия хезмәтенә нәрәтнең 14%, ә эш хезмәтенә һәм транспорт командаларына 86% туры килгән. Мондый кискен үзгәрешләрнең сәбәбе – Оренбург губернасының чик буендагы төбәктән акрынлап ил эчендәге өлкә булып китүе булган.

Эш хезмәтендә булган эшче командалар XIX гасырның 30 елларында 252 чакрымга сузылган Верхнеуральск – Эстәрлетамак арасындагы “сәүдә” трактын төзегән (урман кисү һәм төпләү, юл буйлап канаулар казу, күперләр салу, юлны билгеләүче кыска баганалар - “надолблар” һәм чакрым баганаларын җиргә казып урнаштыру h.б. эшләр). Соңрак бу юл Бөгелмәгә кадәр сузылган. Оренбург линиясен “турайту” максатыннан чыгып, 1835-1838- елларда Орск — Троицк арасында яңа чик буе корылмалары төзелгән. Бу эшне дә башкорт эш командалары башкарган.

Чиксез авыр хезмәт “транспорт командаларына” эләккәннәр җилкәсенә төшкән. Үзләренең җигүле атлары, арба-чаналары белән олаучылык вазифасын үтәргә тиешле бу командага эләккән башкорт казаклары, бернинди түләүсез, Оренбург һәм яңа крепостьларга азык-төлек, утын, төзү материаллары ташыган. Йөкләрен китереп тапшыргач, шушы ук отрядлар линия буенда яшәүче казаклар өчен печән хәзерләүгә тартылганнар. Башкорт гаскәре Русиягә яңа кушылган җирләрдәге ныгытма - корылмалар төзүдә дә катнашкан. Оренбург, Уфа кебек шәһәрләрне төзекләндерүдә, алардагы корылмаларны (мәсәлән, Оренбургтагы Кәрван-Сарайны) төзүдә дә күп көч куйган башкорт командалары. Почта йөртү йөкләмәсен дә искә төшерик.

Хәрби идарә таләбе белән башкарылган бу озак вакытка сузылган командировкалар халыкның төп шөгыле булган игенчелек, терлекчелек эшләрен алып баруны катлауландырган. Шуңа күрә кайбер эшләрне (мәсәлән, почта хезмәтен) башкару өчен алар линия буенда яшәүче Оренбург гаскәре казакларын яллый торган булганнар. Ялланган казакларга алар дирбия-сбруе белән үз атларын һәм арба-чаналарын да биргән. 1828 елда хәрби губернатор башкортларга почта йөртү өчен башка гаскәрләрдән дә наемщиклар яллауны рөхсәт итәргә мәҗбүр булган. Бу эшне кыш айларында башкарырга риза булган наемщикларга башкортлар һәр пар ат өчен ассигнация (кәгазь акча) белән 160-175 сумга кадәр түләгәннәр. Сүз уңаеннан искәртим: XIX гасырда киң кулланышка кергән кәгазь акчаларның бернинди гарантиясе булмаган; аның 1сумы көмеш акчага 3 тиеннән 25 тиенгә кадәр туры килгән.

Бөтен Оренбург линиясе буйлап почта йөртү хезмәтләрен башкару өчен башкорт гаскәреннән 204 пар ат таләп ителгән. Натуралата бирелгән азык-төлек һәм фуражны, шулай ук акчалата бу эшне башкаручыга бирелә торган ярдәм акчасын да санаганда, һәр пар ат ассигнация белән 250-350 сумга төшкән. Барлык башкорт кантоннарына почта йөртү йөкләмәсен үтәү өчен төрле вакытта һәр елны 80 меңнән 100 меңгә кадәр кәгазь акча кирәк булган. Җан башыннан санаганда, һәр кеше 30 тиеннән 1 сум 70 тиенгә кадәр

(кантон белән линия арасының зурлыгына карап) почта салымы түләгән.

Болардан тыш халык өстенә төшкән башка чыгымнар да сизелерлек булган. Мисал итеп, ревизия документларын тутыру, язу эшләрен башкаручыга түләү һәм махсус (герблы) кәгазь өчен җан башыннан иллешәр тиен җыелуны әйтергә мөмкин. Әле аларны язучыларга ашлык белән дә түләгәннәр. Бу җыемнар башта очраклы булса, соңрак даими бюрократик изү коралы булып киткән. Җирле түрәләрнең вотчина җирләрен киметергә тырышулары, соңрак бу җирләргә килеп урнашкан халыкның урман-печәнлекләрне законсыз басып алулары монда яшәүче халыкка зыян китергән, һәм аларны дәүләт оешмаларына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр иткән. Төрле үтенеч-шикаятләр язу өчен дә герблы кәгазь кирәк булган, төрледән-төрле штрафлар да халык җилкәсенә төшкән. Шундый һәрбер кәгазьне тутыру өчен 3 сумга кадәр чыгым кирәк булган. Мәсәлән, безнең бабаларыбызга үз җирләрендә вотчина хокукларын саклап калыр өчен ярты гасырдан артык дәгъвалашырга туры килүен исәпкә алсак, бу вакыт эчендә күпме рәсми кәгазь язылганын да, аңа күпме акча киткәнен дә чамаларга була. Бу теманы йомгаклап, шуны да әйтергә кирәк: башкорт гаскәрендәге хезмәт авыр булса да, ул хезмәттә катнашканнарның аң-белеме артуына да игътибар итик. Юкка гына татар халкында “Йөргән таш шомара” дигән әйтем барлыкка килмәгәндер. Казаклар йөргән яңа урыннар, төрле халыклар, башка телләр белән танышканнар, “дөнья күргәннәр”.

Вотчина җирләре өчен дәгъвалашу

Әти-әни, Ватан һәм дә икмәк!
Бу сүзләрдә – тормыш мәгънәсе.
Бәхет, хезмәт, ирек, яшәү яме –
Шул сүзләргә бәйле һәммәсе.

Энҗе Мөэминова

Бәзәкә вотчинасының тарихы Кама буе - Вятка (Нократ) якларында XVII-XIX гасырларда булган иҗтимагый-икътисадый вәзгыятьне, бу җирлеккә килеп чыккан төрле диндәге халыкларның күчеш-урнашу һәм үзара мөнәсәбәтләрен күзалларга ярдәм итә. Шул ук вакытта илнең кечкенә генә күзәнәге булган авыл мисалында безгә хакимият алып барган рус булмаган халыкларны кысрыклау, аларның хокукларын (бигрәк тә җир хокукларын) чикләү сәясәтен дә күрү, аңлау мөмкинлекләре туа. Хәтта вотчина хокукын раслаучы рәсми кәгазьләре булган бәзәкәлеләргә дә бу сәясәтне үз язмышларында татырга туры килгән. Үз вотчиналары өчен озакка сузылган көрәш бу җирләрнең чикләрен билгеләүдән башланган. Бу хактагы материаллар Казанда Милли архивта Алабуга өяз суды фондында саклана. Күптөрле документлардан торган 184 битле папка “Алабуга һәм Сарапул өязендәге башкорт һәм типтәрләрнең җирбиләүчелек хокуклары хакындагы эш” дип атала (Кушымта № 12).

Межалаштыру эшләре Бәзәкәдә 1805 елның 16 сентябрендә узган. Бу эшкә керешкәндә үк бабаларыбыз үзләренеке дип санаган күп кенә

кишәрлекләрнең биләмә чикләренә кертелмәве, бу җирләргә күрше авылларның дәгъва итүләре ачыкланган. Межалаштыру эшен башкаручылар, күпсанлы кәгазьләрне тутырганнан соң, 1807 елның 2 январендә Вятка межалаштыру конторасы Бәзәкә җирләре хакында катгый карар кабул ителүен дәгъвачыларга җиткергән. Бу карар 14 январьда Сенатның беренче һәм алтынчы департаментларына, ә 29-30 январьда Вятка казна палатасы һәм Уфа экспедициясенә җибәрелгән. Шулай җирле түрәләр бу эш тәмамланды, бәхәсләр бетерелергә тиеш дигән карар кабул иткәннәр.

Ләкин бәзәкәлеләрне бу карар канәгатьләндермәгән. Һәм алар Мәскәүдә урнашкан межалаштыру канцеляриясенә Вятка межалаштыру конторасының карарына шикаять белән мөрәҗәгать иткәннәр. Шикаятьтә Бәзәкә авылының 7205 (1697) елда Петр I раслаган ярлыкау грамотасы һәм 207 (1699) елда воевода Кудрявцовтан алган күчермәгә таянып, вотчина хокукы булуы нигезләнгән. Бәзәкәлеләр бабаларының үз җирләренең кайбер өлешләрен Богородское (Ык Тамагы), Богоявленское (Озын Тау), Сәйтәк, Тәкәш, Макар Тоймасы, Сарсаз, Песәй һәм башка күрше авыл кешеләренә – крестьян (урыс), чирмеш, татар һәм типтәрләргә, шулай ук Иске Җөмҗә арларына Камадагы атауны чистартуны - килешенгән түләү хакына вакытлыча биреп торуларын да язганнар. Ләкин күршеләре бәзәкәлеләрнең җирләрендә рөхсәтсез урман төпләгәннәр, авылларын нигезләгәннәр һәм башка явызлыклар кылганнар. Бу хакта бәзәкәлеләр 1784, 1794 һәм 1803 елларда Минзәлә өяз судына шикаятьләрен дә белдергән булганнар.

Моның өстенә, авыл янында ук Бәзәкә инешенең ике ягындагы печәнлек болыннарының күп еллар элек Бәзәкә биләмәсеннән казна оброгына алынуының хаксызлыгыннан, бу җирләр өчен оброк түләүнең күп мәртәбәләр бер кешедән икенчесенә күчерелүеннән дә зарланган алар. 1803 елгы 6 март Сенат карары нигезендә элеккеге 30 сум оброкны түләү шарты белән бу печәнлекләр авылга кайтарылган. Ләкин, 1808, 1809, 1810 еллар өчен бәзәкәлеләр бу салымны тулысынча түләгән булсалар да, Вятка казна палатасы печәнлекләрне Озын Тау кешеләренә күчергән. Межалаштыру барышында землемер Малинин бәзәкәлеләрнең китергән дәлилләрен һәм ярлыкау грамоталарын кабул итмәгән; һәм, киресенчә, күрше авыл халкы дәгъвалаган межа һәм табигый чикләрне, чокыр-тауларны алар күрсәткәнчә билгеләгән. Бәзәкә авылы ышанычлысы Максютов 1806 елның 24 февралендә Вятка межалаштыру конторасына бу хакта шикаять белдерсә дә, контора аның үтенечен кире каккан. Мәскәүгә җибәрелгән шикаятькә бәзәкәлеләр ярлыкау грамотасының күчермәсен дә теркәгән.

Межалаштыру канцеляриясе 1808 елның 11 февралендә Вяткадан барлык кәгазьләрне сораткан. Материаллар шул ук елның 15 апрелендә Мәскәүгә җибәрелгән. Җавап көткән арада, Вятка губернасындагы казна урманнарының баш караучысы бәзәкәлеләрне гаепләүнең тагын бер юлын тапкан. “Алабуга округындагы Бәзәкә, Турай һәм Кураз авылларының башкорт һәм татарлары, элек төрле авылларда яшәүче казна крестьяннары биләмәсе булган чиктәш җир һәм урманнарны дәгъвалап, баш землемерга шикаять җибәргәннәр. Ул башкортларның бу җирләрне үзләштерүгә нинди

хокуклары бар? Бу билгеле түгел”, - дип язган ул Вятка губернаторына һәм башкорт-типтәрләрнең хокукларын тикшерү хакында тиешле оешмаларга әмер бирүнең кирәклеген күрсәткән. “Аларның махсус өстенлекләре булмаган очракта межалаштыру инструкциясе нигезендә башкорт-типтәрләргә бирелгән хокуклар рус крестьяннарына да бирелергә тиешлеген” ассызыклап, ул, мәхкамә карары кабул ителгәнче, биләмә чикләрен күрсәткән планнарны хуҗаларына бирми торырга тәкъдим иткән.

Вятка губерна идарәсе 1812 елгы 17 апрель карары белән Алабуга өяз мәхкамәсенә (суд) бу мәсьәләне тикшерүне йөкләп, Бәзәкә, Турай һәм Кураз башкортларын, җирләренә хокукларын раслаган барлык документлары белән чакырып, тикшерергә кушкан. Шулай Алабуга өяз мәхкамәсендә озак еллар дәвам иткән яңа тикшерү башланган. Дәгъвалашучы якларга яңадан документларны барлау, ышанычлылар билгеләү, пүнәтәй һәм шаһитларны җыю кебек иксез-чиксез мәшәкатьләр аша узарга туры килгән. Тикшерү барышында төрле чорда Бәзәкә биләмәсеннән 19 кишәрлекнең казнага алынуы ачыкланган. Бәзәкә чикләрендә Сәйтәк, Ык Тамагы, Озын Тау авыллары нигезләнүе хакында сүз булган иде инде. Калган кишәрлекләрне казна төрле шарт нигезендә башка тирә-юньдәге авыл җәмгыятьләренә биргән. Шулай, Бәзәкә белән бер йорт тәшкил иткән Кураз, Турай авылларыннан тыш, Тәкәш, Песәй, Ахтиял, Иж Тамагы, Монай, Бондюг, Тойма һәм Алнаш һәм Камай волостьләрендәге исемнәре күрсәтелмәгән авыллар да Бәзәкә вотчинасына кергән җирләр өчен бәхәскә кереп киткәннәр.

Димәк, Алабуга өяз мәхкамәсендә яңа тикшерү бер чиновникның “Алабуга һәм Сарапул башкортларының казна крестьяннары җирләреннән артык җирләре булырга тиеш түгел” дигән ялган фаразыннан чыгып башланган. Шулай булса да, барлык тикшерү этапларын үтеп, бу эш Сенатның межалаштыру департаментына барып җиткән. Эшне межалаштыру канцеляриясенә кайтарганда, Сенат 1828 елның 31 октябрендә бирелгән указын да җибәргән. Анда Бәзәкә биләмәләрен 1765 елгы чикләре кысаларында калдыру, ә дәгъвалы җирләрне, “3” тамгалы бер кишәрлектән башка, элек бирелгән дачаларында калдыру хакында карар булган. 1832 елда башкорт-типтәрләрнең җирләренә булган хокукларын югары хакимияттә караганнан соң, патша Николай I шул ук елның 10 апрелендә Сенатка үз указын юллаган. Русия законнарының тулы җыелмасында 5287 номер белән урын алган бу указда “башкорт җирләре хакында барлык тикшерүләрне туктатып, аларның үз җирләренә хокукларын раслап, халыкны бөлгенлеккә төшерүче дәгъваларны туктатырга; бу көннән башкортларның барлык күрсәтелгән җирләренең бәхәссез хуҗасы булуларын танырга” дигән карар урын алган була.

Патша указыннан соң 1834 елда бәзәкәлеләргә биләмәләренең планы һәм межалаштыру кенәгәсе тапшырылган. Ләкин бәзәкәлеләр тынычланырга да өлгермәгәннәр, 1841 елда Алабуга өяз мәхкамәсе тикшерүне яңартып җибәргән. Бу юлы Бәзәкә халкы үз арасыннан сайланган ышанычлыларга ярдәмгә Башкорт-мещеряк гаскәре идарәсе штатындагы стряпчийларны да җәлеп иткән. Стряпчий – ул суд эшләрен алып бару тәртибен күзәтүче

чиновник. Катлаулы очракларда авыл ышанычлылары стряпчийларның күзәтүе һәм җитәкчелеге ярдәмендә эш йөрткәннәр. Мәхкамә карары белән килешмәгән очракта стряпчий, үзенең ризасызлыгын белдереп, югары инстанцияләргә мөрәҗәгать итәргә тиеш булган.

Бәзәкә халкы хокукларын яклап, 11-башкорт кантонының стряпчие Скарятинов 1842 елның 21 октябрендә өяз мәхкамәсенә, барлык элек китерелгән дәлилләрне кабатлап, яңа аңлатма язуын тапшырган. Ләкин мәхкамә, патша карарын да, Скарятинов язмасындагы дәлилләрне дә исәпкә алмыйча, тикшерү эшен дәвам иткән. 1849 елның җәендә Алабуга өяз мәхкамәсе үзенең утырышларын Бәзәкә авылында уздыру карарын кабул иткән. Утырыш 1849 елның 20 июнендә Бәзәкәдә ачылган. Ә 24 июньдә утырышка килгән стряпчий Туленков Бәзәкә биләмәсендә бернинди дә артык казна җирләре булмавын, киресенчә, 1697 елгы грамотада күрсәтелгән җирләрнең межа эченә кертелмәвен дәлилләгән.

Мисал өчен грамотада Бәзәкә биләмәсе эчендә Озын Тауның саналуын китереп, аның законсыз рәвештә казна җиренә әйләнүен күрсәткән; бу һәм грамотага кергән башка җирләрнең дә (мәсәлән, Бәзәкә инеше тамагы Бәзәкә биләмәсе эчендә булырга тиеш, ә ул межалаштыру чорында казна җире булып киткән) Бәзәкәнеке булуы актка язылырга тиешлеген ассызыклаган. Шулай итеп, Туленков аклану урынына һөҗүм тактикасын сайлап алган. Ләкин бу адым да уңышка китермәгән. Өяз суды, Бәзәкәгә килүенең максатын аның биләмәсе эчендәге казна җирләрен табу, ә “биләмә тышындагы Бәзәкә җирләрен эзләү безнең бурычка керми” дип, Туленковның таләпләрен кире каккан. Шуның белән 25 июньдә мәхкамә Бәзәкәдәге утырышын тәмамлаган.

Авылдагы бу биш көнлек утырышның бабаларыбыздан күпме борчылу, никадәр чыгым таләп иткәнен без, мөгаен, күзаллап та бетерә алмабыздыр. Ә суд моның белән эшен тәмамламаган бит әле. Өяз мәхкамәсе, китерелгән дәлилләргә игътибар итмичә, Мәскәүдән Бәзәкә дачасына караган межалаштыру документларын сораткан. Моңа каршы межалаштыру канцеляриясе 1850 елның 7 ноябрендә Алабугага яңа указ җибәргән. “Башкортлар һәм типтәрләр хуҗа булган бу җирләр электән җәнлек, бал һәм акчалата ясак түләү шарты белән аларныкы саналып килгән. Бөек падишаһ кушуы белән Сенат тарафыннан 1754 елның 24 мартында Оренбург губернаторы Неплюев әфәндегә бирелгән указда алар бу ясактан азат ителгән. Шушы указ һәм межалаштыру инструкциясенең 12-бүлеге 19-пункты нигезендә бу документларда күрсәтелгән башкорт-типтәр биләмәләрен аларда калдырырга, ә урыс казна крестьяннарын җир мәсьәләсендә алар белән тигезләү кирәкми”, - дигән катгый карар булган бу указда.

Әмма Алабуга хөкемдарлары бәзәкәлеләрнең җир хокукларын танымау юлыннан һаман да чигенмәгәннәр. Мәскәүдән кирәкле документларны кайтара алмаса да, өяз мәхкамәсе 1851 елның 15 июненә Бәзәкәдә яңа утырышын билгеләгән (күрәсең, бәзәкәлеләр беренчесендә бик яхшы кунак иткәннәрдер диярга генә кала). 1851 елның җәенә билгеләнгән утырыш, ни сәбәпледер, Бәзәкәдә 1852 елның 23-26 июнендә генә узган. Бу юлы Алабуга өяз землемеры Титов суд әгъзаларына тагын бер кат алар башлаган эшнең

күптән тәмамланганын исбатлаган. Стряпчий Хребтович тикшерү барышында җыелган барлык документларны Уфага, башкорт һәм аларның припущенникларының хокукларын тикшерү өчен патша карары белән оештырылган комиссиягә җибәрү тиешлеген аңлаткан. Бу тәкъдимне кабул итеп, утырышта катнашучылар таралышкан. Вятка суд палатасы 1852 елның 19 ноябрь һәм 22 декабрь указы белән "Бәзәкә эшен" тәмамларга кушкан.

Ләкин 1859 елның 12 августында тынгысыз өяз мәхкамәсе башкортларның җир хокукларын тикшерү хакында яңа карар кабул иткән. Аның нигезендә "элекке судлар биләмәнең чикләре хакындагы бәхәсләрне генә туктаттылар, ләкин бәзәкәлеләргә бирелгән план һәм межа кенәгәләре аларның җиргә хокукларын раслау өчен дәлил була алмый" дигән фикер урын алган була. Димәк, Алабуга хөкемдарлары бәзәкәлеләрнең җир хокукларын чикләү юлларын эзләүне дәвам иткәннәр. Аларны 1863 елда башкортлар хакында кабул ителгән яңа кагыйдәләрнең нәшер ителүе генә туктаткан. Александр II 1861-1866 елларда уздырган крестьян реформасының бер өлеше булып "Башкортлар хакындагы положение" торган. Вотчина җирләренә аның 15, 17, 20 маддәләре багышланган. Аларда элекке заманнарда яклагыш грамоталары нигезендә яки башка нигездә башкортларныкы саналган, генераль межевание вакытында аларныкы дип танылган җирләр бу җәмгыятьләрнең үз милке булуы, башкорт җәмгыятьләре бу җирләрне сатарга яки арендага бирергә, җәмгыятьнең һәр әгъзасы үз өлешен шәхси милек итеп бүлеп бирүне таләп итәргә хаклылыгы расланган. Шулай итеп, Бәзәкә җәмгыятенең җирле түрәләр белән дәгъвалашуы, бәзәкәлеләрнең дәгъвалары кабул ителмичә, тәмамланган.

Бәзәкәдә XIX гасыр ревизияләре

Сан ягыннан байтак булсак та без,
Сансыз халык идек Рәсәйдә.
Хәсән Туфан

XIX гасырда Русиядә 1812, 1816, 1834, 1850 һәм 1858 елларда биш ревизия уздырылган. Бәзәкәдә бу ревизияләр башкорт һәм типтәр сословиеләрендә аерым булган. Аларның материаллары Казан, Киров, Уфа архивларында саклана. Безнең карамакта алтынчы-унынчы ревизияләрнең тулы исемлекләре бар. Аларда бирелгән мәгълүмат нигезендә ярты гасыр эчендә Бәзәкә халкы составындагы үзгәрешләрне тикшерү өчен махсус төзелгән җыелма таблица кушымтада бирелә (Кушымта № 11).

Алтынчы ревизия Бәзәкәдә 1811 елның 20 сентябрендә уздырылган. Исемлекнең башында бирелгән кереш текстан (преамбуладан) без шактый күп мәгълүмат алабыз. Анда Вятка губернасы Алабуга өязендә урнашкан Бәзәкә авылының Байлар волостенең унберенче башкорт кантонына каравы, аның старшина Смаил (Исмәгыйль) Әмиров кул астындагы команда - "башкорт йорты"ның бер өлеше булуы хакында әйтелгән. Бәзәкә командасының төрле авыллардан җыелганлыгы, аларның хезмәтләре өчен патша тарафыннан бирелгән җирләрдә яшәгәнлеге, даими салымнардан азат

булулары да шушы ук текстан аңлашыла. Халык санын алганда ирләрне генә язганнар, хатын-кызлар исемлеккә кертелмәгән.

Старшина Смаил Әмиров кул астына Бәзәкәдән башка тагын дүрт авыл кергән: Кураз (Әтәс), Турай, Корбан чишмәсе, Әхтиял чишмәсе. Бу биш авылда 509 ир-ат (аларның 286-сы бәзәкәлеләр) булган. Бу команда белән старшина тагын 12 хәрби чиновник ярдәмендә идарә иткән. Аларның бишесе Әтәс белән Турайда яшәгән, җидесе бәзәкәлеләр булган. Менә аларның исемнәре: походтагы есаул дәрәҗәсендәге "йорт" старшинасы ярдәмчесе ***Идрис Ильясов,*** "йорт" есаулы ***Зәйнебәшар Шоңкаров,*** "йорт" сотнигы ***Сәйфелмөлек Сәпәров,*** хорунжий ***Зәйни Сәпәров,*** походтагы есаул ***Тойчин Мәкъсудов***, походтагы старшина ***Зәйни Ильясов.*** Рәсми рәвештә чиновниклар рәтенә кертелгән бу шәхесләр авылда гына түгел, кантонда да "аксөяк", ягъни түрәләр составында саналган.

Алар арасында 32 яшьлек указлы мулла ***Имангол Йосыпов*** аерым урын алып торган. Әлбәттә, 1788 елда Әби-патша указы белән барлыкка килгән Диния нәзарәте үзенең эшчәнлеген әле оештыра гына башлаган чорда, Русия мөселманнары арасында указлы муллалар бик аз булган. Ә указлы мулла исемен, Диния нәзарәтендә имтиханда ислам нигезләрен белүләрен уңышлы исбатлап, губерна хакимиятеннән указ (таныклык) алган дин әһеле йөрткән. Бу очракта исә Имангол хәзрәтне Бәзәкә имамы итеп Вятка губернаторы түгел, ә Башкорт-мещеряк гаскәре башлыгы Оренбург губернаторы билгеләгән дип әйтү дөрес булыр. Дини вазифага ия булу аларны дөньяви вазифалардан азат итмәгән. Указлы мулла үз абруен белеме белән генә түгел, үз-үзен тотышы, үзенең эшләре белән дә ныгытырга тиеш булган. Чөнки иң мөһим эшләрнең берсе – тәрбия өчен мулла җаваплы булган. Авылның бөтен тормышына ул турыдан-туры катнашкан. Мулла дини йолаларны башкаручы гына түгел, башкаларга йола-догаларны өйрәтүче дә булган. Һәрбер мулла диярлек үз мәдрәсәсен дә тоткан. Кирәк чагында мулла судья да, табиб та булган. Ләкин ул үз сословиесендә калган. Имангол хәзрәт тә ревизия вакытында авылдашлары белән бер исемлеккә язылган.

С.Әмировның килеп чыгышы, аның кайчан, нинди шартларда "йорт" старшинасы булуы безгә билгеле түгел. Бәлки аның тамырлары Бәзәкәдә булып, башкорт гаскәре оешкан чорда яңадан расланган Бәзәкә җирләренең ярлыкаш грамотасы да аңа бирелгәндер. Һәм ул төрле төбәкләрдән, төрле халыклардан җыелган "йорт"ы белән монда кайтып урнашкандыр. 1781 елда исемлеккә кергән 40 башкорт хуҗалыгы аның командасы булгандыр. Ә инде ул чорда Бәзәкәдә яшәгән 17 ясаклы татар хуҗалыгы 1781-1795 еллар аралыгында аның "йорт"ына алынган һәм башкорт булып исәпләнә башлагандыр дип фаразларга була.

РС 1812-дә күрсәтелгән Бәзәкә халкын (ир-атларын) яшь ягыннан төркемнәргә бүлеп карыйк: 1)16 яшькә кадәрге малай һәм яшүсмерләр — 123 җан; 2) 17-20 яшьлекләр — 28 җан; 3) 21 -30 — 41 җан; 4) 31-40 — 46 җан; 5) 41-50 — 30 җан; 6) 51-60 — 12 җан; 7) 60 яшьтән өлкәннәр — 10 җан булган. Һәр төркем үз эченә унар ел алырга тиеш булса да, мин бу принципны бераз үзгәртергә булдым: беренче төркемгә 16 яшькә кадәрге

малайларны кертеп, икенче төркемдә 17-20 яшьлек егетләрне аерым күрсәттем. Моның сәбәбе: 17 яшькә җиткән егетләр махсус исемлеккә кертелгән һәм наряд хезмәтенә чиратка куелган, ягъни башкорт гаскәренә хәзерлек төркемен тәшкил иткән. Аларны “линия”дәге (чик буендагы) гамәли хезмәткә әзерләүне өлкән буын үз авылларында алып барган.

Күрүебезчә, авылда булган 286 ир-атның 43% (123 җан) малай һәм үсмерләрдән торган. Гаскәр хезмәтендә саналучылар (21-50 яшьлекләр) 40,9% (117 кеше) тәшкил иткән. Бу санга хезмәт чиратына кертелгән 28 егетне дә кушсак, казаклар саны 50% тан артып китә (145 кеше). Линия хезмәтеннән азат булган бәзәкәлеләр арасында 12 кешенең 60 яшькә кадәр булуын да исәпкә алыйк (алар арасында 52 яшьлек старшина үзе дә керә). Димәк, бу төркемгә кергәннәрнең кайберләре гаскәр формалашкан чорда гына түгел, әле соңрак та “линия”хезмәтен дәвам иткән икән. Иң өлкәннәр 10 кеше булган.

Авыл тормышындагы күпсанлы мәсьәләләрне чишүдә гаскәри башлыклар гына түгел, аксакаллар да зур роль уйнаган. Иң өлкәннәр (88 яшьлек Хуҗаш Сөләйман улы, 84 яшьлек Гадел Давыт улы, 84 яшьлек Ядегәр Бики улы, 79 яшьлек Әхмәр Уразман улы, 74 яшьлек Мостай (Мостафа) Муса улы, 71 яшьлек Коштан Сәмәнәй улы, 69 яшьлек Шоңкар Бики улы, 69 яшьлек Рәхмәй (Рәхмәтулла) Рәхманкол улы) хуплау-киңәшеннән башка авылда бер эш тә эшләнмәгәндер. Аксакалларның барысын да тумышлары белән Бәзәкәдән булганнардыр дип фаразларга да була. Дөрес, бу фаразны исбатлау өчен безгә конкрет фактлар җитми. Ревизия уздырганда нәсел фамилияләре сакланмау, барлык ревизияләрнең материаллары безнең көннәргә килеп җитмәү безгә хәтта РС 1812 дә теркәлгән өлкәннәрне дә XVII-XVIII гасыр документларында очраган исемнәр белән берләштерү мөмкинлеген бирми. Нәселебездә сакланып килгән шәҗәрә ярдәме белән генә мин үзебезнең бабаларыбызны барлый алдым. Бәлки бу китапны укучы авылдашлар да үз шәҗәрәләре ярдәме белән буыннарны тоташтыра алырлар.

Нәселләр хакында. РС 1812 дә язылган Бәзәкәдә 71 хуҗалыкта яшәүче 286 ир-ат, санап чыгаруым буенча, ***илле алты нәселдән*** торган. Минем фикеремчә, аларның күпчелеге Бәзәкә авылына нигез салучыларның дәвамчылары булган. Алар XVI-XVII гасырларда үз тормыш-хезмәтләрен, нигездә, Кама аръягындагы патша кулы җитмәгән җирләрдә алып баруны кулайрак күргәннәр, дип уйларга була. XVIII гасыр азагында алар, күрәсең, Бәзәкәгә кайткан (1781 елда күрсәтелгән 40 башкорт хуҗалыгы). Алар арасында тамырлары татар-башкортка да, фин-угырларга да барып тоташкан нәселләр булуы да мөмкин (бу фактка Бәзәкә кешеләре кыяфәтенең төрле антропологик типта булуы аңлатма була ала). Бу фикерне РС 1812 дә исәпкә алынган ир-атлар арасында өлкән буыннарның аз санда булуы да куәтли.

Бәзәкәдә бу чорда яшәгән гаиләләр хакында да мәгълүматны барлыйк. Демография белгечләре гаиләләрне берничә төргә бүлеп карый. Аның беренчесе *гади (кечкенә) гаилә* дип атала. Ул аерым хуҗалык алып бара торган никахлы пар һәм аларның өйләнмәгән балаларыннан гыйбарәт.

Икенчесе - *катлаулы*, яки *бүленмәгән (зур)* гаилә. Монсы бер хуҗалыкта яшәүче үзара туган булган берничә буынны, ике яисә берничә никахлы парны берләштергән гаилә. Шуңа күрә галимнәр катлаулы гаиләләрне тагын берничә типка бүләләр: өч яки күбрәк буыннан торган, ике яки икедән артык өйләнешкән туганнарны (һәм аларның балаларын) бер хуҗалыкта туплаучы гаилә h.б.

Бәзәкәлеләрнең күпчелеге бу чорда катлаулы гаиләләрдә яшәгән – 71 хуҗалыкның 37 сендә бүленмәгән гаилә булган. Шуларның уналтысында өч һәм күбрәк буынлы, уникесендә агалы-энеле гаиләләр тормыш иткән. Калган тугыз гаилә тагын да катлаулырак; алар арасында, үз чиратында, төрле бүлемнәр булырга мөмкин – үз гаиләләре белән бергә яшәүче туганнар, үз яннарына апа-сеңелләренең өйләнгән улларын сыендырган h.б.

34 гади гаиләнең сигезендә берәр генә ир-ат күрсәтелгән. Гаиләдәге иң өлкән ир-ат (бабаймы-атамы ул яки туганнарның олысы туры килгәнме), хәтта ул бик карт, көчсез булып, хуҗалык эшләрен башкара алмаса да, гаилә башлыгы – хуҗа саналган. Ул имана, мал-мөлкәт хуҗасы буларак, авыл җыеннарында катнашкан. Авыл милкен сату, арендага бирү h.б. мәсьәләләр чишүдә һәрбер хуҗалык башлыгының тавышы исәптә булган. Алар өстендә авыл җәмгыяте һәм дәүләт йөкләгән бурычлар да булган. Ә бүленмәгән гаилә эчендәге кечкенә гаилә башлыкларының мондый хокук-бурычлары булмаган, чөнки алар аерым хуҗалык алып бармаган. Күп очракта катлаулы гаиләләр хуҗалык башлыгының вафатыннан соң таркалганнар. Берничә гади гаилә бүленеп чыгып, үз хуҗалыклары белән яши башлагач, аларның башлыклары мөстәкыйльлек белән бергә үзләренә тиешле хокук-бурычларга да ия булып киткән.

Гаиләләрнең күләмен чамалар өчен бер хуҗалыкта ничә ир-ат булуын да карап карыйк. РС 1811дә бер ир-атлы 8 хуҗалык, ике ир-атлы – 14, өч ир-атлы – 10, дүрт ир-атлы – 12, биш ир-атлы – 7, алты ир-атлы – 4, җиде ир-атлы – 5, сигез ир-атлы – 7, тугыз ир-атлы – 1 гаилә теркәлгән. Ә 1 хуҗалыкта бергә яшәүче 17 ир-ат күрсәтелгән. Хатын-кызлар исәпкә алынмау сәбәпле гаиләнең зурлыгын тулысынча билгеләп булмаса да, бу саннар ярдәме белән аны чамаларга була.

Иң зур гаилә Мәкъсудовларныкы булган. Монда без асылда дүрт гаиләнең бер хуҗалыкта яшәвен күрәбез. Өч бертуган – биш малае белән 58 яшьлек Салих, шулай ук биш малае белән 42 яшьлек Моратхуҗа һәм ике малае белән 40 яшьлек Сәйфин – өч аерым гаилә тәшкил итсәләр дә, бергә яшәгәннәр. Дүртенче гаиләне дә аерып карарга була – Моратхуҗа улы Хәкимнең дә малае бар. Шулай итеп, бу бер хуҗалыкта 17 ир-ат теркәлгән. Бу нәсел мисалында без бу берәмлектә төрле гаилә типларын билгели алабыз. Минем фикеремчә, аерым хуҗалык булып яшәүче походтагы есаул 35 яшьлек Тойчин Мәкъсудов һәм аның ике улы да шушы Мәкъсуд нәселеннән булырга тиеш. Болай санаганда, бу нәселдә 20 ир-ат РС 1812гә язылган булып чыга. Әгәр дә без нәселнең хатын-кызларын да исәпкә алсак, бу күпҗанлы нәсел авыл халкының уннан бер өлешен тәшкил иткәнлеген билгели алабыз.

Йорт старшинасы Исмәгыйль Әмировның нәселе дә шундый ук ишле булган. Аның үз гаиләсе аерым хуҗалык булып яшәүче гади гаиләләрдән булган. Ләкин тагын ике хуҗалыкта Әмирнекеләр яшәгәнен күрәбез. Аның берсендә өч бертуган - Исхак (46 яшь), Имангол (43 яшь) һәм Гобәйдулла (32 яшь) балалары белән – барлыгы 8 ир-ат булган. Икенче хуҗалыкта алты бертуган - Зәбир (37 яшь) улы белән, Фәзаил (35) улы белән һәм аларның дүрт энеләре Фәтхулла (29), Габделгаффар (19), Габделхәер (18) һәм Габделнасыйр (13 лет) күрсәтелгән. Димәк, өч хуҗалык булып яшәгән нәселдә дә 19 җан исәпләнгән. Болардан тыш тагын унбер нәсел ике-өч аерым хуҗалыкларга бүленеп яшәгән.

РС 1812 дә 72 -нче хуҗалык та күрсәтелгән. Ул яңа төпләнгән Корбансу авылында поход старшинасы ***Зәйни Ильясов***ның хуҗалыгы. Күрәсең, ул, авылдан аерым яшәргә теләп, Корбансу чишмәсенең Бәзәкә инешенә кушылган җирендә үз кишәрлегендә яңа авылга нигез салган. Минем карамакта РС 1812 гә караган аерым типтәр исемлеге дә бар. Анда 12 хуҗалык күрсәтелгән. Димәк, 1812 елга Бәзәкәдә барлык хуҗалыклар саны 84 булган. Ә РС 1795 тә Бәзәкәдә 95 хуҗалык булган. Шулай итеп, 11 хуҗалык югалган булып чыга. Ир-атлар саны исә 266 дан 327 гә җиткән. Бу үзгәрешләрне туганлык җепләре белән бәйләнгән гаиләләр башкорт гаскәре составына кергәндә берләшкәндер дип фаразларга була.

Бабаларыбызның тормышында җир эшкәртү, иген игү, терлек асрау элеккечә төп урынны биләп торган. Сөрүлек җирләре, гадәттә, өч басуга бүленгән: уҗым (арыш), сабан ашлыгы, пар. Пар дип арыш чәчәр өчен ял итәргә калдырылган җир аталган. Чәчүлек җиренең 40 %ына кадәр арыш алып торган. Язгы кыр эшләре апрель азагында басу сөрүдән башланган. Игенчелектә, гадәти буларак, сабан, сука, тырма, урак, чалгы кебек эш коралларыннан файдаланганнар. Сабан чирәм җирләрен һәм авыр туфраклы җирләрне эшкәртү өчен кулланылган. Акрынлап авыр сабанны җиңел сука алмаштырган. Җирне бер тапкыр сабан белән сөрү ике тапкыр сука белән сукалауга тиң саналган. Язын сөрелгән җирләрнең яртысына солы, калган өлешенә, туфракның сыйфатына карап, арпа, борай, тары, бодай, карабодай, киндер, җитен, борчак, ясмык чәчкәннәр. Уракка, печән өсте узгач, июль азагы-августта төшкәннәр. Игенне урак белән урганнар. Печән, бодай һәм карабодайны чалгы белән чапканнар. Киндер һәм җитенне кул белән йолыкканнар. Көлтәләргә бәйләнгән игенне, юешләнүдән саклау өчен, җир өстеннән бераз күтәртеп, такта яки чыбык-чабык (я ылыс) түшәлгән махсус мәйданчыкларга өеп куйганнар. Уҗым ашлыгын (арышны) августта чәчеп бетерергә тырышканнар.

Көтүлекләргә бай булган Бәзәкәдә мал асрауга да зур игътибар бирелгән. Борынгыдан килгән балыкчылык, аучылык-сунарчылык, чолыкчылык та бабаларыбыздан читтә калмаган. Бәзәкә табигате бу һөнәрләргә үзе тартып торган. Балыкка һәм киек кошларга бай елга-күлләр, сунарчылык һәм чолыкчылык өчен кулай булган урман-кырлар – барысы да булган Бәзәкә биләмәсендә. Ә әрәмә! Утынын да биргән ул, печәнен дә биргән, төрле җиләк-җимеш, чикләвек, дару үләнен дә шуннан җыйганнар. Чабата, төрле

әржә-кәржин-бишекләр үрү өчен юкә кабыгы, кайры, каен тузы, талчыбык, шомырт чыбыгы кебек чимал дисеңме, савыт-саба ясау өчен кулланылган юкә кебек агачлар дисеңме, барысын да әрәмә биргән. Бу юлларны язганда, хәтерем Харрас Әюпнең “Авылым юкәләренә” исемле шигырен китереп чыгарды. Шуннан берничә юл:

“Гөжләп тора, көйләр көйләп тора –
Бал исенә чумган юкәлек.
Шунда кемдер килеп чыгар төсле,
Чабаталык юкә күтәреп!
...
Бөтенесе юкәлектән иде:
Кабык бишек,чыпта, мунчала;
Аркан булып тартты авылны ул
Якты көнгә... Юкә булса да...”

Тормышның нигезен натураль хуҗалык тәшкил иткән. Эш коралларын, чана, арба h.б. көнкүреш кирәк-яракларын күп очракта хуҗалыкларда бабаларыбыз үзләре ясаган. Һәрбер авылда итекче, читекче, чабатачылар, балта осталары, тегүчеләр, күн эшкәртүчеләр, буяучылар, мич чыгаручылар h.б. һөнәрләргә ия кешеләр булган.

Хуҗалык эшләрендә хатын-кызлар да зур роль уйнаган. Балаларны карау-тәрбияләү, ашау пешерү, йорт-җирләрен тәртиптә саклау да алар карамагында булган, печән хәзерләү, игеннәрне урып-җыюда да алар ирләр белән бергә эшләгәннәр. Гаилә әгъзаларын кием белән тәэмин итү дә алар өстендә булган. Җитен-киндер чәчү-үстерү, җыю-эшкәртүне нигездә хатын-кыз башкарган. Сарык йонын һәм киндер-җитен эрләп, алар үз өйләрендә тукыма тукыганнар, кулдан күлмәк-ыштан, камзул-җилән кебек киемнәр теккән-чиккәннәр. Өй янындагы җирләр тулысынча алар карамагында булган. Яшелчә үстерүдән тыш (бу һөнәр татар авылларында нык таралмаган булса да, шалкан, кишер, чөгендер кебек тамыр азыклары үстерелгән, бәрәңге XIX гасырның 50-елларында гына кулланышка керә башлаган), хатын-кызлар иртә яздан караңгы көзгә кадәр урман-кырларда, әрәмә-болыннарда төрле җиләк, гөлҗимеш, чикләвек, үлән, балан җыйганнар. Кыш көнендә бу җәй хәзерләнгән нигъмәтләр азык буларак та, дару буларак та кулланылган.

Бетмәс-төкәнмәс хуҗалык эшләреннән бабаларыбызны башкорт гаскәрендәге хезмәт аерган. Алдагы бүлекләрдә сүз барган гомум кагыйдәләрне Бәзәкәгә бәйләп карыйк. РС 1812дә 21 яшьтән 50 яшькә кадәр 117 кеше, 17-20 яшьлекләр 28 кеше күрсәтелгән дидек. Димәк, авылда бу чорда 145 ир-ат мәҗбүри рәвештә ярты еллык гаскәри хезмәтләрен үтәргә тиеш булганнар. Ярты ел дип әйтүнең чынбарлыкка туры килмәвен дә искә төшерик, чөнки авылдан җибәрелүчеләргә, кантон үзәгендә җыелып, линиягә хезмәт урынына барып җитү өчен дә вакыт кирәклеген онытмыйк. Шуңа күрә 15 майда башлана торган җәйге нәрәткә, мартның икенче яртысында ук чыгып китә торган булганнар. Чират 4-5 елга бер тапкыр килеп җиткән очракта, Бәзәкәдә 30-40 хуҗалык, кимендә, 7-8 айга (аның кызу эш өстенә туры килүен дә истә тотыйк) җигелеп эшли торган ир-егетләрсез калган. Бу

тыныч вакытта. Ә 1812 елда “Француз сугышы” башлангач, нәрәтләр икеләтә зурайган. 1812-1814 еллар бөтен ил өчен дә, Башкорт гаскәре өчен дә иң авыр еллар булган.

Зур сугышта катнашу өчен махсус башкорт һәм мишәр полклары оештырылган. “Башкорт халкы тарихы”нда түбәндәге мәгълүмат бирелгән: 1811-1814 елларда һәр башкорт полкында 500 рядовой башкорт, 10 урядник, 5 хорунжий, 5 сотник, 5 есаул, 1 командир һәм аның ярдәмчесе (христианнардан торган казак полкларында да шундый ук штат) булган. Болар өстенә гаскәри хезмәттә саналмаган берәр писарь, квартирмейстер һәм мулла да булган. Шулай итеп, полкта барлыгы 530 кеше каралган була. Барлыгы 20 башкорт полкы оештырылган. Башкорт полклары атлы гаскәрләр сафында булган. Һәр башкорт ике ат (җайдак һәм йөк төялгән), милли кием һәм корал белән тәэмин ителгән булырга тиеш булган. Милли хәрби кием – зәңгәр яки ак төстәге постау кафтан, зәңгәр төстәге кызыл лампаслы киң чалбар, очлы киез башлык, каеш-пута, күн портупея һәм итектән гыйбарәт булган. Нигездә, башкортлар җәя-ук һәм сөңге белән коралланган, кайберләрендә кылыч, мылтык, пистолет та булган. Барлык кием һәм коралны башкорт казаклары үз хисабына булдырган.

Минзәлә өязенең 11-нче Байлар кантонына кергән бәзәкәлеләр тулысынча 11-кантон башкортларыннан торган 6-нчы полк составында булган. Алтынчы полк походка Минзәләдән 21сентябрьдә чыккан. Аның юлы Алабуга, Арча, Казан, Свияжск һәм Чабаксар аша Түбән Новгородка (татарлар аны Нижгар дип йөрткәннәр) булган. Полклар, Нижгарда җыелып, армиягә җибәрелгәннәр. Алтынчы полк анда 16 октябрьдә килеп җиткән. Ләкин аны сугыш кырына түгел, ә Идел буе төбәгендә башланган чуалышларны бастырырга җибәргәннәр. 25 октябрьдә полк Устюжнага чыгарга приказ алган. Анда заводчик А.И.Яковлевның Череповец һәм Устюжно-Железополье өязләрендә яшәүче 220 крестьяны Урал заводларына эшкә барудан баш тарткан булган. 25 декабрьда Устюжнага килеп җиткән полк полиция хезмәтен башкаруга керешкән: корал кулланып баш күтәрүчеләрне бастырган.

Шуннан соң патша әмере белән полк Санкт-Петербург-Вологда юлын саклаган, соңрак Витебск шәһәренә күчерелгән. Анда шулай ук полиция хезмәтендә булган. 1814 елның 1 октябрендә полк Витебсктан Борисов шәһәренә каравыл тотарга җибәрелгән. Белоруссиядә 1813-1814 елларда хезмәт иткән өченче, бишенче һәм алтынчы башкорт полклары Неман елгасындагы кордоннарны саклаган, әсирләрне саклап озата барган, рекрут төркемнәрен озатып йөргән. Шулай итеп, алтынчы полк сугышта катнашмаган. Сугышның үзенә катнашмасалар да, күпчакрымлы маршлар, салкын тию һәм башка авырулар башкорт полкларына күп зыян китергән. Хәтта туган якларына кайтканда да югалтулар шактый булган. Мәсәлән, 1815 елның 1 гыйнварына туган якларына кайтып җиткәндә, алтынчы полкның штатында 1 штаб-офицер, полк командиры һәм аның ярдәмчесе, 5 есаул, 5 сотник, 5 хорунжий, 10 үрәтник, 1 писер -язу эшләрен алып баручы солдат, 463 башкорт казагы, денщик, 477 ат булган.

Бәзәкәлеләрдән ничә кеше бу полкта хезмәт иткәне безгә төгәл билгеле булмаса да, чама белән алар кырык-илле кешедән ким булмаган дип уйларга була. Документлардан без алтынчы полкта хезмәт иткән бер генә кешенең исемен беләбез. Ул 1781 елда Бәзәкәдә туган зауряд-сотник Шәмсетдин Смагил улы Госманов. 11-кантонның 1836 елгы формуляр исемлегендә аның 1812-1814 елларда алтынчы полк составында армиядә булуы, поход һәм сугышларда катнашмавы язылган. Шулай да ул “1812 елгы Ватан сугышы истәлегенә” дигән көмеш медаль белән бүләкләнгән.

1812 елда Ватан сугышы башлану сәбәпле алтынчы ревизия кайбер төбәкләрдә уздырылмыйча калган. Шуңа күрә, сугыш тәмамланганнан соң, аның нәтиҗәләрен дә исәпкә алып, хөкүмәт яңа, җиденче ревизияне уздыру карарын кабул иткән. Бәзәкәдә *җиденче ревизия* 1816 елның 8 августында узган. Ике ревизия материалларын чагыштырып карасак, биш ел эчендә авылда шактый күп үзгәрешләр булуын күрәбез. Иң беренче чиратта, йорт старшинасы 52 яшьлек Смаил Әмировны 1811 елда йорт есаулы булган 24 яшьлек *Зейнебәшар Шоңкаров* алыштыруын күрәбез. Бу хәлнең ничек һәм кайчан булганлыгын без төгәл генә билгели алмыйбыз. С.Әмиров, чираты җитеп, ялга киткәнме, әллә Ватан сугышы бу вакыйганы тизләткәнме, һәм авыр сынаулар чорында йорт белән җитәкчелек итүне яшь булдыклы есаулга тапшырганнармы, моны төгәл генә әйтеп булмый. Мәсьәләне башта авыл җыенында хәл итәргә кирәк булган. Аннан соң старшинаны кантон җыенында берничә кандидатура арасыннан күпчеләк тавыш белән сайлау уздырылган. Кандидатлар закон буенча русча һәм татарча укый-яза белергә тиеш булганнар. Шунсыз кантон башлыгы аларны йорт старшинасы итеп билгеләмәгән. РС 1816 да Бәзәкә авылының 28 яшьлек йорт старшинасы Зейнебәшар Шоңкаров җитәкчелегендә булуы теркәлгән. Димәк, ул барлык бу этапларны узган дип әйтергә хаклыбыз.

Зейнебәшар Шоңкаров йортында барлыгы 570 ир-ат һәм 579 хатын-кыз булуы күрсәтелгән. Шулардан 318 ир-ат һәм 334 хатын-кыз Бәзәкәдә яшәгән. Аның карамагында тагын биш авыл халкы - Турай (162 ир, 148 хатын-кыз), Кураз (Әтәс) (67 - 87), Корбан чишмәсе (12 - 5), Әхтиял чишмәсе (10 - 6) һәм Кукшан (1ир, 2 хатын) булган. Ике ревизия арасында биш ел эчендә РС 1812-дә күрсәтелгән 286 ир-атның 24 вафат булуы, 3 ир-атның исемлеккә 1812 елда кермәгәнлеге ачыклануы, 53 малай туганлыгы хакында да РС 1816-да мәгълүмат бирелгән. Җиденче ревизиягә хатын-кызлар да язылган, аерым графаларда аларның исеме, гаиләдәге урыны һәм яше күрсәтелгән. Ләкин алар хакындагы материалдан аларның нәсел-нәсәбе һәм шундый башка мәгълүматны табу мөмкин түгел. Калган 8-10 - ревизияләр вакытында да шул ук хәл кабатланган. Ревизия материалларыннан хатын-кызларның язмышын да (вафат булганмы ул, кияүгә чыкканмы h.б.), нәселен дә билгеләп булмый. Шуңа күрә җыелма таблицага хатын-кызлар кертелмәде.

Тагын бер күзәтү. Биш ел эчендә хуҗалыклар саны күзгә күренеп арткан. Әгәр дә 1812 елда Бәзәкәдә 72 хуҗалык күрсәтелгән булса, 1816 елда аларның саны 118-гә җиткән. Яңа хуҗалыклар читтән килүчеләр хисабына түгел, ә зур хуҗалыклар бүленүе аркасында барлыкка килүенә игътибар

итик. Ягъни, туганлык җепләре берләштергән бер хуҗалыкта яшәгән гаиләләр мөстәкыйль яши башлаганнар. Бу хәл, гадәттә, зур гаиләнең (хуҗалыкның) башлыгы вафатыннан соң күзәтелә. Мәсәлән, 1812 елда безнең бабабыз 88 яшьлек Хуҗаш Сөләйман улы вафатыннан соң аның үз гаиләләре булган уллары өч аерым хуҗалык булып яши башлаган. Зур гаилә булып яшәгән башка нәселләрнең дә, мәсәлән, Сәпәрнекеләрне, Мәкъсудныкыларны әйтергә мөмкин, хуҗалыклары бүленгәнлеген күрәбез.

Утрак тормышта яшәгән, аерым алганда, ясаклы татарлардан чыккан һәм башкорт гаскәренә теркәлгән бәзәкәлеләргә, күрәсең, зур гаиләләр ул кадәр кирәк булмагандыр. Хәер, башкорт гаскәре оешкан чорда Бәзәкәдә дә бүленмәгән гаиләләрнең күпчелекне тәшкил итүен РС 1812 дә күргән идек. 1816 елга авылда 11 бүленмәгән гаилә генә калган. Нәтиҗәдә авылда биш ел эчендә зур үзгәрешләр булган: хуҗалыкларның 90% бер-ике буыннан гына торган (ата-ана һәм балалар) гади гаилә тәшкил иткән. Шушы чордан алып, Бәзәкә халкының күпчелеге гади гаиләләрне өстен күргән. Бу фактны башка ревизияләрнең материаллары да исбатлый.

Күпхатынлылык мәсьәләсенә дә кагылмыйча ярамас. РС 1816 да З.Шоңкаровның өч хатыны һәм тагын ун ир-атның икешәр хатыны булуы күрсәтелгән. Гаиләләрнең 90 %-тан артыгында ирләрнең бер хатынлы булганлыгы күренә. Ләкин шуңа да игътибар итик: күп кенә очракларда “2-хатын” яки “улы беренче хатыннан” кебек искәрмәгә юлыгабыз. Бу язмалар ирнең хатыны вафатыннан соң икенче (өченче) тапкыр өйләнгән очракларның күп булуын күрсәтә. Гомумән, барлык ревизия материалларын тикшерсәк, хатын-кызларның вафаты еш кына бала табу белән бәйле булган (“бала тапканнан соң өзлегү”) дигән нәтиҗә ясарга була.

Сигезенче ревизия материалларына күчик. Бәзәкәдә ул 1834 елның 8 февралендә узган. Составында Бәзәкә авылы булган 23-йортта йорт старшинасы алмашынганлыгына игътибар итик. Зәйнебәшар Шоңкаровка алмашка Әхмәт Батырев килгән. Бу старшина 23-йорттагы Турай яки Кураз авылында яшәгән чиновник булырга тиеш (Бәзәкә исемлегендә ул юк). Йорт башлыгының кайчан алмашынуы хакында төгәл мәгълүмат юк. Шулай да бу факт 1821 елдан соң булгандыр, чөнки Зәйнебәшар Шоңкаровка 1821 елның 16 маенда “14-нче класслы чиновник” дәрәҗәсе бирелүе һәм аның башкорт сословиесеннән чыгарылуы хакында язма бар. Аңлатып китим. Русиядә 1714 елда Петр I тарафыннан кертелгән “Табель о рангах” исемле канун чиновникларны 14 класска (дәрәҗәгә) бүлгән (иң югарысы – 1-дәрәҗә, иң түбәне 14 нче дәрәҗә саналган). XIX гасырның беренче яртысында башкорт-мишәр гаскәрендә 14-дәрәҗәгә ирешкән кешеләр шәхси дворяннар (морзалар) сословиесенә күчерелгәннәр. Зәйнебәшар Шоңкаров та хатыннары һәм 1821 елдан соң туган балалары белән, Бәзәкәдә яшәвен дәвам итсә дә, РС 1834-тә аерым исемлектә (чиновник-морзалар исемлегендә) күрсәтелгән. Аның 1821 елга кадәр дөньяга килгән балалары башкорт сословиесендә калган.

РС 1834-тә Бәзәкәдә барлыгы 434 ир-ат һәм 421 хатын-кыз теркәлгән. Хуҗалыклар саны 162-гә җиткән. 53 яңа хуҗалык барлыкка килүе үсеп

өйләнгән малайларның башка чыгуы белән аңлатыла. Шушы вакыт эчендә хуҗалыкларында ир-атлар калмау сәбәпле тугыз хуҗалык юкка чыккан. Бу 162 хуҗалыкта 60 яшьтән узган 17 ир-ат кына теркәлгән. Ике ревизия арасындагы 18 ел эчендә Бәзәкәдә 197 малай туган, 87 ир-егет вафат булган.

1822 елда Гайнулла Фәйзуллин, 1823 елда Хәмидулла Әптиев һәм Фәтхулла Әмиров Себергә сөрелгәннәр. Тагын өч кеше – 1827 елда Габделхалик Салихов, 1833 елда Гыйбадулла Минегулов һәм Тимерҗан Каранаев рекрутлыкка җибәрелгәннәр, берсе - Габделхалик Миргалимов – шул ук 1833 елда авылдан качып китергә мәҗбүр булган. Бу җиде кешенең мондый җәзаларга тартылуы нинди вакыйгалар белән бәйле булгандыр, безгә билгеле түгел. Шулай да алар нәрсәгәдер ризасызлык белдергән, куелган таләпләргә буйсынмаган булырга тиешлеге көн кебек ачык. Иң зур ризасызлык гаскәри хезмәттән булган. Чик саклау хезмәтенең авыр шартлары, линия-дистанциядәге түрәләрнең нәрәттәге казакларны кыерсытуы һ.б. сәбәпләр аларны командадан качып китү кебек адымнарга китергән. Андыйларны барча кантоннардан эзләгәннәр, хәтта «Оренбургские губернские ведомости» исемле газетта “күрсәтелгән билгеләр буенча дезертирлар эзләү” хакында игъланнарга кадәр урнаштырылган. Качкыннарны тоткан өчен 75 тиеннән 1 сум 50 тиенгә кадәр түләү дә каралган булган. Тотылган очракта качкыннар каты җәзага тартылган. Шпицрутен (таяк) аркылы уздырганнан соң аларны рекрутлык, Себер (сөрген яки каторга), хәтта үлем җәзасы көткән.

РС 1834-тә авылда ике указлы мулла булуы да күрсәтелгән: чирек гасырдан артык тәҗрибәсе булган имам 54 яшьлек Иманкол Йосыповтан тыш 36 яшьлек указлы мулла Шаһиислам Рәфыйков та теркәлгән. Аның гаиләсе хакында да мәгълүмат бирелгән: яшь мулланың 32 яшьлек Зөһрә исемле хатыны һәм ике улы – 11 яшьлек Ибраһим һәм 1 яшьлек Мәһди күрсәтелгән. Шуны да ассызыкларга кирәк: 36 яшьлек Шаһиислам Рафиков чыгышы белән килмешәк түгел, төп Бәзәкә кешесе Рәфыйкъ Сардинов улы булган.

Иманкол Йосыпов хакындагы мәгълүматларны барлауны дәвам итик. Аның ишле гаиләсе (9 ир-ат һәм 7 хатын-кыз) – бүленмәгән гаиләнең ачык мисалы булып тора. Аның эчендә ике гади гаилә булуы күренә: беренчесендә - Иманкол хәзрәт үзе, хатыны, дүрт өйләнмәгән улы һәм өч кызы; икенчесендә – аның өлкән улы Габделлатыйф хатыны, өч улы һәм ике кызы белән. Ягъни алар, аерым хуҗалыклар булып яшәсәләр дә, ишле гаиләдән саналырлар иде. Бу өч буыннан торган гаиләнең авылда иң зур гаилә булуын да искәртеп үтик. Аңа охшаш гаиләләр Бәзәкәдә башка калмаган диярлек мөмкин. Хәтта өч буыннан гыйбарәт булган гаиләләр эчендә дә шактый үзгәрешләр күренә – гадәти буларак, өлкән буынны улы гаиләсендә яшәүче әнисе (әбиләр) тәшкил иткән. Күпхатынлылыкның да авылга хас булмавы күренә: 9 ир-ат кына икешәр хатын белән яшәгәнен күрәбез.

Тугызынчы ревизия нәрсә сөйли? Бәзәкәдә ул 1850 елның 11 августында оештырылган. Исемлекнең дөреслеген тикшерү өчен аны өч тапкыр мир җыенында кычкырып укып чыкканнар. Исемлекне язган писарь, 23-йортның башлыгы урядник Хисмәтулла Зәйнебәшар улы Шоңкаров һәм 12-кантон

җитәкчесе хорунжий Солтанов, исемлекне раслап, кулларын куйганнар. Ике ревизия арасында үткән 16 ел эчендә 74 ир-ат вафат булган, 203 малай дөньяга килгән. Хатын-кызлар хакында мондый мәгълүматны биреп булмый. Шулай да без аларның саны да артуын күрәбез. Бәзәкәдә халык саны табигый рәвештә арта барган. 1850 елда авылда 207 хуҗалык булган, аларда 558 ир-ат һәм 503 хатын-кыз яшәгән.

Бу юлы да 23-йорт башлыгы үзгәрүгә игътибар итик. Йорт белән идарә итү 1850 елда Шоңкар Бикиевның оныгы, 44 яшьлек урядник Хисмәтулла Зәйнебәшар улына күчкән. Башка Бәзәкә башлыкларыннан аермалы буларак, архивта аның 1858 елда тутырылган формуляры сакланган. Анда аңа 52 яшь булуы язылган. Хисмәтулланың хезмәт этапларын күздән кичерик: 1826 елның 2 маеннан ул гади казак буларак 11 башкорт кантонында гаскәри хезмәткә керешкән; 1835 елның 5 маеннан урядник, 1850 елның 4 маеннан йорт старшинасы, 1852 елның 22 декабреннән зауряд-хорунжий булган; 1858 елның 9 июненнән йорт старшинасы булудан азат ителгән. 1858 елның 20 августыннан вакытлыча 5 йортның старшинасы итеп билгеләнгән. Походларда һәм сугышларда катнашмаган, бүләкләре һәм аерым билгеләре юклыгы күрсәтелгән. Казна йортларында тәрбияләнмәгән, татарча укый-яза белүе язылган. Хатыны – типтәр Фәтхулла Тукаев кызы Гарифә, 3 баласы – 1846 елның 5 февралендә туган улы Шәрәфетдин, Гарифә (20.03.1847) һәм Шәгърифә (10.10.1851) исемле ике кызы булуы әйтелгән. Сәламәтлеге булмавы сәбәпле 1860 елның 4 сентябрендә хезмәтеннән азат ителгән.

РС 1850дә игътибарны җәлеп итәрлек тагын берничә факт бар. 1836 елда 32 яшьлек Төхфәтулла Зәйнебәшаров һәм 50 яшьлек Шангәрәй Салихов Себергә сөрелгәннәр. Аларның Себергә сөрелүенең сәбәбе билгеле булмаса да, мондый җәзаның юкка гына бирелмәвен беләбез. Тагын ике бәзәкәле – Хәмидулла Сәткулов (1842 елдан) һәм Исмәгыйль Баязитов (1849 елдан) авылдан китеп хәбәрсез югалган, тагын икесе – Иманкол-хәзрәтнең уллары Габделвәли һәм Габделгалләм – авылдан качып ук киткәннәр. РС 1834 тә өч бәзәкәленең Себергә, тагын өчесенең рекрутлыкка (бу чараның да җәза формасы булуын искә төшерик) җибәрелүен, берсенең качып киткәнлеген күргән идек. Бу вакыйгаларның барысын да бәзәкәлеләрнең төрле административ изү-кысуларга каршы чыгуларын күрсәтүче фактор дип кабул итеп була. РС 1850 дә без моңа кадәр Бәзәкәдә күрелмәгән тагын бер вакыйгага тап булдык: дүрт бәзәкәле христиан динен кабул иткән – 1849 елда 23 яшьлек Әхмәтша Батыршин, 30 яшьлек Ибәтулла Рәфыйков һәм 36 яшьлек Габделсаттар Яхъин, 1850 елда 29 яшьлек Мөхәмәдьяр Исмәгыйлов. Бу адымга җитлеккән ир-атларны нәрсә этәргәндер, анысы безгә билгесез. Берәр җәзадан качканнармы, башка сәбәп булганмы – ничек булса да, бу дүрт кеше авылда мөселманнар арасында кала алмаган. Ул чор кануннары буенча алар рус я керәшен авылына күчерелгән булырга тиеш.

Унынчы ревизия Бәзәкәдә !859 елның 26 февралендә, ягъни алдагысыннан бары җиде ел ярым вакыт узгач кына, уздырылган. Ике ревизия арасының кыскалыгын илдә реформалар чоры башлануы белән аңлатып була. Бер яктан, хәзерләнүче крестьян реформасы, икенче яктан,

башкорт гаскәрендә башланган үзгәрешләр салым түләүче катлауларның төгәл санын барлауны таләп иткән. Сүз уңаеннан шуны да әйтим, РС 1859 материалларын мин Казанда да, Кировта да таба алмадым. Аның саклану урынын миңа шул ук Илдар әфәнде Нәфыйков хәбәр итте. Уфада Оренбург хәрби губернаторы фондында аның 1863 елда эшләнгән күчермәсе иде ул. Шуңа күрә аңа 1859-1863 еллар арасында Бәзәкәдә булган үлем-китем, хатын-кызларның кияүгә чыгу яисә аерылу еллары да өстәлгән булып чыкты бу документта. Унынчы ревизиянең бу формада халык исәбен алуның соңгысы булуын да ассызыклыйк. Күрәсең, феодаль дәүләт ихтияҗларыннан чыгып уздырылган чара үз вазифасын инде үтәгән, ә яңа чор өчен яңа формалар да кирәк булган.

Башкорт гаскәрендә башланган үзгәрешләрне РС 1859да да күреп була. Беренчедән, кереш сүздә үк 1855 елдан Бәзәкәнең Вятка губернасы Алабуга өязендәге 17 башкорт кантонының өченче йортына керүе язылган. Икенчедән, бу йорттагы авыллар составы да үзгәргән – монда хәзер Кураз, Ахтиял чишмәсе (икенче исеме Чулман), Песәй, Корбансу (Бәзәкә) һәм Сарсаз авылларында яшәүче башкорт һәм типтәрләр кергән. Өченчедән, элек исәпкә аерым алынган типтәрләр башкортлар белән бер исемлеккә язылган. Моның сәбәбе – 1855 елда типтәр гаскәре бетерелеп, аларны башкорт гаскәре составына күчерү булган. Элек типтәр булган башкортларны Бәзәкәнең төп исемлегенә язу авылда хуҗалык һәм халык санын шактый арттырган: 1859 елга Бәзәкәдә 257 хуҗалыкта 757 ир-ат һәм 697 хатын-кыз яшәве теркәлгән.

Хәзер XIX гасырда узган барлык халык санын алу материалларын бер таблицага туплап, чагыштырып карыйк.

Таблица № 1

	РС 1795	РС 1812	РС 1816	РС 1834	РС 1850	РС 1859	В % к РС 1795
Хуҗалык саны	95	72	118	162	207	257	270.5
Ир-атлар	244	290	318	434	559	757	310
Хатын-кызлар	261		334	421	503	697	267
Барлык җан исәбе	505		604	855	1062	1454	288
Уртача 1 хуҗалыкта	5,3		5,2	5,3	5,1	5,6	0.3
Ир-ат	2,6	4	2,5	2,7	2,7	2,9	
Хатын-кыз	2,7		2,7	2,6	2,4	2,7	

Таблицадан авылда ревизиядән ревизиягә хуҗалыклар һәм халык саны артып баруы ачык күренә. Бишенче һәм унынчы ревизияләр арасында үткән алты ярым дистә ел эчендә хуҗалык саны 270.5 %, халык саны 288 %ка җиткән. Ләкин бер хуҗалыкта яшәгән кешеләр санында үзгәреш бик кечкенә булган. Бу саннар бәзәкәлеләрнең ата-ана һәм балалардан торган гади гаиләне кулай күрүләрен раслый. Димәк, аерым ревизия материалларын анализлаганда күренгән тенденция гасыр уртасына кагыйдә булып киткән дигән нәтиҗә ясый алабыз. Бәзәкә авылы хуҗалыгында уртача биш кешедән генә торган гаилә яшәгән. Бары гасыр башында гына (РС 1812), бер нәселдәге

гади гаиләләрнең күбесе берләшкән хуҗалыкта яшәгәнлекләрен искә төшереп үтәргә була. Авылда халык саны артуының табигый үсешкә кайтып калуын да ассызыклыйк. Бәзәкә җәмгыятенә бер ят ир кеше дә кабул ителмәгән. Аның төп сәбәбе җиргә бәйле: халык саны арткан саен кими барган үз биләмәсендәге җирләрне читләргә биреп булмый ич! Моңа кушып, башкорт гаскәрендә булган авылларга үз кешеләрен читкә җибәрү һәм яңаларны кабул итү мәсьәләсен гаскәр җитәкчеләре генә хәл иткәнлеген дә өстәргә кирәк.

Бу алты дистә ел эчендә авылда башка үзгәрешләр дә булган. Беренчедән, балаларга бирелә торган исемнәр үзгәргән: әгәр дә элек бәзәкәлеләрнең күпчелегенә төрки исемнәр хас булса, XIX гасырда аларны мөселман исемнәре алмаштырган. Һәм тагын бер күзәтү: XIX гасыр урталарына кадәр бабаларыбыз киленне башка авылдан алырга тырышсалар, бу чорда бәзәкәлеләр арасында өйләнешү дә арткан. Буыннар алмашыну барышында борынгы бабалардан килгән туганлык җепләре нечкәрүен, йола буенча да, ислам дине буенча да дүртенче-бишенче буыннарда ерак туганнар арасында никах рөхсәт ителүен күрсәтә торган факт булып тора бу.

Тагын бер таблицага күз салыйк. Анда мин, алтынчы һәм тугызынчы ревизия материаллары нигезендә авылның ир-егетләрен яшьләре буенча төркемнәргә бүлеп, чагыштырып карарга булдым.

Таблица № 2

төркемнәр	РС 1812	%	РС 1850	%
16 яшькә кадәр	123	42,4	213	38,1
17 - 20	28	9,7	61	10,9
21 - 30	41	14,1	93	16,6
31 - 40	46	15,9	81	14,5
41 - 50	30	10,3	40	7,1
51 - 60	12	4,1	49	8,8
61 - 70	4	1,4	14	2,6
70 яшьтән өлкән	6	2	8	1,5
Барлыгы	290	100	559	100

Бу таблица, минем фикеремчә, кызыклы гына күзәтү ясарга мөмкинлек бирә. Гаскәри хезмәтне башкаручылар саны, 17 яшьләрне дә кертеп, РС1812-дә халыкның нәкъ яртысын алып торса, 1850 елга бу төркемнәр 1 %-ка кимегән. Шулай ук авыл халкы составында балалар һәм яшүсмерләр саны 3 %-ка кимүен, ә 50 яшьтән узган өлкәннәрнең 5,4 %-ка артуын күрәбез.

Шулай итеп, без бу бүлектә, XIX гасыр ревизия материаллары нигезендә, төп Бәзәкә авылы яшәешенең кайбер якларын ачыкладык. Ләкин Бәзәкә инеше буенда берничә авыл булуын да онытмыйк. Алар хакында ревизия материаллары нинди мәгълүмат бирә икән?

Бәзәкәнең иярчен авыллары

И җир тоткан башкорт татарларым,
И эш тоткан мишәр татарларым,
Керәшен һәм типтәр татарларым, -
Сездән башка нишләр татарларым?!

Роберт Миңнуллин

Моңа кадәр без, нигездә, XVIII гасырда ясаклы татар булган һәм вотчина хокукына ия булган төп Бәзәкә халкы хакында гына сүз алып бардык. Ләкин РС 1762 – өченче ревизия материалларыннан Бәзәкә инеше буенда, иң кимендә, өч авыл урнашканын күзәткән идек. Калган ике авылның тарихына күчик.

Башта рәсми документларда Бозак Токмак исемен йөрткән авыл язмышы хакында кыскача мәгълүмат бирелгән иде инде. Шуңа тагын бер-ике фикер генә өстим. Бу авылга бәйле башка ревизия материалларын мин очратмадым. Аның хакында кайбер мәгълүмат Бәзәкә җирләре өчен дәгъва материаллары арасында гына табылуын искә төшерик. Анда бәзәкәләләрнең 1804 елда бу авыл кешеләрен яшәгән җирләреннән куып җибәрүләре, ә бозаклыларның күрше Тәкәш авылына күчеп китәргә мәҗбүр булулары хакында сөйләнә. Бәзәкәләләрнең тәкәшләләр белән ике арадагы җирләр өчен дәгъвалашулары да күрсәтелгән. Бу фактны дәгъвалы җирне Бозактан күчкән кешеләр эшкәрткәннәрдер дип аңлатып була (алар ничектер тормыш алып барырга тиеш бит).

Бу кешеләрдән бушаган җирләрдә “яңа нигез салынган авыл Корбан чишмәсе яки шул ук Бәзәкә” исемле авыл барлыкка килгән дип фараз кылырга да була. РС 1812-дән башлап, һәрбер ревизия материалларында 23-йорт составында Корбан Чишмәсе (татарчасы Корбансу) авылы ике исем белән күрсәтелгән. Бәзәкә исеменең саклануына берничә аңлатма бар: беренчесе – авылның Корбансу инеше Бәзәкә инешенә килеп кушылган җирдә урнашуы булса, икенчесе – бу авылга Бәзәкә кешеләре бүленеп чыгуы. Аның нигез салучысы да бәзәкәле Зәйни (Зәйнетдин) Ильясов булган. Походлар вакытында старшина хезмәтен башкарган Зәйни бәлки монда үз утарын булдырырга уйлагандыр дигән фикер дә туа. Аңлатманың өченчесе дә бар: Корбансуда яшәгән халык, Бәзәкә авылыннан читтәрәк яшәсә дә, үзен Бәзәкә халкыннан аермаган – җир биләмәләре дә бергә булган, җыеннары да бергә узган. Ә Бәзәкә авылы, зурая-зурая, XIX гасырның икенче яртысында Корбансу авылы халкын да үз эченә алган. Корбансу авылына караган ревизия материалларын бер таблицага кертеп карыйк.

Таблица № 3

Корбансу халкы ревизия материалларында

	РС 1795	РС 1812	РС 1816	РС 1834	РС 1850	РС 1859
Хуҗалык саны	-	1	5	6	7	7
Ир-атлар		4	12	22	22	22

Хатын-кызлар				14	26	28
Барлык җан саны				36	48	50
Уртача бер хуҗалыкта				6	7	7
Ир-ат		4	3	3,7	3,1	3,1
Хатын-кыз				2,3	3,7	4

Корбансуда 1816 елга хуҗалыклар саны 1812 елгы ревизия вакытында исемлеккә керми калган бәзәкәлеләр хисабына арткан. Бары бер генә кеше, Хәкимулла Габделгафаров, Казан губернасыннан күчеп килгән була. Ләкин ул, нәселен калдырмыйча, 32 яшендә 1818 елда вафат булган. Корбансу авылында бер хуҗалыкка уртача 6-7 кеше туры килгән. Бу авылда барлыгы дүрт нәсел кешеләре яшәгән. 1833 елда авылга нигез салучы Зәйнетдин Ильясов вафат булган. Аның дәвамчылары – дүрт улы, гаскәр җитәкчелеге ризалыгын алып, үз гаиләләре белән (барлыгы 6 ир-ат һәм 5 хатын-кыз) 1835 елда 21-йортка кергән Минзәлә өязе Баланлы авылына күчеп киткәннәр. Бу күченүнең сәбәпләре билгеле түгел, ләкин башка өяздәге башка йортка, башка авылга күченү өчен җитди сәбәп һәм башкорт гаскәре башлыгының рөхсәте кирәк булуын искәртәм.

Авылда калган өч нәселгә караган җиде хуҗалыкта 1859 елга 22 ир-ат һәм 28 хатын-кыз яшәгән. Алабуга өязендәге торак пунктларының 1859 елгы исемлегендә Корбансу авылының халкы бәзәкәлеләргә кушылып саналган. Күрәсең, Бәзәкәдән чыккан кешеләр буларак, алар үзләрен зур Бәзәкәдән аермаганнар. Документларда да Корбансу авылының гамәлдә булмавы күрсәтелә. Бу авылга нигез салучы З.Ильясов вафатыннан соң авыл да таркалган; аның нәселе Баланлыга, ә калганнары Бәзәкәгә күченгән.

Типтәрләрнең тарихын өйрәнүне дәвам итик. Типтәрләрне исәпкә алган барлык ревизия материалларын бер таблицага җыеп караганда, типтәр Бәзәкәсендәге үзгәрешләрне ачык күзалларга була. Дүртенче (РС 1782) һәм бишенче (РС 1795) ревизия язмалары табылмаса да, 1795 елга караган саннар безгә башка чыганаклардан билгеле.

Таблица № 4

Бәзәкә типтәрләре ревизия материалларында

	РС1722	РС1748	РС1764	РС1795	РС1811	РС1816	РС1834	РС1850	РС1858
хуҗалык	2	8	7	12	12	14	14	14	25
Ир-атлар	9	10	17	22	35	45	63	92	89
Хатын-кыз				11		21	44	79	69
Барлык җан саны				33		66	107	171	168
Уртача бер хуҗалыкта				2,75		4,7	7,6	12,2	6,3
Ир-ат	4,5	1,2	2,4	1,8	2,9	3,2	4,5	6,6	3,6
Хатын-кыз				1		1,5	3,1	5,6	2,7

1795 елда типтәр Бәзәкәсендә 22 ир-ат һәм 11 хатын-кыз яшәгән 12 хуҗалык булган. РС 1811-нең кереш өлешендә типтәрләр окладта торучы

казна крестьяннары дип күрсәтелгән. Ике ревизия арасында 20 малай туган, 3 ир-ат вафат булган, берсе – Ишим Кариев - 1805 елда Себергә каторгага җибәрелгән, тагын берәү – Кутый Ибрашев – шул ук 1805 елда югалган. 12 хуҗалыкның икесендә - Заитовлар, дүртесендә — Ибрашевлар яшәгән. Рәхимовлар, Карсановлар һәм Балтановлар шулай ук икешәр хуҗалык булып торганнар. РС 1722, РС 1764 һәм РС 1811 язмаларын чагыштырып караганда, аларның барысы да бер тамырдан – Әлмәт (Калмәт) нәселеннән чыкканлыгын билгеләп була. Димәк, 1811 елда Бәзәкәдә бер генә типтәр нәселе калган. Тагын бер күзәтү - типтәрләр арасында илле яшьтән узган бары өч кеше генә булган.

1816, 1834 һәм 1850 елгы ревизия материалларында типтәрләрдә халык санының даими үсүе, ә хуҗалык саны үзгәрмичә саклануы күренә. Нәтиҗәдә 1816 елда бер хуҗалыкка уртача 4,7 җан туры килсә, 1850 елда бу сан 12,2-гә җиткән. Бу фактны типтәрләрнең припущенник булуы, ягъни үз җирләре булмавы белән аңлатып була. Межалаштыру вакытында алар кулланышына бирелгән җирләр 1895 елгы җан башыннан чыгып кына билгеләнгән булган. Ә яңа хуҗалыкларның каралты-кураларын урнаштырыр өчен урын беткән булып чыга (биләмә хуҗаларының үзләрендә дә бу процесс бик көчле булуын онытмыйк). Икенче яктан, күп кеше теркәлгән хуҗалыклар уллары башка авылларга мулла булып киткән гаиләләргә генә хас булган. Эш шунда ки, халык санын алу вакытында исемлеккә кергән кеше, нинди сәбәп белән һәм кайда гына яшәмәсен, элек теркәлгән җирендә исәпкә алынган. Яңа урында аңа халыкның төп байлыгы булган җир бирелмәвен дә онытмыйк.

Бәзәкәдә күп кешеле типтәр хуҗалыгы икәү булган. Аның берсе старшина Райман Ибрашев, икенчесе Балтан Буляков хуҗалыклары. Аларның икесенең дә уллары - Райман улы Зәйнетдин һәм Балтан улы Габделлатиф, Бәзәкә имамы Иманкол Йосыпов мәдрәсәсендә белем алып, күрше авылларга мулла булып киткәннәр. Анализ ясау өчен бу ике хуҗалыкта барган үзгәрешләрне күрсәткән ревизия мәгълүматларын таблицага кертик.

Таблица № 5

Мулла нәселләре ревизия материалларында

	1811	1816	1834	1850	1858
Райман Ибрашев хуҗалыгында Зәйнетдин Райманов гаиләсе	5м.	5м.+2ж.	13м.+6ж. 7+3	22м.+6ж. 11+3	9м.+3ж. 6+3
Балтан Буляков хуҗалыгында Габделлатыйф Балтанов гаиләсе	4	4	6+2 5+1	7+11 5+10	8+11 5+10

Таблицада һәр ике хуҗалыкта да беренче юлда хуҗалыкта ревизияләр барышында исәпкә алынган кеше саны, икенче юлда башка авылда яшәгән муллаларның гаиләсендәге кеше саны бирелде. 1834 елда Райман Ибрашев хуҗалыгында 13 ир-ат һәм 6 хатын-кыз, барлыгы 19 кеше язылуына игътибар итик. Шулардан 10 кеше (7 ир-ат һәм 3 хатын-кыз) Бәзәкәдә яшәмәүче Зәйнетдин мулла гаиләсе әгъзалары булган. Балтан Буляков хуҗалыгында

язылган 8 кешенең (6 ир-ат һәм 2 хатын-кыз) алтысы (5 ир-ат һәм 1 хатын-кыз) Габделлатыйф хәзрәт гаиләсеннән. 1820 елда Балтан Буляков вафатыннан соң хуҗалык аның өлкән улы Габделлатыйфка күчкән. Ул авылда яшәмәгән, Бәзәкәдә аның әнисе һәм өйләнмәгән энесе генә калганнар. 1850 елга бу гаиләләр тагын да ишәйгәнлеген күрәбез.

Ревизия материалларын анализлауны дәвам итик. Әгәр дә РС 1811-нең керешендә алар казна окладында торучы типтәрләр дип язылган булса, РС 1816-да типтәрләр, РС 1850-дә татарлардан чыккан типтәрләр дип күрсәтелгәннәр. Ә менә РС 1858-дә алар типтәрләрдән чыккан башкортлар дип аталган. Бер үк нәсел кешеләрен төрле сословиеләрдә күрсәтү типтәрләрнең этник яктан татар булуын күрсәтә. Ә РС 1858-дәге язма дәүләтнең рус булмаган халыклардан торган гаскәрләрдә үзгәрүләр башлануның чагылышы булып тора. Аерым сословие буларак формалашкан чордан ук типтәрләрнең казна крестьяннары һәм башкорт катлаулары арасында урталыкта булуы патша хакимиятен борчып торган. Берничә тапкыр хакимият типтәрләрне казна крестьяннары белән берләштерүне башлап караган булган, ләкин һәрвакыт аларның каршылыгына очраган, чөнки мөселманнар өчен “крестьян” дип язылу динне алмаштыруга тиң саналган (“крестьян” – “христиан” төшенчәсенең халык сөйләмендә кулланылган үзгәргән варианты булган). Бигрәк тә 1834-35 елгы чуалышлар типтәрләрне казна крестьяннары катлавына кушуның көтелмәгән нәтиҗәгә китерү мөмкинлеген ачык күрсәткән. Шулай да типтәр мәсьәләсен чишүнең кирәклеге XIX гасыр урталарына өлгереп җиткән була. Һәм 1855 елда типтәрләр һәм мишәрләр башкорт сословиесенә кертелгән, гаскәрнең исеме дә Башкорт гаскәре дип йөртелә башлаган.

РС 1858 күрсәткән тагын бер фактка игътибар итик. Ул да булса, Бәзәкәдәге типтәр хуҗалыкларының саны кискен арту. 40 ел эчендә 14 хуҗалык булып яшәгән типтәрләр 1858 елга 25 хуҗалык тәшкил иткәннәр. Бу вакыйганың аңлатмасы: башкорт булып киткән типтәрләргә дәүләт утызар дисәтинә җир бирергә тиеш булган; шуңа күрә бер хуҗалыкта яшәүче катлаулы гаиләләр барысы да аерым хуҗалык булып язылуны мәгъкуль күргәннәр. Бәзәкәлеләрнең үзләренә дә җирләре аз булуы хакында сүз булган иде. Бу факт дәүләтне типтәрләргә җирне казнаның буш җирләреннән бүлеп бирергә мәҗбүр иткән. 1864 һәм 1884 елларда ике төркемгә бүленгән типтәрләр үзләренә бирелгән җирләргә күчеп киткәннәр һәм Минзәлә өязендә Шикәрле Каен, Алабуга өязендә Яңа Бәзәкә авылларына нигез салганнар.

Башкорт гаскәрендәге үзгәрешләр

Кара да гына урман, караңгы төн,
Нинди юллар белән үтәрбез.
Дус-иш белән бергә эш иткәндә,
Теләкләргә тизрәк җитәрбез.

Татар халык җыры

XIX гасырның 30-40-елларында Русия хөкүмәте алдына илдә крепостнойлыкны бетерүнең зарурилыгы килеп баскан. Илдәге климатик

шартлар һәм примитив корал белән эшкәртелгән ашламасыз җирләрдән алынган уңышның түбәнлеге еш кына ачлыкка китергән. Мәсәлән, бу ике дистә елга да тулмаган чорда Русиядә сигез уңышсыз ел булган. Проблеманың кичектергесез чишелергә тиешлелеген аңлаган хөкүмәт авыл хуҗалыгында реформалар башлап җибәргән. 1837 елда казна җирләре һәм урманнары белән идарә итү өчен дәүләт милке министрлыгы оештырылган. Бу оешманың башлыгы итеп билгеләнгән П.Д. Киселев министрлыкның төп бурычын казна крестьяннары яшәгән авылларны үзгәртеп кору дип билгеләгән. Үзгәрешләр белән идарә итү өчен губерналарда дәүләт милке палаталары, өязләрдә округ идарәләре оештырылган. Волость һәм авылларда крестьян үзидарәсенә нигезләнгән адымнар ясалган.

Киселев реформасы турыдан-туры башкорт гаскәре җирләренә кагылмаса да, анда да шуңа охшаш чаралар күренә башлаган. Оренбург хәрби губернаторы канцеляриясендә бу чорда Башкорт-мещеряк гаскәре казакларын я удел (патша нәселенең милке) идарәсе, я дәүләт милке министрлыгы карамагына күчерү хакындагы фикер кабат-кабат тикшерелгән. Моның сәбәбе – Русия чикләре казах далалары һәм Урта Азиягә күчә барган саен Ырымбур чикләрен саклауның кирәге дә беткән. Димәк, башкорт-мишәр, типтәр, рус казаклары гаскәрләренең дә кирәге бетә барган.

XIX гасырның 30-елларында хәрби губернатор карамагында булган халыкны күзәтүне көчәйтү максатында Башкорт гаскәре командующие һәм аның канцеляриясе, шулай ук попечительство аппараты оештырылган. “Гомум тынычлык, куркынычсызлык һәм тәртипне саклау өчен” һәр авылда җирле полициягә, ягъни становой приставка буйсынган сотский һәм десятскийлар һәм авыл башлыгы билгеләнә башлаган. Бу чараларның төп мәгънәсе – башкорт-мишәрләр арасында хәрби-феодаль тәртип һәм хәрби-полиция күзәтүен урнаштыру булган. Халыкның тормышы, тәртибе шулай нык күзәтү астына эләккән. Ирекле рәвештә авылдан чыгып китү дә катгый тыелган. 30-40 - еллар күптөрле үзгәртүләргә һәм яңалыкларга бай булган. Әлбәттә, һәр яңа үзгәреш җирле түрәләрнең басымын, эш йөкләмәләренең артуын, халык хокукларының кысылуын да алып килгән. Шуңа күрә генерал-губернаторның яисә гаскәр башлыгының һәр әмерен халык үзләренең тормышын һәм милли гореф-гадәтләрен җимерүче зур бәхетсезлек, яңа афәт кебек кабул иткән. Хакимияттән һәр вакыт үзенә яңа авырлыклар көтәргә өйрәнгән халык кайчагында хәтта аның прогрессив чараларына да каршы чыккан.

Мисал өчен, ашлык саклау өчен икмәк магазиннарын булдыруны алыйк (бу чорда “магазин” сүзе белән кибет түгел, ә склад, саклау урынын атаганнар). 1799 елда ук Оренбург губернасы авылларында запас магазиннарын оештырылу каралган була. Аларда җыелган ашлык икмәк уңмаган елларда халыкны ачлыктан сакларга һәм чәчү материалы белән тәэмин итәргә тиеш булган. Беренче елларда башкорт, мишәр, типтәрләр ашлык йөкләмәсеннән азат ителгәннәр. 1822-1823 еллардан алар да, башкалар белән бергә, икмәк урынына ассигнация (кәгазь акча) белән җан башына 25 тиен түләргә тиеш булганнар. 1834 елда бу җыем һәр җан

башыннан икмәк һәм унар тиен акчадан торган кушма салымга алмаштырылган. Бу салым ревизиядә күрсәтелгән һәрбер җан башына берәр *чирек* (якынча 8 пот) уҗым ашлыгы, яртышар чирек сабан ашлыгы һәм кәгазь акча белән 1сум 60 тиен (көмеш акчага 48 тиен) җыелганчы түләнергә тиеш булган.

Утрак тормыш белән яшәүче кантоннарда (Бәзәкә кергән 11-кантон да шундыйлардан) бу салымны ашлыклата түләгәннәр. 1837 елда аларда авыл җәмгыятьләре хисабына запас ашлык магазиннары төзү хакында указ кабул ителгән. Ә.З.Әсфәндияров күрсәткәнчә, бирелгән план нигезендә шундый бер магазин төзү 50-елларда авыл халкына уртача көмеш акча белән 150 сумга төшкән. Икмәк уңмаганда, ачлык янаганда, чәчү орлыгы булмаган очракларда халыкның бу магазиннарга җыелган ашлыктан файдалануы каралган булган. Ләкин нигездә халыкны кайгыртуга юнәлтелгән бу чара халыктан өстәмә чыгымнар таләп иткән. Үз чиратында, яңадан-яңа чыгымнар халыкның ризасызлыгын тудырган. Бәзәкәдә беренче шундый магазин 30-еллар азагында төзелгән. Алабуга өязендәге торак җирләре исемлегендә 1869 елга авылда өч запас икмәк магазины булуы күрсәтелгән. Магазиннарны төзү эшләре шактый авыр барган, еш кына төрле дәгъваларга, тикшерү эшләре башлануга китергән. Алабуга өяз суды фондында сакланган Бәзәкәдә икенче икмәк магазинын төзүгә бәйле материаллардагы берничә фактка игътибар итик.

Бәзәкәдә икенче магазин салу эше 12- башкорт кантоны башлыгы сотник Кеяковның авылдагы беренче магазинны төзәтү һәм өстәмә яңа магазин салу хакындагы 1855 елның 13 маенда бирелгән боерыгыннан башланган. Йорт старшинасы зауряд-хорунжий Хисмәтулла Шоңкаров үз карамагында булган Бәзәкә һәм Турай авылы вәкилләреннән 31 майда җыен җыеп, аларга бу боерыкның үтәлүе мәҗбүрилеген аңлаткан. Җыенда бу хакта приговор төзелгән. Приговорда 23-йорт өчен 12 амбарлы өстәмә магазин төзүнең мөһимлеге, аны төзү һәм искесен төзәтүгә 600 бүрәнә һәм 48 имән багана кирәклеге күрсәтелгән. Бу материалны үз дачаларына кергән урманда үзләре хәзерләргә, магазинны да үзләре төзергә алынган алар. Ләкин төзү эшләренең дөреслеген тикшереп, эштә катнашучыларны өйрәтү өчен балта остасын – бәзәкәле Габделкаһир Тойчиновны ялларга булганнар. Плотникка түләү өчен һәр җан башыннан алтышар тиен, ә агач материалын кисү-яру һәм кирәкле тимер-томыр алу өчен дүртәр тиен алып, 910 кешедән көмеш акча белән 91 сум җыю тиешлеген билгеләгәннәр (Кушымта № 13.1).

Төзү эшләре озакка сузылган. Бу хакта без йорт старшинасы Шоңкаровның 1856 елның 3 сентябрендә авыл башлыгы (старостасы) Камалетдин Хөсәеновка эшне кызулату хакында биргән язма боерыгыннан беләбез (Кушымта № 13.2). Бер елдан артык вакыт үтсә дә, төзү эшләре дә башланмаган, хәтта акча да җыелып бетмәгән булган. Старшинаның эшне тизләтүе нәтиҗә биргән: икенче плотник Габделсадыйк Имангулов кулы астында эшләгән бәзәкәләләр 1856 елда магазинны салып бетергәннәр. Ләкин төзелеш эшләре соңында плотник белән йорт старшинасы арасында низаг чыккан. Талаш тирәнгә киткән: Г.Имангулов 1857 елда хәтта дүрт тапкыр –

30 гыйнвар, 28 март, 10 май һәм 30декабрьдә – старшина Шоңкаров өстеннән шикаять белән башкорт гаскәре башлыгына мөрәҗәгать иткән.

Эшнең эчтәлеге попечитель майор Богдановның 1862 елның 27 октябрь рапортында бик тәфсилләп язылган (Кушымта № 13.3). Балта эше остасы булган Г.Имангуловны яллаганда, старшина аның бу эше хәрби хезмәт хисабына саналачагын да вәгъдә иткән икән. Моның өстенә, авыл җәмгыяте аңа көмеш акча белән җан башыннан утызар тиен түләү дә билгеләгән. Ләкин төзү эшләре беткәч, авыл халкыннан җыелган акчаны бирү урнына Шоңкаров кенәгәгә кеше башыннан унар тиен җыелуын язарга боерган. Боерык үтәлмәгән очракта: “Мин синең башыңны бетерәм”, - дип тә янаган. Шушы сәбәпләр Г.Имангуловны югарыдагы түрәләрдән яклау сорарга этәргән. Һәм ул Шоңкаровка карата тикшерү эшләре уздыруны, аны закон буенча хөкем итүне һәм тикшерү эшләре вакытына старшина вазифаларыннан азат итүне сораган. Димәк, гади бәзәкәләләр старшиналары өстеннән шикаят язу гына түгел, аны закон буенча хөкем итүне сорарлык дәрәҗәдә белемле һәм тәвәккәл булулары хакында да сөйли бу документ.

Шикаять буенча тикшерү эшләре башланган. Майор Богданов фикеренчә, моңа кантон башлыгы сотник Кеяковның Шоңкаровны күралмавы ярдәм иткән. “Нәтиҗәдә Шоңкаров үз йортында закон рөхсәт итмәгән акча җыюга юл куюда гына гаепле. Ләкин бу акчаны җәмгыять үз теләге белән иҗтимагый хаҗәтләр өчен җыйган. Һәм беркем дә моңа дәгъва белдермәгән, - дип язган майор. – Шоңкаров бу эш аркасында йорт старшинасы вазифасыннан азат ителгән инде. Шуңа күрә ул башка җаваплы саналырга тиеш түгел”. Ләкин Алабуга өяз суды 1865 елның 22 апрелендә бу эш буенча үз карарын чыгарган: Х.Шоңкаровка артык акча җыйган өчен шелтә белдергән...

Хөкүмәтнең халыкны кайгыртуын күрсәткән тагын бер чара – ул авыл халкын бәрәңге үстерүгә күнектерү булган. Нигезендә изге максат яткан бу эш, дәүләтнең башка шундый башлангычлары кебек, тупас көч куллану, мәҗбүр итү аркылы уздырылган. Аның өстенә 1830 елда яңа азык культурасын халык арасына тарата башлау холера эпидемиясе белән бергә туры килгән. Нәтиҗәдә халык арасында төрле хорафат, имеш-мимешләр һәм чуалыш, баш күтәрүләр башланган. 30-40-еллар Русия тарихына хәтта “бәрәңге бунтлары” исеме белән кереп калган. Бу чуалышлар Идел-Урал буйларында бигрәк көчле булган.

Бу урында Габдулла Тукайның “Бәрәңге һәм мәгърифәт” исемле шигырен ничек искә төшермисең? Халык арасында бәрәңге утырта башлау чорын шул кадәр оста үткенлек белән тасвирлаган шигырьдән бер өзек:

И бәрәңге! Син күрендең әүвәле күрнешкә чит;
Шаулады, сине күргәч, барлык мужик: ул дип “җәдит”!
Ул бәрәңгене китергән дип бу җиргә дәһриләр
Һәм эчендә ул бәрәңгенең, имеш, дип зәһре бар.
И бәрәңге, күп әзаларга синең сабрың беләм,
Ташлады йолкып мужик халкы төбең-тамрың белән.

Ул бәрәңгене ашаучыны ора дип алласы,
Син аталдың ул заман: “кяфер вә шайтан алмасы”!

Әлбәттә, безнең бабаларыбыз да шул кадәр хирыслык белән бәрәңгегә каршы торганнардыр дип әйтерлек дәлилләр булмаса да, алар арасында да каршылыклар булуында шик юк. Башкорт-мишәр гаскәре җирләрендә бәрәңге үстерү 30-елларда башланса да, эш бик акрын барган. Ә.З.Әсфәндияров сүзләренчә, 1840 елда составына Бәзәкә дә кергән 11-кантонда 157 авылның җидесендә генә барлыгы 33 чирек бәрәңге утыртканнар. “1840 елда Бәзәкә авылында 881 җанга уҗым ашлыгы 223 чирек, сабан ашлыгы 318 чирек чәчелгән. Бәрәңге алар өчен әлегә таныш булмаган культура”, - дип язган ул. Русиядә хәтта 1875 елда да бәрәңге барлык чәчүлек җирләренең 1,5 процентын гына алып торган. Димәк, бәрәңгенең авылда да, илдә дә “икенче икмәк” булып китү вакыты әле алда булганлагы күренә.

40-елларда Башкорт гаскәре җирлегендәге авыл тормышын яхшыртуга юнәлтелгән тагын бер чарага кагылыйк. Авылларның күпчелегенә ул чорда бер нәселгә караган хуҗалыкларның борынгыдан килгән оялап урнашу тәртибе хас булган. “Урамнан барам дип уйлыйсың, ләкин кинәт кенә юлыңда я читән, я капка, я амбар, я аулак почмак, я шуның ише башка нәрсәгә килеп терәләсең”; “буталып беткән кечкенә урам һәм тыкрыклар, тәртипсез урнашкан хуҗалык һәм каралты-куралар”; “тыкрык һәм урамнарның сәер лабиринты”, - кебек бәяләмәләрне башкорт авылларына килеп чыккан чиновникларның язмаларында даими очратып була.

1843 елда Оренбург хәрби губернаторы башкорт гаскәре җирләрендәге авылларны мәҗбүри рәвештә үзгәртеп төзү планын раслаган. Бу планның нигезе буларак шәһәрләр өчен кабул ителгән “Төзелеш уставы” алынган. Планда тыкрыклар белән кварталларга бүленгән туры һәм киң урамнар каралган була. Җәмәгать биналары урнашкан төп урам тракт яки юлаучылар уза торган юлның ике ягында булырга тиеш булган. Планда урамнарның киңлеге 10-15 сажин булуы, йортлар фасадлары белән урам сызыгында бер-берсенә каршы урнашырга, янгыннан саклану өчен хуҗалыклар арасында 12 сажинга (25 метр) кадәр бушлык калдыруы каралган. Мунчалар һәм тимерче алачыклары каралты-курадан читтә, елга, күл, ерынты-чокыр ярларында төзелү дә күрсәтелгән була.

Бу план кантон башлыкларына җибәрелгән. Аларның вазыйфаларына тагын бер эш өстәлгән – югарыдагы түрәләрнең әмерләрен үтәп, шушы план нигезендә яңа йортлар салу һәм авылларны төзекләндерү эшләренең барышын күзәтеп тору. Кантон башлыклары, үз чиратында, бу эшләрне йорт старшиналары һәм авыл башлыкларыннан таләп иткәннәр. 1845-1846 елларда урманлы төбәкләрдә яшәүче башкортлар көзен һәм кышын төзү эшләре өчен җитәрлек агач әзерләргә тиеш булалар. Һәр хуҗалыкка 200 гә кадәр бүрәнә әзерләргә рөхсәт ителгән. Яңа йортларның биеклеге идәннән түшәмгә кадәр өч аршиннан да ким булмаска, урамга караган алгы якта ике-өч тәрәзә булырга тиешлеге күрсәтелгән була.

Шулай 1847 елдан башкорт гаскәренә кергән авылларны инеш-елга

үзәннәреннән почта йөргән тракт һәм гади юл буйларына күчерү башланган, йортлар салынган, хуҗалык, каралты-кураларның гадәти күренеше үзгәргән. Түрәләрнең боерыклары, хәрби катлауларга хас рәвештә, берсүзсез диярлек үтәлгән һәм уңай нәтиҗәләргә китергән: 4-5 ел эчендә Башкорт-мещеряк гаскәре җирләрендә торак фонды яртылаш яңартылган. Әлбәттә, мәзәк вакыйгалар да булмый калмаган. Мәсәлән, Ә.З.Әсфәндияров 17 - кантон башлыгы сотник Манашевның 1859 елда биргән боерыгын китабына керткән. Боерыкта ул йорт старшиналары һәм авыл башлыкларыннан "иске биналарны кичектерүсез планга күчерергә, тиз арада капка һәм коймаларны куярга, урамга кереп торган йортларны сүтәргә" кушкан. Монсы гына ярар иде. Ләкин боерыкның дәвамы игътибарны җәлеп итәрлек: "Урамнарның чисталыгын тикшереп торырга, җыен шакшыны себерке белән иң кимендә атнага ике тапкыр себерергә; шулай ук ишек алларын да, һәм бүлмә эчләрен дә, һәм халык киеменең пөхтәлеген дә күзәтергә".

Авылларны төзекләндерү тулысынча 70-елларга тәмамланган. Авылларның кыяфәтен үзгәрткән бу чараның нәтиҗәсен, эзләрен әле бүген дә, бу эшләрдән соң гасыр ярым вакыт үткәч тә, күреп була. Мәсәлән, хәзерге Әгерҗе һәм Менделеев районнарының авыллары аша үткәндә, урам-йортларның урнашуында аерма күренә. Мисал өчен, миңа яхшы таныш Иж-Бубый һәм Бәзәкә авылларын алыйк. Элек ясаклы татарлар яшәгән Иж-Бубый авылында борынгыдан калган кәкре урамнар, аерым кишәрлекләрдә урнашкан төркем-төркем йортларны бүген дә очратырга мөмкин. Бәзәкәгә исә тыкрыклар белән кварталларга бүленгән урамнар хас, йортларның тәрәзәләре дә урам аша бер-берсенә карап тора. Бу аерманың сәбәпләрен эзләргә мине үз авылы Иж-Бубыйдан Бәзәкәгә озата килгән Раиф әфәнде Гәрәевнең соравы этәрде.

Һичшиксез, Бәзәкәдә дә борынгыдан килгән урам-йортларның урнашуын әле XX гасырның урталарында да очратып була иде. Мәсәлән, мин туып үскән йорт, башка йортлардан аермалы буларак, урамда түгел, ә йортлар артындагы аерым бер кишәрлек эчендә урнашкан иде. Моның сәбәбен мин хәзер генә аңлата алам. Авылны үзгәртеп корганда "турайтылган" Кече урамга фасады белән чыгып торган йортны урядник Мөхәмәтгали Бикташев салып кергән, ә ул йортның артында калган элеккеге өйдә аның энесе Ибраһим (безнең әтинең бабасы) яшәп калган. Гомумән алганда, бу кишәрлек Хуҗашныкылар дип йөртелгән нәселнең җирләре булган. XIX гасыр ахырына бу урында инде биш хуҗалык булган: алгы рәттә урам буйлап Мөхәммәтгалинең уллары Әхмәтгәрәй, Шаһиәхмәт, Әхмәтҗанның йортлары, соңгы ике йорт арасындагы тыкрык эчендә аның олы улы Мөхәммәтҗан һәм безнең бабабыз Мәхмүт Ибраһимов хуҗалыклары урнашкан булган. Әле минем балачагымда да монда бу нәселдән булган биш гаилә яши иде. 1951 елда безнең хуҗалык алга, элеккеге Әхмәтгәрәй нигезенә күчерелгәч, тыкрык бетерелде.

Бәзәкә авылының урамнары "турайтылган" вакытны төгәл билгеләр өчен конкрет материал булмаса да, чамалап, бу вакыйга XIX гасырның 50 елларына туры килгәндер дип әйтергә мөмкин: РС 1850-дә Мөхәмметгали

һәм Ибраһим Бикташевларның гаиләләре бер хуҗалыкта, ә РС 1858-дә аерым хуҗалык булып теркәлгән. Бу бер дәлил. Икенчесе - Вятка губернасы идарәсенең статистика комитеты җыйган XIX гасырның икенче яртысына караган документларда Бәзәкәдә йорт-кураларның сыйфатлылыгы, ныклыгына игътибар ителгән. 1887 елгы чыганакта 243 торак бинадан өчесе генә салам түбәле булуы, ә 240-ының түбәләре агачтан – такта һәм дранча белән ябылуы күрсәтелгән. Башкорт гаскәре җирләрендә авылларны үзгәртеп кору, һичшиксез, уңай нәтиҗәләргә китергән. Ләкин бу прогрессив чараның да, авылларны үзгәртеп кору, каралты-кураларны төзекләндерү яки яңадан салуның күп вакыт таләп итүен исәпкә алмыйча, һәрвакыттагыча, ашыктыргыч һәм мәҗбүри үткәрелгәнен дә әйтергә кирәктер.

Башкорт гаскәрендә хезмәт итүче халык көндәлек тормышындагы төрле урынсыз вак тыюлар, кирәкмәгән бәйләнү-каныгулардан да газап чиккән. Ә инде, Бәзәкәдәге кебек, кантон башлыгы һәм йорт старшинасы арасындагы низаг килеп кушылган очракта бу бәйләнүләр икеләтә арткан. Шундый вакыйганы алтынчы попечительлек җитәкчесе майор Богданов Башкорт гаскәре командующие исеменә 1862 елның 27 октябрендә язылган рапортында тасвирлаган (Кушымта, № 13.3).

Аның эчтәлеге: 17 кантонның элеккеге башлыгы сотник Кеяков 1858 елның 25 январендә, йорт старшинасы зауряд-хорунжий Шоңкаровны ярамаган эшләрдә гаепләп, командующийга рапорт юллаган. “Башлыкларның катгый тыюларына карамыйча, старшина тәртипләре шикле булган кешеләргә Минзәлә ярминкәсенә барырга рөхсәт иткән ялган таныклыклар биргән, - дип язган Кеяков. – Моннан тыш Шоңкаров үзенә йөкләнгән вазифаларны бик акрын башкара, хуҗалыкка кагылышлы күрсәтмәләргә зур игътибарсызлык күрсәтә, хезмәтендә җитәкчеләр кушканны тыңламый; бу хакта үзенә бирелгән кисәтү һәм шелтәләрне кабул итми”. Үз сүзләрен раслап, бәзәкәлеләргә старшина Шоңкаров биргән биш таныклыкны һәм аның Кеяковка язган өч рапортын да өстәгән ул.

Тикшерү барышында ачыкланган берничә фактка тукталыйк. Авыл халкы үз ихтияры белән авылдан китеп йөри алмаган. Моның өчен аңа, йорт старшинасыннан рөхсәт кәгазе алып, ул кәгазьне кантон башлыгыннан раслатырга кирәк булган. Старшина исә тәртибе яхшы булган кешеләргә генә җиде көнгә кадәр авылдан китеп торырга рөхсәт бирә алган. Шоңкаров авылның биш кешесенә Минзәлә ярминкәсенә барыр өчен шундый рөхсәт кәгазе биргән булган. Мәсәлән, Ильяс Низаметдинов ярминкәгә карамадан үзе ясаган дугаларны сату өчен барырга җыенган булган. Рөхсәт кәгазләре һәм старшинаның бу хактагы рапорты белән ул сотник Кеяковка килгән. Ләкин Кеяков, рөхсәт кәгазе өчен үзе таләп иткән 1 сум 50 тиен акчаны ала алмагач, рөхсәт кәгазьләрен бирмәгән, Шоңкаров өстеннән язган шикаятьтә бу кешеләрнең тәртипләрен дә шик астына алган. Тикшерү вакытында алар арасыннан бары Хисмәтулла Мендеевнең генә басу читәннәрен тәртиптә тотмаганлыгы һәм авылдан рөхсәтсез киткәнлеге өчен мир приговоры белән суктырылганлыгы билгеле булган. Шикаятне тикшергән майор Богданов сотник күрсәткән кәгазьләрнең кем тарафыннандыр төзәтелгәнлеген,

төзәтүченең Кеяковның үзе генә булу мөмкинлеген ачыклаган. “Димәк, сотник, ни сәбәпләр беләндер, Шоңкаровка яла яккан”, - дигән нәтиҗәгә килгән ул. Шулай булгач, кылмаган гамәлләре өчен зауряд-хорунжий Шоңкаровның җаваплылыкка тартыла алмавын күрсәтеп, сотник Кеяков гамәлләре хакындагы хөкемне майор башкорт гаскәре җитәкчелегенә калдырган. Шулай итеп, бу документтан без башкорт гаскәрендәге эчке тәртипләр хакында да кайбер мәгълүматлар алабыз. Ул тәртипләрнең хәрби оешмаларга хас булган катгый таләпләргә кайтып калуын да искә төшерик.

XIX гасырның 60-елларында уздырылган Бөек реформалар чорына рус булмаган халыкларны берләштергән гаскәр системасының кирәклеге калмаган була. Башкорт гаскәрендә хезмәт итүчеләрнең күпчелеге 1855 елгы үзгәрешләрдән соң хәрби хезмәткә тартылмаса да, формаль яктан аларда һаман да әле хәрби статус сакланган. Халыкның һәр адымын чикләүгә нигезләнгән хәрби хезмәт тәртипләренең тыныч тормышта да кулланылуы ризасызлык күренешләрен арттырган. Хакимият органнарында бу хәлне үзгәртүнең кирәклеге, башкорт сословиесендәгеләрнең хокукларын да башка катлау крестьяннары хокуклары белән тәңгәлләштерүнең зарурилыгын аңлау үсә барган.

Бу вакытка башкорт, мишәр һәм типтәрләрнең йөкләмәләре дәүләт крестьяннары үти торган йөкләмәләргә якынайган. Ләкин көндәлек хәрби тәртипләрдән азат булган бу катлау икътисадый яктан башкортлардан күпкә көчлерәк булган. Вотчина хокукына ия булган Башкорт гаскәре казаклары башка крестьяннардан оброк һәм җан башыннан түләнә торган салымнарны түләмәгән. Әмма вотчина хокукы өчен үтәлә торган хәрби хезмәт, еллар үтүе белән, башта эш хезмәтенә, соңрак казна салымына әйләнгән. Гамәлдә нәкъ шушы салым дәүләт файдасына җыела торган төп феодаль оброк булган да инде.

Крестьян реформаларын хәзерләгәндә, хәрби сословиегә караган рус булмаган халыкларны да дәүләт крестьяннары белән тәңгәлләштерерлек кагыйдәләр хәзерләнә башлаган. Моның беренче адымнары 50-елларда ук ясалган. 1855 елның 22 феврале кагыйдәләре буенча Оренбург, Пермь һәм Вятка губерналарында яшәүче типтәр һәм бобыльләр Башкорт-мещеряк гаскәренә кушылган, гаскәр үзе дә Башкорт гаскәре исемен алган. Гаскәрнең штаты зурайтылган, кантоннар саны 28 гә җиткән. Вятка губернасының Алабуга һәм Сарапул өязләрендәге башка авыллар белән бергә Бәзәкә үзәге Салагыш авылында булган 17-кантонга кергән. Шул ук вакытта гаскәр җитәкчелеге хәрби хезмәтне үтәүче кантоннар санын киметү эшен дә алып барган. Нәтиҗәдә 60-еллар башына хәрби хезмәт үтәү башкорт гаскәренең көньяктагы 9 кантоны халкына гына калдырылган, калган кантоннарда хәрби хезмәт акчалата казна салымына алмаштырылган.

Чишелеш таләп итә торган мөһим җир мәсьәләсе дә алгы планга чыккан. 1856 елдан Уфада вотчина хокуклары булмаган башкортларга (элеккеге припущенник, типтәр, бобыльләргә) җир бүлеп бирү мәсьәләсен карау өчен махсус комиссия эшләгән. Бу комиссиядә Бәзәкә авылында яшәүче башкорт булып киткән типтәрләрнең дә Бәзәкә җирләренә хокуклары тикшерелгән.

Аларның вотчина хокукларына ия булмаулары хакында карар кабул ителгән. Шул ук вакытта Бәзәкә вотчинасының җирләре бәзәкәләләрнең үзләренә җитмәве дә ачыкланган. 1832 елгы указ буенча башкортларга җан башыннан 40 дисәтинә, припущенник булган типтәрләргә 30 дисәтинә җир каралган булган. РС 1816да күрсәтелгән 324 җан бәзәкәләгә 8908 дисәтинә җир кирәк булган, ә аларның биләмәсендә барлыгы 4358 дисәтинә генә җир булган, ягъни бер җанга 11 дисәтинә генә туры килгәнлеге ачыкланган. Типтәрләргә дә сигезәр дисәтинә генә бирелгән булган. Шуңа күрә 1858 елда хәрби совет Бәзәкә биләмәсендә калган барлык 4050 дисәтинә җирне вотчинникларга калдырып, җиденче ревизиядә күрсәтелгән 43 җан типтәрне Минзәлә өязендәге буш казна җирләренә - Бәзәкәдән 50 чакрымда булган Шикәрле Каен һәм 69 чакрымдагы Каран-Азик исемле кишәрлекләргә күчерү хакында карар кабул иткән. 1864 елда Бәзәкә типтәрләренә бу җирләрдә утызар дисәтинә җир бүлеп бирелгән.

Аларны яңа җирләргә күчерүгә әзерләнгәндә, кайбер типтәр гаиләләренең Бәзәкәдә яшәмәүләре ачыкланган. Алар ревизия вакытларында Бәзәкә халкы исәбенә керсәләр дә, Алабуга өязенең башка авылларына муллалыкка чакырылу сәбәпле дистәләгән еллар шул авылларда тормыш көткәннәр. Мәсәлән, 20 еллар уртасыннан ук Кичкутанда муллалык вазифасын башкарган Габделлатиф Балтанов үзенең елдан ел ишәя барган гаиләсе белән Бәзәкәдә саналган гына (хәзерге тел белән әйтсәк, пропискада булган). Башкорт гаскәре башлыгының 1858 елгы 22 август тәкъдиме белән Вятка казна палатасы аның 13 ир-ат һәм 21 хатын-кыздан торган ишле гаиләсен Бәзәкә җәмгыятеннән яшәгән авылы Кичкутанга күчерү хакында карар кабул иткән.

Кичкутан җәмгыяте бу карар белән өлешчә генә ризалашкан. 1859 елның 17 мартында аның ышанычлысы Йөзекәй Мөхәммәдиев Башкорт гаскәре башлыгына үтенеч белән мөрәҗәгать иткән. Анда ул мулла Балтановның әтиләре гаиләсеннән аерым төрле авылларда яшәүче өч улын - Мөхәммәтсадыйк, Мөхәммәткамал һәм Габсаттарны гаиләләре белән (барлыгы 8 ир-ат һәм 11 хатын-кыз) кире Бәзәкә исемлегенә кайтаруны үтенгән булган. Сәбәп буларак үтенечтә Кичкутан авылының чәчүлек җирләре җитмәве күрсәтелгән. 1860 елның 4 мартында 17-кантон башлыгына гаскәр башлыгыннан үтенечнең канәгатьләндерелүе һәм мулла Балтанов гаиләсенең аның белән яшәмәгән өлешен кире Бәзәкәгә күчерү хакында күрсәтмә җибәрелгән. Ләкин Кичкутан халкы тынычланырга өлгермәгән: Вятка казна палатасы 1864 елда Кичкутан халкы түләргә тиешле салымнар исемлегенә күчерелгән сигез ир-атның исемнәрен дә керткән. Авылда теркәлгән 198 җан урынына салым 206 җан башыннан билгеләнгән. Димәк, бу сигез ир-ат өлешен дә кичкутанлылар түләргә тиеш булган (салымнар җан башыннан билгеләнгән, ләкин аларны түләү бөтен җәмгыятьнең бурычы саналган). 1864 елның 27 июнендә Йөзекәй Мөхәммәдиев бу хәлләрне аңлатып, яңа үтенеч юллаган. Яңа тикшерү эше башланган. Төрле оешмалар үзара аңлашканнан соң, 1865 елның 13 январендә Вятка казна палатасы Балтановлардан булган сигез җанның Бәзәкәгә күчерелүе хакында карар

кабул иткән. Шулай итеп, бу биш ел буена барган аңлашылмаучылык Кичкутан халкы файдасына хәл ителгән.

Ул арада башкортлар белән идарә итү өчен яңа кагыйдәләр хәзерләнүе дәвам иткән. Башкорт гаскәре һәм кантон системасыннан яңа төр идарәгә күчү эше генерал-губернатор А.П.Безак җитәкчелегендә тормышка ашырылган. Русиянең яңа хәрби министры Д.А.Милютин кушуы буенча ул 1861 елдан башкорт һәм типтәрләрне акрынлап полиция карамагына күчергән һәм башка чаралар ярдәмендә аларны реформага әзерли башлаган. 1861 елның 19 февраль Положениесе нигезендә хәзерләнгән проектны Дәүләт советы тикшергәннән соң, 1863 елның 14 маенда император Александр II “Башкортлар хакындагы Положение”не раслаган. Анда “Башкорт гаскәре дигән уртак исеме булган, башкорт, мещеряк, типтәр һәм бобыль дип аталучы инородецлар бу Положениедә билгеләнгән ирекле авыл халкына тиешле хокукларга ия” дип язылган була.

“Башкортлар хакындагы Положение” ике кисәктән торган. Беренче өлешенә Башкорт гаскәре хезмәтендә булганнарның яңа халәтенә караган кануннар кергән. Анда шәхси һәм милек хокуклары, волость һәм авыл идарәләрен оештыру, халык өстенә билгеләнгән йөкләмә һәм акчалата җыемнар каралган. Икенче өлешендә башкортларны хәрби халәттән тыныч тормышка күчерү чорында алар белән махсус идарә итү кагыйдәләре куелган.

“19 февраль Положениесе”нең төп статьялары үзгәрешсез диярлек 1863 елгы 14 майда кабул ителгән “Башкортлар хакындагы Положение”гә кергән. Беренче чиратта аларның шәхси һәм милек хокуклары билгеләнгән. Хәзер алар шәхсән һәм бөтен җәмгыятьләре исеменнән казна, төрле оешмалар һәм аерым кешеләр белән килешүләр төзи алганнар, сату-алу эшләрен алып бару, үз авылларында сәнәгать һәм һөнәр белән шөгыльләнү, үзләре җитештергән малны авылларда һәм шәһәрләрдә сату хокукына ия булганнар. Аларның гражданлык хокуклары арасында төрле суд эшләрендә катнашу да каралган (элек бу эшләрне алар кантон башлыгы рөхсәтеннән башка эшли алмаганнар). Тикшерү һәм суд карарыннан, яки авыл җыены приговорыннан башка хәзер аларның хокукларын чикләү һәм җәзага тарту катгый тыелган. Алар авыл һәм волость крестьян үзидарәсе органнарына сайлый һәм сайлана алган, авыл тормышында хуҗалык һәм идарә мәсьәләләрен үзләре хәл иткән, вак җинаятьләрне үзләре тикшереп, карар чыгарган. Балаларын гомуми уку йортларында укыта алу, үз теләге белән башка сословиеләргә һәм җәмгыятьләргә күчү, хәрби хезмәткә китү яисә рекрутлыкка яллану, яшәгән җиреннән башка җиргә барып кайту кебек хокуклар да каралган була. Кагыйдәләрдә күчмә һәм күчемсез милекне сатып алу һәм залогка бирү мөмкинлеге булуын аерып күрсәтик.

Башкортларны җир хуҗасы булмыйча, җирдән файдаланучы гына булган удел яисә казна крестьяннары рәтенә күчерү, ягъни аларның вотчина хокукларын бетерү дә каралган булган. Хөкүмәтне бу адымнан бары тик яңа канун кагыйдәләрен игълан иткәндә вотчинниклар арасында да чуалышлар башлану мөмкинлеге генә туктаткан. 14 май Положениесе башкортларның бәхәссез милке булган вотчина җирләрен җәмгыятьләрнең милке буларак

калдырган. Ызанлау вакытында “кирәгеннән артык” табылган җәмгыять җирләре губернатор тарафыннан расланган волость җыены приговоры буенча сатылу мөмкинлеге ачылган. Бу адымга җәмгыять башкортларның үзләрендә канун билгеләгән җир кишәрлекләре булган очракта гына бара алган. “Артык” җирләрне саткан очракта керем акчасының ике өлеше вотчинникларга таратылырга, бер өлеше мир капиталын тутырырга тиеш булган.

14 май Положениесе элеккеге ярымхәрби йорт-кантон системасын җәмгыяви оешмаларга – авыл һәм волость җәмгыятьләренә алмаштырган. Положение элек тә башкорт авылларында эшләп килгән идарә органнарына кайбер үзгәрешләр генә керткән. Авыл белән идарә итү авыл җыены һәм җыенда өч елга сайланган староста кулында булган. Гадәти буларак, староста вазифасы авылның абруйлы кешеләренә тапшырылган. Кирәк чагында җәмгыять махсус салым җыючыларны, икмәк магазиннарын караучыларны, урман һәм басу сакчыларын һәм авыл писерләрен билгели алган. Авыл үзидарәсе җитәкчеләре үз вазифаларын бушлай диярлек башкарган, моның өчен аларга дәүләт йөкләмәләрен үтәүдә өстенлекләр бирелгән.

Авыл җыены хуҗалык башлыклары һәм барлык сайланган кешеләрдән торган. Хөкемгә тартылган кешеләр җыенда катнаша алмаган. Һәрбер авылда элеккечә игенче тормышы белән бәйле булган барлык мәсьәләләр авыл җыеннарында хәл ителгән: имана җирләрен бүлү, күпер һәм юлларны ремонтлау һ.б. Моннан тыш авыл җыены әдәпсез, бозык кешеләрне авылдан куу хакында приговорлар төзи алган, ниндидер гаебе булган хуҗалык башлыкларының җыенда катнашуын вакытлыча тыйган, үз составына башка җирләрдән килүчеләрне кабул итү-итмәү мәсьәләсен караган. Биләмәнең буш кишәрлекләре һәм бүленми торган җирләре дә җыен карамагында булган. Шулай ук мир чыгымнары өчен акча җыюны билгеләү, казна өчен булган салым һәм йөкләмәләрне тарату, авыл мәхәлләсендәге мулла вазифасына кандидатлар билгеләү һ.б. мәсьәләләрне чишү белән дә җыен идарә иткән.

Җыенда барлык мәсьәләләр дә бертавыштан яки күпчелек тавыш белән хәл ителгән. Кайвакытта хуҗалык башлыклары тавышларының өчтән ике өлеше кирәк булган. Җыен карары староста катнашы белән узганда гына гамәлгә керә алган. Ләкин авыл эшләрен еш кына җыен түгел, ә староста, мулла һәм авыл куштаннарыннан торган төркем хәл иткән. Староста үзе һәрвакыт җыенда сайланган. Аның вазифалары: җыенны чакыру һәм бетерү, җыен узганда тәртипне саклау; җыен карарлары, волость идарәсе һәм башка начальникларның күрсәтмә-әмерләренең үтәлүен булдыру; ызан (межа) билгеләренең булуын, юллар, күперләр, түшәмә юллар һәм кичүләрнең төзеклеген тикшерү, авылдан китү өчен билетлар бирү. Шулай ук салымнарны вакытында түләү һәм мир милке дә староста карамагында булган. Староста полиция хезмәтенә караган кайбер тәртип һәм куркынычсызлык саклау, мәсәлән, үзара тынышмаган авылдашларының эшләрен карау, аларның милкен саклау, качкыннарны тоту кебек эшләрне дә башкарган. Старостаның вак гаепләр өчен авылдашларына җәза бирү хокукы да булган: ике шаһит һәм картлар катнашы белән ул гаеплеләрне ике көнгә

кадәр җәмгыяви эшләргә билгеләргә, мир файдасына бер сумга кадәр акча түләтергә яки ике тәүлеккә кадәр кулга алырга хаклы булган. Җәза белән ризалашмаганнар исә ике тәүлек эчендә шикаять белән волость судына мөрәҗәгать итә алганнар.

Волость идарәсе крестьян үзидарәсенең иң югары органы саналган. Ул волость җыены, волость старшинасы һәм волость судыннан гыйбарәт булган, волость җирлеге белән идарә иткән, андагы тәртип өчен җаваплы булган. Волость җыенына авыл һәм волость идарәсендә эшләүчеләр һәм һәр 25 хуҗалыктан сайланган вәкилләр кергән. Авыллардан җыелган вәкилләр волость җыенында өч елга волость старшинасын, аның ярдәмчесен, салым җыючыларны, волость суды әгъзаларын сайлаган. Гадәттә, волость җыены өч айга бер тапкыр, старшина һәм вәкилләрнең өчтән ике өлеше катнашы белән уздырылган. Волость идарәсе, киңәш органы буларак, атнага бер җыелган. Авыл һәм волость үзидарә органнарында җәмәгать эшләрен алып баручыларның күпчелеге русча укый-яза белмәгән. Аларны контрольдә тоту һәм язу эшләрен башкару өчен өяз хакимияте тарафыннан писерләр билгеләнгән. Күп мәсьәләләрне дә старшина түгел, ә писер хәл иткән. Үзидарә органнарына сайланган кешеләр, беренче чиратта, хакимият алдында җавап тотканнар. Алар өяз хакимияте кушканны төгәл башкарырга тырышканнар, салымнарны бүлүгә һәм җыюга, игенчеләрнең дәүләт алдындагы йөкләмәләре вакытында үтәлү өчен җаваплы булганнар, вак җинаятьләрне тикшергәннәр һ.б.

Хакимият “Башкортлар хакындагы Положение”не игълан итүгә җентекләп хәзерләнгән. Кантон башлыкларына халык тәртибен күзәтү хакында тәфсилле инструкцияләр бирелгән. Халык арасында яңа Положение кертелү хакында татарчага тәрҗемә ителгән өндәмә таратылган. Анда, авыл җәмгыятьләрен оештырганда, алардагы халык санын, кирәге булмаганда, арттырмау; мөмкин булганда, вотчинниклар һәм припущенникларга аерым җәмгыятьләр оештыру каралган була. Кантон башлыклары волость җәмгыятьләрендәге халык саны (1 меңнән 5 меңгә кадәр) артык күп булмаска тиешлеген дә күзәткән.

Шул ук 1863 елда барлык 11 кантонда да авыл һәм волость җәмгыятьләре барлыкка килгән (барлыгы 808 авыл һәм 130 волостьта). Минзәлә өязендәге унберенче кантонга кергән җирләрдә 12 волость һәм 54 авыл җәмгыяте оештырылган. Барлык җәмгыятьләрдә дә сайлаулар узган. 1865 ел 2 июлендә Александр II раслаган “Башкортлар белән идарә итүне хәрби министрлыктан гражданлык оешмаларына күчерү” хакындагы Дәүләт советы карары нигезендә кантон оешмалары бетерелгән. Аларның вазифалары губерна һәм өязләрдә оештырылган крестьян эшләрен алып баручы оешмаларга һәм мировой посредникларга күчкән. Шулай итеп, Идел-Урал төбәгендә рус булмаган халыкларның тормышын хәрби-административ нигездә оештыру юкка чыгарылган. Хакимиятнең бу адымын Русиядә яңа чор башлануын билгеләгән крестьян реформасының бер өлеше булган дип бәяләргә мөмкин.

Яңа шартларда

Бу дөньяда без дә яшәп киттек:
Тир агыздык... сөйдек... еладык...
Кичергәннәр – ерак дәверләргә
Зур бер дастан итеп юлларлык...

Харрас Әюп

Биш губернада (Вятка, Оренбург, Пермь, Самара һәм Уфа) яшәгән Башкорт гаскәренә караган халыкны гражданлык органнарына күчерү 1866 елның 1 февраленә тәмам булган. Бу бәзәкәлеләрнең ике губерна түрәләренә буйсынуына чик куйган. Бәзәкә, бу төбәктәге башкорт сословиесенә кергән башка авыллар кебек, хәзер тулысынча Вятка губернасы һәм аның Алабуга өязе оешмаларына гына буйсынган. Бу авыллар белән идарә итү өчен Алабуга өязендә үзәге Салагыш авылы (хәзерге Әгерҗе районы) булган яңа волость барлыкка килгән. Ләкин ул билгеле чикләре булган башка волостьлар кебек территориаль берлек итеп оештырылмаган. Аны административ-сословие нигезендә төзелгән берлек дип билгеләргә мөмкин. Салагыш волостенә вотчина хокукына ия булган авыллар гына кергән.

Үзәк статистика комитетының 1839-1873 елгы мәгълүматны туплаган басмасы (“Вятка губернасындагы торак урыннарның исемлеге”) күрсәтүенчә, волость 16 авылны берләштергән. Алардагы 1566 хуҗалыкта барлыгы 9321 кеше (ике җенестәгеләрне санап) яшәгән. Бу авыллар Алабуга өязендә электән оештырылган биш волость территориясендә таралып урнашкан булган. Мәсәлән, Бәзәкә, Корбансу, Турай, Кураз, Песәй, Ахтиял авыллары Күрәк волостеның Кама буендагы көньяк-көнчыгыш өлешен алып торган. Кайбер авылларның халкы Салагыш волостенә өлешчә генә кергән (мәсәлән, Песәй авылында электән вотчинниклар белән бер авыл булып яшәгән ясаклы татарлар Күрәк волостенда саналган).

Тагын бер үзенчәлеккә игътибар итик – Салагыш волосте мөселман динендәге төрки-татар телендә сөйләшүче халыкны – төбәктәге вотчина хокукына ия башкорт (татар) һәм типтәрләрне генә берләштергән бердән-бер волость булган. Башка волостьлар төрле халыклар (мари, рус, удмурт, татарлар) яшәгән авыллардан торган, ә волость үзәкләре рус авылларында урнашкан булган. Бу тәртип, Русиядә патша хакимияте җимерелеп, советлар хакимияте урнашкач та күпмедер вакыт сакланган әле. Бу губернадагы бердәнбер чыгарманы төрлечә аңлатып була торгандыр. Мәсәлән, реформа шартларында бу төбәктә дә канәгатьсезлек тудырмас өчен хакимият, Байлар волостеның бер өлешен Салагыш волостена бүлеп алып, күнегелгән идарәнең элементларын калдырырга булгандыр дип уйларга була.

«Алабуга өязендә, гомумән, сословиеләр һәм халыклар бик буталып беткән. Мәсәлән, хәзерге вакытта казна крестьяннары катлавына керүче һәм татар булып саналучы Әсән волостендагы Яңа Бәзәкә пүчинкәсендә яшәүчеләр, әле күптән түгел генә башкорт – типтәр - припущенниклар иде. Шуңа нигезләнеп, Яңа бәзәкәлеләрне “казна крестьяннарына караган татарлар, элеккеге типтәр-припущенниклардан булган башкортлар” дип

атыйлар. Әсән волостендагы күченүчеләр өчен казна тарафыннан әзерләнгән кишәрлекләрне алып (припущенник буларак, моны алар җиңел эшли алдылар), алар бу адымнары белән элеккеге катлауларыннан чыктылар һәм типтәрләрдән казна крестьяннары булып киттеләр; дөреслеккә туры килмәсә дә, үзләрен татар итеп саныйлар, чөнки татарлар белән алар тулысынча тәңгәлләштеләр. Башкалар аларны вотчинниклар яки припущенниклар дип уйламасыннар өчен дә үзләрен татар дип атыйлар”, - дигән аңлатма бирелгән “Алабуга өязе статистика мәгълүматлары” исемле җыентыкның кереш өлешендә.

Минем фикеремчә, бу мәгълүмат төбәкнең төрки телле мөселман халкы әле XIX гасырның икенче яртысында да этник төркемнәргә бүленмәгән бербөтен масса булып яшәвен күрсәтә. Шул ук вакытта ул чиновникларның да, халыкның да “башкорт”, “типтәр” атамаларын “казна (дәүләт) крестьяннары” атамасы белән тәңгәл санавын да аңлата. “Крестьян” (“христиан”нан барлыкка килгән төшенчә) һәм “татар” төшенчәләре алар өчен этник билгеләмә булган. Җыентыкны төзүчеләр дә, үзләренең хезмәтендә өяздәге мөселманнар хакында сүз барганда, еш кына “татар” сүзен кулланганнар.

Яңа чор башланганда, Бәзәкә авылы волостьта иң зур авылларның берсе булган. Алабуга өязенең 1859 елгы торак урыннары исемлегендә бирелгән мәгълүмат: “Бәзәкә – Бәзәкә инеше буенда өяз шәһәреннән 30, станнан 25 чакрым ераклыкта урнашкан *башкорт* авылы. Анда 265 хуҗалыкта 778 ир-ат һәм 725 хатын-кыз яши. Барлык халык мөселман динендә, *татар* кавеменнән”. Курсив белән аерым күрсәтелгән сүзләргә игътибар итик. Бу белешмәдә дә, алда сөйләнгән кебек, “*башкорт* авылы” сүзләре крестьян сословиесенең бер катлавын аңлата, ә “*татар* кавеменнән” дигән сүзләрнең этник атама икәнлеге ачык күренә. Белешмәдә авылда агач мәчет булуы, халыкның игенчелек һәм йөк ташу белән шөгыльләнүе дә күрсәтелгән.

Тагын бер искәрмә. Соңгы, 1858 елгы унынчы ревизиядә Бәзәкәдә 257 хуҗалыкта 757 ир-ат һәм 697 хатын-кыз күрсәтелгән иде. Алдарак китерелгән саннардагы аерма торак урыннары исемлегендә Корбансу авылында саналган кешеләрне Бәзәкә халкына кушып бирү белән аңлатыла. Ревизияләр вакытында алар аерым исемлектә бирелсәләр дә, Корбансу исеменә “шулай ук Бәзәкә” дигән сүзләр өстәлүе бу авылның гамәлдә Бәзәкә авылының бер өлешен тәшкил иткәнлеген аңлата.

Авыл халкы нинди генә чорда, нинди генә гасырда яшәмәсен, аның иң зур байлыгы җир булган. Бәзәкәләләрне гаскәри буйсынудан гражданлык халәтенә күчергәндә Бәзәкә вотчинасындагы җирләрнең аларның үзләренә дә җитмәгәнлеге ачык күренгән. Шуңа күрә 1858 елда ук Башкорт гаскәренең хәрби советы Бәзәкә типтәрләренә (РС 1816 буенча 43 җан) Минзәлә өязендәге Шикәрле Каен (Бәзәкәдән 50 чакрымда) һәм Каран-Азик (69 чакрымда) исемендәге күп җирле казна кишәрлекләреннән урын тапкан. Бу җирләрдә 1864 елда аларга 1832 елгы закон буенча тиеш булган утызар дисәтинә җир бүленеп бирелгән. Күченү исемлегенә керми калган типтәрләр (1858 елга Бәзәкәдә типтәрләрендә ир атлар саны 89-га җиткән була),

Бәзәкәдә җир бирелмәгәч, Тәкәш авылына күченгәннәр һәм егерме елга якын Тәкәштә үзләренә яңа җирдә кишәрлекләр бүлеп бирүне көткәннәр. Ниһаять, 80-елларда аларга да шул ук Алабуга өязендә Новоусовский һәм Крутовражский исемле кишәрлекләрне биргәннәр. 1884-1885 елларда монда Яңа Бәзәкә пүчинкәсе (Хәзер Әгерҗе районындагы шул исемдәге авыл) барлыкка килгән.

“Вятка губернасы статистика материаллары. Алабуга өязе” исемле җыентыкта бу авыл хакында бирелгән белешмә: “Яңа Бәзәкә (Новоусовский, Крутовражский) пүчинкәсе Уса инеше буенда, өяз шәһәреннән 72 чакрым, волость идарәсеннән 23 чакрым, мәчеттән 5 чакрым ераклыкта урнашкан. Аның указы булмаган үз мулласы бар; ул балалар укыту белән дә шөгыльләнә. Анда казнадан 58-номерлы Новоусовский һәм Крутовражский исемле ике кишәрлектән гыйбарәт “Яңа Бәзәкә” җирлеген кабул итеп алган типтәрләр яши. Бәзәкә авылында алар электән припущенник булып яшәгән. Ләкин 1860-елларда борынгыдан җир хуҗасы булган бәзәкәләләр куып җибәргәч, типтәрләр Күрәк волосте Тәкәш авылына күченеп, егерме елга якын бөтенләй җирсез яшәгәннәр. Тәкәштән алар Яңа Бәзәкә җирләренә 1884-85 елларда күченгән. Яңа Бәзәкәдә ревизиягә кергән 24 һәм исемлектә күрсәтелмәгән 12, барлыгы 36 җан санала. Аларга җир башта исемлеккә кергән җан исәбеннән бирелгән; 1887 елда җирне, һәр хуҗалыкта икешәр җан санап, яңадан 40 кишәрлеккә бүлгәннәр; бары тик бер солдат һәм бер ятимгә берәр җаннан торган кишәрлек бүленгән. Псәй авылы кешесенә алты дисәтинә урман кишәрлеген, чистартып, чәчүлек җире ясау, урман материалларын арендатор куллану шарты белән җәмгыять 12 сумнан 12 елга арендага биргән. Мал-туар авыл кырларында көтүчесез йөри”.

Шулай итеп, 60-еллар уртасыннан Бәзәкәдә җир хуҗалары – вотчинниклар гына калган. Ләкин типтәр-припущенниклардан кайтарылган җир дә гамәлдә авыл халкының җиргә кытлыгын үзгәртмәгән, чөнки 1859 елга, РС 1816-да күрсәтелгән ир-ат саны белән чагыштырганда, халык саны икеләтә арткан була инде. Ә бу бер җанга 5 дисәтинәдән бераз гына артык җир туры килгән дигән сүз. Бу 5 дисәтинәгә чәчүлекләрдән тыш урман-әрәмәлекләр, болыннар, күлләр, сазлыклар һәм башкалар керүен, 1805 елда ызанлау уздырганда 4050 дисәтинәнең 903 дисәтинәсе генә чәчү җирләре саналганлыгын исәпкә алыйк. XIX гасырның икенче яртысында Салагыш волостенда чәчүлекләр барлык биләмәләрнең биштән берен алып торган. Бу уртача санны Бәзәкәгә карата куллансак, бер җанга бер дисәтинәдән бераз артыграк чәчүлек туры килгән дип билгеләп була.

Урманнар хакында. Ызанлау чорында Бәзәкә дачасының 2300 дисәтинәдән артык җирендә төзелешкә һәм утынга яраклы урман-әрәмәлекләр булганын күргән идек. XIX гасырның 70-нче елларына урманнар юкка чыккан, әрәмәлекләр генә калган. Бәзәкә урманнары бигрәк тә 30-50-елларда бетерелүгә дучар булган, чөнки нәкъ бу чорда анда хәзерләнгән бүрәнә Оренбург линиясендәге торак җирләр-ныгытмаларны төзүдә кулланылган. Калган агачларын, төпләп, Урал заводлары өчен күмер һәм поташ та (селте үзлекләре булган ак матдә) хәзерләгәннәр. Авылны 40-50

елларда яңа план белән төзегәндә, һәр хуҗалыкка 200 агач бүленүен дә исәпкә алсак, шактый агач төпләнгән. Нәтиҗәдә 80 - еллар уртасына Салагыш волостеның Турай бүлемендә утынга һәм колга-казыкка (киртәгә) яраклы агачлар гына, ә Бәзәкә биләмәсендә, гомумән, куаклыклар гына (әрәмә) калган була.

Бәзәкә авылы кергән Салагыш волостеның икътисадый хәлен аның идарәсе 1874 елда Вяткага җибәргән рапортыннан күреп була. Волостьта 16 авыллы 6 җәмгыять саналган (Бәзәкә һәм Корбансу авыллары аерым җәмгыять тәшкил иткән). Анда барлыгы 1506 йорт (1503 крестьян йорты һәм 3 йортта җәмгыять оешмалары урнашкан) һәм 13 мәчет исәпләнгән. Волостьта ике запас ашлык магазины (ул чорда бу сүз белән кибет түгел, ә саклау урыны аталуын искә төшерик) һәм дүрт амбар булган. Аларда 972 чиректән бераз артыграк уҗым ашлыгы һәм 412 чирек сабан ашлыгы сакланган (1 чирек – якынча 8 пот исәпләнгән). Шул ук вакытта волость халкының 1158 чирек уҗым һәм 740 чирек сабан ашлыгыннан гыйбарәт недоимкасы булган.

Бу чорда халык санын белү өчен волость идарәләрендә гаилә исемлекләре төзелгән. Волостьта 1874 елда крестьян гаиләләрендә 4590 ир-ат һәм 4424 хатын-кыз, рухани гаиләләрендә 26 ир-ат һәм 52 хатын-кыз яшәгән. Волостьтагы җир күләме 43734 дисәтинә булган; шуның 307 дисәтинәсе хуҗалык урнашкан җирләр, чәчүлекләр – 4651, урман-әрәмәлекләр – 23959, көтүлекләр – 2841, болыннар – 3134, эшкә ярамаган уңайсыз җирләр 8841 дисәтинә тәшкил иткән. Шул ук елда 3251 чирек ашлык чәчелгән: уҗым 1846 чирек, 52 чирек сабан бодае, 68 чирек арпа, 870 чирек солы, 90 чирек кара бодай һәм 1254 чирек калган бөртеклеләр чәчелгән. 13909 чирек уңыш җыелган: 8307 — арыш, 236 — бодай, 272 — арпа, 3480 — солы, 360 — кара бодай һәм 1254 чирек башка бөртекле ашлык алынган. Шулай ук 397 пот җитен һәм 315 пот киндер орлыгы чәчелгән; ул чәчүлекләрдән җитен орлыгы 397 пот, сүсе 494 пот, киндер орлыгы 487 пот, сүсе 417 пот алынган. Волостьтагы атлар саны 2140 баш, мөгезле терлек 2480 баш, сарык 3464 баш булган. 135 умартачының 2218 умартасы булган; алардан 272 пот бал, 51 пот балавыз җыелган. Бер хуҗалыкка уртача 1,4 баш ат, 1,6 баш мөгезле терлек, 2,3 баш сарык туры килгән. Бу мәгълүматлардан без 1874 елда волостьта уңыш уртача булган дип бәяли алабыз.

Ул заманда уңышны чәчелгән ашлыкның күләме белән чагыштырып билгеләгәннәр (мәсәлән, бер чәчелгән орлыкка биш җыелган орлык туры килгәндә, уңышның коэффициенты 1:5 булган, ул “сам-пят” дип аталган). XIX гасырның икенче яртысында Русиядә гадәти уңыш “сам-3” – “сам-5” булган: “начар елларда “сам-друг”ка кадәр (1:2) төшкән, яхшы елларда “сам-4”, “сам-5”ка кадәр күтәрелеп, гасырлар дәвамында “сам-3”дан уза алмаган. “Бу уңыш, нигездә, игенченең үз гаиләсенә генә ашарга җиткән”, - дигән бәяләмә биргән Америка галиме Р.Пайпс “Россия при старом режиме” исемле хезмәтендә.

Салагыш волостенда 1874 елда җыелган уңышны “сам”нарга күчерсәк, “сам-4,28” килеп чыга. Русия шартларында бу уңышны уртача дип бәяләдек.

Р.Пайпс билгеләвенчә, “1:4 коэффициенты игенчелек белән шөгыльләнүгә ниндидер мәгънә бирә, чөнки бу очракта халыкны тукландырып була. [...] Бер чәчелгән орлыкка, иң кимендә, биш орлык җыйганда гына цивилизация башлана дип әйтергә була; азык-төлек читтән кертелмәгәндә, халыкның күп өлешенә азык-төлек җитештерүдән башка төр хезмәткә күчү мөмкинлеген нәкъ шушы минимум билгели. Түбән уңышларга дучар илдә югары үсешкә ия сәнәгать, сәүдә, транспорт була алмый”.

80-елларда земстволар үз губерналарындагы крестьян хуҗалыкларын тикшерүне башлап җибәргән. Вятка губернасында крестьяннарның икътисадый хәлен анкеталар аркылы киңәйтеп тикшерү 1884-1893-елларда узган. Аның нәтиҗәсе күптомлы “Вятка губернасы статистикасына караган материаллар” исеме белән дөнья күргән. Алабуга өязе һәм андагы авылларның икътисадый халәтен тасвирлауга “Материаллар”ның ике җыентыктан торган алтынчы томы багышланган (җыентыклар 1889-1890-елларда Вятка шәһәрендә басылган). Җыентыкларның беренчесендә өяздәге җирләрне тасвирлаган материаллар урын алган: өязнең территориясенә һәм җир биләмәләренә, туфрагына, игенчелеккә һәм уңышка, печәнлекләргә җентекле характеристика бирелгән. Шулай ук җыелган ашлык, җир һәм болыннарны арендага алу, кул көче бәяләре күрсәтелгән. Икенче җыентыкта авылларның тасвирламасы урын алган. Анда авылның демографиясе, иҗтимагый-икътисади халәте, хуҗалыкларның хәле, һөнәрчелекнең үсеше, умартачылык һәм башка кәсепләр, уку-укыту хакында да мәгълүмат бар. Мондый тасвирламаның үрнәге итеп, алдарак китерелгән Яңа Бәзәкә авылы тасвирламасын күрсәтергә була. Ә менә Бәзәкә авылы хакында (шулай ук Салагыш волостена караган башка авыллар хакында да) китапта мондый тасвирлама юк.

Җыентыкларда бирелгән искәрмәләрдән мондагы җирбиләүче татар һәм типтәрләр үз хуҗалыкларын тасвирлаудан баш тартканлыгы аңлашыла. Ә чиновниклар, күрәсең, баш күтәрүләр башланудан куркып, аларны мәҗбүр итмәгәннәрдер, чөнки авыл халкы баш күтәрү өчен башка сәбәпләр дә җитәрлек булган. Өяз крестьяннарының икътисадый хәле елдан-ел начарая баруы недоимкаларның үсүенә китергән; шуңа карамастан, хөкүмәт йөкләмә-салымнарны арттыра барган. Мөселман халкын патша хөкүмәтенең дини һәм милли сәясәте дә сагаерга мәҗбүр иткән. Яңа йөкләмә-салымнарның артуы, милли-дини басым үсүенә җавап буларак, 1878-1879 елларда Идел-Уралда татар крестьяннарының хәрәкәте күтәрелгән. Салагыш волостенда актив чыгышлар булмаса да, халык арасындагы киеренкелек ачык сизелгән. Җирле хакимиятнең һәрбер әмере (бигрәк тә язма булганда) төрле имеш-мимешләр, мәсәлән, мондый очракларда киң урын ала торган мөселманнарны чукындыру, җир кишәрлекләрен киметү кебек хәбәрләр таралуга сәбәп булган. Шуңа күрә бу очракта да һәр хуҗалыкның хәлен тикшерү хакындагы әмер волостьта яшәүче халыкны шомга салгандыр дип уйларга була. Ә Алабуга өязе җитәкчелеге, халык хәрәкәтен кузгатмас өчен, хуҗалыклардан белешмәләр алмыйча, волость идарәсендә булган авыллар хакындагы мәгълүматны гына файдаланырга булгандыр дигән нәтиҗәгә киләбез.

Вятка губернасына караган гомуми мәгълүматлардан башлыйк. Губернада бер татар хуҗалыгына уртача 12,3 дисәтинә, бер башкорт хуҗалыгына 16,2 дисәтинә имана җире туры килгән. Милек күләме буенча төркемнәргә бүлеп караганда, түбәндәге хәл ачыклана: татарларда җирсез яки аз җирлеләр (1-10 дисәтинәле) барлык хуҗалыкларның 47,5%, 10-25 дисәтинәле уртача җирлеләр — 45,4%, җирләре 25 дисәтинәдән артык булган күп җирлеләр — 7,1% тәшкил иткән. Башкортларда шул ук күләмдәге кишәрлекләрнең чагыштырмасы — 30,4%, 50,7% һәм 18,9% булган. Хуҗалыкларның мөмкинлеген күрү өчен мал күләменә дә игътибар итик. Уртача бер хуҗалыкка (малны эре терлеккә күчереп санаганда) татарларда 2,4 баш, башкортларда 2,5 баш туры килгән. Хуҗалыкның хәлен билгеләү өчен крестьян тормышында зур роль уйнаган ат санын белү мөһим булган. Түбәндәге таблица бер хуҗалыкка туры килгән ат саны буенча чагыштырма материал бирә.

Таблица № 6

Вятка губернасында татар һәм башкорт хуҗалыкларында ат саны

хуҗалыклар	татарлар	башкортлар	бәзәкәлеләр
малсыз	18,2%	17,9%	9,9%
атсыз	33,4%	32,2%	19,8% (61)
бер атлылар	44,9%	46,2%	27,7% (116)
ике атлылар	15,5%	14,9%	19,2% (59)
күп атлылар	6,2%	6,7%	23,4% (72)

Игътибар итик: татар һәм башкорт хуҗалыкларында атлы-атсызлар арасында бүленеш бер тирәдә булган. Ә бәзәкәлеләр исә бу бүленешкә чыгарма булып торган. Моның сәбәпләрен соңрак тикшерербез.

“Статистика материаллары” җыентыгында Салагыш волосте җирлегенә бирелгән тасвирламадан өзекләр: “Күрәк волосте җирләре арасындагы берничә авыл (Псәй, Турай, Сарсаз, Бәзәкә) волость идарәсе булган Салагыш авылыннан 20-25 чакрым ераклыкта урнашкан. Салагыш волосте чикләреннән аларны Күрәк һәм Әсән волостьларындагы авыллар аерган. [...] Гомумән, Салагыш волосте өязнең биш аерым җирлегенә таралган. Ул, башка волостьлар кебек, чикләре берләштергән аерым территориаль берәмлек түгел; ә сословиегә бәйле административ берәмлек буларак барлыкка килгән, чөнки волостьнең бар халкын җир хокукына ия булган вотчинниклар – башкорт һәм типтәрләр тәшкил итә”. Бу аңлатмадан соң Салагыш волостендагы басу-кырларның тигез булуы, бары Бәзәкә басуының гына Сәйтәк авылына килеп җиткән урында калкулыклар, чокыр-ерынтылар күп булуы күрсәтелгән.

Авылларның тасвирламасы сораулар басылган махсус бланкларда аларга җавап формасында бирелгән. Бәзәкә авылы хакындагы мәгълүмат 1887 елда тутырылган ике бланктан гыйбарәт. Корбансу авылы белән бергә Бәзәкә аерым авыл җәмгыяте саналган. Казна палатасының 1866 елда төзелгән салым кәгазьләрендә анда 685 ир-ат һәм 649 хатын-кыз теркәлүе күрсәтелгән. 1861-елгы Крестьян реформасын уздырганда, крестьяннар дистәләгән разрядларга бүленгән була. Бәзәкәлеләрнең разряды тасвирламада “мир

кулланышындагы үз җирләре булган хәрби идарәнең элеккеге башкортлары, хәзер гражданлык хокукларына ия ирекле обывательләр” дип билгеләнгән.

Мир милкендә барлыгы 2990 дисәтинә җир исәпләнгән, шуның 992 дисәтинәсе чәчүлекләр булган. Җирләргә шәхси һәм башка төрле милек авылда булмаган. “Казна палатасының салым кәгазенә Бәзәкә авыл җәмгыятендә ике авыл – Бәзәкә һәм Корбансу язылган. Ләкин гамәлдә бер авыл гына бар – Бәзәкә авылы. Ә Корбансу халкы Бәзәкәдә яши”, - дип искәртеп, волость старшинасы Ахунҗан Фазуллин кул куйган. Бәзәкәдә 225 хуҗалыкта 243 йорт булуы, ул йортларның 240 агач (такта һәм дранча) түбәле һәм бары өчесе генә салам түбәле булуы күрсәтелгән. Ике агач мәчет, шулай ук агачтан салынган такта түбәле ике ашлык запасы магазины, яши торган йортның астында сату-алу кибете, Бәзәкә инешендә су көче белән тарттыра торган ике он тегермәне булган.

Чәчүлекләр, болыннар, көтүлекләр һәм башка шундый җирләр белән бәзәкәлеләр бергә файдаланганнар. Аларның төп шөгыльләре игенчелек булган. Җирләр туфрак сыйфатына карап түгел, ә кишәрлекләрнең зурлыгыннан чыгып бүленгән: бер җанга һәр басу һәм болында җирәбә буенча берәр кишәрлек бирелергә тиеш булган. Кишәрлекләрнең киңлеге бер җанга 3 сажиннан 10-15 сажинга кадәр чыккан. Чиновниклар татарларның җирләрен вак кишәрлекләргә бүлүне яратмауларын да искәртеп язганнар. “Татарлар, табигатьтән килгән чиксез энергияләре аркасында үзләренең кечкенә хуҗалыкларындагы эшләрен бик тиз бетерәләр, һәм өйдә кул кушырып утырмас өчен, эшне, киресенчә, бик акрын башкара торган арларга эшкә ялланалар. Гомумән, эшне уңышлы һәм бик тиз башкаруда татарлар башка өяз халыклары арасында беренче урынны алып тора; алар артыннан руслар, чирмешләр һәм, нинаять, арлар бара”, - кебек үзенчәлекләр дә аларның күзеннән читтә калмаган.

Бәзәкәлеләрнең төп һөнәре булган игенчелеккә киңрәк тукталыйк. Волостьта кыр эшләрендә гадәти өч басуга бүлеп эшләү системасы кулланылган, ягъни ел саен алмаштырып, бер басуга уҗым, икенчесенә сабан ашлыгы чәчкәннәр, өченчесе ял иткән. Арышны көздән уҗымга чәчеп калдырганнар. Сабан басуында яртысына солы, чирегенә борай чәчелгән; калган чирегенә арпа, бодай һәм бик аз күләмдә карабодай, җитен, киндер, борчак, ясмык чәчкәннәр, бәрәңге басуда бик кечкенә урын биләгән, аны өй янындагы бакчаларда үстергәннәр. Җитен, киндер, борчак, ясмыкны бер хуҗалыкка 5-10 кадак кына чәчкәннәр. Ашлама – тирес – күбесенчә беренче кар төшкәч, авыл янындагы кырларга гына чыгарылган. Өемнәрдә кышлаган тиресне, язын кишәрлектә таратып, ашлык чәчелгәннән соң тырмалаганнар яки сөргәннәр. Тирес кергән җир парга калдырылган, көзен арыш чәчелгән; арыштан соң сабан ашлыгы, сабаннан соң парга калган. Туфракны эшкәрткәндә бер төрәнле җиңел сука, авыр җирләрдә ике төрәнле авыр сабан да кулланылган. Ызанның тирәнлеге 12-15 см булган. Җиңел туфракта бер кеше ат белән көнгә 2/3 дисәтинә, авыр балчыклы туфракта 1/3 дисәтинә сукалаган.

Бер дисәтинә җиргә уртача 10 пот арыш, 12 пот борай, 13-14 пот солы, 9 пот арпа, 10 пот бодай, 5 пот карабодай, 9 пот җитен чәчелгән. Орлыкка үзләре үстергән ашлыкны гына кулланганнар. Сабан ашлыгын, төбәктәге башка авыллардагы кебек, апрель азагы-май башында чәчкәннәр: башта солы, аннан арпа, борай, борчак киткән, җитен, киндер, карабодайга чират 20 май тирәсендә җиткән. Арышны күпчелек авылларда тырма астына, бик азында сукалап чәчкәннәр; сабан ашлыгын бөтен авылларда тырмага чәчкәннәр. Арыш урагы 20 июльдән башланган, сабанга 1 августта тотынганнар. 1 августтан уҗым арышны да чәчә башлаганнар. Ашлык урак белән урылган, борчак чалгы (литовка) белән чабылган. Урылган ашлыкны, көлтәләргә бәйләп, кырда сосланнарга һәм бәбкәләргә тезгәннәр. Соңрак хуҗалыктагы ындырларга алып кайтып, саклар өчен кибәннәргә салганнар. Ашлыкны чи килеш кулдан чабагачлар белән сукканнар, агач көрәкләр белән җилгәргәннәр. Әвеннәр булмаган, ашлыкны өйләрдә һәм мунчаларда киптергәннәр. Статистика җыентыгында ашлык бәясе дә күрсәтелгән: 1887 елның көзендә арышның поты 32-34 тиен, солыныкы 23 тиен булса, язын арышның поты 40 тиенгә җиткән.

Кама үзәнендәге болыннарның муллыгы, үләннең куелыгы, киң яфраклы, озын булып үсүе күрсәтелгән. “Печәнгә 20 июньнән төшәләр. Кама буе печәнлекләре дисәтинәдән 275 пот печән бирә. Волостьның болыннары, урман-кырлары көтүлекләр өчен файдаланыла. Көтүләр болынга печән чабылганнан соң чыгарыла, аңа кадәр урман-кырларда йөри. Волость көтүлекләре, башкалар белән чагыштырганда, бик яхшылардан санала – маллар беркайчан да ач калмый. Көтүлекләр барысы да коры һәм мул үләнле җирдә. Бәзәкәдә киртә белән бүленеп алынган аерым утарлар бар. Анда күбрәк бозау көтәләр. Көтүләр көтүчесез йөри”.

Волостьтагы малның күләме дә күрсәтелгән: 1887 елда волостьтә 2044 зур ат, 486 яшь ат, 1306 савым сыер, 1167 тана, 3932 сарык һәм 1680 кәҗә асралган, эре терлеккә күчереп санаганда, барлыгы 4740 баш мал булган, ягъни, бер хуҗалыкка 2,5 баш туры килгән. Бөтенләй мал-туары булмаган 269 хуҗалык, яки бар хуҗалыкларның 14,4 %, атсыз хуҗалыклар 312 (27,5 %), сыерсыз хуҗалыклар 932 (51,1 %) булган. Һәрбер хуҗалыкта йорт тирәсендә кечкенә генә яшелчә бакчасы булган. Анда берничәшәр түтәл суган, бәрәңге, кишер, шалкан, чөгендер кебек яшелчәләрне үстергәннәр. Йорт янындагы кишәрлекләргә, мөмкинлек булганда, ел саен тирес кертелгән.

Бу вакыт эчендә җан башына туры килгән җир күләменең дә кимүенә игътибар итик. Икътисадчылар исәбенчә, ул чорда Идел-Урал төбәгендә тормыш алып барыр өчен җан башына якынча 5 дисәтинә җир кирәк булган. Статистиклар санавы буенча, Вятка губернасындагы татарларның 1 хуҗалыгына уртача 12,3 дисәтинә, башкортларда - 16,2 дисәтинә туры килгәнен язып үткән идем. Ягъни, татар һәм башкорт хуҗалыкларында җир җитәрлек булып саналган, чөнки 10 дисәтинәдән кимрәк җир туры килгәндә генә хуҗалык аз җирле исәпләнгән. 1860-1880 елларда Бәзәкә биләмәсенә кергән җирләр күләме кимүен күрәбез. Әгәр дә 1866 елда Бәзәкә вотчинасында 4050 дисәтинә җир исәпләнүен язган булсак, 1887 елда бу

биләмәдә 2990 дисәтинә генә булуы күрсәтелгән. Бәзәкәләләрнең артык җирләре булмавы хакында әйтелгән иде инде. Бер меңнән артык дисәтинә җирнең юкка чыгуы хакында безгә бернәрсә дә билгеле булмаса да, без бу җирләр, бәлки, недоимка түләү өчен сатылгандыр дип кенә әйтә алабыз.

1890-елларга Бәзәкәдә бер хуҗалыкка 9,7 дисәтинә җир туры килгән, аның 1,9 дисәтинәсе чәчүлек җирләре булган. Димәк, бәзәкәләләр гасыр азагында аз җирлеләр рәтендә булганнар. Әлбәттә, бу уртача сан авылда барлык хуҗалык та җиргә кытлык кичергән дигән сүз түгел. Ләкин җир җан башыннан чыгып бүленгәндә, хуҗалыкта ир-атлар күп булган очракта гына аның җире дә җитәрлек булган. Соңгы тапкыр җир бүлү Бәзәкәдә 1866 елда окладка (дәүләткә салым түләүчеләр исемлегенә) керткәндә булган. Мисал өчен җиде кешедән торган ике хуҗалыкны алыйк. Бер гаиләдә биш малай, икенчесендә биш кыз үсә ди. Димәк, беренчесенә алты имана җир, икенчесенә бер имана җир туры килгән була. Һәм бу бүленеш җирне яңадан җан башыннан чыгып бүлгәнчегә кадәр сакланган. Закон буенча җирне яңадан бүлү унике елга бер тапкыр мөмкин булса да, җирләренә үзләре хуҗа булган Бәзәкәдә бу бүленеш башка уздырылмаган.

Авылда мул тормыш алып бару өчен хуҗалыкта имана җире күп булу гына җитми, аны эшкәртүче эшче көчләр дә кирәк. Димәк, авыл халкы тормышында игенчелек кебек үк зур роль уйнаган терлекчелек хакында да сүз булырга тиеш. Крестьяннар малны нигездә үз хуҗалыкларында куллану өчен асраганнар. Атлар һәм үгезләр (бик сирәк очракта) хуҗалыктагы эшләрне башкару, йөк ташу өчен кулланылган. Йорттагы терлек һәм кош-корт гаиләне ит, сөт һәм йомырка белән тәэмин иткән, шулай ук һөнәрчелек һәм йорт кирәк-яраклары өчен чимал биргән (тире, йон, сөяк, кош мамыгы h.б). Крестьян хуҗалыгында атның булу-булмавы бик зур әһәмияткә ия булуын тагын бер мәртәбә ассызыклыйм. Аты булмаган игенче үз имана кишәрлеген вакытында эшкәртә алмаган, соңга калып сукалаган, соңга калып чәчкән. Чөнки аңа, бу эшләрне башкарыр өчен, читтән ат алып торырга яки кеше яллап эшләтергә туры килгән. Маллары булмаган хуҗалыкларның басуларын ашларлык тиресе дә булмаган, димәк, җирнең уңдырышлыгы да кимрәк булган.

Реформадан соңгы чорның үзенчәлеге – авылдашлар арасында мөлкәт ягыннан катлауларга бүленүнең көчәюе. Бу процессны җан башына бәйле имана мисалында түгел, ә хуҗалыктагы атлар саныннан караганда ачык күзәтеп була. Минем карамакта Бәзәкә авылында 1889-1891 елларга караган атлар саны хакындагы мәгълүмат бар. Чагыштырып карыйк. 1889-1890 хуҗалык елында Бәзәкәдәге 309 хуҗалыкта 17 айгыр, 179 алаша, 242 бия - барлыгы 438 эшкә яраклы ат һәм 121 үсмер ат (колын, тай, байтал h.б.) булган. Шул 309 хуҗалыкның 61-е атсыз, 117-се бер атлы, 59-ы ике атлы, 72-сендә өч һәм күбрәк эшкә яраклы ат булган (үсмер атлар исәпкә алынмады). Димәк, авылның 178 хуҗалыгы ярлылар катлавын, 59 хуҗалык – урта хәлле, ә 72 хуҗалык хәллеләр катлавын тәшкил иткән. Авыл ярлылары күп очракта үз иманаларын баерак авылдашларына арендага биргәннәр, чөнки, маллары булмау сәбәпле, үз җирләрен үзләре эшкәртә алмаганнар. Шулай имана

җирләренең шактый өлеше байлар кулында тупланган. Бу факт та Бәзәкәдә крестьяннар арасында барган *поляризациянең* (капма-каршы катлауларга бүленүең) көчле булуын күрсәтә. Ләкин аның Бәзәкәдә авыл хуҗалыгы өлкәләренә бәйле рәвештә түгел, бәлки бәзәкәлеләрнең капиталистик мөнәсәбәтләргә активрак тартыла башлавын күрсәтә торган фактор булуына игътибар итик.

Игенчелектән һәм терлекчелектән килгән керемнең түбән булуы гаилә әһелләрен табыш китерә торган ниндидер өстәмә һөнәр белән шөгыльләнергә мәҗбүр иткән. Патриархаль тормыш көткән бәзәкәлеләрнең, башка авылларда яшәүчеләрнеке кебек үк, борын-борыннан өстәмә ярдәмчел һөнәрләре булган. Авылларда үз тире эшкәртүчеләре, читек-кәвеш каючылары, тун-толып һәм башка өске кием тегүчеләре булган кебек, балта осталары, мич чыгаручылары һәм башка авыл тормышында кирәк булган эшләрне башкаручылар да булган. Гомумән, савыт-сабадан алып, арба-чанага кадәр барлык хуҗалык кирәк-яракларын авыл осталары башкарган. Хатын-кызлар да ир-аттан калышмаган. Йортны алып бару, бала тәрбияләү, ашау хәзерләүдән тыш, алар кышларын армый-талмый җеп эрләгән, киндер-киҗе суккан, тула баскан, кием-салым теккән-чиккән, оек-оекбаш, бияләй, шәл, челтәр бәйләгән, өен бизәгән, ә кыр эшләре башлангач, ирләр белән бергә басу-кырларда, болыннарда да эшләгән. Вакыт узуы белән, әлбәттә, өйдә сугылган тукымаларны “фабричный” ситцылар алмаштыра башлаган, ләкин көндәлек кием булып өйдә хәзерләнгән кием калган.

Унтугызынчы гасыр азагына Бәзәкәдә, кәсепкә әйләнеп, нинди шөгыльләр сакланган соң? Монда да, башка авыллардагы кебек, тире эшкәртүгә бәйле һөнәрчелек – аяк киеме тегү, ат дирбиясе һ.б. хуҗалыкта кирәкле нәрсәләр өчен тире-күн куллану, агач эшкәртү - арба-чаналар, тәртә-дугалар һ.б. ясау киң таралган; тырма-көрәк кебек коралларны да үзләре ясаганнар, чабата үрү белән дә шөгыльләнгәннәр. Үз хуҗалыгында куллану яки күршеләр белән алмашу өчен хәзерләнә торган әйберләр акрынлап сатыла торган товарга әйләнгән, күпмедер керем китерә башлаган.

Мәсәлән, чабата үрү белән гадәттә үз өйләрендә картлар һәм балалар шөгыльләнгән; ә 1877 елда Бәзәкәдә дүрт кеше чабатаны сату өчен үргән – алар елга 720 пар татар чабатасы үреп, базарларда сатканнар һәм бу һөнәрдән икешәр сум керем алганнар. Күп хуҗалыкларда чыпта-каплар сукканнар. 32 кеше чана ясау белән шөгыльләнгән (елга 800 чана ясау аларга 35 сумнан 75 сумга кадәр табыш китергән). 15 кеше карамадан дуга бөгү белән шөгыльләнгән (барлыгы елга 1500 дуга ясалган, һәрбер һөнәрче 10-20 сум керем алган); 5 кеше имәннән 250 пар чана табаны ясап саткан, 2 кеше шомырт чыбыгыннан әрҗәләр үргән (75 әрҗә сатылган); бер кеше туладан 40 эшләпә басып, 15 сум керем алган.

Бу мәгълүмат китерелгән документта җир кишәрлекләренең кечкенә һәм халыкның буш вакыты күп булуы бу кәсепләрнең 15-20 ел элек барлыкка килүенә сәбәп итеп күрсәтелгән. Шулай итеп, авылга капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керүен күрсәткән бу мәгълүмат авыл хуҗалыгында ярдәмчел роль үтәгән һөнәрчелекнең XIX гасыр азагына кәсеп формасын

алып, сату өчен товар хәзерләүгә күчүен тасвирлый. Игенчеләр бу кәсепләре белән үз йортларында шөгыльләнгән. Әзер товарны алар үзләре базарларда саткан яки алыпсатарларга һәм эшмәкәрләргә тапшырган. Өлгеррәк булган эшмәкәр-авылдашлар шулай баеп, тора-бара әзер товарны сатып алуны гына үз өстенә алган. Мәсәлән, үзләре әзерләгән кайры-мунчаладан кап сугу белән шөгыльләнүчеләрдән эшмәкәр әзер товарны сатып алган һәм аны Озын Тау һәм Ык Тамагы пристаньнарына илтеп саткан, чөнки анда капка сорау бик күп булган. Китерелгән саннар арба-чана ясауда бәзәкәлеләр җитештерү эшен өлешләргә бүлеп эшләгән, ягъни бу өлкәдә мануфактура элементлары күренә дигән нәтиҗә ясарга да мөмкинлек бирә.

Җир азлыктан, мал юклыктан интеккән ярлылар тормыш өчен кирәкле керемне һөнәрчелек-кәсепчелек ярдәмендә дә тулысынча таба алмаганнар. Ярлылана барган авылдашларның бер өлеше, үзенең имана җирен арендага биреп, акрынлап авыл хуҗалыгыннан аерыла һәм яллы эшчегә әверелә барган. Бабаларыбыз авылдан вакытлыча читкә китеп тә эшләгәннәр – урман кискәннәр, бүрәнә ташыганнар, сал агызганнар, такта ярганнар һ.б. эшләр башкарганнар. Вятка статистика комитеты күрсәтүенчә, 1874 елда 277 бәзәкәле авылдан читкә китеп эшләгән. Ләкин авылны бөтенләйгә ташлап читкә китүчеләр бик сирәк булган.

Унтугызынчы гасырның урталарыннан Алабуга өязендә химия сәнәгате зур үсеш алган. 1-гильдияле Алабуга сәүдәгәрләре Ушковлар, өяздә җирләр сатып алып, шунда химия заводларына нигез салганнар. 1850 елда Алабугадан 30 чакрым ераклыкта булган Кокшан авылы янында К.Я.Ушков Кокшан химия заводына оештырган. Бу завод яхшы гына эшләп киткәч, аның улы П.К.Ушков 1868 елда Тойма елгасы буенда урнашкан Бондюга авылы тирәсендә икенче заводны эшләтеп җибәргән. Кокшан заводына чимал аннан шулай ук 30 чакрымдагы Ык Тамагы авылы янында Кама буенда төзелгән пристань аркылы килсә, Бондюг заводы өчен Озын Тау авылы янында махсус пристань булдырылган. Заводларын эш көчләре белән тәэмин итү Ушковлар өчен авыр булмаган: тирә-юньдәге авыллар, бигрәк тә кытлык еллардан соң, теләсә нинди эшкә керешергә әзер торган бик күп эшче биргән.

Күп кенә бәзәкәлеләр дә авылдан берсе егерме-утыз, икенчесе ун чакрымда урнашкан бу заводларда үзләренә эш тапканнар. Башта алар, завод цехларын салганда, урман төпләү, җир чистарту, казу, төзү кебек эшләрдә катнашканнар. Заводлар эшли башлагач, үз атлары – олаулары белән пристаньнардан заводларга чимал, кире юнәлештә завод продукциясен ташыганнар. Иң таралганы – Бәзәкәдә Ушков заводлары өчен 20 литрлы бутыльлар утырта торган кәрҗиннәр үрү, төрле әрҗә, каплар ясау булган. Шулай XIX гасыр азагына авылда һөнәрчелеккә алмашка кәсеп килгән.

Бу кәсепнең Бәзәкәдә үсеп китүенә авылның табигате дә ярдәм иткән: авыл биләмәсендәге тал, шомырт кебек куаклыклар белән капланган күпсанлы күлләр һәм инеш ярларында чимал җитәрлек булган. Элек тә хуҗалык өчен кирәк булган әрҗә-кәрҗиннәрне шомырт һәм талчыбыктан үргән бәзәкәлеләр бу эшне заводларның даими заказы белән башкара башлаганнар. Араларында табылган уңганрак-башлырак эшмәкәрләр, заводка

приказчик булып урнашып, зур заказны авылдашлары арасында тараткан. Бәзәкәлеләр үз өйләрендә эшләгәннәр, ә алар өчен эш бирүче – хуҗа саналган приказчик, әзер кәрҗиннәрне җыеп алып, акчасын түләгән, заводка илтеп тапшырган. Шулай Бәзәкәдә кәрҗин үрү буенча мануфактура тибындагы Ушков заводының ярдәмчел һөнәрханәсе - әртил барлыкка килгән, ә вак һөнәрчеләр ялланып эшләүче эшчеләргә әйләнә башлаган. Кәрҗин үрү белән күбрәк ярлылар шөгыльләнгән. Алар пристаньнарда грузчик та булганнар, заводта кара эшкә дә ялланганнар. Ә хәллерәкләр, ике-өч һәм күбрәк атлары булганнар, заводлар өчен йөк ташу белән шөгыльләнгәннәр.

Шундый эшмәкәрләрнең берсе Гыйльмебәшар Шәмсебәшар улы Шоңкаров булган. Аның XIX гасырның беренче чирегендә йорт старшинасы булып, шәхси дворянин дәрәҗәсенә ирешкән Зәйнебәшар Шоңкаровның оныгы икәнен искә төшерик. 70-90 елларда Гыйльмебәшар авылның иң зур байларыннан саналган. 1897 елгы беренче Бөтенрусия халык санын алу материалларында 48 яшьлек Гыйльмебәшар хакында түбәндәге мәгълүмат бирелгән: төп шөгыле – игенчелек, өстәмә шөгыле - сәүдәгәрдә хезмәт итү. Аның хуҗалыгында өч йорт булган (берсе калай, калганнары такта түбәле); 80 яшьлек әнисе, 43 һәм 25 яшьлек ике хатыны, 1 айдан 14 яшькә кадәр булган алты улы һәм 10 яшьлек бер кызы булган. Гыйльмебәшар үзе, әнисе, икенче хатыны, кызы һәм уку яшендәге өч улы мөселманча укый-яза белгәннәр. Хуҗалыктагы эшләрне башкару өчен анда ялланып эшләүче өч ир-ат хезмәтче (берсе рус милләтеннән) һәм бер асрау кыз булган. Шулай итеп, Гыйльмебәшар Шоңкаровның хуҗалыгында 10 ир-ат һәм 5 хатын-кыз яшәгән, ягъни бу хуҗалыкта кеше саны да иң зурлардан булган.

“Ниләр килмәде безнең бу башка...”

Их син, тормыш...
Ниләр йөкләсәң дә,
Үтибез бит аны арттырып,
Тартырыннан ашкан йөкне тартып,
Сырты сына язган ат кебек,
Ат кебек...

Хәсән Туфан

60-нчы елларда башланган реформалар чоры Русия халкы өчен зур авырлыклар да алып килгән. Бәзәкәлеләр дә, әлбәттә, бу авырлыклардан читтә калмаган. Җан башына тигән имана җиренең күләме кимү, табигать шартларының тотрыклы булмавы, примитив эш кораллары куллану, туфракка ашлама кертелмәү, җирнең начар эшкәртелүе кебек сәбәпләр аркасында еш кына кирәк кадәр уңыш җыеп булмаган. 1863 елдан 1893 елга кадәр узган өч дистә ел эчендә Идел-Урал төбәгендә ашлык бөтенләй уңмаган дүрт кытлык елы (1867, 1877, 1883 һәм 1891) һәм җиде аз уңышлы еллар (1864, 1865, 1868, 1870, 1873, 1880 һәм 1887) булган, ягъни һәр өченче ел авыл өчен бик авырга туры килгән. Уңышсыз кытлык елларына еш кына күп югалтулы тиф һәм ваба авырулары ияргән.

Хәлсез крестьян хуҗалыгына, шул исәптән Бәзәкәдә дә, иген уңмау бик нык тәэсир иткән. Мәсәлән, 60-нчы елларны карыйк. 1864, 1865 ашлык начар уңган еллардан соң авыл аңына килеп өлгермәгән, 1867-нче кытлык елы һәм 1868-нче аз уңышлы ел бабаларыбызны бөлгенлеккә төшергән. Ачлы-туклы тормыш алып барган халыкны холера, тиф авырулары аяктан еккан, үлем-китем арткан. Минем карамакта авыл муллалары тарафыннан Вятка губернасы статистика комитетына 1869 елның январендә бирелгән 1868 елда авылда туган һәм үлгәннәр саны хакындагы белешмә бар. Бәзәкәнең беренче мәчетендәге указлы мулла Габделхәлил Габделгалләмов күрсәтүенчә, бу мәхәлләдә 1868 елда 31 малай һәм 18 кыз, указлы мулла Миннихуҗа Гыймранов карамагындагы икенче мәчет мәхәлләсендә 15 малай һәм 8 кыз туган. Беренче мәхәлләдә 50, икенчесендә 12 кеше, барлыгы 62 кеше вафат булган. Яшь буенча карасак, ике мәхәлләдә ун яшькә кадәр булган 42 бала (16 малай һәм 26 кыз), яки барлык үлгәннәрнең 67,7% вафат булган. Калганнары 54-79 яшьтәге өлкәннәр булган. Бу саннар үзләре генә дә балалар арасында үлемнең күп булуы, ә 1864-1868 ачлык елларында аның артуы хакында сөйли.

Уңышсыз елларда ашарга җитәрлек тә уңыш җыя алмаган халык еллар буена салымнарын түли алмаган, недоимкалар үскән. Менә Казан губернаторының шушы елларда дәүләт мөлкәте министрлыгына җибәргән рапортыннан бер өзек: “Мамадыш төбәгенең төрле татар авылларыннан булган дәүләт крестьяннарын соңгы елларда игеннәрнең бик начар булуы чиктән тыш бөлгенлеккә төшерде: аларның хәтта үзләрен туйдыра алырлык та хәлләре юк. Аларның кырлары чәчелми, акчалары гомумән юк, балалары хәер сораша”. Бу сүзләр бер үк шартларда яшәгән күрше Алабуга өязе халкы тормышына да туры килә.

70-елларда авыл хуҗалыгының хәле илдә дә, төбәктә дә начарлана гына барган. Ашлык тамырда килеш черегән 1877 елгы кытлыктан соң авыл халкының күп өлеше хәерче хәленә төшкән. Земстволар күпмедер күләмдә ссуда биргән. Ләкин ул халык хәлен яхшырта алмаган. Авыл халкы төрле бәла-казалардан хәл алып та өлгермәгән, 1883 елгы ачлык аларны тагын аяктан еккан. 1884 елда авыл хуҗалыгының кризис хәленә төшүенең сәбәпләрен ачыклау өчен Идел-Урал төбәгенә Петербургтан барон А.А.Икскуль-Гильденбандт җибәрелгән.

“Шөбһәсез, халыкның бөлгенлеккә төшүенең күзгә күренеп торган сәбәпләре - 1874 елдан бер өзлексез булып торган начар уңышлар, 1877 елда ашлыкның уңмавы, үткән елгы уңышның җитәрлек булмавы. Ләкин бу уңышларның начарлыгы салкыннар, корылык, боз бәрү яки вакытсыз зур яңгырлар һәм башка без алдан күрә алмаган очраклы хәлләрдән генә тормый. Эш хуҗалыкны начар алып бару һәм ашлама кертмәү аркасында туфракның ярлылануында, коралларның канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә булмавында, кырларны начар эшкәртүдә, аларның бер өлешен җиренә җиткереп эшләмәү яки атлары булмау сәбәпле бөтенләй чәчмичә калдыруда һәм башка авыл хуҗалыгын яхшыртмыйча үзгәртеп булмый торган хәлләрдә”, - дип ассызыклаган барон үзенең 1884 елның 20 маенда эчке эшләр министры Д.А.Толстойга җибәргән хисап язмасында.

1891 елда тагын коточкыч кытлык елы килгән. Бу ачлык алдыннан килгән 1886-1890 ашлык уңмаган елларда крестьяннарның булган запаслары да беткән була. 1891 елгы ачлык илнең 17 губернасында (шул исәптән, Вятка губернасында да) бик көчле булган. Эчке эшләр министрлыгының үзәк статистика комитеты мәгълүматларында күрсәтелгәнчә, 1891 елгы уңышны җыеп бетерүгә ашлык уңмаган губерналарда җан башына барлыгы 8,56 пот кына (140 кг) ашлык җыелган. Бу күләм киләсе елга кадәр хәтта ашарга да җитмәслек булган (моның өчен җан башына иң кимендә 13 пот ашлык җыелырга тиешлеген күрсәтик). Ашлыкның исә, крестьяннарның үзләре ашаудан тыш, терлек азыгы һәм чәчү орлыгы буларак та кирәклеген исәпкә алсак, кимендә тагын 5-6 пот ашлык җитмәвен күрәбез.

1891 елгы кытлык һәм аның нәтиҗәсе булган ачлык һәм тиф-холера эпидемияләре авыл хуҗалыгының һәлакәт хәленә төшүен Русия җәмгыятенә аермачык күрсәткән. Бу турыда бөтен ил җәмәгатьчелеге сөйли башлаган. Халыкка килгән бәла-казаны хөкүмәт кенә шактый озак вакыт танырга теләмәгән, аны гадәттәге иген уңмау дип санап, ачлыктан интегүчеләргә ил күләмендә ярдәм күрсәтергә рөхсәт бирмәгән. 1891 елгы ачлык газета-журналларда да, Л.Н.Толстой, В.Г.Короленко кебек язучыларның публицистик һәм әдәби әсәрләрендә дә киң чагылыш тапканнан соң гына дәүләт үз чараларын күрә башлаган.

«Вятские губернские ведомости» газеты, 1891 елның 7 сентябреннән башлап, һәр санында диярлек моңа кадәр күренмәгән күләмдә ашлыкның уңмавын, ачлыктан интеккән авылларның хәлен тасвирлаган, аларга оештырылган ярдәм хакында язып килгән. Газетның 14 сентябрьдәге 74-санында ачлыктан интегүчеләргә ярдәм оештыру өчен төзелгән Вятка өязе вакытлы комитетының карары басылган. Мондый комитетлар башка өязләрдә дә ачылуы, алар кабул иткән карарлар, башкарган эшләр хакында да газет даими хәбәр итеп барган. Газетның 98, 99-саннарында (7 һәм 11 декабрь) Вятка губернаторы губерна земствосының еллык җыелышында ясаган нотыгы тулысынча басылган. Губернатор төбәктәге көчле корылык аркасында уңыш булмавы, күрше губерналарның да шундый ук кытлыкка дучар булуы, шуңа күрә читтән ярдәм көтүнең мөмкин булмавы хакында тәфсилләп сөйләгән. Губернатор һәм башка чыгыш ясаучылар ачлыктан интегүчеләргә азык-төлек ссудасы бирүне оештыру, крестьяннарга эш урыннары табу мөмкинлеген булдыру хакында да сөйләгәннәр.

Газетларда 1891 елның сентябрь-октябрь айларында ук авылларда башланган ачлыкның коточкыч мисаллары тасвирланган. Менә бер-ике күренеш. “Татар, рус, ар авылларының кайсы гына йортына керсәгез дә, сез гаиләләрнең чиксез ярлылыгына, начар киенгән, ябыгып беткән балаларга тап булырсыз... Мич эченә күз салсагыз, сез ниндидер кара түгәрәкләр күрерсез: әллә балчык, әллә таш (ә бу ипи бит!). Кайберләрендә “муллык” табарсыз: 3-4 бәрәңге яки эчендә алабута булган бәлеш – гаиләнең исән калуы өчен бик кирәк булган бу өлеше дә еш кына күршеләрдән бурычка алынган булуы мөмкин» (ВГВ, 1891, 25 ноябрь, № 91). Казанда басыла торган “Волжский вестник” газетында Сембер губернасыннан килгән язмада

шундый ук күренеш тасвирланган: “Фәкыйрьлек монда шул кадәр куркыныч, кешеләр хайван ашамаганны ашарга мәҗбүр. Икмәкне бераз гына арыш һәм кибәк кушылган алабутадан әзерлиләр; тәме ачы, күңел кайтаргыч, үзе пешеп җитмәгән кебек юеш булса да, ул өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә бердәнбер ризык булып кала” (ВВ, 1891, 22 октябрь № 240).

Вятка губернаторы 1891 елның йомгак-отчетында: “Хисап тоткан елдагы кытлык һәм соңгы биш елдагы уңышның бик түбән булуының нәтиҗәсе – крестьяннарның көндәлек тормышының бик нык таркалуы, эш малы санының кискен кимүе, чәчүлек мәйданнарының азаюы азык-төлек һәм чәчү орлыгына чиксез мохтаҗлык тудырды”, - дип ассызыклаган. Бу сүзләргә губернада йогышлы авырулар эпидемиясе башлануын да өстәгән губернатор. Ачлыктан хәлсезләнгән кешеләр холера, тиф кебек авыруларны бик тиз эләктергән. Бәзәкәне дә эпидемия читләтеп узмаган – бу хакта метрик кенәгәләрдәге мәгълүмат ачык сөйли. Метрик кенәгәләрдә муллалар авылдашларының гаиләдә булган хәлләрен (бала туу, кеше үлү, өйләнешү) теркәп барган. Менә алардан алынган берничә сан. Әгәр дә гадәти елларда авылда елына уртача 30-60 кеше вафат булса, 1892 елда 154 кеше вафат булган (1891 елгы метрик кенәгәләр сакланмаган, 1890 елда 60 кеше, 1894 елда 45 кеше вафат булган).

Идел-Урал төбәге губерналарыннан шундый отчетлар килгәннән һәм матбугатта күтәрелгән кискен тәнкыйтьтән соң гына хөкүмәт ачлыктан интегүчеләр өчен акча җыю, ашханәләр ачу, медицина ярдәме һәм ссуда бирүне оештыруга рөхсәт биргән. Хакимият, соңга калып булса да, җан башына айга 12,3 кг ашлыкны ссуда итеп бирүне оештырган. Ләкин бу күләм җитәрлек булмаган, чөнки бер кешене туендырыр өчен бер җанга айга 18-19 кг, яки елга 13-14 пот ашлык кирәк булган.

Корылык һәм ачлык еллары авыл халкы өчен авыр сынауга әверелгән. Аның тормышында игенчелек кебек үк зур роль уйнаган терлекчелеккә дә бу елларда зур зыян килгән. Үзе ачлыктан интеккән авыл халкы булган малын, беренче чиратта атларын, ничек булса да саклап калырга тырышкан. Ләкин 1891 елда атларның төп азыгының берсе булган солы бөтенләй уңмаган. Корылык кырларга гына түгел, болын-печәнлекләргә дә зур зыян китергән. Нәтиҗәдә малларны ашатыр өчен азык булмау терлек арасында төрле авырулар таралуга, мал кырылуга китергән. Ашатырга печәне дә, саламы да бетеп, маллары күтәрәмгә калганчы, авыл халкы вак терлекләрен дә, эре мөгезле терлекне дә, хәтта атларны да сатуга керешкән. Киров өлкә архивында сакланган материаллар 1891 елгы кытлыкның терлекчелеккә, шул исәптән ат тотуга китергән зыянның зур булуын күрсәтә.

Менә Бәзәкәдәге хәлне яктырткан Хәрби министрлык таләбе буенча төзелгән исемлекне алыйк. 1890 елда авылның 309 хуҗалыгында 17 айгыр, 421 эш аты һәм 121 үсмер ат булган. Атсыз бик ярлы хуҗалыклар 19,7%, бер атлы ярлы хуҗалыклар 37,9%, ике атлылар (урта хәллеләр) 19,1%, өч һәм өчтән артык атлары булган таза хәллеләр 23,3% тәшкил иткән. 1891 елгы корылыктан соң авылда атлар саны кискен кимегән. 1891 ел нәтиҗәләрен исәпкә алып, Хәрби министрлык таләбе буенча төзелгән исемлектә 309

хуҗалыкның 237-се (76,6%) атсыз булуы, 72-сендә (23,4%) генә атлар саклануы күрсәтелгән. Аларда барлыгы 6 айгыр, 186 эш аты һәм 120 үсмер ат булган. 72 атлы хуҗалыкның дүртесендә (1,3%) берәр үсмер ат кына сакланган; бер атлы хуҗалыклар - 14 (4,5%), ике атлылар - 23 (7,5%), өч һәм аннан күбрәк атлы хуҗалыклар 31 (10,1%) булган. Бу хуҗалыкларда (берсеннән кала) колын яки үсмер атлар да булган. Бер ел эчендә 247 атның юкка чыгуы 1891 елгы ачлыкның Бәзәкәдә никадәр көчле булуын тасвирлый. Иң соңгы чиккә җиткән авыл халкы үз тормышын саклап калыр өчен атларын сатканмы, икмәккә алмаштырганмы, үзе суеп ашаганмы яки йогышлы авырулар эпидемиясенә юлыкканмы - без моны әйтә алмыйбыз. Ләкин бу мәгълүмат авыл халкы арасында барган капма-каршы төркемнәргә бүленүнең (поляризациянең) тагын да кискенләшүен күрсәтә. Бу афәт нәтиҗәсендә ярлылар тагын да ярлыланган. Урта хәлле гаиләләрдә дә бөлгенлеккә төшүчеләр аз булмаган. Хәтта бай хуҗалыклар да шактый зыян күргән. Әгәр дә кытлык елына кадәр өч һәм күбрәк атлы хуҗалыклар 72 булса, 1892 елга бу катлауда 31 хуҗалык кына калган, ә 41 хуҗалык 1-2 атлылар катлавына күчкән.

Күп атлыларны тагын да ваграк төркемнәргә аерып карасак, алар арасында да тигезлек булмавын күрербез. Өчәр эш аты 15 хуҗалыкта калган, барысында да үсмер атлар да (6 хуҗалыкта берәр, тагын 6-сында икешәр, 3-сендә өчәр колын) булган. Алты хуҗалыкта дүртәр ат (4-сендә берәр, берсендә ике, тагын берсендә дүрт үсмер ат) булган; биш хуҗалыкта бишәр ат һәм 6 колын булган. Болардан тыш авылның иң бай тагын биш хуҗалыгы күп атлы булган. Аларның хуҗаларының исемен әйтик. Тажетдин Зәйнебәшаров хуҗалыгында 9 эш аты һәм 5 колын күрсәтелгән; Мифтахетдин Низаметдинов шулай ук 9 ат һәм 3 колын иясе булган; Гайнетдин Хисаметдинов хуҗалыгында 7 ат һәм 13 үсмер ат язылган; Гыйльмибәшар Шонкаровның 7 аты һәм 3 колыны, Мөхәммәтсадыйк Имангуловның 6 аты һәм 2 колыны күрсәтелгән. Шуны да өстәргә кирәк – бу күп атлы хуҗалыклар йөк ташу, Бондюг заводы өчен башка эшләр башкару аркасында гына үзләренең хуҗалыкларын һәм малларын саклап калган, ә кайбер очракларда үз атларын сатарга мәҗбүр булган бәзәкәлеләр хисабына хәлләрен яхшырта да алган дип әйтергә була.

Бик күп кеше һәм мал гомерен алып киткән 1891 елгы ачлыктан соң бәзәкәлеләр, төбәктәге башка крестьяннар кебек үк, хуҗалыкларын бик озак вакыт рәткә кертә алмаганнар. Халык никадәр ачлыктан зыян күрсә дә, хөкүмәт аның салымнарын киметмәгән. Халыкның хөкүмәт алдындагы бурычы арта гына барган: еллык салымнарны түләү өстенә халыкка ачлык вакытында ярдәм буларак икмәкләтә алган ссуданы да кайтарырга кирәк булган, хөкүмәт аны кайтаруны гына өч елга кичектергән. Ә бит әле халыкка чәчүлек орлык һәм эш малы алырга да каяндыр акча табарган кирәк булган. Бабаларыбыз, ачлыкка дучар булган башка авыл халкы кебек, зур авырлык белән генә бу халәттән чыккан.

Киров архивыннан алынган бу чорга караган тагын берничә мәгълүмат. Ул 1899-1900 хуҗалык елында Вятка губернасы Алабуга өязендәге авыл

хуҗалыгының халәтен тасвирлаган белешмәдә бирелгән. Урыннардагы хәбәрчеләрдән алынган мәгълүмат нигезендә язылган белешмә әле гасыр ахырында да өяз 70-80 еллар дәрәҗәсенә кайта алмаганын күрсәтә. Белешмәдә 1898 елда иген уңмавы күрсәтелгән. Ләкин 1899/1900 елгы кыш уртача карлы, уҗымнар өчен яхшы, файдалы узган; иң суык ай февраль булган. “Икътисадый фактор буларак крестьяннар өчен ягулык та бик мөһим урын алып тора. Өяздә өйләрне мичләргә утын һәм салам ягып җылытканнар. Бер мичкә елына 8 сажин утын яки 16 йөк салам китә. Салагыш волостенда ягулыкны үз биләмәләрендә хәзерләгәннәр”, - дип язылган белешмәдә.

Хәбәрчеләр халыкның кышны уңышлы чыгуын билгеләгән (җавапларның яртысында “яхшы”, икенче яртысында “канәгатьләнерлек” дип күрсәтелгән). Июнь аенда һава торышының игеннәр өчен канәгатьләнерлек булуы, шулай да кайбер җирләрдә боз, көчле яңгырлар явуы, чүп үләненең күплеге, кырау төшүенең ашлыкка зыян китерүе әйтелгән. Өяз хакимиятенең, барлык мөмкинлекләрдән файдаланып, халыкны атлы итәргә тырышуына карамастан, бу максатка ирешеп булмаган. “Моның төп сәбәбе – атларның ачлыктан кырылуы һәм гомуми ярлылык. Үткән ел дала атлары таратылса да, өяздәге атсызлар саны шактый зур булып кала. 23 апрельгә волость идарәләреннән җыелган мәгълүмат күрсәтүенчә, өяздә атсыз хуҗалыклар 2757, яки 7,54% исәпләнә. Шулай булгач, үткән 1899 ел белән чагыштырганда, атсызлар саны өч тапкыр кимегән (малларны барлаганда 6636 атсыз хуҗалык күрсәтелгән булган – А.М.). Сабан ашлыгын чәчкәндә, атсызлар төрле юллардан файдаланган: акча яки соңыннан эш белән түләп, җәмгыять ярдәме белән дә чәчкәннәр”, - дигән мәгълүмат бирелгән белешмәдә.

“Алабуга өязендә зур хуҗалыклар күп түгел. Шуңа күрә авыл хуҗалыгы эшләренә көнлекчеләрне крестьяннар яллый. Эш көчләренә хаҗәт крестьяннарда тиз арада эшләнергә тиешле авыл хуҗалыгы эшләре вакытында килеп чыга. Кайбер җирле крестьяннар барлык көчләрен дә үз хуҗалыкларында кулланып бетерми, шуңа күрә алар башкаларга үз кул көчләрен тәкъдим итәләр. Үз хуҗалыкларын алар кыска вакытка гына калдыра алалар, шул сәбәпле ялланып эшләүнең төп формасы булып көнлек эш санала... Күбесенчә көнлекчеләрне сөрүгә һәм уруга яллыйлар”, - дип өстәлгән язмада. Белешмәдә шулай ук 1900 елның май аенда бер эш көненең уртача хакы да күрсәтелгән: үз аты белән ялланучының бер көне 67-77 тиен, атсыз көнлекченең 29-34 тиен торган; хатын-кызга көнгә 22-29 тиен, яшүсмергә – 14-16 тиен түләгәннәр. Көнлекчеләр барысы да үз ашауларын ашаган.

“Безнең халыкның төп байлыгы икмәк, аның җитешлеге һәм җитмәве теге яки бу елның иминлеген билгели. Авыл хуҗалыгы елы өяздә нинди булган соң? Үз икмәге декабрь-январьга кадәр халыкның 10 процентына җитә, февральга кадәр – 8%, мартка – 16%, апрельга - 10%, майга – 22%, июньгә – 6%, июльгә – 28%. Гадәти елда үз икмәге уртача 5 айга җитүе 13 җавапта, 10 айга – 14 җавапта, яңа уңышка кадәр 43 җавапта күрсәтелгән” (Бәзәкә урнашкан көньяк төбәгеннән алынган җавапларның чагыштырмасы -

6 – 6 – 15 — А.М.). Икмәк җитмәвенең аны көз көне салым түләү өчен сату һәм башка сәбәпләр аркасында булуы да аңлатылган. Терлекчелек хәле хакында да материал бар. Өяздә маллар 15 октябрьдә абзарга кертелгән. Салагыш волостендә малны көтүгә 24 апрельдә чыгарсалар, абзарга 17 октябрьдә керткәннәр. Димәк абзарда тоту чоры уртача 157 көн тәшкил иткән. Өяз буенча малның 48.17% тук, 47.58% уртача һәм 9.25% ябыккан килеш көтүгә чыгарылган. 1900 елның 23 апреленә волость идарәләре өяздә 54530 ат, 51817 сыер һәм 145139 сарык булуын хәбәр иткәннәр. Белешмәдә китерелгән мәгълүматны йомгаклап, XIX гасыр тәмамланганда авыл халкы тормышының яхшы якка үзгәрмәвен билгели алабыз.

1897 елгы халык санын алу материалларында Бәзәкә

Җиде бабаң карап тора сиңа,
Җиденең дә җиде бабасы...
Күзләренә күренер дә идең, -
Югалгансың... Каян табасы?!
Харрас Әюп

1897 елда Русия империясендә мөһим иҗтимагый чара – бөтен ил күләмендә беренче тапкыр халык санын алу уздырылган. 1719 — 1858 елларда Русиядә булган җан исәбен алу формасы 1861 елгы крестьян реформасыннан соң европалашуга күз тоткан хакимиятне канәгатьләндерә алмаган, чөнки илдә башланган буржуаз реформалар халык санын исәпкә алу формаларын да үзгәртүне көн кадагына куйган. “Принципиаль булган яңа критерийлар буенча халык исәбен алу хакында Русиядә 1857 елда ук сөйли башлыйлар, - дип яза И.К.Заһидуллин үзенең «Перепись 1857 года и татары Казанской губернии» исемле хезмәтендә. – […] Илдәге барлык халыкның исәбен алуга Русия империясе гамәлдә реформадан соңгы чор буена хәзерлек алып барган. [...] Статистика фәненең барлык казанышларын бу эшнең нигезенә салып, хакимият үзе көткәннән дә артыкны эшләп куйган дип бәяләргә була”.

1895 елның 5 июнендә патша Николай II “Русиядә беренче бөтен халык санын алу хакындагы положение”га кул куйган. Анда бу эшнең төп максаты итеп “халыкның санын, составын һәм төбәкләргә таралуын төгәл ачыклау” билгеләнгән. Документ “империядә яшәүче, рус гражданлыгында яки чит ил гражданины булмасын, ике җенестәге, төрле яшьтәге, сословиедәге, диндәге һәм кавемдәге барлык халык” исәпкә алынырга тиешлеген күрсәткән. Исәпкә алуның нигезе булып һәрбер хуҗалыкны тикшерү алынган. Мөмкин кадәр күп күләмдә статистика буенча узган халыкара конференцияләрдә эшләнгән мәгълүмат җыю тиешлеге хакында карар кабул ителгән. Бөтен бу мәгълүмат, тикшерелүчеләрнең телдән биргән җавабы буенча, хисапчылар тарафыннан сорау алу кәгазьләренә язылырга тиеш булган; бу мәгълүматны раслаучы бернинди документ та таләп ителмәве дә каралган була.

“1897 елгы җан исәбен алу XVIII-XIX гасырның беренче яртысында салым салу өчен уздырылган халык хисабын алудан тамырдан аерыла, - дип

искәртә И.К.Заһидуллин. – Аның нормативлары Европа стандартлары буенча эшләнә, һәм кеше турында 14 төрле мәгълүмат - респондентның исем-фамилиясе, гаилә хәле, гаилә хуҗасына карата кем булуы (кызы, улы, ир туганы һ.б.), җенесе, яше, сословиесе, дине, туган урыны, торган урыны, даими яшәгән урыны, туган теле, укый-яза белү-белмәве, шөгыле, физик кимчелекләре - хисап бланкларына языла”.

Илдәге халык өчен өч төрле исәпкә алу бланкы (сорау алу кәгазе) эшләнгән. Авыл җәмгыятьләрендә тутыру өчен аның “А” хәрефе белән билгеләнгәне кулланылган. Һәрбер хуҗалыкка хисапчы ун кешегә хисапланган аерым бланк тутырырга тиеш булган. Әгәр дә хуҗалыктагы кеше саны аннан күбрәк булса, икенче бланк тутырылган. Исәпкә алу кәгазьләре рус телендә басылган, ләкин үз язма теле булган халык (мәсәлән, татарлар) яшәгән төбәкләрдә графаларда бирелгән русча язмаларның астында аның тәрҗемәсе басылган. Мәсәлән, Идел-Урал төбәгенең 13 губернасы өчен “татар (Казан) шивәсендә” 1331 мең “А” форматындагы бланк әзерләнгән. Үзәк перепись комиссиясе санап чыгарганча, Вятка губернасы өчен шундый 70 мең бланк кирәк булачагы билгеләнгән.

Бу яңа, дәүләт дәрәҗәсендәге мөһим эшне башкару җирле хакимияткә йөкләнгән. Губернада сан алу комиссиясенең башлыгы итеп губернатор билгеләнгән, өяздәге җан исәбе алу комиссияләрен өяз дворян собраниесе рәисе яисә өяз земство управасы рәисе җитәкләгән. Җан исәбен алу участоклары земский начальник кул астындагы җирлек кысаларында урнаштырылган, ә санау бүлекләре волость чикләренә тәңгәл китереп төзелгән. Беренче чиратта булачак хисапчылар исемлеге төзелгән. Алар өчен җан исәбен алу бланкларын тутыру тәртибен аңлаткан махсус кулланма эшләнгән. Перепись 1897 елның 28 январенә билгеләнгән. 1896 елның 31 августында расланган инструкция буенча бу датага 20 көн - бер ай кала хисап алу эшләре башланырга һәм өч көн кала тәмамланырга тиеш булган.

Өязләрдә аңлату эшләре 1896 елның октябрендә башланган. Волость идарәләренә хисапчыларны җыеп, земский начальниклар инструктаж уздырганнар, алар өчен язылган кулланмаларны таратканнар, бланкларны тутырырга өйрәткәннәр, авылларда йөргәндә кирәк булачак хисапчы портфеле, значогы, кәгазьләрне тутыру үрнәкләрен, кирәк санда бланкларны өләшкәннәр. Мондый оештыру эшләре 1896 елның декабрендә башкарылган. Гомумән алганда, төбәкләргә билгеләнгән хисапчылар арасында рус булмаган милләт вәкилләре бик аз булган. Һичшиксез, бу татар авылларында аңлату эшләрен алып баруны кыенлаштырган, төрле ялган сүзләр, имеш-мимешләр таралуга нигез булган.

Переписька хәзерләнүнең иң мөһим өлеше булып, халыкка аның максатын һәм тәртибен аңлату торган, чөнки дәүләтнең бу чираттагы чарасы да Русия халкын, гадәттәгечә, ким дигәндә, сагайтачагы алдан ук билгеле булган. Хөкүмәтнең һәрбер яңа чарасы моңа кадәр дә халыкның бер өлешендә, аз гына булса да, өмет тудырса, икенчеләрендә зур шикләнүләр уятып килгән ич. Бу юлы да, күп тапкырлар булган кебек, хөкүмәт халыкның чарада катнашудан баш тарту яисә хакимияткә буйсынмау мөмкинлеген

фаразлаган. 1895 елның 7 августындагы циркуляр белән эчке эшләр министры җәмгыятьтә тынычлыкны саклау өчен губернаторларга барлык мөмкин булган чаралардан файдалану тиешлеге хакында боерык биргән. Анда җирле хакимият кенә түгел, халык үзе дә бу чараны кабул итеп алырга һәм аны уңышлы уздыруда ярдәм итәргә тиешлегенә басым ясалган.

Хакимият аңлату эшләрен алып баруны, беренче чиратта, руханиларга йөкләгән. Мөселманнарны алыйк. 1896 елның 2 июнендә эчке эшләр министры Мәхкамәи шәргыя Ырынбургиягә үз күрсәтмәсен җибәргән. Анда мөселман руханиларына халык арасында аңлату эшләрен алып баруны йөкләү каралган була. Шул ук елның 18 июлендә Мәхкамә ахун һәм муллаларга үзенең типографиядә листовка формасында басылган боерыгын юллаган; битнең сул ягында русча текст, уң ягында аның татар теленә тәрҗемәсе урнаштырылган. Татар телендәге текстны монда тулысынча китерәм.

“Җәмгыя-и шәргыя-и мөхәммәдия-и ырынбургия нәзаратында улган ахундлар һәм имамларга

Тиз заманда мәмләкәттә булган барча халык хисап ителенәчәктер. Бу сәбәбдән Җәмгыяи шәргыя сезләргә боерадыр: әһелләреңезгә аңлатасыз: бу хисап государь императорның галиләре буенча әҗра кылынадыр; фәкать шул касәденә безнең Русиядә күпме халык тереклек итәдер; рус халкы күпме; мөселман күпме; каю мәзһәбләр; яһүдиләр күпме; мәҗүсиләр күпме; вә гайреләр. Кем ни кәсеп илә шөгыльләнә; ничә яшендә; күпме өй җәмәгате бар; вә гайреләр. Бу мәгълүмат фәкать дөрес хисап өчен зарурдыр. Бу хисаптан дине исламга вә ислам мәктәп вә мәдрәсәләренә һич зарар килмиячәктер. Ушандак бу хисаб сәбәбеннән җирләребез алыныр вә я түләүләр арттырылыр диеп тә һич хәвеф итмәсеннәр. Шуның өчен хисап язылган вакытларда каршылык кылмай һәр хосуста тугры вә дөрес күстәрергә тиеш. Государь императорның максуды һәм шулдыр. Бу тәдбир господин министр внутренних дел бу ел 2 июль 3095 рәкамле таләбе буенча әҗра иделенәдер”.

Боерыкның ахырында мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов, мәхкамә әгъзалары ахуннар Ризаэддин әл-Фәхреддин, мирза Гыйниятулла бин Мөхәммәдмуса Капкаев, Хәсәнгата Мөхәммәд углы, сәркатиб өчен Җәникаев, өстәл башы Дәүләтбаев исемнәре куелган.

Шулай итеп, Мәхкамә-и шәргыя җан исәбен алуның әһәмиятен һәм аның максатын мәхәлләләрдә аңлатуны барлык дин әһелләренә йөкләгән. Боерык барлык муллаларга җиткерелеп, алар аңлату эшләрен оештыра башласалар да, мөфтинең аңлатуы да, мөселманнар яшәгән губерналарда хакимият тарафыннан башкарылган башка чаралар да теләгән нәтиҗәгә китермәгән. Татар авылларында хәл катлаулана барган: базар-ярминкәләрдән, өяз-волость үзәкләреннән кайтучылар хисап алу файдасына булмаган төрле хәвефле имеш-мимешләр дә алып кайткан. Авылларда киеренкелек үсә бару губерна башлыкларын махсус рәвештә мөселманнарга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр иткән.

“Басма сүз белән татар крестьяннарына йогынты ясауда күрше Вятка губернасы җитәкчелеге уңышлырак, алдан күреп эш иткән. Аның башлыгы Клингенберг мөселманнар арасында тараткан мөрәҗәгатендә җан исәбе алуның аларның дини хокукларына зыян китермәячәгенә үзенең гарантиясен биргән”, - дип яза И.К.Заһидуллин күрсәтелгән хезмәтендә. Үзе кылган чараларның нәтиҗәсезлеген күргән Казан губернаторы күршесенең мөрәҗәгатен сүзгә-сүз кулланып, үз мөрәҗәгатен бастыруын да язган ул.

Кызганыч, мин архивларда Вятка губернаторының мөрәҗәгатенә тап булмадым. Ике губернаторның да мөрәҗәгатьләре тәңгәл килүен исәпкә алып, И.К.Заһидуллин китабында китергән мөрәҗәгатьтән кулланырга булдым. Ике телдә басылган текстның татарчасын китерәм.

“Казан каласының губернаторыннан һәммә халыкка игълан ителәдер

Үземә башкарып торырга бирелгән губернада торучы мөселманнар арасында Русия җирендә бар халыкны санап язасы тугърысында һәр төрле ялган сүзләр йөри башлаганны ишеткәч ул тугърыда һәрбер кешегә аерым-ачык аңлату миңа кирәк күк табылды.

Бөтен халыкны санау тугърысында һәрбер кеше менә боларны белеп торырга тиеш.

Безнең падишаһлыкта тора торган бар халыкларны санарлар тик кешеләрне болай санап язу бүтән нәстә өчен түгел әмма фәкать халыкларның дөрес хисабын белер өчен генә булыр.

Аннары халыкны санап чыкканнан соң һичбер төрле алмашыну, үзгәртү булмас:

мөселманнарның моңар тикле булган мәдрәсәләре белән мәктәпләре моннан болай да элеккечә калырлар аларның балаларын да һичкем көчләп алып укытмас мәсчедләрен я бүтән төрла намаз укый торган урыннарын ябып бикләп бетерергә һичкемнең уена да кереп чыкмай.

Шуңар күрә һәрбер өйнең хуҗасы бер дә курыкмыйча җаваплар бирергә тиеш әгәр дә берәү начальникларның кушканнарына анык салмыенча аларның кушканына каршы килсә ул чакта ул кеше кабын (гатәбәт) күрми калмас.

Бу хәзер әйтә торган сүзләремне бар волостной сходларда халыкка әйтеп белгертергә аннары кәгазьгә басып волостной правлениеләрдә халык күп җыела торган төшләрдә кадаклап куярга. Әгәр дә кем дә кем бу хәбәрне язган кәгазьне сораса аңар бирергә кушам.

Казан губернаторы Полторацкий”.

1896 елның декабрендә таратылган һәм халык арасында “тынычландыру язмасы” буларак танылган Вятка губернаторының мондый өндәмәсе, күрәсең, үз бурычын үтәгән. Кайбер авылларына хәтта гаскәр дә кертергә туры килгән күрше Казан һәм Уфа губерналарыннан аермалы буларак, Вятка губернасында халык санын алу чагыштырмача тыныч үткән. Мәсәлән, Уфа губернасының татар авылларындагы ризасызлыклар сословиене күрсәткән графага бәйле булган (“Крестьян” һәм “христиан” сүзләрен мөселман халкы тәңгәл санаулары хакында язылган иде инде).

Мөселманнарда ризасызлык тудырмас өчен, Уфа губернаторы Н.Богданович 1896 елгы 29 декабрь циркуляры белән “гадәттән тыш очракларда җирле халыкны тынычландыру һәм халык санын алуны каршылыкларсыз уздыруны тәэмин итү өчен” сословиене күрсәтә торган графада этник башкортлардан тыш башка мөселманнарга карата да “крестьян” сүзе урынына “башкорт” сүзе кулланырга рөхсәт иткән. Бу алымны башка губерналарда да кулланганнар. Моның дәлиле итеп Бәзәкә халкының башкорт сословиесендә танылуын әйтергә була.

Декабрь азагыннан башлап, гыйнвар ае дәвамында хисапчылар, йорттан йортка кереп, гаилә әгъзалары биргән җавапларны теркәргә һәм 28 гыйнварда авыл җыеннарында тагын бер тикшереп, төзәтергә тиеш булганнар. Бәлки бу чаралар да өстәмә аңлатулар белән бергә Вятка губернасында яшәүче мөселманнарның шик-шөбһәләрен киметкәндер.

Киров өлкәсе дәүләт архивында Бәзәкәдә узган 1897 елгы халык санын алуның каралама материаллары сакланган. Ул Минзәлә өязеннән чакырылган укымышлы мөселман - хисапчы Арыслангали Хәмитов тарафыннан рус телендә карандаш белән тутырылган бланклар. Бланкларның беренче бите тулысынча тутырылмаган, анда авыл, волость, өяз, губерна исемнәре аталмаган, хуҗалык хакындагы белешмәләр дә тулы бирелмәгән; хисапчының фамилиясе дә тулысынча язылмаган (кайбер бланкларда аның “Арысл...” өлеше генә укыла).

Бәзәкәдә бу вакытта 381 хуҗалык булган. Аларда авылда даими яшәүче 1020 ир-ат һәм 945 хатын-кыз күрсәтелгән. Бу кешеләрдән 1014 ир-ат һәм 922 хатын-кыз Бәзәкә җәмгыятенә теркәлгән. Барлык теркәлгән халыкның башкорт сословиесендә булуы тәгаенләнгән. Аларның төп шөгыле игенчелек булуы язылган. Өстәмә шөгыльләр графасында көнлекчелек, умартачылык, балык тоту күрсәтелгән; бер кеше вак-төяк сату кибете булуын, тагын берәү үзен сәүдәгәрдә хезмәттә торуын яздырган. Бәзәкә җәмгыятендә теркәлмәгән читтән килеп яшәүчеләр арасында ике гаилә башлыгы вак-төяк сату кибете тоткан, тагын икесе имам вазифасын башкарган. Бу гаиләләр каралты-куралары белән йортлары һәм яшелчә бакчалары урнашкан җирләрне арендага алганлыгы күрсәтелгән. Алар арасында ике гаилә мещан, тагын икесе – дәүләт крестьяннары, берсе типтәр сословиесеннән булган.

Йортларның абсолют күпчелегенең түбәсе такта яки агачтан, бары бер хуҗалыкта гына кабык-кайры һәм дүрт хуҗалыкта салам түбә булуы күрсәтелгән. 17 хуҗалыкта икешәр, берсендә өч йорт булган.

Туган тел хакындагы җаваплар игътибарны җәлеп итә. 9 бланкта язылганнар “төрки” телдә, калганнары – “мөселман” телендә сөйләшкәннәр (ике очракта башта язылган “төрки” сүзе сызылган һәм “мөселман” сүзенә алмаштырылган). Укый белү хакында уңай җавапны якынча авылның ярты халкы биргән. Белем алган урыннары – “мәдрәсә” яки “мулладан” дип язылган. Хуҗалык башлыкларыннан 64 кеше мөселманча укый белгән. Ирләрнең яшьләре кимегән саен, укый белүчеләр саны арта барганы күренә. Хатын-кызлар арасында укый белүчеләр күбрәк булуы игътибарга лаек (алар һәр гаиләдә диярлек булган).

Авылның мәчет һәм имамнары

Мәңге шулай үреләсе икән
Караңгыдан һаман яктыга,
Ике арада бәргәләнә икән
Кешеләргә дигән Ак Дога.
Харрас Әюп

Авыл кешесенең узган дәверләрдәге аң-белем дәрәҗәсе мәдәни тормыш чыганагы булган ислам дине, шәригать кануннары нигезенә корылган мәчет-мәдрәсәләр белән бәйле. Башка татар мөселман авылларындагы кебек, Бәзәкәдә дә иҗтимагый һәм рухи тормышның үзәге мәчет саналган. Гадәти буларак, һәр авылда, кимендә, бер мәчет булган. Мәчет-мәдрәсә биналарын төзүгә Русия хөкүмәте бернинди ярдәм дә күрсәтмәгән. Алар халык хисабына һәм аның көче белән, яисә байларның матди ярдәме белән төзелгән. Мәхәллә авылдагы барлык җәмгыять биналарын үз хисабына тоткан, аларны ремонтлаган. Имам һәм мөәзиннәр (азанчылар) да мәхәллә хисабына яшәгән. Барлык мөселманнарга хас булганча, бәзәкәлеләр өчен дә ислам дини кануннар җыентыгы гына булмаган, халыкның шәхси һәм иҗтимагый тормыш нормаларын да үз эченә алган, кешенең дөньяга карашын да формалаштыручы булган.

Авыл кешесенең бөтен көндәлек тормышы шәригать кануннарына нигезләнгән, ә мөселман руханилары җәмгыятьне берләштерүче ролен үтәгән. Һәрбер авыл җәмгыятен “бик кечкенә дәүләт итеп күзалларга була: аның үз кануннары, гадәтләре, иҗтимагый тәртипләре, оешмалары һәм традицияләре, ислам рухы белән сугарылып, даими көчен һәм сафлыгын саклый, - дип язган 1881 елда бөек төрки-татар мәгърифәтчесе Исмәгыйль Гаспринский. - [...] Бу җәмгыятьнең бернинди санкция һәм багышлауларга мохтажы булмаган искиткеч бәйсез руханилары бар. Һәрбер хәзерлекле мөселман кешесе, мәхәллә ризалыгы булганда, укытучы, мөәзин, имам, ахун һ.б. була ала”.

Казандагы руханиларны хәзерләү академиясе профессоры М.Машановның 1910 елгы миссионерлар съездында ясаган чыгышында мөселман руханиларына биргән тасвирламасы да бик үзенчәлекле. “Үзе дә халыктан чыккан мулла мәхәллә кешеләренең барлык ихтыяҗ-мәнфәгатьләрен генә түгел, хәтта барлык мәхәббәт-нәфрәт тойгыларын, гадәт-омтылышларын, иҗтимагый һәм дини идеалларын белә; ул үзе дә мәхәллә халкының тормышы белән яши һәм аларның мәнфәгатьләрен чагылдырган бар нәрсәне күңеленә ала, - дип ассызыклаган профессор. – Үз мәхәлләсе халкының рухи ихтыяҗларын башкаручы буларак, ул алар белән бербөтенне тәшкил итә кебек; мәхәллә халкы аңа үз кешесенә караган кебек карый, бары тик ул, башкаларга караганда, белемлерәк, аңлырак; шуңа күрә мәхәллә халкы күп очракта үзләренең рухи җитәкчеләренең сүзенә карусыз буйсына”.

Шәригать кануннары һәм гореф-гадәткә нигезләнгән тәртипләр кеше тормышының бар якларын үз эченә алган. Традицион булган торак-каралтыларга, кием тегелешенә, баш киемнәренең формасына үзгәреш

кертергә ярамаган кебек, бабалар заманыннан килгән эш һәм тормыш кагыйдәләренең, гаилә әгъзалары һәм авылдашлар арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзгәрүе дә хупланмаган. Дини җәмгыять тарафыннан тикшерелеп торган җәмгыяви фикер бу гадәт-нормаларга буйсынмаган кешеләрнең гамәлләрен гаеп санаган. Кешеләр, Аллаһ алдында гаепле булуга караганда, халык хөкеменнән күбрәк курыккан. Моңа мәхәлләнең бөтен яшәеше булышкан. Мәхәллә халкы арасында дини тәрбия оештыру, ислам диненә өндәү, гыйбадәтханәдә мөселманнарга фарыз булган биш вакыт намазны гамәл кылу руханиларга йөкләнгән. Гамәлләрнең вакытын кичектерү рөхсәт ителмәгән. Зәмһәрир салкындамы ул, карлы-бозлы яңгырдамы яки кызу урак өстендәме, гыйбадәт йорты юлы ябылмаган. Мулла өчен тәнәфес, ял, яисә авыру вакытта эштән азат итү каралмаган. Мәхәлләдә руханилар алып барган хезмәтләр өчен күләме билгесез хезмәт хакының хәер-сәдака формасында бирелүе гасырлардан килгән тәртип буенча дәвам иткән.

Фарыз булган дини гамәлләрне үтәү өстенә авыл имамнары үз мәхәлләләрендә юридик һәм гражданлык актларын төзү хокукларына да ия булган. Яңа туган балаларны, гүр ияләрен теркәү, яңа гаилә корып яшәүчеләрнең никахлашуларын, ир белән хатын арасында никахны туктату-аерылышу фактларын раслау, аларны махсус “Метрик кенәгәләргә” язу шулай ук мулла вазифасы саналган. Гражданлык актларын теркәгән “Метрик кенәгәләр” һәр ел Уфага, Диния нәзарәтенә тапшырылып барган. Мәхәллә халкының рухи җитәкчесе буларак, ул аның әхлак-әдәбен, шәригать күрсәтмәләрен үтәвен күзәтеп торган, аларны бозучыларны җәзага тарткан. Варис малларын төгәл итеп бүлү дә аның эше булган.

Гаилә тормышында була торган барлык вакыйгаларда мулла иң хөрмәтле һәм иң кирәкле кеше булган: никах укыган, исем кушкан; аны авырулар янына да чакырганнар. Күп кенә руханилар авыру янында догалар уку белән генә чикләнмәгән, табиб та булган. Үзе ачкан мәдрәсәдә укытучы, балалар тәрбиячесе булуы да аның өлкәннәргә йогынтысын арттырган. Ә бу авыл җәмәгатьчелеген оештыруга, аның берлеген саклауга зур этәргеч булган. Имамның авылдагы эшләре дини кысалар белән генә чикләнмәгән. Ул авыл җәмгыятенең барлык эшләрендә катнашкан, һәрбер карар кабул ителгәндә ул үз фикерен белдергән, тормышта килеп чыккан мәсьәләләрне чишкәндә мәхәллә халкының киңәшчесе булган. Мулла, дини кануннарны белүче һәм аларны мәхәллә халкына аңлатучы буларак, авылда җәмәгатьчелек фикере формалашуына зур йогынты ясаган, теге яки бу кеше кылган эшләрне, шәригать күзлегеннән карап, яклап чыккан яки кире каккан.

Бәзәкәнең безгә исеме билгеле булган беренче мулласы ***Имангол Йосыпов*** (1778-1840) булган. Аның хакындагы мәгълүмат халык санын алу материалларында табылды. РС 1811 дә аның 32 яшьле указлы мулла булуы һәм 9 яшьлек Габделгалим белән 3 яшьлек Габделвәли исемле ике улы барлыгы күрсәтелгән. Моннан чыгып, Имангол хәзрәт хакында тагын нәрсәләр сөйләп була? Дәүләт тарафыннан танылган “указлы мулла” дәрәҗәсенә ия булу өчен аның җитәрлек белеме булырга тиешлеге көн кебек ачык. Ләкин аның кайсы мәдрәсәдә, нинди мөдәрристә белем алганлыгы

билгеле түгел. Күрсәтелгән саннарны да игътибарга алып, без, Имангол-шәкерт 20-22 яшендә белем эстәвен тәмамлап, шул ук вакытта өйләнгән булырга тиеш дигән нәтиҗәгә килә алабыз (аның олы улына 9 яшь тулуы моңа дәлил булып тора). Бу хәлләр Башкорт-мещеряк гаскәрен оештыручы Оренбург наместнигы О.А.Игельстромның кантон начальникларын билгеләп, йорт старшиналарын һәм указлы муллаларны үзе раслаган заманда булуын да искә төшерик.

“Павел 1-нченең 1798 ел 10 апрель указыннан күренгәнчә, регуляр булмаган Башкорт-мещеряк гаскәреннән сайланган муллалар хәрби хезмәттән азат саналырга тиешләр. Руханиларны билгеләү хокукын хөкүмәт хәрби җитәкчеләргә тапшырды: кантон башлыклары мулла яки мәзинлеккә кандидатлар белән үзләре танышып һәм “яңа рухани хезмәт урыннарының авылларда кирәклеген тикшереп”, имтихан тапшырыр өчен кандидатларны Уфадагы дини идарәгә җибәрделәр”, - дип язган О.А.Игельстром. Бу хаттан өзекләрне И.К.Загидуллин “Мусульманское богослужение в учреждениях Российской империи” исемле китабында китергән. Димәк без, бу юлны Имангол Йосыпов та узган булырга тиеш дип, нәтиҗә ясый алабыз.

Имангол хәзрәт тә, башка муллалар кебек, билгеле бер хезмәт хакы алмаган. Ләкин аны эшкә чакырган җәмгыять мулланың яшәешен һәм эш урынын тәэмин итәргә тиеш булган. Билгеле, мәхәллә мулласының яшәешенә һәм үзен тотышына яшәү мохите зур тәэсир ясаган. Авыл кешеләре белән бертөсле хокуклар, авылда яшәр өчен кирәк булган крестьян хуҗалыгын алып бару аны авылдашлары белән тәнгәлләштергән. Мулла үзенең әхлак йөзе, табигате белән дә авылдашларыннан бик аз аерылган. Миссионер Я.Д.Кобловның муллаларны тасвирлап әйткән “аның уй-фикерләре дә мәхәллә халкыныкыннан аерылмый диярлек, чөнки мулла үзе дә, мәхәллә халкы да бер үк тәрбия һәм белем алган” дигән сүзләрен Имангол хәзрәткә дә юнәлтеп буладыр.

Мәнфәгатьләре һәм карашлары уртак булу мулланы мәхәллә халкына якынайткан. “Аларның юлбашчысы һәм җитәкчесе булуны үз өстенә алып, ул күп очракларда аларны үзе теләгән юнәлештә җитәкли. Мулланы алдау яки аннан берәр нәрсәне яшерү бик авыр. Ул мәхәллә халкының барлык адымнарын да, хәтта фикерләрен дә аңлый, чөнки ул алар белән бер тормышта яши һәм шуңа күрә һәрвакыт аларны үз йогынтысына буйсындыра ала. Икенче яктан караганда, мәхәллә халкы муллада үзләренә чит кешене түгел, бәлки үзләре арасыннан чыккан кешене күрә һәм аның авторитетына бернинди каршылыксыз таяна”, - дип дәвам иткән үз фикерен Я.Д.Коблов. Һәр мулланың авторитеты аның кешелек сыйфатларына, акыл-белеменә, яшәү рәвешенә, үз-үзен тотышына бик нык бәйле булган. Әгәр дә мулла үз вазифаларын тырышып башкарса, авылдашлары өчен үрнәк булса, мәхәллә халкының тәртибе сагында торса, ул авылдашларының ихтирамын яулаган һәм авылның иҗтимагый-мәдәни тормышының җитәкчесе булган.

Имангол Йосыпов шундый җитәкчеләрдән булгандыр дип уйлыйк. Ревизия материалларыннан күренгәнчә, 1840 елда вафатына кадәр ул үз хезмәтен башкарган. Дистәләгән еллар мулла вазифасын башкарганда аның

күз алдында ничәмә-ничә буын бәзәкәлеләр үсеп җиткән. Һәрбер бәзәкәлене яхшы белгән Имангол хәзрәт аларның тормышында булган бөтен мөһим вакыйгаларда актив катнашкан (никах уку, бала туып, аңа исем кушу, гаилә әгъзаларын соңгы юлга озату һ.б.) Ярты гасырга якын муллалык дәверендә ул ничә буын балаларның укытучысы һәм тәрбиячесе булган. Имангол хәзрәтнең барлык муллаларга да бирелгән юридик статусына хас булган килештерү функциясе дә аның абруен арттырган. Мәхәлләнең рухи җитәкчесе буларак, ул гаилә конфликтларын тикшергән, үгет-нәсихәт биргән, хөкемдар сыйфатында шәригать кануннары нигезендә варислар арасында мирас бүлгән. Имамнар рәсми хакимият йөкләгән эшләрне дә башкарган, мәсәлән, хөкүмәт боерыкларын халыкка җиткерү һәм аңлату алар вазыйфасы булган. Барлык бу вазыйфаларны үтәүче буларак, авылда мулла үз кулында зур көч туплаган кеше булган.

Бәзәкәдә беренче мәчетнең кайчан төзелгәнлеге билгеле булмаса да, без Имангол Йосыпов муллалыкка указ алганда, мәчет инде булган дип әйтә алабыз. XIX гасырның 20-30 елларына кадәр мәчет бинасына аерым таләпләр куелмаган, бары тик ул җомга намазына килүчеләрне сыйдырырлык бина булырга тиеш булган. Мәчетләрне корганда кулланыла торган махсус кагыйдәләр XIX гасыр урталарына гына урнашкан. Шул ук 20-30 елларда мәчетләрне биш вакыт намаз укый торган гади мәчетләргә һәм җомга намазын уку өчен эшләнгән җәмигъ мәчетләргә бүлә башлаганнар. Гади авыл мәчетенә бер мулла һәм бер азанчы тиеш булса, җәмигъ мәчеткә тагын бер мулла өстәлгән. Күрәсең, нәкъ шул вакытта Бәзәкә мәчете дә җәмигъ мәчет булып киткән, һәм бу бәзәкәлеләргә икенче мулланы чакыру мөмкинлеген биргән. Бу үзгәрешләрне РС 1834 материалларына нигезләнеп әйтеп була.

Җәмәгатьчелек алдында зур абруе булган имам-мөдәрриснең тәкъдиме, гадәттә, булачак мулланың кандидатурасын сайлаганда, кабул ителгән. Имангол хәзрәт тә, мөмкинлек барлыкка килгәч, Бәзәкәнең икенче мулласы итеп үз шәкертен тәкъдим иткәндер дип уйларга була. РС 1834 материалларында Бәзәкәдә ике указлы мулла булуы күрсәтелгән: аның берсе 54 яшьлек Йосыф улы Имангол булса, икенчесе - 36 яшьлек Рәфыйкъ улы Шаһиислам булган. Ул 20-елларның урталарыннан Имангол хәзрәткә хәлфә буларак ярдәм итеп, берничә ел эчендә бәзәкәлеләргә үзен танытканнан соң 30-елларга кергәндә муллалыкка указ алган булса кирәк. Мулла вазифаларын башкарыр өчен кешенең ислам гыйлемнәреннән белеме булырга тиешлеге аңлашыла. Бу белемнәр исә, Оренбург диния идарәсе каршында имтихан тапшырып, муллалык указы алу өчен җитәрлек булырга тиеш. Указлы муллага Оренбург диния идарәсе, имам-хатыйп (вәгазь сөйләүче) исеменнән тыш, мөдәррис (мәдрәсә җитәкчесе) һәм мөгаллим (укытучы) исемнәрен дә биргән. Мөгаллим шәкертләргә ислам нигезләрен бирсә, мөдәррис, үз мөмкинлекләренә карап, шәкертләрен муллалыкка да хәзерләгән.

Башкорт гаскәрендәге указлы муллалар алдына О.А.Игельстром күрше авылларга руханилар хәзерләү өчен үз мәдрәсәләрен булдыру бурычын да куйган. Имангол хәзрәтнең дә шундый мәдрәсәсе булган дип фаразлыйк (минем кулда бу хакта рәсми документлар булмаса да, ерак бабалар яшәгән

заманнарда авылда укымышлы хәзрәт һәм аның зур мәдрәсәсе булуы, күршетирә авыллардагы мулла нәселләренең күбесенең тамырлары Бәзәкәгә кайтып калуы хакында мин сабый чакта ишеткән риваятьләрдә сөйләнә иде). Мәдрәсәдә уку күп елларга сузылган, чөнки гарәп һәм фарсы телләрен, дин тәгълиматын өйрәнү күп вакыт һәм шәкертнең ата-анасыннан матди чыгымнар да таләп иткән. Үз авылларында заманы өчен яхшы белем бирә торган мәдрәсә булганда, башкорт һәм типтәр гаскәрендә хезмәт итүче бәзәкәлеләр арасында үзләренең улларын чит җирләргә атаклы мәдрәсәләргә белем эстәргә җибәрерлек кешеләр булды микән?

Имангол хәзрәт иң элек авылдашларының балаларына ислам нигезләрен өйрәтүдән башлагандыр дип, күз алдына китерик. Тора-бара, укуга һәвәслек күрсәткән шәкертләрен ул ислам гыйлемнәре белән дә таныштырып, аларны, әти-әниләренең рөхсәте белән, муллалыкка да хәзерли башлагандыр. Алар арасында, һичшиксез, Рәфыйкъ Сардин улы Шаһиислам һәм мулланың үз улы Габделгалим булуын күрсәтергә була. Әлбәттә, мондый шәкертләр күп була алмаса да, Имангол хәзрәт 20-еллар уртасына 4-5 мулла әзерли алган дип әйтеп була.

Бу факт Р.Мәрданов хезмәтләрендә дә раслана. Үзенең мәкаләләрендә һәм “Тарихта тибрәлгән Тәбәрле” исемле саллы китабында ул тамырлары Бәзәкәгә барып тоташкан ике мулла хакында мәгълүмат китерә. Архив документларына нигезләнеп (соңрак бу документларны ул миңа да бирде), галим үзенең ерак бабасы Гыйззәтулла Мәндекәй улының (1801-1868) Төрдәле авылы (хәзерге Әгерҗе районы) халкы тарафыннан 1824 елда муллалыкка чакырылуы хакында язды. Гыйззәтулла хәзрәт, Төрдәледә төпләнеп, “44 ел дәвамында имамлык итә, балаларга сабак укыта. Шул исәптән, күршедәге Кырынды авылының православие динендә дип исәпләнгән татар балаларына да яшерен рәвештә дин сабагын өйрәтә. Шул гамәлләре өчен жандарм күзәтүе астына алына. Гыйззәтулла мулланың вафатыннан соң аның эшен уллары дәвам итә. Кырынды халкын православие диненнән ваз кичәргә һәм шул авылда чиркәү төзүгә каршы котыртулары өчен Гыйззәтулла мулланың өч улы: Әхмәди, Мөхәммәтшакир һәм Мөхәммәтсадыйк унар елга сөргенгә җибәреләләр. Кырындыда чиркәү төзелсә дә, йөз ел чамасы керәшен булып исәпләнгән татарлар, рәсми рәвештә мөселманлыкка кайтуга ирешкәннәр” , - дип яза галим.

Бәзәкәдән чыккан икенче мулла – типтәр Зәйнетдин Райман улы (1802-1852) хакында да мәгълүматлар китергән Р.Мәрданов. “Авылдашларыбыз 1826 елда Иске Бәзәкәнең Зәйнетдин Райман улын Тәбәрлегә мулла итеп чакырганнар”, - дип язган Р.Мәрданов үз әсәрендә һәм мулланың үзе һәм аның варислары хакында мәгълүматлар да китергән.

Бу мәгълүматка, көтмәгәндә, Илдар әфәнде Нәфыйков җибәргән материаллар арасыннан тагын бер факт өстәлде: шушы ук чорда имам вазифаларын башкарыр өчен шул ук төбәктәге Кичкутан авылы халкы да Бәзәкәдән Балтанов Габдуллатыйфны чакырткан икән. Әгәр дә без Шаһиислам Рәфыйковның бу Бәзәкәдән чыккан өч мулла белән чордаш булуын исәпкә алсак, алар дүртесе дә бер чорда бер үк мөдәрристән дәрес

алганнардыр дигән нәтиҗәгә киләбез. Ягъни аларның остазы Бәзәкә имамы Иманкол хәзрәт булганлыгын әйтә алабыз. Димәк, аның үз мәдрәсәсе булган, һәм ул шактый уңышлы эшләп килгән икән дигән нәтиҗәгә килеп, Р.Мәрданов фикеренә кушылырга гына кала. “Бер үк чорда Бәзәкәнең ике яшь кешесе (әле бу безгә билгелеләре генә) мулла итеп башка авылларга чакырылу факты – Бәзәкәдә ул чорда, күрәсең, яхшы мәдрәсә булгандыр дип фаразларга да этәргеч бирә”, - дип язган иде Р.Ф.Мәрданов 2004 елның 23 июлендә “Менделеев яңалыклары” газетасында басылган “Бәзәкә авылы тарихына кайбер мәгълүматлар” исемле мәкаләсендә. Безгә, тагын ике мулланың исемен өстәп, аның күзәтүе белән ризалашырга гына кала. Менә шулай, архив материаллары көтелмәгән нәтиҗәгә дә китерә ала икән!

Архив документлары мулланы чакыру һәм аны раслау барышын күрсәтү өчен дә өстәмә материаллар бирде. Шаһиислам Рәфыйкъ улының Бәзәкәгә икенче мулла буларак билгеләнүе хакында конкрет материаллар табылмады. Шулай да, РС 1834-тә аның указлы мулла буларак күрсәтелүе ул да указ алуның барлык этапларын узгандыр дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Бу этапларны без Тәбәрле мулласы Зәйнетдин Райман улы һәм Кичкутан имамы Габделлатыйф Балтан улы документларыннан ачыклыйбыз (Кушымта № 14). Документлар бу ике бәзәкәленең муллалыкка килү юлларын күрсәтә. Алар икесе дә 20-еллар урталаларында муллалык вазыйфасын үти башлаганнар. Берсе Тәбәрлегә, икенчесе Кичкутанга авыл халкы чакыруы буенча килеп, алар 4-5 ел буена указсыз гына мулла вазыйфасын башкарган. Без бу фактны, бер яктан, хәзрәтләр тәҗрибә төпләгән һәм Диния нәзарәте каршында имтихан тоту өчен хәзерләнгән дип кабул итсәк, икенче яктан, авыл халкы да алардан имтихан алган дип әйтә алабыз. Имам булып җитлеккәч, хәзрәтләр рәсми рәвештә указ алу юлына басканнар. Моның өчен аларга, беренче чиратта, Тәбәрле һәм Кичкутан мәхәлләләре халкы җыеныннан мәчетләренә имам чакыру хакында приговор алу кирәк булган.

Икенче адым – туган авыллары җәмгыятеннән авылдан китәргә рөхсәт биргән приговор алу. Аны алганнан соң, мәхәллә халкы вәкилләре кул куйган һәм старшина мөһере белән расланган приговорны Алабуга өяз судында беркетергә кирәк булган. Бу документлары безнең көннәргә килеп җиткән Габделлатыйф Балтанов шуннан соң Уфага, Оренбург диния нәзарәтенә имтихан бирергә юл тоткан. Ләкин ул бераз ашыккан булып чыга. Уфада аңа имтихан тотар өчен Вятка губерна идарәсеннән рөхсәт алып килергә тиешлеген аңлатканнар. Уфадан Вяткага һәм кире Уфага сәяхәт өчен җитәрлек байлыгы булмаган Габделлатыйф хәзрәт 1832 елның декабрендә император Николай I-нең үзенә үтенеч белән мөрәҗәгать иткән. Бу үтенечнең нәтиҗәсе ничек булгандыр, безгә билгеле түгел. Ләкин, төрле җәфа-газаплар чигеп булса да, Габделлатыйф Балтановның указлы мулла булуын башка документларга таянып әйтеп була.

Ә менә Зәйнетдин Райман улының документлар җыюы уңышлырак барган. “1826 елгы архив документында Тәбәрледә мәчет бар дип күрсәтелгән, һәм аңа Иске Бәзәкә авылы кешесе Зәйнетдин Райман улы (1802-1852) мулла итеп сайлап куелган. Берничә елдан Зәйнетдин хәзрәт Тәбәрле

халкы үзен шундагы мәчеткә имам итеп сайлауны белдереп, махсус имамлык указы алу өчен документлар туплап, губерна идарәсенә мөрәҗәгать иткән. Тупланган документларны үз гаризасы (1831 елның декабре), Тәбәрле халкының Тәбәрленең гомуми җыелышында Зәйнетдин Райман улын мулла итеп раслауга ризалык белдергән карары (1831 елның 25 гыйнвары), Бәзәкә авылы типтәрләре җыелышында Зәйнетдиннең Тәбәрлегә имам итеп расланyына каршы булмауларын белдергән рәсми карар (1531 елның 25 ноябре) тәшкил иткән", - дип яза Р.Мәрданов "Тарихта тибрәлгән Тәбәрле" исемле әсәрендә.

"1831 елның 31 декабрендә Вятка губернасы идарәсе, шул чор кануннары буенча Уфага - Диния нәзарәтенә мөрәҗәгать итеп, Зәйнетдин Райман улының шәригать белемен тикшереп имтихан кылырга һәм, яраклы дип табылса, Тәбәрле мәчетенә билгеләүне сорый, - дип дәвам итә Р.Мәрданов. – Зәйнетдин мулла 1832 елның 16 июнендә Уфада Диния нәзарәтендә имтихан тотып, 25 июнь көнне, 897 номерлы имамлык указы алган һәм Тәбәрле мәчетендә рәсми рәвештә мулла итеп расланган". Оренбург Диния нәзарәте юлламасы буенча указны Вятка губерна идарәсе рәсмиләштерүен дә моңа өстәргә кирәк. Бу катлаулы юлны барлык указлы муллалар да үтәргә тиеш булуын ассызыклыйм. Муллалар, гарәп, фарсы, чагатай (төрки), татар телләрен шактый яхшы белсәләр дә, рус телендә "бик сай йөзүләрен" искәртик. Ә бу аларга, указ алу өчен инстанцияләр буенча йөргәндә, шактый авырлыклар тудырган дип әйтергә дә хаклыбыз.

1852 елдагы вафатына кадәр Зәйнетдин хәзрәт ишле гаиләсе белән Тәбәрледә яшәсә дә, халык санын алу вакытларында алар Бәзәкә типтәрләре исемлегендә саналган. Алты улы арасында аның хезмәтен дәвам итүчеләр булмаган. "Ул заман кануннары буенча, авыл халкы аларга имана җире бүлеп бирә алмау сәбәпле, [...] 1868 елда Зәйнетдин мулла [уллары] Олы Юл урамының көнбатыш очында, әрәмәлекне әрчеп, җир эшкәртеп, күпер янында йорт төзеп урнашкан, - дип язган Р.Мәрданов әсәрендә. - [...] Башта Иске Бәзәкәдә, аннары Шикәрле Каен авылында документаль язып йөртелгән Зәйнетдин мулла гаиләсе исә 1871 елда Тәбәрледә имана җире алып, рәсми рәвештә тулы хокуклы буларак, шушында теркәлүгә ирешкән". Шулай итеп, Зәйнетдин мулла нәселе үзләре чистарткан җирләрне имана җире итеп рәсмиләштергән һәм Тәбәрледә яшәвен дәвам иткән.

Бәзәкәдән күрше авылларга имам булып китеп, гомерләрен халыкка дини-әхлакый тәрбия бирүгә багышлаган башка авылдашларыбызның язмышына да кыскача гына тукталыйк.

Бәзәкәдән чыккан өченче мулла, Габделлатыйф Балтанов (1795-1858 елдан соң), озак еллар дәвамында Кичкутанда мулла һәм мөдәррис булып кына калмаган. Ул тирә-юньдә дан казанган атаклы Балтановлар нәселенә нигез салган. Аның уллары Мөхәммәтсадыйк (1818 елда туган), Мөхәммәткамал (1822), Габсаттар (1826) һәм Мөхәммәтлатыйф (1829), әтиләре мәдрәсәсендә укыганнан соң башка мәдрәсәләрдә белемнәрен арттырып, тирә-күрше авылларда мулла булып киткәннәр. Мәсәлән, РС 1858 дә 40 яшьлек Мөхәммәтсадыйкның Тойма авылында (хәзерге Менделеев

районы) мулла булуы күрсәтелгән. Мөхәммәткамал һәм Габсаттар мәхдүмнәрнең муллалык хезмәтен кайда башкарулары әйтелмәсә дә, аларның да төрле авылларда мулла вазыйфасын үтәүләре һәм гаиләләре белән әтиләреннән аерым яшәүләре хакында Кичкутан авылы вәкиле Йөзекәй Мөхәмәдиевнең башкорт гаскәре башлыгына 1859 елның 17 мартында җибәргән мөрәҗәгатеннән аңларга була. Кече улы Мөхәммәтлатыйф исә Кичкутанда әтисен алмаштырган. Бу хакта аның кулы белән тутырылган 1864 елгы метрика кенәгәсе күрсәтә.

Исегезгә төшерим, 50 елларның икенче яртысында башкорт-типтәр гаскәрләре берләштерелә. Шул ук чорда Вятка казна палатасы, башкорт гаскәре башлыгының 1858 ел 22-август аңлатмасына нигезләнеп, мулла Габделлатыйф Балтановның гаиләсен Бәзәкәдән Кичкутан авылы җәмгыятенә күчерү хакында карар кабул иткән. Бу хакта РС1858-дә аңлатма бирелгән. Хәзрәтнең 13 ир-ат һәм 21 хатын-кыздан гыйбарәт булган ишле гаиләсе ике өлешкә бүленгән – беренчесенә Кичкутанда яшәүче 5 ир-ат һәм 11 хатын-кыз (мулла үзе, хатыны, кызлары һәм кече улы Мөхәммәтлатыйф гаиләсе белән) керсә, икенчесендә гаиләнең Кичкутанда яшәмәүче 8 ир-аты һәм 10 хатын-кызы булган. Гаскәр башлыгы хатында беренче хуҗалык хакында гына сүз барса да, салымнарны билгеләгәндә, Вятка казна палатасы гаиләнең икенче өлешен дә Кичкутан исемлегенә керткән. Шул аңлашылмаучылыкны бетерергә теләп, Йөзекәй Мөхәмәдиев гаскәр башлыгына мөрәҗәгать иткән була да инде.

Кичкутан авылы буенча 1897 елгы Бөтенрусия халык саны алу материалларында 68 яшьлек указлы мулла Мөхәммәтлатыйф Габделлатыйф улының гаиләсендә 8 ир-ат һәм 5 хатын-кыз күрсәтелгән. Аның уллары Таҗетдин (1858 елда туган) һәм Габдулла (1872) Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлаганнар һәм шулай ук авылларында мулла булганнар: беренчесе указын 1881 елның 11 декабрендә, икенчесе 1900 елның 17 апрелендә алган. Балтановлар династиясе хакында сүземне тәмамлап, Габделлатыйф хәзрәтнең дистәләгән оныгы һәм оныкчыгы атаклы Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем алганлыгын күрсәтим. Оныклары бабалары һәм аталары кебек Алабуга һәм Сарапул өязләрендә имамлык вазыйфасын башкарсалар, оныкчыклары иске тормышны җимерүче һәм Совет Татарстанында яңа тормыш төзүчеләр рәтенә баскан. Берсе дә репрессия машинасыннан читтә калмаган.

РС 1834 мәгълүматлары буенча без Иманкол хәзрәт Йосыповның ишле гаиләсенә тукталган идек. Бу гаиләнең язмышындагы үзгәрешләрне дә күрсәтик. 1840 елда Иманкол-хәзрәт алтмыш яшендә вафат булган. Аның ишле гаиләсе өч мөстәкыйль хуҗалыкка бүленгән. Ике өлкән улы гаиләләре белән үз хуҗалыкларында яши башлаган. Һәрбер гаиләдә өч-дүрт ир бала булуы аларның тормышлары нык булгандыр дип уйларга мөмкинлек бирә. Ә менә төп йортта калган Габделвәли (1840 елда) һәм Габделгалләм (1844 елда) авылдан качып киткәннәр. Нәтиҗәдә 1834 елда 16 кешедән торган гаиләдән Иманкол-мулла йортында аның төпчек улы егерме яшьлек Габделсатдик белән Габделвәлинең унике яшьлек улы Габделнәфыйк кына калганнар. РС

1858 дә хәзрәтнең дәвамчыларында дүрт хуҗалык булуы, качкыннарның табылмавы язылган.

20-еллар урталарында имамлык хезмәтенә керешкән Шаһиислам Рәфыйкъ улы Имангол хәзрәтнең вафатыннан соң да хезмәтен дәвам иткән. РС 1850 язмаларында аның Бәзәкәдә указлы мулла булуы күрсәтелгән. Ләкин РС 1858 материалларында аның Иж-Бәйке авылында указлы мулла булуы язылган. Үзенең туган авылында чирек гасыр чамасы муллалык вазыйфасын башкарган хәзрәт нинди сәбәпләр аркасында картлык көннәрендә башка авыл мулласы булып киткән икән? Моның сәбәпләре безгә билгеле булмаса да, 60 яшен тутырып килгән хәзрәтнең үз теләге белән нигезен ташлап китүенә ышанып булмый. Димәк, безгә, хәзрәт белән йорт старшинасы яки авыл куштаннары арасында ниндидер мәсьәләләр буенча аңлашылмаучылык (низаг) килеп чыккандыр һәм Шаһиислам хәзрәт Иж-Бәйкегә күченергә мәҗбүр булгандыр, дип уйларга кала.

Мәчетне мәхәллә халкы җыелу һәм җәмгыять алдына килеп чыккан мәсьәләләрне чишү урыны дип күрсәткән идек инде. Авыл муллаларының крестьяннарны яклап чыгыш ясаулары халык сайлаган юлның дөреслеген көчәйткән, мәхәллә халкын берләштергән. Әгәр дә мулла фикере халыкның күпчелеге яклаган фикер белән тәңгәл килмәсә, мулла эшсез калырга, хәтта төрле янаулар аркасында авылдан күченеп китәргә дә мәҗбүр булган. Бу очракта да шулай булырга мөмкин. Ничек кенә булмасын, ләкин Шаһиислам хәзрәттән соң Бәзәкәдә читтән килгәннәр генә муллалык вазыйфасын башкарган.

Бәзәкәгә читтән чакырылган беренче мулла кем булгандыр, тәгаен генә әйтеп булмый. Ләкин ул 1840 елда Имангол хәзрәтнең вафатыннан соң чакырылган булырга тиеш. Бәлки ул Минзәлә өязе Тымытык авылы типтәре Мөхәммәдсалих Мөхәммәдсадыйк улы булгандыр. Аның хакындагы мәгълүмат бик аз. 2000-еллар башында Хәй абый Гыйльфанов миңа Бәзәкә муллаларының шәҗәрәсен язып җибәргән иде. Менә Мөхәммәдсалих хәзрәт шәҗәрәсе: “Исәнгол – Гаделшаһ – Мөхәммәдсадыйк – Мөхәммәдсалих”. Бәзәкә зиратындагы кабер ташларын барлаганда, Мөхәммәдсалих хәзрәтнең кабере өстенә куелган ташны да фотога төшереп алган галим Раиф Мәрданов ташта язылганнарны укып, бу фотоны һәм язмаларын миңа җибәрде. Менә аның язмасы: “Бу таш зур түгел, аның биеклеге 50 см, киңлеге 34 см. Язулары түбәндәгечә.

Алгы ягында:

1 юл) мәдфүн *(монда җирләнгән)* 2) имам 3) *[Мөхәммәдсалих]* имам вә мөдәррис 4) Мөхәммәдсадыйк угылы 5) Гаделшин мәсихия (*милади ел исәбе)* сәнә 6) 1895 нче һиҗрия илә 7) 1313 нче елда

Арткы ягында:

1) язгучы (*язучы)* кияве 2) мулла Тажетдин бине 3) Мөхәммәдшакир угылы Габдессәламов”.

Р.Мәрданов аңлатуынча, ташта имамның исеме укылмаган; ул аны архив материалларыннан тапкан һәм шуңа күрә квадрат җәяләр эченә куйган. Шулай итеп, бу таштан без Мөхәммәдсалих хәзрәтнең мулла һәм

мөдәррис хезмәтен башкарганлыгын һәм аның 1895 елда вафат булганлыгын белдек. Бәзәкә авылы буенча 1897 елгы Бөтенрусия халык санын алу материалларында хәзрәтнең авыл җәмгыятеннән арендага алган җирдә төзелгән хуҗалыгында 19 яшьлек улы Мөхәммәдшәрип Мөхәммәдсалихов хуҗа буларак язылган. Аның белән бергә әнисе, ике ир туганы һәм сеңлесе яшәве, арендага алган җирдә йортларыннан тыш яшелчә бакчасы булуы да күрсәтелгән. Бу нәселнең дәвамчылары бүген дә Бәзәкәдә яши.

Мөхәммәдсалих Мөхәммәдсадыйк улы Гаделшингә ташны кияве – мулла Тажетдин Мөхәммәдшакир улы Габдессәламов язып куйган икән. Ул мин кереш сүздә үземнең беренче тарих укытучым дип атаган Тажимулла абзый Шакиров. Күрәсең, ул да, Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлап, Мөхәммәдсалих хәзрәтнең кызына өйләнгән һәм балалар укыткан, күпмедер вакыт мулла да булып торган. Белемле кеше буларак, революциядән соң рәсми муллалык эшеннән читләшкән, фамилиясен дә әтисенең исеменә күчергән һәм репрессияләрдән читтә кала алган.

Бәзәкәгә читтән килгән тагын бер имам – Сарапул өязе Салагыш авылы типтәре Габделхәлим Габделгалләм улы Сәйфуллин (1832-1917) булган. 1834 елгы ревизия материалларында мин аның бабалары хакында мәгълүмат таптым. Салагыш авылы халкын исәпкә алган РС 1834-тә Тойма авылы указлы мулласы 49 яшьлек Сәйфулла Ишкенин, аның 43 яшьлек хатыны Меюрбик, 26 яшьлек улы Габделгалләм, 1 яшьлек оныгы Габделхәлим, ике кызы (16 яшьлек Фәрхиҗиһан һәм 3 яшьлек Шәмсекамәр) күрсәтелгән. Димәк, Габделхәлим бине Габделгалләм бине Сәйфулла бине Ишкенә муллалар нәселен дәвам иткән. Иң кимендә, аның бабасы, бабасыннан соң әтисе Тойма авылында муллалык вазыйфасын башкарганнар.

Габделхәлим хәзрәт хакында да мәгълүмат күп түгел. Күрәсең, ул бабасы Сәйфулла хәзрәт мәдрәсәсендә белем алгандыр. Диния нәзарәте каршында имтихан тотып, муллалыкка указ алуы 50-нче еллар урталарына туры килгән булырга тиеш. Ягъни Бәзәкә имамы Шаһиислам хәзрәт безгә билгеле булмаган сәбәпләр буенча туган авылын ташлап китәргә мәҗбүр булган чорда Габделхәлим мәхдүм указлы мулла булып өлгергән дип фаразлый алабыз. Шулай Тойма мулласы Сәйфулла хәзрәтнең оныгы яшь указлы мулла Габделхәлим Бәзәкәнең җәмигъ мәчетенә мулла булып киткән булырга тиеш. Архив материалларыннан хәзрәтнең 1860 елдан Бәзәкәдә үз мәктәбен ачуы, 1895 елда аның әле балаларны укытуын дәвам итүе һәм ахун дәрәҗәсендә булуын белә алабыз. Моннан тыш, Габделхәлим хәзрәтнең 1966 елда, бәзәкәлеләрне окладка утыртканда, Бәзәкә җәмгыяте әгъзасы булып язылганлыгын да күрсәтергә кирәк.

1897 елгы Бөтенрусия халык санын алу материалларында 64 яшьлек указлы мулла Габделхәлим Габделгалләм улы Сәйфуллин хуҗалыгында 5 ир-ат һәм 6 хатын-кыз теркәлгән. Хәлим хәзрәт гаиләсендә, кечкенә балалардан кала, барчасы да укый-яза белгән. Хәзрәт үзе һәм 4 улы мәдрәсәдә белем алганнар. Хәзрәтнең өлкән улы 24 яшьлек Гайнетдиннең 21 яшьлек хатыны һәм ике кызы булуы күрсәтелгән. Башка чыганаклардан мин Хәлим хәзрәтнең өч улы – Фәтхетдин (1864-1924), Рәфагетдин (1876-1937), Әхмәтсафа (1884-

1975) һәм кызы Фәхирәнең (1893-1994) атаклы Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем алулары хакында беләм. Аларның XX гасырдагы язмышлары хакында сүз соңрак булыр.

Бәзәкәгә читтән килгән өченче имам – Мамадыш өязе крестьяны Гыймранов Минехужа. Ул чорның атаклы Түнтәр мәдрәсәсен тәмамлаган шәкертне, аның оныклары Фәйзелхак абый Хөснетдинов һәм Хәй абый Гыйлфанов сөйләве буенча, күпмедер вакыт Бәзәкәдә яшәгән һәм Бәзәкә халкы рөхсәте белән авылда икенче мәчетне төзеткән сәүдәгәр алып килгән. Хәй абый икенче мәчет 1856 елда төзелгән дип саный иде. Ләкин бу факт 60-нчы еллар урталарында булгандыр, чөнки Вятка губернасының 1859 елгы исемлегендә Бәзәкә авылында бер агач мәчет, ә 1869 елгы исемлектә ике агач мәчет күрсәтелгән. Димәк, икенче мәчет шушы ун ел эчендә төзелгән дип әйтә алабыз.

Минехужа хәзрәт үзен Хужа-Әхрар дип атарга яраткан (“әхрар” – гарәпчәдән татарчага “азатлар, ирек сөючеләр, аксөякләр” дип тәрҗемә ителә; күрәсең, хәзрәткә үз исеме бик гади, кара халыкка хас исем булып тоелгандыр, һәм ул исеменә мулланы зурлап күрсәтә торган сүзне кушкандыр). Минехужа хәзрәтнең яшәгән елларын мин тәгаен гына белә алмадым. Оныклары аны 1898 елда вафат булган дип санасалар да, 1897 елгы Бөтенрусия халык санын алу материалларында аның исеме күрсәтелмәгән. Анда йорт-каралтыларның хужасы буларак 28 яшьлек казна крестьяннарыннан булган Мөхәммәтзакир Минехужин язылган. Гаиләдә ике ир-ат һәм 4 хатын-кыз булган, арендага алынган җирдә ике торак йорт булуы әйтелгән. Мөхәммәтзакир мәхдүмнең Иж-Бубый шәкерте булуын да күрсәтеп узу кирәктер. Күрәсең, ул әтисе исән чакта ук, 1895 елда Мөхәммәдсалих хәзрәтнең вафатыннан соң мулла вазыйфасын башкара башлагандыр дип фаразларга була.

Шулай итеп, өч читтән килгән мулла да Бәзәкәдә яшәп калган, балалар-оныклар үстергән, ләкин барлык рәсми документларда да алар читтән килгән кеше буларак теркәлгән. Гадәти буларак, алар хакындагы мәгълүмат Бәзәкә халкы исемлеге ахырында бирелгән. Хәтта аларның Бәзәкәдә туган уллары, аталарының эшен Бәзәкәдә дәвам итсәләр дә, барыбер аталары чыккан төбәк кешесе саналганнар. Ә бу исә, әйткәнемчә, аларны Бәзәкә җирен арендага алып яшәргә мәҗбүр иткән.

Бу бүлеккә йомгак итеп, авылда ислам диненә игътибарның көчәюен чагылдырган бер күренешне күрсәтәсем килә. XVIII гасырда туган кешеләрнең күпчелеге Хужаш, Бикташ, Йөзекәй, Әмир, Шоңкар кебек төркитатар исемнәрен йөрткән. Ә XIX гасырда мондый исемнәрне ислам динен, Аллаһ, Пәйгамбәрне олылап кушылган исемнәр алмаштырган. Шулай Бәзәкәдә Хәбибулла, Нигъмәтулла, Кәлимулла, Шәрәфетдин, Хисаметдин, Мөхәммәтдин, Мөхәммәтгали, Габделкәрим кебек исемнәр киң таралган. Дөрес, авылда элек тә мөселманнарга хас исемнәр шактый булган, ләкин авыл кешесе аларны кыскартып, көчкә танырлык дәрәҗәдә үзгәртә торган булган. Мәсәлән, минем ерак бабам Сөләйман (Пәйгамбәр исеме) Сөлүк-староста булып тарихка кереп калган. Бу факт XIX гасырда ислам диненең

җәмгыять тормышына тирән үтеп керүенең бер күрсәткече буларак кабул ителергә тиеш. Ләкин гади сөйләмдә бәзәкәләләр мулла кушкан тулы исемне кыскарта торган булганнар: Хаҗиәхмәт – Хаҗи, Гыймазетдин – Гыймади, Минтаҗетдин – Минтач, Минһаҗетдин – Минәч, Ибәтулла – Ибәт h.б..

Бәзәкәдә балаларны укыту

Күңелдән сагынам “тоткынлыгымны”, мәктәбемне мин,
“Нигә соң үстем инде һәм нигә “дәү” булдым инде”, - дим.
Габдулла Тукай

Татар яшәгән җирдә мәчет-мәдрәсә һәм мулла булырга тиешлегенә безнең халык борынгы заманнардан ук ияләнгән, чөнки шәригать кануннарында халыкка дини белем бирү мулла вазыйфаларының иң мөһимнәреннән саналган. Әби-патша әмере белән кабул ителгән ислам диненә бәйле законнар да руханыйларның бу вазыйфасын саклаган. Мәсәлән, Оренбург диния нәзарәте каршында имтихан тоткан һәрбер кеше мулла булу өчен указга таныклык алу белән бергә имам-хатыйп (хөтбә укучы), мөдәррис яки мөгаллим исемнәрен дә алган. Мәхәллә халкы аны шәригать кануннары сагында торучы һәм дини йолаларны үтәүче, балаларга дин нигезләрен аңлатучы, тәрбияче һәм укытучы буларак кабул иткән. Ягъни балаларга башлангыч дини белем бирү мулла өчен дә, халык өчен дә мәҗбүри саналган.

Бәзәкәдә беренче мәктәпнең кайчан барлыкка килгәнлеге безгә билгесез, чөнки бу турыда рәсми документлар табылмады. Ләкин авылда мәчет һәм мулла булган очракта, һичшиксез, мәктәп тә булган. Сабый чагымда ишеткән бик күп риваятьләрдә әби-бабаларыбыз һәм аларның бик борынгы бабалары да ислам динендә булулары, бу диннең нигезләренә мулла-абыстайларның өйрәтүе хакында сөйләнә иде. Үз мәдрәсәсен булдырган Бәзәкәнең беренче указлы мулласы Имангол Йосыпов хакында мин алдагы бүлектә язган идем. Мәчет янында мәдрәсә-мәктәп булдыру мулланың вазыйфасы саналса да, ул уку йортларында бирелгән белемнең күләме беркем тарафыннан да билгеләнмәгән. Бу күләм бары тик мулланың үз белеме дәрәҗәсе һәм теләгеннән чыгып кына билгеләнгән. Ул чорда уку йортын мәдрәсә (гарәпчәдән “дәрес укыла торган урын”) дип тә, мәктәп (“яза торган урын”) дип тә атау мөмкин булган. Татар уку йортларын бүлү, ягъни башлангыч белем бирә торганнарын “мәктәп”, урта һәм югары белем бирә торганннарын “мәдрәсә” дип билгеләү җәдитчә (яңача) укыту башлангач, Х1Х–ХХ гасыр кисешендә генә кулланышка кергән.

Мәктәптә укыту-тәрбия эшләрен оештыру аның максаты, бурычлары белән билгеләнә. Мөселман мәктәпләренең төп максаты, ислам белгече Я.Д.Коблов фикеренчә – “мөселман балаларын уку-язуга өйрәтү, аларны ислам нигезләре белән таныштыру, аларга яхшы әхлак тәрбиясе бирү һәм шуның белән илдәге тынычлыкка ярдәм итү” булган. Шушы максаттан чыгып, уку курсына гарәп әлифбасын өйрәнү (аңа бер ел да, күбрәк вакыт та, гадәттә, ике-өч ел кирәк була алган), укый – яза (кайвакыт) белү, дин нигезләре һәм башлангыч хисап алымнарын үзләштерү кергән. Авыл мәктәп-

мәдрәсәләрендә күп очракта дәреслекләрнең булмавын да күрсәтергә кирәк. Төп игътибар догалар ятлауга, дини йолаларны өйрәтүгә бирелгән. Ә инде күбрәк белем бирә торган мәдрәсәләрдә шәкертләр дәреслекләрне күчереп язганнар. Малайлар мулладан, кызлар абыстайдан белем алган.

Мәктәп-мәдрәсәләрнең рәсми рәвештә расланган программалары яки уставлары булмаган. Һәр мулла үзе белгәнне балаларга өйрәтергә тырышкан. Ул үзе укыганда нинди ысуллар белән белем эстәгән булса, шул ысулларны үз укучыларына карата да кулланган. Укыту берничә этаптан торган. Укуны 5-8 яшьлек малайлар әлифба белән танышудан башлаганнар. “Әлепбитиси”ләрне һәм төрле иҗекләрне үзләштерү балаларга бик авырдан бирелгән (гарәп алфавитындагы 29 хәрефнең язылышы берничә төрле булуы һәм аларның гомуми саны 118 гә җитүе, моның өстенә сузык авазларның җитәрлек булмавы, аларны билгеләү өчен хәрефләрнең өстендә һәм астында төрле билгеләр кулланылуы, төрки телдә укырга өйрәтә торган әсбабларның булмавы h.б. сәбәпләр укуны катлауландырган). Катлаулы иҗек ысулы белән әлифбаны өйрәнгән чорда малайлар дини кагыйдәләрне дә үзләштергәннәр.

Уку механизмы белән танышканнан соң укучылар дини-тәрбияви характердагы китапларны өйрәнүгә керешкәннәр. “Мәктәптә уку курсын узу вакыты билгеләнми; класс кебек бүлемнәргә бүлү дә юк, - дип язылган эчке эшләр министрлыгына җибәрелгән бер аңлатмада. – Бер китапны өйрәнүдән икенчесенә, мәсәлән, “Иман шарты”ннан “Һәфтияк”кә күчү класстан класска күчүгә тиң булган”. Укыту ысуллары да үзенчәлекле булган. “Һәрбер укучы уку курсын башкалардан аерым, мөстәкыйль үтә; һәркөнне ул аның янында утыручы малайныкыннан үзгә булган үз биремен ала. Укучылар муллалары биргән дәресне, бер-берсеннән уздырырга тырышып, кычкырып ятлыйлар, - дип тасвирлаган мөселман мәктәбендә дәрес барышын Я.Д.Коблов. – Шуңа күрә бертуктаусыз гүләп торган мәктәптә аерым сүзләрне аңлап та булмый”. Мондый укыту ысулы барлык укучылар белән берьюлы эшләү мөмкинлеген чикләгән. Шуңа күрә мулла өлкән укучылары арасыннан үзенә “хәлфә” исемен йөрткән ярдәмчеләр сайлаган. Бу очракта мөдәррис аларны муллалыкка да хәзерләгән. Ислам фәннәрен уңышлы өйрәнгәннәрен соңрак ул башка авылларга имам итеп тәкъдим иткән.

“Иман шарты” һәм “Һәфтияк”не өйрәнгәннән соң балалар 1186 елда вафат булган С.Бакырганиның “Ахыр заман китабы”, XII гасыр азагы – XIII гасыр башы шагыйре Кол Галинең “Кыйсса-и Йосыф”, 1451 елда вафат булган М.Чәләбинең “Мөхәммәдия”, Т.Ялчыголның (1768-1838) “Рисалә-и Газизә”, билгесез авторларның “Бәдәвәм” һәм “Кисекбаш китабы” кебек шәрекъ классикасының татарлар арасында киң таралган төрки телле әсәрләрен дә укыганнар. Әлбәттә, бу әсәрләр һәр мәктәптә дә булган дигән сүз түгел. Китапларның күбесе зур мәдрәсәләрдә шәкертләр тарафыннан күчерелгән булуын да, аларның кулдан-кулга, буыннан-буынга күчүен дә кисәтик. Әсәрләрне әби-бабаларыбыз укып кына калмаган, аларны ятлаганнар. Әле мин үскән чакта да безнең әбиләребез алардан өзекләр көйләп йөриләр иде.

Бу әсәрләр балаларның дини-әхлакый тәрбиясендә зур роль уйнаган. Диалоглар, төрле хикәяләр формасында мәзәк һәм гыйбрәтле хәлләрне тасвирлап язылган китаплар балаларга җайлы гына ислам кыйммәтләрен үзләштерергә ярдәм иткән. Аларны укыганда, балалар әсәрнең герое белән бергә хәсрәтләнгәннәр һәм куанганнар, юаныч һәм гыйбрәт-сабак алганнар. Үгет-нәсыйхәт белән тулы китапларны уку балаларга тарих, география, әдәп һәм башка өлкәләрдән булган мәгълүмат белән танышу мөмкинлеген дә биргән, ә бу, үз чиратында, аларның аң-белемен, фикер йөртү дәрәҗәсен үстергән. Бу әсәрләрдә галимнәр, киң белемле шәхесләр макталган, белем эстәү, чит телләрне өйрәнү зур байлык саналган. Мәсәлән, “Кыйсса-и Йосыф” поэмасы героеның 72 тел белүе аның иң күркәм сыйфатлары буларак тасвирланган. Әлбәттә, авыл мәктәп-мәдрәсәләрендә белем алучы балаларның барлык бу әсәрләрне уку мөмкинлеге булмаган (беренчедән, авылда китаплар аз таралган булса, икенче яктан, бала 3-4 ел мәктәпкә йөргәннән соң, аның укуы тәмамланган).

Бала укуга һәвәс һәм сәләтле булса, ул бик кыска вакыт эчендә хәреф таный башлап, бер ел эчендә берничә китапны өйрәнә алган. Ләкин гамәлдә, мәктәпкә өч-дүрт ел йөреп тә, хәреф таный алмый калган балалар да җитәрлек булган. Әгәр дә мулланың җитәрлек белеме һәм мәдрәсәсен киңәйтергә теләге булса, мәхәллә балаларына башлангыч дини белем биргәннән соң, ул теләкләре булган ата-аналарның балаларын муллалыкка хәзерләргә җыенуы хакында мәчеттә белдергән. Калганы инде ата-ана мөмкинлекләреннән дә, шәкерт һәм мулланың тырышлыгыннан да торган. Шулай мәдрәсә барлыкка килгән. Мәдрәсә ачу өчен аерым бина да, бернинди җиһаз да, хәтта дәреслекләр дә таләп ителмәгән. Имангол Йосыповның мәдрәсәсе шулай эшли башлагандыр дип уйларга була.

Бәзәкәдәге мәктәпләр хакындагы беренче мәгълүматлар Х1Х гасыр азагы – ХХ гасыр башына гына карый. Вятка губернасы халык мәктәпләре дирекциясе фондында 1911 елга караган белешмәдә беренче мәчет каршындагы уку йорты 1860 елда, икенче мәчет каршындагысы 1875 елда ачылганлыгы күрсәтелгән. Менә Вятка губернасы татар мөселман мәктәпләренең 1895 елның 1 июненә төзелгән исемлектән өзек: “6. Салагыш волосте Бәзәкә авылында:

1) Мулла Гыймранов йортында; ахун Минехужа һәм аның хатыны Раузателҗинан укыталар; 10 малай һәм 15 кыз укый.

2) Хатыйб Сәйфуллин йортының арткы өлешендә, аш өендә; хатыйб Габделхәлим Габделгалләмов һәм аның хатыны Бибидурратилодинан Зиман укыталар; 35 малай һәм 25 кыз укый.

3) Имам Мөхәммәтсадыйков йортында, аш өендә; имам Мөхәммәтсалих Мөхәммәтсадыйков укыта;15 малай һәм 15 кыз укый”.

Бу мәгълүмат безгә нәрсә бирә соң? 1) Авылдагы өч мулланың, кечкенә генә булса да, үз мәдрәсәсе булган. Аларда барлыгы 60 малай һәм 50 кыз бала укыган. Барлык уку йортлары имамнарның үз өйләрендә булуы да укучыларның күп булмавының сәбәбе булгандыр. 2) Исемлек төзүгә зур игътибар бирелмәгәнлеге сизелеп тора. Бу имамнарның дәрәҗәләрен төрлечә

һәм тулы күрсәтмәүдә дә күренә (мәсәлән, Хәлим хәзрәтне “ахун, имам-хатыйб һәм мөдәррис” дип язу дөрес булыр иде). Мондый исемлекләрдә, һич югы, аларның “мөдәррис”ме, “мөгаллим”ме булуы күрсәтелергә тиеш. 3) Укучыларның саны якынча гына күрсәтелүе сизелә (кагыйдә буларак, бу саннар “түгәрәк” була алмый). Шул ук вакытта, беренче һәм өченче сан астында бирелгән мәктәпләрдә укучылар саны, якынча, дөреслеккә туры килсә, беренче мәхәллә мәктәбендә балалар саны артык күп күрсәтелгән (аш өенә 60 бала ничек сыйды икән?). Моңа өстәп, Хәлим хәзрәт һәм аның хатыныннан тыш, бу кадәр баланы укыту өчен тагын да укытучылар булырга тиеш, дип әйтәсе килә. Һәм бу укытучылар хәзрәтнең өлкән улы Гайнетдин һәм аның хатыны булса кирәк.

Бу игътибарсызлыкларның үз аңлатмасы бар. Мәгълүматны тикшерүчеләргә авыл старостасы һәм муллалар үзләре биргән. Өяз-губерна башлыкларының күрсәтмәләрен үтәргә тиеш булган староста һәм муллалар, бу таләпләргә буйсынсалар да, мәктәпләр хакында да, гомумән, авыл хакында да төгәл мәгълүмат бирергә ашкынып тормаганнар. Татар авылларына хас булган бу сыйфат хакында шактый документларда язылган. Авыллардан килгән мәгълүматның җитәрлек булмавын без башка документларда да очратабыз. Мәсәлән, Вятка губернасы Алабуга өязе мөселман мәктәп-мәдрәсәләренең 1899 елгы исемлегендә Бәзәкәдә гомумән бер генә мәктәп күрсәтелгән. Анда ул мәктәпнең укыту өчен җайланмаган үз бинасы булуы, 30 малай һәм 20 кызны мулла Мөхәммәтзакир Минехуҗа улы Гыймранов укытуы гына күрсәтелгән. Башка мәктәпләр, мәсәлән, Хәлим хәзрәт мәктәбе өчен исемлектә урын табылмаган.

1903/1904 уку елының икенче яртысында Вятка губернасы Алабуга өязенең халык мәктәпләре инспекторы Сергей Парамонов Алабуга өязендәге башлангыч мөселман мәктәпләре белән танышып йөргән. Үзенең шактый күләмле отчетында ул игътибарга лаек күзәтүләр ясаган. Башта ул саннарны атаган: бу вакытта өяздә 25 башлангыч мөселман мәктәбе булган, аның берсе халык мәктәбе, калган 24 өяз мәктәпләре саналган. Уку елының беренче яртысында инспектор 7 мәктәпне, икенчесендә калган 18-ен караган. Ул да Бәзәкәдә бер генә, Мөхәммәтзакир Минехуҗинның мәктәбе белән генә танышкан.

Мәктәпләрне йөреп чыгуның максаты буларак, ул алар белән танышуны, аларның тышкы күренешен генә түгел, мөмкин булган кадәр, аларның эчке халәте белән дә танышуны куйган. Ләкин уку-тәрбия эшләренең оештырылуы һәм укытучыларның хезмәте белән танышу, мөселман мәктәпләренең үзенчәлекләренә һәм рус мәктәпләреннән аермалыкларына төшенергә тырышу юлында аңа бик җитди киртәләргә тап булырга туры килгән. Менә алар: “1) муллаларның (мәсәлән, Кодаш, Бәзәкә, Дөм-Дөм авылларында) бик начар, ә кайчак бөтенләй русча сөйләшә белмәүләре аркасында мәктәпләр хакында мәгълүмат алу мөмкинлеге булмау; 2) фәннәрне укытуның педагогик ысуллары һәм алымнары белән бөтенләй таныш булмаган муллалар программалар һәм уку барышы хакындагы сорауларга канәгатьләндерерлек җавап бирә алмыйлар; шуның аркасында мөселман мәктәпләренең тормышы

билгесез булып кала; 3) муллаларның мәктәп тормышындагы күп кенә фактларны әйтми калулары яки чынбарлыкка туры килмәгән мәгълүмат бирүләре”, - дип санап киткән инспектор.

Инспекторның бу күзәтүләре минем сүзләрне раслый. “Мөселман мәктәпләренең барысының да диярлек, юридик күзлектән караганда, яшәргә хокуклары юк, чөнки аларның берсендә дә уку-укыту администрациясенең законлы рөхсәте юк. Алар арасыннан бик азы гына 1870 елның 26 март законы басылганчы ачылган (бу закон буенча, мөселман мәктәпләре администрация рөхсәте булган очракта гына ачылырга хаклы дип табылган – А.М.). Ләкин аларның барысы да администрациягә хәбәр итмичә генә һәм аның катнашыннан башка гына ачылганнар һәм яшәп киләләр, - дип үзенең күзәтүләрен җиткергән инспектор. – Бу күренеш, бер яктан, администрациядән рөхсәт сорау кирәклеген муллаларның белмәве белән аңлатыла. Икенче яктан, минем фикеремчә, алар үзләре чит дип санаган кешеләрнең мәктәп эшләренә катнашуларын теләми. Муллалар “бу кешеләр мөселман мәктәпләренә ярдәм итү турында уйлау түгел, хәтта аларның яшәешен дә теләмиләр, чөнки ниндидер яшерен һәм усал максатларны күз алдында тоталар”, - дип саный. Шуңа күрә муллаларның мәктәпләрне тикшерүчеләргә карата үз мөнәсәбәтләрендә дә һәм аларның мондый кешеләр белән аралашырга теләмәүләрендә дә билгеле бер очракларда күрәлмаучанлыкка күчә торган ышанмаучылык сизелеп тора”.

Инспекторның отчетында тикшерүчеләргә күп авырлыклар китерә торган бу күренешләрне бетерү өчен кулланылырга тиешле тәкъдимнәре дә бар: 1) мулла булырга теләгән кешеләр рус телен җитәрлек дәрәҗәдә үзләштергән булырга, ягъни дөрес һәм аңлаешлы итеп рус телендә сөйләшә, укый һәм яза белергә тиешләр; 2) укыту эшен һәм укучыларны грамотага, ягъни уку-язу һәм арифметика нигезләрен өйрәтү юлларын белү мәҗбүри; 3) муллаларны яңа мәктәпләрне ачу кагыйдәләре белән таныштыру, ягъни алар, яңа мәктәпне ачканчы ук, һичшиксез, уку-укыту идарәләреннән рөхсәт сорарга кирәклеген белергә тиешләр; 4) ачылырга тиешле мөселман уку йортларының (мәктәп-мәдрәсәләрнең) инспекция карамагында булуын һәм мәктәп җитәкчеләренең тикшерүчеләргә ярдәм итәргә бурычлы икәнлеген мөселман дини идарәсе аркылы муллаларга җиткерергә кирәк. Димәк, инспектор фикеренчә, аның эшендә очраган авырлыкларның күбесе мөселман мәктәпләре җитәкчеләренең рус телен һәм педагогик алымнарны белмәүләре белән аңлатыла. Моның өстенә, муллаларның Русия законнарыннан хәбәрдар булмаулары да ачыкланган икән.

Татар мәктәпләре белән танышканда, инспекторның күзенә ташланган җитешсезлекләр: 1) биналарның зурлыгы аларда укучы балалар саны белән тәңгәл түгел. Кайбер очракларда (мәсәлән, Бәзәкә, Дөм-Дөм, Тойма, Кодаш һәм башка авылларда) бу туры килмәү чиксез кысынкылык тудыра; 2) яктылык, һава, җылылык һәм шулай ук чисталык җитмәү; мәктәп биналарының бу җитешсезлекләре, теге яки бу дәрәҗәдә барлык мөселман мәктәпләренә хас. “Мәктәп өчен бина билгеләгәндә, аның гигиена шартларына, күрәсең, игътибар итмәгәннәр. Аларны укыту урыны булу гына

кызыктырганга ошый. Үз өйләрендә гигиена таләпләренә игътибар итәргә күнекмәгән кешеләрнең мәктәп бинасына карата да шундый ук мөнәсәбәтләре аңлашыла, - дип язган тикшерүче. Һәм нәтиҗә дә ясаган: - Биналардагы бу җитешсезлекләр, һичшиксез, балаларның саулыгына кире йогынты ясый. Ә кайбер мәктәпләрдә уку вакытында укучыларның бөтен тормышлары шул бинада үтүен, киштә-сәндерәләрдә һәм мич башларында аларның мендәр-юрганнары һәм башка кирәк-яракларның тәртипсез ятуын да исәпкә алганда, аларда йогышлы авырулар таралуының ихтималлыгы бик зур икәнлеген танырга кирәк”.

Әлбәттә, инспектор мәктәпләрдә укыту-тәрбия эшләренең барышына да игътибар иткән. “Мәктәпләрдә мөселман дине, мөселманча уку-язу, хисап нигезләре укытыла. Ләкин соңгысы белән берничә мәктәптә генә шөгыльләнәләр. Бер мәктәптә дә укучылар рус грамотасына өйрәтелмиләр, - дип язган ул. – Минем аңлавымча, моның сәбәпләре: 1) мөселман мәктәпләрен ачу максаты, муллалар фикеренчә, рус грамотасына түгел, ә татар грамотасына өйрәтү; моны мәктәпнең исеме үк күрсәтә; 2) рус телен бөтенләй белмәүче крестьян малайларына бер үк вакытта рус һәм татар грамотасын өйрәнү бик авыр бирелә ченәк; 3) муллаларның күпчелеге үзләре дә җитәрлек дәрәҗәдә рус теле белән таныш түгел, алар аз белемлеләр; 4) моның өчен буш вакытлары юк; 5) җәмгыять үзе балаларга рус грамотасын өйрәтүнең кирәклеген күрми һәм үз наданлыгы аркасында моңа каршы чыга”.

Өяз мәктәпләрендә, мәсәлән, Бәзәкәдә, балаларның укулары өч елга кадәр баруын күрсәткән инспектор. “Һәрбер укучы мәктәптә укый алган кадәр укый, аларның мәктәптәге вакытлары бернинди билгеле һәм мәҗбүри кысалар белән чикләнмәгән”, - дип аңлаткан ул. Бу мәктәпләрдә укытуда кадими ысуллар кулланылуын һәм укыту ысулларының камил булмауларын билгеләп, ул: “Рус мәктәбендә балалар 4-5 ай эчендә өйрәнгәнне (мәсәлән, укырга) мөселман мәктәпләрендә укучылар ел-ел ярымда да өйрәнеп җитә алмыйлар”, - дип өстәп куйган. Бәйрәм көннәреннән тыш һәр көнне дәресләр, иртәнге 8 яки 9 дан башланып, төштән соңгы 3 яки 4 сәгатьтә тәмам булуына, бу 6-7 сәгатькә сузылган дәресләрнең бер генә тапкыр (төшке ашка) бер сәгатькә бүленүенә, рус мәктәпләрендә укучылар ял итәр өчен куеллган дәрес арасындагы тәнәфесләрнең булмавына игътибар иткән тикшерүче.

Авыл мәктәпләрендә укулар, көз көне октябрь аенда башланып, язын апрельдән дә соңламыйча, тәмамланган. Уку сәгатьләренең бүленешен дә күрсәткән инспектор: һәр көнне дин дәресләренә һәм хисапка өйрәтүгә берәр сәгать, укырга өйрәтүгә 2-3 сәгать, язарга - 2 сәгать билгеләнгән икән. Кулланыла торган китап һәм дәреслекләр: мөселман диненә өйрәтүдә Корьән, “Һәфтияк” һәм Әхмәтһади Мәкъсудовның “Гакаидел исламия”, “Шаригател Исламия” һәм “Гыйбадател Исламия” китапларыннан файдаланганнар. Укырга балаларны “Иман шарты”, “Һәфтияк” һәм Корьән буенча өйрәткәннәр. Моннан тыш, Таһировның дәреслеге һәм Мәкъсудовның “Мөгаллимин сабиян” китабыннан да кулланганнар. Ул вакытта бары бер генә мәктәптә – Алабугада өяз чиновниклары рөхсәте белән ачылган мәктәптә генә укытуда җәдид (яңа) ысулы кулланылганлыгы әйтелгән.

Шулай итеп, без Вятка губернасы Алабуга өязенең халык мәктәпләре инспекторы Сергей Парамоновның күләмле һәм шактый объектив күзәтүләре белән танышып чыктык. Нәтиҗә: Муллаларның рәсми тикшерүче белән бик сак аралашуларын, гомумән, татар авылларына хас булган өяз һәм губерна чиновникларына карата мөнәсәбәтне дәвам итү дип кабул итеп була. Бу очракларда муллалар һәм башкалар, гадәти буларак, рус телен белмәүне, шуңа күрә килгән кешеләрнең таләпләрен аңлый алмауны сәбәп итеп күрсәткәннәр. 1903-1904 уку елында Алабуга өязендәге мөселман башлангыч мәктәпләренең (өяз рәхсәте белән ачылган Алабугадагы мәктәптән кала) барысында да гасырдан гасырга күчеп килгән традицон укыту ысуллары кулланылган. Ул чорда мондый мәктәпләр кадим мәктәпләр исемен алган була.

Ләкин вакыт узу белән традицион булган мәктәпләргә дә үзгәрешләр килеп җиткән. 1908-1916 елларда Бәзәкә мәктәпләрендә белем алган минем әтием, Мәхмүтов Хаҗиәхмәт (1900-1980) һәм аның чордашлары сөйләвенчә, алар укырга кергәндә, Бәзәкәдә дә инде яңача укыта башлаганнар. Закир-мулла, Фәтхетдин–хәзрәт, Тажетдин-мулла һ.б. аларны укырга аваз ысулы белән өйрәткәннәр. Ә әтидән бер яшькә генә олы булган абыйсы Нуриәхмәт иҗек ысулы белән укырга өйрәтә торган мәктәпкә эләккән. Ике ел Бәзәкәдә мәктәпкә йөреп, хәреф таный алмаган олы малаен әтиләре, бәлки рәт чыгар дип, өченче елга күрше авыл мәктәбенә Псәйгә җибәргән. Ләкин анда да кулланышта булган иҗек ысулы аның уку теләген бөтенләй юкка чыгарган һәм аны кире алып кайтканнар. Бары ярты елда “чатнатып” укый башлаган энесеннән калышмау теләге генә аның мәктәпкә булган мөнәсәбәтен үзгәрткән. Хәреф танырга да ул энесеннән өйрәнгән.

Шулай итеп, якынча, 1907-1910 елларда Бәзәкәнең яшь муллалары яңа, аваз ысулы (җәдид ысулы) белән укыта башлаганнар. Бу ысулның эчтәлегенә тукталыйк. Әле Х1Х гасырның 80-еллар башында ук Кырым татары, мәгърифәтче Исмәгыйль-бәк Гаспринский Русия мөселманнарының тормышын яхшы якка үзгәртүне максат итеп куйган. Үзгәрешләрне ул башлангыч мөселман мәктәпләрен реформалаудан башларга булган. Реформаның нигезе - “ысуле җәдид” (яңа метод). И. Гаспринскийның яңа методы - аваз ысулы белән хәреф танырга өйрәтү һәм мөселман башлангыч мәктәпләренең программасына элек укытылмаган дөньяви фәннәрне (арифметика, география, тарих һәм башкаларны) укытуны кертү булган.

“Ысуле җәдид” мәктәпләрдән катлаулы иҗек ысулына нигезләнгән “ысуле кадим”не (иске методны) кысып чыгарырга тиеш була. Үз идеяләрен И. Гаспринский үзе чыгара башлаган “Тәрҗеман” газетасы аша тараткан. Газетада яңа ысулның уңай яклары күрсәтелгән, җәдид мәктәпләрендә уздырылган беренче имтиханнар тасвирланган. Мәсәлән, “Тәрҗеман”ның 1894 елгы 2 октябрь санында ассызыкланылганча, бу күрсәтмә имтиханнарда “моңа кадәр күрелмәгән манзараны күрү мөмкин иде: 5-6 ай элек кенә укый башлаган балалар туган телләрендә инде укыйлар һәм язалар, Корьәннән гарәпчә укырга тырышалар һәм иман һәм арифметикадан кайбер нәрсәләрне белүләрен күрсәтәләр”.

Күзгә күренеп торган уңышларга карамастан, яңа, җиңеләйтеләгән ысул белән укытуга күчү күп кенә каршылыкларга очраган. Мөселман мәктәпләрен яхшы белүче Н.А.Бобровников, җәдид мәктәпләренең барлыкка килүен анализлаганда, “иске мәктәпнең тиз генә бирешәсе килми һәм ул яңа ысулга нигезләнгән мәктәпләрне динсезлектә гаепли, дини авторитетларга таянып, мәктәп реформасы дингә каршы эш дип раслый”, - дигән нәтиҗәгә килгән. Кадимчеләрнең бу каршылыгы үзгәреш юлларын тагын да катлауландыра дип күрсәткән ул. Империядә яшәгән мөселман халкы өчен заманчарак булган мәктәпне төзүгә дәүләт тә берничек тә булышмый; булышмый гына түгел, каршы килә. Нәтиҗәдә “мөселман мәктәпләре реформа өчен кирәк булган чыгымнарны мөселман җәмгыятенең үз эчендә генә эзләргә тиеш була, - дип ассызыклаган шул ук Бобровников. – [...] ысулы җәдид юнәлеше рус шартларында туган күренеш булуы күренеп тора; аның таралуы һәм көчәюе әллә кайдан килеп чыккан агитаторлар тарафыннан түгел, ә төбәкләрдә күренекле шәхесләр тарафыннан эшләнә”.

Әлбәттә, бу чорда ачылган җәдид мәктәпләре чиста дини укытудан дөньяви укытуга күчешнең төрле баскычларын тәшкил иткән. Моның сәбәпләре – яңа мәктәпләр барлыкка килгәндә, аларга дөрес юнәлеш бирә торган үзәкнең, хәзерләнгән программа һәм дәреслекләрнең булмавы, әзерлекле педагогик кадрларның җитешмәве булган. Мәктәпләрнең күбесе дини белем нигезләре белән генә таныштырудан ерак китә алмаган. Аларның кадими мәктәпләрдән бердәнбер аермасы – яңа укытучылар (мөгаллимнәр), дәреслекләр һәм укыту барышын берничә тапкыр тизләтә торган аваз ысулы белән хәреф таныту булган. Икенчеләрендә, шуңа өстәп, төркем-дәресләргә бүлеп укытканнар. Дөрес, бу бүленеш заман мәктәпләрендәгедән аермалы, үзенчәлекле төстә алып барылган – төркемнәргә бүлү балаларның укый торган китап исемнәренә карап ясалган. Бу мәктәпләрне без күчеш чоры мәктәпләре дип атый алабыз. Тиз арада хәреф танып, сабый чактан ук таныш ана телендә язылган китапларны аңлап уку балаларда укуга мәхәббәт уяткан, аларның аң-фикере үсешенә булышкан.

Башлангыч җәдид мәктәпләре системасының барлыкка килүе 1905-1907 еллар революциясе йогынтысы белән бәйле. Бу чорда беренче җәдид мәктәпләрендә белем алган мөгаллимнәр күренә башлаган. Хөр фикерле, заманы өчен киң белемле мулла-мөгаллимнәр, авылларына кайтып, укыту системасын үзгәртү эшенә керешкәннәр. Шулар арасында бу вакытка бөтен татар-мөселман дөньясында шөһрәт казанырга өлгергән Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем алган Бәзәкә муллалары Мөхәммәтзакир Минихуҗин (Гыймранов) һәм Фәтхетдин Сәйфуллиннар да булган. “Мөгаен, Европа Русиясендәге мәктәп-мәдрәсәләрнең барлыгы диярлек, теге яки бу чамада, яңа ысул белән укыту юнәлешенең йогынтысына бирелә бара. Миндә моны расларлык мәгълүмат бар. Әлбәттә, бу уку йортларында Европа үрнәгендәге өстәл-парталар, бертөрле кием h.б. бар дип әйткән сүз түгел. [...] Мәктәпләрнең бик күбесе мөселман мәктәпләренең традицион йөзен саклаган, ләкин аларда яңа китаплар һәм яңа яшь укытучылар барлыкка килгән. [...] Күзәтүләрем мине “Европа Русиясендәге мөселман уку

йортларын иске һәм яңа методлыларга бүлү өчен вакыт узган инде” дигән фикергә китерә”, - дип язган 1910 елда Н.А.Бобровников.

Моның чыннан да шулай булуын без Бәзәкә мәктәпләре мисалында да күрәбез. Тышкы яктан да, муллаларның үз-үзен тотышларыннан да аларның кадими мәктәпләрдән аермасын күреп булмаган. Алабуга өязе мөселман мәктәпләрендә 1911 елда уздырылган ревизия хакындагы отчет бу фикергә дәлил булып тора. Анда Бәзәкә авылында ике мәктәп булуы, аларның беренчесендә (1860 елда ачылганында) мулла Фәтхетдин Сәйфуллин, икенчесендә (1875 елда ачылганында) мулла Мөхәммәтзакир Минихуҗин укытуы күрсәтелгән. Ике мәктәпнең дә шәхси мәктәп булуы һәм рөхсәтсез яшәве, укытуның “Корьән кушуы буенча” алып барылуы язылган. Муллаларның “белем цензы” һәм укыту өчен рөхсәтләре булмавы, ләкин “дин нигезләрен өйрәтүне үзләренең бурычлары” дип санаганга бу эш белән шөгыльләнүләре әйтелгән. Ревизиянең 1911 елда, муллалар икесе дә белем алган атаклы Иж-Бубый мәдрәсәсе хөкүмәт тарафыннан ябылган һәм аның җитәкче һәм укытучыларының судка тартылган чорда узуын искә алыйк. Бу очракта Бәзәкә муллаларының үз белемнәрен һәм үз укыту ысулларын ни өчен тикшерүчәләрдән яшерүләре аңлашылса кирәк.

1914 елда Бәзәкәдә Алабуга өяз земствосы карары белән өч еллык рус-татар башлангыч мәктәбе ачылган. Мөселман мәктәпләре авыл җәмгыяте хисабына көн күрсә, бу мәктәп Бәзәкәдә земство тарафыннан тәэмин ителгән беренче мәктәп булган. Шуңа күрә ул авыл мәктәпләреннән шактый аерылып торган. Земство мәктәбе катнаш мәктәп саналган, ягъни анда малайлар белән бергә кызлар да укый алган. Мәктәптә парталар, класс тактасы, “аяклы счет”лар, уку әсбаблары кулланылган. Укыту земство башлангыч рус-татар мәктәпләре өчен эшләнгән махсус программа нигезендә төзелгән дәреслекләр ярдәмендә алып барылган. Төп укыту теле рус теле булган. Бу мәктәпкә ачылган көненнән йөри башлаган минем әти сөйләвенчә, эшләвенең беренче елында мәктәптә 10-15 бала гына укыган. Алар да бик озак вакыт рус милләтеннән булган учительницага күнегә алмый газапланганнар. Чөнки ул татар телен белмәсә, укучыларының рус телен аңлаулары да шул кадәр генә булган. Ләкин ике як та тырыша торгач, эш, акрынлап, рәтләнгән. Шулай тагын да көчлерәк үзгәрешләр алып киләчәк революция алдыннан Бәзәкәдә заманча мәктәп барлыкка килгән.

Егерменче гасыр башында авыл тормышы

Тормыш дигәннәре безгә бер дә
Колачларын җәеп тормаган, -
Безнең өчен беркем чәчмәгән дә
Безнең өчен беркем урмаган.

Роберт Миңнуллин

Унтугызынчы гасырда чишелмәгән икътисадый, сәяси-иҗтимагый, милли һәм башка проблемалары белән Русия яңа гасырга килеп кергән. Аларга нигезләнгән конфликтлар, күбәя барып, илне революцион үзгәрүләргә

китергән. Рус-япон сугышында зур Русия дәүләтенең күп кешене хәйран калдырган кечкенә Япониядән җиңелүе, 1905-1907 елгы революция, Дәүләт Думасының барлыкка килүе, эчке эшләр министры П.А.Столыпин исемен алган аграр реформа, Беренче бөтендөнья сугышы, нинаять, 1917 елгы революцияләр – XX гасыр башында Русиядә яки Русия катнашында булган мөһим вакыйгаларның кыскача исемлеге. Һичшиксез, бу вакыйгаларның һәрберсе турыдан-туры яки читләтеп кенә булса да күпмилләтле дәүләтнең барлык халыкларына да кагылган.

Башкалалардан һәм зур сәнәгать үзәкләреннән еракта булган Вятка губернасында, төгәлрәк булсак, аның Алабуга өязендә һәм Бәзәкә авылында яшәүче халык бу чорда ниләр белән мәшгуль булган соң?

Вятка губернасы авыл хуҗалыгы өлкәсе булып кала биргән. Алабуга өязендә эшләп килә торган химия заводлары шактый зур үсеш кичерсәләр дә, халыкның иң зур өлешен акрынлап базар мөнәсәбәтләренә тартыла барган крестьяннар тәшкил иткән. Моңа аларны нужа, мохтаҗлык, салым һәм недоимкалар түләү өчен кирәк булган акча юклыгы этәргән. Ягъни базарда товарлыклы икмәк сатуның үсеше авылда ашлык уңышы артуына бәйле булмаган. Үз хуҗалыкларын элеккечә, борынгыдан калган ысуллар белән алып барган крестьяннар, шуңа күрә хуҗалыкларының күбесендә уңыш артуы да булмаган. Шулай булгач, икмәкне һәм башка авыл хуҗалыгы продукциясен крестьяннар үз гаиләсеннән артып кала башлаганга базарга алып чыкканнар дип тә әйтеп булмый.

Авылларда элеккечә өч басулы чәчү әйләнеше хөкем сөргән. Галимнәр фикеренчә, әгәр дә басуларга җитәрлек дәрәҗәдә ашлама кертелсә, бу системаны кулланганда да, тотрыклы уңыш алып булыр иде. Ләкин һава шартлары гына түгел, илдәге сәяси, иҗтимагый-икътисадый һәм демографик халәт тә XIX гасырның икенче яртысында ук традицион системаның яшәешен уңайсыз шартларга куйган. “Өч басулы чәчү системасы кризисы” башланган: басуларда туфракның ярлылануы һәм уңдырышлылыгы кимү ашлык уңышлары кимүгә китергән. Үз кишәрлекләреннән җыйган уңышка гаиләсен туйдыра һәм салымнарын түли алмаган игенчеләр башка кәсеп эзләргә, һөнәрчелек, зимагурлык кебек эшләр белән шөгыльләнергә мәҗбүр булганнар. Вятка губернасы Алабуга өязе буенча 1899-1900 хуҗалык елына караган белешмә бу фикерләрне раслый.

Алабуга өязендәге барлык татар авыллары халкы кебек, бәзәкәлеләр дә үз кишәрлекләреннән тулысынча файдаланырга тырышканнар. Үз басуларында алар элеккечә, беренче чиратта, арыш белән солыга иң күп урын биргәннәр. Уҗым басуы, гадәти буларак, игенченең ярты җирен (ә кайчакта күбрәк тә) алып торган. Аңа тулысынча арыш чәчелгән. Бу өч басулык чәчү таләпләренә дә туры килгән. Корылык булган елларда да арыш башка игеннәргә караганда яхшырак уңыш биргән, салкыннарга да бирешмәгән, начар сыйфатлы һәм начар эшкәртелгән җирдә дә үскән. Вятка губернасында 1900 елда җыелган ашлыкның 53,9 % арышка туры килгән. Шул ук елда губерна чәчүлекләренең 35,8 %-ына солы чәчелгән булган. XIX - XX гасыр башында төбәктә солы чәчүлекләренең артуына, бер яктан, туфрак

уңдырышлылыгының аңа артык тәэсир итмәве булса, икенче яктан, капиталистик җитештерү үскән чорда җигүле транспортны куллану нык арткан. Үз чиратында, атлар өчен фуражның кирәклеге арту базарларда солыга кытлык тудырган һәм солы чәчүлекләренең киңәюенә китергән.

Арпа, борай, кара бодай, тары, борчак, ясмыкны игенчеләр әз-әзләп, үзләренә кирәк булган кадәр генә үстергәннәр. XX гасыр башында да авылларда (шул исәптән, Бәзәкәдә дә) сакланып килгән ярымнатураль хуҗалыкларда җитен һәм киндер үстерү дә дәвам иткән. Дөрес, авылга “фабричный” тукымалар (ситсы, сатин һ.б.) үтеп керү аларның хуҗалыктагы ролен киметкән. Ләкин әле киемнәрнең күпчелеге дә өйдә тукылган җитен-киндер тукымалардан булган, хуҗалыкта да җитен-киндер сүсе үз урынын саклаган.

Крестьян хуҗалыгына бар нәрсә дә йогынты ясаган. Иген уңышы турыдан-туры табигать шартларына бәйле булган. Өяздә уңышсыз 1899-елга алмашка шактый яхшы уңышлы 1900-ел килгән. Ләкин 1901-елда Идел-Урал төбәгенең 17 губернасында, шул исәптән, Вятка губернасында да, иген тагын уңмаган. Ягъни XX гасыр башында да илдә 1861 елгы крестьян реформасыннан соңгы елларга хас булган, һәр 6-7 ел саен кабатланып килгән хәл – кытлык еллары сакланып калган. Гадәти буларак, кытлык еллар ике ел рәттән килгән. Ә кытлыктан соң эштән чыккан хуҗалыкны торгызыр өчен вакыт һәм акча кирәк булган.

Игенчелек кебек үк авыл тормышы өчен мөһим булган терлекчелекнең хәле шулай ук тотрыклы булмаган. Корылык һәм ачлык елларында терлек саны кискен кимегән. Бу чор авыл халкы өчен авыр сынауга әверелгән. Кыш көне терлек, азык җитмәү сәбәпле хәлсезләнеп, күтәрәмгә калган. Терлек азыгы беткәч, крестьяннар вак терлекләрен дә, мөгезле эре терлекне дә, хәтта атларын да сатканнар. Корылыктан соң терлек санын тергезү өчен күп акча һәм вакыт кирәк булган. Губерна һәм өяздә XIX гасырның соңгы чирегендә кулланыышта булган Казах далаларыннан ат кайтарту, атсыз хуҗалыкларга аларны арзан бәягә сату (еш кына, ссуда бүлеп биреп) алымыннан XX гасыр башында да файдаланганнар. Корылык, ачлык нәтиҗәләрен ярлы һәм урта хәлле хуҗалыклар земство һәм хөкүмәт оешмаларыннан акча, азык-төлек һәм чәчү орлыгыннан гыйбарәт ссуда алып кына җиңеп чыга алганнар.

Салым түләү, хөкүмәткә һәм байларга (хәлле кешеләргә) булган бурычларны кайтару зарурилыгы, кыш көннәрендә терлекләрне ашатыр өчен азык җитмәве көз көне күпләп терлек сатуга һәм яз көне, киресенчә, сатып алуга сәбәп булган. Терлекчелек продукциясе, нигездә, гаиләне тукландыру һәм киендерү өчен кулланылган. Йорт хайваннары һәм кош-корт гаиләне ит, сөт, йомырка белән тәэмин иткән, һөнәрчелек һәм йорт кирәк-яраклары өчен чимал (тире, йон, каз мамыгы, сөяк һ.б.) биргән. Ат һәм үгезләр йөк ташу, җир сөрү һәм авыл хуҗалыгындагы башка эшләрне башкару өчен файдаланылган. Терлек асрау игенчеләргә басуларын ашлау өчен тирес биргән. Терлекчелектән кергән продукциянең күпмедер өлеше базарларда да сатылган. Шәһәр халкы саны үсә барган саен терлекчелек продукциясенә ихтыяҗ арта барган...

Русиядә 1905 ел тарихта “Канлы якшәмбе” исемен алган 9 гыйнвар вакыйгаларыннан башланып киткән. Ике башкала һәм университет үзәкләрендә митинг-демонстрацияләр гөжләгән. Завод-фабрикалары күп булган зур шәһәрләрдә эшчеләрнең чуалышлары башланган, Милли хәрәкәт җанланган. Идел Буе һәм көньяк губерналарда крестьяннар хәрәкәткә килгән. Бу вакыйгалар барысы да илдә башланган беренче революциянең күренешләре булган. Ләкин Алабуга өязе, нигездә, көндәлек тормышы белән яшәвен дәвам иткән (хәер, бөтен провинциаль Русиядә шул ук хәл күзәтелгән диярга мөмкин). Революция елларында төбәк халкының пассив булуын, мөгаен, өяздә зур алпавыт утарлары булмау белән аңлатып була торгандыр, ягъни крестьяннарның төп таләбе булган “Крестьяннарга җир!” лозунгын кую өчен шартлар булмаган. Моны өяз исправнигының 1906 елның 27 февральдә язылган рапортыннан да күреп була. “Крестьян халкының күбесе реформаларны ваемсыз кабул итте; реформадан алар бары тик җир өстәлүне һәм җир өчен түләнә торган салымнарның бер өлешен киметүне генә көтә”, - дип күрсәткән ул. Хәер, Алабуганың үзендә дә 1905 елда шәһәр театры бинасында бер генә митинг булуын искәрткән инспектор.

Вятка губернаторының 1905 елгы отчетына Алабуга өязенең земство идарәсе хәзерләгән мәгълүматларда һава торышының иген үсешендәге роленә зур игътибар бирелгән. “Төп азык икмәге саналган арыш өчен отчет елы, алдагы 1904 ел белән чагыштырганда, уңышсыз булды. Ә сабан ашлыгы һәм бигрәк тә печән өчен отчет елы уңышлы булды дип әйтеп була, - дип күрсәтелгән бу белешмәдә. – […] Арышны чәчүгә һәм уҗымның үсүенә көзге салкын җилле-яңгырлы һава комачаулады. Кар төшкәнче туфрак туңып каткан иде. Кыш күпкарлы, уртача булды; ә яз, соңгарак калса да, бик дәррәү килде. Кар 15 апрельгә эреп бетте”. Өяздә сабан ашлыкларын чәчүнең вакыты да (солыны 27 апрельдә, арпаны 1 майда чәчә башлаганнар), игеннәрне җыю вакыты да (арышны 24 июнь – 5 август аралыгында, сабан ашлыкларын – 6 – 26 августта уруга керешкәннәр) төгәл күрсәтелгән. Шулай ук язның салкын килүе арышның үсүен акрынайтуы да, урып-җыю чорында яңгырларның күп булуы да искә алынган.

Шул ук 1905 елгы отчет өчен губерна статистик комитеты хәзерләгән мәгълүматларда Алабуга өязендә 1905 елда җыелган уңыш хакында да язылган. Уңыш үлчәме “сам”нарда бирелгән: арыш – сам 4,8; солы – 5,5; бодай – 4,8; арпа – 8,3; карабодай - 4,3; бәрәңге – 8,8; җитен – 4.8; киндер – сам 4.3 булган. Бу саннар Алабуга өязендә уңышның уртача булуын күрсәтә. Эшче көчләрнең 1905 елдагы көнлек кыр эшләрендәге уртача бәясе дә күрсәтелгән: атлы көнлекчегә 0,9-1 сум, атсызга – 45-55 тиен, хатын-кызга – 35-40 тиен түләнгән. Ашлык бәяләренең ел фасылларына бәйле булуы хакында да мәгълүмат бирелгән. Мәсәлән, игеннәрне урып-җыю тәмамлангач ук сатканда, арышның поты 40 тиен, арыш оны - 45,5 тиен, солы – 30 тиен торган; кыш көне шулар ук 54, 60 һәм 65 тиен; җәй башында бәяләр 58, 65 һәм 37 тиенгә җиткән. Йорт хайваннарының өяз буенча бәясе: ат уртача 43 сум 76 тиен, сыер – 24 сум 95 тиен, сарык – 3 сум 10 тиен торган. Салагыш

волостендә бәяләр үзгәрәк булган: ат бәясе 30 сумнан 40 сумга кадәр, сыер 18-25 сум, сарык 2-5 сум булган.

Бу вакытта Бәзәкәдә эшләр ничек барган соң? Алабуга өязенең 1905 елгы торак урыннары исемлегендә Бәзәкәдә 367 хуҗалык күрсәтелгән. Бу хуҗалыкларда барлыгы 1066 ир-ат һәм 1028 хатын-кыз яшәгән. Җәмгыять биләмәсендә 2986 дисәтинә җир булган, ягъни бер хуҗалыкка 8,16 дисәтинә туры килгән. Авылда хуҗалык саны арта барган саен кишәрлекләрнең күләме дә кими баруын күрәбез. Бу күләмгә басу-чәчүлекләрдән тыш болын-әрәмәләр, чокыр-чакырлар, сазлыклар һәм күлләр дә керүен искә төшерү кирәктер. Болай да җитмәгән басу-чәчүлекләрнең туфрагы ярлылануы табигый уңышның кимүенә китергән. Бәзәкәләләр никадәр тырышып эшләсәләр дә, өстәмә керемсез үз гаиләләренә җитәрлек тә уңыш ала алмаганнар.

Авыл халкы элеккечә таныш кәсепләре белән шөгыльләнгән, Ушков заводлары өчен кәрҗин үргән, йөк ташыган. Ушковлар яңа цехлар ачканнар, товар җитештерүләрен арттыра барганнар. 1905 елда Бондюг заводында инде 1294 эшче, ә Кокшан заводында 450 кеше эшләгән, аларның беренчесе 1758607 сумлык, икенчесе 637650 сумлык продукция җитештергән. XX гасыр башында бу заводларда ялланып эшләүче бәзәкәләләр саны да арта барган. Алар инде көнлекче - йөк ташучылар булып кына түгел, даими эшкә дә урнаша башлаганнар, бигрәк тә авылдан 10-12 чакрым ераклыкта гына булган һәм тизрәк киңәйгән Бондюг заводына.

Өстәмә керем бәзәкәләләргә һаман үсә барган салымнарны түләр өчен дә кирәк булган. Элеккечә алар авылдашлар арасында чиратлап һәм тигез бүленеп эшли торган йөкләмәләрне дә башкарганнар. XX гасыр башында бу йөкләмәләр арасында мәҗбүри булганнарын атап үтим: 1) волость һәм авыл идарәләренең күптөрле йомышларын үтәү; 2) волость һәм авыл идарәләре хезмәткәрләренә хезмәтләрен үтәү өчен кирәк булганда, олаулар бирү; 3) авыл аркылы узучы солдатлар һәм яңа гына армиягә алынганнар төркемнәренә, шулай ук чиновникларга фатир бирү; 4) юлларны төзәтү, күперләр һәм түшәмә юллар төзү, күперләрне һәм кичүләрне рәттә тоту; 5)җәмгыять карамагында булган запас икмәк магазиннарын һәм авылны янгыннардан саклау, тоткыннарны өяз чикләренә кадәр озату, мәетләрне һәм җинаять эзләрен саклау. Бу йөкләмәләр арасында иң авыры булып юл йөкләмәсе саналган; шулай ук беренче һәм икенче төркемгә кергәннәре дә вакыт таләп итүе белән бергә күп мәшәкатьләр дә китергән (бигрәк тә аларны кызу эш өстендә башкарырга туры килгәндә).

XX гасыр башында Вятка губернасында авыл хуҗалыгы обзорлары басыла башлаган. Күләме зур булмаган бу китапчыкларда өязләр буенча статистика материаллары, һава торышы, ашлык басуларының хәле һәм башка мәгълүматлар даими биреп барылган. Менә Алабуга өязендә 1913 елның 25 июненә булган икмәк һәм үләннәр хәленең тасвирламасыннан өзек: “Май уртасыннан башлап бүгенгә кадәр барган яңгырлар туфракта кирәгеннән артык юешлеккә китерде. Кайбер җирләрдә яңгыр һәм боз явып уҗымга зыян килде. Шулай ук сабан ашлыгына да; көчле яңгырларның нәтиҗәсе – чүп

басу. Арыш өяз буенча уртача 30 майда баш чыгара башлады (5 майдан 3 июнь аралыгында). Бу араның зурлыгының сәбәбе – күп җирләрдә арыш кар астыннан бик начар – сирәк булып чыкты, көчле яңгырлар аркасында гына, майның икенче яртысыннан башлап, көчле тармакланып китте һәм начардан яхшыга әйләнде. Һәм бу арыш соңрак баш чыгара һәм серкә очыра башлады. Өяз буенча уртача алганда, арышның серкә очыруы 15 июньнән башланды (1 июньнән 3 июльгә кадәр); монда да шул ук сәбәп: туктамыйча яуган яңгырлар арышның серкә очыруын һәм өлгерүен дә тоткарлады".

Обзорларда аерым Салагыш волосте буенча да мәгълүмат бар. Мәсәлән, шул ук елда, дүрт баллы системадан чыгып, уҗым чәчүлекләренең торышы бәяләнгән (2.0 – начар, 3.0 – урта, 3.2 – уртадан югары, 3.5 – яхшы). Кар астына кергәндә, уҗымнарның хәле волостьтә 4.0 балл, өяздә – 3.0 балл җыйган; кар астыннан чыкканда волостьтә дә, өяздә дә уртача – 3.0 балл бирелгән; 1 июньгә хәл шундый ук калган; 25 июньгә волостьтә – 3.5, өяздә – 3.6 баллга бәяләнгән. Сабан ашлыкларның хәлен таблицадан белик.

Таблица № 5

Салагыш волостендә сабан ашлыкларының хәле

	солы	арпа	бәрәңге	бодай	борай	борчак	карабодай
1 июньгә	3.3	3.3	3.8	3.3	3.3	3.3	3.5
25 июньгә	3.5	3.8	3.5	2.8	3.8	3.8	4.0

Сабан ашлыкларының (бодайдан кала) хәле яхшы якка үзгәрә баруын күрсәтеп, статистиклар: "Бу вакыт эчендә үләннәрнең хәле дә шулай ук яхшырды, сазлыктагы печәнлекләрдән башка, чөнки юешлек күп булганда, мондагы үләннәрнең сыйфаты да начарлана, күләме дә кими, ә коры елларда – киресенчә", - дип язып куйганнар.

Алабуга өязендә 1912-1917 елларда ашлык уңышының динамикасын күрсәткән тагын ике таблицага игътибар итик; аның беренчесендә 1 дисәтинәдән җыелган уңыш потларда, икенчесендә – "сам"нарда бирелгән.

Таблица № 6

Алабуга өязендә 1912 – 1917 елларда ашлык уңышы (1 дисәтинәдән потларда)

	1912	1913	1914	1915	1916	1912-16с	1917	1912-17
арыш	89	72	48	64	54	67	43	63
солы	69	55	51	59	56	57	30	53
арпа	87	78	72	73	53	61	31	56
бодай	11	55	67	56	39	46	29	43
борай	18	68	65	68	44	53	50	51
карабодай	41	23	11	27	1	23	13	21
борчак	28	29	13	19	20	22	14	20
киндер	22	22	15	30	16	21	19	21
бәрәңге	360	372	312	324	306	326	378	342

Таблица № 7

Алабуга өязендә 1912 – 1917 елларда ашлык уңышы (1 дисәтинәдән “сам”нарда)

	1912	1913	1914	1915	1916	1912-16	1917	1912-17
арыш	9.4	7.6	5.5	6.7	5.7	7.0	4.5	6.6
солы	5.3	4.2	3.3	4.5	4.3	4.4	2.3	4.1
арпа	2.7	7.8	7.2	7.3	5.3	6.1	3.1	5.6
бодай	1.1	5.5	6.7	5.6	3.9	4.6	2.9	4.3
борай	1.4	5.4	5.2	5.4	3.5	4.2	4.0	4.1
җитен	3.4	4.0	1.8	3.3	1.7	2.8	1.4	2.6
карабодай	9.1	5.2	2.4	5.9	2.5	5.0	2.8	4.7
борчак	4.7	4.8	2.2	3.1	3.3	3.6	2.3	3.4
киндер	2.7	2.7	1.9	3.7	2.0	2.6	2.4	2.6
бәрәңге	6.0	6.2	5.2	5.4	5.1	5.6	6.3	5.7

Печән уңышы: Алабуга өязендә бу елларда су баса торган болыннардан уртача бер дисәтинәдән 107 пот, коры җирдәге болыннардан – 61 пот, сазлыктагы болыннардан 53 пот печән җыйганнар; губерна буенча бу саннар 93, 47 һәм 4 пот тәшкил иткән.

Күргәнебезчә, XIX гасырның икенче яртысы белән чагыштырганда, уңыш коэффициенты төрле культураларда 2.6 “сам”нан 6.6 “сам”га кадәр җитсә дә, уртача 4.6 “сам”ны тәшкил иткән, ягъни уңыш үсеше зур булган дип әйтеп булмый. Уртача күрсәткеч 4.6 “сам” булганда, аның гаиләне ашату, чәчү һәм салымнар түләүгә генә җитүе хакында сүз барган иде иде. Димәк, җитештерү шартлары элеккечә саклганда, өяздә җитәрлек кадәр товарлыклы икмәк җитештереп булмавын да күрсәтә бу саннар. Шулай да, революция алдыннан килгән биш елда уңыш җыю динамикасының уңай булуын күзәтеп була. Моны бигрәк тә арыш, арпа, карабодай, бәрәңге уңышлары күрсәтә. Уңышның һава шартларына бәйлелеге хакында да әйтеп була. Бу яктан 1912 ел бик кызыклы нәтиҗә биргән: арыш, карабодай, бәрәңге рекордлы уңыш бирсә, сабан ашлыгының уңышы шул ук вакытта бик түбән булган. 1916 елның уңышы түбән булуын, мөгаен, сугыш чоры булу белән аңлатып була торгандыр. Революцион 1917 елда, илнең хуҗалыгы таркалуы, эшче кулларның һәм атларның җитмәве тагын да ныграк сизелгән елда, эшләрнең тагын да начараюын күрәбез.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында патша хөкүмәте илдәге азык-төлек өлкәсендәге хәлне тәртипкә салырга кирәклегенә төшенә башлаган. Бу өлкә өчен җаваплы орган (ул Махсус совещание исемен йөрткән) карары буенча, авыл хуҗалыгы министрлыгы 1916 елда беренче Бөтенрусия авыл хуҗалыгы переписен уздырырга булган. Авыл хуҗалыгы хәлен белү максаты белән Русия статистикасы патша заманында уздырган бу иң масштаблы чараларның берсе 1916 елның май-июлендә 77 губерна һәм өлкәдә үткәрелгән. Ләкин аның нәтиҗәләре билгеле булганчы, илдә Февраль революциясе башланып, патша хөкүмәте бәреп төшерелгән, 300 ел дәвамында ил белән идарә иткән Романовлар династиясе юкка чыккан.

1917 елның февралендә дәүләт җитәкчелегенә килгән Вакытлы хөкүмәт алдына чишелергә тиешле бик күп мәсьәләләр арасында халыкны азык-төлек белән тәэмин итү проблемасы да булган. Көн тәртибендә торган аграр реформаны үткәрү өчен җир биләүчеләр һәм җир кулланышы хакында төгәл мәгълүмат кирәк булган кебек, илдә катлауланган азык-төлек мәсьәләсен чишү өчен 1916 елгы авыл хуҗалыгы переписен яңарту таләп ителгән. Переписьнең яңа программасы Мәскәүдә 1917 елның 18-21 апрелендә узган земство статистикларының Бөтенрусия съездында расланган. Якынлашып килә торган азык-төлек фаҗигасы Вакытлы хөкүмәтне яңа авыл хуҗалыгы переписен 1917 елның җәендә үк уздырырга этәргән.

Икенче Бөтенрусия авыл хуҗалыгы переписе крестьяннар өчен иң кызу эш өсте булган май-апрель айларында уздырылган. Анда хуҗалыклар саны, гаилә составы, мал-туарның төрләре һәм саны, чәчүлекләрнең күләме, аларның бөртеклеләрнең төрләренә карап бүленеше, файдаланышта булган җир-сулар, авыл-хуҗалыгы инвентаренең төрләре кебек мәгълүмат җыелган. Перепись материаллары (57 губерна буенча өязләп саналган нәтиҗәләре) 1923 елда, совет чорында, басылган. Ул җыентыкның керешендә материалның тулы булмавы 1917 елның җәендә барлык губерналарда да аграр хәрәкәтнең көчле булуы белән аңлатылган, кайбер төбәкләрдә халыкның переписьтә катнашудан тулысынча баш тартулары әйтелгән.

Илдә хәлнең бик катлаулы булуына карамастан (1917 елгы революцияләр, гражданнар сугышы һәм аннан соңгы вакыйгалар), җирле архивларда бу переписькә караган күп кенә материаллар, шул исәптән, хуҗалык саен тутырылган бланклар сакланган. Бу кәгазьләрне Русия тарихында зур борылыш чорында авыл хәлләрен тасвирлаган бәя биреп бетермәслек байлык дип билгеләргә кирәк. Бәзәкә авылы материаллары Татарстан милли архивында сакланган. Алар 462 хуҗалыкта хуҗалык саен сораштырып аерым-аерым тутырылган махсус сорау кәгазьләреннән һәм гомуми нәтиҗә чыгарган 11 йомгаклау бланкларыннан гыйбарәт. Бу материалларны җентекләп өйрәнү аның уникаль чыганак булуын күрсәтте. Материалларның тулы булмавын да әйтергә кирәк: берничә дистә (40 чамасы) сорау кәгазьләре һәм 1 йомгаклау бланкының, ни сәбәпледер, юкка чыкканлыгы ачыкланды. Шулай булса да, бу чыганак нигезендә без авылның 1917 елның көзенә булган халәтен тулысынча тасвирлый алабыз.

Документларның беренче төркеме - сорау кәгазьләре (опросный лист) – конкрет хуҗалыктагы гаилә хакында мәгълүмат бирә. Йорт хуҗасы – гаилә башлыгы хакында исеме, атасының исеме (фамилиясе) һәм яше бирелгән, ә гаилә әгъзалары хакында гаилә башлыгына карата туганлык билгесе һәм яше генә күрсәтелгән. Хуҗалыктагы җирнең күләме (имана саны), йорт хайваннарының төрләре һәм саны, чәчелгән бөртеклеләрнең төрләре һәм күләме (потлап) язылып алынган. Моннан тыш, кайбер кәгазьләрдә өстәмә шөгыльләр, аренда (алу һәм бирү), армиягә чакырылган һәм хәрби заводларга эшкә алынганнар хакында мәгълүмат та очрый.

Барлыгы 462 хуҗалыкның сорау кәгазъләре сакланган. Аларның икесендә хуҗаның исем-фамилиясе генә күрсәтелеп, мәгълүмат бирүдән баш

тартты дип язылган. 16 кәгазьдә шулай ук мәгълүмат бирелмәгән, чөнки бу йортларның хуҗалары бу вакытта авылда булмаган. 452 хуҗалыкта Бәзәкә авылы җәмгыятен тәшкил итүчеләр яшәгән, 10 хуҗалыкта читтән килгән гаиләләр көн күргән. Алар арасына үз гаиләләре белән Бәзәкәдә яшәүче мулла-мөәзиннәр, кибет тотучылар, тегүче һәм тимерче кергән. Алар игенчелек белән шөгыльләнмәгән, чөнки имана җирләре булмаган. 16 хуҗалыкта гаилә башлыгы итеп хатын-кызлар күрсәтелгән, кагыйдә буларак, бу кечкенә балалары булган тол хатыннар. Кайбер кәгазьләрдә хәрби хезмәттә сугышта булучылар (11 кеше), Бондюг, Ижау һәм Кокшан заводларында учетта торучылар (13 кеше) күрсәтелгән; шулай ук “корт каравылчысы”, “балыкчы”, “балык сатучы”, “кара эштә”, “алыпсатар” кебек язмалар да очрый (Кушымта № 15).

Йорт хайваннарының төрләре һәм саны, чәчелгән бөртеклеләрнең күләме һәм төрләре хакындагы мәгълүмат авыл тормышын тасвирлаучы иң кызыклы материал булып тора. Чәчүлекләрдән башлыйк. Бәзәкә биләмәсе авыл җәмгыятенең үз милке булуын искә алыйк. Бәзәкәлеләр җирдән иманаларга бүлеп файдаланганнар. Салым һәм башка җыемнарны да имана саныннан чыгып бүлгәннәр. Имана (русча “разверсточная единица”) – җир бүлгәндә, бер җан башына туры килгән җир күләме; авыл җәмгыятендә булган җаннарның саны соңгы ревизиядәге ир-ат саныннан, авылда яшәүчеләр яки эшче куллардан чыгып (бу очракта 1 ир-ат һәм 1 хатын-кыз бер җанны тәшкил иткән) алынган. Бәзәкәдә, авыл җәмгыятен 1866 елда “окладка утыртканда” исемлеккә кертелгән 1858 елгы ревизиядәге ир-ат саныннан чыгып, хуҗалыкларга бүленгән имана саны 1917 елга да сакланган булырга тиеш.

Бәзәкә хуҗалыкларында бер иманадан җиде иманага кадәр булган. Бер иманалы хуҗалыклар – 119, ике иманалы – 146, өч иманалы – 99, дүрт иманалы – 39, биш иманалы – 28, алты иманалы – 10 хуҗалык булган. Җиде имана бер генә хуҗалыкта булган. Аның башлыгы – 34 яшьлек Хикмәтулла Әлмөхәммәтов саналган; хуҗалыкта аның белән бергә 24 яшьлек хатыны, 3,5 яшьлек кызы һәм ике өйләнмәгән 30 һәм 20 яшьлек энеләре язылган. Хуҗаның ике энесе өйләнеп, аерым хуҗалык белән яши башласалар, иманалар да бүленәчәге аңлашыла. Хәер, бу хуҗалык, җире күп булса да, бай булган дип әйтә алмыйбыз; хуҗалыкта бер ат, бер сыер һәм бәтие белән бер сарык булган, ике ярым имана җирендә 15 пот арыш һәм 20 пот солы чәчелгән, калган дүрт ярым имана өч кешегә арендага бирелгән.

Җир арендасы хакында. Авылда арендага өстәмә чәчүлекләрне 17 хуҗалык алган (0,4 иманадан 4 иманага кадәр). Арендага җирне күбрәк үз туганнарыннан яки авылдан китеп яшәгән күршеләреннән ала торган булганнар. Иманаларын арендага бирүче хуҗалыклар да 17 булган. 27 хуҗалык иген чәчмәгән (аларның күбесе иманасын арендага биргән). Сәбәбе – эшче куллар яки “симәнә” - орлык булмау. Чәчүлекләр хакындагы мәгълүматны өйрәнгәндә күзгә ташланганы – хуҗалыкларның яртысында диярлек (203 хуҗалыкта) ике генә культура - арыш һәм солы гына чәчелгән. Хуҗалыкта бер имана булган очракта, кагыйдә буларак, биш пот арыш һәм

алты ярым пот солы чәчкәннәр. Башка бөртеклеләрне – бодай, арпа, борай, карабодай, борчак, җитен, киндерне бик аз чәчкәннәр. Аларның барысы да бары тик бер хуҗалыкта - Кәлимулла Нигъмәтуллин хуҗалыгында гына чәчелгән.

Бу хуҗалык хакында мәгълүмат. Хуҗаның үзенә 60 яшь, хатынына 55 яшь булган. Алар белән 35, 29, 25, 19 һәм 10 яшьлек биш улы һәм 19, 17 һәм 16 яшьлек өч кызы яшәгән. Ике өлкән уллары өйләнгән, киленнәр 33 һәм 29 яшьлек; ике яшь гаиләгә өч бала күрсәтелгән (7 һәм 5 яшьлек малайлар һәм 6 яшьлек кыз бала). Шулай итеп хуҗалыкта 15 кеше – 8 ир-ат һәм 7 хатын-кыз яшәгән. Икенче улының Бондюг заводында эшләгәнлеге әйтелгән. Кәлимулла Нигъмәтуллин хуҗалыгында 8 ат, 3 сыер, 2 бозау, 12 сарык тоткан. Аның 5 имана җире булган, тагын 3 имана җирен ул арендага алган. Бу җирләрдә 43 пот арыш, 45 пот солы, 5 пот бодай, 13 пот арпа, 6 пот борай, 2 пот борчак, ярты пот җитен һәм 0,1 пот киндер чәчелгән. Барлык бу мәгълүмат хуҗалыкның аягында нык торуын, гаилә әгъзаларының эшчән булуын күрсәтә. Эшче кулларны читтән яллау хакында бер нәрсә дә әйтелмәгән, барлык эшне үзләре башкарган дип уйларга була. Ләкин бу хуҗалыкта игенне ашарга гына түгел, сатарга да, ягъни товарлыклы ашлык та үстергәннәрдер дип уйлау урынлы. Ә атлар саны гаиләдәге ир-атлар, өстәмә керем булдыру өчен, олаучылык белән дә шөгыльләнгәннәрдер дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Тагын ике хуҗалыкка игътибар итик. 1) 30 яшьлек Хикмәтулла Сәлимуллин хуҗалыгы – 5 кешедән гыйбарәт гаилә: 26 яшьлек энесе, 3 яшьлек улы, 23 яшьлек хатыны һәм 28 яшьлек килене; хуҗалыкта 2 ат, 1 сыер, 2 бозау, 8 сарык; 2 имана җирдә 10 пот арыш һәм 13 пот солы чәчелгән. Имана җирләренең 1,9 дисәтинәсе чәчелгән басу, 1,2 дисәтинә парга калдырылган булуы күрсәтелгән.

2) 60 яшьлек Гайнетдин Әхмәдьянов хуҗалыгы – гаиләсе шулай ук 5 кешедән: 55 яшьлек хатыны, 20 һәм 29 яшьлек ике улы һәм 18 яшьлек кызы. Хуҗалыкта 2 ат, 1 сыер, 6 сарык, 6 имана җир. Аның 5,9 дисәтинәсендә утызар пот арыш һәм солы, 2 пот бодай, 6 пот борай чәчелгән. 3,6 дисәтинәсе парга калдырылган.

Күргәнебезчә, ике хуҗалык та гаиләдәге эшче куллар һәм күчмә мал буенча тәңгәлләшәләр дип әйтә алабыз. Ләкин икенче хуҗалыкта җир өчләтә артыграк. Бу факт безгә, бу хуҗалык товарлыклы икмәк җитештереп, базар өчен эшләгән дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә; шул ук вакытта, беренче хуҗалык җирләреннән җыелган уңыш үз хуҗалыгындагы чыгымнарга гына җиткән булырга тиеш дип уйларга кала.

Безнең бабабыз хуҗалыгы хакында сөйләп китим: 45 яшьлек Ибраһимов Мәхмүт гаиләсендә 40 яшьлек хатыны, 17, 16 һәм 13 яшьлек өч улы, 12 һәм 8 яшьлек ике кызы күрсәтелгән. Барысының да укый-яза белгәнлеге язылган. Бабабызның хуҗалыгында 2 ат, 1 сыер, 2 бәтие белән 4 сарык һәм кәҗә булган. Өч имана җиренең 2,9 дисәтинәсендә 15 пот арыш, 14 пот солы һәм 5 пот бодай чәчелгән, 1,8 дисәтинәсе парга калдырылган. Бабабызның каеш-күн, дирбия товары белән сату итүе дә күрсәтелгән.

Хуҗалыкта товарны саклар өчен төзелгән ике таш келәт тә булган. Хуҗалыктагы барлык мал Мәхмүт бабай тырышлыгы нәтиҗәсе булганын ассызыклыйм. Бабабызның әтисе, Ибраһим бабай 1891 елгы ачлык вакытында атын да югалткан, хатыны белән үсмер улын да, фәкыйрьлектә калдырып, әллә тифтан, әллә ачлыктан вафат булган. Мәхмүт мөстәкыйль тормыш башлаганда, аларның бары тик гади дүрт почмаклы йорты һәм имана җирләре генә булган. 1898 елда әнисе Мәфтүха әби Мәхмүтне авылдашы Зәйнулла Хисмәтулла улының Шәмсекамал исемле кызына өйләндергән. Күрәсең, Мәхмүт бик тырыш һәм эшчән егет булгандыр. Акрынлап Мәхмүтнең хуҗалыгы аякка баскан: ул атлы-сыерлы булган, кыр эшләреннән бушаган арада тире, күннән эшләнгән товар (сбруй-дирбия, чүәк-читек һ.б.) сатып алып, аны күрше авылларда һәм базарларда сата башлаган. Баштарак бу товарларны үзе эшләп тә сатып караган, ләкин ерактагы авылларда очсызрак бәягә товар сатып алып, аны базарларда сату төшемлерәк булуын аңлап алган. Әтиебез бабайның Минзәлә, Алабуга ярминкәләрендә сату иткәнен, берничә тапкыр, авылдашлары белән бергә сату эше белән ерак Мәкәржәгә дә барып җитүен сөйли иде. Димәк, бабабызның үткенлеге, үҗәтлеге, өлгерлеге дә җитәрлек булган. Кыскасы, 1917 елга бабабыз аягында нык тора торган урта хәлле крестьян булган дип әйтеп була.

Тагын бер нәселдәге хәлләргә игътибар итик әле. Сүз XIX гасыр башында йорт старшинасы булган, үзенең хезмәте белән шәхси дворянлык алуга ирешкән Зәйнебәшар Шоңкаровның дәвамчылары хакында. XIX гасыр азагында Бәзәкәдә иң зур байлардан саналган аның оныгы Гыйлмебәшар Шоңкаров турында инде сөйләнгән иде. 1898 елда нык хуҗалыгын, ике хатынын һәм иң олысы 17 яшенә җитеп килгән алты улын калдырып, ул кинәт кенә үлеп киткән. 1917 елгы язмаларда Гыйлмебәшар малайлары хакында нинди мәгълүмат бирелгән икән? Гыйлмебәшар утары урынына без дүрт аерым хуҗалык күрәбез:

1) 33 яшьлек Гомәр Шоңкаров гаиләсендә 35 яшьлек хатыны, 5 һәм 2 яшьлек ике улы һәм 14, 12, 10 һәм 8 яшьлек дүрт кызы язылган. Аның хуҗалыгында бернинди мал да күрсәтелмәгән, бер имана җирендә 5 пот арыш һәм 6,5 пот солы чәчелгәне күрсәтелгән.

2) Икенче хуҗалыкта 28 яшьлек Госман Шоңкаров һңм аның 60 яшьлек әнисе яшәгән. Бу хуҗалыкның малы нәкъ беренче хуҗалыктагы кебек, бары тик көн саен ашарга сораучы балалар гына юк.

3) 30 яшьлек Мулланур Шоңкаров хуҗалыгында 19 яшьлек хатыны, Минзәлә өязендә фельдшер булып эшләүче 26 яшьлек энесе (Мирсәетгали булырга тиеш) һәм аның 20 яшьлек хатыны язылган. Аларның ике имана җирендә 10 пот арыш һәм 13 пот солы чәчелгән. Мулланурның Иж заводында учетта торуы күрсәтелгән (күрәсең, ул шунда эшләгәндер дә).

4) 22 яшьлек Шоңкар Гыйлмебәшаров һәм аның 19 яшьлек энесе (Зиннур) хуҗалыгында шулай ук ике имана күрсәтелгән. Алар иманаларын мулла Рәфагетдин Хәлимовка салым хакына арендага биргәннәр, ягъни Рәфагетдин хәзрәт алар өстенә төшкән салымнарны түләп барырга тиеш

булган. Җирләреннән “котылган” туганнар авылдан да чыгып киткән. Шоңкарның Иж заводында учетта торуы күрсәтелгән, Зиннур хакында “авылда юк” дип язылган.

Шулай итеп, Гыйлмебәшарның хатын-кыз һәм бала-чага кулына калган легендар байлыгыннан 1917 елга алты малае арасында бүленгән имана җире һәм, мөгаен, йортлары гына калган. Авылда иң байлардан булган хуҗалыкның бөлгенлеккә төшүенең сәбәбе хуҗасының үлеме һәм көчле хуҗалыкның бүленгәнлеге генә булганмы, аңа башка сәбәпләр дә өстәлгәнме, безгә билгесез. Ләкин мөстәкыйль юлга кереп китәргә мәҗбүр булган балалары авылның мал-туары булмаган иң ярлылар арасына кергәнлеген күрәбез. Бу нәселнең язмышы, минем фикеремчә, авыл халкы тормышының тотрыклы булуы өчен бик күп шартларның бергә туры килүе кирәклегенең ачык мисалы булып тора.

1917 елгы переписьнең икенче төркем документларына күчик. Бу хуҗалыклардан алынган мәгълүматның йомгаклары беркетелгән махсус бланклар. Авыл якынча кырыгар хуҗалыктан торган 12 төркемгә бүленгән булырга тиеш. Унбер бланк сакланган, сигезенче номер астындагысы безгә килеп җитмәгән. Бланкларда төркемдәге халыкның саны һәм составы, йорт хайваннарының саны һәм төрләре, чәчүлек җирләренең чәчелгән ашлык төрләре буенча күләменең җыелма мәгълүматы китерелгән.

Сакланган 11 бланкны бер таблицага җыйгач (Кушымта № 16) түбәндәге картина килеп чыкты. Бланкларга 428 хуҗалык кергән (сорау алу кәгазьләренең 462 булуын, анда да берничә хуҗалыкның булмавын искә төшерик). Аларда язган вакытта авылда булган 1071 (380 эшкә яраклы, 170 эшкә яртылаш яраклы) ир-ат күрсәтелгән; мобилизацияләнгән 159, башка сәбәпләр белән авылда булмаган 38 ир-ат күрсәтелгән. 1119 хатын-кызның барысы да авылда яшәгән (545 эшкә яраклы, 134 эшкә яртылаш яраклы булган). Шулай итеп, мәгълүмат җыйган вакытта авылда 2190 кеше булган. Хуҗалыкларда эшкә яраклы ир-атларның бүленеше – 113 хуҗалыкта эшләүче ир-атлар бөтенләй булмаган, бер ир-атлы 250 хуҗалык, икешәр ир-атлы – 55, өчәр ир-атлы 10 хуҗалык (процентларга күчергәндә 26,4% : 58,4% : 12,8% : 2,3%) булган.

Мал-туарны хисаплауга күчик. Санаучылар Бәзәкәдә мал-туары булган 333 хуҗалык (барлык хуҗалыкларның 77,8 %) тапканнар. Бу хуҗалыкларда эш атлары 471, яшь атлар 8, айгырлар 11; савым сыерлар 415, башмак таналар 49, үгезләр 7, бер яшьлек таналар 8, бозаулар 224; 1374 сарык, 389 бәти, 26 кәҗә һәм 13 кәҗә бәтие булган. Бу малның хуҗалыклардагы бүленеше белән дә танышыйк. Атсыз хуҗалыклар 83 (19,4%), бер атлылар – 185 (43, 2%), ике атлылар 106 (24,8%), өч һәм күбрәк атлы 15 (3,5%) булган. Сыерсыз хуҗалыклар 100 (23,4%), бер сыерлы – 197 (46%), ике сыерлы – 87 (20,3%), өч һәм күбрәк сыерлы 25 (5,8%) булган.

Исегезгә төшерим: атсыз хуҗалык фәкыйрь, бер атлылар ярлы хуҗалык саналган. Китерелгән мәгълүмат күрсәтүенчә, Бәзәкә халкының 60 процентта артыгы фәкыйрь һәм ярлылар төркемен тәшкил иткән; бары чиреккә якын хуҗалыклар гына урта хәллеләр рәтенә кергән; һәм

хуҗалыкларның 3,5% гына хәлле хуҗалык дип атап булган. Хуҗалыкның ат белән тәэмин ителүе игенчелекнең үсешенә зур йогынты ясавы билгеле. 1917 елда Бәзәкәдә ашлык чәчелгән басулар 1297,7 дисәтинә тәшкил иткән, 737,5 дисәтинә парга калдырылган; 11 дисәтинәдә уҗым, 19,5 дисәтинәдә сабан ашлыгы чәчелмичә калган.

Шулай итеп, 1917 елгы перепись материаллары авылыбызның яңа чорга күчү алдыннан булган яшәеше хакында иң тулы мәгълүмат бирә дип йомгаклый алабыз. Русия алып барган сугыш шартларында авылда крестьяннарның фәкыйрьләшә баруын исбат итәрлек мәгълүмат тупламасын эченә алган мондый чыганак 1917 елга илдәге халыкның ризасызлыгы һәм революцион хәрәкәтнең үсешен тасвирларга мөмкинлек бирә.

Болгавыр еллар, шаукымлы көннәр...

Күп яшәдек без богауда,
Ачлык безне гел буды;
Кара көннәр узып китте,
Үч алыр көннәр туды.

Әхмәт Фәйзи

1917 ел... Беренче бөтендөнья сугышының өченче елы үтеп бара. “Патшаны бәреп төшергәннәр!” - дигән хәбәр ил буенча яшен тизлегендә таралган. Русиядә яшәгән бар халыклар бу хәбәрне рухландыргыч көч буларак кабул иткән. Патша самодержавиесе режимын җимереп, Февраль революциясе тиз вакыт эчендә Русия халкы алдында яңа горизонтлар ачып җибәргән, аны иң тирән яшерелгән өметләренең эшкә ашырылдырачагына ышандырган. Берничә айга (ә теләкләр – гомерлеккә!) Русия дөньяда иң ирекле ил булып киткән. Бөтен ил белән бергә татар халкы да хәрәкәткә килгән. Шәһәр-авылларда митинг-демонстрацияләр, күп санлы съездлар кайнаган. Ниндиләре генә булмаган алар арасында! Төрле партияләр, милли оешмалар съездлары дисеңме, эшчеләр, крестьяннар, интеллигенция съездларымы, руханилар, хәрбиләр, хатын-кызлар съездлары ... – барысы да булган. Һәм аларның барысында да бөтен Русия игътибарын җәлеп иткән мәсьәләләр алгы планга чыккан. Барысында да чорның иң мөһим мәсьәләләре – сугыш һәм солых, җир мәсьәләсе, демократик республика һәм Учредительное собрание, милләтләр арасында тигез хокуклылык һәм үзбилгеләнү... – болар барысы да көн тәртибендә урын алган...

Бәзәкә халкы (безнең бабаларыбыз һәм әтиләребез - минем әтигә ул вакытта әле 17 яшь тулып кына килә торган булган) самодержавиенең юкка чыгуы хакындагы хәбәрне ничек кабул итте икән? Бу вакыйгалардан соң 100 ел үтеп барганда, без бу сорауга җавап бирә алабызмы? Миңа калса, патшаның бәреп төшерелгәнлеге хакындагы хәбәрне ишеткәч, алар аптырап калгандыр. “Ничек инде? Ил патшасыз була аламы? Хәзер безнең белән нәрсә булыр?” – кебек сорауларга җавап эзләп, ак сакаллы картлар да, яшь егетләр дә җитәрлек баш ваткандыр. Ләкин көндәлек тормыш үзенекен иткән: патша, бармы ул, әллә бәреп төшерелгәнме – ул кайдадыр бик ераклта; шулай ук,

кайдадыр бик ераста, сугыш дәвам итә, халык съезд-корылтайларга җыела, митинглар бара... Ә монда – игенче өчен, һәрвакыттагыча, беренче урынга язгы кыр эшләре чыга: яз көне патша-сугышлар турында уйларга түгел, иген чәчәргә кирәк. Яшь-таза ир-егетләрне сугышка җибәргән авыл өчен басу-кырларны буш калдырмау – таш яуса да, һичшиксез, үтәлергә тиешле бурыч. Аның артыннан печән хәзерләү, игеннәрне җыеп алу...

Шулай да, инде яз-җәйләрдә үк, кызу эш өстендә авылда мөселман агитаторлары һәм төрле партияләрнең вәкилләре күренә башлаган. Алар аңлаткан лозунглар арасында халыкка аңлаешлы “Бетсен сугыш!”, “Җир игенчеләргә бирелергә тиеш!” кебекләре дә булган.

Алабуга өязендә, башка җирләрдәге кебек үк, хакимияттә үзгәрешләр башланган. Земство управасы (ә аның хезмәткәрләре арасында либераллар да, эсер-меньшевиклар да булган) җитәкчелекне үз кулына алырга уйлаган. Ләкин Советларның беренче өяз съездында ук крестьян, эшче, солдат депутатлары Алабуга советының башкарма комитетын сайлаган. Башкарма комитетта аз санда булган большевиклар һәм мөселман активистлары бик актив рәвештә эшне үз кулларына алганнар. Башкарма комитетның өяз белән җитәкчелек итү бүлегенең 1918 елның ноябреннән 1920 елның ноябренә кадәрге вакытны эченә алган отчетында: “Советларның беренче өч съезды кайчан узганлыгын төгәл генә билгеләп булмый, чөнки булган ике эвакуация барышында (Алабуга аклар кулына төшкән чорда – А.М.) мәгълүматлар юкка чыккан”, - дип аңлатылган. Шушы ук отчетта ике ел эчендә Алабугада Советларның барлыгы 9 съезды булуы һәм IV - IX съездларның узган вакытлары да күрсәтелгән: IV съезд 1918 елның 20 февралендә, V съезд – 1918 елның июнендә, VI съезд – 1918 елның 1 декабрендә, VII съезд –1919 елның 28 июнендә, VIII съезд –1920 елның 10 февралендә һәм IX съезд –1920 елның 15 августында үткәрелгән икән.

Мөселман активистлары хакында. Ул чорда Алабугада яңача фикер йөртүче һәм үз халкына хезмәт итәргә теләүче берничә татар егете калкып чыккан. Заманы өчен алар бик яхшы белемле, зыялы егетләр, бер-берсен дә яхшы белгәннәр. Атаклы Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Ижаудагы югары башлангыч училищедә укып, алар халык мәктәпләре укытучысы дигән таныклык та алганнар, рус-татар мәктәпләрендә балалар да укытканнар. Югары башлангыч училище дигәнем, башлангыч мәктәп кенә булмаган; ул, алты еллык булып, педучилище ролен дә үтәгән. Кемнәр соң бу егетләр? Алар барысы да Алабуга өязеннән - Балтач авылы егете Юныс Нуриман улы Вәлидов (1889-1925), Тирсә авылы егете Гасыйм Гата улы Мансуров (1894-1955), Кичкутан авылы егетләре, тамырлары Бәзәкәгә барып тоташкан бертуган Гыйрфанетдин һәм Гобәйдулла Балтановлар һәм башкалар булган. Араларында бәзәкәле Зиннур Шоңкаров (Бәшаров) булуын да әйтим. Алар дөньяны үзгәртергә, социаль һәм милли тигезсезлекләрне бетерергә уйлаганнар. Халкын ирекле, мәгърифәтле, хөр фикерле итеп күрү хакында хыялланган егетләр, җиң сызганып, эшкә керешкән. Тынгысыз җаннар өяздә яңа хакимият урнаштыруга, бу процесска татар халкын да катнаштыруга барлык көчләрен куйганнар.

1917 елның 20-22 июнендә Алабугада өяз мөселманнарының съезды үткән. Анда 15 волостьтан 67 делегат катнашкан, даими эшләүче өяз мөселман комитеты сайланган. Аның председателе итеп большевик Мансуров Гасыйм билгеләнгән. Съездда шулай ук өяз управасына һәм крестьян, эшче, солдат депутатларының Алабуга советы башкарма комитетына вәкилләр сайланган. Аларның берсе Юныс Вәлидов булган. Озак тотмыйча, 1917 елның 14-15 августында өяз мөселманнарының икенче съездын да уздырганнар. Бу юлы мәдәни-милли автономия һәм өяздә халыкны укыту мәсьәләләре көн үзәгендә булган. Өяздәге контрреволюцион күренешләр белән көрәшү чаралары хакында да, Учредительный собраниегә сайлаулар хакында да сөйләшкән-киңәшкәннәр. Бу вакыйгаларга татар халкын хәзерләү өчен авылларга пропагандистлар җибәрергә карар кабул ителгән. Салагыш волостена М.А.Дулатов дигән кеше җибәрелгән.

1917 елның 25-27 октябрендә Петроградта II Бөтенрусия Советлары съездында илдә Совет власте игълан ителгән. Съезд солых һәм җир турында декретлар кабул иткән, беренче Совет хөкүмәтен – халык комиссарлары Советын (СНК) сайлаган. 2 ноябрьдә СНК “Русия халыкларының хокуклары хакында Декларация” кабул иткән. Пропагандага бик зур урын биргән большевиклар аны кыска вакыт эчендә халык арасында киң тарату хәстәрен дә күргәннәр. Мәсәлән, ул шунда ук татар теленә тәрҗемә ителеп, барлык татар газеталарында һәм прокламация формасында басылып таратылган. 1917 елның 20 ноябрендә СНК утырышында “Русия һәм Шәрыкның барлык хезмәтчән мөселманнарына Мөрәҗәгать” кабул ителгән. “Русия һәм Шәрыкның хезмәтчән һәм хокуксыз мөселманнары, без сезгә мөрәҗәгать итәбез. Русия мөселманнары, Идел Буе һәм Кырым татарлары, Себер һәм Төркестанның кыргызлары һәм сартлары, Кавказ арты төрекләре һәм татарлары, Кавказ чеченнары һәм башка мөселман кавказлылар, - Русия патшалары тарафыннан мәчетләре һәм иман йортлары җимерелгән, йола һәм гореф-гадәтләре бозылганнар, барыгыз да. Бүгеннән сезнең иманыгыз һәм гореф-гадәтләрегез, сезнең милли һәм мәдәни оешмаларыгыз ирекле һәм имин (кагылгысыз) дип игълан ителә. Үзегезнең милли тормышыгызны ирекле һәм тоткарлыксыз оештырыгыз. Сезнең моңа хакыгыз бар. Сез үз илегезнең хуҗалары булырга тиешсез. Үз тормышыгызны сез үзегезгә охшаганча оештырырга тиешсез”, - дип язылган булган мөрәҗәгатьтә. Әлбәттә инде, бу мөрәҗәгать, шулай ук татарчага тәрҗемә ителеп, басылган һәм өязләргә җибәрелгән.

Барлык мөселман халыкларының, татар халкының, безнең Алабуга егетләренең дә, иң изге теләкләрен чагылдырган бу мөрәҗәгать, бу вәгъдәләр күпләрнең йөрәгенә юл тапкандыр. Революция чорына хас булган романтик хисләрне дә онытмыйк. Чыннан да, Вакытлы хөкүмәткә өметләре өзелгән бик күпләр, мондый вәгъдәләрнең йогынтысына бирелеп, большевикларның беренче адымнарын хуплап каршы алганнар. Алабугада Совет власте 1917 елның 6 (19) ноябрендә, өяздә – 1918 елның февралендә урнаштырылган. Шул ук елның 4 апрелендә өяз земство управасы таратылган. “Аның җитәкчеләре булган уң эсерлар һәм меньшевиклар таратылыр алдыннан

качтылар, эш кәгазьләре һәм архив исән калган”, - дип күрсәтелгән архив документларында. Өяздә хакимият крестьян, эшче һәм солдат депутатлары советының башкарма комитетына күчкән. 1918 елның 26 апрелендә башкарма комитет мөселманнар өчен мәдәни-агарту бүлеген булдыру хакында карар кабул иткән.

Алабуга өяз башкарма комитеты фондын өйрәнеп утырганда мин бик кызыклы документка тап булдым. Чорның революцион рухын чагылдырган, бик тиз арада булачак коммунистик киләчәкне якынайту романтикасы белән сугарылган бу документ 1919 елның 20 февралендә кабул ителгән. Аның тулы тәрҗемәсен китерәм. “РКПБның Алабуга оешмасы бу елның 6 февралендә уздырган гомуми җыелышта һәм крестьян, эшче, солдат депутатлары өяз Советының башкарма комитеты 4 февральдә үткәргән утырышта Алабуга өязен “Алабуга хезмәт коммунасы” дигән исемгә алмаштыру мәсьәләсе тикшерелде, чөнки коммуналь стройны аякка бастыру өчен беренче адымнар инде эшләнде: сәүдә шәһәр идарәсе кулында, йортлар коммуналь мал булып санала, өяз хезмәт коммуналары челтәре белән капланды. Болар барысы да исем алмаштыру өчен конкрет төшенчәнең принциплары булып тора. Шулай алмаштыруның бик мөһим булуын һәм чынбарлыктан килеп чыгуын танып, Алабуга өязен “Алабуга хезмәт коммунасы” дип атарга дигән карар кабул ителде. Шушы карар нигезендә барлык совет оешмаларына өяз белән идарә итүче бүлек язма документларда “Алабуга өязе” дигән сүзләр урынына “Алабуга хезмәт коммунасы” сүзләрен кулланырга куша. Совет оешмаларының барлык штемпель һәм печатьләре совет типографиясе һәм кулланучылар җәмгыяте союзы типографиясенә бирелгән үрнәк буенча үзгәртелергә тиеш”.

Өяз бу яңа исемгә күнегеп җитәргә өлгермәгән, гражданнар сугышы башланган. 1918-1919 елларда өяз җирләре берничә тапкыр аклар белән кызыллар арасында барган сугыш кырына әверелгән. Бу чорда Советларның өяз башкарма комитеты белән параллель рәвештә өяздә мөстәкыйль эш алып барган революцион хакимият органнары да барлыкка килгән. 1918 елның февраль - апрель айларында Кызыл гвардиянең хәрби-революцион штабы; чехословакларның һөҗүменнән соң, 1918 елның октябреннән 4 декабрьгә кадәр - беренче Ревком; Колчак гаскәрләренең беренче һөҗүменнән соң, 1919 елның13 мартыннан 2 маена кадәр – икенче Ревком; Колчак гаскәрләренең икенче һөҗүменнән соң, 1919 елның 28 маеннан 1 июленә кадәр – өченче Ревкомнар эшләгән. Бу революцион оешмалар, өязне саклау максатыннан чыгып, барлык совет оешмаларының эшен берләштерүче гадәттән тыш орган буларак эш алып барган. Беренче Ревком составында мөселман эшләре буенча Алабуга комиссариаты да булган (җитәкчесе Х.Г. Габдрахманов). Аның эше – татар авылларында Совет властеның политикасын аңлату, контрреволюция белән көрәшү өчен оештырылган кораллы төркемнәрдә һәм продоотрядлар составында крестьяннарның “артык булган” азык-төлеген тартып алуда катнашу булган.

1918 елның ноябрендә өяз аклардан азат ителгәннән соң, мөселман эшләре комиссариаты яңа составта эшен дәвам иткән (комиссары Искәндәров

Н., бүлек секретаре Сәхәбетдинов Ә.). Комиссариат составында җиде бүлекчә оештырылган: гомуми (җитәкчесе Бакеев А.), халык мәгарифе (Балтанов Г.), агитация һәм оештыру (Валидов Ю.Н.), контрреволюция, саботаж һәм спекуляциягә каршы көрәш (Усманов М.У.), статистика, хәрби һәм нәшрият бүлекчәләре. 1918 елның декабрендә “Чулман (Кама)” исемле газет чыга башлаган. Ул дүрт айга кадәр чыгарылган, 1919 елның апрелендә колчакчыларның яңа һөҗүме һәм эвакуация аркасында туктатылган. Бүлек әгъзалары барысы да акларга каршы сугышка киткән.

Халык белән эшләү өчен мөселман комиссариаты, кагыйдә буларак, татарларның иң белемле өлешен – җәдид һәм рус-татар мәктәпләре укытучыларын җәлеп иткән. Мисал өчен, 1918-1919 елларда мөселман эшләре бүлегендә эшләгән укытучылар исемлеге белән танышыйк.

1. Юныс Вәлидов – бүлек җитәкчесе – VI крестьян съездыннан эшли.
2. Нәҗип Искәндәров – газета редакторы һәм коллегия әгъзасы - V крестьян съездыннан,
3. Зиннур Шоңкаров – агитация һәм пропаганда бүлекчәсе җитәкчесе – 5 декабрьдән (аның Бәзәкәдән булуын искә төшерик – А.М.),
4. Нури Исламов – контрреволюциягә каршы көрәш бүлекчәсе җитәкчесе - V крестьян съездыннан,
5. Салих Хәсәнкаев - авыл статистикасы бүлекчәсе җитәкчесе – 1 ноябрьдән,
6. Мәгъсум Мусин – авыл статистикасы бүлекчәсе секретаре – 27 гыйнвардан,
7. Әгъләметдин Сәхәбетдинов – бүлек секретаре – 1 ноябрьдән.

Исемлек 1919 елның 10 февралендә төзелгән.

Гражданнар сугышының иң авыр көннәрендә дә яшь Советлар хакимияте басма сүзгә чиксез игътибар биргән: китап, газета, листовкалар еш кына корал, азык-төлек, фураж белән бер дәрәҗәдә мөһим булган. Аклардан азат ителгән территорияләрдә шунда ук рус һәм башка халыклар телләрендә газеталар чыгаруны көйләп җибәргәннәр, листовкалар бастырганнар. 1919 елның маенда өяз аклардан азат ителеп, Алабугада Совет власте яңартылу белән “Кызыл юл (Красный путь)” исемле газет чыга башлаган. Газетны чыгару өчен Хәсәнкаев С., Исламов Н. һәм Мансуров Г. җаваплы булганнар. Һәрбер санның тиражы мең ярымга җиткән җиде сан чыгарылган.

Өяздә Совет властеның җирле органнары 1918 елның март-апрель айларында оешып беткән. Бәзәкәдә крестьян депутаталары Советы 1917 елның көзендә үк барлыкка килгән. Оештыручыларның берсе укытучы Зиннур Шоңкаров (Бәшаров) булган. Аның тәкъдиме белән җыелган авыл җыенында өч кешедән торган авыл советы сайланган. Аның рәисе итеп Гафаров Әхтәмҗан (1865 елда Бәзәкәдә туган, укый-яза белми, урта хәлле, гаиләсе ун кешедән гыйбарәт, патша армиясендә пехотада хезмәт иткән), рәис ярдәмчесе итеп Сафиуллин Хикмәтулла (1869 елда Бәзәкәдә туган, укый-яза белми, ярлы, гаиләсендә 11 кеше булган, армия хезмәтендә булмаган) сайланганнар. Бәзәкәләләр арасында документларны русча алып барырлык белемле кеше табылмагач, авыл советына секретарь итеп Стрелков Федор

Афанасьевич (1887 елда туган, керәшен, башлангыч белемле, ярлы) чакырылган. Авыл советының бу составы нинди эшләр башкарырга өлгергәндер, мәгълүмат очрамады.

Беренче авыл һәм волость советларына сайлаулар һәр көздә узарга тиеш булса да, бу чорда алар ешрак та булган (я яңа закон чыккан, я башка сәбәпләр барлыкка килгән; мәсәлән, тулыр-тулмас ике ел эчендә өяздә алты тапкыр власть алмашынуы үзе генә дә ни торгандыр!). Миңа калса, Советлар власте яшәвенең беренче биш елы безнең бабаларыбыз өчен иң авыр елларның берсе булгандыр. Беренчедән, гадәти көндәлек тормыш рәвеше үзгәреп кенә калмаган, бар нәрсә дә чәлперәмә килгән – гадәтләнгән тормыш тәртибе дә, гаилә һәм җәмгыятьтә гасырлар буена тәрбияләнгән традицион мөнәсәбәтләр дә, яхшылык-яманлык, игелек-явызлык кебек төшенчәләр дә... Бу инде әллә кайда ераклта барган сугыш яки революция генә түгел. Алардан, Ходай Тәгаләгә инанып һәм язмышка бирелеп кенә, бер почмакта читтә генә утырып калып булмый. Революция һәм сугыш (гражданнар сугышы) синең авылыңа, синең өеңә килеп җиткән...

Халык нәрсә эшләргә белмәгән – һәр ай диярлек өяздә алмашынып торган властьларга ничек яраклашырга? Гомер буе тир генә түгел, кан түгеп тапкан малыңны ничек саклап калырга? Кемгә ышанырга? Тегеләре дә, болары да терлек һәм кош-кортны, икмәк, печән, фуражны һәм башка кирәк-яракны тартып алу гына түгел, олаулары белән атларны да, аларны карарга яшь егетләрне дә үзләре белән алып китәргә генә торганнар ич. Билгеле, халыкның күбесе яңа хакимиятнең революцион идеалларын аңламаган гына түгел, алар хакында ишетмәгән дә булган. Җирдә оҗмах вәгъдә иткән яңа властька гамәлдә киресен эшләргә – крестьяннарның авырлык белән эшләп тапкан икмәген-малын, гадәттән тыш чаралар кулланып, тартып алырга туры килгән. Күпләрнең пассивлыгы, үз милкен саклап калырга теләүчеләрнең каршы килүләре, искелек сагында торучыларның баш күтәрүләре – болар барысы да яңа хакимиятне аларга каршы сәяси һәм икътисадый көч куллануга китергән. Шулай итеп, бу вакыйгалар халыкны капма-каршы торган ике лагерьга бүлгән.

1918-1919 елларда өяз территориясе, шул исәптән Бәзәкә дә, берничә тапкыр кызыллардан акларга, аклардан кызылларга кулдан-кулга күчкән. Бәзәкәнең үзендә һәм аның тирәсендә аклар белән кызыллар арасында бәрелешләр булмаса да, атышлар күп булган: мылтыктан да атканнар, пулеметтан да, хәтта пушкадан да; аклар да аткан, кызыллар да. Төрле хәлләр булган – талаулар да, урлаулар да; авылның бер ягыннан аклар чыгып барганда, икенче ягыннан кызыллар килеп керүләр дә. Әтиебез Мәхмүтов Хаҗиәхмәт истәлекләреннән: “Староста, Солтан абзый авылга керә торган юлларга безне, үсмер малайларны, каравылга куя иде. Безгә наказы: килүчеләр күренү белән, аңа хәбәр итәргә. Ул үзе белән патша заманыннан калган староста мөһер-билгесен һәм кемнәндер алган буденновканы кесәсендә йөртә иде. Акларның килү хәбәрен әйтсәң, муенына мөһерен элеп куя, кызыллар килгәндә – башына буденновкасын кия”.

Үзәк хакимиятнең сугыш чоры законнарының беренчеләре арасында азык-төлек эшен үзәкләштерү, икмәк монополиясен кертү хакындагы декретлар кабул ителгән. Азык-төлек халык комиссариаты үзгәрми торган бәяләргә халыктан икмәк сатып алуны оештыру эшендә чикләнмәгән хокукларга ия булган. Азык-төлек комитетлары, азык-төлек отрядлары (продотрядлар), ярлылар комитетлары (комбедлар) эшләрен җәелдереп җибәргән. Алар, сатып алуга караганда, икмәк һәм башка азык-төлекне тартып алуны кулайрак күргән. Хөкүмәтнең азык-төлек өлкәсендәге сәясәтенең иң югары ноктасы булып 1919 елның 11 январендә РСФСРның халык комиссарлары советы кабул иткән продразверстка кертү хакындагы декрет санала. Башта продразверстка икмәк һәм фураж ашлыгына кертелгән, соңрак ит һәм бәрәңгегә, ә 1920 ел азагына барлык авыл хуҗалыгы продуктларын үз эченә алган. Баштарак продразверстка кулакларның һәм урта хәлле крестьяннарның “артык” икмәген алуны күз алдында тоткан була. Ләкин чынлыкта (бу вакытка җир турындагы декрет нигезендә авыл халкының күпчелеге урта хәлле – середняк саналганын да онытмыйк) алардан “артыгын” гына түгел, соңгысын да – крестьяннар кытлык елларында да күз карасы кебек саклаган “симәнә” орлыгын да тартып алганнар.

Азык-төлекнең “артык” булуын ничек белгәннәр соң? Ул шактый ирекле рәвештә билгеләнгән: нигез итеп губерна буенча чәчүлекләрнең һәм җыелган уңышның күләме, калган запаслар алынган, һәм шул саннарны өяз, волость, авыл һәм хуҗалыкларга бүлеп таратканнар. Разверстка илдәге халыкның күпчелеге – крестьяннарның мәнфәгатьләренә кагылган, шуңа күрә каршылыклы күренешләргә дә нигез булган. Ул крестьяннарның иген игү теләкләрен юкка чыгарган (“әгәр дә бөтен эшләгәнең тартып алына икән, нәрсә хакына иртә таңнан караңгы төнгә кадәр сукаларга, чәчәргә, бил бөгәргә?”), чәчүлек җирләренең һәм икмәк җитештерүчәнлегенең кимүенә, крестьяннарның натураль хуҗалыкка күчүенә h.б. китергән. Крестьяннарны кысрыклау продразверстка белән генә чикләнмәгән; аларга башка эшләр дә йөкләнгән – олаулар бирү, юлларны төзек тоту, натураль налог, махсус салымнар, армиягә мобилизацияләүләр...

Вәгъдә ителгән оҗмахның коточкыч тәмугка әйләнә баруын күреп тә, ни өчен крестьяннарның күпчелеге гражданнар сугышы елларында ук Совет власте ягына баскан соң? Алар илне дә бушлай диярлек ашаткан, Кызыл Армиягә улларын да биргән, чиге булмаган йөкләмәләр дә үтәгән ләбаса! Шулай булмаса, Совет власте сакланып кала алыр иде микән? Җаваплар төрле булырга мөмкин, ләкин, минемчә, иң мөһиме – язмышка буйсыну һәм Совет властеның крестьяннарга бирелгән җирне тартып алмавына инану булгандыр. Крестьяннар өчен аклар “аксөяк”, җирне кире алучылар, ә кызыллар, нәрсә генә эшләсәләр дә, үзеңнекеләр. Шуңа күрә акларның барлык һөҗүмнәре, шәһәрләрдән ераккарак китү белән, уңышсызлыкка очраган түгелме?

Аклардан арынган авыл-волостьларда хакимиятнең җирле органнарын торгызу өчен авыл җыеннары җыелган, Советларның волость һәм өяз

съездлары уздырылган. Бу съездларда чыгыш ясаучы крестьян депутатлары аклар китергән зарар хакында сөйләгән, талаулар, халыкны мыскыл итүләрнең күп кенә мисалларын китергән, авыл тормышын тәртипкә салу өчен ярдәм кирәклеген ассызыклаган. Бу вакытта Алабуга өязе төзелешенә кайбер үзгәрешләр кертелеп, Салагыш волосте таратылган, Бәзәкә Күрәк волостена күчерелгән.

1919 елның 15 июнендә Күрәк волосте крестьян депутатларының җыены узган. Җыенда һәр авылдан берәр кеше катнашкан. Бәзәкәдән Гыймазетдин Нәҗметдинов булган. Җыенда каралган мәсьәләләр: 1. Агымдагы момент. 2. Урыннардан докладлар. 3. Авыл советларына сайлау уздыру өчен инструктор билгеләү. Беренче мәсьәлә буенча район вәкиле Виноградов Кызыл Армиянең алга баруы һәм Уфа шәһәрен алуы хакында сөйләгән. Икенче мәсьәләне караганда, чыгыш ясаучылар барысы да ярлы һәм урта хәлле крестьяннарның аклар тарафыннан талануына, икмәк булмавына зарланганнар, волость халкының хакимияткә салкын караулары хакында да сүз барган. Бәзәкә вәкиленең протоколга кергән сүзләре: “Совет властена, берничә кешедән кала, халыкның мөнәсәбәте яхшы. Тугыз мең пот икмәк җитми. Аклар белән киткәннәр барысы да әйләнеп кайтты”. Җыенның карары: өч кешедән торган комиссия төзергә, аңа аклар тарафыннан китерелгән зыян хакында барлык мәгълүматны туплауны йөкләргә.

Волость җыеннары еш булган. 1919 елның 18 июнендәгесендә Бәзәкәдән Хикмәтулла Сафиуллин һәм Шәйгалләм Шәймәрданов, 16 июльдә – Әхмәдиша Җиһаншин һәм Бикмөхәммәд Әхмәдьянов, 24 июльдә - Хикмәтулла Сафиуллин һәм Фәрдетдин Биктимеров, 28 августта – Исмәгыйль Сафиуллиннар катнашкан. 18 июньдә узган икенче волость җыенында Күрәк волисполкомының яңа составы расланган, аның рәисе итеп Ижевка авылы вәкиле Егор Плеханов сайланган.

1919 елның 28 июнендә Советларның VII өяз съезды булган. Анда өяздәге эшләрнең колчакчыларны куганнан соңгы торышы тикшерелгән. Менә Салагыш волосте вәкиле Юныс Вәлидов чыгышыннан өзекләр: “Салагыш волосте Алабуга өязенең Кама буе волостьларының берсе. Акларның ике һөҗүмендә дә, аларның юлы өстендә булганга, иң күп зыян күргән волостьлардан берсе. Шуңа күрә волостьның икътисадый хәле бик кызганыч. [...] Үткән ел булган икмәкне учетка алганда, 41 мең пот икмәкнең җитмәве ачыкланды. [...] Волостьның сәяси кыяфәтенә килгәндә, ул түбәндәгечә: халык ике капма-каршы лагерьга бүленгән. Укытучылар, зыялыларның бер өлеше һәм яшь крестьяннар Совет властен яклап калдылар, эш яхшы гына бара иде, ләкин мобилизациягә бәйле фажига булды – Салагыш авылындагы кулак элементлары һәм алар тарафыннан алданган халыкның бер өлеше, баш күтәреп, өч хезмәткәрне – авыл башкарма комитеты рәисе В.Сәхәбетдиновны, секретарьны һәм военрукны үтерде. [...] Акларның соңгы һөҗүменнән волость бик күп зыян күрде – бик күп ат, арба һәм башка әйберләне алып киттеләр. Совет властена каршыларның барысы да аклар белән качтылар, бөтен волость җирләреннән барлык Совет власте дошманнары куылды. Волость халкының революцион рухы күтәренке. Соңгы

көннәрдә хезмәт артельләрен оештыру эше башланып китте. Чәчелмәгән басулар күп, авыл хуҗалыгы кораллары бик кирәк”.

Советларның VII өяз съезды, якындагы бурыч итеп, Совет властен нык ытуны һәм өяз хуҗалыгының хәлен ачыклауны билгеләгән. Контрреволюциядән зарар күргәннәргә ярдәм күрсәтү өчен өяз һәм волость комиссияләре оештырылган. Алар авыллар буенча хуҗалыклар саны, аларның эшкә яраклы эш һәм тарту көчләре, орлык белән тәэмин ителүе h.б. турысында мәгълүмат туплый башлаганнар. Комиссияләр җыйган мәгълүматтан берничә сан: 1919 елның 10 сентябренә Күрәк волостена 45 авыл кергән; татар авыллары арасында хуҗалык саны буенча иң зурысы Салагыш булган – 758 хуҗалык; Бәзәкәдә – 447, Турайда – 401, Камайда – 280, Кичкутанда - 230, Песәйдә – 145, Иж-Бубыйда – 76 хуҗалык булган; күрше рус авылы Ык Тамагында 200 хуҗалык күрсәтелгән. 1919 елның 20 ноябренә Күрәк волостеның 45 авылында 3029 эш аты сакланып калган була. Атлар белән волостьта иң “яхшы тәэмин ителгән” авыл Бәзәкә булган икән – безнең авылда 183 эш аты күрсәтелгән. 1919 елның 17 декабренә волость буенча 8957 “эшкә яраклы элемент” (Бәзәкәдә – 674 кеше) саналган.

Өяз хакимияте авылларны атлар белән тәэмин итү эшен дә башлап җибәргән, ләкин барысын да тәэмин итә алмаган. “Халыкны ат һәм башка авыл хуҗалыгы хайваннары белән тулысынча тәэмин итеп булмый, чөнки хәзерге вакытта волостьта әйтелгән хайваннар бетте”, - дип хәбәр иткән Алабугага Күрәк волисполкомы рәисе Габдрахманов 1919 елның 13 декабрендә. Чәчүлекләр хакында да мәгълүмат бар. Мәсәлән, Бәзәкәдә 1919 елда җәмәгать көче белән бары тик 123 дисәтинә сабан ашлыгы чәчелгән; аның 104 дисәтинәсендә солы, 5 дисәтинәсендә карабодай, 4 дисәтинәсендә арпа, 6 дисәтинәсендә борчак, берәр дисәтинәсендә тары һәм киндер чәчкәннәр. Басуларның чәчелми калуы симәнә юклыгы белән аңлатылган. Шунда ук барлык өйләр янындагы бакчаларда да ашлык чәчелүе күрсәтелгән. Бу мәгълүмат Бәзәкәдә натураль хуҗалыкка кайтуны дәлилли: үз бакчаңда чәчелгән – ул синеке, ә җәмәгать чәчүлегендәге уңышны, һичшиксез, “властьлар алып китәчәк”. 1920 елга Бәзәкәдә сабан ашлыгын 426 дисәтинәдә чәчүне планлаштырганнар, шул кадәр үк җирне парга калдырырга булганнар.

Губерна һәм өяз җитәкчелеге крестьян хуҗалыгын торгызуга зур көч куйган. Моны өяз башкарма комитетына Күрәктән килгән мәгълүмат ачык күрсәтә. 1920 елның 31 августына Күрәк волостенда 4145 эшче ат, 1035 сыер, 3329 сарык, 97 кәҗә булган; маллар саны Бәзәкәдә дә күзгә күренеп арткан: авылда 315 ат, 384 сыер, 1071 сарык һәм 17 кәҗә булуы күрсәтелгән. Таланган авылларда хакимият ярдәменнән башка малның бер ел эчендә бу кадәр артуын күз алдына китереп тә булмас иде. Хакимиятнең фәкыйрьлеккә калган крестьян хуҗалыкларына ярдәм күрсәтүе хакында сугыштан зарар күргәннәргә ярдәм күрсәтү өчен оештырылган өяз комиссиясе протоколларында бик күп дәлилләр саклана.

Архивларда шулай ук беренче авыл советлары һәм алар составына сайланып эшләгән кешеләр хакында да шактый күп материал җыелган. Мәсәлән, 1920 елның 6 апрелендә Бәзәкәдә авыл җыены узган. Барлыгы 300

кеше катнашкан җыенны авыл советы рәисе Сафиуллин Хикмәтулла һәм секретаре Гайнуллин Хикмәтулла алып барганнар. Өяз идарәсе вәкиле Әлмәтев үз чыгышының төп темасы итеп аклардан соң калган разруха белән көрәш мәсьәләсен куйган. Җыенда авыл советының яңа составын да сайлаганнар: рәисе итеп Мөхәмәтҗанов Мулланур, секретаре – Кәлимуллин Мифтахетдин сайланган. Гомумән, ул елларда авыл советы җитәкчеләре еш алмашып торган.

Менә 1920 елда Күрәк волостенда төзелгән волостьтагы авыл советлары әгъзалары һәм депутатларының гомуми исемлегеннән алынган Бәзәкә авыл советына кергән кешеләр исемлеге (нумерация волость буенча бирелгән):

“123. Салих Шакиров 1882 елда туган, хәрби хезмәттә булган, урта хәлле, депутат;

124. Хәсән Шәйхеләхмәтев 1876 елда туган, хәрби хезмәттә булган, ярлы, депутат;

125. Закир Садыйков 1868 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

126. Тажетдин Камалетдинов 1862 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

127. Закир Сиракаев 1883 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

128. Якуб Әхмәдьянов 1870 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

129. Гобәйдулла Гарифуллин 1876 елда туган, хәрби хезмәттә булган, урта хәлле, депутат;

130. Минәхмәт Ибәтуллин 1872 елда туган, хәрби хезмәттә булган, ярлы, депутат;

131. Галләм Галимов 1865 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

132. Дәүләтша Сабитов 1881 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

133. Җәләлетдин Шәрәфетдинов 1879 елда туган, хәрби хезмәттә булган, урта хәлле, депутат;

134. Сабир Шакиров 1877 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

135. Мөхәммәтгәрәй Әхмәтгәрәев 1881 елда туган, хәрби хезмәттә булган, ярлы, депутат;

136. Шакиржан Мөхәммәтҗанов 1865 елда туган, хәрби хезмәттә булган, ярлы, депутат;

137. Төхвәтулла Гобәйдуллин 1857 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, урта хәлле, депутат;

138. Төхвәтулла Кыямов 1857 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, урта хәлле, депутат;

139. Низаметдин Низаметдинов 1852 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

140. Мифтахетдин Калимуллин 1882 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

141. Мөхәмәтша Мөхәмәдиев 1875 елда туган, хәрби хезмәттә булган, ярлы, депутат;

142. Сәлимулла Нәбиуллин 1885 елда туган, хәрби хезмәттә булган, ярлы, депутат;

143. Гайнулла Хисмәтуллин 1855 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

144. Габдулла Кәлимуллин 1877 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, урта хәлле, депутат;

145. Гайнулла Гыйбадуллин 1850 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, депутат;

146. Нәҗметдин Кабиров 1880 елда туган, хәрби хезмәттә булган, ярлы, депутат;

147. Әхтәмҗан Гафаров 1865 елда туган, хәрби хезмәттә булган, урта хәлле, авыл советы рәисе;

148. Сибәгатулла Гыйззәтуллин 1872 елда туган, хәрби хезмәттә булган, урта хәлле, авыл советы рәисенең ярдәмчесе;

149. Хикмәтулла Гайнуллин 1889 елда туган, хәрби хезмәттә булмаган, ярлы, авыл советы секретаре”.

Авыл советлары, нигездә, авылда туган хуҗалык мәсьәләләре белән шөгыльләнгәннәр, волость һәм өяз таләбе буенча авылдагы хуҗалыкларның хәле хакында төрле мәгълүмат җыеп җибәргәннәр. Җирле советлар үтәргә тиешле күп кенә йөкләмәләр арасында гражданнар сугышы шартларында Кызыл Армияне кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе дә булган. Алабуга өязе территориясендә Гражданнар сугышы барган 1918-1919 елларда да, сугыш-бәрелешләр ерагаеп, акларны илдән куган 1920-1922 елларда да крестьяннарны армия сафларына мобилизацияләү барган. Авылның типсә тимер өзәрлек егетләрен көчләре кирәк булган җир эшләреннән аеру дигән сүз була бу.

Бу эш белән Күрәк волостенда махсус оештырылган волость хәрби комиссариаты шөгыльләнгән. Мобилизация исемлегенә сау-сәламәт, яше 18 дән 40 ка кадәр булган, хуҗалыгында чит кеше хезмәтеннән файдаланмаган ир-атлар кертелгән. Исемлек авыл советында бәзәкәлеләрнең туган еллары буенча төзелгән. Волость хәрби комиссариаты, исемлекне тикшергәннән соң, Алабуга өяз военкоматына тапшырган. Архивта Күрәк волосте хәрби комиссариаты фондында калын-калын папкаларда сакланган материаллар безгә 1884-1900 елларда туган һәм гражданнар сугышы елларында Кызыл Армия сафларына чакырылган бәзәкәлеләрнең исемнәрен ачыкларга мөмкинлек бирде. Мобилизация Алабуга өяз военкоматы приказыннан башлана торган булган. Бик күп приказлар арасыннан берсенең кыскартылган вариантын, тәрҗемә итеп, китапка да кертергә булдым.

“Алабуга военкоматының 1919 ел 10 июнь 80 номерлы Приказы

[…]10. Казан губвоенкомының, эшче-крестьян оборона Советы карарына нигезләнгән бу елның 7 июнь 505 номерлы приказыннан чыгып, 1900 елда

туган һәм Алабуга шәһәре һәм өязендә даими яки вакытлыча яшәүче гражданнарны Кызыл Армия сафларына хәрби хезмәткә чакыру игълан ителә.

11. Исемлектә күрсәтелгән гражданнар 14 июньдә иртәнге сәгать 9 га Алабуга өяз военкоматының кабул итү комиссиясенә килеп җитәргә тиешләр (адресы: Карл Маркс урамы, элеккеге нотариус Нечаев фатиры). […]

12. Чакыру буенча килүдән азат ителәләр:

а) Республика Ревсоветының 1918 елның 15 ноябрь № 260 Приказы нигезендә хәрби строевой хезмәттәгеләр, хәрби эшләр наркоматы карамагында булган төрле оешмаларда хезмәт итүчеләр;

б) үзләре килә алмаган һәм тиешле медицина шәһадәтнамәләре белән расланган каты авыруга дучар булганнар.

13. Волость военкомнары кабул итү комиссиясенә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны үзләре алып килергә һәм, билгеле тәртиптә төзелгән исемлекнең үзләрендә булган ике нөсхәсе белән үз волосте гражданнарын кабул иткәндә катнашырга тиеш.

14. Ир-атларны исәпкә алганда военкомат биргән шәхси карточкалары барлык чакырылганнарның үзләре белән булырга тиеш.

[…]

16. Чакырылганнар җыелу пунктларыннан кире җибәрелми, шуңа күрә армия сафларына китәргә әзер булып килергә тиешләр.

17. Бу приказ буенча чакырылган гражданнар РСФСРның илдәге хәрби хәлгә карап биргән күрсәтмәләренә кадәр хәрби хезмәттә булырга тиешләр.

18. Вакытында килмәгән өчен волость военкомнары гына түгел, чакырылганнарның гаилә башлыклары һәм авыл советлары да җаваплы санала.

Өяз военкомы В.Тимофеев”.

Бу приказ буенча Бәзәкәдән 17 кеше армия хезмәтенә чакырылган. Алар арасында безнең әтиебез Мәхмүтов Хаҗиәхмәт тә булган (ни сәбәпледер ул Мәхмүт-Ибраһимов Хаҗиәхмәт формасында язылган). Аларның исемнәре (Күрәк волосте гомуми исемлегендәге саннар белән бирелә):

“1900 елда туган, кеше хезмәтеннән файдаланмаганнарның
Күрәк волосте исемлеге. 1919 елның 14 июнендә төзелгән.

Бәзәкә

83. Мөхәмәтдинов Фәтхетдин
84. Мөхәмәтҗанов Хаҗимөхәмәт
85.Гыйләҗетдинов Мөхәмәдкәрим
86. Гайнетдинов Гыйләҗетдин
87. Гыймазетдинов Мөхәмәтзакир
88. Шаһимәрданов Харис
89. Шакиров Мөхәмәтзакир
90. Гафаров Мөхәмәткарим
91. Нигаматуллин Исрафил
92. Шайхидинов Шайханур
93. Әхмәтсахибов Әхмәтзәки

[…]

138. Сираҗетдинов Мөхәмәтдин
139.Мәхмүт-Ибраһимов Хаҗиәхмәт
140. Араслан-Галеев Дәүләтша
141. Гыймазетдинов Баһаутдин
142. Исмәгыйлев Динмөхәмәт
143. Сибәгатуллин Мулланур”

Хәрби комиссарның 1919 елның 5 августы хәбәре буенча, Күрәк волостеннан бу чакырылу исемлегенә кергән 155 кеше хәрби частьларга җибәрелгән. Алар арасында Бәзәкәдән чакырылган 17 кешедән унбере фронтка җибәрелгән: Шәйхетдинов Шәйхенур, Гыймазетдинов Мөхәммәдзакир, Мөхәмәтдинов Фәтхетдин, Вәлиев Харис, Исмәгыйлев Шәймөхәмәт, Гыймазетдинов Баһаутдин, Сибәгатуллин Мулланур, Мәхмүтов Хаҗиәхмәт, Шакиров Мөхәммәдзакир, Нигамәтуллин Исрафил, Сираҗетдинов Мөхәмәтдин. Бу хәрби хезмәткә алынган красноармеецлар исемлеге Алабуга өяз башкарма комитетының социаль-тәэминат бүлеге Күрәк волисполкомына җибәргән рәсми хаттан алынды. Анда аларның гаиләләренә азык-төлек паегы бирелергә тиешлеге күрсәтелгән, азык-төлек паегы бирелергә тиешле гаиләләрне барларга, төшеп калганнар булган очракта яңа тулыландырылган исемлек төзү кирәклеге әйтелгән.

Архив материалларындагы исемлекләрдән санап, мин, Гражданнар сугышы елларында 140 чамасы бәзәкәле мобилизация исемлекләренә керергә тиеш булган, дигән фикергә килдем. Бу исемлекләр, туган елларына карап, авыл советында төзелгән. Патша армиясендә хезмәт иткәннәрнең нинди гаскәрләрдә хезмәт итүләре дә күрсәтелгән. Мәсәлән, 1892 елда туганнар исемлегенә 18 пехотинец, 2 артиллерист һәм 6 хезмәттә булмаганнар кергән. Тагын бер өстәмә. РСФСР һәм Германия арасында Брест солыхы төзелгәч, авылга военнопленныйлар кайта башлаган. Ике ай ял иткәннән соң, яшьләре туры килгәндә, алар да Кызыл Армия сафларына чакырылган.

Аклар да үз отрядларына җирле халыкны мобилизацияләгәннәр. Ләкин, документлардан күренгәнчә һәм әти-бабайларыбыз сөйләвенчә, авыл аркылы узган аклар отрядлары рус һәм православныйлар булган; татар крестьяннарын алар олаучы итеп кенә кулланганнар. Авылдан арба-дирбияләре белән җигүле атларны алып киткәндә, аларны карар өчен ирегетләрне дә алганнар, ә болары, җаен табып, качып китү ягын караганнар. Мәсәлән, безнең Нуриәхмәт абый шулай аклар белән китәргә мәҗбүр булган, ләкин, үзе сөйләвенчә, әле Сарапулга җиткәнче үк, атына атланып, качып кайта алган. Минем фикеремне раслый торган бер кызыклы документ китерергә булдым. Ул Ык Тамагы авыл советы хәбәре: “Иске армиянең 1889-1898 елларда туган, авылга кайтканнан соң ике ай узган военнопленныйларын мобилизацияләү хакындагы приказны үтәп булмый: аларның барысын да аклар мобилизацияләделәр”.

Шуны да өстәргә кирәктер: бәзәкәлеләрнең күпчелеге Ак армиягә дә, Кызыл армиягә дә китәргә ашкынып тормаган. Бу хакта, мәсәлән, Бәзәкә авыл советына Күрәк волвоенкоматыннан килгән приказлар сөйли. Менә аларның бер-икесенең тәрҗемәсе:

1.1919 елның октябрь аендә җибәрелгән приказ: “Күрәк волвоенкоматы сезгә 1919 елның 17 октябрендә иртәнге сәгать 9-га 18 яшьтән 40 яшькә кадәр булган, билгеләнгән вакытка килмәгән гражданнарны Бондюг заводына яңадан тикшерүгә җибәрергә боера. Шулай ук чакыруга тулысынча килмәгән 1901 елгы гражданнарны җибәрү мәҗбүри. Вакытында үтәмәгән өчен авыл

советының барлык составы, Совет властена буйсынмаган һәм дезертирларны яшергән өчен, революцион трибунал судына тартылачак.

2.1919 елның 20 октябрендә җибәрелгән приказ: “Күрәк волвоенкоматы сезгә авыл советының күзәтүе астында җәмгыятегезнең хәрби хезмәткә алынган барлык гражданнарын 1919 елның 27 октябрендә иртәнге сәгать 8-гә Алабугага озатырга боера”. Бу боерыктан соң, алдагы приказдагы кебек, аны үтәмәүчеләр дезертир булып саналачаклары һәм ревтрибунал судына тартылачаклары кисәтелгән.

Бу документлар халыкка Совет власте тарафыннан кертелгән яңа тәртипләргә күнегергә туры килгән гаять катлаулы чорны аңларга ярдәм итәр, дип уйлыйм.

Рәхимсез ачлык еллары

Дөнья җимерелде, сугыш бара -
Ата белән бала сугыша.
Тагын Ачлык килде...
Кеше һаман
Җирдә яшәү өчен тырыша.

1920 ел – Татарстан республикасы барлыкка килгән ел. Үзбилгеләнү татар халкы өчен күптән өлгергән мәсьәлә булган. Аның тарихы зур булса да, мин берничә фактка гына тукталам. 1919 елның азагында Мәскәүдә Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының II Бөтенрусия съезды узган. Ул 1918 елның 23 мартында ук “Правда” газетында басылган Наркомнацның “Татар-Башкорт Совет республикасы хакында Положение”не тормышка ашыру турында карар кабул иткән һәм ТБССР ревкомын сайлаган. Ләкин 1919 елның мартында төзелгән Башкорт республикасының барлык делегатлары берләштерелгән республика төзүгә каршы чыкканнар. Мәсьәләне хәл итү РКП(б)ның Үзәк комитетына күчерелгән. В.И.Ленин тәкъдиме буенча ҮКның Политбюросы 1919 елның 13 декабрендә ТБССР хакындагы Положениене юкка чыгарган. 1920 елның 26 январендә ул “Татарстан Совет социалистик республикасын» оештыруны нигездә кулай тапкан. Шул ук вакытта булачак республиканың чикләрен өйрәнү һәм билгеләү өчен комиссия дә оештырылган.

Республиканы оештыру эшләре белән бәйле рәвештә Казан губернасы җир бүлегенең соравы буенча Казан губернасы Алабуга хезмәт коммунасының Күрәк волосте да берләштерелгән мәгълүмат әзерләгән. Казан губернасы җир бүлегенең җитәкчесе Алабуга өязен яхшы белгән Юныс Вәлидов булганлыгын да искәртим. Волость белешмәсеннән Бәзәкә хакындагы мәгълүматны гына китерәм: 1920 елның 22 январенә Бәзәкәдә 1298 ир-ат һәм 1250 хатын-кыз, барлыгы 2548 кеше яшәгән. Алар арасыннан 1320 кеше (632 ир-ат һәм 688 хатын-кыз) эшкә яраклы булмаган. Димәк, бәзәкәлеләрнең яртысыннан кимрәге - 1228 кеше генә эшкә яраклы саналган. Бәзәкә халкының яшь буенча бүленешенә дә игътибар итик: 7 яшькә кадәр 307 малай һәм 234 кыз бала булган, 8 яшьтән 13 яшькә кадәр – 147 малай һәм 248 кыз, 14 яшьтән 17 яшькә кадәр булган яшүсмерләр – 115 егет һәм 99 кыз,

18 яшьтән 60 яшькә кадәрге өлкәннәр – 551 ир-ат һәм 463 хатын-кыз, 60 яшьтән узганнар – 178 ир-ат һәм 196 хатын-кыз булган. Авылда булган терлек һәм авыл хуҗалыгы инвентаре саны да китерелгән: 436 ат, 434 савым сыер, 9 бозау, 15 кәҗә саналган; ә барлык инвентарь 285 сука, 238 тырма, 390 чалгы һәм 500 урактан гыйбарәт булган.

Алабуга өязенең ТАССР составына керүе күздә тотылган булса да, башта ул республика составына кертелмәгән. Ә Алабуга хезмәт коммунасы 1919 елда ук үзен Казан губернасы составына алу хакында Казан губерна советына мөрәҗәгать иткән булган. “Моннан күп еллар элек, патша заманында, Алабуга халкы өязне Казан губернасы составына кушу мәсьәләсен күтәргән иде, ләкин хакимият халык ихтияҗларына гомумән игътибар итмәде, - дип язылган мөрәҗәгатьтә. - [...] [Хәзер] тормыш үзе кушылу мәсьәләсен тикшерүне көн үзәгенә куйды, чөнки бу изге уй һәрбер алабугалының йөрәгенә бик тирән кереп утырган...”. Алабугадан һәр ике губерна үзәгенә бару арасын (Казанга 180 чакрым, Вяткага 400 чакрымнан артык) һәм Вятка юлының авырлыкларын күрсәтеп, алабугалылар өстәп куйганнар: “Алабуга ничек кенә яшәмәсен, Вятканың аның хакында бер кайгысы да юк, Алабуга аны гына үз эшләре белән борчымасын (күрәсең, алар барысы да Вятка өчен бик вак күренәдер)”.

Тагын бер, минем фикеремчә, уникаль документ. Ул төбәкнең Татарстан республикасына керү мәсьәләсен хакимиятнең барлык баскычларында тикшерелгәнлеген күрсәтә торган чыганакларның берсе – Күрәк волосте башкарма комитетының утырыш протоколы. 1920 елның 5 октябрендә үткән бу утырышта Татарстан республикасына керү мәсьәләсе махсус тикшерелгән. Утырышта, комитет әгъзаларыннан кала, волостьтан 17 вәкил катнашкан. Бик кызу барган сөйләшүдән соң түбәндәге карар кабул ителгән: “Гомуми җыелыш Вятка губернасы Күрәк волостенда калуны хуплады, ләкин мөселман авыллары, бу фикергә каршы булып, үз теләкләре белән Татар Совет республикасына күчү теләген белдерделәр. Теләк белдергән авылларның исемлеге: 1) Псәй, 2) Тат.Сарсаз, 3) Тойма, 4) Тәкәш, 5) Камай, 6)Турай, 7) Илкә, 8) Кураз, 9) Бәзәкә, 10) Тат.Ахтиял, 11) Тугыҗа һәм 12) Тат.Кокшан”.

Бу авылларның теләкләре кабул ителгән. Күрәк волостеның удмуртлар яшәгән күп кенә авыллары Алабуга өязеннән чыгарылган. Кыскартылган Алабуга өязендә, татар авылларыннан тыш, төбәктәге удмурт авылларының бер өлеше һәм рус авыллары да калган. 1921 елның 5 январендә РСФСРның Бөтенрусия үзәк башкарма комитеты карары белән бу өяз, Вятка губернасыннан чыгарылып, ТАССРга бирелгән. ТАССР халык комиссарлары советының 1921 елның 10 июнь карары белән республика составында Алабуга кантоны оешкан. Кантон территориясен билгеләгәндә, Бәзәкә авылы Күрәк волостенда калган. 1925 елда волость үзәге Камай авылына күчерелгән.

20-еллар башы – “хәрби коммунизм” политикасының уңышсызлыгын күреп, дәүләт, эчке төзелешенә үзгәрешләр кертү белән бергә, икътисад өлкәсендә дә яңа адымнар ясаган чор. 1921 елның мартында РКП(б)ның X

съездында В.И.Ленин “хәрби коммунизм” политикасыннан яңа экономик политикага – НЭПка күчүне игълан иткән. Аның эчтәлегенең нигезе – продразверстканы продналогка алмаштыру булган. Продналог продразверсткага караганда ике тапкырга киметелгән, хосусый предприятиеләр һәм ирекле сәүдә рөхсәт ителгән. Авылларда өлешчә җир арендасы һәм яллы хезмәттән файдалану рөхсәт ителгән. Ләкин бу адым соңга калган, чөнки якынлашып килә торган һәлакәтне (ачлыкны) туктата алмаган: продотрядлар эшчәнлеге нәтиҗәсендә орлыксыз калган хуҗалыклар табигать көчләренә каршы тора алырлык дәрәҗәдә булмаган.

Оешып кына килә торган Татарстан республикасында яңа тыныч тормышны башларга да өлгермәгәннәр, аның барлык территориясендә коточкыч ачлык башланган. Әлбәттә, фаҗига кинәт кенә, искәрмәстән килеп кермәгән. Аның сәбәпләре күп булган, аны зур бер йомгакка укмашкан сәбәпләр нәтиҗәсе дип әйтеп буладыр. Җиде елдан артыграк дәвам иткән сугыш (беренче Бөтендөнья сугышына Гражданнар сугышы өстәлгән) авыллардан крестьяннарның иң эшчән һәм җигелеп эшли торган өлешен суырып алган. Эшче куллар, атлар, орлык, инвентарьның җитешмәве аркасында чәчелми калган басуларның күләме елдан-ел арткан. Нәтиҗәдә күп кенә шәһәр һәм бистәләрне азык-төлек белән тәэмин итү кимегән. Продразверстка һәм “хәрби коммунизм” политикасын кертү крестьяннарны бөтенләй бөлгенлеккә төшергән, чөнки продотрядлар аларның барлык икмәген вәхшиләрчә, кырып-себереп алып бетергән.

Бу сәбәпләргә климатик фактор да кушылган. Алабуга өязендә 1920 елның җәенә үк игенчелектә уңайсыз шартлар күзәтелгән: көзен чәчелгән уҗым язын шытмаган. Өяз җитәкчелеге ул җирләргә сабан ашлыгы чәчүне оештырган, ансы да корылык аркасында уңай нәтиҗә бирмәгән. 1920 елның көзендә өяз җитәкчелеге (Г.Балтанов, Ефстафьев) ашыгыч, кичектергесез чараларга керешкән. Өяз башкарма комитетының 1920 елның 20 ноябрь карары белән волостьлардагы җир комитетлары, 1921 елның кыр эшләрен башкару өчен, крестьян хуҗалыкларына сабан ашлыгы һәм соң чәчелә торган игеннәр – карабодай, җитен, киндер һәм бәрәңге орлыгын өләшә башлаган. Алабуга өязенә, сабан ашлыгы чәчелергә тиеш булган 63 мең дисәтинә җирне дә кертеп, 600 мең пот орлык кирәк булган. Ләкин Идел Буенда тарала барган ачлык шартларында дәүләт орлык фондыннан өязгә бу кадәр ашлык орлыгын бирә алмаганнар.

Бәзәкәдәге хәлләргә игътибар итик. 1921 елның 7 январендә 300 кеше катнашы белән Бәзәкә авыл җәмгыятенең гомуми җыены үткән. Җыелышның рәисе Гайнулла Гыйбадуллин, секретаре Хикмәтулла Гайнуллин булган. Анда кантон вәкиле Мәҗитов катнашкан. Каралган мәсьәләләр: агымдагы момент һәм сабан басуын 1921 елның язында орлык белән тәэмин итү. Икенче мәсьәлә буенчы җыенның карары: “Без, Бәзәкә авылы гражданнары, симәнә материалын үзебездә саклап калырга вәгъдә бирәбез һәм 1921 елгы сабан басуына тулысынча ашлык чәчеп, җирнең бер генә дисәтинәсен дә буш калдырмаска вәгъдә итәбез. Рәис: укый-яза белмәүче Гыйбадуллин, секретарь Х. Гайнуллин”. Кантон вәкиле Мәҗитов авыл җитәкчеләреннән тагын бер

бик үзенчәлекле өстәмә документ та алган әле. Аның текстын тәрҗемә итмичә рус телендә калдырам: “Дана настоящая расписка Бизякинским сельсоветом гражданину то-есть товарищу в том заручаемся за Бизякинское сельское общество что засевать яровой полей в 1921 году не оставить не засеянной ни одну десятину. Подписались: Председатель сельсовета Х. Гайнуллин, секретарь Гайнуллин, член Сибагатулла Гизатуллин (неграмотный, за него расписался Габдрахманов)”. Карар өстенә расписка да таләп итү, минем фикеремчә, 1921 елның никадәр катлаулы булуын ачык күрсәтә.

1921 елның февралендә Бәзәкәдә 1242 ир-ат һәм 1335 хатын-кыз яшәгән. Шушы саннар алынган Күрәк волосте башкарма комитеты отчетыннан күренгәнчә, бу вакытта Бәзәкә хуҗалыкларында 197 эш аты, 35 өч яшьлек атлар, 214 сыер, 15 башмак тана, 5 кәҗә һәм 586 сарык калган булган. “Совет властена халык теләктәшлек күрсәтә иде, ләкин ачлар күренә башлагач, кайбер авылларда халыкның мөнәсәбәте дошманлыкка таба үзгәрә бара, халык ихтияҗлары бик начар үтәлә”, - дип күрсәткәннән соң, отчет төзүче, төшенкелеккә бирелеп, - “күрсәтмәләр бик кирәк: икмәксез калган гражданнар белән нәрсә эшләргә – артык азык-төлек юк, ә ачларның саны көннән-көн арта бара”, - дип өстәп куйган.

1921 елның 14 мартында Алабуга кантоны башкарма комитеты, халыкта булган йорт хайваннарын саклап калу максатыннан чыгып, халыкны рөхсәтсез мал чалудан һәм терлеген сатудан тыеп, үз боерыгын чыгарган. Волость башкарма комитетлары шәхси хуҗалыклардагы халык һәм мал санын өстәмә учетка алганнар. Күрәк волосте кантонга түбәндәге мәгълүматны җиткергән: волостьта 27392 җан, аларның эшкә яраклысы – 6290; 16 яшьтән олыраклар – 14852 җан; балалар: 1 яшькә кадәр – 1991; 5 яшькә кадәр – 3355; 10 яшькә кадәр – 3689; 16 яшькә кадәр – 3505 җан булган. Мал саны: 4 яшькә кадәр эш атлары – 660, 4 яшьтән олыраклар – 2479, яшь атлар – 220, колыннар - 145; сыерлар - 2897, нәсел үгезләре - 43, бер яшькә кадәр бозаулар – 736, ике яшькә кадәр – 300; сарыклар – 4871, бәтиләре - 1969; кәҗәләр – 209, кәҗә бәтиләре - 89; тавыклар – 9271, казлар - 1116, үрдәкләр - 277, күркәләр - 22, барлык кош-корт – 10686 булган.

Бәзәкә буенча 1921 елның 27 маена бирелгән мәгълүмат: 484 хуҗалыкта 1242 ир-ат (берсе рус милләтеннән) һәм 1335 хатын-кыз, 2577 кеше яшәгән; аларның 163 эш аты һәм 168 ике яшькә җитмәгән ат, 235 савым сыер һәм 201 - 2 яшькә кадәрге бозау, 360 сарык, 8 кәҗә, 1210 баш кош-корт һәм 368 дисәтинә коры җирләрдәге пакуслары (печәнлекләре) булган.

1921 елның 12-13 июнендә Алабуга кантон Советларының Х съезды җыелган. Анда 151 делегат катнашкан (74 - крестьяннардан, 34 - эшчеләрдән, 43 -хезмәткәрләрдән). Көн тәртибенә кергән мәсьәләләр: узган елгы иген уңмау, продразверстканы продналогка алмаштыру, кооперация оештыру, вак сәнәгатьне шәхси кулларга тапшыру. Тыныч тормышка күчү хакында да сүз барган, авыл хуҗалыгы артельләре һәм кулланучылар җәмгыятьләре турысында да сөйләшкәннәр. Бу адымнар, чыгыш ясаучылар фикеренчә, авыл хуҗалыгын алып баруны яхшырту мөмкинлеген бирәчәк, чөнки

әртилләр авыл хуҗалыгы инвентаре һәм башка кирәк-ярак белән тәэмин ителәчәк. Өяз буенча 1920 елда продразверстканың якынча 40-50 процентка гына үтәлүе күрсәтелгән (бер дисәтинәдән: азык-төлек культуралары – 7 пот, мал өчен үстерелгәннәре – 9 пот, кузаклылар һәм ярма – 7 пот, зәйтүнчәләр – 13 пот, сабан саламы – 29 кадак, арыш саламы 1 пот 30 кадак, печән 3 пот, бәрәңге – 72 кадак һәм кош-корт продукциясе – 1-2 кадак тапшырылырга тиеш булган). Разверстканың начар үтәлүе җәй коры килүе аркасында 1920 елның уңышы начар булуы белән аңлатылган.

Корылык-кытлык 1921 елда тагын да көчлерәк булган. Ул елның уңышы чәчелгән орлыкны да кайтармаган: кантон буенча уртача бер дисәтинәдән арыш 4,5 пот, солы – 6,6 пот, арпа – 7,3 пот, бодай – 6,9 пот, карабодай – 5,6 пот, борчак – 8,9 пот, тары – 6,9 пот, борай – 6,7 пот алынган. Барлык җыелган ашлыкны арышка күчереп санаганда, кантон буенча барлык уңыш 39 324 пот тәшкил иткән; ә ихтияҗ - 3 597 185 пот булган.

Ике ел рәттән кабатланган корылык бик зур мәйданнарны эштән чыгарган. Чәчелгән ашлыклар шытмаган. Шытканнары да, печәнлекләрдәге үләннәр кебек үк, көеп беткән. 1921-1922 елларда коточкыч ачлык моңа кадәр күренмәгән күләмдә ил буенча таралган. Ачлыкка каршы көрәш Советларның иң мөһим бурычы дип игълан ителгән. Бу көрәштә төрле чаралар кулланылган: халык арасында иганә җыю, җәмәгать ашханәләре ачу, ачларга ярдәм атналары үткәрү h.б. уздырылган. 1921 елның 18 һәм 21 июль декретлары белән Бөтенрусия үзәк башкарма комитеты (ВЦИК) ачларга ярдәм итү үзәк комиссиясен – Помголны оештырган. Халыкара җәмәгатьчелек, Межрабпром (эшчеләрнең халыкара комитеты), АРА (Америка ярдәм администрациясе), Кызыл Хач оешмалары да Русиягә саллы ярдәм күрсәткәннәр.

Алабуга кантоны - Татарстан республикасы - Идел-Урал җирләре хәвефле ачлык-үлем яулап алган бер генә төбәк булмаган, ләкин ачлык үзенең рәхимсез йөзен нәкъ бу территориядә коточкыч масштабларда күрсәткән дип әйтеп буладыр. 1921 елның июль азагында Татарстанда да ачларга ярдәм комиссиясе – Помголның бүлеге оештырылган. 1922 елның январенда республикада яшәүче 2,7 миллион кешенең 2,4 миллионы ачлыктан интеккән. Ачлыкка тиф эпидемиясе өстәлгән. Республика Помголы адресына илнең башка төбәкләреннән 8 миллион поттан артык азык-төлек килгән, Кызыл Хачның Русия җәмгыяте 1,3 миллион сум акча бүлеп биргән. АРАдан 3 миллион поттан артык азык-төлек (он, ярма, арыш, кукуруза) килгән. Баштарак АРА ярдәме балаларга һәм авыруларга гына тиеш булган. Алабуга кантонының волость үзәкләрендә 1922 елның январь ае башында АРА ачкан 11 ашханәдә 7700 бала тукланган.

1922 елның январь-февраль айларында кантонда ачлык куркыныч дәрәҗәгә җиткән. 1922 елның 22 февралендә Алабуга кантоны башкарма комитеты җитәкчеләре ВЦИК каршындагы ачларга ярдәм итү үзәк комиссиясенең рәисе М.И.Калининга хат белән мөрәҗәгать иткәннәр (Бу хат Алабугада чыга торган “Музейный вестник”та тулысынча басылган). Шуннан берничә өзек. “Татарстан республикасының Алабуга кантонының

168 мең дисәтинә чәчүлекләрендә үскән ашлыктан 1921 елга кадәр ел саен 2-3 миллион пот ашлык артып калып, кантоннан читкә җибәрелә иде. Элеккеге Алабуга статистика бүлеге мәгълүматларына караганда, өяздә, тулаем алганда, 1914 елда - 11 702 908 пот, 1916 елда – 11 354 505 пот һәм 1918 елда – 3 655 523 пот уңыш алынган”, - дип язган хат авторлары.

“1921 елда җәй коры килү аркасында кантон кирәк булган кадәр икмәк ала алмады дип әйтү генә аз булыр; җыелган ашлык халыкны һәм терлекләрне ашату өчен дә җитми, язын чәчү өчен орлык та юк (уҗым чәчү өчен 1921 елда кантон 170 мең потка якын орлык алды). Кантонда яшәүче 152 мең кешенең 90% ачлыктан интегә. Халык төрле суррогатларны – зирек, усак кебек агачларның кайрысын, пычкы чүбе, алабута h.б. ризык итеп куллана, ләкин бу суррогатлар да бар кешедә дә юк. Чиста икмәкне кантон халкының 1-2 процентында гына очратып була. Гомумән, кантонның хәле коточкыч, - дип билгеләгән борчулы авторлар. – Ачлыктан халык бар терлеген аяусыз бетерергә кереште; моның, әлбәттә, соңрак авыл хуҗалыгы үсешенә һәм игенчелекне күтәрүгә йогынтысы зур булачак”.

Хатка җавап булганмы, юкмы, ансы безгә билгесез. Ләкин Алабуга җитәкчелеге тасвирлаган фактлар кантонның бар авылларына да, шул исәптән Бәзәкәгә дә, хас булган. Бу ачлыкны безнең әби-бабайлар Бөек Ватан сугышы елларында исләренә еш төшерәләр иде. Ул чагында күргәннәрне сөйләп, алар үзләрен дә, безне – бала-чагаларны да тыныч ландырырга тырышалар иде. Алар сөйләгәннән минем исемдә калганнары: авыл тирәсендәге чокыр-тауларда, әрәмәдә, болыннарда ашарга ярарлык бер нәрсә дә калмаган, чөнки күп хуҗалыкларда иген бөтенләй уңмаган. Малларны ашатырлык печән-салам да булмагач, кешеләрнең күбесе көздән үк малын саткан яки суеп ашаган. Кешеләр ачлыктан кайсы бик нык ябыккан, тире белән сөяккә генә калган, кайсы-берсе, киресенчә, шешенгән. Авыл буйлап көн саен дистәләгән хәерчеләр йөргән, шуңа күрә ишек-капкаларны биклеп тотканнар. Авылда бер эт, бер мәче калмаган. Ачлыкка бик күп кешене алып киткән әллә тиф, әллә холера эпидемиясе өстәлгән. Шул эпидемия вакытында башта безнең әтинең энесе 18 яшьлек Мулламөхәммәт вафат булган. Төпчек улыннан авыру йоктырган Мәхмүт бабай да, 50 яшенә җитәр-җитмәс, якты дөнья белән хушлашкан. Әтиебез Кызыл Армиядән кайтуына (ярты ел чамасы Омск госпиталендә тиф белән көрәшеп исән калганнан соң ул 1922 елның көзендә өенә җибәрелгән), аны 1920 елда бабай салган алты почмаклы зур яңа йортта әнисе Шәмсекамал әби, абыйсы Нуриәхмәт, ике сеңлесе Нурдидә белән Минеһәдия һәм яшь җиңгәсе Фәтхия каршы алганнар.

Ачлык һәм ул алып килгән афәтләр белән көрәш мәсьәләсе 1922 елның 8-9 ноябрендә узган Алабуга кантоны Советларының XI съездында төп мәсьәлә буларак каралган. Чыгыш ясаучылар Гражданнар сугышы башыннан ук күзәтелгән чәчүлекләрнең кимүе, гомумән, крестьян хуҗалыкларының җимерелүе, эш көчләренең җитешмәве хакында сөйләгәннәр. Бу һәм башка сәбәпләр аркасында көзге һәм язгы чәчүләр вакытында 36,3% басуларның чәчелми калуын күрсәтеп, табигатьнең һәрбер бозылуы хәлне тагын да начарлату мөмкинлегенә дә басым ясаганнар. Ул чыннан да озак көттермәгән:

көзен яңгырларның булмавы, корткычларның күренә башлавы h.б. яңа ачлыкның кабатлану мөмкинлеген арттырган. Чыгышларда коточкыч мәгълүмат китерелгән. 1921 елның сентябреннән алып, бер ел эчендә кантонда 7515 өлкән кеше, 341 бала вафат булган. Ачларның саны - 380752 өлкән кеше, 299081 бала булган, ягъни нәтиҗәдә барлык өяз халкының уртача 65% тәшкил иткән. Помгол балаларны ашатуны оештырган: 1921 елның октябрендә кантонда 7600 кешелек 107 җәмәгать ашханәсе эшләгән, 1922 елның маенда 30000 кешелек 120 җәмәгать ашханәсе булган.

Алабуга кантоныннан ике мәртәбә ач балаларны төркем-төркем җыеп, кытлык булмаган төбәкләргә җибәргәннәр. 250 баладан торган беренче төркем Сәмәркандка җибәрелгән; ләкин юл шартлары бик авыр булганмы, яисә балалар ачлыктан шул кадәр өзлеккәннәрме, бары 27 бала гына билгеләнгән урынга барып җиткән. 500 баладан булган икенче төркем Киевка җибәрелгән (бу сәфәр, күрәсең, уңышлырак килеп чыккандыр – коточкыч саннар күрсәтелмәгән). Съездда китерелгән башка фактлар: Татар педагогик курсларында 1921-1922 уку елында укулар өч ай гына барган; ягарга утын, курсантларны ашатырга паеклар булмау сәбәпле укулар тукталган; укучылар хәер сорашырга мәҗбүр булган. Продналогның үтәлеше 4,5 – 14 % кына булган. 1921 елда ук эш хайваннары җитмәве бик нык сизелгән. 1922 елда хайваннарның саны тагын да кимегән; 1921 ел белән чагыштырганда, мөгезле вак терлек 58 %, мөгезле эре терлек – 32 %, эш хайваннары – 24 % ка кимегән.

Кытлык афәте ачлык булган төбәкләрдә әле үзен бик озак сиздергән. Шулай да үзәк оешмалар үз эшләрен туктаткан яки үзгәрткән. 1922 елның җәеннән АРАның ярдәм программасы туктатылган. Помгол (ачларга ярдәм комитеты) кытлык нәтиҗәләре белән көрәш комитеты (Последголод) итеп үзгәртелгән. Ачлыкка дучар булган авылларда бернәрсәсе дә калмаган халыкка күп әйбер кирәк булган: исән калганнарга ризык, ташланган җирләрне сөрү өчен эш хайваны h әм чәчү өчен орлык... 1922 елның азагына гына ачлык алып килгән афәтнең кимүе күзгә чалына башлаган.

Дәүләттән килгән ярдәмне халык арасында тарату эше белән җирле хакимият органнары шөгыльләнгән. Үзәктән нинди ярдәм килгәнен күзаллар өчен Күрәк волисполкомы протоколларына күз салыйк.

1923 елның 5 феврале. Волость авылларына авыл хуҗалыгы инвентаре h әм Последголодтан килгән лотерея билетларын тарату бара. Бәзәкә 1 сука, 15 урак h әм 102 билетка ия булган.

1923 елның 5 мае. “Икмәк булмау сәбәпле” арыш паекларын таратканнар. Волость 450 пот арыш алган (Бәзәкә h әм Турайга 70-әр пот, башка авылларга – 10 поттан 40 потка кадәр бүленгән).

Күрәк волисполком рәисенең 1923 елның 13 май утырышында ясаган чыгышыннан өзекләр: “Кытлык афәтен авыл хуҗалыгы бик авыр кичерде. Авыл халкының күпчелегенә эш атлары h әм симәнә җитми. Игенчеләргә льготалы шартларда орлык ссудасы h әм эш атларын бүлеп бирү хәлне бераз рәтләде. Атсызларның җирләрен эшкәртүне түләү хакына яки түләүсез оештыру кирәк, h әм ул мәҗбүри тәртиптә уздырылырга тиеш. Ахыр чиктә

килешү системасын куллану урын алырга тиеш. Чәчү кампаниясен уздыру белән бергә саранчага каршы кискен чараларга керешергә кирәк”. Башкарма комитетның карары: “Атсызларның җирләрен вакытлыча воскресниклар оештыру юлы белән эшкәртү өчен кискен чаралар куллану мәҗбүри”.

1923 елның 15 май утырышы. Последголод 1925 ел уңышын җыйганнан соң кайтару шарты белән ссуда итеп биргән арыш паекларын тарату. Бәзәкә 30 пот алган. Симәнә тарату.

Күргәнебезчә, үзенең дә бөтен хуҗалыгы җимерелгән, бөлгенлектә булган ил игенчеләргә күп ярдәм күрсәтә алмаган. Шулай да бу ярдәм авыл халкына исән калырга мөмкинлек биргән. Ә исән калганнар, һәр вакыттагыча, рәттән чыккан хуҗалыкларын төзәтү эшенә тотынганнар.

Яңа тормышка яраклашу

“Ата”, “ана” дидек гомер буе,
Әйтә алам менә хатасыз:
Сәбәп нидер, әллә ничек шунда -
Безнең заман ата-анасыз.
Хәсән Туфан

Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң авылга кызылармеецлар кайта башлаган. Дөнья күрергә өлгергән, чыныккан ир-егетләр туганнарын, авыл-җирне, тыныч тормышны сагынып кайткан. Авылда булган хәлләр белән бераз танышып алгач, алар, җиң сызганып, эшкә керешкәннәр. Кытлыктан җәфа чиккән, бөлгән авылда исә эшнең чиге-кырые күренмәгән: хуҗалыкларны торгызырга, атын-малын, чәчүлек симәнәсен табарга, ничә ел сука күрмәгән басуларны сукаларга... Моның өстенә авыл тәртипләренә яңалыклар кертергә – армиядән кайткан ир-егетләр эшләмичә, бу эшләрне кем эшләсен?! “Күп яшәгән күп белмәс, күпне күргән күп белер”, - дигән әйтемне тормышта кулланып, алар авыл җыенында да, картларны читкәрәк этәреп, беренче планга чыккканнар. Безнең әтиләр истәлекләреннән: бу чорда атна саен диярлек була торган җыеннарда, революциягә кадәр беркемнең башына да килә алмаган күренешне күзәтү мөмкин булган; яшьләр еш кына иске гореф-гадәтләрнең сакчысы саналган картларга каршы сүз әйтергә дә курыкмаганнар. Бетмәс-төкәнмәс яңа заман куйган мәсьәләләрне чишкәндә яшьләрнең тавышы өскә чыккан. Элеккеге кызылармеецлар авыл тормышын яңача оештырырга азапланган авыл советы эшендә дә катнашырга тырышканнар. Ләкин авыл советының эше, нигездә, волость һәм кантон башкарма комитетларыннан һәм башка совет оешмаларыннан килгән инструкция-күрсәтмәләр нигезендә алып барылганга күрә алар күп үзгәртүләр кертә алмаганнар.

Җир хакындагы декретны тормышка ашыру авылда урта хәллеләр – “средняклар” (бу атама ул чор өчен киң таралган, татарча язылган рәсми документларда да кулланылган) санын арттырырга тиеш булган. Ләкин гражданнар сугышы, продразверстка һәм кытлык авылдагы хуҗалыкларны байлыкта түгел, фәкыйрьлектә тигезләгән. Крестьян хуҗалыгын тиз арада

аякка бастыруны крестьяннар үзләре дә иң беренче булып башкарылырга тиешле зарури бурыч дип уйлаганнар. Крестьян хуҗалыгын торгызу дәүләт органнары тарафыннан да бик мөһим эш саналган, чөнки илгә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештереп тапшыручылар, алпавыт хуҗалыклары юкка чыгарылганнан соң, нәкъ менә крестьян хуҗалыгы булган. Авыл хуҗалыгын торгызу һәм ышанычлы уңыш алу өчен, совет хакимияте урнашкан чорда ук, хөкүмәт коллектив хуҗалыклар (күмәк җир эшкәртү ширкәтләре, төрле артель, кооператив, коммуна, совхозлар) оештыру максатын куйган була. Ләкин ил буенча коллектив хуҗалыклар оештырыла башласа да, авыл халкының күпчелеге аерым хуҗалык тарафдары булып кала биргән. Бу Бәзәкә активистлары алдына тагын бер зур проблеманы куйган – югарыгы органнар аларга, коллектив хуҗалыкларның үзләренә охшаган формасын сайлап алып, авылда оештырырга кушканнар.

1924 елның 21 маенда, шактый зур төркем җыелып, Бәзәкәдә “авыл хуҗалыгы продуктларын һәм үзләре ясаган әйберләрне сатуга ярдәм итү өчен авыл хуҗалыгы кооперативы” ачу хакында сөйләшкәннәр. Җыелышта авыл хуҗалыгы ширкәтен оештыру хакында карар кабул ителгән. Иллешәр тиен ширкәткә керү взносы һәм 1 сум 50 тиен күләмендә пай билгеләнгән, иң ярлыларга түләүне 2 айга кичектерергә булганнар. Кооператив идарәсенә Гәрәев Мөхәммәткәрим, Гайнуллин Хикмәтулла, Башаров Госманны, кандидат итеп Мөхәммәдьянов Ахун, Кәшфетдинов Әхкәмне; ревкомиссиягә - Ямангол ов Сәмигулла, Мөхәммәдьянов Мулланур, Ситдыйков Зиннурны һәм кандидат итеп Гобәйдуллин Зиннур, Төхвәтуллин Гатаулланы сайланганнар. Секретаре армиядән шактый “шомарып”, белем алып кайткан, рус телен (язмасын да) яхшы ук өйрәнгән Мәхмүтов Хаҗиәхмәт булган. Алабуга кооперативлар союзына әгъза булып керергә карар кылынган.

Җыелышта ширкәтнең конкрет максатларын һәм эш юнәлешләрен билгеләгән устав кабул иткәннәр. “Ширкәт үзенең максаты итеп: а) үз әгъзаларына хуҗалыкларында килеп чыккан төрле хаҗәтләрен каплау өчен натуралата кредит бирү; б) акча кертү операцияләрен киңәйтеп, халыкның эшсез яткан акчаларын туплау; в) исәп-хисапны җиңеләйтүгә ярдәм итү; г) ширкәт әгъзаларының кәсеп һәм хуҗалыкларында кирәк булган инвентарь, материаллар, чимал һәм җиһазларны алу; д) үз әгъзаларының эшләгән продукциясен сатуда арадашчылык итү; е) үз әгъзаларының җитештерү хуҗалыкларының эшен яхшырту һәм үстерү өчен төрле хуҗалык оешмалары һәм предприятиеләре оештыру; ж) җирле халык арасында авыл хуҗалыгы, кәсеп һәм кооперация хакындагы белемнәрне таратуны саный”, - дип ачыкланган ширкәтнең максатлары.

Бәзәкә авыл хуҗалыгы кооператив ширкәте 1924 елның 18 июлендә ТАССР Наркомземы каршындагы авыл хуҗалыгы һәм вак һөнәрчелеккә ярдәм итү бюросында № 408 сан астында теркәлгән. Кооператив ширкәткә 39 йорт хуҗасы нигез салган. Аларның тулы исемлеген китерәм.

Таблица № 8

Бәзәкә авыл хуҗалыгы кооператив ширкәтенә нигез салучлыр исемлеге

Исем, фамилия	Милләә -те	Парт.	Гаилә әгъз. саны	Гра-мот-ность	йорт	ат	сыер	Мал-мөлкәте бәясе
Мәхмүтов Хажи	тат	б/п	4	Грам.	1	1	1	255
Кәшфетдинов Әхтәм			3	Грам.	1	1	1	270
Серакаев Мөхәммәтзакир			2	Грам.	1	1	1	280
Мөхәммәтдинов Муфтах			7	Грам.	1	1	1	280
Гәрәев Мөхәммәткәрим			5	Грам.	1	1	1	270
Хөснетдинов Кирами			5	Грам.	1	1	1	240
Мәхмүтов Нури			4	Грам.	1	1	1	250
Гайнуллин Хикмәт			4	грам	1	1	1	260
Бәшаров Госман			4	грам	1	-	1	120
Гәрәев Габдулла			5	грам	1	1	1	200
Фазлыев Хуҗа			3	негр.	1	1	1	210
Закиров Сабир			3	Негр.	1	-	-	85
Бәшаров Гомәр			8	грам	1	-	1	90
Ямангoлов Сәлим			4	грам	1	1	1	180
Фәтхуллин Ибәт			5	грам	1	1	1	270
Галләмов Фаттах			2	грам	1	1	1	180
Шайгалләмов Закир			2	грам	1	-	1	120
Минихуҗин Мөхәммәтзакир			8	грам	1	1	1	210
Хөснетдинов Гыйлфан			6	грам	1	1	1	230
Гыйлфанов Биктимер			4	грам	1	-	-	160
Фәссахова Сара			5	н/г	1	1	1	195
Шәрәфетдинов Җәләй			4	грам	1	1	1	215
Төхвәтуллин Гатаулла			4	н/г	1	1	1	225
Гарифуллин Хикмәт			7	н/г	1	1	1	210
Әхмәдьянов Әхмәтша			2	н/г	1	-	1	130
Хуҗин Нургали			3	н/г	1	-	1	145
Шоңкаров Мулланур			4	грам	1	1	1	215
Зәйнетдинов Фаттахетдин			7	грам	1	1	1	210
Исмәгыйлов Минрахман			5	н/г	1	1	1	235
Мөхәммәдьянов Мулланур			4	грам	1	1	1	195
Галеев Багаданур			6	грам	1	-	1	215
Төхвәтуллин Гыйнният			6	грам	1	1	1	255
Ситдыйков Закир			8	грам	1	1	1	215
Гобәйдуллин Зиннур			5	н/г	1	1	1	250
Муллахмәтов Гәрәй			5	грам	1	1	1	290
Хуҗин Мингали			3	н/г	1	1	-	180
Мөхәммәдьянов Ахун			4	грам	1	1	1	300
Гобәйдуллин Нәби			3	н/г	1	-	1	130
Дәүләтшин Гәрәй			7	грам	2	1	-	220

Ширкәтне оештыручылар, күргәнебезчә, ярлы һәм урта хәлле крестьяннар булган: аерым бер хуҗалык мал-мөлкәтенең бәясе 300 сумнан артмаган. 9 хуҗалык атсыз, 5 хуҗалык сыерсыз булган. Оештыручылар арасында 28 кеше укый-яза белгән, 11 кешенең белеме булмаган. Кооперативта авыл советының тулы составы булуын да әйтеп китик. Бу аңлашыла да: югарыдан килгән әмерне алар үтәмәсә – кем үтәсен? Авыл советы рәисе Бәшаров Госманның мал-мөлкәтенә игътибар итик – ярлының да ярлысы булган икән - барлык малы 120 сумга бәяләнгән. Ә менә мал-

мөлкәте 260 сумлык булган авыл советы секретаре Гайнуллин Хикмәтне, рәис белән чагыштырганда, бай дип әйтеп тә буладыр. Оештыручылар арасында икенче мәчет мулласы Минихуҗин (Гыймранов) Мөхәммәтзакир һәм азанчысы Хөснетдинов Гыйлфан булуы да игътибарны җәлеп итә. Аларның бу яңа эшкә алынуын, беренчедән, авыл активы белән бергә булуын гына түгел, тормышны яхшы белүләрен дә күрсәтсә, икенчедән, үзләрен саклап калырга тырышу дип аңлап та булса кирәк.

Бәзәкә ширкәтенең нинди эшләр белән шөгыльләнүе хакында ширкәтнең еллык отчетыннан белеп була. Ул вакытта хуҗалык елы 1 октябрьдан башланган. Шуңа күрә отчет 1924 елның 1 октябреннән 1925 елның 1 октябренә кадәр вакытны үз эченә алган. Шул отчеттан берничә мәгълүмат. Ширкәт бакалея-мануфактура товарларын һәм авыл хуҗалыгы материалларын һәм продуктларын сату белән шөгыльләнгән. Уставы 1924 елның 18 июнендә теркәлгән, 21 июньдә эшләрен башлап җибәргән. Алабуга коопсоюзы әгъзасы. Пай взносы 1,5 сум, керү 50 тиен. Барлыгы 60 әгъзасы булган, 1500 сумга кадәр кредитлар ачылган. Ел башында 42 әгъза булган, ел дәвамында 20 кеше кергән; 2 кеше вафат булган. Әгъзаларның чәчүлек җирләре: 1-2 дисәтинә – 46 хуҗалык, 2-4 дисәтинә -12 хуҗалык, 4-8 дисәтинә – 2 хуҗалыкта булган. Атсызлар бишәү, калган 55 әгъза берәр атлы; 1 сыерлы - 33, 2 сыерлы – 22 кеше булган. Идарәдә өч түләүле әгъза, ревкомиссиядә 3 кеше, тагын 2 хезмәткәр ялланып эшләгән. Барлыгы 67 ширкәт җыелышы, 12 идарә утырышы, 3 ревизия уздырылган. Еллык әйләнеш: дебет -125879,49 сум; кредит шул ук, ел азагына – 17109,80 сум калган. Капиталлар: ел башына - 6,50 сум, керем - 712,50 сум, барлыгы ел азагына – 719 сум. Сату өчен әзерләнгән: 72,39 сумлык 75 пот арыш, 6088,25 сумлык 25055 пот печән, 4833,91 сумлык 34181 кәрҗин, 4048,80 сумлык 310200 кыршау, 4855,46 сумлык башка товарлар.

Бу саннарга карасак, ширкәт беренче елны начар эшләмәгән дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Яңа 20 әгъза керүен (ягъни оешманың составы 130 % ка үсүен) кооперативның абруе үсүен күрсәтә торган фактор дип кабул итеп була. Чәчүлек җирләренең җан башыннан (“по едокам”) бүленгәнлеген искә төшерсәк, отчетта күрсәтелгән дисәтинәләр кешенең байлыгын түгел, ә гаиләсенең зурлыгын күрсәтүен дә аңларбыз. Үрелгән кәрҗиннәр, бөгелгән кыршаулар саны ширкәт продукциясен күп күләмдә Бондюг химия заводына сату өчен әзерләвен күрсәтә.

Архивта шушы ук заманда Бәзәкә авылының халәтен сурәтләгән документ та табылды. Ул авылда тутырылган анкетаның караламасы. 1924 елда Алабуга кантоны авылларының хәлен белү өчен анкетирование уздырылган булган. Анкетада сораулар язылмаган, саннар астында җаваплар гына бирелгән. Шул җавапларны тулысынча китерәм.

“447 хуҗалык, авыл советы составында 12 кеше, партиялеләр юк.

1. Халкы 2 меңгә кадәр
2. Авыл дүрт районга бүленгән
3. 25 гомуми җыелыш, 2 авыл советы утырышы уздырылган

4. Авыл хуҗалыгы налогына һәм ссуданы кайтаруга халыкның карашы аңлы. Авыл хуҗалыгы налогы ...%, ссуда - 70 %
5. Авыл хуҗалыгы налогының әһәмияте җитәрлек аңлатылды
6. Мәктәп хезмәткәре – авыл советы әгъзасы
7. Уку йортлары (изба-читальня – А.М.) юк, мөмкинлек юк
8. –
9. Мәктәптәге балалар саны - ..., мәктәптән тыш - ..., укый-яза белмәүче зурлар 1 мең чамасы
10. Халык һәм терлекне ашату өчен ашлык яңа уңышка кадәр җитмәячәк
11. Хәзер бар кеше дә диярлек икмәкне сатып ала
12. Бала табулар артты, 5 гаилә корылды
13. Йорт хайваннары саны яшь терлек хисабына артты. Шулай ук өлешчә заводта эшләп алган өстәмә керем хисабына. Атсызлар 140 хуҗалык
14. Чәчү өчен 1500 пот чамасы сабан орлыгы кирәк, ләкин халык ссуда алудан баш тарта
15. Пожар обозының хәле яхшы, пожарлар юк
16. Бер мунчадан кала биналар страховать ителгән, ерткычлар күзгә күренеп ...(дәвамы юк – А.М.)
17. Тычкан һәм күселәр хәтта күбрәк
18. Артельләр юк
19. Тегермәннәр юк
20. Күперләр төзек түгел, юллар шулай ук, чокырларның күплеге җирне боза
21. Урман юк, әрәмә генә
22. –
23. Дин әһелләре тыныч, дингә каршы пропаганда юк
24. Комсомоллар дүртәү, ләкин иҗтимагый эшләрдә өлешчә генә катнашалар
25. Татар телен тормышка ашыру уздырылмаган
26. Допризывниклар 28, ләкин иҗтимагый эшләрдә катнашмыйлар
27. Өстәмә керем заводтан һәм үз өйләрендә кәрҗин үрүдән
28. Советка каршы чыгышлар юк
29. –
30. –
31. Техаппарат туры килә
32. Кооператив авыл хуҗалыгы азык-төлек ширкәтенең авторитеты юк
33. Чәчүлекләр һәм терлек страхованиесе бик начар
34. Кызыл Армиядән кайтучылар 7, берсе авыл советында”.

Анкета 1924 елда да кытлык елларының кайтавазлары авылда әле көчле булганлыгын күрсәтә. Аның 10-11 һәм 14-нче пунктлары бу фикерне раслый. Аларның саклануы хакында башка документлар да сөйли. Мәсәлән, волисполком протоколларында 1924 елда язгы чәчү өчен сабан ашлыгы симәнәсен бүлү хакында язылган: 1924 елның язында бәзәкәлеләргә 730 пот

солы, 10 пот арпа, 30 пот бодай, 150 пот карабодай, 40 пот борчак – барлыгы 1060 пот симәнә бүлеп бирелгән. Димәк, язгы чәчүне уздырыр өчен бәзәкәлеләрнең үз орлыклары җитәрлек булмаган. Ссуда алырга теләмәсәләр дә, алырга туры килгән. Авылдашларның ссуда алырга теләмәве авыл советының эшләрен җиренә җиткереп башкармауларын күрсәткән факт буларак кабул ителгән. Анкетаның кайбер пунктлары тутырылмыйча калуы авыл советында учет эшенең начар куелуы хакында сөйли. Авыл советының ел буена ике генә утырыш уздыруы аның эшендәге җитешсезлек саналган. Минем уйлавымча, 25 гомуми җыелыш уздырылуы бәзәкәлеләрнең артык активлыгын түгел, ә авыл советының составының йомшаклыгын күрсәтә торган факт. 1924 елның көзендә Бәзәкә авыл советына чираттагы сайлаулар узган. Сайлау нәтиҗәсендә авыл советына сайланганнар:

Башаров Госман, рәис - 1889 елда туган, үзлегеннән белем алган, ярлы, Кызыл Армиядә хезмәт итмәгән, 3-тапкыр сайланган.

Гобәев Нәби, рәис ярдәмчесе - 1882 елда туган, үзлегеннән белем алган, ярлы, Кызыл Армиядә хезмәт итмәгән, 4-тапкыр сайланган.

Стрелков Федор Афанасьевич, секретарь - 1887 елда туган, белеме уртадан түбәнерәк, ярлы, Кызыл Армиядә хезмәт итмәгән, 7-тапкыр сайланган.

Сафиуллин Хикмәтулла - 1869 елда туган, белеме юк, Кызыл Армиядә хезмәт итмәгән, 3-тапкыр сайланган.

Газизов Минәхмәт - 1886 елда туган, белеме юк, Кызыл Армиядә хезмәт иткән, 2-тапкыр сайланган.

Ишмурдин Дәүләт - 1901 елда туган, белеме юк, Кызыл Армиядә хезмәт иткән, 1-тапкыр сайланган.

Исмәгыйлев Ислам – 1898 елда туган, аз белемле, Кызыл Армиядә хезмәт иткән, 1-тапкыр сайланган.

Шәрипов Закир – 1882 елда туган, белеме юк, Кызыл Армиядә хезмәт итмәгән, 1-тапкыр сайланган.

Клячев Гатаулла – 1891 елда туган, башлангыч белемле, Кызыл Армиядә хезмәт иткән, 2-тапкыр сайланган.

Назыров Әхәт – 1901 елда туган, белеме уртадан түбәнрәк, Кызыл Армиядә хезмәт иткән, 2-тапкыр сайланган (мәктәп хезмәткәре).

Күрүебезчә, авыл советы составына, анда 1 елдан 6 елга кадәр эшләү стажы булган, тәҗрибәле кешеләр сайланган (авыл советы җитәкчелегенең яңадан тулысынча сайлануы үзе генә ни тора!). Шул ук вакытта өч кешенең беренче тапкыр сайлануын һәм биш вәкилнең Кызыл Армия сафларында хезмәт итеп кайткан кешеләр булуын авыл советының эшен активлаштыру өчен ясалган адым дип кабул итеп була.

Тагын бер мөһим документка тукталыйк. Ул бәзәкәлеләрнең 1925 елдагы икътисадый халәтен тасвирлаучы хуҗалык башлыклары исемлеге. Бу исемлектә гаиләдәге кеше саны, һәр хуҗалыкның уҗым һәм сабан ашлыгы чәчелгән җир күләме күрсәтелгән (Кушымта №). Исемлеккә барлыгы 473 хуҗалык кергән; аларда 2191 кеше (едок) яшәгән. 4281 дисәтинә җире булган авылда 1925 елда барлыгы 841,31 дисәтинә басу чәчелгән, аның 414,51

дисәтинәсендә уҗым, 426,80 дисәтинәсендә сабан ашлыгы булган. Исемлектә тагын да әһәмиятле мәгълүмат бар, ул да булса – һәр хуҗалыктагы кешеләр саны һәм чәчүлекләр күләме. Бу материаллардан кеше башына 0,19 дисәтинә уҗым һәм 0,20 дисәтинә сабан ашлыгы чәчелгәнлеге аңлашыла. Гаиләнең зурлыгына карап, хуҗалыктагы җир күләме килеп чыккан. Мәсәлән, Шәрипов Гайнетдин һәм Нәҗметдинов Низаметдин гаиләләрендә 13-әр кеше булган, аларның чәчүлекләре 4,68 дисәтинәгә җиткән. Бертуган Мәхмүтовларның хуҗалыклары бу вакытта инде аерылган булса да, чәчүлек җирләре әле бүленмәгән булган. Шуңа күрә аларны бер хуҗалык итеп санаганнар. Бу хуҗалыкта 10 кешегә 3,90 дисәтинә чәчелгән; аның 1,90 дисәтинәсенә уҗым, 2,00 дисәтинәгә сабан ашлыгы чәчелгән. Шундый ук зурлыктагы чәчүлекләр тагын 4 хуҗалыкта булган. 19 хуҗалыкта 1 кешелек норма гына чәчелгән (аларның 7-сендә 2-3 кеше күрсәтелгән булса да).

Бер фактка игътибар итик. 473-сан астында икенче мәчет мулласы Закир (Мини)Хуҗин һәм аның гаиләсендә 9 кеше булуы язылган. Шулай булуга карамастан аңа җир бирелмәгән. Искә төшерик: ике мәчетнең мулласы да Бәзәкәгә башка җирләрдән чакырылган була һәм алар Бәзәкә авыл җәмгыяте составына кермәгән. Шуңа күрә революциягә кадәр дә аларга җир бирелмәгән булган, аннан соң да, хәзер инде дин әһелләре булганга, җирләре булмаган икән. Бәлки шуңа күрә беренче мәчет муллаларын - Хәлимов Фәтхетдинне һәм Әхмәтсафа Сәйфуллинны исемлеккә дә кертеп тормаганнардыр. Ә икенче мәчет азанчысы Хөснетдинов Гыйлфанга (8 кешелек гаиләсе белән) 3,12 дисәтинә чәчүлек җирләре бирелгән. Аның улы, Хәй абый Гыйлфанов хатирәләреннән: аның әтисе мөселманча яхшы белемле указлы мулла гына булмаган, аның кешеләрне дәвалау сәләте дә булган һәм ул шәрык медицинасын да яхшы белгән. 1921-1922 еллардагы ачлык һәм эпидемия вакытында авылдашларына Гыйлфан хәзрәтнең зур ярдәме тигән; шуңа күрә бәзәкәлеләр җыеннарында аны һәм гаиләсен авыл җәмгыятенә кабул иткәннәр һәм җир дә бүлеп биргәннәр.

Шул ук 1924-1925 елларда, Татарстанда крестьян хуҗалыкларының социаль катлауларга аерылуын ачыклау максатыннан чыгып, тикшерү үткәрелгән. Аның шактый кызыклы нәтиҗәләренә тукталыр алдыннан Советлар Россиясендә җир мәсьәләсе чишелешен искә төшерик. 1918 елның 19 февралендә кабул ителгән “Җир социализациясе хакында”гы декретта, барлык җирләрне дәүләт милке дип игълан итү, бөтен халык җир фондын оештыру һәм ул җирләрне крестьяннарга файдалану өчен түләүсез тапшыру каралган була. Җирне кеше (едок-тамак) башыннан хезмәт нормасы буенча өләшү тиеш булган. Күчеш вакытына билгеләнгән хезмәт нормасы – бер тулы көчле эшче бер ат белән бер көн эчендә эшкәртә алырлык җир. Элеккеге җирне ир-ат (җан) башыннан бүлүдән хезмәт нормасы буенча бүлүгә күчү 1918 елның көзенә тәмамланырга тиеш булган. Ләкин башта сугыш, продразверстка, кытлык, ачлык, эпидемияләр, аннан соң бу афәтләр аркасында бөлгенлеккә төшкән хуҗалыкларны торгызу – болар барысы да җир мәсьәләсен тулысынча чишүне кичектергән. 1923-25 елларда икенче планга чигерелгән мәсьәлә алгы планга чыккан. Илдә җир кулланышы

хакында төгәл мәгълүмат алу өчен, авыллардан җыйган төрле материалларга өстәп, галимнәрнең тикшерүләре дә уздырыла башлаган.

“Татарстан республикасында яшәүче крестьяннар җирдән хәзергә община нигезендә файдаланучы җир җәмгыятьләренә берләшкәннәр, ягъни крестьян гаиләсе үзенә тиешле җирне, гаиләдәге кеше (тамак) саныннан чыгып, җәмгыятьтән ала”, - дип аңлатылган тикшерү материалларында. “Крестьян хуҗалыкларының тормыш рәвеше тамакка (едокка) һәм хезмәтчегә (эшче кулларга) нигезләнгән. […] Тамак крестьян хуҗалыгы продукциясен кулланучы һәм, өлешчә, хезмәт кулланышы мөмкинлекләрен (җирне) туплаучы булса, хезмәтче – продукция җитештерүче һәм үз хезмәтен куючы булып тора. […Ул] хуҗалык ресурсларын тутырырга, җыелган җитмәүчелекләрне бетерергә, яңа байлыклар тупларга тырыша. Гадәттә, хуҗалыкта хезмәтчеләр никадәр күп булса, хуҗалыкта эшләнгән эшләрнең абсолют суммасы да шул кадәр зуррак була. […] Крестьян хуҗалыгының өченче тоткасы – җир һәм җитештерү чаралары. Әгәр дә хезмәт куелмаса, алар барысы да үле капитал була”.

Революциягә кадәр төп байлык булып җир саналган, чөнки эшче куллар җитәрлек булып, алар, примитив эш кораллары кулланып та, җирне эшкәртеп бетерә алганнар. Ә эш көчләре җитмәгән хәлсезләнгән авылда җир чыннан да үле капиталга әйләнгән. Шуңа күрә тикшерүчеләр хуҗалыкларны мөлкәте буенча группаларга бүлү өчен нәкъ менә кеше ресурсын алганнар. Алар Татарстанга хас булган крестьян хуҗалыгының өч төрен күрсәткәннәр: “ярлы, шулар ук аз гаиләле; урта хәлле, уртача гаиләле һәм көчле - зур гаиләле, тамакларга да, шул ук вакытта эшчеләргә дә бай хуҗалык”. Ул чор авыл яшәеше шартларында, шулай итеп, гаиләдәге тамаклар саны хуҗалыкның төп тоткасы булган, чөнки тамак – ашаучы гына түгел, ул җир алучы да булган. Ләкин бу гына аз – хуҗалык көчле булсын өчен, тамак җир эшкәртә алырлык эшче дә булырга тиеш, чөнки гаиләсендә ун тамак, ләкин ике генә эшче булган атсыз хуҗалык үз җирен эшкәртә алмаган.

Сугыш һәм ачлыктан акрынлап мантый башлаган авылда тикшерүчеләр позитив үзгәрешләрне дә күрсәткән: авылдашларның яшь буыны, үсеп җитеп, эшкә ярый башлавы, терлекчелекнең торгызыла башлавы h.б. Тикшерү материалларында 1924 елдан 1927 елга ярлы хуҗалыкларның 10,76 % ка кимүе, аның 9,6% урта хәллеләр, 1,16% күп чәчүлеклеләр рәтенә күчүе әйтелгән. Шулай ук терлекчелектәге үзгәрешләр дә күрсәтелгән: “Атсыз һәм сыерсыз хуҗалыклар саны бөтен җирдә дә кими. Бер һәм ике атлыларның һәм сыерларның саны үсүе күзәтелә”. Бер эш атын тоту хуҗалыкка уртача 84,40 сумга төшүе дә урын алган материалларда. Тикшерү материаллары авторлары килгән нәтиҗәләр: “Барлык күзәтүләр күрсәткәнчә, төркемнәр арасында кискен аермалыклар юк. Кеше көченнән кулланучы дип үз хуҗалыкларында яллы хезмәтне киң кулланучы 0,6% хуҗалыкны гына әйтеп була. 10-16 һәм 16-дан артык дисәтинә чәчүлекләре булган соңгы ике төркем башкалардан чәчүлекләренең зурлыгы, арендагы җир алу, авыл хуҗалыгы һәм башка эшләренә ялчылар яллау белән аерыла. Татарстандагы барлык хуҗалыкларның 1,89 %-ын тәшкил иткән бу төркемнәрне кулак

хуҗалыклары төркеменә кушарга була. Ярлы хуҗалыклар республикада 49,33% дип санарга мөмкин”.

Төркемнәр арасында зур аерымлыклар булмавын Бәзәкә авыл советы җибәргән материаллар да раслый. Алардан авылда зур бай хуҗалыкларның булмавы, ә ярлы һәм урта хәлле хуҗалыклар саны, якынча, тигез булуы күзәтелә. Авыл бик зур авырлыклар белән ачлыкны җиңгән. Мәсәлән, Бәзәкә авыл советының 1925 ел 12 август протоколыннан бәзәкәлеләрнең 1922, 1923, 1924 елларда алган симәнә ссудалары өчен бурычларын әле түләп бетерә алмаулары хакында белә алабыз. Нинди байлык хакында сүз барырга мөмкин бу очракта?

Кантисполком вәкиле Бигиев 1926 елда Камай волосте авыл советлары эшчәнлеген тикшергән. Аның отчетыннан: “Бәзәкә – 495 хуҗалыклы 2298 кешеле (тамаклы) татар авылы. Авыл советының көндәлек эшчәнлеге хакында. Авыл 8 районга бүленгән һәм һәрбер районга 1 авыл советы әгъзасы беркетелгән. Авыл советы утырышы 1 тапкыр, җыелышлар 6 булган. аларда куелган мәсьәләләр: халыкара хәл, Парижская коммуна, радиоалгыч хакында, мәктәпләр төзү, советларның XV кантон съезды хакында, нәсел үгезе, күперләрне төзекләндерү һәм башкалар. Шулай ук Кредит кооперативы үзара ярдәм оешмасының эше хакында доклад тыңланган. Мәктәп хезмәткәрләре җыелышларда докладлар ясыйлар һәм актив катнашалар. Чәчү кампаниясе уздырылды. Кредит кооперативы үзара ярдәм оешмасында сортировка һәм триер бар. 1000 поттан артык симәнә сортларга аерылды, 150 пот агуланды. Агроном доклад белән чыгыш ясады, ләкин нәтиҗә юк. Авылда кооператив юк, партия һәм комсомол әгъзалары да юк. Үткән елгы авыл хуҗалыгы налогы һәм семссуда 93 % ка үтәлгән. Барлык төрле бурычлар 397 пот. Җитәкче күрсәтмәләр авыл советында бар. Эшләрнең учеты юк”. Камай волосте авыл советлары эшчәнлеге буенча нәтиҗә ясаганда, Бәзәкә авыл советын Бигиев начар эшли торган авыл советлары арасында атаган.

1926 елдан сакланган мәгълүмат бәзәкәлеләрнең тормышы яхшы якка үзгәрә башлаганлыгын күрсәтә. 1926 елның язында Бәзәкә басуларында 70 дисәтинә бодай, 150 дисәтинә солы, 20 дисәтинә арпа, 120 дисәтинә карабодай, 21 дисәтинә, тары, 3 дисәтинә ясмык, 5 дисәтинә җитен чәчелгән, 8 дисәтинә бәрәңге утыртылган. Гамәли сабан ашлыгы чәчүлекләре 397 дисәтинә тәшкил иткән. Борчак, киндер, вика чәчелергә тиешле 10 дисәтинә җир, орлык булмау сәбәпле, чәчелмичә калган. Авылдагы терлекчелекнең хәле хакында да мәгълүмат бар. 1926 елның 1 июленә авылда 3-4 яшьлек атлар 50, 4 яшьтән өлкәнерәк эш атлары 383, 1 яше тулмаган колыннар 20, 1-2 яшьлекләр 19; эре мөгезле терлек – 2 яшьтән олырак сыерлар 471, 1-2 яшьлек таналар 109, бозаулар 60, үгезләр 3; сарыклар 891, бәтиләре 170; кәҗәләр 26, бәтиләре 41 булган. 1693 баш кош-корт саналган.

Бу саннар 1926 елның җәенә бәзәкәлеләрнең хуҗалыклары шактый торгызылганлыгын дәлилли. Шулай итеп, җир турындагы декретның тормышка ашырылуы 20-еллар урталарына Бәзәкәдә урта хәлле хуҗалыклар саны артуына китергән. Моңа крестьяннарга өстәмә кәсепләр белән

шөгыльләнүне рөхсәт иткән яңа икътисадый сәясәтнең (НЭП) йогынтысы да, һичшиксез, булган. Алып-сату, җирен арендага бирү, кәрҗин-чабата үрү һ.б. шундый кәсепләрдән килгән керем, гадәти буларак, хуҗалыкларны торгызуга (ат-сыер, примитив һәм яхшырак та эш кораллары алу), 1920-1925 елларда алган ссудаларны, дәүләт һәм җирле салымнарны һәм җыелган недоимкаларны түләүгә киткән. Продразверстканы продналогка алмаштыру кытлык елларына туры килеп, аның ике тапкыр кимүе дә ул чагында артык сизелмичә генә калган; киметелгән продналог та недоимкаларны җыйган.

1923 елдан крестьяннардан җыела торган барлык җирле һәм дәүләт салымнары бер авыл хуҗалыгы налогына берләштерелгән. Аны натурлата да, акчалата да түләп булган. 1924 елның январеннән бу салым акчалата гына җыела башлаган. Берләштерелгән авыл хуҗалыгы налогына нәрсәләр кергән соң? Мисал өчен Сиракаев Закирның 1929-1930 елга билгеләнгән берләштерелгән авыл хуҗалыгы салымы кәгазенә (окладной лист) күз салыйк. Аның 1,65 дисәтинә чәчүлекләреннән 33 сум, 1,40 дисәтинә болынныннан 21,90 сум керем булырга тиеш дип хисапланган. Аты аңа 21 сумлык, сыеры 18 сумлык, 4 сарыгы 4,80 сумлык, 1 умартасы 2 сумлык керем китерергә тиеш булган. Димәк, аның хуҗалыгы, тулаем алганда, 105,50 сумлык доход китерергә тиеш булган. Моннан тыш, аның җир эшләренә карамаган кәсебе (ул 2-разрядлы патент буенча тимер-томыр әйберләре белән сату иткән) 79 сумлык дип саналган. Шулай итеп, аның еллык кереме 185 сумга җиткән. Гаиләдә ике кеше булган. Шушы саннардан чыгып, Сиракаев Закир дәүләткә 10 сум 75 тиен налог түләргә тиеш булган.

Тагын бер кызыклы документка тукталыйк. 1927/28 хуҗалык елында авыл хуҗалыгы налогын түләүче бәзәкәлеләрнең җир эшләренә карамаган кәсептән алынган керемнәре хакында анкетирование уздырылган. Шунсы кызык – керемнең күләмен волость налог комитеты билгеләгән. Барлыгы рус һәм татар телләрендә 22 тутырылган анкета сакланган. Бер анкетага алты кешедән торган балыкчылар артеле кергән. Бу артельнең килешү буенча 5 елга төзелгәнлеге, 60 сажинлык җәтмәләре булуы, балык тоту елга 9 айга җитүе дә күрсәтелгән. Еллык налог аларга 70 сум билгеләнгән.

Җир эшләренә карамаган керемнәр хакындагы анкетаны дүрт дин әһеле - муллалар Минихуҗин Закир (350 сум налог билгеләнгән), Кодрачев Латыйп (400 сум налог), Хәлимов Сафа (90 сум налог) һәм азанчы Хөснетдинов Гыйлфан (ул әле сепаратордан да керем алган, барлык налогы 180 сум билгеләнгән) тутырган. Сепаратордан керем алган өчен тагын алты бәзәкәлегә - Мөхәмәтьянов Ахун (65 сум), Нәҗметдинов Кәшфетдин (70 сум), Башаров Госман (77 сум 75 тиен), Шайгалләмов Зиннур (65 сум), Сәмигуллин Мәхмүт (40 сум) һәм Сабитов Шакирга (30 руб.) - налог билгеләнгән. Гобәйдуллин Төхбәтулла 90 сум налогны атлы яргычы өчен түләргә тиеш булган; Зәйнуллин Хуҗаәхмәткә шулай ук яргычы булган өчен 60 сум налог салынган; Хөсәенов Авзалетдингә бәйрәм көннәрендә ипи пешереп саткан өчен 50 сум налог, тегүче Ямангулов Сәлимуллага 60 сум налог куелган.

Бәзәкәдә бу чорда бер дистә чамасы алыпсатарлар да булганлыгы билгеле. Ләкин аларның берсенең дә анкетасы юк – алар сакланмаганмы, әллә аларның әле налог салырлык керемнәре булмаганмы, билгеле түгел. Сепаратор өчен налогның төрле күләмдә билгеләнүенә игътибар итик (30 сумнан 77,50 суга кадәр). Дөрес, соңгы очракта Бәшаров Госманга налог сепаратор өчен генә салынмаган дип уйлап була, чөнки Госман абзый ул чорда авыл советы рәисе буларак эш хакы алган (ул да җир эше түгел ич!). налоглар хакында сүз барганда, тагын бер искәрмә – күп хуҗалыклар налогларын вакытында түли алмаган, бурычлары җыелган. Мәсәлән, 1927 елның 1 январенә Бәзәкә буенча төзелгән недоимщиклар исемлегенә 102 кеше кергән; аларның гомуми бурычы 442 сум 48 тиен булган. Уртача санаганда, недоимщикларның һәрберсенең дәүләткә бурычы 4 сумнан аз гына артыгырак булган.

Хәзерге күзлектән караганда, бу бурычны бик кечкенә дип кабул итәргә була торгандыр, ләкин ул чорда мондый акчаны табу да бик авыр булган. Чагыштыру өчен: язгы һәм җәйге кызу эш өстендә ялланган батрак көненә 50 тиенгә, я аена 8 сумга кадәр ала алган. Менә Бәзәкә авыл советы 1925 елның 16 апрелендә төзегән батраклар хакындагы мәгълүмат: “29 яшьлек Бәхтегәрәев Шакир, Дәүләтшин Нурыйда көненә 50 тиен алып, язын-көзен эшли; 15 яшьлек Мөхәмәдьянов Хаҗи Төхвәтуллин Гаптуллада вакытлыча эшли (эш хакы төгәл билгеләнмәгән); 15 яшьлек Минигалеев Фәсыйх Серакаев Закирда вакытлыча эшли (эш хакы төгәл билгеләнмәгән); 25 яшьлек Хөсәенов Хөснетдин Садыйкова Мәгъруфада айга 8 сум алып вакытлыча эшли; 15 яшьлек Гимашев Минигәрәй Муллахмәтов Гәрәйдә вакытлыча эшли (эш хакы төгәл билгеләнмәгән)”.

Бәзәкәлеләргә электән өстәмә керем бирә торган тагын бер юл – Бондюг һәм Кокшан заводларында даими яки көнләп эшләү. Ләкин әле анда да эш рәткә салынып бетмәү сәбәпле крестьяннарның эше өчен бик аз түләгәннәр, түләүләр дә даими булмаган. Заводлардагы бу җитешсезлекләрне прокурор тикшерүе ачыклаган. Мәсәлән, 1925 елның 15 мартына Бондюг заводы 13 бәзәкәлегә 96 сум 53 тиен, Кокшан заводы 7 бәзәкәлегә 66 сум 46 тиен бурычлы булган.

1927 елның 21 октябрь карары белән бик ярлы крестьян хуҗалыклары районнардагы салым комиссияләре карары белән тулысынча яки өлешчә авыл хуҗалыгы налогын түләүдән азат ителә алганнар. Бәзәкә буенча 1927-1928 хуҗалык елына мондый ташламага 94 йорт хуҗасы дәгъва кылган. Алар арасыннан 26 дәгъва кире кагылган, 68 дәгъвачы уңай җавап алган.

Илдә барган халык хуҗалыгын торгызу эшләре җайланган саен акрынлап базар механизмы да эшли башлаган. Шәһәр кибетләренең киштәләрендә товарлар арткан. Ярмарка һәм базарлар активлашкан. Анда крестьяннар үзләре үстергән авыл хуҗалыгы продукциясенең артып калган өлешен сата алганнар. Сүз уңаеннан әйтеп китим: 1925 елның маенда Бондюг базары Бәзәкәгә күчерелгән. 1925 елның 19 маенда узган гомуми җыелыш базар көне итеп якшәмбене билгеләгән.

Бүгенге укучыга ул чордагы базар бәяләре белән танышу кызык булырга тиеш. Алабуга кантоны базарларында 1925 елда булган уртача еллык бәяләр белән танышыйк. Бәяләр потка күрсәтелгән: арыш оны 1,34 сум, солы 1,04 сум, борчак 2,16 сум, печән 0,38 сум, сыер ите 7,45 сум, атлан май 20,20 сум, сарымай 23,30 сум булган. Бәрәңгенең бәясе арыш бәясенә бәйле булып, аның өчтән берен тәшкил иткән. Красный Бор базарында көзен ат 170 сум, сыер 50 сум, сарык 8 сум торган. Бакалея товарлары бәясе (шул ук базарда): товарның күләме фунт – чирек булган; шикәрнең чиреге – 32 тиен, чәй – 4,30 сум, тоз – 2 тиен, сабын – 22 тиен, шырпы – 15 тиен пачкасы, керосин – 12 тиен литры, ситсы – 46 тиен метры, көнбагыш маеның чиреге – 35 тиен булган.

1927 елның декабрендә Бәзәкә авыл хуҗалыгы кооператив ширкәте үзенең эшчәнлеген туктаткан. 1924-1925 елларда, эшчәнлеген башлап җибәргәндә, ширкәт уңай роль уйнаган дип фаразларга буладыр. Ләкин соңрак аның эшләре аксый башлаган. Бердән, бераз тернәкләнеп алу белән, ширкәт әгъзалары, кооперативны ташлап, бар игътибарларын үз хуҗалыкларына һәм алып-сату кебек өстәмә кәсепләргә юнәлткәннәр. Аларның бергә эшләү тәҗрибәләре булмау да комачаулыклар тудырган, кредитлар да җитәрлек булмаган. Барлык бу сәбәпләр ширкәтнең таралуына китергән.

Бу елларда авылга, Кызыл Армиядә хезмәтен тәмамлап, берничә егет кайткан. Алар арасында Габдулла Төхвәтуллин дә булган. “Бу вакытта дәүләт карарларын үтәү өчен мәктәп-училищеләр бетереп кайткан кешеләр авылда юк иде, фәкать Кызыл армиядә яшьләрне тәрбияләп, аң-белем биреп кайтардылар һәм алар, укытучылар белән бергә, дәүләт карарларын үтәү өстендә эш алып бардылар. Алар авыл советы депутатлары һәм исполком членнары булдылар. 1926 нчы елда армиядән Тухбатуллин Габдулла кайтты, ул авылга нык кына яңалык кертте. Крестьяннар комитеты төзеде һәм аның председателе булды; игеннәрнең уңышын арттыру буенча халыкка белем бирә башлады (сортировка алып кайтты)”, - дип искә алган бу вакыйганы Габделхак абый Хөснетдинов (1914-2003). Бәзәкә колхозында һәм промысловый артельдә ярты гасырдан артык төрле эшләр (счетовод ярдәмчесеннән алып баш бухгалтерга кадәр) башкарган һәм авыл тормышын яхшы белгән Габделхак Гыйлфан улы язмаларын аның кызы Гүзәл Габдуллина интернетта “Бизяки.РФ” сайтына урнаштырды һәм миңа да җибәрде.

Кулакларга каршы көрәш

Чабаталы гына булсалар да,
Түзде еллар, түзде барына:
Җан күтәрмәс кимсетүләренә,
Яшәү өчен налогларына...
Харрас Әюп

1925 елның ахырында узган большевиклар партиясенең XIV съезды илдә индустриализацияләү сәясәтен игълан иткән. Фабрика-заводларны торгызу,

аларны киңәйтү һәм техник яктан яңарту белән бергә яңа сәнәгать төзелешләрен башлап җибәрү хакында карар кабул ителгән. Индустриализация һәм халык хуҗалыгын реконструкцияләү темпларын үстерү максатыннан чыгып 1928/29 – 1932/33 елларга СССР халык хуҗалыгы үсешенең беренче бишьеллык планы эшләнгән. Нәтиҗәдә индустриаль җитештерүнең географиясе үзгәрә башлаган, яңа шәһәр һәм поселоклар барлыкка килгән. Шәһәр халкы саны үсүе илдә авыл хуҗалыгы продукциясенә ихтияҗны арттырган.

Илебез икътисады аграр секторының нигезен ярымнатураль характерда булган вак крестьян хуҗалыклары тәшкил иткән. Нәкъ алар илдәге бар халыкны азык-төлек белән тәэмин итәргә тиеш булган. 1926 елда Татарстандагы чәчүлек җирләре сугышка кадәр булган чәчүлекләрдән бераз артып китсә дә, алардан җыелган гомум уңыш сугышка кадәрге уңышның 80 процентын гына тәшкил иткән. Ашлыкның товарлыклылыгы, тагын да кимрәк булып, ел саен кими барган: 1913 ел белән чагыштырганда, 1926 елда ул аның 79 %, 1927 елда – 64 %, 1928 елда – 42 % тәшкил иткән. Крестьян хуҗалыгында төп урын алып торган арыш һәм солы уңышы иң яхшы елларда да гектарына 7 центнердан артмаган. Дөрес, зуррак уңышны көтеп тә булмагандыр: уңдырышлылыгы беткән җирләрдә, шул ук сука, тырма, урак, чалгы кебек гади корал кулланып, зур уңыш алып булмый. Республикада крестьян хуҗалыкларының 20 %-ка якыны атсыз булган. Терлекчелек өлкәсенең дә продукция бирерлек мөмкинлеге бик кечкенә булган. Шулай итеп, крестьян хуҗалыклары илнең үсә торган сәнәгатен җитәрлек чимал белән, ә арта барган шәһәр халкын азык-төлек белән даими тәэмин итә алырлык дәрәҗәдә булмаган.

Димәк, илнең аграр секторын тамырдан үзгәртү икътисадый яктан зарур булган. НЭП-ка күчү программасы вак крестьян хуҗалыкларындагы җитештерүчеләрне киң кооперациягә берләштерүне дә күз алдында тоткан була; бу берләштерү нигезендә зур көчле хуҗалыклар барлыкка килеп, илне авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итәргә тиеш булган. Ләкин авылда барлыкка килә башлаган кооперациянең төрле формалары озын гомерле булып чыкмаган. Бәзәкә мисалында күренгәнчә, 1-2 ел эшләп карап, аларның күпчелеге таркала барган. Крестьяннарның күбесе дәүләт кредитлары, акча һәм орлык ссудалары, атлар һәм инвентарь алганда төрле ташламалар алу, шулай итеп үзенең бөлгенлеккә төшкән хуҗалыгын торгызу максатыннан чыгып кына кооперациягә язылган. Дәүләтнең крестьян хуҗалыкларына карата эшләнгән “кызылгвардеецлар һөҗүме”, ягъни тиз арада аларны берләштерү уңышсыз булып чыккан, чөнки бу программа эшли башласын өчен күп керемнәр һәм вакыт кирәк булган.

Көчле шәхси крестьян хуҗалыкларына терәк булу урынына хакимият авылга басым ясауга күчкән. Ул авыл хуҗалыгында җитештерү процессын һәм, бигрәк тә, ашлык һәм терлекчелек продукциясен сатуны үз контроле астына алу, азык-төлеккә даими бәяләр урнаштыру сәясәтен ешрак куллана башлаган. Табигый, крестьяннарның күпчелеге бу басымны ошатмаган, чөнки үзе тапкан малдан кеше файдасын да үзе күрергә тиешлеге алар

тарафыннан гаделлекнең бер чагылышы булып саналган. Дәүләт билгеләгән түбән сатып алу бәяләренә каршы крестьяннар икмәкне сатуны туктату-яшерү юлына, ә хөкүмәт чиктән тыш чаралар кулланып, икмәкне көчләп җыю юлына баскан. Һәм 1927-1928 елларда илдә икмәк хәзерләү кризисы барлыкка килгән.

1928 елда И.В.Сталин авылда сыйнфый көрәш көчәюе хакында игълан иткән һәм крестьяннардан бик югары салым җыю кирәклеген нигезләгән. Бу салымны җыю механизмы итеп, халыкта “кайчы” исемен алган сәнәгать товарларына югары хак һәм азык-төлеккә түбән хак билгеләп, бәяләр арасында зур аерма булдыру кулланылган. Ләкин бу адым гына җитәрлек булмаган. Авыл халкыннан ул үзе җитештергән азык-төлекне һәм җитештерү чараларын (иң элек, җирен) тартып алуның тагын бер юлы табылган. Ул *раскулачивание* - кулакларга каршы көрәш исемен алган. Бу көрәшне Совет хакимияте “хәрби коммунизм” чорында 1918 елда ук башлап җибәргән була: кулак җирләренең бер өлешен конфискацияләү белән бергә, хәлле крестьяннарга, “чит элемент” буларак, төрле чиктән тыш салымнар (контрибуция) билгеләнгән, аларның сайлау хокуклары чикләнгән h.б..

Бәзәкәлеләрнең бер өлешенең сайлау хокуклары чикләнүе хакындагы беренче мәгълүматлар статистика материалларында һәм төрле җыелыш протоколларында очрый. Мәсәлән, Алабуга өязе халкының составы хакында волостьлар буенча төзелгән мәгълүматлар арасында түбәндәге саннарга тап булдым: 1920 елның 1 январенә Бәзәкәдә 1121 ир-ат һәм 1430 хатын-кыз саналган; 90 ир-ат Кызыл Армиягә чакырылган; 1918 елгы РСФСР Конституциясенең 10 статьясы нигезендә 300 ир-ат (армиядәгеләрдән кала) һәм 374 хатын-кыз сайлау хокукына ия булган. 1921 елның көзендә авылдагы 484 хуҗалыкта 2176 кеше яшәве, аларның 691-нең сайлау хокукына ия булуы күрсәтелгән.

Крестьяннарга карата булган көчләү чаралары илдә хуҗалыклар торгызылган чорда бераз кимеп торган дип әйтеп буладыр, чөнки бөлгенлеккә төшкән авыл халкы арасында “чын кулак”ны, япа-көндез шәм кабызып эзләсәң дә, табып булды микән? Документлардан бәзәкәлеләр арасында алар күренми. Шулай да, 1926 елда 9 гаиләнең сайлау хокукы чикләнгәнен күрәбез. Алар Вәлиев Габдрахман хатыны Бәдәр һәм кызы Фәрхиҗиһан белән, Нурый һәм Гайниҗинан Дәүләтшиннар, Габдулла һәм Фәрхитҗә Кәлимуллиннар, Латыйф һәм Әсма Көдрәчовлар, Закир, Җиһан һәм Шамил Минихуҗиннар, Закир һәм Биби Серакаевлар, Сафа, Минихәят һәм Әхмәтзия Сәйфуллиннар, Гыйлфан һәм Җинан Хөснетдиновлар, Шәйгалләм һәм Әсма Шәймәрдановлар булган. Бераз соңрак аларны әле көчлерәк җәза да көткән.

20-еллар азагында, Совет хакимияте НЭП-тан баш тарту һәм тоташтан колхозлаштыруга күчкән чорда крестьяннарга басым тагын да көчәйгән. Авылларда махсус вәкилләр һәм кораллы отрядлар еш күренә башлаган. Алар крестьян хуҗалыкларының берсен дә калдырмыйча тентүләр уздырып, “артык” икмәкләрен талаган. Ашлыгын яшергән кеше очраса, аны кулак дип тапканнар, спекуляциядә гаепләп, хөкемгә тартканнар, барлык мал-мөлкәтен,

терлеген, инвентарен конфискацияләгәннәр. Гомумән, 1914-1922 еллар фаҗигасыннан соң яңа гына аягына баса башлаган крестьяннарны алда шуннан да ким булмаган авырлыклар көткән икән. Совет хакимияте аерым крестьян хуҗалыгын изү, җимерү юлына баскан.

Габделхак абый Хөснетдинов истәлекләреннән бер өзек: “Совет дәүләтенең 1924-25 елдан башлап авыл хуҗалыгын үзгәртеп кору турында бер-бер артлы төрле карарлары чыкты, крестьян комитетлары төзелде, крестьяннарны берләштереп эшләтү өчен колхозлар-совхозлар төзү турында сүзләр алып бара башланды. Ул гомер-гомер буена бер формада яшәп килгән крестьяннарның тормышын һәм культурасын җимерде, дини бәйрәмнәрен генә түгел, милли бәйрәмнәреннән дә мәхрүм итте”, - дип язган ул бу еллар турында.

1928 ел башында барлык республика һәм өлкәләргә илдә икмәк хәзерләүнең катгый планы таратылган. Крестьяннар икмәкне юк бәягә дәүләткә тапшырудан баш тартсалар, аларның бу адымы “саботаж” исемен алган, үзләре хөкемгә тартылган, табылган ашлыклары конфискацияләнгән. 1928 елның январь-февралендә генә дә Татарстанда саботаж өчен 533 кеше хөкем ителгән. Конфискациягә эләккән икмәкнең чиреген ярлыларга өләшкәннәр. Шулай итеп ярлылар һәм хәллерәк крестьяннар арасында дошманлык мөнәсәбәтләре тууга өстәмә сәбәп барлыкка килгән. Кулга алыну куркынычы һәм ешая барган кулга алулар, икмәк тапшырудан баш тартучыларны сайлау хокукларыннан мәхрүм итү, халыкка башка төрле басым ясау алымнары крестьяннарны колхозларга берләшүгә этәрергә тиеш булган. Шуны да ассызыкларга кирәк, бу очракта кулаклар һәм дин әһелләре генә түгел, урта хәллеләр дә, хәтта ярлылар да репрессияләрнең төрле формаларына тартылган.

“Шулай ук, Габдулла Тухбатуллин республиканың төрле урыннарында коллективизация булуын һәм бездә дә булачагын халыкка аңлата башлады, - дип искә алган Габделхак абый. - Бу аңлату халыкка ошамады, бигрәк тә авыл куштаннарына, һәм алар аңа каршы килә башладылар. Тора-бара 1929 нчы елның август аенда 7 кешене Тухбатуллинга ияртеп кулга алдылар”.

Бу кулга алулар хакында архив материаллары да сакланган. Бәзәкәдә бу вакыйга 1929 елның 28 октябрендә булган. Кулга алынганнар: Гайнетдинов Гариф Таҗетдин улы, 1894 елда туган, единоличник, Гобәйдуллин Гомәр, 1898 елда туган, единоличник, Гәрәев Кәрим, 1907 елда туган, единоличник, Дәүләтшин Нурый, 1878 елда туган, таза тормышлы крестьян, сәүдәгәр, Төхвәтуллин Габдулла, 1902 елда туган, единоличник, урта хәлле, крестьян комитеты рәисе, Шәяхмәтов Ясәви, 1887 елда туган, единоличник, урта хәлле, плотник, Шәймәрданов Шәйгардан, 1875 елда туган, крестьян, элеккеге сәүдәгәр. Бераз соңрак, 1929 елның 10 декабрендә, Габделхак абыйның әтисе, Хөснетдинов Гыйлфан (1876 елда туган, единоличник, азанчы) да кулга алынган.

Аларны Казанда ТАССРның ОГПУ каршындагы “өчлек” хөкем иткән (өчлеккә хакимиятнең өч тармагы - партия, советлар һәм хөкем органнарының вәкилләре кергән). 1930 елның 21 январендә бәзәкәлеләрдән

ике кеше - Төхвәтуллин Габдулла һәм Дәүләтшин Нурый – “колхоз оештыруга һәм икмәк хәзерләүгә каршылык күрсәткән өчен” мәгънәле 58-11 маддә буенча иң югары җәзага һәм мал-мөлкәтен конфискацияләүгә хөкем ителгәннәр; алар Казанда 1930 елда атылганнар. Тагын ике кеше - Хөснетдинов Гыйлфан һәм Шәймәрданов Шәйгардан – “Совет хакимияте чараларына каршы агитация алып барган өчен” шул ук 58-11 маддә буенча 1930 елның 5 февралендә Северный крайга сөргенгә һәм мал-мөлкәтен конфискацияләүгә хөкем ителгән. Калган дүрт кеше шул ук маддә буенча өч елга концлагерьга җибәрелгән.

Бу фаҗигага тарыган кешеләр арасында “кулак” исеме йөртерлек кешеләр булды микән? Хәер, аларның барысының да 58-11 маддә белән гаепләнүе гаепләнүченең социаль йөзе мөһим булмавын күрсәтә. Җәзалары төрле булса да, алар барысы да сәяси корбаннар. Беренче чиратта, 28 яшьлек Габдулла Төхвәтуллинның язмышы тетрәндерә. Кызыл Армиядән аң-белем җыеп кайткан, крестьян комитетын оештырган актив егетнең “колхозларга каршы агитация алып баруы” булды микән? Минем фикеремчә, Габдулланың актив эшчәнлеген ошатмаган авыл куштаннары аңа яла яккан булырга тиеш. Габделхак абый язмаларыннан да шундый нәтиҗәгә килеп була.

1930 елның январендә ВКП(б)ның ҮК кулакларга каршы көрәшне көчәйтү хакында ике махсус карар кабул иткән. Шулар нигезендә 16 февральдә “Татарстанда кулакларны сыйныф буларак юк итү” исемле ТАССРның ЦИК һәм СНК карары барлыкка килгән. Бу карар буенча Татарстанда җир арендасы һәм яллы хезмәт куллану тыелган, җирле органнарга кулакларның милкен конфискацияләү хокукы бирелгән. Кулак хуҗалыкларын өч төркемгә бүлү каралган. Беренче төркемгә советларга һәм революциягә каршы актив көрәшүчеләрне кертү һәм аларга карата иң каты репрессив чаралар (ату, төрмәләргә һәм концлагерьләргә ябу, махсус оештырылган спецпоселениеләргә сөрү, барлык милкен тартып алу һ.б.) куллану билгеләнгән. Икенче төркемгә икътисадый яктан көчле кулак хуҗалыкларын һәм беренче категория буенча хөкем ителгәннәрнең гаиләләре кергән. Аларга карата җитештерү чараларын тартып алу (конфискация) һәм илнең ерак районнарына (Себер, Соловки, Казахстан һ.б.) сөрү каралган була. Кулакларның иң күп өлеше (75-80%) – Совет хакимиятенә каршы актив чыкмаучылар, ләкин яллы хезмәттән файдаланучылар, вак җитештерү һәм сәүдә белән шөгыльләнүчеләр – өченче төркемне тәшкил иткәннәр. Бу төркемдәгеләрне шул ук төбәкләрдә, гадәти буларак, начаррак җирләргә күчерү каралган була. Шушы кагыйдәләр көчләп күмәкләштерүгә нигез булган.

Күмәкләштерүдәге уңыш һәм уңышсызлыклар, бөтен илдәге кебек, Алабуга районы авылларында да кулакларга каршы көрәш кампанияләре белән бергә үрелеп барган. Бәзәкәдә мәсьәлә ничегрәк чишелгән соң? Безнең көннәргә килеп җиткән чыганаклар буенча бу мәсьәләгә дә ачыклык кертеп карыйк. Барлык җирләрдәге кебек, Бәзәкәдә дә ул совет һәм партия оешмалары катнашы белән иҗтимагый хәрәкәт төсендә барган. Теге яки бу кешене “кулаклар” исемлегенә кертеп җәзага тарту, гадәти буларак, авыл

активы яки “авыл өчлеге” (партия, колхоз һәм авыл вәкилләреннән торган төркем) җыелышларында каралган. Күпме кешене “кулак” дип танырга тиешлеге хакында контроль саннар “югарыдан” төшерелгән. Әле 1930 елда ук ВКП(б)ның Татар обкомы бюросы барлык өч категория кулаклар санын республика өчен чагыштырмача 4 % дип билгеләп куйган була (искә төшерик әле: 1927 елда республикада крестьян хуҗалыклары хәлен өйрәнгән комиссия Татарстанда бары тик 2,4 % хуҗалыкларны кулак хуҗалыгы һәм, аның 0,6 % гына эксплуататор сыйныфына кертеп була дип нәтиҗә ясаган иде).

Обком бюросының бу карары өстәмә күрсәтмәләр белән “яшерен” грифы астында төбәкләргә җибәрелгән. Күрсәтмәләрдә авыл һәм волость советларына авылдан күчерелергә тиешле кулак хуҗалыклары исемлеген (гаиләдәге бар кешене язып) 1930 елның 10 мартына тәмамларга дигән боерык та булган. Мәскәү – Казан – Алабуга – Камай баскычларын узып, Бәзәкәгә килеп җиткән бу катгый боерыкны үтәү өчен авыл советы активына авылдагы кулакларны табарга кирәк була (ә план һичшиксез үтәлергә тиеш). Әти сөйләвенчә, озак баш ватканнан соң (авылда “чын кулак” дип атарлык кеше дә юк дәрәҗәсендә), алар, иң йомшак җәза бирә торган өченче категориягә кертеп, “хокукларыннан мәхрүм ителгәннәр” исемлеген күчереп бирергә булганнар. Шулай итеп авыл советы активы үз авылдашларын авыр җәзадан йолып калырга тырышкан, чөнки моның дәвамы авылдан куылу, сөргенгә җибәрелү кебек җәзалар булуы һәркемгә аңлашылган. Исемлекләргә кергәннәр үз хокукларын кайтару өчен төрле партия һәм дәүләт оешмаларының бусагасын таптаган, ә инде дөреслек табуга ышанмаганнар кулга алынганчы авылдан күчеп китү ягын караган.

Архивта эзләнгәндә, миңа берничә саллы папкага җыелган Алабуга кантоны буенча “хокукларыннан мәхрүм ителгән гражданнарның” үтенечләре һәм шикаятьләре һәм алар буенча кабул ителгән карарлар белән танышырга туры килде. Шулардан бәзәкәлеләргә бәйле ике-өч фактны гына китерәм. Аңлашылмаучылык килеп чыкмасын өчен документларда Яр Чаллы кантоны исеме күрсәтелүен әйтергә кирәк, чөнки бу чорда Камай волосте Яр Чаллы кантонына күчерелгән булган. Беренче факт Сиракаев Закирга бәйле. Яр Чаллы кантоны башкарма комитеты президиумы 1930 елның 19 апрель утырышында аның үтенечен тикшергән. Шул утырыш протоколыннан өземтә: “Тыңланды: Бәзәкә гражданины 1873 елда туган Сиракаев Закирның үтенече. Гаиләсе бар – 50 яшьлек хатыны. Сату иткән өчен айлау хокукыннан мәхрүм ителгән. Революциягә кадәр һәм аннан соң да даими рәвештә тимер-томыр товарлары белән 2-разряд патенты буенча сату иткән. Даими рәвештә батраклар хезмәтеннән файдаланган, моның өстенә сезонникларны яллаган. Совет хакимиятенең барлык чараларына дошманнарча караган. Совет хезмәткәрләренә каршы агитация алып бара. Ярлылар һәм урта хәллеләр җыелышында кабул ителгән карар нигезендә раскулачить итәргә.

Карар: Мал-мөлкәте 1427 сумлык алынган, кулак, 3-категория буенча җәза бирергә”. Сиракаев Закир җиңел котылган дип әйтеп була, чөнки өченче категория буенча, еракка җибәрмичә, үз төбәгендә генә калдырылган.

Икенче факт Кәлимуллин Габдуллага кагыла. Аның үтенечен шул ук оешма 1930 елның 23 июнендә тикшергән. Утырыш протоколыннан өземтә: “Тыңланды: Бәзәкә авылы гражданины, 1874 елда туган Кәлимуллин Габдулланың үтенече. Кулак, 3-категориягә кергән. Элек аяк киеме һәм бакалея белән 2-разряд патенты буенча сату итүче буларак, 1925 елда сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән. Совет хакимиятенең барлык чараларына дошманнарча караган. Даими батрак тоткан. 616 сумлык мал-мөлкәте тартып алынган. Карар: Үтенечен кире кагарга, раскулачиваниене расларга”. Папкада башка документлар да бар. Мәсәлән, Кәлимуллин Габдулла аны уңай тасвирлаган татарча язылган Бәзәкә авыл советы белешмәсен тапшырган: “Бу белешмә биреләдер Чаллы кантоны Камай вулысы Бәзәкә авыл гражданы Кәлимуллин Гаптуллага аның өчен дөреслектә ул һәр вакытта үзенә тиешле булган салымнарны 100% белән түләп барды һәм төрле заготовка шикелле кампанияләрдә аяк чалу эше сизелмәде. Хөкүмәткә ышанычлыклы кеше икәнлеге күрсәтеп биреләдер.

Бәзәкә авыл советы рәисе – Гыйззәтуллин.

Язучы Мәхмүтов”.

Кәлимуллин тапшырган икенче документның рус теленнән тәрҗемәсе: “Моны тапшыручы Кәлимуллин Гаптулла Госторгның Әгерҗе хәзерләү пункты өчен утильтовар (крестьян хуҗалыкларының төрле калдыкларын) җыючы булып тора һәм […] (сүзләр аңлашылмый – А.М.) нигезендә калдыкларны патент алмыйча гына саф акчага җыю хокукына ия. Гр. Кәлимуллин Госторг хезмәтендә саналмый”. Болардан тыш тагын бер язма – Кәлимуллинның гарәп графикасында язылган үз аңлатма-үтенече дә бар. Ул анда, үзенең 10 тамактан торган зур гаиләсе булуын аңлатып, тормышында күргән барлык авырлык-михнәтләрне җентекләп язган. Аның документлары белән танышканда, безнең алга иртә таңнан төнгә кадәр җигелеп эшләүче авыл ире килеп баса. 1925 елгы исемлектә бу гаиләдә 8 тамак – хатыны һәм алты кызы булуы күрсәтелгән; ике улы соңрак - 1926 һәм 1928 елларда туган. Бу ишле гаиләне туендырырга-киендерергә, бер-бер артлы туган алты кызның киләчәге хакында да уйларга (кияүгә биргәндә дә кеше алдында хур булмаска) кирәк. Төрле салымнарны да түләргә кирәк.

Тормышының очын-очка бәйләр өчен Габдулла абзый алып сату эшенә керешкән (гаепләмәдә яңгырый торган “обувь”, “бакалея” сүзләренең бергә килүе – революциягә кадәр дә, аннан соң да – ул, гамәлдә, алыпсатар товары – кулдан тегелгән чүәк-кәвеш, очсыз кәнфит-прәннек кенә булуын, шулай да ачтан үлмәслек керем китерүен күрсәтә). 1925 елда “лишенецлар” исемлегенә кертелгәч, сату эшен ташлап, авыл хуҗалыгы калдыкларын җыюга тотынуы да аның теше-тырнагы белән аягына басарга тырышуын күрсәтә. Кызлар кул астына керә башласалар да, хуҗалык эшләрендә ирләр көче дә кирәк шул – батрак та кирәк, кызу эш өстендә көннекчеләр ялламыйча да булмый. Аның конфискациягә эләккән (талап алынган) бар байлыгының гомуми бәясе 616 сум булуын да искә төшерергә бик вакыт. Кайсы яктан карасаң да, бу суммага, бай (кулак) исемен алу өчен бик күпне өстәргә кирәк булыр иде. Габдулла абзыйны бер дә, кеше хезмәтен кулланып, симереп ятучы

“канэчкеч” итеп күзаллап булмас иде. Ләкин карар кабул итүчеләр бернәрсәне дә игътибарга алмаганнар, хәтта авыл советы биргән уңай характеристикага да карамаганнар.

Әти сөйләвенчә, мондый уңай белешмәләр биргән өчен аларның үзләренә дә зур куркыныч янаган. “Югарыдагылардан “кулакларны һәм башка совет власте дошманнарын яклыйсыз яки яшерәсез”, - дигән шелтә сүзләрен генә ишетеп калсак, әле бер хәл. Төрмәгә дип авылдан алып китүләр, кулга алулар, сөргенгә җибәрү белән куркытулар – болардан беребез дә – авыл советы активы да, авылның иң абруйлы картлары да - читтә кала алмадык. Шулай да булдыра алган кадәр авылдашларга ярдәм итәргә тырыштык”, - дип искә ала иде ул.

Авыл активистларына “өстәгеләр”дән генә куркыныч янамаган, авылдашлардан да һөҗүм итүләр булган. Г. Хөснетдинов үз язмаларында шундый берничә фактны китергән: “Авылның кайбер кешеләренә тагын йөрәк керде, колхозга кертүдә эшләгән авыл советы членнарыннан h.б. ачу алуны күздә тоталар. Нәтиҗәдә, 1930 ел апрель азагында сал эшләгәндә эшләгән җирендә авыл советы исполком члены Садриев Миннәхмәтне вәхшиләрчә балта белән чабып үтерәләр. Бәшаров Госманга дә куркыныч туа башлый, аны якын дуслары Иж заводына төнлә белән алып чыгып китәләр. Көз, ноябрь айларында (25 ендә) кич сәгать 9-10 да авыл советына Шәрифуллин Габденурны чакыралар. Ике чакыруга ул килми. Өченче чакыруда төшә; кайту уңаенда тау төшкәндә Хуҗәхмәт сушилкасында тотып алалар һәм буып үтереп, авылдан 3 км ераклыкта имән агачына илтеп асып куялар. 1931 ел сентябрь азагында төрмәдән качып кайткан Гимазтинов Г-ны тотарга төшкәч Гимазтинов Салах белән икебезгә аттылар. Бу турда гаепле кеше ачыкланмады...”.

1931 елның көзендә безнең әтигә дә һөҗүм булган. Әтиебез, авыл советы секретаре Мәхмүтов Хаҗи, гадәттәгечә, өйдә кич белән (дөресерәге, төнгә кадәр) төрле кәгазьләр белән утырганда, аңа тәрәзә аша мылтыктан атканнар. Ләкин, ни сәбәпледер, пуля аңа тимәгән, матчага кереп калган. Мин үскәндә, безнең иске өйнең алгы як матчасында ул пуля бар иде әле. Шул вакыттан калган әтинең гадәте – лампа кабызгач та, ул тәрәзә пәрдәләрен бик пөхтә итеп тартып куя иде.

Габделхак абый Бәшаров Госманга дә куркыныч туа башлавы хакында язган. Бу аңлашыла да, чөнки Госман абзый берничә ел авыл советы рәисе вазыйфаларын үтәгән, 1926 елда Татарстанның алтынчы чакырылыш эшче, крестьян һәм кызылармеец депутатлары советларының үзәк башкарма комитеты әгъзасы итеп сайланган булган. 1927 елдан ул Камай волосте башкарма комитеты рәисе итеп сайланган, Камай волостендә авыл хуҗалыгы әртилләрен оештыру өчен җаваплы булган. Аннан соң тагын Бәзәкә авыл советы рәисе итеп сайланган.

1931 елның 15 апрелендә Бәзәкәдә кулакларга каршы көрәшнең икенче дулкыны башланган. Бу көнне гаиләләре белән бергә Вәлиев Габдрахман (1865 елгы), Гатауллин Минимөхәмәт (1905 елгы), Кәлимуллин Габдулла (1874 елгы), Муллахмәтов Гәрәй (1889 елгы), Рамазанов Минhаҗ (1865

елгы), Сәйфуллин Сафа (1884 елгы), Төхвәтуллин Сәлим (1906 елгы), Төхвәтуллин Сөнгать (1886 елгы), Хөсәинов Афзалетдин (1876 елгы), Шәйгалләмов Фәттах (1892 елгы) авылдан алып кителгәннәр. 1932 елның 10 маенда кулга алулар дәвам иткән - бу юлы Төхвәтуллин Гатаулла (1892 елгы), Хуҗин Нурый (1906 елгы), Шәяхмәтов Әхмәтсахиб (1862 елгы), Шәйдәүләтов Шәйми (1901 елгы) кулга алынганнар. Аларның барысы да ТАССРның ГПУ каршындагы "өчлеге" тарафыннан 1931 елның 22 августында һәм 1932 елның 21 сентябрендә "кулак - дини төркем әгъзалары" буларак "колхозга каршы һәм дини агитация" алып баруда гаепләнеп, 58-11, 58-10 маддәләр буенча хөкем ителгәннәр. Аларның барлык мал-мөлкәтен тартып алып, гаиләләре белән Урал өлкәсендәге зур төзелешләр тирәсендә барлыкка килгән махсус лагерьләргә озатканнар.

Крестьяннарның Себер сөргенен махсус өйрәнгән С.А.Красильников: "Бу сөрген гадәти сөрген булмыйча, административ сөрген булган, чөнки репрессияләр бөтен гаиләгә (имчәк баладан картларга кадәр) кагылган, мәҗбүри эш белән бергә барган (моңа кадәр сөрген хөкем җәзасы гына булган) һәм вакыты билгеләнмәгән (моңа кадәр сөргеннең бер төре дә ун елдан артмаган)", - дип бәяләгән.

Раскулачивание һәм махсус лагерьләргә сөрү махсус план һәм разнарядкалар буенча эшләнгән. Мәсәлән, Татарстанның җәза органнары Урал өлкәсен очсыз эш көчләре белән тәэмин итәргә тиеш булган (Татарстаннан сөрелгәннәрнең иң кимендә өчтән бере шунда җибәрелгән). Иң элек алар күпләп җибәрелгән Магнитканы әйтергә кирәк (монда завод һәм шәһәр төзелеше 1929 елның июнендә башланган). "1931 елның язына Магниткада киң күләмдә җир казу һәм бетон кою эшләре башланды, - дип яза Магнитка сөргенен өйрәнүче галим С. Әхмәтҗанов. – Шул максаттан чыгып, 1931 елның 25 апрелендә ВКП(б) Үзәк комитеты Политбюросының "Магнитогорск һәм Кузнецк заводларын вакытында сафка кертү өчен кадрларны хәзерләү" хакындагы карары дөнья күрә. […] Бу карарга өстәп, һичшиксез, җирле партия органнарына һәм ОГПУга раскулачиваниене киңәйтү һәм кулак (крестьян) гаиләләрен күпләп Магнитка төзелешенә җибәрү хакында яшерен күрсәтмәләр булгандыр".

Чыннан да, 1931-1932 елларда сөрелгән бәзәкәлеләрнең күпчелеге гаиләләре белән Магниткага эләккән. Менә берничә факт. Гәрәй Мулләхмәтов белән бергә Магниткага аның хатыны Кадерле (1899 елда туган), уллары 1915 елгы Мәхмүт һәм 1930 елгы Зиннур, кызлары 1914 елгы Хәдичә, 1920 елгы Фәтхия, 1924 елгы Мәдинә һәм 1928 елгы Нажия эләккәннәр (Кадерле - Әминә апа Бәдертдинованың әнисе; аны, ире үлгәннән соң, дүрт бала белән тол калган Гәрәйгә кияүгә биргәннәр; әнисе янына сыймаган кечкенә Әминә әнисенең абзасы Кәшфетдин карамагында үскән). Элегерәк сүз булган Кәлимуллин Габдулла белән бергә аның 1877 елда туган хатыны Фәрхитҗә, кызлары 1915 елгы Хатирә һәм 1918 елгы Зәйтунә, кечкенә уллары 1926 елгы Габделхәй һәм 1928 елгы Сәетҗан шулай ук Магниткага сөрелгәннәр. Аның олы кызлары, бу вакытта инде кияүдә булып, сөргеннән котылып калган.

Административ басым, колхозга каршы хәрәкәт белән көрәш, һичшиксез, үз нәтиҗәләрен бирмичә калмаган. Ләкин мондый сәясәт крестьяннарны да каршы торуның төрле формаларын эзләргә мәҗбүр иткән. Әти сөйләгәннәрдән: ул чорда авылда булган терлекне бетерү (хәтта атларны да), мал-мөлкәтен сатып яисә ташлап калдырып, гаиләсе белән авылдан китү очраклары бик еш булган. Ә китә торган җир ул чорда күп булган – кая карама, төзелеш бара, гади эшче кая да җитмәгән. Шәһәрләрдә дә, эшчеләр поселокларында да, завод-фабрикаларда һәм төзелешләрдә – бөтен җирдә эш көчләре кирәк булган. Ләкин крестьяннарның колхозлаштыруга һәм раскулачиваниегә каршы торуларының бу формасы озакка сузылмаган. 1932 елда илдә катгый паспорт системасы кертелгән; паспортлары кулларына бирелмәгән крестьяннар тулаем үз хуҗалыкларына беркетелеп калган.

Бәзәкәлеләрне кулаклар сыйныфына кертү һәм хөкемгә тарту 1933 елда да дәвам иткән. Менә гаиләсе белән волостька озатылган бәзәкәле Хатруллин (бәлки фамилиясе ялгыш язылгандыр – ул Хәйбуллин булырга мөмкин, чөнки Хатруллин фамилиясе бәзәкәлеләрнең бер исемлегендә дә очрамады) Хикмәткә русча язылган характеристиканың тәрҗемәсе: “1883 елда туган Бәзәкә авылы кешесе, революциягә кадәр игенчелек белән шөгыльләнгән, 1 өе, 2 ат абзары, 1 амбары, 1 мунчасы һәм каралты-курасы булган; иске армиядә хезмәт итмәгән. Революциядән соң шулай ук игенчелек белән шөгыльләнгән, күрсәтелгән хуҗалыгы һәм малы булган; чәчүлек җире 7 га, 1930 елда 2 га басу һәм 5 га болынны арендага алган; яллы хезмәттән даими кулланмаган, кызу эш өстендә 5 кә кадәр көннекчеләр яллаган. 25 умарта тоткан. Кызыл Армиядә хезмәттә булмаган, раскулачиваниегә һәм читкә җибәрүгә эләкмәгән.

1931 елда аның хуҗалыгы хәлле хуҗалыклар исемлегенә кертелгән һәм аңа үзгәрми торган йөкләмә һәм шәхси салым билгеләнгән. 1931 елда дәүләт йөкләмәсен үтәмәгән өчен 18 айга хөкем ителгән, ләкин Татарстан республикасы суды белән бу хөкем юкка чыгарылган. 1933 елга аның сабан җире 1,38 га, аның 0,50 гектарына бодай чәчелергә тиеш, 0,75 кг орлык кирәк булачак. Солы - 0,13 га, 0,20 кг орлык; борай - 0,20 га, 0,30 кг орлык; тары - 0,25 га, 0,8 кг орлык; бәрәңге - 0,30 га, 41,20 кг орлык кирәк булачак.

Хәзерге вакытта тикшергәндә 28 кг төрле ашлык орлыгы, 100 кг бәрәңгесе барлыгы билгеле булды; ашлыкның 60 % гына сортларга аерылган, тирес чыгарылмаган, көлне хәзерләмәгән, авыл хуҗалыгы инвентаре төзәтелмәгән. Ит тапшыру буенча план үтәлмәгән. Кулак буларак колхозга каршы сыйнфый куркыныч элемент.

1933 елның 13 апреле.

Авыл советы председателе Гыймазетдинов

Колхоз председателе Исмәгыйлов

Актив Галеев, Гизатуллин

Секретарь ...”.

Күрүебезчә, бу характеристика Хатруллинга авыл советы тарафыннан бирелгән. Папкадагы башка документларыннан без бу гаиләдә 5 кеше булуын, хуҗаның үзеннән башка 1884 елгы хатыны Баял, ике улы – 1913 елгы

Гали һәм 1918 елгы Нәгыйм, 1923 елгы кызы Рәбига булганлыгын беләбез. Тагын бер мәгълүматка игътибар итик: “1932 елга кадәр хуҗалык хәлле саналган, акланганнан соң хәзерге вакытта урта хәлле санала”. Документлардан күренгәнчә, бу гаилә “артык орлык”ны яшергән һәм шуңа күрә репрессиягә эләккән булып чыга. Авылдан алып киткәннән соң, аларның язмышы нинди булгандыр, мин белә алмадым. “Хәтер китабы”нда Хатруллин да, Хәйбуллин да юк...

Габделхак абый язмаларыннан: “Бу вакытта авылда 598 хуҗалык була, болардан: 6 хуҗалык - Магнитогорскига җибәрелә, 6 хуҗалык - үзләрен чыгарып җибәрәләр авылдан, 12 хуҗалык – Тихигора артеленә барып керә, 3 хуҗалык – Алабуга маслотрест заводына китәләр, 2 хуҗалык – Монай колхозына керәләр”. Монда әйтелгән беренче 12 хуҗалык раскулачиваниегә эләккән, соңгы 17 хуҗалык, репрессияне көтеп тормыйча, үзләре авылны ташлап китүчеләр булган дип бәяләргә була.

Колхозлаштыру

Башлап кемнәр
төпкә җигелгән дә,
Кемнәр утка кергән,
кемнәр бөгелгән...
Акыл белән бәя бирер өчен,
Без әзерме әле бүгеннән?

Марсель Галиев

60-елларның беренче яртысында минем Казан университетының тарих-филология факультетында читтән торып укып йөргән чагым. Ә бу Сталин культын фаш итә башлаган, илебезнең тарихын өйрәнүдә яңа юллар эзләгән чор. Миңа Татарстан тарихыннан контроль эш язып тапшырырга кирәк иде. Мин, авылларны колхозлаштыру темасын алып, эшемә әтиемнең истәлекләрен дә кертергә булдым. Әти – Мәхмүтов Хаҗиәхмәт (1900-1980) өч ел Кызыл Армия сафларында гражданнар сугышында катнашкан, авылга кайткач, күп эшләрдә үзен актив күрсәткән, 1927-1937 елларда авыл советы секретаре булган кеше. Димәк, ул елларда булган хәлләрне ул бик яхшы белә. Дөрес, ул үткәннәр хакында сөйләргә яратмый, ләкин, университеттан шундый бирем бирделәр дигәч, ризалашты.

Әтинең шул вакытта сөйләгәннәреннән берничә өзекне монда да кулланырга булдым. “Мин ул елларда авыл советы секретаре булып эшли идем. Алабугадан көн саен катгый рәвештә авылда колхоз оештыруны таләп итәләр. 1930 елда көн саен диярлек волость, кантон кешеләре килеп, җыеннар уздыра, бәзәкәлеләрне колхоз оештырырга үгетли. Ә безнең бәзәкәлеләрне үгетләп кенә колхозга кертеп буламы соң? Беркемнең дә ата-бабалары мирасы булган үз җире белән аерыласы килми. Безгә ярдәмгә Мәскәүдән килгән “егермебишмеңче” Кондаков Әхмәтҗан исемле кешене китерделәр. Нинаять, без авыл активыннан 10-15 кеше җыелып, колхоз оештырдык”.

Тагын бер истәлек: “1929-нчы елның азагында, 1930 нчы елның башында колхозга берләштерү буенча бездә дә эш башланды, - дип язган Габделхак абый Хөснетдинов. - Безгә Мәскәүдән 25 меңчеләрдән *(двадцати пятитысячники*) Кондаков Әхмәтҗан дигән кеше килде. Аны, килү белән, авыл куштаннары үзләре янына алдылар; һәр көнне аны кунакка чакыру башланды. Шулай ук аның белән бергә, укытучы – алдынгы кешебез, дип, Елизавета Смирнованы чакырдылар. Алар һәр көн ашка йөри торгач, танышып киттеләр һәм өйләнешеп тә куйдылар. Кондаков һәр көн исерек, колхоз турында уйламый. Ә авыл халкына шул гына кирәк, чөнки колхозга керү өчен тиешле аңлату алып барылмады. Тора-бара районнан килеп 15нче мартта мәктәпнең олы бүлмәсенә барлык кешене чакырып өсләреннән бикләп, кем керә – аны ачып керттеләр, шулай иртәдән төнгә тикле җәзалап гаризаларга кул куярга мәҗбүр иттеләр”.

Өстәп әйтим, Колхозцентр кабул иткән, СССРның СНК һәм ЦИК тарафыннан расланган авыл хуҗалыгы әртиленең үрнәк Уставы 1930 елның 2 мартында “Правда” газетында басылган була. Ул, шунда ук, татар теленә тәрҗемәсе ясалып, аерым китапчык итеп нәшер ителгән һәм барлык татар авылларына таратылган. “Егермебишмеңче”ләр хәрәкәте дә партия карары белән коллективизацияне уңышлы уздыру максатында 1929-1930 елларда башланган эш: крестьяннарга ярдәмгә Мәскәү, Казан һәм башка төбәкләрдән 25 мең алдынгы эшчеләрне җибәрү каралган була. Авылларны колхозлаштыруда аларның роле нинди булгандыр, төгәл генә әйтеп булмый. Ләкин күп кенә галимнәр бүген дә аларның бик сирәге генә авылда төпләнеп, җигелеп эшли алды дигән фикердә тора.

Шулай итеп, Мәскәүдән килгән “егермебишмеңче” Кондаков Әхмәтҗан Бәзәкәдә колхоз оештырырга тиеш булган. Бу эштә аның роле никадәр булгандыр, әйтүе кыен (күргәнегезчә, әти аны телгә генә алган, ә Габделхак абый тискәре характеристика биргән). Ләкин факт факт булып калган: Бәзәкәдә колхоз оешу хакындагы архивта сакланган документларда Кондаковның фамилиясе бар. Колхозны оештыру җыелышында да ул рәис булган.

Бу җыелыш 1931 елның 13 январендә мәктәптә узган. Җыелышның карандаш белән рус телендә кулдан язылган протоколы да бар. Җыелышта катнашканнар: Сираев Ф., Кәшфиев Әх., Фәтхуллин Мул., Мини Әхмәт, Ситдиков З., Мәхмутов Х., Кондаков, Төхвәтуллин Салаватулла, Төхвәтуллин Сөнгатулла. Җыелышның рәисе Кондаков, секретаре мәктәп директоры Әгъләмов булган. Көн тәртибенә авыл хуҗалыгы әртиле оештыру, уставын кабул итү һәм исемен билгеләү; идарә һәм ревкомиссия әгъзаларын сайлау куелган. Авыл хуҗалыгы әртилен оештыруның зарурилыгы хакында чыгышлардан соң әртил уставы тулысынча укылган. Бертавыштан “Сталино” исемендәге авыл хуҗалыгы әртилен оештыру хакында карар һәм Устав (үзгәрешләрсез генә) кабул ителгән. Идарә дә бертавыштан сайланган: рәисе – Кондаков, секретаре Мәхмүтов Хаҗи, рәис урынбасары Сираев Фатих булган. Ревкомиссиягә бертавыштан Ситдыйков Закир, Мәүләвиева

Минниса, Фәтхуллин Муллахмәт сайланганнар. Җыелыш кичке сәгать җидедә тәмамланган. Протоколга Кондаков һәм Әгъләмов кул куйганнар.

Бу протокол белән бергә башка документлар да бар. Иң элек ул авыл хуҗалыгы әртиленең татар телендәге Уставы – дәфтәр битенең дүрттән бер өлеше зурлыгындагы кечкенә китапчык. Ахырында буш бите дә бар. Шул буш биттә карандаш белән татарча (яңалифтә) “Уставка кул куючылар” дигән язудан соң имзалар куелган һәм исемнәрнең тулы варианты бирелгән: Вәлеев, Мәхмүтов, Гобәйдуллин, Мәрьям, Шәйдуллин, Төхвәтуллин, Мәүләвиева, Төхвәтуллин Сал., Камалетдинов, Фәтхуллин, Сираев, 12. Кәшбиев (имзаларның төрле хәрефләр белән – гарәп, рус, латин – куелганлыгы да игътибарга лаек).

Кабул ителгән Устав 10 бүлек, 22 пункттан гыйбарәт. Кушымталары да бар. Анда 1930 елның 2 мартында “Правда” газетында басылган И.В.Сталинның “Уңышлардан баш әйләнү” исемле мәкаләсенең татарчага тәрҗемәсе һәм башка кайбер өстәмә материаллар урын алган. Бу мәкаләнең Уставка кушымта итеп бирелүе, күрәсең, “бөек юлбашчының” халык мәнфәгатьләрен кайгыртуын, колхозлаштыру хәрәкәтенең ирекле булуын ассызыклавын күрсәтү өчен эшләнгәндер. Уставның беренче битендә *“Колхоз синтр тарафыннан кабул ителгән СССР җир эшләре халык комиссариаты тарафыннан мәгъкүл табылган Һәм Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан тәмам расланган устаф”* дигән искәрмә бирелгән.

Бу урында уставның, минем фикеремчә, иң мөһим һәм тирән эчтәлекле берничә пунктын тулысынча китерергә кирәк. Беренче пунктта әртилнең максаты һәм бурычлары билгеләнгән: “Хезмәт ияләренең дошманнары булган кулакларны бөтен эксплуататорларны һәм хезмәт ияләренең һәммә дошманнарын, шулай ук наданлык, мохтаҗлыкны һәм аерым хуҗалыкларның артта калуларын тәмам җимерүне чын-чыннан тәэмин кылу, коллектифләшкән хуҗалыкның эшләп чыгарышын һәм таварлылыгын иң югары дәрәҗәгә күтәреп оештыруны да тәэмин кылу өчен җәмәгатьләштерелгән эшләп чыгару кораллары һәм тулай оештырылган көч белән зур коллектив хуҗалык торгызырга теләп, *Алабуга* районы *Бәзәкә* авылының батрак, ярлы һәм урта хәлле крәстияннәре үз теләкләре белән авыл хуҗалыгы әртиленә берләшәләр”.

Ике пункттан гыйбарәт икенче бүлектә сүз җир хакында бара. “Әртил члиннәренең җирләрен аерып тора торган бөтен мижалар (ызаннар) бетерелә һәм бөтен җир берләштерелеп әртилнең файдалануына бирелә, - дип күрсәтелгән беренче пунктта. - Бөтен яраклы җирләрне берләштергән чагында усадьба янындагы җирләр (яшелчә, җимеш бакчалары һ.б.) ялгыз файдалану өчен калдырылалар. Бу әртилнең правлениесе карары һәм бу карарны опщый җыелышның раславы буенча, бик кирәк булганда, усадьба җиренең мигдары үзгәрергә мөмкин”. Икенче пункты кисәтеп куя: “Әртилнең берләштергән җирләре һич бер төрле юл белән киметелергә тиеш түгел. Әртилдән чыккан кешеләргә әртил җиреннән җир бирелми. Әртилдән чыгучылар дәүләт фондындагы артык җирдән җир ала алалар”.

Өченче бүлек җитештерү коралларына багышланган. “Әртилнең бөтен эш хәйваннары, авыл хуҗалыгы кораллары, бөтен товарлыклы азык (продуктивный) хәйваннары, бөтен орлык запаслары, җәмәгатьләштерелгән хәйваннарны туйдыру өчен җитәрлек күләмдә хәйван азыклары, әртил хуҗалыгын алып бару өчен кирәкле булган бөтен каралтылар һәм бөтен эшләп чыгару предприятиеләре җәмәгатьләштереләләр.

Әртил членнарының торак урыннары (жилые постройки) җәмәгатьләштерелми.

Авыл хуҗалыгы инвентарен җәмәгатьләштергәндә әртил членнарының усадьба янындагы җирне эшләр өчен кирәк булган вак күләмдәге авыл хуҗалыгы инвентаре җәмәгатьләштерелми. Җәмәгатьләштерелгән эш хәйваннарыннан әртил правлениясе кирәк булган вакытта әртил членнарының кирәкләрен үтәр өчен кирәкле кадәр атлар аера.

Бер сыерлы хуҗалыкларда сөт хәйваны җәмәгатьләштерелми. Күп сыерлы хуҗалыкларда бер сыер калдырыла. Калганнары җәмәгатьләштерелә. Җитештерүчеләр (производители) һич шөбһәсез җәмәгатьләштереләләр. Җәмәгатьләштерелгән сөт хәйваннарыннан әртилнең товар хуҗалыгы төзелә.

Вак хәйваннарны: чучка, сарык, кәҗәләрне җәмәгатьләштерү вак хәйванчылык промышленносте алга киткән районнарда гына эшләргә мөмкин. Монда да әртил тарафыннан куелган микдарда вак хәйван әртил членнарының үзләрендә калдырыла. Вак хәйванчылык промышленносте булмаган районнарда чучка, сарык кебек хәйваннар җәмәгатьләштерелми. Йорт кошлары җәмәгатьләштерелми. Ялгыз файдалану өчен вак хәйваннарны, йорт кошларын калдыру белән бер рәттән колхозлар промышленность нигезендә җәмәгатьләштерелгән вак хәйванчылык һәм кошчылык эшен оештыралар.

Иген булмаудан һәм мал азыксыз калудан страховайт юлында әртил янында калганда кагылмый торган орлык һәм мал азыгы фонды оештырыла”.

Уставның алтынчы бүлеге “Әртилнең байлыгы” исеме астында бирелгән. Дүрт пунктта гыйбарәт бу бүлекне тулысынча китерәм:

“1. Әртилгә керүче һәрбер член хуҗалыкта аның өлешенә тигән мал-мөлкәтнең җәмәгатьләштерелгән һәм җәмәгатьләштерелмәгәннәрен исәпләп, сумына 2 тиеннән башлап 10 тиенгә кадәр акчалата керү (вступительный) взносы түләргә тиеш. Монда йорт җиһазлары һәм үзе өчен кирәкле әйберләр исәпкә кермиләр.

Әгәр дә әртилгә керүченең төп доход урыны хезмәт хакы була икән (агрономнар, укытучылар, җир төзүчеләр, районда хезмәт итүчеләр) керем түләве правление тарафыннан билгеләнә, ләкин ул еллык хезмәт хакының 10%-нан да артык булмаска тиеш.

Батраклар өчен керү түләве 5 сумнан да артык билгеләнергә тиеш түгел. Һәр вакыт колхоздан читтә торучы эшчеләр устафта күрсәтелгәнчә милекләренең 2 дән алып 10% кадәре керү взносыннан башка тагын еллык эш хакларының 3 %ын кертәләр.

2. Әртил членнарының җәмәгатьләштерелгән мал-мөлкәтләренең эш һәм азык (продуктивный) хәйваннары, инвентарь, хуҗалык каралтылары һәм башкалар чирек өлешеннән алып яртысына чаклы өлеше, әртилнең бүленми торган фондына хисапланып, калган өлеше әртил членының пае итеп исәпләнелә. Мөлкәтләрне бүленми торган фондка хисаплаганда, хуҗалыкның хәленә карап, ныклы хәллеләр өчен % күтәренкерәк булырга кирәк.

3. Әртилдән чыгучы член белән хисаплашуны правление башкара һәм аңа паен кире кайтара. Әртилдән чыгучы членга җир әртил җиреннән бирелмичә, башка чит җирдән бирелергә мөмкин. Чыгучы член белән хисаплашу, хуҗалык елы бетеп, аның нәтиҗәләре мәгълүм булганнан соң гына үтәлә.

4. Әртилнең еллык доходы суммасыннан иң элек хуҗалык расходлары һәм хуҗалыкка бәйләнгән расходлар каплана; шулай ук хезмәткә яраксыз булганнар өчен тотылган расходлар каплана, бүленми торган фондка 10-30 % ка кадәр, башка җәмәгать фондларына 5-15 % ка кадәр һәм хезмәт өчен хисапны өзүләре аерыла”.

Сталин исемендәге авыл хуҗалыгы әртиле оешу мәсьәләсенә кайтыйк. Документлар арасында тагын бер исемлек бар. Менә ул.

Таблица № 9

Алабуга районы Бәзәкә авылында 1931 елның 13 январендә оештырылган авыл хуҗалыгы әртиле әгъзалары исемлеге

№	*Фамилиясе - исеме*	*Яше, парт.*	*Социаль хәле*	*Барлык кеше*	*Эшкә яраклы*	*Эш хайваны*
1.	Муллахмәтов Габдулла	Комсом.	Батрак	1	1	
2	Мәхмутов Хаҗи	30	Средняк	7	2	1
3	Мәүләвиева Минниса		Батрак	5	4	
4	Сираев Фатых		Ниже ср.	2	2	1
5	Гимашев Нәҗметдин-сыз.		Средняк			
6	Ситдиков Закир- сызылган		Средняк			
7	Төхвәтуллин Сөнгатулла		Средняк	5	2	1
8	Төхвәтуллин Салаватулла		Средняк	4	3	1
9	Фәтхуллин Муллахмәт		Средняк			1
10	Кәшфиев Әхкәми		Ниже ср.	5	2	1
11	Гобәйдуллин Гайнулла		Бедняк	3	2	
12	Камалетдинов Фәйзи	Комсом.	Служ.	1	1	
13	Вәлеев Харис		Бедняк	4	2	
14	Әхмәтҗанов Мул-сызылган		Средняк			
15	Закиров Минәхмәт	37	Батрак	1	1	
16	Госманова Мәрьям	30	Бедняк	5	1	
17	Шәйдуллина Мәхуб		Бедняк	3	2	
18	Гаптерәхманов Т			2	1	
	Барлыгы			55	28	6

Исемлектә барлыгы 18 хуҗалык иясе күрсәтелгән. Шуларның унбише исемлеккә имзаларын куйган, өч урта хәллесе, күрәсең, кире уйлаган – алар исемлектән сызылганнар (“бу исемлектәге имзаларның, сызылганнардан кала, дөреслеген Бәзәкә авыл советы раслый” дигән язма һәм мөһер

өстәлгән). Кул куючылар арасында 3 батрак, 4 бедняк, 4 средняк күрсәтелгән; ике кеше үзенең сыйнфый хәлен “урта хәлледән түбәнерәк” дип билгеләгән, исемлеккә соңгы кертелгән Гаптерәхмановның сыйнфый хәле язылмаган. 15 хуҗалыкта 55 кеше яшәгән, аларның 28 эшкә яраклы булган. Яңа оешкан әртилдә барлыгы алты ат булуын игътибарга алыйк. Турысын әйтергә кирәк, яңа оешкан күмәк хуҗалыкның хәлен кызыгырлык дип әйтеп булмый. Башында акылы, тормыш тәҗрибәсе, җитәрлек мал-мөлкәте булган кеше, ай-һай, үз теләге белән анда барып керер микән?

Бер вакытта ук авыл советы һәм әртилдә дә секретарь вазыйфасын үтәргә тиеш булган әтиебез Мәхмүтов Хаҗи сөйләвенчә, әртил эшләре башта бик авырдан барган. Кая анда яңа әгъзалар кабул итү! Бәзәкәлеләр әртилне бөтенләй санга сукмаганнар. Кондаков озакламый Бәзәкәдән кире алынган, аның урынына икенче “егермебишмеңче” – Бондюг заводы эшчесе Салих Гимазтинов җибәрелгән. Бондюг заводы Бәзәкә колхозын шефлыкка алган. Волость һәм район җитәкчелегенең авыл советына басымы да артканнан арта барган. “Өстән төшерелгән” төрле күрсәтмә һәм боерыклар, разнарядкалар алардан колхозчыларның санын арттыруны, авылдагы төрле “корткыч һәм кулакларны” ачыклауны һ.б. таләп иткәннәр. Әти сүзе белән әйтсәм, авыл активистларының тормышы ул чорда “кыл өстендә” булган.

Габделхак абый язмаларыннан: “Бу үзгәртеп кору (коллективлаштыру) бик зур борылыш булды. Крестьянның җирен-суын, атын-сбруен-симәнәсен, эш коралларын һәм барлык ашлыгын тартып алу, өстәмәсенә гомумиләшкән малларга фермалар җиткерү өчен сарайларын сүтеп алу крестьяннарда кайгы-хәсрәт һәм зур ачу тудырды, моның белән кешеләрнең сүтелгән урыннары ачык калып, урамнарның яме бетте, авылның матурлыгын җимерде. Бөтен маллары, тавыгына тикле учетка алынды. Аларга төрледән-төрле налоглар-заемнар салынды, ит-сөт-йомырка тапшыру һәм башкалар. Өстәмәсенә, мондагы ирләр бозык канлы, киләчәккә таза-чиста канлы балалар табу өчен хатыннарга чиста канлы ирләр китереләчәк дигән төрле агитациялар таралды. Болар бөтенесе крестьянны утка-суга салды һәм ачу тудырды. Гомергә бер тугандай яшәп килгән авыл халкын бер-берсенә дошманнаштырды”.

Архив документлары нәрсә сөйли? Шуны да карыйк. Менә Бәзәкә авылы буенча 1931 елга икмәк хәзерләү планы. Авылда барлыгы 601 хуҗалык күрсәтелгән. Колхозның чәчүлек җирләре 198,65 гектар, аерым хуҗалыкларда 513,15 гектар, барлыгы 711,80 гектар булган, ягъни уртача бер хуҗалыкка 1,22 гектар чәчүлекләр туры килгән. Бер шундый хуҗалык уртача 13,49 центнер уңыш алырга тиеш булган; димәк, колхозга 2184 центнер, аерым хуҗалыкларга 5644 центнер тулаем уңыш җыю каралган булган. 1931 елның 19 ноябренә Бәзәкә авыл советы буенча тутырылган сводкада китерелгән саннар: план буенча колхоз 1076 центнер ашлык тапшырырга тиеш булган, үтәлгән 704 центнер; аерым хуҗалыклар – йөкләмә 3474 центнер, үтәлгән 1538 центнер; 26 хуҗалыкка билгеләнгән катгый йөкләмә - 450 центнер, үтәлгән 373 центнер. Шулай итеп, Бәзәкә авыл советы хуҗалыклары икмәк хәзерләү планы буенча 5000 центнер икмәк тапшырырга

тиеш булса, 1931 елның 19 ноябренә 2516 центнер тапшырылган, ягъни план 50,3 %-ка үтәлгән булып чыга.

Бу саннар арасында колхозчылар саны да, аерым хуҗалыклар саны да юк. Исебезгә төшерик: 13 гыйнварда колхозга 15 хуҗалык керде. План күрәсең, коллхозга керәчәк хуҗалыкларны күздә тотып төзелгән. Документларда китерелгән саннардан файдаланып, бу план буенча колхозда 1931 елда 130 хуҗалыктан да ким булмаска тиеш булган. Саннар үтәлгәнме? Бу сорауны ачыкларга безгә берничә документ ярдәм итәр. Аларның беренчесе Бәзәкә авылының 1937-1939 елларга караган хуҗалык кенәгәләре буенча төзелгән исемлек.

Таблица № 10

1931 елда колхозга кергән бәзәкәлеләрнең исемлеге

1	Шәяхмәтев Ясәви 1886	24	Гиззатуллин Нәбиулла 1888
2	Зәйнеттинев Фәттахи 1898	25	Гомәров Хәмәт 1916
3	Гайнетдинов Баһау 1879	26	Хөрмәтуллин Сибагат 1914
4	Шәйдуллин Хажи 1913	27	Гыйлфанов Гаптелхак 1914
5	Ситдикова Гайшә 1878	28	Шибаев Әһли 1876
6	Исмәгыйлев Шәйми 1901	29	Бикмөхәмәтев Тимерша 1916
7	Хәсәнов Зәйнетдин 1880	30	Шибаев Фәрди 1881
8	Зиннуров Мулланур 1913	31	Муллахмәтов Хуҗахмәт 1888
9	Мәүләвиева Минниса 1883	32	Зиннатуллина Латифа 1863
10	Шәйдулатов Мөхәмәтша 1914	33	Фазуллин Шәех 1904
11	Нәбиуллин Ясәви 1902	34	Газизов Сәхип 1899
12	Сабитов Шәхми 1898	35	Нәбиуллин Хәким 1909
13	Низаметдинов Кәшфи 1886	36	Исламова Фәхернур 1873
14	Шәрипов Минәчтин 1905	37	Кәримов Хажи 1914
15	Гыймадиев Хәмәт 1907	38	Әхмәтҗанов Нури 1870
16	Газизов Гәрәй 1921	39	Башаров Госман 1889
17	Ибәтуллин Садыйк 1893	40	Мәхмүтов Хажи
18	Шакиров Мөхәмәтҗан 1875	41	Төхфәтуллин Гәрәй 1893
19	Көләчев Габдулла 1883	42	Төхфәтуллина Минебәдәр 1917
20	Фатхуллин Муллахмәт 1886	43	Бикмөхәмәтев Фәтхи 1904
21	Исхаков Гыйлаҗ 1863	44	Баһаветдинов Касыйм 1903
22	Гимашев Нәҗметдин 1875	45	Габидуллин Габдулла 1905
23	Баһаветдинова Фәтхия 1900	46	Гафаров Зариф 1874

Исемлек кенәгәләрдәге йортлар тәртибендә төзелгән һәм тулы түгел, чөнки кайбер кенәгәләрдә битләре җитешми; моның өстенә, күп кенә хуҗалыкларда колхозга керү вакыты күрсәтелмәгән. Шулай булса да, бу исемлек безгә бик мөһим.

Икенче документ - икмәк хәзерләү буенча “бишлек” утырышының протоколы. Бу утырышта Алабуга районы башкарма комитеты президиумы әгъзалары катнашында узган. Шуннан кайбер мәгълүмат. Беренче булып, икмәк хәзерләү планына аныклык кертү. Бу мәсьәлә буенча Зубков дигән кеше (бишлек җитәкчесе булырга тиеш) чыгыш ясаган. Аның чыгышының эчтәлеге: “Икмәк хәзерләү барышында планлаштыруда бер төркем җитешсезлекләр ачыкланды. […] Бәзәкә кебек кайбер авылларга карата аңлы

рәвештә кулак авылларына тиешле арттырылган план төшерелде, ләкин хәзерләү барышында моның чынбарлыкка туры килмәве ачыкланды; һәм хәзер план үтәлми. План үтәлсен өчен вәкилләр бу авылларда төрле чиктән тыш тупаслыкларга барып җитәләр. Шуңа күрә, саклана торган запастан кайбер авылларның планын киметергә һәм бу хакта яшерен рәвештә авыллардагы һәм төбәктәге вәкилләргә җиткерергә кирәк”.

Утырышта еллык планнарны Сарайлы авылына 1000 ц, Полянка, Монай, Трехсвятское, Гришкино авылларына һәрберсенә 500 ц, Бәзәкәгә 1500 ц, Камайга 150 центнерга киметергә дигән карар кабул ителгән. Карарның икенче пункты тирән мәгънәле: “Күрсәтелгән планнарны киметү хакында җаваплы вәкилләргә генә хәбәр итәргә”. Димәк, саналган авылларда колхозлаштыру эшләре шул кадәр авырдан барган, Бәзәкәне бөтен авылы белән “кулак авылы” дип атаганнар. Ләкин Бәзәкә авылының мөмкинлекләрен исәпкә алмыйча гына билгеләнгән 5000 центнер икмәк тапшыру планы, вәкилләрнең “чиктән тыш тупаслыкларына” карамастан, авыл халкы күтәрә алмаслык булган. Бу очракта вәкилләр, күрәсең, халыкның байлыгын түгел, психологиясен күз алдында тоткандыр. Шуны аңлаган район җитәкчелеге, бәзәкәлеләрдән (хәтта җитәкчеләреннән дә) яшерен рәвештә, планны 30 %ка киметкән.

“Чиктән тыш тупаслыклар” хакында. Ул “тупаслыклар”ның төрләре күп булган. Гадәттә, авылга вәкил бер үзе генә түгел, бер төркем кеше белән килә торган була. Араларында бер-ике милиционер, волость идарәсендәгеләр дә булган. Барысы да кара күн тужуркадан, кораллары да бар. Авыл җыеннарында да, бәзәкәлеләрне аерым-аерым авыл советына “сөйләшү”гә чакырып та, вәкил, беренче карашка, бик җиңел генә, бик гади сораулар куя торган булган (мәсәлән, “кем колхозга каршы?”, “син Совет властен таныйсыңмы?” кебекләрне). Кем инде аек акылдан бу сорауларга туры җавап бирсен? Колхозга каршы түгел икәнсең, димәк, әртилгә язылырга кирәк. Совет властен танымыйм дип әйтергә дә кешенең башы ике түгел.

Әти сөйләгәннәрдән. Бер заман вәкилләрнең берсе, мәктәп залында зур җыен җыеп, ишек төбенә каравыл куйган. Каравылга наказ бирелгән: килгәннәрне барысын да кертергә, китәргә теләүчеләрне берсен дә чыгармаска. Башта ул әртил тормышының рәхәтлелекләре хакында озак кына сөйләгән, аннан соң: “Кем колхозга каршы, кайтып китә аласыз”, - дигән. Карар кабул итүне катлауландырган фактор да булган: Бәзәкәдә күптән түгел генә бер төркем “кулак” кулга алынган була. Һәм җыеннан китүчеләрне дә шул ук язмыш көткәнлеге ачык аңлашылган. Шулай да, берничә кеше чыгып киткән. Калганнарны вәкил Сталин исемендәге әртилнең яңа әгъзалары булулары белән котлап, авыл советы активына барысыннан да әртилгә үз теләкләре белән керүләре хакында имзаларын җыярга кушкан. Шулай әртил 100 дән артык кешегә арткан.

Әтинең бу истәлекләрен исбатлый торган бер документка архивта тап булдым мин. Ул 1933 елның беренче яртысында язылган Сталин ис. Бәзәкә колхозының хисап-тасвирламасы. “Коллектив хуҗалык 1931 елда оешкан. Хәзерге вакытта 123 хуҗалык бар. 1932 елгы язгы чәчү вакытында колхоз

бик зур югалту кичерде (100 хуҗалык колхоздан чыкты). Шулай да колхозчыларның калган аңлы өлеше (43 хуҗалык) язгы чәчү планын срогында һәм тулысынча үтәде”, - дип башланган ул. Минем фикеремчә, 100 хуҗалыкның колхозны ташлавын аларның ничек итеп “үз теләкләре белән” колхозга керүләре аңлата. Ничек кенә булмасын, бу документ әртил әгъзалары саны үсешен дә күрсәтә – 1933 елның башына колхоздагы хуҗалыклар саны 123-кә җиткән. Ләкин бу сан район җитәкчелеген канәгатьләндерерлек булмаган шул – авыл хуҗалыкларының бары 25 % гына колхозга язылган.

1933 елгы хисапка кайтыйк. “1933 елгы язгы чәчү планын аерым хуҗалыклардан алган җир хисабына 84 гектарга арттырып үтәлде. Иртә чәчелә торган сабан ашлыклары 6 көндә, соң чәчелә торганнары 3 көндә чәчелде, пар җирләре 20 майга 100 % ка сөрелде. Колхозның 40 гектарлык яшелчә фермасы бар; 1933 елда колхоз үз башлангычы белән 100 парник рамы булдырды. Яшелчәлек белән 2 ел гына шөгыльләнсә дә, колхоз бик яхшы нәтиҗәләргә ирешті һәм 1932 елгы район күргәзмәсендә бүләкләнде. Сөт-товарлыклы ферма өчен 1933 елда 100 баш терлеккә хисапланган яңа терлек абзары җиткерелде”, - дип колхозның уңышлары күрсәтелгән хисапта.

Хисапта 1-2-квартал финанс планының вакытыннан алда арттырып үтәлүе дә, I-II бишьеллык заемнары тулысынча урнаштырылуы да, бригадалар арасында һәм эчендә социалистик ярыш җәелдерелүе дә урын алган. Ярыш нәтиҗәсендә нормаларны арттырып үтәү дә (2 төрәнле сука белән бер көнгә 1,80 га җир сөрелгән, кул белән 1 кеше 6 гектарга кадәр иген чәчкән) күрсәтелгән. “Колхозчыларны кырда ашату оештырылды. Җәйге чәчү вакытында колхоз стена гәзите чыгарды, бригадаларны күчмә Кызыл байрак белән бүләкләүне оештырды һәм башкалар, - дип кырда эшләүчеләргә күрсәтелгән игътибар да яктыртылган хисапта. – Колхозның көчле балык әртиле бар, ул районда бер үзе генә 1932 елгы балык тоту планын үтәде; 1933 елның беренче квартал планы шулай ук үтәлде”.

Архив материаллары безгә райондагы колхозлаштыру темплары белән танышырга да мөмкинлек бирә. Менә 1934 елның декабрендә Алабуга районы авыл советлары буенча авыл хуҗалыгының хәле һәм халык саны хакында җыелган мәгълүмат. “Коллективлаштыру бигрәк тә 1933 елдан үсеш алды. Әгәр дә 1932 елның 1 гыйнварыннан 1933 елның 1 гыйнварына кадәр үсеш 4 % булса, 1933 елның 1 гыйнварыннан 1934 елның 1 гыйнварына ул 21% тәшкил итте, - дип язылган анда. - Коллективлаштыруны Абалач, Тогай, Брөшле, Бәзәкә ... (барлыгы 13 авыл саналган – А.М.) авыллары артка тарта. Аларда коллективлаштыру проценты 33-тән 50-гә кадәр. […] Татар авыллары арасында бигрәк тә Бәзәкә (49 %) һәм Иске Гришкино (33 %) коллективлаштыру процентын аска тарталар. Бу безнең алга бу авылларны махсус җитәкчелеккә алу бурычын куя; аларны районның җитәкче оешмалары үз кулы астына алырга тиеш. […] Хәзер бездә күмәкләштермәгән булып Абалач, Тогай, Брөшле, Бәзәкә h.б. калды (барлыгы 13 авыл – А.М.). Бер яктан, бу авыл советларының сыйнфый сизгерлеге кимү белән

аңлатылса, икенчедән, массакүләм аңлату эшләренең бик начар оештырылуын күрсәтә”.

1920-1930 елларда авыл тормышында иң зур роль уйнаган оешма – советлар хакимиятенең иң түбән баскычын тәшкил иткән авыл советы булган. Аның эшчәнлегенең һәр ягы мөһим булган – авылдагы халык һәм хуҗалык санын барлаумы ул, терлекчелек яки игенчелекнең торышын, юллар, күперләр, коеларның хәлен тикшереп торумы, төрле-төрле салымнар җыюмы, мәктәп, уку йорты, клуб эшчәнлеген күзәтүме, h.б., h.б.. Бәзәкә авыл советының 1933 елдагы эшчәнлеген тасвирлаган бер документ белән танышыйк. Ул 1934 елның 29 гыйнварында төзелгән ревизия акты. Бу көнне Бәзәкә авыл советының 1933 елның 1 гыйнварыннан алып 1934 елның 1 гыйнварына кадәр булган эшләре буенча тикшерү узган. Ул Бәзәкә авыл советы тикшерү комиссиясе әгъзалары Шакиров Ф., Әхмәтҗанов Х., Садыйков Гата, авыл советы рәисе ярдәмчесе Гиздәтуллин Н, язучы Мәхмутов Х.-ларның катнашы белән Садыков рәислеге астында булган. Актның беренче ике бүлегендә авыл советы составына кагылышлы мәгълүмат урын алган. Башта шул мәгълүматны карап чыгыйк.

Таблица № 11

1933 елның 1 ноябренә Бәзәкә авыл советы составы

Фамилиясе һәм исеме	Партий-ность	Туган елы	Кол-хозда-мы	Соц. чыгы-шы	Соц. хәле	Совет-лар эшен-дә	Искәр-мәләр
Гыймазетдинов Гыйлфан	ВКПб	1888	Да	Крест	Бедняк	1919	Рәис
Гыйззәтуллин Нәби	б/п	1888	Да	Крест	Бедняк	1929	Урынб.
Мәхмүтов Хаҗи	б/п	1900	Да	Крест	Середн	1929	Секр.
Ганиев Габденур	ВКПб	1911	Да	Крест	Бедняк	1931	парторг
Бәшаров Госман	б/п	1888	Да	Крест	Середн	1926	
Гыйлфанов Фәттах	ВЛКСМ	1909	Да	Крест	Бедняк	1932	
Бикмөхәмәтев Фәтхи	б/п	1905	Да	Крест	Середн	1931	
Зиннуров Мулланур	ВЛКСМ	1913	Да	Крест	Середн	1933	
Габдрахманова Татҗибә	б/п	1885	Да	Крест	Бедняк	1929	
Шәймәрданов Шәйхнур	б/п	1909	Да	Крест	Бедняк	1933	
Фәттахов Низамби	б/п	1906	Ед/л	Крест	Бедняк	1930	
Гыймазетдинов Муфтах	б/п	1898	Да	Крест	Середн	1932	
Идаев Гайнетдин	б/п	1896	Да	Крест	Середн	1932	
Хуҗин Гыйлми	б/п	1907	Да	Крест	Середн	1932	
Гайнуллин Кәлимулла	б/п	1896	Да	Крест	Бедняк	1932	
Маннапов Сәхип	б/п	1897	Да	Крест	Середн	1932	
Газизов Миннәхмәт	б/п	1890	Да	Крест	Середн	1932	
Гайсин Минегали	б/п	1907	Да	Крест	Середн	1932	
Гыймадиев Кәшаф	б/п	1906	Да	Крест	Середн	1932	
Минһаҗетдинов Кирам	б/п	1910	Да	Крест	Середн	1932	
Шәрифуллин Нурый	б/п	1905	Да	Крест	Середн	1931	
Хикмәтуллин Мулланур	б/п	1907	Да	Крест	Середн	1932	
Низаметдинов Гали	б/п	1905	Да	Крест	Бедняк	1932	
Мөхәмәтҗанов Минәхм	б/п	1884	Да	Крест	Середн	1932	
Әхмәтҗанов Кәрәми	б/п	1905	Да	Крест	Бедняк	1932	

Ревизионная комиссия							
Садыков Гата		1902	к/х	Крест	Служ	1932	
Шакиров Фәйзи		1892	к/х	Крест	Служ	1932	
Хуҗин Закир		1893	ед/л	Крест	бедняк	1931	

Авыл советы рәисе урынына Ф.Шакиров Секретарь Мәхмүтов”.

Димәк, 1933 елның 1 ноябренә Бәзәкә авыл советында 25 депутат булып, аның 24 колхоз әгъзасы һәм берсе аерым хуҗалык хуҗасы булган. Сыйнфый хәле буенча депутатларның 10 ярлы һәм 15 урта хәлле дип күрсәтелгән. Депутатлар арасында ике коммунист һәм ике комсомол әгъзасы булган. Авыл советы рәисе булып 1930 елда Бәзәкәгә өч елга кантоннан җибәрелгән ВКП(б) әгъзасы Гыймазетдинов Гыйлфан эшләгән. Тумышы белән Псәй авылыннан булган Гыйлфан абзый 1919 елдан совет органнарында эшли башлаган: башта Псәй авыл советы рәисе, аннан соң Күрәк /Камай/ волисполкомы рәисе, Алабуга кантисполкомында бүлек мөдире. Бәзәкәгә командировкага 1933 ел азагына кадәр җибәрелгән булса да, шунда төпләнеп калган һәм күп еллар авыл советы рәисе вазыйфасын башкарган. Депутатларның күпчелеге (14 кеше) авыл советына беренче тапкыр 1932 елда, икесе 1933 елда сайланганнар. Калганнарның авыл советында эшләү тәҗрибәләре зуррак. Өч кешедән торган ревкомиссия аерым сайланган; аларның икесе укытучы, берсе аерым хуҗалык хуҗасы булуына да басым ясарга кирәк.

Тагын бер таблица белән танышыйк.

Таблица № 12

1933 елның 5 ноябренә Бәзәкә авыл советы буенча хуҗалыклар һәм халык саны

Сектор исеме	Хуҗалык саны	Барлык кеше	18 яшькә кадәр егетлар	18 яшькә кадәр кызлар	18 яшь-тән алып ирләр	18 яшь-тән алып х-кызлар	Читтә эшләүче-ләр
Колхозчы	202	905	187	224	202	292	45 тр/сп
Аерым хуҗ.	313	1439	296	378	324	441	136 тр/сп
Барлыгы	515	2344	483	602	526	733	181

Бу саннардан аңлашылганча, 1933 елның азагына Бәзәкә хуҗалыкларының бары 40% гына колхозга кергән икән, ә 60% ялгыз хуҗалык булып яши биргән. Тикшерү актында күрсәтелгән тагын бер санны өстик: 313 ялгыз хуҗалыкның 226-сы үз җиренә ия булган, 87 хуҗалыкның җире булмавы күрсәтелгән. Бу хуҗалыкларны без читтә эшләүчеләрнеке булгандыр дип фаразлый алабыз (читтә эшләүче 136 эшкә яраклы кешенең ялгыз хуҗалыклардан булуы язылган). Колхозчы гаиләләреннән дә читтә эшләүчеләр булуы (45 кеше) күзгә ташлана (бу гаиләләр, күрәсең, колхозга күптән түгел генә кергәндер). Актта шулай ук 1933 ел дәвамында авылда 87 бала тууы, 94 кеше вафат булуы да теркәлгән.

Актның дүртенче бүлегендә сүз терлекчелек хакында бара. Атлар: 1933 елда – колхозда 140 (шуның 15 яшь ат), аерым хуҗаларда 169 (1 яшь ат); 1932 елда – колхозда 108, аерым хуҗаларда - 207 ат булган, ягъни 1932 елда авылда барлыгы 315 ат булса, 1933 елда 309 ат булган. Игътибар итик – бер ел эчендә колхоз атлары саны 32 башка артса, ялгыз хуҗалыкларда 38 башка

кимегән. Колхозда атлар саны артуын аңа яңа хуҗалыклар язылуы белән аңлатып була торгандыр дип фараз кылыйк. Мөгезле хайваннар: МТФда барлыгы 112 баш (1932 елда -108) булган, алар арасында савым сыерлар - 49, таналар - 23, бозаулар – 37, нәсел үгезләре - 3; колхозчыларда – 129 баш (88 савым сыер, 12 тана, 25 бозау), 1932 елда – 45 баш булган; аерым хуҗаларда 197 баш (138 савым сыер, 29 тана, 30 бозау), 1932 – 348 баш булган, Барлыгы 1932 – 501, 1933 елда 438 баш булган, ягъни колхозчыларда сыерлар саны күзгә күренеп артса да, мөгезле эре терлекнең гомуми саны 63 башка кимегән. Бу очракта инде ачыктан-ачык ялгыз хуҗалыкларда эре терлекне бетерү барганын күрәбез. Сарыклар: 1933 елда колхозчыларда 192 баш (132-олы сарык, 60 бәрән), 1932 елда – 103 баш булган; аерым хуҗалыкларда 1933 елда 284 баш (93 бәрән), 1932 елда – 421 баш булган. Барлык бу саннар, тулаем алганда, бер яктан, дәүләтнең ялгыз хуҗалыкларны кысрыклавы дәвам итүен күрсәтсә, икенче яктан, аның колхозларга ярдәме хакында да сөйли.

Тикшерү актының бишенче бүлеге “Авыл хуҗалыгының еллык касса эшләре” дигән исем йөртә. Бүлектә авыл советы кассасы аша узган керем-чыгымнарның күләме күрсәтелгән, халыкның нинди салым һәм җыемнар түләгәнлеге бирелгән. Җыемнарның зур өлеше дәүләт бюджетына күчерелгән; ул авыл хуҗалыгы салымы, мәҗбүри страхование, юл төзү, культура җыемнары, заемнардан һәм штрафлардан торган. Барлык салымнар да төрле төркемнәргә бүленеп җыелган. Мәсәлән, 1933 елда *авыл хуҗалыгы салымы* - керем барысы 23672,93 сум булган (колхоздан 2947,87 сум, колхозчылардан – 2656,73 сум, аерым хуҗалык һәм кулаклардан – 18068-33 сум); чыгым барысы 24092,67 сум (колхоздан 2492,86 сум, колхозчылардан – 2947,87 сум, аерым хуҗалык һәм кулаклардан – 17262,57 сум, аерым салымга тартылган хуҗалыкларга кайтару 1225,50 сум) булган.

Мәҗбүри страхование буенча барлыгы керем 14092,01 сум, чыгым 13627,09 сум тәшкил иткән. Ул шулай ук ваклап та күрсәтелгән. Икенче бишьеллык займы буенча барлыгы керем 28745,15 сум, чыгым 28797,87 сум булган. Культура җыемы буенча барлык керем 19609,28 сум, чыгым 19609,28 сум, юл төзү эшенә барлык керем 7961,24 сум, чыгым 7831,95 сум җыелган, төрле штрафлар буенча 6246 сум керем, 5722,22 сум чыгым булган. Шулай итеп, х*өкүмәт җыемнары* авылда барлыгы 116178,26 сум керем, 115420,95 сум чыгым тәшкил иткән.

Моннан тыш авыл бюджетына 1933 елда барлыгы 39171,69 сум кергән. Бу сумма үзара салымнан, кайтарылу шарты белән алынган ссудадан, төрле отчислениеләр, аренда һәм башка төр вакытлы җыемнардан торган. Авыл бюджетыннан укытучыларга, уку йорты мөдиренә, авыл советы әгъзаларына эш хакы түләнгән, бу оешмаларның хуҗалык һәм ремонт эшләренә тотылган, мәктәп балаларына кайнар аш хәзерләү, янгынга каршы чаралар күрү өчен киткән.

Актта шулай ук агрономия чаралары үтәлеше күрсәтелгән. Мәсәлән, көл җыюның планы 190 центнер булса, үтәлеш 41 центнер, кар тоту план буенча 250 га, үтәлеш 185 га, тирес түгү планда 7250 йөк, үтәлеше 1340 йөк

булган. Эш кораллары хакындагы мәгълүмат та игътибарга лаек. 1933 елда колхозда 2 төрәнле 29, 1 төрәнле 12 тимер сабан; 13 рәтле 1, 11 рәтле 1 чәчү машиналары; тырма машинасы 5 данә, сугу машинасы 2 данә булган (машиналарны ат көче белән эшләткәннәр). Аерым хуҗалыкларда барлыгы 7 плуг, 11 тимер тырма булган. Авыл советы күләменә бирелгән төзү эшләре буенча 913 куб. таш, 1017 куб. ком ташу каралган.

Мәктәп эшләре һәм наданлык белән көрәш (ликбез) аерым бүлектә күрсәтелгән: “Мәктәпләр 3 урында, барысы 10 группа. Шунда укучы балалар 1 баскыч 280 бала, 2-нче 80 бала. Барлык укучы балалар 360. Укытучылар 9 кеше. Учет буенча уку яшендәге балалар 100% алынган. Авыл советы күләмендә барлык наданнар һәм аз белемлеләр 448 кеше, шуннан укырга тартылганнары - наданнар 147, аз белемлеләр 159, барлыгы 306 кеше, тартылмаганнар 142 кеше. Шулар өчен хәзерләнгән йортлар 8, укытучы кызылармислар 17 кеше. Шулар эчендә эшләүче 1 кеше” (Искәрмә: “баскыч” сүзен “сыйныф /класс/” дип аңларга кирәк. Димәк, 1933 елда Бәзәкәдә 8 төркем балалар беренче сыйныфта, ике төркем икенче сыйныфта укыган булып чыга).

Сталин ис. колхоз - авыл хуҗалыгы әртиленең дә шул ук 1933 елга караган еллык отчеты хисабы сакланган. Отчеттагы мәгълүмат татар телендә басылган махсус формага язылган. Хуҗалыкның төп тармагы итеп, ни сәбәпледер, яшелчә бакчачылыгы һәм терлекчелек кенә язылган. Колхозның сөт-товарлыклы ферма, ит-товарлыклы ферма, корт-товарлыклы ферма, тимерче алачыгы, 4 кырчылык бригадасы, 1 яшелчә бригадасы, 1 терлекчелек бригадасы күрсәтелгән. Әртилдә 198 хуҗалык, 842 кеше (аларның 462-се – эшкә яраклылар) исәпләнгән; шулар арасыннан 37 кеше читтәге эштә булган (13 кешенең 1 елдан артык авылда юклыгы әйтелгән). 1933 елда әртилгә 128 хуҗалык кергән, 2 хуҗалык чыгарылган.

Сөрелгән җирләре 1701,14 га тәшкил иткән; колхозчыларның ихатадагы яшелчә бакчалары 10,25 га, ихатадан тыш яшелчә бакчалары 70 га биләгән; 892 га болыннары булган. Барлыгы эшкә яраклы җирләр 2673,39 га булган. 1933 елда уңыш алу өчен 405,48 га уҗым, 469,67 га сабан ашлыгы, барлыгы 875,15 га иген чәчелгән. Көзге чәчү өчен кара пар 323,66 га, 1934 елгы язгы чәчү өчен таза пар 502,33 га, барлыгы сөрелгән җир 1701,14 га тәшкил иткән. 1933 елда колхозчылар барлыгы 48613 хезмәт көне, 1932елда 25175 хезмәт көне эшләгәннәр.

1933 елда колхозда 108 ат (өч яшьтән узган бияләр 47, 1 айгыр, 52 алаша, бер яше тулмаган 8 колын); аларның 100 – эш атлары буларак кулланылган. 1934 ел өчен барлыгы 140 ат (өч яшьтән зур бияләр 49, 75 алаша, 1 айгыр, ике яше тулмаган 15 колын), шул санда 125 эш аты планлаштырылган. Мөгезле эре терлек 96 баштан торган (51 савым сыер, бер яшьтән олырак 23 тана, 19 үгез, ике яшьтән олырак өч нәсел үгезе); 1934 елга мөгезле эре терлек 112 баш (49 савым сыер, бер яшъкә кадәр 37 бозау, ике яшьтән олырак 23 тана, 1 нәсел үгезе, ике яшьтән олырак ике нәсел үгезе) билгеләнгән.

Колхозның 100 башка исәпләнгән яңа төзелгән ат абзары, чирләгән хайваннар өчен (ике башлык) изолятор, 983 тонналык ике бәрәңге саклау урыны (берсе яңа), 11 ашлык саклау амбары, бер яңа салынган машина лапасы, 150 кв.метрлык парник һәм теплица, басуда дүрт даими ындыр эшләнгән. Колхоз карамагында барлыгы 130 кв.метрлык өч торак йорт, 40 кв.метрлык идарә йорты, 30 бала йөри торган ясле өчен 1 бина булган.

1933 елда колхоз инде шактый зур күләмдә авыл хуҗалыгы инвентаре һәм машиналарга ия булган: 30 ике төрәнле, 12 бер төрәнле тимер сукалар, 28 тимер, 5 агачтан эшләнгән тырма, 2 болын тырмасы, 1 кул көче белән эшли торган культиватор (сөрелгән җирне йомшарткыч), 6 окучник, 2 чәчкеч, 4 лобогрейка, 4 атлы тырма, 8 печән чабу машинасы, 1 триер, 3 сортировка, 1 үзыргыткыч, 8 җилгәргеч, 1 җитен талкыгыч, 2 тамыр азыгы кискеч, 2 салам кискеч, 2 атлы ашлык сугу машинасы, 10 бер атлык арба, 67 төрле арбалар, 3 сепаратор. Бу машиналарның күбесен эшләтер өчен ат көче кулланылган.

Колхоз оешканда рәтле тимер сукасы да булмаган әртилнең өч ел эчендә шул кадәр моңа кадәр исеме дә ишетелмәгән җайланмалар һәм машиналарга хуҗа булуы авыл халкында бик зур кызыксыну уяткан. Әти сөйләгәннәрдән: колхозга яңа “машина” (эш коралы) кайтуны бала-чага гына түгел, яше-карты көтеп алган. Бу, һичшиксез, дәүләт ярдәмен күрсәтә торган фактор. Димәк, колхозлаштыру чорында дәүләт, берләшергә теләмәгән крестьяннарны куркыту - җәзага тарту кебек алымнарга гына таянмаган; аның кызыксындыру чаралары да җитәрлек булган. Беренче чиратта, аның яшь берләшмәләргә төрле ярдәм күрсәтүен әйтергә кирәк. Авылга үзәктән җибәрелгән авыл хуҗалыгы инвентаренең күптөрлелеге, колхозга тапшырылган терлекнең күплеге ярлыларга гына түгел, урта хәллеләргә дә әртилгә керү өчен көчле дәлил булган. Хакимиятнең көчләп колхозлаштыру темпын бераз киметүе, колхозның материаль-техник базасын булдыруга зур игътибар бирүе, колхозларга завод-фабрикалар күрсәткән ярдәмнең төрләре артуы, шул исәптән, аларны шефлыкка алу формалары күбәюе, ялгыз хуҗалыкларында чиләнгән крестьяннарга, ул чор шигарен кулланса к, “колхозга йөзләре белән борылырга” этәргеч булган.

1933 елгы отчетта колхозчыларның шәхси хуҗалыкларындагы маллары хакында да мәгълүмат бар: сыерлы хуҗалыкларның саны 92, бозау яки тана булган хуҗалыклар 38, сыер-бозаусыз хуҗалыклар 68; 71 хуҗалыкта 128 сарык, ике хуҗалыкта кәҗә булган; 89 хуҗалыкта кош-корт үрчеткәннәр (барлыгы 260 баш). Колхозчылар яшәешендә ихата янында һәм басуда үстергән бәрәңге һәм тары, җитен кебек игеннәрне үстерү бик зур роль уйнаган. Аларның шәхси хуҗалыгы саклануы шулай ук колхоз файдасына сөйләүче фактор һәм халык арасында таратыла торган бик күп мифларга киртә булган.

Отчетның бер бүлеге тулысынча чәчүлекләргә багышланган. 1933 елда 256 гектарга арыш чәчү каралган, арыш басуы 365,5 га булган; язгы бодайны 40 га урынына 60,5 га, солыны - 30 га урынына 41,8 га, ясмык 20 га чәчелгән. Вика, кара борчак, җитен шулай ук егермешәр гектар чәчелергә тиеш булган, ләкин симәнәләре булмаган. Бәрәңге 30 гектарга утыртылган, 5 гектарга

киндер чәчелгән. Планда булган 548 га урынына чәчүлекләр барлыгы 788,97 га җирне биләгән. Силос өчен куллана торган үсемлекләргә план буенча 10 га җир билгеләнгән булса, 3,25 га гына чәчелгән; тамыразык үсемлекләрен 15 га урынына 1,5 га гына чәчкәннәр. План буенча 892 га болыннан печән хәзерләнгән. Яшелчәләргә 40 га бирелгән, 40,5 гектарга яшелчә утыртылган (кәбестә, кишер, помидор, кыяр).

1933 елда колхозның кереме 74300 сум, шуның 31876,79 сумы дәүләткә сату хисабына булган. Чыгым 72226,78 сумлык булган. Шул акчадан 9758,94 сумы яңа төзелеш һәм ремонтка, 2600 сумы продуктовый терлек алуга, 715 сумы эш терлекләре алуга, 3669,76 авыл хуҗалыгы машиналары һәм кораллары алуга, 2647,35 сумы транспорт һәм башка инвентарь алуга, 15 сумы ферма җиһазлары алуга киткән. Бер хезмәт көненә 4,770 кг бөртекле ашлык, 0,310 кг яшелчә, 4 тиен акча туры килгән. Җыелган уңыш хакында мәгълүмат булмаса да, бу саннар үзләре үк 1932-1933 хуҗалык елы Бәзәкәдә уңышлы булуы хакында сөйли. Әти сөйләвенчә, бер яктан, 1933 елда колхоз ирешкән уңышлар, икенче яктан, колхозлаштыруга каршы булган берничә кешене авылдан сөрү, ялгыз хуҗалыкларның җирләрен киметү h.б. чаралар күп кенә бәзәкәлеләрне, совет хакимияте таләпләренә буйсынып, колхоз тормышын, теләсә-теләмәсәләр дә, кабул итәргә этәргән.

Архивта Сталин исемендәге колхозның 1935 елгы отчеты да сакланган. шуннан берничә мәгълүмат. 1936 елның 1 январенә колхозда 1829 кеше яшәгән 406 хуҗалык саналган, алардан 847 кеше эшкә ярарлык булган. Кыр бригадалары 6, тертекчелектә 1, яшелчәлектә 2, җитештерүче бригада 1 булган. 150 урынлы клуб, 50 кешелек уку йорты (изба-читальня), 50 балалык балалар бакчасы (детсад) булган. Эре мөгезле терлек саны 186-га җиткән (76-сы савым сыер), алар өчен яңа ферма җиткерелгән. 1935 елның 1 гыйнварына 160 ат булган (эш атлары – 126). 1936 елның 1 гыйнварына атлар саны 294-кә җиткән (эш атлары – 240). Умарталыкта ел башына 49 умарта, ел азагына 72 умарта булган. 1935 елда 1 хезмәт көненә 3,030 кг икмәк, 2,410 кг бәрәңге, 1,710 кг яшелчә, 6,420 кг салам, 0,02 тиен акча өләшенгән.

Отчетта колхозның җитәкчелек кадрларына да урын бирелгән. Колхоз рәисе - Мөхәмәтҗанов Фәрхи, 1903 елда туган, ВКП(б) члены, аз белемле; аның урынбасары - Фәйрушин Әхмәди, 1898 елда туган, аз белемле, колхозда 1931 елның 13 сентябреннән; ревкомиссия рәисе - Зәйнуллин Фәрди, 1909 елда туган, ВКП(б) члены, урта белемле (мәктәп директоры – А.М.); счетовод Гыйлфанов Габделхак, 1914 елда туган, белеме уртадан түбәнрәк, колхозда 1931 елның 23 апреленнән; сөт-товарлыклы ферма мөдире (МТФ) - Әхмәтҗанов Гали, 1912 елда туган, укый-яза белми, ВЛКСМ члены, колхозда 1931 елның 13 сентябреннән; кыр бригадалары бригадирлары: Мифтахов Кирами, 1914 елда туган, белеме уртадан түбәнрәк, колхозда 1934 елның 29 ноябреннән; Ибәтуллин Гали, 1909 елда туган, ВЛКСМ члены, белеме уртадан түбәнрәк, колхозда 1931 елның 14 октябреннән; Нәбиуллин Хәким, 1909 елда туган, белеме уртадан түбәнрәк, колхозда 1931 елның 12 апреленнән; Тажиев Минһаж, 1901 елда туган, белеме уртадан түбәнрәк, колхозда 1933 елның 6 маеннан; Гыйлфанов Нури, 1908 елда туган, белеме

уртадан түбәнрәк, колхозда 1931 елның 17 мартыннан; Гайсин Шәхми, 1895 елда туган, белеме юк, колхозда 1931 елның 10 апреленнән; яшелчә бригадалары бригадирлары: Ясәвиев Гали, 1915 елда туган, белеме юк, колхозда 1935 елның 27 июненнән; Гыймадиев Хәмәт, 1907 елда туган, белеме юк, колхозда 1933 елның 24 апреленнән.

1935 елдан соң да колхозга керүчеләр булган. Мәсәлән, авылның 1937-1939 елгы хуҗалык кенәгәләрендә 1936 елда 11 хуҗалык, 1937 елда 9 хуҗалык колхозга керүе күрсәтелгән 1938 ел башында колхозда 427 хуҗалык булган, ел барышында 23 хуҗалык кергән, бер хуҗалык чыгарылган. 1939 елның 1 январенә колхозда 446 хуҗалык булган. Эшкә яраклы колхозчылар 620 кеше булган. 1938 елда колхоз 1 йөк автомашинасы алган. Анда, алмашып, 2 шофер – Баһаветдинов Касыйм һәм Сиракаев Закир эшләгәннәр.

1940 елда колхозга кергән хуҗалыклар саны 447 гә җиткән. Аларда яшәгән 1839 кешенең 620-се эшкә яраклы саналган; моннан тыш, 193 эшкә яраклы 12 яшьтән 16 яшькә кадәрге яшьләр булган. Бу елда 60317 ир-ат хезмәт көне һәм 55500 хатын-кыз хезмәт көне эшләнгән. 10 кырчылык бригадасында 501 колхозчы, яшелчәлек бригадасында 58 колхозчы эшләгән; алма бакчасын 1 колхозчы караган, төзү эшләрендә 12 колхозчы, терлекчелектә 24 колхозчы хезмәт күрсәткән. Колхозда 5232,30 га гомуми җирләр, алма бакчасы 66 га, яшелчәлек 6 га, печәнлекләр 861,59 га, көтүлекләр 63,56 га, ихатадагы җирләр 103,62 га (447 колхозчы һәм 6 хезмәткәр хуҗалыкларында) саналган. Колхозның 360 аты, 100 савым сыеры, 160 бозавы булган. 300 тонна икмәк саклауга хәзерләнгән 5 амбары (55 тонна икмәк сыярлык берсе яңа салынган), 950 тонна бәрәңге өчен 3 бәрәңге саклау урыны булдырылган. Колхоз рәисе Мөхәмәтҗанов Фәрхи Мөхәмәтҗан улы, бухгалтер Мөхәмәтҗанов Гәрәй Закир улы, ревкомиссия рәисе Баһаветдинов Касыйм Баһаветдин улы булган. 11 бригадир, 1 агротехник, 1 ветфельдшер, 2 ферма мөдире, 2 шофер, 2 сыер көтүче, 24 конюх эшләгән.

Шулай итеп, без еллык дүрт отчетта бирелгән мәгълүмат белән таныштык. Алар Бәзәкәдә колхоз үсешен ачык тасвирлый. 1931 елда өстән кушу буенча 15 хуҗалыктан оештырылган ярлы гына әртил 5-6 ел эчендә зур күмәк хуҗалык булып китә алган. Бәзәкәлеләр акрынлап тормышның яңа шартларына җайлашканнар. Гаиләнең киләчәге турында, балаларны ашатыр өчен бер телем икмәк турында кайгырту икенче планга күчкән дип әйтеп тә була торгандыр. Коллективизация процессында бәзәкәлеләрнең җирләре, гади инвентаре, эш атлары күмәкләштерелгән. Колхозчылар кулланышында шәхси хуҗалыкларын алып барыр өчен 0,5 гектарга кадәр ихата җирләре, берәр сыер, вак терлек һәм кош-корт калган. 1935 елда кабул ителгән яңа авыл хуҗалыгы әртиле уставы авылда барлыкка килгән яңа мөнәсәбәтләрне законлаштырган, колхоз строеның хокукый нигезләрен, колхозда җитештерү һәм иҗтимагый тормышны оештыру принципларын билгеләгән.

Коллективизация авылда яшәү һәм хезмәт шартларын, гореф-гадәтләрне, тулаем алганда, тормыш рәвешен тамырдан үзгәрткән. Бу елларда авылда барган процесслар җәмгыять яшәешенең төрле яклары белән катлаулы һәм капма-каршы бәйләнештә булган. Авылның иҗтимагый

төзелешендәге кискен үзгәрешләрне аңлау һәм кабул итү өчен крестьяннарның уй-фикерләре, аң-зиһенендә дә үзгәрешләр – “зиһен революциясе” кирәк булган. 1932 елда илдә катгый паспорт системасы кертелгәннән соң колхозчылар гамәлдә җиргә беркетелгән булып чыга. 1935 елгы устав колхоздан ирекле рәвештә чыгуны да тыйган (күп кенә хәзерге галим һәм сәясәтчеләр колхозлаштыруны “Русиядәге икенче крепостнойлык чоры” дип юкка гына атамыйлардыр).

Мәчет-муллалар язмышы

Бисмилласын борынгылар әйткән,
Аминына әле шундый ерак...
Аңа хәтле бардыр янасылар –
Заманалар безнең шундыерак.
Харрас Әюп

Совет хакимияте урнашкан беренче көннәрдән үк дини оешмалар һәм дин әһелләренең эшчәнлеген чикләү башланган. РСФСР Халык комиссарларының советы (СНК) 1918 елның 20 гыйнварында “Вөҗдан иреге, чиркәү һәм дини оешмалар хакында” һәм 21 гыйнварда “Чиркәүне дәүләттән һәм мәктәпне чиркәүдән аеру хакында” исемле ике декрет кабул иткән. Мәктәпләрдә дин дәресләре укытуны тыйган бу декретлар дин әһелләрендә генә түгел, халык арасында да киң ризасызлык тудырган. Хәтта Казан Советының мөселман комиссариаты да бу декретларны ашыгыч рәвештә тормышка ашыруга каршы чыккан. “Мөселманнар үз мәдәни-милли һәм дини эшләрендә үзидарәгә хокуклы һәм Халык комиссарлары советының декретларын мөселман комиссариатлары аша кабул итә һәм, үз халкының рухы һәм көнкүреш шартларыннан чыгып, тормышка ашыра ала. Моның нигезендә аңлатыла ки, Казан губернасындагы барлык мөселман мәктәп-мәдрәсәләрендә дин дәресләре бернинди тоткарлыксыз укытылачак”, - дигән аңлатма бирелгән Комиссариатның 1918 елның 18 мартында кабул иткән карарында.

Шул ук елның маенда узган Казан губернасы татар мөгаллимнәре съезды бу декретларга карата үз мөнәсәбәтен махсус резолюциядә күрсәткән: “1. Казан губернасы мөселман мөгаллимнәре съезды динне дәүләттән аеруны котлый һәм бу чараның безнең күптәнге теләгебез булуын исбатлый.

2. Әгәр дә халкыбызның рухи тормышы, иҗтимагый һәм гаилә хәле хакында сөйләсәк, без түбәндәгене күрәчәкбез: безнең мәктәпкәчә һәм мәктәптән тыш тәрбиябез җайга салынмаган, бездә әле зыялы гаиләләр бик аз. Халык арасында җәмгыяви, дини, милли тәрбия шулай ук әлегә кирәкле юнәлеш алмаган. Шулай булгач, халкыбыз үз балаларына дөрес тәрбия бирүгә хәзергә берничек тә әзер түгел. Шуннан чыгып, съезд балаларга дини тәрбия бирүнең мөһимлеген таный һәм хәзерге моментта динне мәктәпләребездә укытуны кирәк дип таба; съезд хәзерге хакимиятнең дә, халык фикере белән шулай ук килешеп, бу карарга уңай карашына ышана”.

Шулай итеп, Казан губернасы татар укытучылары съезды, халкыбызның рухи тормышында диннең зур роль уйнавын ассызыклап, мәктәпне кичектерүсез мәчеттән аеруга каршы булган. Ул татарларда укыту һәм тәрбия системасының ислам диненең югары әхлак принципларына нигезләнгән традицион тамырларын саклауны яклап чыккан. Бу карарлар хакимият органнарының мөселман дини мәктәпләргә мөнәсәбәтен уңай якка үзгәртмәсә дә, күпмедер вакыт төбәкләрдә яңача укытуга күчү барышын артык зыян китермичә башкару мөмкинлеге биргән.

Үзәк һәм җирле органнар авыл тормышын нигездән үзгәртергә тырышканнар. Әгәр дә җир эшләрен рәткә салу халыкны азык-төлек белән тәэмин итү өчен кирәк булса, икенче (большевиклар өчен, бәлки, беренчедер дә) мөһим проблема – авыл халкының аң-фикерен советлар ягына тарту булган. Моны эшкә ашыру өчен хакимият, беренче чиратта, дин әһелләренең авыл халкына йогынтысын киметү кирәк дип тапкан. Шуңа күрә борын заманнан дин әһелләренең функциясе саналган эшләрне берәмтекләп тә, мөмкин булганда, берьюлы да Совет властеның беренче елларында ук алардан тартып ала башлаганнар. Мулла-мәзиннәргә балаларны укытуны тыю (бу функция махсус ачылган дөньяви мәктәпләргә, мөгаллимнәргә тапшырылган), халык арасында туу, үлү, өйләнешү, аерылышу фактлары теркәлеп барган метрик кенәгәләрне алып баруны бетерү (бу эшләр авыл советларына күчкән), аларны халык дошманы дип игълан итү h.б. шундый адымнар дин әһелләрен халыктан читләштерү өчен эшләнгән.

Советлар хакимияте игълан ителгәч тә кабул ителгән “Динне дәүләттән, мәктәпләрне диннән аеру” хакындагы декретлар гына җитмәгән бу очракта. 1923 елда СССРның эчке эшләр наркоматы (НКВД) илдәге дини оешмаларны исәпкә, үз контроленә алу эшен башлап җибәргән. Моның өчен барлык дини оешмалар (шул исәптән мәхәллә-приходлар да), НКВД бүлекләрендә теркәлергә тиеш булганнар. Татарстан милли архивы фондларында Бәзәкә мәчетләре теркәлүгә багышланган материаллар сакланган. Алар ике мәхәллә җыелышларында кабул ителгән карар һәм исәпкә алу хакындагы гаризалар, җыелыш протоколлары (җыелыш беренче мәхәлләдә 1923 елның 23 июлендә, икенчесендә 31 июльдә узган), дини оешма уставлары, оештыручылар, дин әһелләре һәм мәхәлләнең башкарма органнары әгъзаларының исемлекләреннән гыйбарәт. Барлык бу документлар бер-берсенә тәңгәл килүен, исемнәрдә генә аерма булуын күрсәтеп, аларның эчтәлегенә тукталыйк. Менә 23 июльдә узган гомуми җыелышның карарлары: “1. Беренче мәчет каршында Бәзәкә дини җәмгыятен оештыру.

2. Совет властен тану.

3. Хәзер эшләп килүче мөселман советын тану.

4. Хөкүмәт тарафыннан эшләнгән дини оешма уставын кабул итү.

5. Оештырыла торган мәхәлләне теркәү хакында мөрәҗәгать итү”.

Беренче мәчет мулласы булып революциягә кадәр дә шул мәчеттә эшләгән Хәлимов Фәтхетдин, азанчы булып аның энесе Сәйфуллин Әхмәтсафа сайланган. Беренче мәчетнең идарәсенә, алардан тыш, Ибәт Фәтхуллин, Хөсәенов Авзалетдин һәм Мәхмүтов Хаҗиәхмәт (секретарь)

кергән. Икенче мәчеттә шулай ук элеккеге дин әһелләре – мулла Минехуҗин Мөхәммәтзакир, азанчы Хөснетдинов Гыйлфан, идарәгә Хуҗин Закир, Шәрәфетдинов Гыйлфан, Шәймәрданов Фәттах, Сираҗетдинов Фәрдетдин сайланганнар. Хөснетдинов Гыйлфан секретарь дип күрсәтелгән.

Карарның дүртенче пунктына игътибар итик. Дини җәмгыятьнең уставы хөкүмәт тарафыннан хәзерләнгән, димәк, ул, бер хәрефе дә үзгәртелмичә, кабул ителергә тиеш булган. Хөкүмәт тарафыннан эшләнгән мәхәллә уставының алтынчы маддәсендә мәхәлләнең ябылу тәртибе билгеләнгән. Аның өч очракта ябылуы каралган. “1)губерна яки өлкә карары буенча; 2) оешма әгъзаларының бер өлеше кулга алынса һәм 3) оешма әгъзаларының гомуми җыелышы карары нигезендә. Мәхәллә ябылган (таратылган) очракта җәмгыять файдалануында булган аның барлык милке җыелышта билгеләнгән махсус вәкил төзегән инвентарь исемлеге буенча җирле советка кайтарыла”, - дип язылган анда. Мәчет каршында дини оешмалар булдыру халык теләге белән эшләнгән эш кебек күренсә дә, гамәлдә бу дәүләтнең мәчет-муллалар эшчәнлеген даими күзәтү астына куюны сиздермәс өчен генә булган. Мәчет-мәхәлләләрне катгый кысалар эченә кертеп, атеистик рухтагы тәрбияне алга сөргән хакимиятнең, төрле чаралар ярдәмендә рухи, мәдәни, сәяси өлкәләрдәге үз көндәшен юкка чыгарырга тырышуы дип аңлап була.

Дингә каршы алып барган көрәшендә хакимият киң рәвештә матбугаттан файдаланган. Дин әһелләрен контрреволюцион эшчәнлектә, советларга каршы агитация алып баруда гаепләүләрне үзәк һәм җирле матбугатта бастыру гына җитмәгән, рус һәм башка телләрдә (әлбәттә, татар телендә дә) дингә каршы булган гәзит-журналлар чыга башлаган. Мәсәлән, “Атеист”, “Безбожник” исеме белән Мәскәүдә оештырылган басма органнарны әйтеп була. 1925 елда илдә массакүләм “Союз воинствующих безбожников (Сугышчан алласызлар союзы)” оештырылган. 1929-1933 елларда Казанда ВКП(б)-ның Татар обкомы каршында эшләгән Сугышчан алласызлар советы шул ук исемдәге “Сугышчан алласызлар (Воинствующие безбожники)” журналын чыгарган. Бу һәм шуңа охшаш башка оешмаларның әһелләре халык арасында атеистик карашлар пропагандасын алып барган, мәчет һәм чиркәүләрне ябу һәм җимерү эшләрен дә башлап йөргәннәр. “Алласызлар” һәм башкалар дингә, дини бәйрәмнәргә, дин әһелләренә каршы төрле чаралар оештырганнар, “дәһриләр атналыклары” уздырганнар.

Шулай да, әти һәм аның яшьтәшләре искә алуынча, Бәзәкәдә “алласызлар” бик мантый алмаган. Әлбәттә, яшьләр арасында бу оешма бүлеген булдырырга тырышучылар булган. Ләкин борынгыдан нык әхлак нигезләрен саклап килүче авылда аларның мәчетләрне җимерергә чакыруларын хәтта яшьләр дә кабул итмәгән. Бары тик вакыт-вакыт кына берничә “кызыл авыз, халыкны шомга салып, дөнья бозып” йөргән (бу күршебез Шоңкар абзый сүзе). Аларның конкрет эшләре дә, дини бәйрәмнәр алдыннан мәктәпкә җыелып, “Сугышчан листок”лар чыгару, мулла һәм куштаннарны кимсеткән такмаклар әйтеп, дини бәйрәм көннәрендә урамнан узулардан артыкка китмәгән. “Алласызлар союзы” бүлекчәсен Бәзәкәдә

оештырырга теләгән берничә укытучыны халык авылдан ук куып җибәргән, ә аларга иярергә теләгән яшьләрне ата-бабалары “акылга утырткан”.

Минем әни Вәлиәхмәтева Рөкыя Әхмәт кызы (1912-1982) нәкъ шушы чорда Бәзәкәгә эшкә килгән. Аны 1931 елның августында Алабугадан монда укытучы итеп җибәргәннәр һәм комсомол оешмасының эшен җанландыруны йөкләгәннәр. Ул, актив яшьләр белән танышып (алар арасында бер-ике комсомол әгъзасы да булган), аларга комсомолның төп бурычлары яңа тормыш төзү, авыл яшәешенә яңа төсмерләр кертү булуын, бу эшләрне булганны җимерүдән башлау зур ялгыш булачагын төшендерергә тырышкан. Яшьләрнең яңалыкка омтылуын халык кабул итсен өчен аларның үзләренә зур көч куярга кирәклеген аңлатуларын сөйли иде безгә әниебез.

1920 еллар азагында, Советлар Союзында дин әһелләренә каршы көрәш көчәйгән чорда, Бәзәкә муллалары да сакланып кала алмаган. Совет чорында аларның язмышы, илдәге миллионлаган дин әһелләре язмышы кебек, бик аяныч булган (иң бәхетлеләре, репрессияләр башланганчы, үлеп котылган дип әйтеп була). Габделхәлим ахун Сәйфуллин, Бәзәкәгә XIX гасыр урталарында читтән килгән мулла, гасыр азагында ук беренче мәхәллә белән җитәкчелек итүне улларына тапшырган. Ул 1917 елда 85 яшендә Бәзәкәдә вафат булган. Бәзәкә зиратында күмелгән булса да, үлеме болгавыр елларга туры килү сәбәпле булса кирәк, каберенә таш куелмаган. Аның улы Фәтхетдин мулла (1864-1924) беренче мәчеттә 40 елга якын имам булып торган. Белемле (Иж-Бубыйда белем алган), зыялы имамга Совет властеның беренче елларында күп кенә кайгы-хәсрәтләрне кичерергә туры килсә дә, аңа үз түшәгендә җан бирү “бәхете” насыйп булган. Бәзәкә зиратында аның кабере хәзер дә саклана, 1926 елда куелган кабер ташы да бар.

Ә менә аның энеләре Рәфагетдин (1876-1937) һәм Әхмәтсафаның (1884-1975) язмышлары күпкә фаҗигалырак килеп чыккан. Алар үзләре дә, гаиләләре дә 20-30 еллар корбаны булган. Әхмәтсафа хәзрәт, беренче мәчетнең азанчысы, Бәзәкәдәге башка дин әһелләре белән бер үк вакытта беренчеләрдән булып сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән була. Аның һәм гаиләсендәгеләрнең исемнәре 20-30 елларда төзелгән хокуксызларның барлык исемлекләрендә күренә. Бәзәкә авыл советыннан, аны яклап, төрле оешмаларга җибәрелгән мөрәҗәгатьләре дә архивта сакланган. Бәлки шуңа күрәдер, аны, берничә тапкыр Алабуга төрмәсенә эләксә дә, гел ирекка җибәргәннәр. Нигаять, 1929 елда аны авылдан сөргәннәр, һәм ул гаиләсе белән, Владивостокка барып чыгып, шунда төпләнеп калган. Аның улы Әхмәтзыя һәм асрауга алган кызы Сәкинә шунда югары белем алганнар, зур урыннарда эшләгәннәр. Әхмәтсафа хәзрәт озын гомерле булган, әле 60 еллар азагында ул Бәзәкәгә кунакка да кайткан.

Рәфагетдин хәзрәт башта гади крестьян тормышын сайлаган, ваклап сату белән дә шөгыльләнгән булса да, әтисе вафатыннан һәм энесе сөрелгәннән соң, авылдашлары тәкъдиме буенча, беренче мәчеттә азанчы вазифасын башкарган. Шуңа күрә ул, ахун малае, сатучы һәм азанчы буларак, сайлау хокукыннан мәхрүм ителгән. Ул да 30-елларда берничә

тапкыр Алабуга төрмәсендә утырып чыккан. 1937 елда шунда ук атып үтерелгән.

Түбән мәчет муллаларының язмышы да шулай ук фаҗигалы булган. Алар шулай ук 20-еллар урталарында сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгәннәр. Минехуҗин Мөхәммәт-Закир, әтисе Гыймранов Минехуҗа вафатыннан соң, 1895 елдан, икенче мәчет имам-хатыйбы булган, 1924 елда мәхәлләне теркәгәндә дә мулла буларак сайланган. 20-еллар урталарында аның исеме хокуксызлар исемлекләрендә очраса да, аның моннан соңгы язмышына бәйле документлар архивларда очрамады. Күрәсең, ул да, заман борчу-авырлыкларын күтәрә алмыйча, 20 елларның икенче яртысында вафат булгандыр.

Закир хәзрәтнең олы улы, Гыймранов Әхмәтзәки (1898-1937), 1913 елны Алабуга рус-татар мәктәбен тәмамлаганнан соң, хезмәт юлын Уфа сәүдәгәре Хәкимов кантурында башлап җибәргән. Күрәсең, ул милли-революцион хәрәкәттә катнашкандыр – ак чехлар Уфаны алгач, аны төрмәгә япканнар. 1918 елдан большевиклар партиясендә. 1919 елда Кызыл Армиядә, 1919-1920 елларда Урал өлкәсе ревкомында милли бүлекне җитәкләгән. 1920-1921 елда Мәскәүдә РКП(б)ның оештыру эшләре бүлегенең төркиләр юнәлешендә җаваплы хезмәткәр, 1921 елда Оренбургта РКП(б)ның кыргыз (ул вакытта бу исемне казахлар йөрткән) бүлеген җитәкләгән. 1922-1929 елларда Зәки Гыймранов Казанда, РКП(б)ның шәһәр һәм өлкә комитетында эшләгән, өлкә комитетының чоры өчен бик мөһим булган агитация һәм пропаганда бүлеген җитәкләгән.

1929 елда Зәки Гыймранов яңадан эшли башлаган Казан политехника институты директоры итеп билгеләнгән. 1930 елда бу институт ике мөстәкыйль институтка бүленгәч (химия-технология һәм коммуналь-төзелеш институтлары), ул 1930-1933 елларда Казан коммуналь-төзелеш институтын җитәкләгән, ягъни хәзерге көндә Казан архитектура-төзелеш университеты исемен йөртүче югары уку йортының беренче директоры, аның аякка басып китүенә зур көч куйган шәхес булган. 1934-1936 елларда ул Татарстан китап нәшриятында фән-техника бүлегенең баш редакторы булып эшләгән. 1936 елның 10 сентябрендә ул, “милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасында катнашуда” гаепләнеп, кулга алынган һәм Мәскәүгә җибәрелгән. СССР Югары судының хәрби коллегиясе тарафыннан 1937 елның 3 августында атып үтерү һәм милкен конфискацияләүгә хөкем ителгән. Приговор шул ук көнне Мәскәүдә тормышка ашырылган. Зәки Гыймранов 1957 елның 8 октябрендә акланган.

Икенче мәчетнең азанчысы Гыйлфан Хөснетдинов (1876-1936?), башка дин әһелләре кебек үк, 20-елларда сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән, төрле өстәмә салымнар һәм башка чикләүләрне тулысынча үз җилкәсендә татыганнан соң, 1929 елның 10 декабрендә кулга алынган. ТАССР-ның ОГПУ каршындагы “өчлек” тарафыннан 1930 елның 5 февралендә, 58-11 маддә буенча “Совет власте чараларына каршы агитация өчен”, милке конфискацияләнеп, Северный крайга биш елга сөргенгә озатылган. Аның дүрт баласы (өч улы һәм кызы) әниләренең әнисе Раузателҗинан әби (1870-

1964) карамагында калган. Йорт-каралтысыз калган бу гаилә күп еллар чит кешеләрнең өй-мунчаларында күченеп яшәргә мәҗбүр булган. Әбинең оныкчыгы Гүзәл Габдуллина искә алуынча, Җинан әбинең олы оныгы Габделхак 30-еллар урталарында салып кергән йорт аларның 17-тапкыр күченүе булган. Ә Гыйлфан Хөснетдинов үзе, 1935 елда сөргеннән әйләнеп кайтса да, Бәзәкәдә яшәмәгән. Улларына авырлык китермәс өчен ул күпмедер вакыт әрәмә һәм Идел буендагы землянка-куышларда яшәгән, салкын тидергән һәм 1936-1937 елларда вафат булган.

Бәзәкәдә дин әһеле буларак хокуксызлар исемлегенә эләккән башка кешеләр дә бар: 1876 елда туган мулла малае, азанчы Кудрячов Латыйп 1881 елгы хатыны Әсма белән, 1865 елгы азанчы Гыйззәтуллин Әхмәт 1897 елгы хатыны Шәмсеҗәмал белән, 1870 елгы Хөсәенов Афзали, 1875 елгы хатыны Гиззениса һәм 1913 елгы кызы Рабигаларның исемнәре берничә исемлеккә кергән. Күрәсең, бу бәзәкәлеләр, авыл мәчетләре муллаларсыз калганнан соң, дини йолаларны үтәүне үз өсләренә алганнардыр. Менә архив кәгазьләре арасына кергән бер дәфтәрдәге каралама язмадан өзек: “Бәзәкәдә ике мәчет эшли: 1 мәхәллә Хафизов Закир – колхозчы, дин обрядларын алып бара, 2 мәхәллә – Мөхәммәтҗанов Шакиржан, колхозчы. Хөсәенов Апзал элеккеге мәзин җитәкче, Хәбибуллин Баһаветдин сторож”. Эчендә каралама язмалар булган бу гади дәфтәр хокуксызлар исемлекләре төпләнгән папкага ничектер кереп эләккән; язмаларның авторы да, вакыты да куелмаган. Эчтәлеге буенча, аларны Бондюг районы Алабуга районыннан аерылып чыккан 1935-1936 елларда район белән танышып йөргән башкарма комитет хезмәткәренең үзе өчен язган караламалары булгандыр дип әйтергә мөмкин. Ә аның эчтәлегеннән исә, бәзәкәлеләр мулла-мәзинсез калгач та, мәчетләрен әле эшләтеп килгәннәр, ләкин дини йолаларны гади колхозчылар гына башкарган дигән нәтиҗәгә киләбез.

1935 елда тагын мәчетләрне ябу һәм мәчет манараларын кисү хакында сөйләнә башлаганнар. Район оешмалары кушуы буенча авыл советы бу мәсьәләне хәтта махсус утырышка чыгарган. Әниебез сөйләвенчә, укытучылар мәчет манараларын кисүне дин белән көрәш дип аңлау наданлык билгесе генә булуын авыл активына аңлата алганнар. “Төрле манаралар шәһәрләрдә дә, авылларда да бар. Ул чиркәү манарасы да, пожар каланчасы да, зур шәһәр йортларын бизәү өчен эшләнгән башнялар да булырга мөмкин. Әгәр дә рус авылларын ябылган чиркәү манаралары һәм каланча сурәтләре буенча ерактан танып булса, нигә әле без, мәчетләрне ябып, аларны мәдәни учак итеп файдалансак та, манараларны кисәргә тиеш? Алар да авылыбызны бизәп тора торган төзелеш үрнәге, татар авылы булуын ерактан күрсәтәләр ич”, - дип, авылдашларын үгетләгән алар. Шулай итеп, 1935 елда бәзәкәлеләр мәчетләрен саклап кала алганнар.

1935 елның 29 мартында язылган дини биналар турындагы белешмәдә Алабуга районыннан аерылып чыккан Бондюг районыда 24 дини бина булуы күрсәтелгән. 1936 елның 1 апреленә аларның 17-се ябылган булган. Шулардан 13 бина мәдәни оешмаларга бирелгән, 4 бина склад буларак файдаланылган. Ябылмыйча 6 дини бина калган; аларның дүртесе эшли,

икесе эшләми торган дин йортлары булган. Эшли торган 4 мәчетнең икесе Бәзәкә авылында, берәр мәчет Камай белән Абалач авылларында урнашкан. Эшләми торган дин йортлары – Озын Тау һәм Тат.Чаллы чиркәүләре. Районда рәсми теркәлгән 4 дин әһеле булуы да күрсәтелгән (аларны эшләвен дәвам иткән дүрт мәчет муллалары булырга тиеш дип фаразларга була). Белешмәдә татар авылларында гына дини йортлар (мәчетләр) саклануы, бу өлкәдә эшне арттыру кирәклеге ассызыкланган.

1937 елның 8 августында ТАССР Үзәк башкарма комитеты Президиумы утырышында башка мәсьәләләр белән бергә дин йортларын куллану мәсьәләсе дә каралган. Утырыш протоколының өземтәсе “бәян ителергә тиеш түгел” дигән өстәмә белән районнарга җибәрелгән. Шул өземтәдән ике маддәсен монда кертергә булдым: “1. Эшли торган чиркәү һәм мәчет биналарын колхозларның һәм дәүләт оешмаларының ашлык складлары итеп куллануны катгый тыярга.

2. Элек ябылган чиркәү һәм мәчетләр мәдәни оешмаларга бирелергә тиеш; дин йортлары мәдәни оешмалар өчен җиһазланмаган очракта, колхозчылар, колхозлар һәм авыл советлары мәрәҗәгате һәм район башкарма комитетлары рөхсәте буенча, вакытлы чара буларак, бу биналарны ашлык саклау өчен файдаланырга мөмкин”.

Татар халкы никадәр генә мәчетләрен саклап калырга тырышмасын, заман һәм дәүләт сәясәте үзенекен эшләгән: акрынлап халыкның менталитеты үзгәргән, мәчет-муллаларсыз тәрбияләнгән яңа буыннар үсеп җиткән. Бәзәкәдә дә мәчетләргә йөрүчеләр азайган, дини йолаларны ачык рәвештә үтәү кешеләрдән шактый зур батырлык таләп иткән, динне саклау, балаларга догалар өйрәтү гаиләләрдәге хатын-кызлар кулына күчкән, ягъни тыелган шәхси эш кенә булып калган. Нәтиҗәдә 1939 елга Бәзәкәдә икенче мәхәллә (түбән оч) мәчете бөтенләй бушап калган. Беренче мәхәллә мәчетендә дә җомга һәм бәйрәм намазлары гына укылган, анда да картлар гына катнашкан. Бәзәкә халкы аңында акрынлап, мәчетләрне дин йортлары буларак ябып, биналарын мәдәни максатларда куллану зарурилыгы фикере ныгый барган.

1939 елның март – апрель айларында “Бәзәкә авылы каршында булган колхозчы, эшче, интеллигенция һәм аерым хуҗалыкларның” өч гомуми җыелышы уздырылган. Гомуми җыелышның өч мәртәбә уздырылуы – карар кабул итү өчен кворум кирәк булуы белән аңлатыла (сайлау хокукы булган халыкның кимендә 2/3 өлеше ризалыгын бирергә тиеш булган, ә авылда бу кадәр халыкны сыйдырырлык бина булмаган). Көн тәртибендә “Бәзәкә авылы күләмендә сельмаг, балалар тудыру йорты, фельдшер пункты ачу өчен помещение табу мәсьәләсен хәл кылу” булган.

Март азагында узган беренче җыелышның беркетмәләре сакланмаган. 5-6 апрельдә узган икенче һәм өченче утырыш беркетмәләрендә булган мәгълүмат белән танышыйк. Икенче җыелышта 426 кеше килүе каралган, 316 кеше катнашкан, (өченчесендә 456 – 323). Җыелыш рәисе – Көләчев Г., президиумда Ибәтуллин Гали, Әһлиева Газзә, Газизова Татҗибә, Хәсәнов Фазлый, Кәлимуллин Пәрәвәй, Газизов Минәхмәт; секретаре Белов

(укытучы) булган. Беренче чыгышны Ахметшин фамилияле кеше (район вәкиле булырга тиеш) ясаган: “Кыска вакыт эчендә салына башлаган клубны төгәлләп, сельмаг, балалар тудыру йорты, фельдшер пункты, конный двор, мастерской, артезиан коесы булдыру кирәк. […Моның өчен] хәзерге вакытта буш торган мәчетне мәктәпкә биреп, мәктәптән бушаган йортларны сельмаг, фельдшер пункты, бала тудыру йорты өчен файдаланырга. Бу карарны авыл советы кабул иткән. Сез дә кушылырсыз дип ышанам”. Бу фикерне яклап, Зиннуров, Ибәтуллин, Смирнов, Көләчев, Гобәйдуллин Гомәр, Кәримов, Әхмәтҗанов Галиәхмәт, Бәшаров Госман, Шәйдулаев Шакый чыгышлар ясаган. Сабитов һәм Мөхәмәтшин мәчетне мәктәпкә бирүгә каршы килгәннәр, Сабитов, “агач табып, сельмаг салырга кирәк, ди”. Низаметдинов Газиз “сельмагка правление амбарын бирергә кирәклеген әйтте”. Җыелыш “мәчетне мәктәпкә биреп, мәктәптән бушаган йортларны сельмаг, фельдшер пункты, бала тудыру йорты өчен файдаланырга” дигән авыл советы карарын 314 тавыш белән кабул иткән.

Өченче җыелыш 6 апрельдә узган. Катнашырга тиешле 456 кешенең 323 килгән. Җыелыш рәисе – Көләчев Г., президиумда Ибәтуллин Гали, Әхмәтҗанов Әлмөхәмәт, Низаметдинов Габдрахман, Вәлиева Зифа, Ибраева Маһинур, Шиабиев Закир; секретарь Исхаков. Шул ук мәсьәлә тикшерелгән. Алдагы көндәге җыелышта кабул ителгән карарны яклап, Хәбибуллин Хөсәен, Мәрданов, Шәйдәүләтов Шакый, Исхаков, Башаров, Мәхмүтов сөйләгән. Бу җыелышта хатын-кызлар да активрак булган. Беренчеләрдән сөйләгән Низаметдинова Сабира һәм Сабирова Мәмдүдә: “Без ул мәчетне авыл белән икмәк, йомырка җыеп төзедек, яңа биналарны да шулай салырга кирәк”, - дигән тәкъдим керткәннәр. Солтанова Сәүдә дә аларның тәкъдимен яклап чыккан. “Мәрданов һәм Шәйдәүләтов: 5-10 картның мәчеткә йөргән “сәвабы” безгә булмаячагын, ә яңа оешмаларның файда китерәчәген сөйлиләр”, - дип язылган беркетмәдә. Ибәтуллин да: “Әгәр мәчет бирелсә, 1-Майга кадәр сельмаг ачылачак”, - дип өстәп куйган. Бәшаров һәм Мәхмүтов: “Бу мәчетне бирмәскә тырышучылар дин белән халыкның башын бутаучылар, 314 кеше карарга кушылды, сез дә кушылырсыз дип ышанам”, - дип, чыгышларны йомгаклаганнар. Бу юлы авыл советы карарын 321 тавыш белән кабул иткәнәр.

Җыелыш протоколларына катнашучыларның икенче мәхәллә мәчетен ябу белән килешүләрен имзалаган исемлеге дә беркетелгән. Мәчетне япканда тутырылган анкетада ике Бәзәкә мәчетеннән берсе генә эшләве, ансына да 10-15 кеше генә йөрүе күрсәтелгән. Сайлау хокукы булган 915 кешедән өч җыелышта 735 кеше катнашуы, 731 кешенең мәчетне мәктәпкә бирүне яклавы, 4 кешенең каршы булуы әйтелгән. Мәчет бинасын мәктәпкә бирү карары, аңа, класс бүлмәләре итеп файдалану өчен, күпмедер ремонт эшләре кирәклеге, бу эшләргә мәктәпнең акчасы җитәрлек булуы да күрсәтелгән. Барлык бу документлар нигезендә Татарстан АССРның Югары советы Президиумының 1939 ел 5 май Указы дөнья күргән. Аның эчтәлеге: “Бондюг район Башкарма комитеты президиумының 1939 ел 13 апрельдә кабул ителгән Бәзәкә авылы икенче мәхәллә мәчетен ябу турындагы карарын

расларга. Мәчет бинасын мәктәп итеп файдалану өчен Бондюг райисполкомына тапшырырга.

Президиум рәисе Г.Динмухаметов

Президиум секретаре урынына Г.Ишмуратов

Казань, Кремль, 5 май 1939 ел”.

Районда бердәнбер булып калган Бәзәкәнең беренче мәхәллә мәчете 1941 елда ябылган. Аны ябу процедурасы да 1939 елдагы кебек булган. Ләкин бу юлы 1941 елның гыйнвар-февралендә узган җыелышларның беркетмәләрендә авыл хәлләре хакында да язмалар бар. Мәсәлән: Авыл советы рәисе Гыймазетдинов (1941 ел, 23 гыйнвар): “Узган елда без 1939 елгы икмәкне берничә грамм һәм 1 кг-га якын череп беткән печән өләштек. Бу елда 1 кг-га якын икмәк, 2 кг салам һәм 2 кг печән өләштек. Узган ел безнең симәнә җитмәсә, бу елда тиешле симәнәләр салып куелган. […] Сәламәтлек саклау эше ифрат начар тора”. Бу җыелышта 72 кеше генә катнашкан. Беренче мәхәллә мәчетен культура йорты итү, фельдшер пункты ачу хакында сүз барган.

24 гыйнварда барган икенче җыелыш 332 кеше катнашында булган (468 кеше катнашырга тиеш булып, 19 кеше авыру, 117 кеше “өйдә юк” дип язылган). Гыймазетдинов: “Авылыбызда уку йорты, бала тудыру йорты, библиотека, клубыбыз, урта мәктәбебез һәм яхшы культурный юлыбыз бар. […] Кимчелек - фельдшер пункты юк”. Өченче җыелыш 6 февральдә булган. Аның карары:

“1. Авыл башкарма комитеты карамагына бирелгән беренче мәхәллә мәчетен балалар бакчасына файдалану өчен бирергә.

2. Колхоз идарәсенә йөкләргә тиз көн эчендә шул йорт бәрабәренә балалар бакчасының иске коммуникацияләрен фельдшер пунктына яраклы итеп китерүне”.

Беренче мәхәллә мәчете бинасын Бәзәкә авыл советы башкарма комитетына тапшыру турындагы акт 1941 елның 2 февралендә төзелгән. Аның эчтәлеге: “Аерым җаваплы кеше булмагач, комиссия кергән вакытта мәчетнең ишекләре биксез, ачык, хуҗасыз хәлдә калган. Мәчетнең состояниесе: Мәчет агачтан эшләнгән тар фундаментка салынган. Буе өйалды белән 22 м, иңе 7,5 м, биеклеге эчтән 3,5 м, такта түбәле, 1924 елда яңартып салынган. Ишек алды агач рәшәткә белән әйләндерелгән. Мәчетнең советы яисә аның махсус кешеләре булмаганлыктан комиссия шул хәлдә кабул итте”. Мәчетнең җаваплы кешеләре булмаганлыктан, аның булган милке исемлеген дә комиссия язган: “унлы асылма лампа – 2 (берсе пыяласыз), утызлы лампа – 1 (пыяласыз, тишек, ага), идәнгә җәйгән кошма – 21 (икесе өзгәләнгән), чүбек җәймә – 1 (иске, иңе 2х2,5 м), утын – чама белән 3 кубометр”.

1941 елның 7 февралендә Бондюг районы башкарма комитетының чираттагы утырышында Бәзәкә авыл советы соравы буенча көн тәртибенә кертелгән авылда беренче мәхәллә мәчетен ябу мәсьәләсе дә каралган. Шул утырыш карарыннан: “1. Бәзәкә авылы халкының өч җыелышы узган, аларда 872 сайлаучыдан 635 кеше бер тавыштан мәчетне ябу турында карар кабул

иткән; шуннан чыгып, Бәзәкә авылында беренче мәхәллә мәчетен ябу хакындагы материалларны закон буенча дөрес әзерләнгән дип санарга.

2. Татарстан АССРның Югары советы Президиумыннан мәчетне ябуны һәм бинасын Бәзәкә авыл советы кабул иткән карар буенча мәдәни оешма кулланышына тапшыруны раслауны сорарга”.

Татарстан АССР Югары советы Президиумының Бәзәкәдә беренче мәхәллә мәчетен ябу хакындагы Указы 1941 елның 11 мартында чыккан. Шулай итеп, мәчеттән читләшеп өлгергән бәзәкәлеләр сугыш башланыр алдыннан райондагы соңгы мәчетне япканнар. Ике мәчетнең бинасы да әле озак вакыт бәзәкәлеләргә хезмәт итте. Түбән оч мәчетендә (бәзәкәлеләр икенче мәчетне шулай атыйлар иде) 50-еллар урталарына кадәр Бәзәкә урта мәктәбенең башлангыч класслары укыды (мин үзем дә анда беренче класста укыдым), аннан соң чит авыллардан килеп укучылар өчен интернат булды. Югары оч мәчетенә 1941 елның язында балалар бакчасын күчерделәр (мин өч ел анда йөрдем). Ике мәчет манарасы да озак вакыт авылыбызны бизәп торды. 1951 елның җәендә көчле яшенле яңгыр вакытында югары оч мәчете манарасын яшен сугып, аның калдыкларын сүтеп, түбәсен яңадан ябуларын ул вакытта Бәзәкәдә булган һәркемнең исендәдер әле. Мин дә хәтерлим: көчле яңгыр коя, бертуктаусыз яшен яшьни, күк күкри... Без өйдә (өебез кече урамда булса да, мәчет турысында ук)... Кинәт бик каты шартлау ишетелде һәм мәчет манарасы яна башлады. Манарасыз ятим калса да, мәчет бинасы әле озак еллар балалар бакчасы вазыйфасын үти килде. Түбән оч мәчетенең манарасы 1958 елның җәендә кисеп алынды. Ә мәчет биналары 70 – еллар урталарында сүтелде.

“Без кабызган утлар...”

Алгы көннәр ягына табан
Минем дә бит китәсем килә:
Киләчәккә җитәсем килә! -
Урла мине, алып кит, Заман,
Алгы көннәр ягына табан!

Хәсән Туфан

Большевиклар алдына хакимияткә килгәннән соңгы беренче биш-алты елда яңа совет системасының барлык структураларын оештыру һәм аякка бастыру мәсьәләсе килеп баскан. Бу эшнең иң мөһим юнәлешләренең берсе булып, яңа совет мәктәбен төзү мәсьәләсе булган. Яңа милли мәгариф системасын оештыруда Советларның башкарма комитетлары составында барлыкка килгән төрле исемдәге мөселман бүлекләре зур роль уйнаган. Совет хакимиятенең беренче көннәреннән үк оешкан Алабуга өяз Советы башкарма комитетының мөселман комиссариаты татар авылларында агитация һәм аңлату эшләрен җәелдереп җибәргән. Бу бүлеккә җыелган татар дөньясын революция ярдәме белән яңартуга ышанган укымышлы яшьләр өяздә яңа тормыш оештыру эшенә җиң сызганып керешкән. Юныс Вәлидов, Гасыйм Мансуров, бертуган Гыйрфан һәм Гобәйдулла Балтановлар, үз тирәсенә өяздә бик аз санда булган татар мөгаллимнәрен җыеп, эшне халыкны

мәгърифәтләү, яңача белем бирә торган мәктәпләр, уку йортлары, төрле түгәрәкләр оештырудан башларга булганнар.

Бәзәкәдә Совет властен пропагандалау һәм яңа тормыш өчен агитация эшенә яшь мөгаллимнәр Зиннур Бәшаров, Мәхмут Сәйфуллин, Насырттин Балтин алынганнар. Бәшаров Зиннур Гыйлмебәшар улы (1895-?), XIX гасырда Бәзәкәне үз кубызына биеткән, ләкин 1917 елга фәкыйрьлеккә төшкән нәселнең иң яшь әһеле булган. Ул яшүсмер чагында ук абыйсы Шоңкар Гыйлмебәшаров белән авылдан Ижау шәһәренә күчеп киткән. Шоңкар Иж заводында хәрби хезмәттә булган, ә Зиннур, Ижауда рус-татар башлангыч мәктәбен тәмамлап һәм имтиханнар тапшырып, “татар мәктәбе мөгаллиме” таныклыгын алган. Сәйфуллин Мәхмүт (1898-?), беренче мәхәллә муллалары ахун Хәлим хәзрәтнең оныгы һәм Фәтхетдин хәзрәтнең өлкән улы, Алабугада рус-татар башлангыч мәктәбен тәмамлап һәм имтиханнар тапшырып, шундый ук “татар мәктәбе мөгаллиме” таныклыгын алган. Өченче мөгаллим, чыгышы белән Алабуга өязе Балтач авылыннан булган Балтин Насырттин шулай ук “татар мәктәбе мөгаллиме” таныклыгына ия булган кеше. Менә шушы өч яшь егет Бәзәкәдә агарту эшләрен башлап җибәргән, һәм яңа совет мәктәбе дә алар җитәкчелегендә авылда үзенең беренче адымнарын ясаган.

Димәк, 1917/1918 уку елында ук Бәзәкәдә өч укытучы яңача эшли башлаган. Советларча укыту системасының нигезе итеп, алар 1914 елдан Бәзәкәдә эшләп килгән рус-татар земство мәктәбен алганнар. Һәр укытучының үз төркем укучылары булган. Алар укучыларына уку-язу һәм хисап нигезләрен генә өйрәтеп калмаганнар, үзләре аңлаганча, киләчәк тормышның гаделлек һәм коммунистик нигезләрендә төзеләчәген дә аңлатканнар, халык арасында да аңлату-агарту эшләре алып барганнар. Төрле сәбәпләр аркасында аларның эшләре тотрыклы, даими була алмаган. Ләкин укымышлы яшь укытучыларның революциянең беренче елындагы эшчәнлеге тиз арада иске тормышны үзгәртү теләген күрсәтә торган мисал булып тора. Алар авыл яшьләре өчен төрле түгәрәкләр оештырганнар, иң кечкенә бәзәкәләләр өчен ясли-бакча ачарга омтылганнар һ.б.. Яшь мөгаллимнәргә өяз халык мәгарифе бүлеге һәм мөселман комиссариаты мөмкинлекләре булган кадәр ярдәм күрсәтергә тырышуы хакында архив материаллары сөйли. Менә бер документ:

“Таныклык

Халык мәгарифе бүлегенең мөселман бүлекчәсе Күрәк волосте Бәзәкә авылында яшьләр түгәрәге оештырылуын раслый һәм башкарма комитеттан бу таныклыкны күрсәтүче иптәш Балтинга бу түгәрәк өчен штемпель һәм мөһергә заказга рөхсәт бирүен үтенә.

Халык мәгарифе бүлегенең мөселман бүлекчәсе мөдире Г.Балтанов”.

Өяз халык мәгарифе бүлеге коллегиясе протоколларында Бәзәкә башлангыч мәктәбе шактый еш искә алынган. Мәсәлән, 1919 елның октябрь утырышында Бәзәкә мәктәбе өчен биш унлы лампа (бинаның зурлыгы 45х40х5); мәдәни-агарту түгәрәге өчен бер егермеле лампа кирәклеге

язылган; 1919 елның 2 декабрендә сүз мәктәпнең ике миченә ягулык бирү турында барган һ.б..

Статистик мәгълүматлар да сакланган. 1918-1919 уку елында Бәзәкә мәктәбендә 92 малай һәм 80 кыз бала укуы күрсәтелгән; 1919-1920 уку елында өч укытучы 135 малай һәм 75 кыз баланы укыткан. 1918-1919 уку елындагы 1-баскыч мәктәпләре һәм алардагы укытучылар исемлегендә Бәзәкә мәктәбенең өч комплектында укытучы мөгаллимнәр исеме бирелгән: Шоңкаров Зиннур (бу исем сызылган, чөнки 5 декабрьдан аны өяз шәһәренә мөселман эшләре буенча Алабуга өяз бүлегенең пропаганда һәм агитация бүлекчәсе мөдире итеп күчергәннәр; сызылган исем өстеннән Халитов Сибгатулла язылган), Сәйфуллин Мәхмүт һәм Балтин Насыртин; шулай ук ике класслы земство рус-татар мәктәбен тәмамлаган Сәйфуллина Зөләйханың да укыту хокукы булуы һәм кызларны укытуы күрсәтелгән.

Гражданнар сугышы авырлыкларына карамастан, 1918 елда РСФСРда бердәм хезмәт мәктәбе булдыру хакында Положение кабул ителгән. Шуннан бер өзек. “Барлык мәктәп яшендәге балаларга I һәм II баскыч мәктәпләргә йөрүнең мәҗбүрилеген тормышка ашыру өчен халык мәгарифе бүлекләре кичектермичә мәктәпләр челтәре планын эшләргә, алты яшьтән җиде яшькә кадәр булган барлык балаларны учетка алынырга тиеш; мәктәпләр салу һәм җиһазлау, мәктәп хезмәткәрләрен хезмәт хакы, балаларны ашату һәм аларга уку әсбаблары, аяк һәм өс киеме белән тәэмин итү өчен сметалар хәзерләнергә тиеш”, - дип күрсәтелгән бу документка бирелгән искәрмәдә. Бу күрсәтмә нигезендә Алабуга өязендә дә саналган эшләрне башкара башлаганнар.

Бәзәкә халкының составы хакында 1919 елның 15 февралендә өяз халык мәгарифе бүлегенә авыл советы рәисе Гафаров раслап җибәргән мәгълүмат белән танышыйк: 55 яшьтән узган ирләр – 127 кеше, 50 яшьтән узган хатыннар – 112 кеше, 3 яшькә кадәрге балалар – 104 малай һәм 115 кыз бала, 3 яшьтән 8 яшькә кадәргеләр – 146 малай һәм 163 кыз бала, 8 яшьтән 13 яшькә кадәргеләр 135 малай һәм 137 кыз, 13 яшьтән 18 яшькә кадәргеләр 154 егет һәм 133 кыз булган. Шулардан 25 малай һәм 28 кыз тулы ятим, 15 малай һәм 17 кыз ярым-ятим булуы күрсәтелгән. Авылда барлыгы 1274 ир-ат һәм 1400 хатын-кыз яшәгән. Авыллардан җыелган шундый мәгълүмат нигезендә өяз халык мәгарифе бүлеге мәктәпләр челтәрен төзи башлауга Колчак гаскәренең Алабуганы алуы һәм барлык совет оешмаларының эвакуацияләнүе комачаулаган.

Акларны өяздән куу һәм Совет властен торгызу белән бергә өяз халык мәгарифе бүлеге авылларда совет мәктәпләре оештыру эшен дәвам иткән. Бәзәкәдә яңадан беренче баскыч мәктәбе эшли башлаган. 1919-1920 уку елында балаларга яңача белем бирү эше белән шулай ук 3 укытучы шөгыльләнгән, бу вакытта 92 малай һәм 80 кыз бала укыган. Башка саннар да китерелгән: 1919 елның 1 декабренә 3 мөгаллим һәм 2 мөгаллимә 137 малай һәм 73 кызны укыткан. Күрәк волостендәге авыл советлары вәкилләренең 1920 елның 26 мартында узган җыелыш протоколында китерелгән мәгълүмат: Бәзәкәдә укый-яза белүче һәм белмәүчеләр исемлеген булдырганнар, мәктәп

советын оештырганнар, ләкин дәресләр әле башланмаган. Бәзәкә авыл җәмгыятенең 300 кеше катнашында 6 апрельдә узган гомуми җыелышында төп мәсьәлә булып аклардан соң калган бөлгенлеккә һәм җимереклеккә каршы көрәш торган. Кабул ителгән карарлар арасында авылда наданлыкны бетерү һәм яшьләр союзы оештыру да каралган.

Алабуга өязе халык мәгарифе бүлеге һәм Бәзәкә мәктәбе советы арасында барган хәбәрләшү материаллары да авылда укыту эшләре барышын күзаллау мөмкинлеген бирә. Мәсәлән, 1920 елның 4 октябрендә бәзәкәлеләр 1920-1921 уку елына да Бәзәкә мәктәбе укытучысы итеп билгеләнгән укытучы Балтинның билгесез сәбәп белән эшкә килеп җитмәве, ә мөгаллимә З. Сәйфуллинаның тиф белән чирләве хакында хәбәр иткәннәр. Аларга алмашка укытучылар җибәрүне һәм авылда укучы балалар күп булу сәбәпле тагын бер комплект ачуны сораганнар. Бу хатның бер читенә: “Соңырак җибәрербез”, - дип язып куелган. 24 октябрьдә Бәзәкәдән тагын бер мөгаллимәне алыштыруның кирәклеге турында язганнар: бу юлы Разия Юзикееваның да тиф белән чирли башлавы һәм 8 октябрьдә өенә җибәрелүе хакында хәбәр ителгән. Бу хатка да “Кызганыч, җибәрә алмыйбыз”, - дип язып куелган.

19 октябрьдә җибәрелгән тагын бер мөрәҗәгать: “Бәзәкә мәктәбе советы өяз халык мәгарифе бүлегенә хәбәр итә: Бәзәкә мәктәбендә хәзергә кадәр укытучы Балтин юк, һәм мөгаллимә Сәйфуллина, чирләү аркасында, эшли алмый. Хәзерге вакытта эш урынында Юзикеева һәм яңа билгеләнгән Мәҗитов һәм Плеханова бар, ләкин алар, мәктәп эшләрен элеккеге укытучылардан кабул итеп алмау сәбәпле, өязгә бернинди мәгълүмат та бирә алмыйлар. Мәктәп советы өяз халык мәгарифе бүлегеннән барлык мәктәп кәгазьләрен һәм инвентарьне кабул итеп алу өчен үткән ел укыткан укытучылар Балтин, Шакиров һәм Хамадиновны Бәзәкәгә җибәрүне сорый. Һәм бик кыска вакыт эчендә Балтин белән Сәйфуллинага алмаш җибәрүне дә сорый, чөнки мәктәп тулы көченә эшли алмый.

19 октябрь 1920 ел.

Председатель С.Емангулов

Секретарь урынына Плеханова”.

Мөгаллимәләр, терелгәннән соң, үз эшләрен яңадан башкарырга керешкәннәр, ә Балтин юкка чыккан. Фәйзелхак абый Хөснетдинов: “Ул гражданнар сугышыннан яраланып кайткан коммунист иде, бәлки аны совет властена каршы кешеләр үтергән булгандыр”, - дип сөйләгән иде. Ничек кенә булмасын, 28 октябрьдә Бәзәкәдән Камай авылы гражданины Сәгъдетдин Кәлимуллинны Бәзәкә мәктәбенә укытучы итеп сораган тагын бер хат җибәрелгән. 29 октябрьдә Күрәк волосте мәгариф бүлеге дә бу үтенечне куәтләгән: “Укыту эше аксамасын өчен, бигрәк тә 4000-гә якын халкы булган мондый зур авылда”, - диелгән бу рәсми хатта.

Менә тагын бер хат. “Бәзәкә I баскыч мәктәбе советы өяз халык мәгарифе бүлегеннән безнең балалар бакчасына тәҗрибәле җитәкче җибәрелүен сорый, чөнки безнең балалар бакчасының җитәкче Г. Мәсагутова

балалар белән эшләүне белми һәм, гомумән, мәктәпкәчә тәрбиянең нәрсә икәнен белми. Һәм бакчада балалар саны арттыру хакында кайгыртмый.

Искәрмә: иптәш Мәсагутова балалар бакчасында 10 октябрь тирәсендә генә эшли башлады, көз буена рәтләп эшләмәде. Хәзер дә балаларга бернинди тәрбия бирми.

Бәзәкә балалар бакчасына аның элеккеге җитәкчесен кайтаруны сорыйбыз. Ул хәзер Мордва балалар бакчасында; ул бик тәҗрибәле һәм балаларга бик ягымлы иде.

30 октябрь 1920 ел.

Председатель С.Емангулов.

Секретарь урынына Плеханова.

Авыл советы канәгатьләндерүне сорый.

Председатель Гр.Гыйззәтуллин.

Секретарь Х.Гайнуллин”.

Хат почмагына “Мөхәмәтҗанова билгеләнде. 14 ноябрь” дип язылган. Бу материаллар 1920 елның мартында оештырылган мәктәп советы шактый актив эшли башлавын күрсәтә. Ул укучыларның мәктәпкә йөрүен күзәтеп кенә калмаган, балаларны укыту һәм тәрбиянең сыйфатын да яхшыртырга тырышкан, өяз җитәкчелегеннән мәктәпне һәм балалар бакчасын тәҗрибәле һәм белемле укытучы-тәрбиячеләр белән тәэмин итүләрен таләп иткән. Советлар хакимияте идарәгә килү белән үк Бәзәкәдә татар авылында моңа кадәр күренмәгән генә түгел, хәтта, гомумән, ишетелмәгән нәрсә – балалар бакчасы барлыкка килгән. Аның 1919 елда тулы көчкә эшләгәнлеге соңгы хатның эчтәлегеннән аңлашыла. 1919 елның 15 февраленә 53 ятим һәм 32 ярым-ятим бала булуын исебезгә төшерсәк, мәктәпкә дә, балалар бакчасына да, беренче чиратта, ятимнәрне җыюларын исбат итә алабыз. Бу оешмалар аркылы балаларны киендергәннәр, мәктәп кирәк-яраклары белән тәэмин иткәннәр, һәм, иң мөһиме, ашатканнар да. Ә 1920-1922 елгы ачлык вакытында бу бигрәк тә зарури булган. 1921 елның октябреннән авылда Помгол оештырган ашханә дә эшли башлавын искә төшерик.

Алабуга кантонындагы мәктәпләр хакында 1921 елның 1 гыйнварына тутырылган анкеталар бар. Бәзәкә мәктәбе хакындагы мәгълүмат: беренче баскыч мөселман мәктәбе, малай һәм кыз балалар бергә укый торган катнаш земство мәктәбе буларак, 1914 елда эшли башлаган. Ул арендага алынган дүрт бүлмәле бинада урнашкан (56 кв.аршинлы яки 168 куб.аршинлы ике бүлмә, 42 кв.аршинлы яки 126 куб.аршинлы тагын ике бүлмә). Керосин белән яктыртылган, мич ягып җылытылган. Су кайнату казаннары юк. Бик мохтаж булган балаларга, шулай ук кызылармеец балаларына өске һәм эчке кием, аяк киеме өләшенгән. Укучылар, чирләп 10 дәрес, кием булмау һәм башка сәбәпләр аркасында 180 дәрес калдырганнар.

Таблица № 13

Бәзәкә мәктәбендә 1920/1921 уку елында укучылар саны

Төркем	1920 ел көзенә	Уку елы башына	Ташлаучылар	1.01.1921 елга
1	5	84 м.+65к.= 149	11м.+ 4к.= 15	73м. 61к.=134

2 3 4	52м.+23к.= 75. 41м.+23к.= 74 26м.+10к. 36		4 м. 5 м. 11 м.	48м.+23к.= 71 36м. +33к. =69 15м. +10к. =25
Барлыгы	119м.+58к.= 185	84м. +65к.= 149	31м.+ 4д.= 35	172м.+127к.=299

Укулар 11 октябрьдә башланган, дәресләр 5 сәгать барган. Бу уку елында 5 укытучы эшләгән: 1. Плеханова Александра Семеновна, 20 яшь, рус милләтеннән, Алабуга кызлар гимназиясенең 6 классын тәмамлаган, 1919 елда эшли башлаган, Бәзәкә мәктәбендә – 1920 елдан, рус телен укыта, партиясез, игенчеләрдән; 2. Юзикеева Разия, 18 яшь, башлангыч белемле, 1918 елда эшли башлаган, Бәзәкә мәктәбендә – 1919 елдан, бер төркем алып бара; 3. Сәйфуллина Зөләйха, 22 яшь, ике класслы башлангыч мәктәп тәмамлаган, 1919 елда эшли башлаган, Бәзәкә мәктәбендә –1920 елдан; 4. Кәлимуллин Сәгъди, 30 яшь, 1920 елда Бәзәкә мәктәбендә эшли башлаган, партиясез, бер парлы төркем алып бара; 5. Мәҗитов Нуриәхмәт, 20 яшь, 1918 елда эшли башлаган, Бәзәкә мәктәбендә – с 1920 елдан, партияле, 4 төркем алып бара. 2 укытучы атнага 20 сәгать, өч укытучы –24 сәгать алып барган. Мәктәп советына 2 укытучы, 2 укучы һәм 1 халык вәкиле кергән. Мәҗбүри укыту булмавы бина, укытучылар, дәреслекләр, кием җитмәве белән аңлатылган. Мәктәпнең хуҗалык хезмәткәрләре (каравылчылар) хакында да мәгълүмат бирелгән. Алар - Абзалетдин Хөсәенов, Әхмәтзакир Сиракаев, Госман Шәйхетдинов, Биктимер Садыков булган. Анкетаны Плеханова А.С. тутырган.

Күрүебезчә, Бәзәкә мәктәбендә бу вакытка авылдан чыккан Бәшаров Зиннур да, Сәйфуллин Мәхмүт тә укытмаганнар инде. Бәшаров Зиннур Гыйльмебәшар улы 1918 елда ук Алабугага мөселман бүлекчәсенә эшкә алынган. Алабугага аклар һөҗүме вакытында ул үз теләге белән Кызыл Армиягә киткән. Шуннан соңгы документларда аның хакында башка материал юк. Сәйфуллин Мәхмүт Фәтхетдин улы 1920 елда шулай ук Алабугага эшкә алынган. Аңа ятим балалар өчен Коммуна мәктәбен (Алабуга балалар йортын) оештыру эше тапшырылган. Бу эшне уңышлы гына башкарып, 20 елга якын ул, Бөек Ватан сугышына киткәнче, Алабуга балалар йортының директоры булган.

Икътисади, сәяси проблемаларны исәпкә алмаганда, илдә уку-укыту эшләрен тулы планда җәелдерү өчен, беренче чиратта, укытучы кадрлар җитмәве булган. Без моны Бәзәкә мисалында да ачык күрдек. Совет дәүләте оешкан елларда бу мәсьәләне кыска вакытлы педагогик курслар оештыру юлы белән чишәргә тырышканнар. Мәсәлән 1918 елда Алабугада даими эшли торган беръеллык татар педагогик курслары ачылган. Ләкин, “татар педагогик курслары инде дүрт ел эшләп килсә дә, бер чыгарылыш та булмады, чөнки һәр елны чыгарылыш курслары укучылары, укуларын дәвам итү өчен, тулысынча Казанга җибәрелләләр, - дип ассызыкланылган 1922 елның 8-9 ноябрендә узган Советларның XI Алабуга кантоны съездында. – Ә 1921-1922 уку елында курслар өч ай гына эшләде”. Димәк, бу курслар татар

мәктәпләренә укытучылар түгел, ә югары мәктәпләр өчен хәзерлек курслары ролен үтәгән булып чыга.

Яңа совет мәктәп системасы, һичшиксез, бик авыр шартларда барлыкка килгән. Иске мәктәп җимерелүгә дучар ителгән, ә яңа мәктәпләрне оештыру өчен бик күп нәрсәләрне яңа баштан булдырырга кирәк булган. Уку планнары һәм программалар, яңа дәреслекләр һәм күргәзмә әсбаблар булдыру өчен вакыт һәм, ул чор терминнарын кулланып әйтсәк, “сәяси яктан ышанычлы”, белемле кешеләр таләп ителгән. Мәҗбүри башлангыч белемне һәр авылда оештыру өчен шулай ук яңа ышанычлы кадрлар кирәк булган. Мәҗбүри башлангыч укытуны кертүгә хәзерлек рәвешендә Татарстанда 1927 елның 15 декабренә мәктәпләр санын өлешчә барлау (перепись) билгеләнгән булган. Камай волосте буенча перепись уздырылырга тиешле мәктәпләр исемлегенә Бәзәкә мәктәбе дә кергән. Переписька кадәр уздырылган тикшерү материалларында Бәзәкәдә беренче баскыч мәктәбе булуы күрсәтелгән. Анда өч мәктәп хезмәткәре (укытучылар шулай атала башлаганнар) 124 укучыны укыткан, мәктәпнең аерым бинасы булмаган, һәр комплект (бу сүз “класс-сыйныф” сүзләрен алмаштырган) авыл советы табып биргән бинада эшләгән.

Шулай итеп, тагын бер проблема – мәктәп биналары булмавы ачыкланган. Авылларның бик күбесендә, шул исәптән Бәзәкәдә дә, Совет дәүләтенең беренче ун елы дәверендә балаларны укыту, революциягә кадәрге кебек, аның өчен хәзерләнмәгән гади авыл өйләрендә, һәр мәктәп өчен зарури булган инвентарь һәм җиһазларсыз гына барган. Мәктәп биналарын төзү 1918 елгы РСФСРда бердәм хезмәт мәктәпләре хакындагы Положениедә үк каралган булса да, илдәге сәяси-икътисади проблемалар бу мәсьәләне чишүне чигендерергә мәҗбүр иткән. 20-еллар урталарына, илдәге хәлләр бераз рәтләнгәч, авылларда мәктәп төзелешләре дә җанлана башлаган. Мәсәлән, 1926/1927 уку елында Алабуга кантоны Камай волостенә өч авылда (Бәзәкә, Камай, Тоймада) мәктәп биналары салу өчен 6600 сум акча бүлеп биргән.

Бәзәкәлеләр алдына мәктәп өчен урын табу мәсьәләсе килеп баскан. Авыл эчендә барлык каралты-куралары, спорт мәйданчыгы, зур бакчасы булган яңа мәктәп урнаштырырлык урын табылмаган. Моңа өстәп, “динсезләр мәктәбенә” халыкның мөнәсәбәтен дә исәпкә алырга кирәк. Авыл эчендә “динсез мәктәп” урнаштыруга бәзәкәлеләрнең өлкән буыны, бигрәк тә хакимиятнең дингә карашы үзгәрүгә өметләрен өзмәгән картлар һәм хатын-кызлар каршы чыккан. Авылның активистлары һәм яшь җитәкчеләре, укытучылар мәктәпне авылдан шактый ерак, инешнең сул ягындагы тау башында төзергә булганнар.

Бүгенге күзлектән караганда, бу карар бераз сәеррәк тоела: мәктәп, авылның уртасына туры китереп салынса да, авылдан шактый ерак, шуның өстенә юлны инеш бүлә, укучыларга бер таудан төшәргә, икенчесенә менәргә кирәк (көзге-язгы пычракларда укучыларга да, укытучыларга да юл шактый авыраюын да уйларга кирәк ләбаса). Әлбәттә, ул чорның рухын, идеалларын белгән кеше моны аңлата да аладыр: озакламый бөтен дөньяда революция җиңәчәгенә һәм иң гадел булган строй – социализм төзиячәкләренә чын күңеленнән ышанган (яки ышанырга теләгән) яшьләрнең уй-фикерләре

аларны бик еракка алып киткәндер. Якты киләчәк хакындагы хыялларында алар бу тау башында белем һәм мәгърифәт учагын – барлык мәктәп кирәк-яраклары белән җиһазландырылган иркен кабинетлары, хезмәт тәрбиясе өчен кирәкле инвентарьле мастерскойлары, спортзаллары, укучылар өчен яшәү йортлары (интернат) һәм ашханәләре h.б. булган тулы бер комплекс калкып чыгуы хакында хыялланганнардыр алар. Ягъни, мәктәпнең авылдан ераклыгы да, яз-көз уза алмаслык булган инеш аркылы йөрергә кирәклеге дә, кара йөрәкләрнең көлү-кимсетүләре дә аларны куркытмаган, мәктәпне алар Киләчәк өчен төзи башлаганнар. Бу урында бүлеккә эпиграф итеп бирелгән Хәсән Туфан сүзләре бик туры килә.

Архивта сакланган мәктәп төзү эшен яктырткан документларга таянып, эш барышын күзаллыйк. Эш башында мәктәп җитәкчесе Әгъләмов Солтан һәм авыл советы рәисе Бәшаров Госман булганнар. Төзү материаллары хәзерләү өчен авылга Кама аръягы урманыннан делянка бирелгән. Авыл советы разнарядкасы буенча бәзәкәләләр 1926-1927 ел кышында урман төпләгәннәр, бүрәнә әзерләгәннәр. 1927 елның язгы ташуы вакытында бу бүрәнәләр сал белән Бәзәкә ярына китерелгән (ул чагында Кама елгасы Бәзәкәдән 5-7 км ераклыкта аккан). 1927 елның җәендә башланган төзү эшләре кара көзгә кадәр барган. Мәктәпне җиһазлау өчен 1928 елда Алабуга кантоны халык мәгарифе бүлеге яңа салынган Бәзәкә мәктәбенә 20 ике урынлык парта, егерме 3 урынлык парта, бер начар шкаф, 1 яңа өстәл, 3 яңа урындык, 2 яңа аяклы такта, 1 яңа сәгать, 1 яңа чут (счеты) һәм эчәр су өчен бер яңа савыт бүлеп биргән. Мәктәп Октябрь революциясенең унъеллыгын бәйрәм иткәндә тантаналы рәвештә ачылган. Волостьтан һәм кантоннан килгән хакимият вәкилләре, авыл халкы, балалар катнашында зур җыелыш оештырылган. Яшьләр һәм укытучылар тарафыннан тантаналы бәйрәм концерты куелган. Мәктәп, салыну турында карар кабул ителү елына багышлап, “Октябрьның 9 еллыгы” исемен алган.

Мәктәп, эшен башлап, булган өч комплектны яңа бинага күчерергә өлгермәгән, чөнки беренче көннәрдән үк бинаның ашыгып, чиле-пешле салынганлыгы ачыкланган. Төзелешнең җитешмәгән яклары шул кадәр күп булган ки, яңа салынган мәктәпкә җитди ремонт кирәк булган. Бу хакта архивта бик кызыклы документлар сакланган (Кушымта № 18.1). Аларны, кушымтада биреп, монда эчтәлеген сөйләп китәргә булдым (материаллар рус телендә язылган). Аларның беренчесе - мәктәп мөдире Әгъләмов Солтанның Алабуга кантоны халык мәгарифе бүлегенә 1928 елның 6 мартында җибәргән рәсми хаты. Анда ул яңа бина яшәешенең беренче елында ук ачыкланган бөтен кимчелекләрне санап чыккан. Шуннан берничә өзек. “Төзелеш эшләре кара көздә тәмамлануына бәйле идәнгә чи такталар җәелү сәбәпле, хәзерге вакытта алар барысы да кибеп, йөргән вакытта клавишалар кебек сикерә, баздан җил өрә, ә түшәмнән җир коела”. Шуңа күрә җәй көне сайгакларны яңабаштан җәю һәм кыш көне, түшәмнән барлык җылы чыгып бетмәсен өчен, түшәмне ныгыту кирәклеген язган мәктәп мөдире. Халык мәгарифе кантон бүлегенең идәнне һәм тәрәзәләрне буяу өчен акча бирәчәген искә төшереп, ул барлык тузанлы эшләрне аңа кадәр бетерү тиешлеген кисәткән.

“Мичләр шулай ук салкын вакытта салындылар: һәр салынган кирпеч шунда ук катып барды, шуңа күрә барлык мичләр һәм аларның чормадагы морҗалары яргаланып бетте. Шуңа күрә голланка мичләреннән бөтен төтен бүлмәгә чыга; бер яктан, янгын чыгу ихтималы булса, икенчедән, бина бозыла һәм көне буе бүлмәләрдә сөрем һәм төтен исе аңкып тора”.

Бу хатка кадәр Әгъләмов бинадагы бәдрәф өчен бүленгән бүлмәне класс бүлмәсе итеп үзгәртеп төзү кирәклеген аңлатып, халык мәгарифе кантон бүлегенә тагын бер язма юллаган булуын һәм, бүлекнең ризалыгын алуы турында әйтеп, уку елы беткәч, шул эшкә тотыначагын, димәк, укучы һәм укытучылар өчен бәдрәфне тышта ясарга һәм моңа да күпмедер акча кирәк булачагын язган. Халык мәгарифе кантон бүлеге җибәрәчәк акча бөтен чыгымнарны капламаячагын, бу эшләрнең ремонт буларак, мәктәпнең хуҗалык эшләренә билгеләнгән волость бюджетына керәчәген, бу суммадан шактый күп акча калуын һәм, җәй көннәрендә каравылчы хезмәтен кулланмыйча, экономия ясарга уйлауларын да күрсәткән. Рәсми хатка булачак эшләрнең сметасы да бирелгән. Сметаны да тулысынча кушымтага куеп, монда ремонтның 208,68 сумга (шул исәптән, күчмә бәдрәф - “ватер-клозет” ясау өчен 27,88 сум) төшәчәген күрсәтергә булдым (Кушымта № 18.2).

Шулай итеп, 1927/1928 уку елында, дөресрәге, 1928 елның җәендә узган ремонттан соң, Бәзәкәдә ул чор ихтияҗларына җавап бирә торган яңа бина барлыкка килгән. Ләкин мәктәп эшләп киткән беренче елларда ук бинаның кечкенә булуы да ачыкланган: беренчедән, уку яшендәге балалар саны арткан (алда сөйләнгән бәдрәф урынына класс бүлмәсе ясау яңа комплект - төркем ачылуга бәйле икәнлеген күрсәтү дә җитә); икенчедән, бина башлангыч мәктәп өчен генә салынган булган. Ә барлык мәктәп яшендәге балалар өчен мәҗбүри башлангыч белем кертү, аның җидееллык мәктәп һәм, соңрак, урта мәктәп булып китүе исәпкә алынмаган дип әйтеп була.

20-еллар азагы – илдә халык хуҗалыгын үзгәртеп кору һәм индустриализацияләү еллары. Аның юнәлешләре арасында үз эченә дәүләт мәгариф системасын булдыруны алган мәдәни революция дә булган. Илдә халык хуҗалыгы үсешенең беренче бишьеллык планында бу юнәлештә бик күп бурычлар куелган була. Мәсәлән, Татарстанның беренче бишьеллык планында республикада барлык балаларга мәҗбүри башлангыч белем бирү (всеобуч), 40 яшькә кадәр булган барлык олыларның наданлыгын бетерү, мәктәп һәм мәдәни учаклар (уку йортлары, китапханәләр, клублар h.б. оешмалар) челтәрен киңәйтү каралган булган. 1928 елның 25 июнендә Камай волосте башкарма комитетына җибәргән рәсми хатында Алабуга кантоны башкарма комитеты всеобуч планы буенча 6 ел эчендә халык мәгарифе кантон бүлеге волость кысаларындагы берничә авылда яңа мәктәпләр ачу һәм эшләп килүче мәктәпләрдә комплектлар санын киңәйтүне билгеләгәнен хәбәр иткән. Шул исәптән, Бәзәкәдә булачак үзгәрешләр дә күрсәтелгән. 1926 елда халык санын алганда Бәзәкәдә 2374 кеше яшәве ачыкланган. Бу кадәр халыкка эшләп килгән 3 комплект урынына 5 комплект тиеш икән. Димәк,

1928/1929 уку елында Бәзәкә мәктәбен бер комплектка һәм аннан соңгы елга тагын бер комплектка киңәйтү каралган булган.

1930 елның августында Татарстанда гомуми мәҗбүри уку турында закон кабул ителгән. Законда всеобучны этаплап оештыру бурычы куелган – беренче баскыч мәктәпләре күләмендә 8-10 яшьлек балаларга белем бирү һәм бу баскычны үтмәгән 11-15 яшьлек үсмерләрне мәҗбүри укыту каралган булган. Ләкин татар телен латин алфавиты нигезендә эшләнгән яңа алфавитка – “яңалиф”кә күчерү татар халкы өчен бу мәсьәләне чишүне катлауландырган. “Яңалиф”кә күчү хакындагы карар 1927 елда кабул ителгән. Аны тормышка ашыруны гамәлдә бөтен татар халкын наданлыкка төшерү, аны мең еллык мәдәниятеннән аеру дип атарга мөмкин. Алфавит алмашыну аркасында гарәп шрифтында басылган күпме китап һәм дәреслекләр башта кирәкмәскә әйләнгән, ә берничә дистә ел үткәннән соң, китапханәләрдә сакланып килгән бу хәзинәне укый алырлык кешеләр саны да азайганнан-азая барган. Мең еллык хәзинәне “яңалиф”кә күчерү, барлык мәгариф оешмаларына җитәрлек яңа дәреслекләр һәм әдәбиятны бастыру зур чыгымнар һәм вакыт таләп итүен дә ассызыклыйк.

Безнең әниебез, Вәлиәхмәтова Рөкыя Әхмәт кызы (1912-1982), нәкъ шул чорда, 1931 елның 15 августында, Бәзәкәгә укытучы булып килгән. Истәлекләрендә ул үзенең беренче адымнарын да, Бәзәкәне дә тасвирлаган. “Мин, Вәлиәхмәт кызы Рөкыя, Алабуга педтехникумы каршындагы бер еллык татар укытучылары курсларын тәмамлап, 1931 елны Бәзәкә мәктәбенә укытучы итеп җибәрелдем. Мәхмүт абыйлар (әнинең абыйсы – А.М.) Бондюг Когизында (китап сату системасы – А.М.) эшлиләр иде. Мин берничә көн аларда булдым. Аннан якын бит, 15 августта сәгать өчтә барып җиттем. Мәктәпне эзләп таптым һәм шул көнне, 1-класска билгеләнеп, эшли башладым. Август урталары булса да, эш башланган иде. Өч беренче класс булып, балаларны үзебез җыярга тиеш идек. Балалар һәм аларның әти-әниләре белән таныша башладым. Яхшы ук кына аңлы балалар бар. 47 укучы була”,- дип язган ул.

Димәк, әни килгәндә, Бәзәкәдә башлангыч мәктәп кенә булган. Ул гына да түгел, 1931/1932 уку елында өч беренче класс кына җыелган булып чыга. Бәзәкә мәктәбендә бу елларда тотрыклылык булмаган – бәзәкәлеләрнең “динсез” мәктәпкә мөнәсәбәтләре тискәре булу аркасында укытучылар һәм мөдирләр еш алмашынып торган. Шуңа күрә яңа килгән укытучыларга үз классларына үзләре балаларны җыярга, аларның ата-аналары күңеленә ничектер юллар табарга кирәк булган. 30 еллар уртасына һәр җирдә, шул исәптән Бәзәкәдә дә, балаларга һәм үсмерләргә башлангыч дүрт еллык мәҗбүри укыту кертелгән. Параллель рәвештә зурларны уку-язуга өйрәтү дә киң колач җәйгән. Бу эш белән дә, мәктәп эшләреннән бушагач, укытучылар шөгыльләнгән, аларга ярдәмгә яшь авыл активистлары килгән.

Сугышка кадәр мәктәптә читтән килгән укытучылар гына эшләгән. Гомумән алганда, хакимият укытучыларны авылларда еш алмаштырып тору сәясәтен алып барган. Моның сәбәбен, беренче чиратта, хакимиятнең татар зыялыларына ышанычы булмавы белән аңлатып буладыр (20-30 елларда

татар зыялыларына карата бертуктаусыз яла ягуларны, милләтчелектә гаепләп, җәзага тартуларны әйтү дә җитәдер). Шуңа күрә, ел саен аларны урыннан урынга күчерүләрнең гадәти хәлгә әйләнүен әйтеп була. Бу сәясәт бигрәк тә ирләргә кагылган. Хатын-кызларның да авыл кешесенә тормышка чыкканнары гына (безнең әни, Гөлсем апа Гайнуллина) мәктәптә калганнар.

Әлбәттә, элеккеге тормышны саклап калырга тырышучы бәзәкәлеләр яңа тормыш алып килүче укытучыларны дошман күргәннәр. Әни истәлекләреннән: “Бәзәкәдә колхоз 1931 елның башында ук оештырылган булып саналса да, гамәлдә ул кәгазьдә генә иде. Безгә, Бәзәкәгә яңа гына килгән яшь укытучыларга, бәзәкәлеләрне колхозга җәлеп итү эшен дә йөкләделәр. Кая ул! Бәзәкә бик артта калган авыл, колхоз төзүгә каршылар. Җыелышка килмиләр, безгә караш бөтенләй чит, актив юк диярлек дәрәҗәдә... Алабуга – район үзәгеннән - бик читтә яшибез. Мәктәптә кәгазь, кара, китап юк. Балалар көн саен арта. Эшләве бик читен, тәртип юк. Ярый әле район булыша”.

Тагын кабатлыйм: Бәзәкәгә килгән укытучылар бик яшь, тәҗрибәсез булганнар (мәсәлән, укытучылык эшен башлап кына җибәргән безнең әнигә бары 19 яшь булган). Яшь укытучылар Бәзәкәгә читтән килгәнгә генә түгел, ят мохит, башка дөньядан килүләре белән дә авыл халкына чит-ят булганнар. Алар белән бергә авылга чит гореф-гадәтләр, ят кием-салым, башка культура да килгән. Бәзәкәлеләрдән алар үзләренең “шәһәрчә” киенүләре, укытучы кызлар заман таләбе буенча модалы итеп киселгән чәчләре, яланбаш яки авылда гомергә күрелмәгән эшләпә-башлыклары белән аерылып торганнар. Аларның сөйләм телләре дә Бәзәкә сөйләменә бер дә охшамаган булган. Барлык бу яңалыклар гадәти тормышлары җимерелә баруын борчылып кичерүче бәзәкәлеләрдә килмешәкләргә каршы хисләрне көчәйткән, алар карашынча, бөтен бу бәхетсезлекләрдә нәкъ менә яңа тормыш вәкилләре – укытучылар гаепле булган. Укытучыларның, бәзәкәлеләрдә үзләренә таныч, фикердәш таба алмыйча, авылдан тиз арада китеп бару сәбәпләре арасында бу фактор да булган.

Авылда балаларны тәрбияләү генә түгел, өлкәннәр белән дә бик зур аңлату эшләре алып бару кирәк булган. Әни сөйләгәннәрдән: революциядән соң илдә урнашкан яңа тәртипләрнең Бәзәкәгә дә килеп җитүен, дин гыйлемен укытмаган, ләкин грамотага һәм хезмәткә өйрәткән, гореф-гадәтләрне саклауның мөһимлеген аңлаткан мәктәпкә балаларны бирүнең зарурилыгын, колхозга керүнең мөһимлеген, аның дәүләт таләбе булуын һәм дәүләт ярдәменнән башка кытлык һәм ачлык кебек авылны бимазалый торган афәтләрне җиңеп булмавын аңлаткан укытучылар. Мондый аңлату эшләрен укытучылар, һәр очрактан файдаланып, даими алып барганнар: бәзәкәлеләрнең өйләрендә дә (алар җыелышка килми икән, димәк, укытучылар үзләре аларның өйләренә барган), мәктәп һәм ликбез дәресләрендә дә, аерым очрашулар вакытында да. Авылда наданлыкны бетерү эшләрен алып баруны да яшь укытучыларга йөкләгәннәр (әнинең Бәзәкәгә килүе “яңалиф”кә күчүнең башланган чорына туры килүен дә искә төшерик; димәк, гарәпчә яхшы укый-яза белүчеләрне дә яңача укырга

өйрәтергә кирәк – эш җитәрлек булган). Әни сөйләвенчә, ликбез төркемнәрендә җиде яшьтән алып җитмеш яшькә кадәр булган укырга-язарга өйрәнүчеләр бергә җыела торган булганнар.

Яхшы мәктәп булу өчен бина салу ул әле беренче адым гына, анда барлык көчен балаларны укыту-тәрбиягә багышлаган укытучылар коллективы булуы да зарури. Ә инде укуга, белемгә омтылучы балалар коллективын оештыру – укытучыларның төп максаты. Яшь укытучылар, җиң сызганып, яңа совет мәктәбен аякка бастыру эшенә керешкәннәр. Әниебез, башка укытучылар белән бергә, пионер оешмасын торгызуга, соңрак, өлкән класслар барлыкка килгәч, комсомол оешмасын булдыруга да күп көч салган. Бәзәкәдә беренче пионер төркеме 1927 елның җәендә үк барлыкка килсә дә, ул вакытта пионер хәрәкәте үсеп китә алмаган (пионерлар төркемен җәй көне ялга кайткан Казан дәүләт пединституты студенты Зиннур Гыймранов оештырган була; ул киткәч, төркем таралган). Укучылар белән тәрбия чараларын уздыруда пионер оешмасына зур әһәмият биргән яшь укытучылар аңлату эшләреннән башлаган. “Гомумән, беренче елымны эшләгәндә, мин бик мөһим нәтиҗәгә килдем, - дип сөйли иде әни. – Эшкә керешүне балаларга да һәм аларның әти-әниләренә дә эшнең эчтәлеген һәм максатын аңлатудан башларга кирәк. Шунсыз уңышка ирешеп булмый”. Пионер оешмасын булдыруның максатларын һәм бурычларын да ул башта үз классының иң актив укучыларына һәм аларның ата-аналарына аңлаткан.

Үз классының 10-15 укучысы белән бу эшне башлап җибәргән әни һәм мәктәп мөдире үзләре алдына пионер оешмасына барлык яхшы укучыларны җыю максатын куйганнар һәм акрынлап максатларына ирешкәннәр дә. Балаларны алар өчен яңа булган эшкә тарту авыр булмаган, ә менә өлкәннәрне күндерү – бу эш шактый авыр бирелгән. Барлык укытучылар бергә ата-аналар белән даими аңлату эшләре алып барып һәм, иң мөһиме, аларга пионер оешмасындагы балаларның җаваплылыгы артуын, тәртибе яхшы якка үзгәрүен күрсәтеп, мәктәптә һәм авылда пионер оешмасының тулы көчкә эшләп китүенә ирешкәннәр. Бу эшкә, әлбәттә, берничә ел вакыт кирәк булган. Мәктәптә һәм ликбезда укыту, балалар һәм ата-аналар белән даими алып барылган мәктәптән соңгы эшләр укытучылардан бик күп вакыт таләп иткән. Гамәлдә, укытучылар иртәдән кичкә кадәр эштә булганнар. Шулай булса да, алар үзлегеннән белем алырга да, читтән торып укырга да вакыт тапканнар. Мәсәлән, безнең әни 1931-1934 елларда Алабуга педтехникумында читтән торып укыган һәм башлангыч класс укытучысы дипломын алган.

1931 елда беренче класста укый башлаган балалар, 1934/1935 уку елында дүрт еллык тулы башлангыч белем алып, башлангыч мәктәпне тәмамлаганнар. 1935/1936 уку елында Бәзәкәдә бишенче класс эшли башлаган. Шулай Бәзәкә мәктәбе гомуми җиде еллык укытуга күчкән. Бу вакытка мәктәптә инде дистәгә якын укытучы эшли торган булган. Берничә укытучы, бишенче класс ачылыр алдыннан, аерым фәннәрдән Алабугада кыска вакытлы (бер елга кадәр) хәзерлек курсларында укыган. Мәсәлән, әниебез 5-7 классларда татар теле һәм әдәбиятын укыту өчен хәзерләнгән.

1934/1935 уку елында ул Алабуга педтехникумы каршындагы тугыз айлык курсларның тел һәм әдәбият бүлегендә белем алган. 1935 елның 26 июлендә аның исеменә бирелгән таныклыкта түбәндәге белешмә язылган: “Гр. Р. Вәлиәхмәтовага татар теле һәм әдәбияты фәннәрен тулы булмаган урта мәктәптә укытырга рөхсәт ителә. Урта мәктәптә укытыр өчен ул пединститутның тиешле бүлегенең читтән торып уку яисә кичке бүлекчәсе курсы өчен имтихан тапшырырга тиеш”. 1935 елның 25 сентябрендә әни Казан дәүләт педагогия институты татар әдәбияты һәм лингвистикасы факультетының читтән торып уку бүлегенә кабул ителгән.

Бу ике дата арасында безнең әти-әниләребез тормышында тагын бер мөһим вакыйга булып алган: 1935 елның 4 августында Бәзәкә авыл советында аның секретаре Мәхмүтов Хаҗиәхмәт Мәхмүт улы һәм укытучы Вәлиәхмәтова Рөкыя Әхмәт кызы өйләнешүләре хакында рәсми кәгазь – таныклык алганнар. Бу мулла укый торган никахны алмаштырган яңа йола булган. Туй да – “Кызыл туй” – бик тыйнак, ләкин шул ук вакытта бик тантаналы рәвештә, авыл туйларыннан аермалы итеп оештырылган. Гомумән алганда, нәкъ менә авыл зыялылары һәм активистлары яңа совет тәртип-йолаларын авыл яшәешендә тормышка ашырган - “Кызыл туй”, балага исем кушу - “Кызыл бәби туе”, хәтта яңача соңгы юлга озату - күмү дә. Яңа туган балаларга исемнәрне дә читтән алып, ят исемнәр кушканнар – Альта, Римма, Марсель, Клара h.б. яңа исемнәр нәкъ бу елларда гадәти булган татар-мөселман исемнәренә алмашка килгән. Укытучы балаларына гадәти исем кушу – дини йолаларны саклауга тиң булуын да әйтергә кирәк. Бу хәлләрнең 1935-1937 елларга туры килүен дә искә төшерик. Әни сөйләвенчә, ул елларны һәр укытучы кулга алыну мөмкинлеген тоеп яшәгән.

Революциягә кадәр муллалар башкарган күп кенә йолалар 20 – елларда авыл советы карамагына алынган булсалар да, яңа совет йолалары авылда 30-елларда гына урнаша башлаган. Авылда яңа мөнәсәбәтләр, яңа совет йолалары урнаштыру шулай ук укытучылар һәм авыл активистлары өлешенә тигән; нәкъ менә алар тормыш үрнәге булганнар. Авылдашлар сөйләвенчә, һәм, соңрак, үземнең күзәтүләрем буенча да, авыл интеллигенциясе илдә урнашкан яңа тәртипләрнең илчесе, вәкиле булган, шуңа күрә алар халыкның даими игътибарында булганнар, аларга ялгыш адым ясарга ярамаган. Авылның бөтен иҗтимагый тормышы авыл советы тирәсендә кайнаган (мәктәп ерак, тау башында), анда зыялылар һәм авыл яшьләре көндәлек эшләр белән шөгыльләнгәннәр: сугышчан листоклар, газетлар чыгарганнар, чираттагы эшләрне бүлешкәннәр, төрле чараларны хәзерләгәннәр.

Безнең әти-әниебез дә бу эшләрнең уртасында бөтерелгән. Алар авылның абруйлы һәм хөрмәтле кешеләре булган, чөнки, яңа тормыш төзү тарафдарлары булсалар да, күпләр кебек, иске тормышны, чәлпәрәмә китереп, җимерү хисабына түгел, ә яңалыкларны акрынлап, ипләп кертү яклы булганнар. Гомумән алганда, алар бар нәрсәдә дә үзләре үрнәк булырга тырышканнар: беренчеләрдән булып, патефон, велосипед, радиоприемник кебек авыл өчен чит булган тормыш-көнкүреш әйберләрен өйләрендә булдырганнар. Әнинең, ул тугач та, 1912 елда әтисе Субаев Вәлиәхмәт

Сәгъдетдин улы Сембер ярминкәсендә алган атаклы “Зингер” фирмасының аяклы тегү машинасы булган (ул машинаны әбиебез Сара Гыйззәтулла кызы конфискация вакытында саклап кала алган һәм, әни Бәзәкәдә төпләнгәч, аңа үзе китереп тапшырган).

Иҗтимагый тормышның икенче үзәге мәктәп булган. Әлбәттә, мәктәп бинасының авылдан читтә урнашкан булуы сәбәпле, анда тормыш күбрәк көн яктысында кайнаган, ә кичләрен укытучылар һәм укучылар үз чараларын уздыру өчен ешрак авыл советы, китапханә, клуб, уку йортында (әле минем балачакта да ул “изба-читальня” атамасының кыскартылган варианты – “избач” сүзе белән атала иде) җыелганнар. 1937/1938 уку елында Бәзәкә мәктәбендә 8-класс ачылган, ул урта мәктәп статусын алган һәм исеме дә алмашынган. “Октябрьнең 9 еллыгы” исеме урынына ул Киров исемендәге урта мәктәп дип йөртелә башлаган.

1937/1938 уку елында Бәзәкә мәктәбендә өч беренче һәм икешәр икенче-дүртенче класслар булган; 9 башлангыч сыйныфта барлыгы 297 укучы (аларның 155 кыз бала) белем алган: 1-класста – 105 (51 кыз), 2-класста – 74 (42 кыз), 3-класста – 59 (27 кыз) һәм 4-класста – 59 (35 кыз). 5-7 сыйныфларда шулай ук икешәр төркем булган: алты төркемдә барлыгы 178 укучы (аларның 72 кыз) укыган: 5-класста – 65 (23 кыз), 6-класста – 57 (28 кыз), 7-класста – 56 (22 кыз). Яңа ачылган сигезенче класска 22 егет һәм 8 кыз кабул ителгән. Шулай итеп, мәктәптә бу елны 16 төркемдә 505 укучы булган. Барлык 16 төркем буенча 39 бала, имтиханнарын тапшыра алмыйча, икенче елга калдырылган. Игътибар итик – башлангыч классларда кызлар һәм малайлар саны бер-берсеннән артык аерылмаса, урта классларда кызлар саны кими барган. Димәк, бәзәкәлеләр кызларына укый-яза белү бик җиткән дип уйлаган булып чыга. Бәзәкәдә вакытында башлангыч белем ала алмый калган үсмерләр өчен өч еллык аерым мәктәп тә булган (аның 1-2-классларында унар үсмер, 3-нчесендә 12 үсмер, барлыгы 32 кеше белем алган, аларның 17-се кызлар булган).

1937 ел өчен балалар бакчасының да еллык отчеты сакланган. Бакчага барлыгы 30 бала йөргән, 4 тәрбияче (берсе мөдир вазыйфасын да үтәгән) һәм ике хуҗалык эшләрен башкаручы булган. Бакчаның бюджетына колхоз 3025,62 сум, промстрахкасса 8899,91 сум биргән, ягъни елына 11925,53 сум чыгым булган. Бакчаның бинасы 288 кв.метрлы дүрт бүлмәдән гыйбарәт булган. Мөдире Хәбриева дип күрсәтелгән.

Киров исемендәге Бәзәкә урта мәктәбендә беренче чыгарылыш 1940 елда булган. Бу чыгарылыш чарасыннан фоторәсем сакланган – анда чыгарылыш сыйныф укучылары – үз авылларында тулы урта белем алган беренче бәзәкәлеләр, укытучылар һәм авыл активы сурәтләнгән. 1940 ел татар халкы өчен тагын сынау елы булуын да искә алыйк: тагын бер тапкыр әлифба алмашынган – бу юлы “яңалиф”тән рус алфавиты “кириллица”га нигезләнгән әлифбага күчеш булган. Дөрес, бу юлы күчеш җиңелерәк бирелгәндер дип фаразларга була: халыкның күбесе инде мәктәптә белем алган, рус алфавиты белән рус теле дәресләрендә танышкан булган; шуңа күрә яңа татар әлифбасына күчкәндә, аларга татар кириллицасының алты-

җиде яңа хәрефен генә истә калдырырга кирәк булган. Ә менә өлкәннәрнең күп өлеше тагын “надан”га әйләнгән. Димәк, укытучыларны тагын “ликбез” көткән.

1940 елда бөтен Бондюг районында барлыгы биш урта мәктәп булган: Бондюга эшчеләр поселогында ике мәктәп (берсе рус, икенчесе татар), Бәзәкә һәм Камай авылларында берәр татар мәктәбе һәм Илнәттә мари мәктәбе булган. 1940/1941 уку елында Ык Тамагында тагын бер рус урта мәктәбе ачылган.

1940/1941 уку елында Бәзәкә урта мәктәбендә 19 төркемдә 540 укучы белем алган. Алар гомуми күләме 646 кв.м булган биш бинада укыганнар. Барлыгы 12 класс бүлмәсе (543 кв.м) булган. Җиде төркем икенче сменада укыган. Бу уку елында туган авылы мәктәбендә физика һәм математика фәннәрен Габделхәй Гыйлфан улы Гыйлфанов (1921-2015) укыта башлаган. 1939 елда Алабуга педтехникумын тәмамлаганнан соң ул Казан университетына юллама алган, ләкин анда аңа укырга туры килмәгән. Аны хәрби училищега җибәргәннәр, ләкин аның сәламәтлеге (минем фикеремчә, репрессиягә эләккән мулла малае булуы) аркасында аны кабул итмәгәннәр. Туган ягына әйләнеп кайткач, 1939/1940 уку елын ул Бондюг татар урта мәктәбендә физика-математика укытучысы булып эшләгән һәм 1940/1941 уку елында Бәзәкә урта мәктәбенә күчерелгән. Ләкин ул уку елын тәмамлый алмаган – 1941 елның маенда Кызыр Армиягә хәрби хезмәткә чакырылган.

Хәй абый (аның барлык укучылары, шул исәптән мин дә, аңа нәкъ шулай эндәшә идек; мулла кушкан мөселман исемнәренең кыскартылган варианты совет чорында бик киң кулланылган; хәер, революциягә кадәр дә көнкүрештә озын исемнәрнең бер өлешеннән генә киң файдалана торган булганнар), сугышның беренче айларында ук пленга эләгеп, пленның һәм сугыштан соңгы тикшерүләрнең газапларын узып, 1946 елны авылга кайтты һәм үзенең яраткан эшен дәвам итте. Ул 1946-1982 елларда, пенсиягә чыккан чы, Бәзәкә мәктәбендә математика дәресләрен алып барды. Шушы вакыт аралыгында Хәй абый, читтән торып, 1949 елда Алабуга укытучылар институтының, 1956 елда Казан педагогия институтының физика-математика факультетларын тәмамлады, 1961 елдан завуч, 1965-1970 елларда мәктәп директоры булды. 1963 елда аңа Татарстанның атказанган укытучысы исеме бирелде.

Бу урында әле искә алынмаган сугышка кадәр Бәзәкә мәктәбендә эшләгән укытучыларның исемнәрен әйтеп китү дөрес булыр. Алар барысы да читтән килгән кешеләр булып, күбесе, кагыйдә буларак, бер-ике ел Бәзәкәдә укытканнан соң, башка мәктәпләргә күчерелгән укытучылар булган (бу чорга хас күренеш). Шулай итеп, 1930-елларда Бәзәкәдә эшләгән кешеләрнең исемлеге: Ачаев Иван, Әхмәтвәлиева Мәгъфия, Белов Сергей, Гәрәева Хәлимә, Газизов Латыйф, Графетдинов Гыймаз, Бәдри һәм Гөлсем Гарифҗановлар, Даутова Сәкинә, Димитриев Николай, Егоров Александр, Җәмалеттинова Фәйрузә, Исхаков Фәссах, Комаров Иван, Кошкина Гайшә, Марыскин Закир, Моисеев Иван, Моркин Иван, Мөхәмәттинов Шәех,

Садыйков Гата, Талипова Тайфә, Тулбаев Мәхмут, Феклин Христофор, Федорова Дарья, Хуҗин Гыйлметтин.

Мәрданов Минрахман һәм аның хатыны Вәлидова Тәскирә Бәзәкә мәктәбендә 1936/1937 уку елыннан эшли башлаганнар. 1938 – 1941 елларда М.Мәрданов мәктәп директоры булып эшләгән. Аның хатыны, минем әнинең якын дусты Тәскирә апа, 1940 елны вафат булган һәм Бәзәкә зиратында җирләнгән (аны соңгы юлга озатканда төшерелгән фоторәсем сакланган). 1938 елдан Бәзәкә мәктәбендә Комаров Мирон (1913 елгы), Үтәгән авылыннан Смирнов Иван (1913), Турайдан Ситтиков Мөхәмәтҗан (1913), Псәйдән Шәрәфиев Мирсәет (1908) эшләгәннәр (бу исемнәрне мин хуҗалык кенәгәләреннән алдым).

1940/1941 уку елында Бәзәкә мәктәбендә икенче чыгарылыш булган. Туган авылларында тулы урта белем алган егетләр һәм кызлар үзләренең киләчәк тормышлары хакында планнар корган, югары мәктәпләргә керү хакында хыялланган, яңа тормышка аяк басырга җыенган көннәр... Ләкин барлык бу план-хыялларны 22 июньдә башлаган сугыш чәлпәрәмә китергән...

Сугыш елларында

Уйланыйк үткәннәр хакында:
Кемнәр без,
кемнәр сез
Аяз күк астында?
Тын калыйк һәйкәлләр каршында.
Сиңа да,
миңа да
Тарихны калкыту
Хәтерне барлаудан башлана.

Марсель Галиев

Ике тарихи көн – 1941 елның 22 июне һәм 1945 елның 9 мае. Бу ике дата арасында – буыннар хәтеренә мәңгегә уелып кергән 1418 көн... Ул көннәрне кичергән буыннарның гына түгел, аларның дәвамчылары хәтерендә дә саклана бу көннәр. Югыйсә, “Сугыш эзләре буйлап”, “Георгий тасмасы”, “Үлемсез полк” кебек хәрәкәтләр тумас та иде...

Сугыш... Бөек Ватан сугышы... Һәркем үз тормышын үзе яшәгән кебек, сугышны да ул үзенчә хәтерли һәм үзенчә тасвирлый. Кешеләрнең – ул кырыс елларны кичергәннәрнең дә, сугыштан соң күп еллар узгач туганнарның да – бу сугышка булган мөнәсәбәте дә, мөгаен, үзләренчәдер. Ләкин үз тормышларын кызганмыйча, фронтта да, тылда да үзләрен аямыйча хезмәт күрсәтеп, җиңү көннәрен якынайткан миллионнар хакындагы изге хәтер мәңгегә сакланыр дип ышанасы килә...

Минем дә сугыш һәм аның башлануы хакында үз хәтерем бар. Тормышны кинәт кенә үзгәрткән 22 июнь көне... Миңа әле яңа гына дүрт яшь тулса да, мин бу көнне барлык детальләре белән хәтерлим кебек. Якшәмбе көн. Без өйдә. Әни безнең белән – мин һәм әле яңа гына бер яше тулган

сеңлем Алиса белән маташа. Радиодан акрын гына ниндидер көй агыла. Кинәт кенә музыка өзелә, куркыныч калын ир-ат тавышы ишетелә. Әниебез агара, иреннәре тавышсыз гына “Сугыш” ди, безне икебезне берьюлы кочагына ала. Ә без шунда ук кычкырып елый башлыйбыз. Күрәсең, безне радиодан килгән таныш булмаган тавыш, әнинең төсе үзгәрүе куркыткан, шомга салгандыр. Һәм без, бер нәрсә дә аңламасак та, дәррәү елый башлаганбыздыр. Бу минем беренче хатирәм.

Сугыш башланган көннәр минем истә болай калган: урамда кеше бик күп, “зур абыйлар”, берничә җирдә җыелып, кызу-кызу сөйләшәләр. Егетләр, төркем-төркем тарантас һәм арбаларга утырып, гармуннарда уйнап һәм кычкырып җырлап, урамның очыннан-очына узалар. Миңа бу бәйрәм кебек тоела. Бәйрәмнәрдә генә кешеләр җыела, гармунда уйный, җырлыйлар ич. Бар кешегә дә бик күңелле булырга тиеш, ләкин апа-әбиләр көлешми дә, сөенми дә, киресенчә, бик күбесе елый, күзләрендә яшь. Мин моны аңлый алмыйм, әнидән сорыйм. Әнием миңа аңлата – безнең авылдан бик ераста сугыш башланган икән, урам буйлап җырлап йөрүче егетләр бәйрәм итмиләр, безне дошманнардан саклар өчен фронтка китәр алдыннан, шулай авыл белән саубуллашалар икән. Шул вакытта мин яңа куркыныч сүзләр белән таныша башладым – сугыш, дошман, фронт h.б.

Әнием истәлекләреннән: “Без Гитлер Германиясе белән сугыш, hичшиксез, булачагын белә идек тә кебек, ләкин хөкүмәтебез, ничек булса да, илебезне сугыштан саклап калыр дип өметләнә идек. 1941 елның 14 июнендә “тиздән сугыш башланачак” кебек имеш-мимешләрне кире каккан ТАСС Белдерүе барлык гәзитләрдә басылып чыккач, өметләребез ныгый башлады. Бу белдерүдә Германия һәм Советлар Союзы үзара сугыш башламау хакында 1939 елда төзегән Договорның какшамас булуы, Германия илебезгә каршы сугыш башларга җыена дигән сүзләрнең нигезсез булуы турында язылган иде. Мин бу Белдерүне хәзер дә бик яхшы хәтерлим, чөнки миңа аны атна буена укытучыларга, авыл активына, колхозчыларга аңлатырга туры килде. Һәм нәкъ бер атнадан соң сугыш башланды...”.

Сугыш башлануы турындагы тагын бер хатирәм әтине һәм Шәриф абыйны фронтка озату белән бәйле. Башта Шәриф абыйны озаттык. Әтинең бердәнбер улы Шәриф абый (1923-2001) 1941 елның җәендә, нәкъ сугыш алдыннан, Алабуга педтехникумын тәмамлаган. Алабуга военкоматына теркәлгән абый сугышка да Алабугадан китте. Аны озатуны мин яхшы хәтерлим. Аны һәм дусларын әти Алабугага кадәр озата барды. Үзе белән ул мине дә алды (әнинең әти-әнисе Алабугада яшиләр иде, күрәсең, ул мине аларга кунак итеп алып баргандыр). Без ике тарантаста әрәмә аркылы бик озак бардык. Төн җитте, күктә тулы ай йөзә, шуңа күрә бик якты һәм җылы да. Мин йоклап та алдым, уяндым да, тагын йокладым, ә без бардык та бардык. Бу вакыйга 7-8 август төнендә булганын мин соңрак ачыкладым. Ә иртә белән Шәриф абый, безнең белән хушлашып, сугышка китте.

Әтине шулай ук җәй көне озаттык. Бер төркем авылдашлары белән әти 25 августта киткән икән. Әти хушлаша алсын өчен мине ул көнне бакчага илтмәделәр. Өйдән чыгып киткәндә, патефонда әтинең яраткан “Салкын

чишмә” һәм “Каляу Гайшә” көйләре язылган пластинка уйнап калды (шул вакыттан бирле бу ике моңлы көй әтине сугышка озаткан көйләр булып калды; аларны ишеткәндә хәзер дә минем күңелем әрни). Без чыгып арбага утырдык. Әни һәм башка хатыннар ирләрен Озын Тау пристанена кадәр озата баралар икән. Әни мине алып бармавын әйтте. Мин бик нык еладым, әтиемнән аерыласым килмәде. Басу капкасы – зират янында китүчеләрне озатырга халык җыелган. Тәрбиячеләр бакчадан балаларны да алып чыкканнар. Әни һәм тәрбияче Фәйрүзә апа мине көчкә әтидән аерып алдылар, мин елап калдым...

Бөек Ватан сугышы вакытындагы Бәзәкә хәлләрен тасвирлауны мин бар кешеләрне дә тетрәндергән зур фаҗигага бәйле үземнең балачак тәэсирләремнән башлап җибәрдем. Сугыш чоры хакында күпме генә язылса да, аз булыр, чөнки әле бүген дә аның ачылмаган, өйрәнелмәгән яклары җитәрлек. Бу еллардагы авылыбызның яшәешен мин, ул чорда яшәгән кеше буларак, үземнең балачак тәэсир-истәлекләремне, зурларның хатирәләрен, архивлардан алган материалны да кулланып, язарга булдым.

Абыем Мәхмүтов Шәриф хатирәләреннән: “Мин яңа гына Алабуга педтехникумын тәмамлаган идем. 21 июнь, шимбә көнне безгә дипломнар тапшырдылар, һәм без, бер төркем егет (безнең укыган төркемебездә гел егетләр генә иде) Тойма буендагы болыннарга куна чыгып киттек. Су кердек, балык тоттык, учаклар яктык, учакта бәрәңге пешердек, җырладык, уйнадык, шаярдык... Икенче көнне шәһәргә кайткач, сугыш башланганын белдек. Без бөтенебез бергә, башта техникумга кагылдык, аннан военкоматка киттек. Анда бик күп кеше җыелган, кайбер егетләрнең кулларында котомкалары да бар – алар инде бүген үк сугышка китәргә әзер булып килгәннәр. Бик озак, нәрсә көткәнне дә белмичә, шунда тордык. Соңрак безнең янга военком чыкты, Германиянең безнең илгә кинәт һөҗүм итүен сөйләде, обстановканы аңлатты һәм өйләребезгә таралышырга, ә иртән, дүшәмбедә, эшләгән һәм укыган урыннарыбызда булырга кушты. Техникумда безне, диплом алган егетләрне, аерым җыйдылар, хәзергә 1905-1918 елда туганнарның гына армиягә чакырылуы хакында аңлаттылар, калганнарга туган өйләренә кайтырга киңәш бирделәр”.

Шулай әле 18-не тутырырга гына җыенган (ул 1923 елның 2 июлендә туган) Шәриф абый авылга кайткан. Авылда аның яшьтәшләренең берсе дә чакырылмаган була әле. Һәм ул, әтиләр белән киңәшеп, сугышка кадәр планлаштырылган Березняк шәһәренә әтинең сеңлесе Нурнида апаларга кунакка китеп барган. Алай-болай ул югында повестка килсә, әти телеграмма сугарга тиеш булган. Ләкин Шәриф абый повесткага кадәр кайтып өлгергән. Алабуга военкоматыннан повестка август башында килгән. Абыйны армиягә озату турында мин үз хатирәләремне язган идем инде. Шуңа өстәп, Шәриф абыйның дусты белән төшкән фоторәсем артына язган сүзләрен китерәм: “Без бу карточкага сездән аерылгач сәгать 3тә төштек, 8-е көнне. Ә бүген, 9 августта иртән барып алдык. Мин бу карточканы шуның өчен төштем, әгәр исән йөреп кайта алмасам, сезгә истәлек булып калсын өчен. Югалтмагыз,

ертмагыз, рам эченә куегыз. Улыгыз Мәхмүтов Шәриф, 9 авг. 1941 ел”. Бу рәсемне алганнан соң абыйларны, пароходка утыртып, сугышка озатканнар.

Тагын бер истәлек. Монсы Шәргыя апа Ибәтуллинаныкы:

“Бөек Ватан сугышы башланганда мин 12-13 яшьләрдә идем. 1941 ел. Сугыш башланган көнне без су буенда бәрәңге бакчасында, чүп утап, чүмеч белән бәрәңге өя идек. Авылда ниндидер тавышлар, кычкырышалар, гармуннар уйныйлар. Без, Мәрьям җиңги, Камилә апа, мин, эшне ташлап ашарга кайттык. Өйдәгеләр җылыйлар. Урамнарда, кешеләр җыелышып, сөйләшәләр, җылыйлар. Авылда көндез: “Сугыш башлаган Германия”, - дип, җыелыш җыйдылар. Шул сәгатьтән военкоматка чакырулар.

Көн саен кешеләрне сугышка озату, атлар белән. Иң яхшы атларны озаталар. Кайбер көнне уналтышар егет-абзыйлар сугышка китеп бара. Җылашу, тавыш. Балалар зират капкасына кадәр озата баралар. Ә без, Минегали абыйны сугышка озатып, ун семья члены калдык. Авылдагы ир-егетләр, абзыйлар һәркөнне сугышка озатылып тордылар. Бондюг – хәзерге Менделеевск шәһәре – аркылы пароходларда Кама елгасы буйлап китеп бардылар. Июнь, июль, август айлары гел сугышка озату булды”.

Шәргыя апа сугыш чоры хакында истәлекләрен дә язды, Бөек Ватан сугышына 1941 елның июнь-декабрендә Ватанны сакларга чакырылган Бәзәкә ир-егетләренең исемлеген дә хәзерләде. Бу кыйммәтле чыганакны ул Нәҗип Фатыховның «Бондюг Татарстана – Родина семи героев Советского Союза» (Набережные Челны, 2010, с.417-478) исемле китабына кушымта итеп бирелгән Бондюг райвоенкоматы исемлеге нигезендә әзерләгән. Авылыбызның соңгы 80 еллык тарихын һәм кешеләрен бик яхшы белгән Шәргыя апа, шул бондюглыларның зур исемлегеннән бәзәкәлеләрне бөртекләп җыеп, миңа әйтеп яздырды. Шәргыя апа төзегән 1941 елда фронтка киткән бәзәкәлеләр исемлеген бүгенге көнгә безнең карамакта булган иң тулы исемлек дип әйтеп буладыр. Гомумән алганда, сугыш башланганнан соңгы алты ай эчендә Бәзәкәдән 160 кеше чакырылган булып чыга (Кушымта № 20). Ләкин бу исемлекнең дә тулы булмавын ассызыкларга кирәк, чөнки анда башка военкоматлардан киткән бәзәкәлеләр юк (мәсәлән, Алабуга военкоматы чакыртуы белән киткән Шәриф абый кебек). Сугышны, бертуган Хөснетдинов-Гыйлфановлар кебек, армия хезмәтендә каршы алган авылдашлар да бу исемлектә юк. Моннан тыш, Шәргыя апаның да, 2 мең ярым фамилия-исемнәр арасында бәзәкәлеләрне эзләгәндә, кемнедер төшереп калдыруы мөмкинлеген дә исәпкә алырга кирәк (Н.Фатыхов китабында авыллар күрсәтелмәгән).

Шулай итеп, сугышның өченче көнендә үк, 24 июньдә, Бәзәкәдән сугышка алты кеше, 25 июньдә тагын 43 ир-егет киткән. 1941 елның 25 июнендә фронтка Әхмәтҗанова Нәгыймә исемле 20 яшьлек кыз да җибәрелгән (ул 1940 елдан Бондюг районы сәламәтлек бүлегендә инструктор булып эшләгән җиреннән киткән). Бөек Ватан сугышында катнашкан Бәзәкә кызлары дистәдән ким булмаган. Аларның исемнәре: Габдрәхманова Зәйнәп, Кәлимуллина Мәхмүдә, Көләчева Мәрьям, Косолапова Зоя (укытучы), Минемөхәмәтова Мәрьям, Нәҗметдинова Мәхмүдә, Садриева Миниса,

Сәлимуллина (Ибраева) Рәйсә, Сабитова (Фәтхуллина) Вазиха. Алар барысы да 1942-1943 елларда армиягә җибәрелеп, күбесе зенит частьләрендә хезмәт иткәннәр.

Хәй абый Гыйлфанов җыйган мәгълүмат буенча, Бәзәкәдән сугышта барлыгы 639 кеше катнашкан. Соңгы вакытта Кәлмуллин Рәшит сугышта катнашкан бәзәкәлеләр исемлеген торгызу эшенә кереште. Хәзергә ул авыл советында саклана торган 1940-1945 елгы хужалык кенәгәләреннән бу елларда армиягә алынган 647 кешенең һәм Бондюг райвоенкоматында төзелгән 170 хәбәрсез югалган бәзәкәленең исемнәрен ачыклап, “бизяки.рф” сайтына урнаштырды.

Әни истәлекләреннән: 1941 елда уңыш бик уңган. Һәм барлык авыл халкы – әле сугышка чакырылмаган ир-атлар да, хатын-кызлар һәм картлар да, хәтта яшүсмерләр дә – барысы бергә тизрәк печән хәзерләргә, уңган ашлыкны җыеп бетерергә тырышканнар. Болында һәм басуда эшләүче ир-егетләр саны көннән-көн кими барган. Шулай урак өстендә фронтка китүче ирләрен һәм аталарын хатыннары, кызларына алмаштырырга туры килгән. Авылдан фронт кирәк-яраклары өчен бердәнбер йөк машинасын да, тракторларны да алганнар, колхозда атлар саны да кими барган (аларны шулай ук фронтка озатканнар).

Сентябрьдә әтидән хат килде. Ул әлегә Казаннан ерак булмаган мари урманнарында Суслонгер дигән станция тирәсендә солдатларны сугышка хәзерләү пунктында икән. Әни, җылы киемнәр һәм ашаулар алып, әти янына барып кайтты. Икенче тапкыр барганда ул мине дә үзе белән алды. Бу сәяхәттән минем өчен яңа булган бик күп вакыйгалар хәтеремдә саклана.

Октябрь азагы булгандыр, бик салкын иде. Без бик озак пароходта бардык. Минем өчен бар да яңа, таныш түгел, искиткеч: зур гына ак пароход, анда кешеләрнең күплеге, гел алмашынып торган елга ярлары... Мине бигрәк тә хәйран калдырганы – искиткеч матур ак киемле таләпчән, җитди капитан иде (минем күңелемдә изге хыял барлыкка килде – үскәч, мин дә капитан булам!)... Казанга килеп җиттек. Пристаньда кеше бик күп – тавыш, шау-шу, ыгы-зыгы. Без мин беренче тапкыр күргән трамвайга менеп утырдык. Бер хәрби миңа урын бирде. Әни минем янда, өске таякка эленгән брезент тоткычка тотынган. Атсыз-нисез трамвай кузгалып китте, үзе бара, үзе шалтыр-шолтыр килә, шакылтый, дерелди. Мин бик нык курыксам да, тирә-юньдә мине кызыксындырган нәрсәләр бик күп иде – карарга гына өлгер! Мине танышларында калдырып, әни әти янына ашыкты. Кич белән ул бик күңелсезләнеп кайтып керде – әтине ул күрә алмаган – аларны нәкъ шул көнне иртүк фронтка озатканнар икән...

Өебезгә без бик озак – атна-ун көн булгандыр – кайттык. Көч-хәл белән соңгы пароходларның берсенә эләктек. Тышта бик суык, карлы яңгыр ява. Шуңа күрә бар вакытны аста (базда – трюмда) үткәрәбез. Миңа әле Казанга барганда ук салкын тигән иде. Кайтканда, ютәлгә тагын бер бәла өстәлде – тәнемне, бигрәктә аякларымны, чуан басты. Чишенергә, кием алмаштырырга мөмкинлек булдымы икән, ансын белмим, ләкин, ниһаять, өйгә кайтып җиткәч, аякларымны бер чиләк җылы суда тотканнан соң гына оекларымны

ябышкан тире белән бергә салдыра алдылар. Шулай сәяхәт бик күңелсез тәмамланды. Бер яхшы нәрсә дә булган икән – әни миңа Казанда хәрефләр ябыштырылган шакмаклар алган иде. Кыш буе шулар белән уйный торгач, мин сүзләр төзергә, аннан соң укырга да өйрәндем. Шул вакыттан минем иң яраткан шөгылем китап уку булып китте.

Барлык укытучылар кебек, әни дә бик күп эшли иде. Сеңлем белән мин аны күрми дә идек. Әни истәлекләреннән: “Әтиегезне озатканнан соң мин дүрт кыз бала белән калдым. Олылары – сезнең апаларыгыз Нәҗия белән Рәмзия – мәктәптә укыйлар, Альта балалар бакчасына йөри, ә кечкенә Алиса – өйдә. Аны күршедә тора торган Бәнат апагыз карады. Сезнең икегезне дә күршеләр (әтиегезгә ерак туганнар да әле) Ясәви абзый (Бәнатның абыйсы) белән Миңлекамалттәй дә карарга ярдәм итәләр. Әтиегездән хат-хәбәр юклыгы бик борчый: аның юлдан бер генә хаты килде дә, башка бер хәбәр дә булмады... Мәктәптә эш бик күп иде: ир-ат укытучылар бер-бер артлы сугышка китеп тордылар, алар укыткан фәннәрне кемдер укытырга тиеш. Ир-ат укытучыларны (ә алар мәктәптә күпчелек иде) без – хатын-кызлар алмаштырырга тиеш булдык. Беренче чиректә берничә мәктәп директоры һәм завуч алышынды (аларны РОНО билгели генә, военкоматтан повестка килеп, сугышка китеп баралар). Шуннан соң мине завуч, Гөлсем Гайнуллинаны директор итеп куйдылар. Без, киткән ир-ат укытучылар урынына, мәктәпне бетергән берничә кызны чакырдык, хәтта унынчы класс укучылары да укытты”.

Архивта Бәзәкә мәктәбенең 1941/1942 уку елындагы хәле хакында мәгълүмат сакланган.

Таблица № 14

Класслардагы укучылар саны хакында мәгълүмат.

Класс-лар	Төркем-нәр саны	1.09-гә барлык укучы саны	Китүче-ләр	Шул саннан күчеп китүче	Уку елы азагына укучылар саны	Киләсе класска күчерел-гәннәр	Икенче елга калучы-лар
I	1	57	22	8	35	29	6
II	1	49	8	3	41	29	12
III	1	49	12	2	37	25	12
IV	1	51	18	5	37	28	5
I - IV	4	206	60	18	146	111	35
V	2	77	18	7	59	49	9
VI	1	65	27	18	38	28	9
VII	1	32	6	2	26	24	2
V - VII	4	174	51	27	123	101	20
VIII	-	11	11	-			
IX	-	16	16	-			
X	1	15+11	2	2	24	23	1
Барлыгы	9	422	140	47	293	235	56

I – IV классларда дәресләр, һәрвакыттагы кебек, 1941 елның 1 сентябрендә башланып, 200 эш көне дәвам иткән. V – VII һәм X класс

укучылары (VIII – IX класслар җыелмаган) уңыш җыюда катнашкан. Шуңа күрә алар 1 октябрьдә укый башлаган, укулар 175 эш көне тәшкил иткән. Мәктәп китапханәсендә укытучылар өчен 361 һәм укучыларга класстан тыш укыр өчен 672 китап булган. Уку елы дәвамында укучыларга 781 китап бирелгән. Мәктәп каршында интернат та эшләгән, анда 8 укучы яшәгән (күрәсең, күрше авыллардан килүчеләр булган). V – VII һәм X классларда немец теле укытылуы аерым күрсәтелгән.

Таблицадан күренгәнчә, уку елы барышында мәктәпне төрле сәбәпләр белән 140 укучы ташлаган, шуның 47-се күчеп киткән. Төркемнәр саны икеләтә кыскарган (узган уку елында 19 төркем булган). Бу кыскартулар укытучыларның күбесе сугышка китү белән дә бәйле булган. Бары X-класста гына укучылар саны арткан. Ул, мөгаен, күрше авыллардан укучылар килү һәм уку өчен түләүдән азат ителүчеләрнең саны (бу уку елында алар саны 23-кә җиткән) артуга бәйле булгандыр (VIII-X классларда уку түләүле булган). Икенче елга калганнарның саны күп булуын укучыларның төрле сәбәпләр аркылы дәресләргә йөрмәве белән аңлатып була. Мәктәптә укучылар санының кискен кимүенә игътибар итик: 1 сентябрьгә 422 укучысы булган мәктәптә уку елы азагына 235 укучы калган.

1942/1943 уку елында да мәктәп урта белем бирүне дәвам иткән, чөнки VIII-класска 35 укучы кабул ителгән (күпчелеге – 27 укучы – кызлар булган). I-класска 64 бала кабул ителгән (ике төркемгә бүлеп укытканнар). I – IV классларга уку елы башына барлыгы 184 бала язылган була (аларның 36-сы икенче елга калдырылган бала), V – VII классларда исемлектә 108 укучы (14 күчми калган). Уку елы башлануга мәктәптә 326 укучы булган, аларны I разрядлы дүрт һәм II разрядлы 7 укытучы укытырга тиеш булган. Тулы нагрузка 5 укытучыда, төп нагрузка шулай ук 5 укытучыда булган; бер укытучы - Вәлиәхмәтова Рөкыя – көчле авырудан соң, инвалид буларак пенсия алып, эшләмәгән. I – IV класслар беренче сменада укыганнар. Мәктәптә пионервожатый булмаган; комсомол оешмасының секретаре башлангыч класс укытучысы Әминә Бәдретдинова булган. Техник хезмәткәрләр 4 кеше булган. Мәктәп директоры хезмәтен Гөлсем Гайнуллина, завуч – Дарья Федорова башкарганнар. 1942/1943 уку елының азагына укуын 67 укучы ташлаган, мәктәптә 279 укучы калган. Алардан 248 укучы киләсе класска күчкән, 29 укучы икенче елга калдырылган.

Колхоз хәлләренә кайтыйк. Сугыш чорындагы авыл, колхоз хәлләрен ачыкларга районда ике телдә чыгып килгән “Стахановчы (Стахановец)” газеты материаллары күпмедер мөмкинлек бирә. Газета күп күләмдә агитация материалларын да бастырып килгән. 1941 елның 2 ноябрендә ВКП(б) Үзәк комитетының Октябрь революциясенә багышланган лозунглары басылган. Алар арасында бар халыкка караганнары да, халыкның аерым категорияләренә мөрәҗәгать иткәннәре дә булган. Шуларның берсен генә китерәм: “30 /пункт/. Хатыннар һәм кызлар! Ирләр профессияләрен үзләштерегез, фронтка киткән ирләрне алыштырыгыз!”. И.В.Сталинның 7 ноябрьдә Кызыл мәйданда парадта сөйләгән чыгышы да, 6 ноябрьдә Моссоветның тантаналы утырышында укыган зур доклады да газетада

басылган. Докладының “Безнең бурычларыбыз” исемле бүлегендә И.В.Сталин колхозчыларга мөрәҗәгать иткән: дошманны җиңү өчен, дигән ул, “безең колхозчыларыбыз, ирләр һәм хатын-кызлар үз басуларында армый-талмый эшләргә, илебезгә һәм фронтка күбрәк икмәк, ит, промышленность өчен чимал бирергә тиешләр; безнең бөтен илебез, СССРның барлык халыклары бердәм зур лагерь булып оешырга тиеш” (13 ноябрь саны). Бу материаллар урыннарда җыелыш-утырышларда өйрәнелгән, агитаторлар тарафыннан халыкка аңлатылган. Мондый чаралар хакындагы хәбәрләр дә газет битләрендә урын алган.

Бәзәкә (Сталин исемендәге колхоз) хакындагы газетка килгән кайбер хәбәрләрне карыйк. Менә, мәсәлән, 1941 елның 30 ноябрь санындагы “Юлбашчыбыз күрсәтмәләрен намус белән үтиләр” исеме астында бирелгән баш мәкалә. “Сталин ис. колхоз ашлык тапшыру планын соңгарып үти, ашлык сугу да начар бара иде. Юлбашчы докладын өйрәнгәннән соң икенче көнне үк эш күпкә яхшыра башлады. Колхозчылар ашлык сугуда стахановларча эшли башлады. Ип. Сабитова бригадасы көнгә 40 центнер урынына 48 центнер суктыра. Транспорт бригадасы да графиктан алда бара: 80 центнер урынына 90-ышар центнер икмәк тапшыра. Хәзерге вакытка колхоз икмәк тапшыру планын тулысынча үтәде”. Колхоз алдынгыларының исемнәре дә күрсәтелгән: “Сталин ис. колхозда ип. Г.Сабитова җитәкчелек итә торган ашлык сугу бригадасы барабанщигы ип. Х.Кәримуллин атлы сугу машинасында һәр көнне 45-48 центнер ашлык суга. Аңа көлтә биреп торучы М.Нәҗметдинова ике кеше урынына бер үзе эшләп, көнлек эш нормасын 130% ка үти. Транспорт бригадасы (Низамов) иген тапшыру пунктына 2314 центнер иң яхшы орлык тапшырды”.

Шушы ук санда комсомол райкомы секретаре язмасында “Татарстан комсомолы” танклар колоннасы төзү фондына Сталин ис. колхозның колхозчыларыннан 345 сум, мәктәп укучыларыннан 220 сум акча керүе хакында язылган. 16 декабрь санында Бәзәкә авыл советы рәисе Г.Гыймазетдиновның “6800 сумлык подписка” исемле хәбәре бар: “Хөкүмәтебезнең акчалата һәм әйберләтә түләнә торган лотереен үткәрү турындагы карары чыгарылу уңае белән Сталин ис. колхозның барлык бригадаларында җыелышлар булды. 2-3 көн эчендә 6800 сумлык лотерея алу хакында подписка бирделәр һәм кулдан 3600 сум акча җыелды. Р.Әһлиева, Х.Кәримуллин, И.Гайнуллин иллешәр сумга, Г.Сабитова 40 сумга, 65 яшьлек Г.Дәүләтшин 40 сумга, 76 яшьлек Зәйнуллин 30 сумга язылдылар”. 1942 елның 1 май санында Сталин ис. колхоз колхозчыларының фронтка бәйрәм бүләкләре хәзерләү өчен 2260 сум акча, 170 кг ит, 560 литр сөт, 455 йомырка бүләк итүләре турында хәбәр басылган.

Газетта тәнкыйть материаллары да күренгәли. Мәсәлән, 1942 елның 11 гыйнвар санында Г.Әхтәмовның “Һаман да ашыкмыйлар” исемле язмасы бар. “Сталин ис. колхозда ашлык сугу эшләре гафу ителмәслек акрын темп белән бара, - дигән сүзләр укыйбыз анда. – [...] Бөтен мөмкинлекләр бар. Машина көчләре җитәрлек. Биредә бер катлаулы, бер ярым катлаулы һәм ике атлы сугу машинасы бар. Ашлык сугу эшләрен икешәр смена оештырганда да ат

һәм эш көчләре җитәрлек. Шул ук вакытта аерым бригадаларда кул белән ашлык сугуны да яхшы оештырырга бик мөмкин”. Г.Әхтәмов ашлык сугу машиналарының тулы көченә файдаланмавын, икенче сменада эш оештырылмаганлыгын, 1314 гектардан җыелган ашлыкның 600 гектары гына сугылганлыгын (ягъни планның 48 % ка гына үтәлүен) күрсәтеп, “колхоз председателе Тажиев һәм авыл советы председателе Гыймазетдинов иптәшләр бу мөһим эш белән җитди шөгыльләнергә тиешләр”, - дигән сүзләр белән язмасын тәмамлаган.

Әни сөйләвенчә, 1941-1942 елгы кыш бик салкын булган, колхоз бакчасындагы һәм өйләр янындагы бакчалардагы алмагачлар, шулай ук безнең бакчадагылар да, өшеп беткән. Зәмһәрир суыклары белән килгән үтә салкын кыш, сугыштан килгән хәбәрләрнең кырыслана баруы, көзен хәзерләнгән азык-төлекнең язга таба бетә башлавы халык күңелендә төшенкелек тойгылары уяткан, коточкыч кайгыларны арттырган. Шулай да бу кыш ачлык башлану белән түгел, беренче сугыш кышы булуы белән халыкны күбрәк өркеткән, чөнки хуҗалыкларның күбесендә язга кадәр җитәрлек запаслары булган әле. Кешеләр түземсезлек белән язны көткән, яз килгәч барысы да рәтләнер, җиңү дә килер, ашавы да табылыр кебек тоелган аларга.

Яз да килеп җиткән. 1942 елның мартында ниндидер комиссия килгән. Әни аларны озатып йөргән: авыл советы, мәктәп, колхоз конторасы, балалар бакчасы, фермалар, ашлык амбарлары... Шул йөрүләр вакытында әни инеш аркылы чыкканда бәкегә эләккән һәм көне буе юеш итекләрдә йөргән. Шуннан соң әни чирләде. Баштарак ул үзе дә, башкалар да аның авыруын гади салкын тию дип кенә уйлаганнар. Ләкин авыру көннән-көн көчәя барган, әни аяктан егылып, урын өстендә генә ята башлады.

Мин бу шомлы көннәрне яхшы хәтерлим. Әни гел ятып кына тора, ишетелер-ишетелмәс, авырдан гына сөйләшә. Моның өстенә, әнинең хәлен белергә килгән апалар арткы якта әллә нинди куркыныч нәрсәләр сөйлиләр: имеш, әни инде кешеләрне танымый башлаган, имеш, ул үләчәк яки акылыннан язачак, имеш, безне (Алиса белән мине) детдомга җибәрәчәкләр... Бу сүзләрне ишеткән саен мин, алгы якка йөгереп кереп, урында яткан әнине аптыратырга тотынам: “Әни, син үлмәссең бит? Син мине таныйсыңмы? Мин кем?”. Әни мине тыныч ландыра, мин, арткы өйгә чыгып, теге апаларга кычкырам: “Әни акылыннан язмаган, ул мине таный! Ул үлмәячәк!”. Мондый хәлләр күпме вакытка сузылгандыр, белмим, ләкин бер көнне мин әнидән: “Син Эшти кызы Сания”, - дигән сүзләрне ишеттем... (күршедә яшәгән гел пычрак, ямаулы ертык күлмәктән йөргән Санияне миңа гыйбрәт итеп әйтәләр иде). Бу сүзләрне ишеткәч, мин елый-елый әни янынан атылып чыктым: “Әни акылдан язган, ул мине танымый!”. Бу минем өчен шундый зур тетрәнү, шул кадәр авыр кичереш булды, мин үз эчемә йомылдым, әни янына керми башладым, бер почмакта тавышсыз гына тик елап утыра идем...

Әнине Бондюг больницасына алып киттеләр. Бу инде апрель азагы-май башы булгандыр, чөнки кар инде эреп беткән, тышта коры иде. Шуннан соң булганнарны мин олылар сүзеннән сөйлим. Больницада әнигә бик куркыныч

диагноз куйганнар – менингит. Ул хәзер дә дәвалап булмый торган авырулардан санала, ә сугыш чоры өчен... Күпмедер вакыттан соң, әни һушсыз ятканда, аны, үлгән дип хисаплап, моргка күчергәннәр. Безнең бәхеткә, нәкъ шушы көнне әни янына Алабугадан аның фронттан контузиядән соң сихәтләнергә кайткан абыйсы килгән. Шаһвәли абый, җентекләп карагач, әнинең әле сизелер-сизелмәс сулавын күргән. Ул тавыш күтәргәннән соң әнине яңадан палатага урнаштырганнар... Әнинең организмы бик нык, яшәү теләге бик көчле булган, күрәсең, ул акрынлап терелә башлаган. Әни гомере буена үзенә терелергә ярдәм иткән Ленинградтан эвакуацияләнгән тәҗрибәле доктор Чоловскийны зур хөрмәт белән искә алып сөйли иде.

Әни янына Бондюгка баргалап йөри торган Нәҗия апа (ул аңа өйдән ашау – ипи-сөт алып бара иде) көннәрнең берендә мине дә үзе белән алды (бу әни теләге белән булганмы, яки Нәҗия апаны мин бик аптыратканмынмы – белмим). 1942 елның эссе җәй көне. Миңа яңа гына биш яшь тулган, Нәҗия апага 17 яшь. Ә безгә җәяү 12 чакрым юл үтәргә кирәк (ул заманда машина түгел, юл йорергә ат та юк). Юлның яртысын үттек микән - мин ардым, өйгә кайтуны сорый башладым. Бондюг белән Сәйтәк арасында үрне менгәндә, ялгыз үскән имән агачы янында без ял итәргә туктадык. Бондюг әле күренми (ул тау артында), ә Бәзәкә, уч төбендәге кебек, күренеп тора. Мин тагын, өйгә кайтуны сорап, елый башладым. Нәҗия апа мине ничек күндерер иде микән, белмим, ләкин бу вакытта Бондюг ягыннан безнең янга котомкалы бер бабай килеп җитте. Ул, капчыгыннан каткан ипи кисәге чыгарып, миңа бирде һәм мине үзе белән алып китәргә теләде. Әлбәттә, мин аннан бик каты курыктым һәм, аруымны, капризларымны онытып, Нәҗия апа белән китеп бардым. Ничек булса булды, без әби белән Нуриәхмәт абый кызлары Наилә һәм Фәйрүзә апалар яши торган йортка килеп җиттек. Нәҗия апа, мине аларда калдырып, үзе әни янына, аннан соң өйгә кайтып китте.

Әни янына мине икенче көнне Наилә апа алып барды. Әни бик нык ябыккан, ләкин инде, аркасын мендәргә терәп, ярым утырып тора, бик авырдан гына сөйләшә иде. Шулай да ул, Наилә апа ярдәме белән, яны белән борылып, миңа аркасын күрсәтте. Аркасының уртасында мин ниндидер зур кара түгәрәк күрдем. Ул, күрәсең, пункция алган җирдәге кара көйгән урын булгандыр, ләкин минем исемдә ул зур куркыныч тишек (яра) кебек калган. Әни янында больницада мин тагын булганмынмы, юкмы, Бәзәкәгә кем белән, ничек кайтканмындыр, ансы исемдә юк.

Әнине өйгә көз башында алып кайттылар. Ул үзе әле йөри алмый диярлек, зур авырлык белән, әйберләргә тотынып кына, караваттан өстәл янына барып җитә ала иде. Безнең өйдә миңа аңлашылмаган ниндидер сәер вакыйга булды: безнең гаилә икегә аерылды. Нәҗия апа белән Рәмзия апа арткы өйдә, әни, мин, Алиса – алгы өйдә яши башладык; ашауларыбыз да аерым булып китте, хәтта сыерны да көн аралаш саварга кирәк иде. Әни өйдән чыгып йөри алмый, безгә Алисаны карый торган Бәнат апа булыша, башкалар да (күршеләр, өлкән класс укучылары) булышкалыйлар.

Шундый факт истә калган: көзнең соңгы көннәре. Барлык бәрәңге бакчалары бушап калган, бары безнең инеш буендагы ярты бакчабызда гына бәрәңге казылмаган, чөнки әни авыру, көчкә йөри, ә без кечкенә. Салкынча булса да, кояшлы көн. Безгә бер төркем кызлар килеп керде (араларында мин Әминә апа белән Шәргыя апаны гына хәтерлим). Алар безгә булышырга килгәннәр икән. Кызлар уен-көлке белән бәрәңге алырга, аны чиләк һәм капчыкларда ишек алдына ташырга керештеләр. Бәрәңге бик уңган булып чыкты. Алиса белән мин дә аларга “булышабыз”: безнең кулларга кызлар ике-өч эре бәрәңге салалар, без горур гына, мышный-мышный, аны өскә алып менәбез. Әни өй базы ишеге янында утыра, безне мактый, кызларга рәхмәтләр укый. Шулай Әминә апа җитәкчелегендә мәктәптә укучы кызлар, бәрәңгене казып алып, безне кышка бәрәңге белән тәэмин иттеләр.

Кыш җитте. Әни акрынлап терелә, өй эшләре белән үзе шөгыльләнә башлады. Бер көнне әни, колхоздан ат һәм ярдәмчеләр алып, Кама аръягына утынга чыгып китте (аннан укытучыларга утынга дип хәзерләнгән бүрәнәләр җибәрәләр иде). Алар бик соң кайттылар, без инде куркып та, ачыгып та беткән идек. Әни безне тыныч ландырып, ашатып, йокларга яткырды. Төн уртасында бик каты итеп капка дөбердәүдән уянып киттек. Әни, тиздән кайтасын әйтеп, чыгып китте. Алиса белән без икәү, бер-беребезгә сыенышып, тагын әнине көтә башладык... Сыерыбызга бүреләр өере һөҗүм иткән булып чыкты (капка ачык калып, сыер чыгып киткән, аны эзләүче булмаган; кич кайткач, әни бераз эзләп караган, таба алмагач, иртәгегә калдырган. Сыер басуда булган, төнлә аны бүреләр куа башлаганнар; ул басу капкасы төбенә кадәр кайтып җиткән, ләкин капка бикле булып, ул аны үтә алмаган. Бүреләр өере урап алган сыерны каравылчы күреп, ничектер аларны куып җибәрә алган). Өйгә сыер үз аягы белән кайтты, ләкин аның җилене өзгәләнгән булып, сыерны суярга, иткә тапшырырга туры килде. Шулай 1943 ел башында без сыерсыз калдык. Сугыш чорында моның нәрсә икәнен аңлатып тору кирәкми.

Әнинең ышанычлы ярдәмчесе Бәнат апа, кыш көне чирләп үлеп китте. Безгә арт урамда яши торган Мөхәмәтҗанова Әдияттәй һәм аның үсмер кызлары (ире сугышта, ул биш кызы белән калган - иң олысына, Сабира апага 15-16 яшьләр булса, иң кечесе Мәгъфиягә 2 яшь) ярдәм итә башлады. 1942/1943 уку елында әни, мәктәп эшеннән азат ителеп, инвалидлыкта иде. Ләкин инде язга таба ул үзе агитатор итеп куелган колхоз бригадасында звено башлыгы булып эшли башлады. Бригадиры Фәйрүзә апа Гыйлфанова белән бергә алар көне-төне эштә, язгы чәчүгә хәзерләнә башладылар. Фәйрүзә апаны мин яхшы хәтерлим: ул бик пөхтә киенә, аның өстендә гел үзе матур итеп чиккән ак алъяпкыч була иде.

Чорның тере шаһиты булган “Стахановчы” газетына мөрәҗәгать итик. Аның 1943 елның 14 март санында детсад мөдире, партком секретаре Зифа апа Мөхәмәтҗанованың “Фронт айлыгы нәтиҗәләре” исемле кыска язмасы бар: “Сталин ис. колхоз членнары ярышып эшләп, гүзәл нәтиҗәләр бирәләр. Бигрәк тә 9 бригада (бригадир Н.Хуҗин), 2 бригада (бригадир Ф. Гыйлфанова) һәм 10 бригада аеруча яхшы эшлиләр. Бу бригадалар бүгеннән

үк чәчүгә чыгарга әзер. Машина һәм инвентарьга тулысынча ремонт ясалган. Г.Нәбиуллин, Г.Галиев, Г.Әхмәдиев һәм М.Хафизов иптәшләр язга әзерлектә үрнәк булырлык эшлиләр.

Колхоз басуга 90 тонна тирес чыгарды, 64 центнер көл һәм 46 центнер кош тизәге җыйды".

Шул ук авторның 8 апрельдә басылган тагын бер кечкенә мәкаләсе. "Сталин ис. колхозда авыл хуҗалыгы машиналары һәм инвентарьга ремонт ясау эше яхшы оештырылган. Тимерче Көләчев һәм аның ярдәмчесе Мозаффаров иптәшләр тырышып эшләү нәтиҗәсендә 71 сукага, 33 тырма, 23 культиватор, 10 чәчкеч, 58 арба, 102 комплект сбруйга яхшы сыйфатлы ремонт үткәрелде, - дип күрсәткән ул "Агрочараларга игътибарсыз карыйлар" исемле мдәкаләсендә һәм исемендә үк билгеләгән тәнкыйтькә күчкән. – Ләкин колхозда җитешсезлекләр күп әле. Колхоз җитәкчеләре бу җитешсезлекләрне бетерү өчен бер төрле дә кайгыртучанлык күрсәтми. Семеналар әзерләүгә, агротехника чараларын үткәрүгә тиешле игътибар бирмиләр. Кар тоту 40%, көл җыю – 50%, кош тизәге 18% кына үтәлгән. 3800 тонна тирестән 2150 тонна гына чыгарылган".

Сугыш озакка сузылган саен төрле сәбәпләр аркасында авылда халык саны кими барган. Ачлык һәм төрле авырулар дистәләгән кешеләрнең (бигрәк тә балалар һәм картларның) тормышын өзгән. Күпләрне төрле эшләргә мобилизацияләгәннәр. Фронтка чакырылу һәм хәрби заводларга мобилизацияләү сугыш башыннан азагына кадәр барган. Армиягә яше җиткән егетләрне генә түгел, 40 яшьтән узган өлкән ирләрне дә чакырганнар. Яшүсмер егет-кызларны да урман төпләргә, торф чыгарырыга мобилизация белән җибәргәннәр. Мобилизациягә кызлар да эләккән. Менә 1942-43 елларда Бондюг военкоматы аркылы Чиләбе танк заводына эшкә җибәрелгән 25 кызның исемлеге: Нигамаева Рәбига, Гатауллина Гөлҗиан, Гарифуллина Газзәбикә, Мөфтиева Зәйтүнә, Гәрәева Зәйтүнә, Мөхәмәтҗанова Зәйтүнә, Әхмәтгәрәева Әминә, Зиннурова Мәтлүфә, Бикмөхәмәтова Мәгълүмә, Баһаутдинова Нәсимә, Шәрипова Разия, Шакирова Кәрамиса, Салихова Рәхимә, Фәтхуллина Зәйтунә, Зәйнуллина Фагыйлә, Азина Нәсимә, Мөбәракшина Бәнат, Гыйззатуллина Галимә, Зәйнетдинова Галимә, Закирова Шәмсекамал, Шиябиева Хәдичә, Гыйззәтуллина Зәйтунә, Гайнуллина Нәсимә, Хәбибуллина Мәүлиха һәм Галләмова Хатирә. Бу исемлекне миңа Шәргыя апа төзеп бирде. Сугыштан соң бу кызларның бер өлеше авылга әйләнеп кайткан, бер өлеше Чиләбедә яшәп калган.

Шәргыя апа истәлекләреннән: "Сугыш озакка сузылган саен авылда ир-егетләр саны кими барды. Ә колхозда эшләргә хатын-кызлар, балалар гына кала бирде. Һәм карт-коры бабайлар. Без инде, атлар булмагач, үгез-сыер җиктек. Сука сукаладык, печән ташыдык, урман кистек. Икешәр, ягъни пар үгезләр җигә идек, ату көчләре җитми мескеннәрнең. Үгезләр белән эшләгәндә, кырда куыш ясап куна идек, чөнки үгезләр белән кайтырга озак, алар акрын йөри (үгезләр, мескеннәр, арыйлар, ашарга аз)".

1943 елның языннан әниебез колхоз эшенә чумды. Без аны тагын сирәк күрә башладык - кайбер кичләрдә генә алар безнең өйдә Фәйрүзә апа белән

икесе нәрсәдер язып-сызып утыралар иде. Иртән безне Әдияттәй кызларының берсе уята иде Мин бакчага китәм, ә Гамилә апа я Гайшә (ул миннән ике-өч яшькә генә олы) Алиса белән я бездә калалар, я аны үзләренә алып китәләр иде. Мин бакчадан соң аларга барам, Алиса минем карамакка күчә. Без икәү өйгә кайтып китәбез, анда әниебез хәзерләп калдырган ризыкны ашыйбыз (ул, гадәттә, иртәдән калган кабыклы бәрәңге, ипи, кайчак сөт була), аннан, әни кайтканчы, үз көнебезне үзебез күрәбез – уйныйбыз, укыйбыз, арсак, ятып йоклыйбыз... Әни, эштән кайтып, өй эшләрен карый (ашарга пешерә, сыер сава h.б.), безне ашатып йокларга яткыра да, үзе тагын эшкә китә (газет чыгару, концерт хәзерләү h.б.). Ул елларда бер безнең әни генә түгел, бөтен кеше (үсмерләрдән алып картларга кадәр) шулай гел эштә була иде. Язның беренче көннәреннән кышка кадәр эшкә яраклы бер кешене дә өендә табып булмый – колхоз эшендә булмаса, әрәмәдә утын-печән хәзерли, гөлҗимешен-баланын җыя h.б.

Шул ук 1943 елның бер язгы көнендә әни, колхоздан сатып алып, ачлыктан күтәрәмгә калган, аягында көчкә басып тора торган бер тана алып кайтты. Без аңа элеккеге сыерыбызның исемен бирдек - Манька дип атадык. Ул шул кадәр ябык, тире белән сөяге генә калган, ашарга да көче юк, алдына куйган печән-саламны да берәмтекләп кенә ашый. Ул акрынлап тазарды, зурайды, икенче кышка безгә бозау да алып кайтты, сөт бирә башлады. Сугыш елында сыерың булу бик зур байлык икәнлеген аңлатырга кирәкми. Безнең гаилә ачлыктан интекмәсә дә (укытучыларга ай саен азык-төлек паегы бирелә иде), безгә дә аның белән танышырга туры килде. Ләкин ул әни өйдә безгә ашау хәзерләп калдыра алмаганда гына була иде.

Сугыш еллары исемә төшкәндә, 1942-1943 ел кышы миңа, шулай да, иң авыр кыш булган кебек тоела. Югыйсә, әни дә терелде, таналы да булдык, барысы да яхшыга барган кебек иде. Ләкин әтидән элеккечә бер хәбәр дә юк, әни бик борчыла. Ул военкомат аркылы эзләтеп тә карады, “хәбәрсез югалган” дигән белешмә генә алып кайтты. Әлбәттә, үзләренең сугыштагы якыннары өчен борчылу һәр өйдә, һәр гаиләдә сизелә иде. Көз һәм кыш көннәрендә иртә караңгылана, әни дә өйдә күбрәк була иде. Кичләрен безгә күрше апалар җыела: килгән хатны укырга яки фронтка хат язып җибәрергә, хәбәрләр алышырга яки фронтка җибәрер өчен оекбаш-бияләйләрне бергәләп бәйләргә. Авылда электр уты юк, йортлар керосин лампалары белән яктыртыла, ә керосинны, лампа фитильләрен һәм куыкларын табуы бик авыр. Керосинны кибеттә укытучыларга, анда да бик азлап кына, саталар, ә базарда бик кыйбат, колхозчыларның алырга акчалары юк. Шуңа күрә күрше өйләрнең күбесендә кичләрен яктылык казан астындагы күмердән яки айдан гына төшә иде.

Керосин лампалары төрле зурлыкта – алар номер белән йөриләр (өчледән алып унлыга кадәр, зурыраклары да була, ләкин алар уку йортлары-клубларда гына кулланыла), пыяла куыклы (андый лампа яктыны күбрәк бирә) яисә куыксыз (ансы сукыр лампа дип атала) була. Безнең өйдә матча уртасына эленгән унлы куыклы лампа һәм өстәлдә тора торган җиделе сукыр лампа бар иде. Көндәлек тормышта без дә сукыр лампа гына яндырабыз –

керосинны да җиткерергә кирәк, лампаларга фитиль-куыкларны да базардан да табуы авыр. Күршеләр кич утырырга кергәндә, әни зур лампаны кабыза. Күршеләр үз яңалыкларын әнигә сөйли, кайгыларын уртаклаша. Мин, утның яктылыгыннан файдаланып, бер почмакта китап тотып утырам (мәктәпкә әлегә йөрмәсәм дә, инде шактый калын китаплар укыйм), ләкин олыларның сүзләре дә кызык, мин аларның сөйләшүләрен тыңларга яратам.

Әниебез борчулы апаларны тынычландырырга тырыша, ирләре, уллары табылачагын, озакламый тагын хатлары киләчәген сөйли (миңа ул, бу сүзләре белән, үзен дә тынычландыра кебек тоела). Сүзләрен куәтләгән кебек, ул шкаф башыннан ак сөлгегә төрелгән китабын ала, фал ача: китапны кайдан туры килсә, шуннан ачып, нәрсәдер кычкырып укый да, апаларга аңлата. Аныңча, китаптагы сүзләр дә алда бар да яхшы булачагын күрсәтә, авыр вакытларны ничектер уздырып җибәрергә, авырлыклар, билгесезлек алдында бирешмәскә генә кирәк. Әнинең фал ача торган китабы – Габдулла Тукай шигырьләре. Габдулла Тукайның шигырьләрен яттан белеп тә, әни бу китапны кешеләр алдында да, үзе генә булганда да еш кулына ала иде. Мине бу бик гаҗәпләндерә. Мин, әлбәттә, әнидән сорамыйча калмадым: “Нигә син бу китапны гел укыйсың? Син аны яттан беләсең ич!”. Әнинең җавабы: кирәк чагында тиешле юллар шунда ук искә төшми, ә китапны очраклы рәвештә ачып укысаң, Тукайның беренче җөмләсе үк җавап табарга ярдәм итә. Әнинең шкаф өстендә сөлгегә төреп тота торган тагын бер китабы бар иде. Аны ул бик сирәк, кеше югында гына, кулына ала. Мин, әни бу китапларны, укый алмасам да, шкаф өстенә миннән яшерә, дип уйлый идем.

1943-44 елгы кышны мин берөзлексез барган озын кич кебек хәтерлим, чөнки алар бер-берсен кабатлый иде: безгә, үз кул эшләрен тотып, күршеләр җыелган була; зур лампа кабызыла, кем эрли, кем бәйли. Башта авыл хәбәрләре сөйләнә, фронттан алынган хатлар укыла. Әни фронт хәлләре хакында сөйли, аннан соң, миңа газет биреп, үзе күрсәткән җирдән кычкырып укырга куша да, үзе дә бәйләргә утыра. Ул кышны солдатлар өчен бияләй-оекбашлар бик күп бәйләнде. Бер мәлне гел өч бармаклы бияләй бәйләделәр: берсе баш бармак өчен, икенчесе имән бармак өчен, өченчесе калган өч бармак өчен (алай мылтыктан ату җиңелерәк була икән). Минем дә шундый “ата торган” бармакны бәйлисем килә. Күп кенә ялынганнан соң, мине энә тотарга өйрәткән Зафира апа (бу кич утыруларда ул да була иде) миңа үзе бәйләгән бияләйгә имән бармак өчен булган бүлемне бәйләргә бирде. Зурлар бер кичтә бер пар бияләй бәйләсәләр (артыгырак та булгандыр), мин кич буена шул бармакны бәйләдем. Бәйләп бетерә алгач, күпме сөенгәнемне хәзер дә ачык хәтерлим. Ә инде Зафира апа бияләй эченә: “Бу бияләйне бәйләргә Альта исемле алты яшьлек кыз булышты, ул сугышчы абыйсына төз атуын, җиңеп тиз өенә кайтып җитүен тели”, - дигән язу салгач, минем горурлыгым чиктән ашты.

Зафира апа (ул миннән 7-8 яшькә олырак иде) – безнең күршедәге өйгә 1943 елда күчеп килгән Исмәгыйль абзый һәм Хәмдиттәй (Хәмдениса) Бәхтегәрәевләрнең кызы. Алиса һәм мин аларның кечкенә җылы өйләрендә бик тиз сыеныр урын таптык. Безнең өебез зур, салкын, кеше юк, ә аларда

һәрвакыт кемдер өйдә була иде. Исмәгыйль абзый гел диярлек өйдә. Ул 1943 елны, сугышта яраланып, озак кына госпитальдә ятканнан соң инвалид булып кайтты. Ул еш чирли, шулай да өендә эшли, промартельгә кәрзин, халыкка чабата үрә. Шуңа күрә аларның кечкенә генә өйләрендә юкә кабыгы, талчыбыкның тәмле исе аңкып тора. Мин Исмәгыйль абзыйның эшләвен карарга яратам (ул шул кадәр пөхтә, җиңел эшли, кулына күз иярми, син үрергә тотынсаң, синең кул астыннан да шундый ук матур чабаталар килеп чыгар кебек!). Хәмдиттәй һәм аларның үсмер уллары Зәки абый колхоз эшендә я әрәмәдә булалар, өйләренә кич кенә кайталар. Зафира апа мәктәптә укый, мәктәптән соң өй эшләрен эшли, әтисенә ярдәм итә. Нәкъ менә Зафира ападан мин бәйләргә һәм башка күп кенә көндәлек эшләргә өйрәндем. Аның ярдәме белән мин хәтта мичкә ягарга өйрәндем һәм алты-җиде яшемдә беренче тапкыр плитә өстендә аш та пешердем. Ул аш тәмле булгандырмы, юкмы, әйтә алмыйм, ләкин без аны ашадык, ә әни хәтта мактады да. Ләкин шунда ук ул миңа, янгын чыгу мөмкинлеге хакында аңлатып, зурлардан башка мичне кабызуны катгый тыйды.

Авыл укытучыларына, укытудан башка, ел әйләнәсендә нинди генә эш башкарырга туры килми иде! Алар бик күп нәрсә өчен җаваплы – бригадаларга беркетелгән агитатор, укый-яза белмәгәннәрне укырга-язарга өйрәтү, стена газеты һәм сугышчан листоклар чыгару, дәүләт заемнарын тарату, фронттагылар өчен җылы кием h.б. кирәк-яраклар җыю; фронтка хатларны да алар язарга ярдәм итә, солдатлар өчен оекбаш-бияләй бәйләүне дә оештыра, укучылар белән көл һәм кош тизәге җыя, тирес чыгара, кар тота, апрельдән октябрь азагына кадәр кырдан да кайтып керми...

Менә М.Әминовның “Стахановчы” газетында 1943 елның 9 маенда басылган “Агитаторның эше кырда” исемле язмасы. “Сталин ис. колхозның 3-бригадасында агит-масса эшләре яхшы куелган. Агитатор Әминә Бәдертдинова үз эшенә аеруча җаваплы карый. Бу эшчән комсомолка бригаданың язгы чәчүдә үрнәк эшләве өчен зур тырышлык күрсәтә. Стена газетасы регуляр чыгарылып бара, колхозчыларны фронт эшләре белән таныштыра. Бәдертдинова һәр көнне чәчүчеләр арасында була. Бригадир Габдрахманова белән бергәләп эшлиләр. Ә икенче бригада агитаторы Мостафина Т. кырга бер тапкыр да чыкмаган. Һәр колхозчы ул бригадада 0,30-0,40 га гына җир сөрә”.

Укытучылар мондый эшләрдән тыш төрле бәйрәм чаралары да әзерләргә тиеш иде әле. Һәрбер бәйрәмгә укытучылар һәм укучылар концерт яки спектакль хәзерли. Бу эштә дә Әминә апа беренчеләрдән булды. Ул бар эшкә дә сәләтле; үзе чибәр, пөхтә киенә, матур итеп бии, моңлы җырлый, концертларны алып баручы да ул иде. 1943-1944 елның кышыннан мине дә аларда катнаштыра башладылар. Сәхнәдән беренче укыган шигырем минем бүген дә исемдә. Ул Фатих Кәримнең “*Әткәем”* исемле шигыре иде. Инде олыгайгач, мин язучының бу шигыре 1938 елда, репрессиягә элэгеп, төрмәдә утырганда, кызы Ләйлә исеменнән язылганлыгын белдем. Ә ул чагында бу шигырь яңа гына язылган кебек иде. Менә ул шигырь.

Әткәем.

Нурын сибә кояш, тама тамчы,
Ерганаклар ага, әнкәем;
Тагын җитте бу яз... Нигә кайтмый,
Нигә кайтмый инде әткәем?
Тиздән матур кошлар килер безгә,
Берсен берсе куып уйнарлар,
Тәрәзәгә куныр алар миннән:
“Әткәң кайттымы?!” – дип сорарлар.
Мине якын иткән кошчыкларга
Ни дип җавап бирим, әнкәем?
Тагын җитте бу яз... Нигә кайтмый,
Нигә кайтмый инде әткәем?

Ә ул чагында... мин шигырьне сөйли генә башладым, залдагы апалар мышык-мышык борыннарын тарта башладылар. Укып бетергәндә, залда барысы да диярлек елый иде. Кул чабулар ишетелми... мин югалып калдым. Минем янга Әминә апа чыкты (ул концертны алып баручы), мине җилкәмнән кочаклап алды да, без залның тыныч ланганын көтә башладык. Зал тынгач, Әминә апа миңа шигырьне тагын бер кат сөйләргә кушты. Монсында инде халык дәррәү кул чапты... Моннан соң да мин бик күп концертларда катнаштым. Нинди генә шигырь сөйләсәм дә, миннән “Әткәем”не кабатлап сөйләвемне сорыйлар иде. Иң яратып сөйли торган шигырьләрем Фатих Кәрим, Габдулла Тукай һәм Һади Такташныкылар иде.

Сугыш вакытында да район үзәгендә смотрлар уздырылган. Менә, мәсәлән, “Стахановчы” газетының 1944 елгы 10 февраль санында үзешчән сәнгать район смотрында бәзәкәлеләрнең концерты иң яхшыларыннан булуы хәбәр ителгән; ике укучы кыз Вәлиева һәм Гайнетдинова, чегән биюен бик яхшы башкарып, 400 сум акча белән бүләкләнгәннәр.

Балалар – мәктәптә укучылар һәм кечкенәләр өчен дә. төрле бәйрәмнәр оештыралар иде. Бу бәйрәмнәрне мәктәптә дә, балалар бакчасында да, клубта да, уку йортында да уздырганнар. Моны, мәсәлән, Саимә Шәйдулатовада (Сәйфетдинова) табылган фоторәсем исбатлый. Минем кулга очраклы рәвештә генә эләккән бу шактый таушалган фотода Яңа ел бәйрәмен уздыру өчен киенгән бер төркем бакча балалары сүрәтләнгән. Киемнәр сугышка кадәр үк әзерләнгән булгандыр дип уйлыйм. Ә бәйрәм 1943-1944 еллар кышында булгандыр. Әни белән икәү миңа кар кызының тажын хәзерләгәнне хәтерлим (әнинең мине кызыктыра торган каптырма-төймәләре бар иде; мин берничә тапкыр аларны сорасам да, әни миңа аларны тотып карарга да бирми иде; ә бу юлы бер ялтыравыклы каптырманы үзе таж уртасына урнаштырды).

Бер җәйне (1944 ел булса кирәк) әни сеңлем Алиса белән миңа туйганчы бал ашатырга булган. Безнең бакчада һәр вакыт 1-2 умарта була торган иде, әни чирләгәндә дә, бер умарта калган иде. Умарта караган көнне бал алгач, әни безнең алга ике өй арасындагы тупсага зур табакка салынган барлык алган кәрәзле балны китереп куйды да: “Туйганчы ашагыз, бүтән сорап

аптыратырлык булмасын”, - диде. Без башта балның үзен генә, аннан соң ипи белән, су белән ашадык... Бала күпме бал ашый ала соң? Без күпмедер ашадык та, башка ашый алмыйбыз, ләкин “туйдык, алып куй” дип әйтәсе дә килми. Шуннан: “Без әле туймадык, бал шунда торсын”, - дип, ишегалдына чыгып, уйнап кердек. Тагын аз гына ашадык, тагын уйнап кердек. Шулай ничә тапкыр кабатлангандыр, белмим. Нинаять, әни чик куйды: “Хәзер күпме ашый аласыз, шул кадәр ашагыз да, аннан соң алып куям”, - диде һәм шулай эшләде дә. Соңыннан, без үскәч, әни бу вакыйганы көлеп тә, безне жәлләп тә искә ала иде: “Мин балалар, бер тапкыр булса да, туйганчы (үтләгәнче) ашасыннар, башка сорамаслар, дип уйлаган идем. Ләкин Альта акыллырак булып чыкты – үзе дә күп ашамый, Алисаны да туктата – “тукта, күп ашама, үтләрсең”, - ди һәм аны уйнарга алып чыгып китә. Шулай итеп, сезне бал белән туендыра алмадым”.

Әниебез бик күп эшләсә дә, өйдә булган чакларында безне нәрсә белән булса да сөендерергә, күңелебезне күтәрергә тырыша иде. Аның юкны бар итә торган сәләте бар иде: я ул безнең белән кул астына эләккән нәрсәләрдән төрле уенчыклар ясый, я гади генә әйберләр кулланып, безне телеңне йотарлык ризыклар белән сыйлый (мәсәлән, кычыткан-балтырган турап пешергән ашка бер йомырка сытып болгата да, ул аштан да тәмлерәк ризык булмаган кебек ашыйсың), я ул безнең кечерәйгән берничә күлмәктән менә дигән өр-яңа күлмәк тегеп бирә...

Без бик тиз үстек, ә әниебез безне матур киендерергә тырыша иде. Ул үз киемнәреннән дә, әтинең киемнәреннән дә безгә кием тегә, миңа кечерәйгән күлмәкләрне Алисага яраклаштыра. Кайчак яңа материал да табыла иде. Бер елны (1943, я 1944 ел булгандыр), әни, каяндыр соргылт төстәге бәз табып һәм аны хининга (бизгәк авыруына каршы куллана торган дару, ул тамган җир сап-сары була иде) манып, безгә 1-Май бәйрәменә пардан бик матур ачык сары төстәге күлмәкләр текте. Ул елны май бик җылы килде. Безне, матур күлмәкләр кигән сары күбәләктәй ике кызчыкны, Фәйрүзә апаларда калдырып, өлкәннәр басуга эшкә киттеләр. Аларның ишек алдында кап-кара, ялтырап тора торган тарантас бар иде. Без – Алиса, мин һәм минем яшьтәшем, Фәйрүзә апаның энесе Зәки – озак кына шул тарантас тирәсендә уйнадык. Нәтиҗәдә, безнең матур күлмәкләребез зур-зур кара тапларга буялып беткән иде (тарантас кичтән генә дегет белән буялып, кибәргә куелган булып чыкты). Күпме генә тырышсам да, мин күлмәкләребезне чистарта алмадым, киресенчә, алар тагын да шакшырак булдылар. Һәм мин аларны әнидән яшердем (Алисага күрсәтмичә генә, чоланның бер идән тактасын күтәреп, күлмәкләрне бөгәрләп тыгып куйдым). Ничектер әниебез бу күлмәкләрнең юклыгына бик соң игътибар итте, ләкин мин-тешләктән рәтле җавап ала алмады...

Сугышка кадәр колхозчыларның мәҗбүри хезмәт көне 50 тирәсе булса, сугыш башлангач, дөресрәге, беренче язда ук, бу сан шактый арттырылган. 1942 елның 28 апрелендә ТАССР совнаркомы һәм ВКП(б) обкомының колхозчыларның мәҗбүри эшләнергә тиешле хезмәт көннәренең минимумын 120 көнгә кадәр арттырырга дигән карары чыккан. Мәҗбүри көннәрне

конкрет срокларга бүлү дә каралган булган. Мәсәлән, Бондюг районы кергән зур төркем районнар өчен түбәндәге нормативлар эшләнгән: 15 июньгә кадәр 30, 15 августка – тагын 28, 15 октябрьгә - 46 хезмәт көненнән дә ким булмаска, калган көннәрне 15 октябрьдән соң да эшләргә рөхсәт ителгән.

Һичшиксез, ирекле рәвештә хезмәт көннәрен үтәү күбрәк күләмдә дә булган. Ирләрен, улларын һәм башка туганнарын кырда, болында, ындыр табагында алмаштырган хатын-кызлар үзләре дә мәҗбүри минимумнан күпкә артык булган планнар кабул иткәннәр. Ләкин репрессив чаралар куллану да булган: мәҗбүри минимумны үтәмәгән колхозчыларны колхоздан чыгару һәм аларның ихата җирләрен тартып алу каралган була. 12 яшен тутырган балалар өчен дә мәҗбүри минимум билгеләнгән (50 хезмәт көне). Мәктәпләрдә 5-10 класс укучылары өчен укыту вакыты да кыскартылган: майдан алып октябрьгә кадәр алар колхоз эшен эшләргә тиеш булганнар.

Әлбәттә, бу кискен чараларның да йогынтысы булмый калмагандыр, ләкин өлкәннәр дә, үсмерләр дә ил каршында, фронтовиклар каршында үзләрен бурычлы саныйлар иде. Фашизмның җиңеләчәгенә ышанган колхозчылар үзләренең хезмәтләре белән армия һәм шәһәр халкын азык-төлек белән, завод-фабрикаларны чимал белән тәэмин итүләрен яхшы аңлаганнар. Әлбәттә, үз халкының эшкә яраклы иң зур өлешен фронтка, завод-фабрикаларга, транспортка, утын кисү, торф чыгаруга җибәрергә мәҗбүр булган авыл өчен сугыш еллары бигрәк авырга туры килгән. Шәһәр халкы һәм авыл интеллигенциясе өчен кертелгән билгеләнгән норма буенча азык-төлек белән тәэмин итү колхозчыларга бөтенләй каралмаган була. Авыл халкы яшәешенең төп чыганагы аның ихатасындагы хуҗалыгы булган. Ләкин шәхси хуҗалыктан зур күләмдә налог та алынган, ягъни шәхси хуҗалыктан алынган продукциянең күп өлеше салымга киткән була: һәрбер хуҗалык билгеле бер күләмдә дәүләткә ит, сөт, май, йомырка, йон, бәрәңге тапшырырга тиеш булган. Акчалата салымнар да булган – җир салымы, фронт налогы h.б. Ә бит хуҗаларын фронтка озаткан һәр хуҗалыкта балалар һәм картларны да туйдырырга кирәк булган.

Авыл халкына (ә сугыш елларында ул, нигездә, хатын-кыз, бала-чага һәм карт-корыдан торган) авырлыклар иртәдән кичкә кадәр авыр эшләр башкарудан гына тормаган; аңа ачлыкны да, суыкны да, төрле авыруларны да үз җилкәсендә татырга туры килгән. Ләкин иң авыры фронттан хәбәр көтү булгандыр. “Карт-корылар ачтан үлә, кайберләрен киндер капчыклар белән җирлиләр иде. Һәр көн аның өстенә армиядән кешеләрнең үлү хәбәре килеп тора, - дип язган истәлекләрендә Шәргыя апа. - Ул вакытларда радиолар юк (сугыш башлангач та, авылларда бик сирәк йортларда булган радиоалгычларны ды җыеп алып, районга алып киткәннәр – А.М.). Агитаторлар, ягъни укытучылар, актив хатын-кызлар, өйләргә йөри-йөри семьяларны тынычландырып, газета хәбәрләрен сөйлиләр иде. Түзәргә кирәк, солдатларга оекбашлар бәйләп, военкомат аша озаталар иде”.

Күршедәге карт әбиләр, яз җитә башлагач, җиңел сулап куялар иде: “Кышны да уздырдык. Алла теләсә, хәзер җиңелерәк булыр: төрле үләннәр җыярбыз, тартып-сузып булса да, җиткерербез. Ә анда сугыш та бетәр,

безнекеләр дә кайтыр, алла бирсә, элеккедән дә яхшырак яшәрбез”. Шәргыя апаның истәлекләреннән: “Ә инде җәйгә таба, апрель-май айларында чыккан кычыткан, алабута, юа, төрле үләннәр белән шулпа ясап (үлмәс өчен), көн күрәләр иде. Сыер тоткан хуҗалыклар, сөт-катык сатып, алмашка шырпы-тоз алып кайталар иде Бондюг-Менделевскидан. Ә мөмкинлеге булмаган әби-бабайлар бер-берсеннән утлы күмер алып чыгалар. Салам яндыралар иде, пичкә ягып. Ә саламны (малларга кирәк булганга) мылтыклар белән саклыйлар иде. Хәле булган солдатка хатыннар бәләкәй арба, чана белән әрәмәдән чыбык утын ташыйлар иде”.

Шул ук бәләкәй арба-чаналарда, аркага кия торган котомкаларда хатыннар һәм үсмер кызлар Озын Таудан (10-12 км) һәм Алабугадан (35 км) чәчүгә симәнә ташыйлар иде. Әгәр дә минем исемдә дөрес калган булса, яңа ашлыкны, бөртегенә кадәр диярлек, сакларга Алабуга элеваторына алып китәләр иде. Ә кыш азагы – яз башында колхозга чәчү орлыгын кире ташыйлар. Атлар аз, булганы да кыш чыгуга көчсезләнгән, шуңа күрә симәнәне хатын-кыз ташый. Шәргыя апаның әлегә исән булган ветераннарга багышлаган шигыре (бәет) бар. Шул бәеттән сугыш еллары турындагы өзекне китерәм:

“Каһәрле сугыш еллары
Безнең яшьлеккә килде:
13-14 яшьләрдә
Кирәк җирне сөрергә,
Кырда урак урырга,
Үгез-сыер җигәргә,
Болыннан печән ташып,
Малларны ашатырга.
Хәмдениса, Гөлбостан,
Фәхерниса, Хатимә,
Минекамал, Хәлимә,
Минебаян, Гөлҗинан,
Газдәбану, Гатифә,
Сабира һәм Шәргыя,
Уфалла арбасы тартып,
Симәнә алып кайта.
Бондюгтан – Бәзәкәгә”.

Гомумән алганда, сугыш елларында авыл-шәһәрләрдә калган ачялангач хатын-кызлар, үсмерләр һәм хәтта балалар да, көчләрен генә түгел, тормышларын да кызганмыйча, көне-төне эшлиләр иде. Фронтовиклар гына түгел, тылдагы хатын-кызлар, картлар һәм үсмерләр бергәләп Бөек Җиңүне якынайту өчен тырыштылар. Аларның барысына да, соңгы елларда күрсәтелә башлаган хөрмәт-ихтирам күпме булса да, аз булачак.

Бөек Ватан сугышы елларындагы тормыш турында тагын бер Бәзәкә шагыйрәсе, сугыш чоры баласы Шакирова Фәниянең дә зур гына шигыре бар. Ул анда үзенең сугыш чоры һәм аннан соңгы балачак хатирәләрен тасвирлаган. Бу шигырь-балладаны да мин китапка кертергә булдым.

Сынап сындырган язмыш.
Көтмәгәндә илгә афәт килде,
Илне кара төтен каплады.
Җиңү өчен өметләрен баглап,
Ирләр ил сакларга атлады.
Балаларын, ирләрен озатып,
Бәгырьләре калды өзелеп.
Бала-чага, колхоздагы эшләр
Хатын-кызга калды өелеп.
Җиңү диеп, көнне төнгә ялгап,
Эшли алар, эшли - тырыша.
Бөтен булган ипекәйне җыйнап,
Җибәрәләр алар фронтка.
Кайтып тора кара кәгазьләре,
Эш өстенә кайгы өелә.
Өчпочмаклы сәлам хаты көтеп,
Күпме газиз җаннар тилмерә.
Берәрсенә сәлам хаты килсә,
Шатлык иңә алар иңенә.
Кат-кат җыелып аны укый алар
Ничә кабат микән көненә.
Атлар арган. Ашатырга беткән...
Сукаларда атлар егыла.
Мондый ачы, авыр газаплардан
Бугазларга төер тыгыла.
Исәннәрен фронтка алдылар,
Атлардан да халык аерылды.
Кибән төбе ашлыкларын ашап,
Күпме газиз җаннар кырылды.
Көтүмкәләп, бәләкәй арба сөйрәп,
Алабугадан орлык ташыды.
Чабаталар тузып, табаннар кабарды,
Тешен кысып, халык чыдады.
Көне кызу, авыз чайкый-чайкый,
Көне буе урак урдылар.
Үз динәрен алар хөрмәт итте,
Эссе дими, ураза тоттылар.
Носилкалар белән көлтә ташып,
Тиргә батып, кибән куйдылар.
Тешкәйләрен кысып, түзә-түзә,
Күпме саулыкларын җуйдылар.
Басу капкасында –каравыллар,
Кесәләрне алар капшады.
Безнең әниләрнең күтәреп кайткан

Печәненә кадәр калдырды.
Авырлыклар белән кимсетүләр,
Сугышы да китте озакка.
Таш булып, таш та чыдамас иде
Әниләр кичергән газапка.
Кан тамгандыр алар йөрәгеннән,
Һаман онытылмый яралар.
Өйгә кайткач, тагын йөрәк өзеп,
Ипи сорап елый балалар.
Кояш чыгу белән әни эшкә китә,
Кайта иде, фәкать, кич кенә...
Өйдәге эш, ике нәни бала
Җиде яшьлек кызчык өстендә.
Олы чиләкләрен сөйри-сөйри,
Өй чистарта, суын китерә.
Әни кичтән эштән кайтуына
Ярып бәрәңгеләр пешерә.
Аш пешерү өчен басулардан
Берәмтекләп борчак чүпләдек.
Төрле үлән яфракларын ашап,
Ярый инде, җәен үткәрдек.
Ярап куйды безгә шул чагында
Кычыткан, балтырган, кукысы.
Әле дә тора кебек тамагымда
Алабута ипие ачысы.
Сукыр лампа, керосины беткән,
Табага салып, чыра ягабыз.
Кабыклы бәрәңге өләшенә,
Шулай гына булган чамабыз.
Ул чагында сабын бөтенләй юк,
Селте белән керне уалар.
Су буена төшеп, тукмый-тукмый,
Киндер күлмәкләрен юалар.
Бу ачлыкка тагын афәт булып,
Бизгәк чире килеп кушылды.
Мәрхәмәтсез шушы явыз чирдән
Күпме кеше җаны кырылды.
Өй эченә кергәч, тигезләде,
Чирләделәр өйдә барчасы.
Ашап булмый – әле дә күз алдымда
Тәлинкәдә юа боткасы.
Аврлыкка авырлыклар өстәп,
Налог-заемнарын салганнар.
Акча сорап, әниләрне беркөн
Авыл советына япканнар.

Төне буе елап чыккан алар,
Йөзләр шешкән, күзләр кызарган.
Иртән генә балалар янына
Әнкәй бәгърем кайтып егылган.
Язмыш безне сындырып сынады,
Күрдек бу сугышның газабын.
Алда тагын ниләр көтеп тора?
Белмибез шул гомер азагын.
Өсләрегез бөтен, ис китәрлек,
Туенасыз, тәмләп тамакны.
Әй, Ходаем, балаларга бирмә
Без кичергән авыр газапны.

1944 елда мин мәктәптә укый башладым. Әни миңа мәктәпкә йөрер өчен әтинең чалбарыннан бик матур костюм текте (мин шундый кечкенә булганмынмы, әтинең чалбары зур булганмы, ләкин костюмым үземә бик ошый иде – мин укытучы апалар кебек булдым). Ул елны балаларны мәктәптә җиде яшьтән укыту турында указ чыкты (аңа кадәр сигез яшьтән иде), шуңа күрә беренче класска керүче балалар саны икеләтә артты. Безне өч төркемгә бүлделәр. Мин Рәхилә апа Әлмәтева классында идем. Без укуны түбән мәчет бинасында башлап җибәрдек, соңрак безне тау башындагы зур мәктәпкә күчерделәр (бәлки, бу күченү ике мәктәпне җылытыр өчен утын күп кирәк булганга эшләнгәндер).

Ике бина да безнең өйдән шактый ерак иде: түбән оч мәчетенә кадәр ярты авылны узарга кирәк булса (1 км чамасы араны), карар күзгә якын булса да, тау башындагы мәктәпкә бара торган юл шуннан ким булмагандыр. Мәктәпкә барып җитәр өчен таудан төшәргә, инеш аркылы салынган басмадан яки боз өстеннән чыгып, инеш үзәненнән үтәргә һәм тауга менәргә кирәк иде. Тауга менә торган өч юл бар: берсе туп-турыга тау уртасыннан менә торган бик текә юл, икенчесе тауның уң ягыннан, текә булса да, менү өчен җайлырак юл, өченчесе тауның сул ягыннан, олы чишмә янынан башланган сөзәк юл. Бу киң юлдан җәяүлеләр дә, йөкле арбалар да йөри иде. Без, аяк асты бик пычрак булмаганда, уртадагы туры юлдан йөри идек (50-еллар урталарында ул турда бик матур, менү өчен уңайлы баскыч та төзеп куйдылар). Зур мәктәптә класс бүлмәләре аз иде. Шуңа күрә без бер бүлмәдә берьюлы ике төркем укыдык. Бүлмәдә бер төркем өчен парталар ишеккә, икенчесе өчен стенага каратып тезелгән; безнең класс ишеккә караган өлешендә. Парталар зур, ике-өч урынлы; укучыларның барысы да укырга килгәндә, без өчәр-дүртәр бала бер партага утыра идек...

Сугыш бөтен халык ярдәме белән алып барылды. Алдарак фронтовиклар өчен җылы кием, бүләкләр җыю хакында язган идем. Шулай ук сугыш барышында танклар, самолет, кораблар төзүгә акча җыю, планнан тыш “оборона гектарлары” чәчү, җиңү фондына ашлык, ит, сөт, яшелчә һәм башка азык-төлекне планнан тыш тапшыру кебек чаралар үткәрелә иде. Менә “Стахановчы” гәзитенең 1944 елның 17 февраль саныннан бер хәбәр:

“Мәсәлән, Сталин авыл хуҗалыгы әртиле членнары Я.Шәяхмәтов, М.Газизов, Г.Гыймазетдинов, Г.Гайнетдинов һәм Тажиев иптәшләр колхозның орлык фондына алтышар пот бәрәңге, З.Фатыхов өч пот борчак керттеләр”. Минем дә хәтеремдә: яз башында, ат җигеп, хуҗалыклардан, шул исәптән бездән дә, колхоз басуында утыртыр өчен, капчыклап бәрәңге җыялар иде. Һичшиксез, бу һәм башка азык-төлек кешеләрнең үзләренең ишле гаиләләреннән дә артмас иде, чөнки, бик кысып тотканда да, бик аз кешенең бәрәңгесе җәйгә кадәр җитә иде.

Монысы да хәтеремдә: яз җитү белән (әле кар да эреп бетмәгән була), күршеләрнең күбесе, бәләкәй көрәк, пычак, чиләк һәм капчыклар алып, басу-кырлардан кар астында кыш чыккан өшегән бәрәңге җыярга китәләр иде. Дистәләгән чакрымнар узып, күрше авыл кырларына да барып чыгалар, кайда нәрсә тапсалар, шуны җыеп кайталар иде (бәрәңгенең бик вагы да калмый, өшегәне дә, черегәне дә эшкә ярый). Аны юлда ук очраган бозлы суда юалар, өйгә кайткач, бик яхшылап эшкәртеп, бәрәңге кәлҗемәсе пешерәләр иде. “Сугыш безнең җилкәдә зур яралар калдырды. Яз көне инде Тукай, Псәй, Сарсаз басуларыннан өшегән бәрәңге казып (иртәдән кичкә кадәр), көчкә өйләренә кайтып егылалар иде. Балалар яз көне судан кумак тотып, чир йоктырып, больницаларда яттылар, үлүчеләр дә булды. Менә ул сугышның газаплары, - дип искә ала Шәргыя апа. - Без җиңү көнен бик көтеп алдык. Сугыштан кайтканнар кулларын өзеп, аяксыз, телсез, күзсез, контузия белән кайтучылар да күп иде. Күпме ятимнәр калды. Сугыш бетсә дә, төтене бик күп елларга сузылды. Киергә кием юк, аякта чабата булса бик ярый иде әле. Ә хәзерге балалар өчен бу әкият кенә шикелле”.

Сугыш бетте. Бу хәбәрне безгә әни әйтте. Без дәресне яңа башлаган гына идек, безнең класска әни (завуч) килеп керде. Ул сугыш бетүен, шуңа күрә дәресләр булмаячагын, митингка барачагыбызны аңлатты. Бөтен мәктәбебез белән, колонналарга тезелеп, флаглар белән, олы чишмә янынан авылны уратып, клуб янына митингка киттек. Анда кеше күп җыелган иде инде. Музыка уйный (анда гармуннар да, патефон да бар), кызыл әләмнәр, транспарантлар... Җыр, шатлык авазлары, күп апалар елый. Митинг башланды. Башта районнан килгән бер абый белән бер апа сөйләде, аннан соң безнекеләргә дә чират җитте – авыл советы рәисе, яраланып сугыштан кайткан абыйлар, укытучылар... Бу чыгышлар укучылар башкарган җыр-шигырьләр белән аралашып барды. Мине дә сөйләттеләр (тагын “Әткәем”не сөйләргә туры килде). Митинг беткәч тә әле халык бик озак таралышмады.

Әти кайтты...

Киткәннәрнең җылы аяк эзен
Саклап тора сыман бусага,
Кеше кайта,
Кайта туган өйгә,
Бик күп сулар аккан булса да.

Харрас Әюп

Сугыш беткәч, бөтен авыл солдатлар кайтуын, һич югында, исәнлеген хәбәр иткән хатлар көтеп яши башлады. Акрынлап фронттан җиңеп кайтучылар да күренде. Әтиләре кайткан яки тиздән кайтачаклары турында хәбәр алган классташларым бик бәхетле һәм горур йөриләр, мактанып, әтиләре сөйләгәннәрне безгә дә сөйлиләр. Җәй дә җитте, ә безнең әтидән һаман бер хәбәр дә юк иде. Аның беренче хаты август аенда гына килде. Ниһаять, әти табылды! Ул исән! Ул тиздән кайтачак! Шулай без дә әтинең хатларын көтеп яши башладык. Әтиебез фашистларга пленга эләккән булган икән. Ә хәзер пленнан азат ителгән солдатлар немецлар җимергән завод-фабрикаларны аякка бастырырга тиешләр. Әти башкалар белән бергә Днепропетровск шәһәрендә зур заводны торгыза икән.

Хәзер әтидән хатлар даими килә. Гадәти буларак, хатның башы без укый торган хәрефләр белән язылган була. Ул өлешен без барыбыз да укыйбыз. Хатның икенче өлеше гарәп хәрефләре белән язылган. Ансын әни генә укый. Минем хатның бу өлешен дә укыйсым килә, һәм мин, “мине гарәпчә уку-язуга өйрәт” дип, әнине аптырата башладым. Бик күп тапкыр сораган-ялынганнан соң, минем үҗәтлегемне белгән әни миңа берничә хәреф язылышын күрсәтте. Ул бу язманың бик катлаулы булуын да аңлатты, бөтен хәрефләрне танып язарга өйрәнгәч тә аны укый алу өчен зур тәҗрибә кирәк булуын сөйләде. Гарәп алфавитында “әти”, “әни” кебек гади сүзләрне һәм исем-фамилиямне дә язарга өйрәтте дә, әтинең хатларын биреп, таныш сүзләрне табарга кушты. Мин, әлбәттә, таба алмадым. Әни, әтинең хатыннан минем исемемне һәм тагын бер-ике сүз табып күрсәтеп, гарәп алфавитында нечкә сузык авазларның булмавын, почеркларның төрле булуын һәм, гомумән, мин язарга өйрәнгәнче, әти кайтып җитәчәген аңлатты. Һәм өстәп куйды: “Әгәр кирәк тапсаң, үскәч үзең укырга да, язарга да өйрәнерсең!” (шулай килеп чыкты да).

Тагын 1-сентябрь җитте. Мин, бер класс “сикереп”, икенче класста укымыйча, Әминә апа Бәдертдинова укыта торган өченче класста укый башладым. Әминә апаны мин бик күптән ярата идем, шуңа күрә бу күчүгә нык сөендем. Класстагы барлык укучылар да миннән ике-өч яшькә олырак, алар 8 яшьтән укый башлаганнар. Мин элеккечә яхшы укыдым, авырлыклар сизмәдем. Әминә апа төрле сәбәпләр белән укуда артта калган балаларга биремнәрне еш кына миңа аңлатырга куша иде. Бу, мөгаен, кызык күренеш булгандыр: өстәл артында Әминә апа дәфтәр тикшерә, ә арттагы парталарның берсендә кечкенә кызчык үсмер малайга (я берьюлы берничә малайга) хисап я грамматика дәресләрен аңлата. Миңа бу эш ошый иде (сүз уңаеннан, шуны да әйтеп китим: мин дүрт яшемнән капитан булырга хыялландым, ләкин 1944 елда кызларны “капитанлыкка” укырга алмау турында указ чыкты. Әни миңа ул указны күрсәткәч, “алайса, мин синең кебек укытучы булам” дип, хыялымны үзгәрткән идем). Хәер, малайлар да каршы килмиләр. Гомумән алганда, безнең класс дус һәм тырыш. Малайларның артта калуы да ялкаулыктан түгел, дәрес хәзерләргә, мәктәпкә йөрергә мөмкинлекләре булмаудан килә иде. Ун-унике яшьлек малайлар өйләрендә инде җигелеп эшли – мал карый, утын кисә, эне-сеңелләренә

ярдәмгә килә... Укырга дәреслекләр, дәфтәр, каләм, кара кебек уку әсбаплары юк. Өскә-аякка киергә дә кием җитми. Бу безнең класс 1946/1947 уку елында төшкән фотографиядән дә ачык күренә.

Әти 1946 елның апрелендә кайтты. Кайтты дип әйтү дөреслеккә туры килеп бетми – аны өйгә әни белән Нажия апа җитәкләп алып керделәр, чөнки үзе йөри алмый иде. Плен газапларын үткән әтиебезнең организмы сугыштан соң да үз илебездә дәвам иткән пленга чыдый алмаган, күрәсең, – ул аяктан егылган. Аны, комиссовать итеп, өенә кайтарып җибәргәннәр. Әтине Можга станциясенә кадәр санитар озата килгән, ә аннан Нажия апа белән Ясәви абзый ат белән өйгә алып кайттылар. Менә әти өйдә; ул бик озын буйлы һәм бик ябык (1,80 м буе булган кешенең авырлыгы 50 кг да түгел иде). Аның өстендәге шиненең төсе дә икенче – куе соры төстә иде. Соңрак әти аларны американнар азат итеп, үзләренең киемнәрен дә өләшкәннәрен аңлатты. Безнең гаиләбез түгәрәкләнде (ишәйде дип тә буладыр): әти, әни, Бондюгтан әбине алып килделәр, Нажия апа, Рәмзия апа, Алиса һәм мин.

Әти берничә кич рәттән безгә үз өлешенә тигән газап-нужаларын сөйләде. Бу аңа җиңел бирелми, чөнки ул бар булган хәлләрне яңа баштан кичерә иде кебек. Кайчак ул, сөйләвен дәвам итә алмыйча, озакка туктап кала иде. Андый очракларда әтинең кичерешләрен бөтен нечкәлекләре белән тойган әниебез сүзне икенчегә, көндәлек тормышка бора, кайбер очракта: “Бүгенгә җитте, иртәгә дәвам итәрбез”, - дип, безне тарата, икенче эш куша. Барлык күргәннәрен сөйләп бетергәннән соң, әти минем сугыш хакындагы бетмәс-төкәнмәс сорауларыма катгый рәвештә чик куйды. Гомумән, безнең әти генә түгел, сугыштан кайткан башкалар да, бер сөйләгәннән соң сугышны тизрәк онытырга телиләр иде кебек. Аларның бу халәте 60-елларга кадәр дәвам иткәндер.

Әти сөйләгәннәрдән минем хәтергә уелып кереп калган фактларны бәян итәр алдыннан аның хәрби билетындагы язмаларны китермәкче булдым: “26.08.1941 призван по мобилизации Бондюжским РВК ТАССР. 26.08.1941 по 28.10.1941 – 85 стр.полк – стрелок. 28.10.1941 по 15.11.1941 – 3745 стр.полк – стрелок. 15.11.1941 по 15.05.1945 находился в плену в Германии лагерь 317. С 15.05.45. по 31 марта 1946 года – рабочий батальона при з-де им. Петровского Упр-я НКВД по Днепропетровской обл. УССР».

Шулай итеп, әти армиягә алынганнан соң ике ай чамасы алдагы бүлекләрнең берсендә искә алынган мари урманнарындагы Суслонгер лагерында булган. Суслонгер станциясе янындагы лагерьда сугышка китәргә тиешле солдатлар туплана торган җыю пункты ясалган. Әти сөйләвенчә, андагы шартлар немецларның пленныйлар өчен корылган лагерьларыннан да начаррак булган. Нәкъ менә шушы фронтка китәргә җыенган солдатларның коточкыч шартларда яшәве Суслонгер сүзен соңрак бик күпләргә танытты да инде. Яңа гына авыллардан җыелган халык зур палаткаларда һәм үзләре казыган землянкаларда яшәгән. Лагерьда бернинди дә тәртип булмаган, солдатларга кием, ашау җитмәгән. Сугышка хәзерлек урынына әтиләр утын әзерләргә, яшәү җирләрен рәткә китерергә тиеш булганнар. Сентябрьдә әти янына барып, җылы кием һәм азык-төлек илтеп кайткан әни әтинең бик нык

ябыгуы, кигән киеменең искерүе хакында сөйләгәне дә исемдә (мондый халәт безнең әти өчен бер дә хас нәрсә түгел иде – ул үз гомеренә матур, пөхтә киенергә яратты).

Составында әтиебез дә булган Суслонгерда оештырылган 3745 номерлы укчы полкы фронтка 1941 елның 28 октябрендә озатылган. Ноябрь башларында ул Мәскәүдән бары йөз чакрым тирәсе генә көнбатыштарак булган Көнбатыш фронты составына кушылган. Әтиләрне бер станциядә эшелоннан төшергәннәр. Төнге шактый зур марш-бросоктан соң алар, ниндидер буш җирдә туктап, чокыр-ерынтыларда урнашканнар (ноябрь башы – инде суыклар башланган, ерынтыларда, ичмасам, җилдән сакланып булган). Өстә әтиләр окоплар хәзерләгәннәр, ә чокырда землянклар рәтләгәннәр. Шулай ике-өч көн үткән. Бик тыныч булса да (хәтта ату тавышлары да ишетелмәгән), шомлы көннәр булган бу. “Командирлар бер нәрсә дә аңлатмый, үзләре вакыт-вакыт каядыр юкка чыгалар; бер иртәне уянсак, безнең янда бер командир да юк иде”, - дип сөйләде әти.

Төшкә кадәр көтеп тә, командирлары күренмәгәч, тәҗрибәле солдат һәм старшина-сержантлар (араларында төнлә генә килеп җиткән бер кече лейтенант кына булган), командирлары обстановканы ачыклап кайтуларына өметләнсәләр дә, үзләре тәртип урнаштырырга, коралларын барларга булганнар. Дошманга каршы торырлык коралның юклыгы ачыкланган. Әле юлда ук аларга ике кешегә бер мылтык, кеше саен бишәр патрон һәм биш кешегә бер граната өләшеп, калган коралны фронт кырында алачакларын аңлаткан булганнар. Командованиене кече лейтенант вакытлыча үз өстенә алган, старшина-сержантлар һәм элек Кызыл Армия хезмәтендә булганнар рота-взвод командирлары итеп билгеләнгәннәр. Хәвефле төн узып китмәгән булган әле, әтиләр танклар гөрелдәве, этләр өрүеннән уянып киткәннәр. Землянка-палаткалардан чыксалар, алар үзләрен ерынты ярлары буйлап тезелгән немецлар камап алганын күргәннәр. Аерым төркем булып, немец офицерлары белән бергә аларның юкка чыккан командирлары да булган. Нәкъ алар солдатларга коралларын ташларга кушканнар һәм үзләренең тирән немец тылында булуын, каршы торуның файдасы юклыгын, СССРның җиңелүен игълан иткәннәр...

Шулай 1941 елның 15 ноябрендә әтинең герман плены башланган. Аларны, колонналарга тезеп, көнбатышка таба куганнар. Суслонгердан ук бергә булырга тырышкан бер төркем татар качарга булган. Җаен китереп, 10-12 татар кача алган. Атна-ун көн чамасы алар Белоруссия урман-сазлыкларында адашып йөргәннәр, ләкин дошманнар этләр ярдәме белән аларның эзенә төшкән. Эзәрлекләүләрдән котылырга тырышкан вакытта берничә кеше һәлак булган, берничәсе яралганган (әтинең дә кулы яралганган). Кыйналган, этләрдән таланган җиде татар, ахыр чиктә, Оршадагы әсирләрне күчерү лагеренә китереп ташланганнар.

Шуннан соң яңа газаплар башланган. Орша лагере. Этаплап көнбатышка таба озату. Яңа лагерьлар. Җәзалар. Һәм тоташ, ияләшеп булмый торган ачлык. Кара көз һәм кыш айларында да ачык һавада яки көч-хәл белән әмәлләнгән землянка-баракларда урнашкан әсир солдатлар

бернинди медицина ярдәмен күрмичә төрле авырулардан, ачлыктан, суыктан йөзләп-меңләп кырылган. Әтинең ниндидер чүпрәк белән аннан-моннан бәйләп куйган яраланган кулы шешкән, хәтта ул, аңын югалтып, егылган. Аның иптәшләре әсирләр арасында булган табибне тиз генә эзләп тапканнар, чөнки хәлсезләнгән кешеләрне шунда ук ата торган булганнар. Ул чүпрәкне алып ташлаганда, әтинең кулында гангрена башлана язган икән. Табиб кичекмичә операция ясарга кирәклеген аңлаткан. Һәм, гади пәкене утта кыздырып, шешне ярган, яраны чистарткан, аның өстенә көл сибеп, әтинең күлмәгеннән ертып алган чүпрәк белән тагын бәйләп куйган. Соңрак, ниндидер дарулар табып, бу табиб әтине аякка бастырган, сул кулындагы бер-ике бармагы гына бөгелмәс булып калган иде.

Нибаять, Белоруссия, Польша, Германия лагерьларын узып, әти Австриянең Санкт-Иоганн шәһәрендә рәсми исеме Шталаг 317 “Маркт Понгау” булган лагерьга килеп җиткән. Маркт Понгау лагерьлар комплексы, әсирләр өчен махсус төзелеп, совет солдатларына аерым булган Төньяк лагерьдан һәм европалылар өчен оештырылган Көньяк лагерьдан торган. Совет әсирләре күбесенчә лагерьдан читтә булган эшләрдә кулланылганнар. Әти башкалар белән бергә таш ваткан, төзелешләргә гравий, ком, таш ташыган. 1943 елның язында берничә әсир белән бергә аны бер австрияле фермер арендага алган. Анда да җиңел булмаган, әлбәттә, чөнки аларны коллар урынына тотканнар. Шул ук иртәдән кичкә кадәрге авыр эш, шул ук ачлык... Аларны бигрәк тә билгесезлек борчыган. Сугыш бетмәгәнлеген белсәләр дә, фронт кая кадәр барып җиткәнлеген белмәгәннәр.

Һәм менә шушы хуторда әтине тетрәндергән бер вакыйга булган. Бер иртәдә, әтиләр дуңгыз ашатканда, өйдән хуҗа хатын чыгып, “Альта!” – дип кычкырган. Кызының исемен ишеткән әти, хәлдән таеп, басып торган җиренә шап итеп утырган. Бер мизгел эчендә аның башына нинди генә уйлар килмәгән: башта ул, немецлар Бәзәкәгә җиткәннәр дә, семьясы ничектер бу хуторга китерелгән дип уйлаган. Шунда ук моның мөмкин булмавы турында да уйлап өлгергән. Бу чакыруга бер кып-кызыл битле таза гына хатын-кыз килеп чыккач кына, хуҗаларның кызына адаш асравы булуын аңлаган. Аның нинди хәлдә калуына игътибар иткән иптәшләренә һәм асрау хатынга аның да Альта исемле кызы булуын аңлаткан. Шуннан соң бу асрау аларга юк-юк та, чөгендер, гәрәнкә кебек малларга ашата торган яшелчәләрдән өлеш чыгара башлаган, кайбер чакта хуҗалардан калган ризык та, дуңгызлар өчен пешерелгән азыклар да эләккәләгән. Әти миңа: “Синең исемең миңа исән калырга ярдәм итте”, - дигән иде.

Үземнең хатирәләремә сеңлем Әнисәнең истәлекләреннән өзекләр дә өстәргә булдым. Язганымча, әти, башка солдатлар кебек үк, егерме еллап сугыш вакыйгаларына кагылмады. Алар, тормышларының бу чорына нокта куйган шикелле, сугышта күргән газаплары, хәтта кылган батырлыклары турында да искә төшерергә яратмыйлар иде. 1965 елда сугышның тәмамлануының 20 еллык юбилееннан соң гына хәтер ишекләре ачыла башлады. Ләкин ул вакытта мин авылда юк идем инде. Ә әтиләр белән үскән Әнисә (ул урта мәктәпне дә авылда бетерде) әти сөйләгәннәрдән күп кенә

вакыйгаларны хәтеренә сеңдергән. Үзенең хатирәләрен ул “Әтиемнең ике сугышы” исеме белән “бизяки.рф” сайтына җибәрде. Шул язмалардан берничә өзек.

Австриягә әтиләрне терлек ташу өчен көйләнгән товар вагоннарына төяп җибәргәннәр. “Без, татарлар, бергәрәк булырга тырыша идек, бер-беребезгә ярдәм итәбез, бигрәк тә яралыларны сакларга тырышабыз. Ноябрь азагы, ярыклардан салкын җил өрә, яңгыр ява. Киемнәрне бүлешәбез, җылырак булсын өчен бер төркемгә укмашабыз... Вагонның икенче яртысында украин солдатлары. Алар арасында бер яшь кенә яралы лейтенант бар иде. Аңа ярдәм итү урынына юлдашлары аның плащ-палаткасын, итекләрен талап алдылар, хәтта гимнастеркасын да салдырырга теләгәннәр иде. Без аны яклый башладык. Алар: “Ул барыбер үлә, аңа кием нәрсәгә”, - дип көләләр. Бу егетне без үз яныбызга алдык – бик кызганыч иде. Австриягә кадәр ул безең белән булды. Соңыннан нәрсә булгандыр, белмим”, - дип сөйләде әти.

Маркт Понгау лагерен 1941 елда әзерләп бетергәннәр. 8 гектар җир биләгән Төньяк лагерендә һәрберсе 45-50 метр озынлыктагы 25-30 барак булган. Берьюлы анда 10000 кеше сыйган. Лагерьда әсирләрне ярым ач тотканнар, вакыт-вакыт йөзәр грамм дөге, шикәр комы һәм аз гына тәмәке биргәннәр. Тартмыйча түзә алмаганнар ризыкларын тәмәкегә алмаштыра торган булганнар. Шулай бик күп кеше ачлыктан үлгән. Әти һәрвакыт тартмаганга гына исән калуын әйтә иде. Таш чыгарырга йөргәндә, кемдер әкәм-төкәмнәрнең ашарга яраганлыгын сөйләгән. Әтиләр аларны куеннарына җыйганнар. Иртә белән ашарбыз дип, күлмәкләренә төреп киштәләрдә калдырганнар. Төнлә ниндидер шомлы тавыштан уянып киткәннәр. Ләкин караңгы, бернәрсә дә күренми, ә урыннан торырга ярамый, шуңа күрә иртән генә күргәннәр – барлык әкәм-төкәм таралышып беткән, шулай итеп, әтиләргә французлар яратып ашый торган ризык тәтемәгән. Эшкә барганда очраткан ташландык калдык-постыкларны, бәрәңге кабыгын әсирләр җыярга тотынуга сакчылар аларга ут ача, этләр өстертә, иң кимендә, кыйный торган булганнар.

Әти кемнәндер безнең якта исеме дә ишетелмәгән эдельвейс дип атала торган чәчәк үсүен, аны тапкан кешенең барлык теләкләре үтәләчәге хакында ишеткән. Кайда гына эшләтсәләр дә, ул шул чәчәкне эзләгән. Һәм морадына ирешкән: хуҗалары батракларын Альп тауларына печән әзерләргә җибәргәч, ташлар арасында шул чәчәккә юлыккан. Ул безгә: “Мин эдельвейс чәчәген таптым. Шуңа күрә өйгә исән кайтып җитә алдым”, - ди торган иде.

1944 елда бөтенләй хәлсезләнгән әтине лазаретка салганнар. Анда, бераз рәткә керә башлагач та, әти санитарларга ярдәм итә башлаган. Лазарет врачы, әтинең тырышлыгын, пөхтәлеген күреп, лазаретта эштә калдырган. Кайчак ул анда күргән коточкыч хәлләрне искә ала иде. “Лазаретның бер башында яралыларны һәм авыруларны кабул итәләр, икенче башыннан, мәет һәм әле җаннары чыкмаганнарны да, носилкаларга салып, чокырга чыгарып ташлыйлар. Чокырның бер каты тулгач, аңа юка гына итеп балчык сибәләр һәм икенче кат мәетләрне ташлыйлар. Чокырдан гел кеше тавышы,

ыңгырашуы ишетелеп тора. Бу мәхшәрне ишетү бик авыр иде. Кайчак әсирләрне машиналарга төяп алып китәләр. Аларны Маркт Понгау лагерыннан ерак булмаган Маутхаузен мичләрендә яндыруларын сөйлиләр иде. Иртә-кичен шул якта кара төтен күтәрелә, янган ит исе килә. Кеше күп нәрсәгә күнегә дип сөйлиләр, ләкин бу тәмугка күнегеп булмады”, - дип сөйләде әти.

Маркт Понгау лагерында яшерен Сопротивление оешмасы да булган. Әсирләр 1945 елның 7 маенда бу оешма җитәкчелегендә баш күтәргән. Лагерь белән идарә итүне оешма үз кулына алган. Зур баракта җыелыш җыйганнар, каяндыр табылган кызыл җәймә белән капланган өстәл артына президиум утырган. Җыелышны алып баручы әсирләрне җиңү белән котлаган, алга таба көткән эшләр белән таныштырган. Шунда ук кулга алынган бер төркем немец офицерларын һәм полицайларны алып килгәннәр. Халык самосуд ясарга теләсә дә, җитәкчелек аларны тыеп кала алган. Тоткыннарга җәза карарын чыгарып, аларны кайдадыр алып киткәннәр. 8 майда кич белән Маркт Понгауга американнарның парашютистлар полкы солдатлары килгән; әсирләр оешмасы лагерьны аларга тапшырган. Алар әсирләрнең ашавын рәткә салганнар, кием өләшкәннәр. 10 майда немец сакчыларын америка хәрбиләре алыштырган. Элеккеге әсирләр лагерьда да, читкә дә иркен чыгып йөри алганнар. Шулай Шталаг 317-дәге тоткыннар өчен сугыш беткән.

Әти пленнан биш фотосурәт алып кайтты. Лагерь азат ителгәч тә рус зираты исемен йөрткән җирдә әсирләр үз куллары белән һәлак булганнар мемориалын төзегәннәр. Фоторәсемнәр шул мемориалдан. Барлык рәсемнәр артында әти кулы белән язылган мәгълүмат бар. Бер һәйкәлдә “Монда 1941 елда немец фашистлары тарафыннан җәзаланып, ачлыктан һәлак булган 167 кызылармеец күмелгән, бер өлеше әле үлеп җитмәгән булган. Җәфаланучылар хатирәсе мәңге яшәсен!” дигән рус телендә язу да бар. Икенче рәсем артына әти язган: “ 1945 елның 7 июне - немец фашистлары тарафыннан җәзаланып ачлыктан үлгән 3500 кеше күмелгән туганнар кабере өстенә әсирләр көче белән эшләнгән һәйкәлне ачу. Бу көн мәңге истә алачак”. Рәсемдә һәйкәлләр тирәсенә җыелган меңләгән әсирлектән котылган солдатлар төшерелгән, араларында әти дә бар. Тагын бер рәсемдә азат ителгәннән соң вафат булган ике татар - Танаев Сәет һәм А.Шакиров кабере өстендәге һәйкәл сурәтләнгән; таш 1945 елның 26 маенда куелган. Тагын бер фотода әтинең дусты – кукмаралы Закиров Габдулла; ул 1945 елның 14 июнендә Австриядә борынгы Леобен шәһәрендә Америка солдатының хәрби киеменнән төшкән.

Әтинең пленнан алып кайткан калай жетоны да саклана. Әгәр дә әсирнең муенында бу жетон күренмәсә, аны шунда ук атканнар. Аның бер ягына Stalag 317 XVIII c 40521, икенче ягына T 147 дип чукып язылган, өч почмагында тишекләр бар. XVIII – барак номеры, 40521 – әтинең номеры, T 147 – барактагы урын номеры. Жетон икегә сындырылган, ләкин язылганны хәзер дә укып була.

Әтидән калган кәгазьләр арасында әсирлектән туган иленә кайту юлын бик җентекләп язып барган чирек дәфтәр бите бар. Ул язманы ничек бар, шулай китерәм: “306 лагеря выехали 4/VIII. Прибыли Рум. Сигет 14/VIII. От Сигета выб. 9/IX. Прибыли Львов 13/IX. От Львова прибыли Зем.Вода 15/IX-45 г. от Зем.Вода Радатыч прибыли 16/IX-45 г. Выбыли 21/ X-45 г.”. Бу язмаларның мөһимлеге эшелон маршрутын төгәл билгеләве белән генә бетми. Мәсәлән, Австриядән Украинага бер тәүлеккә дә сузылмаган юлны үтәр өчен әтиләр эшелонына ике ай ярым вакыт кирәк булган. Моны, һичшиксез, юллар җимереклеге, транспорт чаралары җитешмәве белән дә аңлатып буладыр. Шулай да... Чиктәш Сегед станциясендә элеккеге әсирләр айга якын тоткарланган. Моны аларның язмышын хәл итү өчен НКВД органнарына вакыт кирәк булгандыр дип фаразларга була. Радатычта тагын айдан артык булулары, минемчә, бу фикерне дәлилли генә. Туган илләрендә әсирләрне хезмәт лагерьларына таратканнар. Әти УССРның Днепропетровск өлкәсе буенча НКВД идарәсе Петровский ис. заводның хезмәт батальонына эләккән.

Әти кайтканда, язганымча, бик ябык һәм бик чирле иде. Гаилә архивында ул алып кайткан ике белешмә бар. Аның беренчесе икенче махсус больницаның баш врачына 1946 елның 19 мартында язылган юллама: “Металлургия җиһазлары заводы каршындагы 72-аерым хезмәт батальоны командованиесе ип. Мәхмүтов Хаҗи Мәхмүт улына аның авыруы һәм физик эшкә яраклы булмавы хакында белешмә бирүегезне сорый. 72-аерым хезмәт батальоны командиры лейтенант Холодко”. Икенчесе - Днепропетровск өлкәсе буенча НКВД идарәсе 1946 елның 31 мартында биргән белешмә: “Гр-н Мәхмүтов Хаҗи, 1900 елгы, чыннан да Петровский ис. заводның хезмәт батальонында иде. Бүгеннән, эшкә яраклы булмау сәбәпле, даими яшәү урынына җибәрелә - Татарстан АССР Бондюг районы Бәзәкә авылы.

У.Н.К.В.Д.ның Д/П Өлкә тикшерү-фильтрация комиссиясе рәисе майор Студенков”.

Әтидә көчле радикулит иде: аркасы сызлый, аяклары тотмый; аны аякка бастырыр өчен әни ниләр генә эшләмәде. Ел дәвамында (ә бәлки озаграктыр да) көн саен мунча ягу... Әни һәм Нажия апа, ике ягыннан тотып, әтине мунчага илтәләр иде. Анда аны чабалар, массаж ясыйлар, төрле үлән һәм кушымталардан ясалган ваннага яткыралар... Өч-дүрт сәгать шундый дәваланудан соң әти үз аягы белән өйгә кайта (әни аңа бераз гына ярдәм итә). Һәм бу көн саен кабатлана. Аны өйдә дә дәваладылар, район больницасында да бер айдан артык ятып кайтты. Әтинең 1946 елның 19 сентябреннән 21 октябренә кадәр стационар дәвалануда булуы һәм үзгәрешләрсез өенә җибәрелүе хакында да справка сакланган. Аңа бер елга 2-группа инвалидлык билгеләделәр. Әнинең һәм имче әбиләрнең дәвалаулары уңышлырак булды – әти акрынлап терелә башлады. Әтинең хәрби билетында “1947 елның 11 августында строевой булмаган хезмәткә яраклы дип табылды” дигән билге бар. 1947 елның 1 сентябреннән әти Бондюг райуполминзагының авыл хуҗалыгы азыкларын хәзерләү агенты булып эшли башлады. 1956 елның 1

мартыннан аны Бондюг РайФОсының участок инспекторы итеп күчерделәр. Бу эштә ул 1960 елның мартында пенсиягә чыкканчы эшләде.

1956 елда узган КПССның XX съездына кадәр, башка әсирлектә булганнар кебек, әти дә тынычлык күрмәде. Аларны НКВД тикшереп торды, алып та китәләр иде. Шуңа күрә, алай-болай кирәк була калса дип, ишек янындагы кадакка озак еллар әти өчен әзерләнгән котомка эленеп торды (анда вакыт-вакыт алмашынып тора торган сохари һәм запас күлмәк-ыштан салынган була иде). 1949-1951 елларда аны ике тапкыр төнлә белән район үзәгенә НКВДга допроска алып киттеләр. Икесендә дә әти безнең белән мәңгелеккә саубуллашып китте, ләкин ул, безнең бәхеткә, кире кайтты. Еллар буена төннәрен капка шакылдаганын көтеп яшәүгә олылар ничек түзгәннәрдер, күз алдына да китереп булмый. Әсирлектә булган еллар сугышта катнашу яки хезмәт стажы буларак саналмады. Әтине (башка әсирләр белән бергә) 1956 елдан соң гына акладылар. 1965 елда җиңүнең 20 еллык юбилеена аңа да юбилей медале бирелде. Шуннан соң гына әти үзен чыннан да акланган дип саный башлады. Ләкин 1980 елдагы вафатына кадәр ул төшендә әсирлек чорына кайта, ыңгыраша, кычкыра иде. Әни белән Әнисә аны уятып тынычландыралар иде.

Сугыш башында, 1941 елда ук, пленга эләккән әсирләр, бик зур фажигалар кичереп, өйләренә кайтып җитә алганнар. Алар арасында авылның иң абруйлы шәхесләреннән саналган минем әтием дә, бертуган Фәйзелхак һәм Габделхәй Гыйлфан Хөснетдинов уллары да булган. Нинди генә авырлыклар күрсәләр дә, алар исән һәм Кеше булып кала алганнар. Ул мәхшәрдә исән калу, әлбәттә, үзе зур бәхет. Ләкин исән кала алуның, бәхет кенә түгел, башка сәбәпләре булуын да күрсәтергә кирәк – монда бик көчле яшәргә омтылу да (әтинең эдельвейс чәчәген эзләве генә дә ни тора), какшамас рух та, тормышның иң кырыенда булып, үзеңә таяныч таба алу да: ачтан үлмәскә, тиф һәм башка йогышлы авырулар эләктермәскә, язмышыңны үз абруеңны төшермичә кабул итә белергә, дошман формасын кимәскә h.б., h.б. Чыныккан, барлык авырлыкларны да үз җилкәләрендә татыган, сынмаган шәхесләр... Аннан ирек һәм... дәүләт иминлеге органнары хезмәткәрләре белән очрашу. Аннан – күп елларга сузылган тыныч тормышка кайту һәм туган ягында абруй казану...

Балачагым авылы

Балачакта откан әкиятләрнең
Азагы бит әле бетмәде:
Сагындыра туган авылымның
Балачакта калган көртләре.

Рашат Низами

Минем беренче хатирәләрем өч-дүрт яшьлек вакытым белән бәйле. Нәкъ шул вакытта мин үзем һәм тирә-юньдәге кешеләр, вакыйгалар белән кызыксына башлаганмындыр, мөгаен. Әлбәттә, сабый баланың хәтеренә кереп калырлык вакыйгалар тормышның аерым бер мизгелләре генә була

ала. Шундый мизгелләрнең берсе – ул сеңелем Алисаның тууы. Миңа әле яңа гына өч яшь тулды. Моңа кадәр безнең гаиләдәге һәм тирә-юньдәге кешеләр - “дөнья”ның үзәгендә - мин үземне генә күрә идем. Ә хәзер барысының игътибары курчак кебек кечкенә кызчыкка күчте. Хәер, мин үзем дә аны яңа курчак кебек кабул иттем бугай: көтмәгәндә, олы курчак җанланды, тавыш бирә, селкенә башлады. Ләкин әни миңа бу “курчак” белән хәзергә уйнарга ярамаганлыкны, аның әлегә бик кечкенә бала булуын, ул минем кебек үскәч, аның белән бергә уйнарга да кызык булачагын аңлатты. Ә хәзергә мин, аның зур апасы буларак, аңа ярдәм итәргә, аны сакларга тиеш икәнмен. Шулай мин олылар арасына кереп киттем.

Шул ук вакытта мин безнең авылның бик зур икәнен дә аңлый башладым кебек. Сеңлем тугач, мине балалар бакчасына бирделәр. Ул түбән очта, безнең өйдән ерак урнашкан иде (якынча, бер чакрым ара булгандыр). Анда барганда мин бик ара идем. Мине бакчага озатучылар, аруымны әйтсәм, күпмедер күтәреп алып бара торган иде. Әти хакындагы беренче хатирәләрем дә шул бакчага бару белән бәйле. Ул, эшкә барганда, мине дә үзе белән алып, балалар бакчасына илтеп куярга булган. Ләкин бер-ике тыкрык арасын үтүгә мин көйсезләнә, кулга күтәрүне сорый башладым. Әти мине почмактагы зур ташка бастырып, минем кебек үскән кызларга киреләнү ярамаганны аңлатты да, без юлыбызны дәвам иттек (минем балачагымда әтиләр урам буйлап кызларын күтәреп йөрмиләр иде шул). Детсад белән бәйле тагын бер хатирә: аның бинасы ике катлы, икенче катка текә баскычтан менәсе иде. Мин шул баскычтан егылып, күлмәк якасындагы сәдәп белән иягемне бик нык канаттым; шул яра эзе бу бина хакында гомерлек истәлек булып калды. 1941 ел башында ул бинада янгын чыгып, безне буш тора торган югары оч мәчете бинасына күчерделәр. Шулай минем юлым кыскарды, чөнки яңа бакчабыз безнең өй турысында ук Олы урамда иде. Бу беренче истәлекләргә мин инде алдарак сөйләгән сугыш еллары хатирәләрен дә кушарга кирәк.

Балачагымның мәктәпкә кадәрге чорында мин, авылыбызның бик зур булуын аңласам да, авыл белән бик аз гына таныш идем, чөнки без олылардан башка өйләребездән ерак китәргә базмый идек. Уйнаганда да үз урамыбыз (анда да ике-өч тыкрык арасы белән чикләнеп) һәм инеш буеннан ерак китми идек. Мәктәптә укый башлагач кына мин авыл белән ныклап таныша башладым. Беренчедән, без укуларны түбән мәчет бинасында башлап җибәрдек - дәрескә барып җитү өчен ярты авылны узарга кирәк иде. Икенчедән, классташ кызлар авылның төрле очларында яшиләр – мәктәптән бушагач, я мин аларның берәрсенә керәм, я аларны үземә ияртеп алып кайтам. Мин үсә төшкән саен авылыбыз турындагы белгәннәрем дә арта барды. Шулай йөри торгач, мин авылыбызның барлык урам-тыкрыкларын таный башладым. Шуңа күрә, “балачак авылым” дигәндә, минем күз алдыма 1944-1951 елгы Бәзәкә килә.

Нәкъ шул еллардагы авылымны (һәм үзебезнең яшәешне дә) бу бүлектә тасвирлап бирергә булдым. Безнең авыл төньяктан көньякка ага торган тар һәм аз сулы инеш буйлап урнашкан. Авыл якынча ике чакрымга сузылган өч

урам һәм бик күп тыкырыклардан тора. Уртадагы урам төп урам булып санала, аны без Олы урам дип йөртә идек. Ул шактый туры (безнең өйдән бакчага барганда тыкырык башында Олы урам чатына басып карасаң, ул ике якка да үтәләй күренә) һәм урамнарның иң озыны иде. Бу урамда йортлар олы юл – тракт буйлап салынган, андагы биналарга барлык җәмәгать оешмалары урнашкан – авыл советы, почта, ике колхоз идарәсе, уку йорты һәм китапханә, ике кибет, фельдшер пункты. Ике мәчет бинасы да шул ук урамда салынган булган: беренчесе авыл уртасында, авыл аша уза торган тракт уңга борылган җирнең сул ягында; икенчесе – беренче мәчеттән бер чакрым түбәнрәк, авыл урнашкан калкулык беткән җирдә. Минем балачакта беренчесендә балалар бакчасы, икенчесендә берничә башлангыч класс урнашкан иде.

Олы юл белән авылга кергәндә үк ике якка да Арт урам сузылган. Ул Олы урамнан таррак та, кыеграк та иде. Озак вакыт мин аның нигә Арт урам дип йөртелүен аңламыйча аптырадым. Бала фикере буенча бу исем белән өченче, безнең урам аталырга тиеш, ә бу урамга Алгы урам исеме туры килә, чөнки ул, район үзәгеннән килгәндә, беренче иде. Ләкин өченче урам Кече урам дип атала. Бу урам аскы өлешендә инеш үзәненең барлык борылышларын кабатлый, уртадан, инештән аерылып, төньякка таба турыга китә иде. Бик кызыксынучан, үҗәт бала буларак, мин башымда туган сорауга җавап тапканчы олыларны аптырата идем. Бу юлы да миңа, нинәять, кемдер Арт урамның исеме елгага карата килеп чыкканын һәм аның башкалардан соңрак барлыкка килгәнлеген аңлатты.

Авыл урамнары басу капкалары белән тәмамлана иде. Олы юлдан авылга басу капкасы (аны “зират капкасы” дип тә атыйлар) алып керә. Урамның ике ягына ике юан багана казып бастырып куелган. Аның берсенә “капка” – юан колгалардан аркылыга ясалган дүрт почмаклы рәшәткә - ныгытылган. Олы урамның төньяк очындагы һәм олы юлның икенче башындагы капкалар, әгәр ялгышмасам, шулай ук дүрт почмаклы итеп ясалган читән капка булган. Көндез күп очракта басу капкасы ачык тора, кич белән ул ябыла һәм юан бау-аркан белән икенче баганага беркетелә. Калган ике урам авылны басу-кырлардан аерып торган читән белән тәмамланган. Караңгы төшкәч, авылны хәвеф-хәтәрдан сакларга каравылчылар чыга, алар, кулларындагы пар тукмакларын шакылдатып, урамнардан төнгә ике-өч тапкыр узалар иде.

Авылның түбән очында Олы юл, сулга борылып, салмак кына таудан төшә һәм инеш, аркылы салынган күпердән чыгып, каршы яктагы тауга менә. Анда да юлның ике ягында йортлар салынган. Авылның ул өлеше Тау башы дип атала. Тау асты дип йөртелә торган ярым урам да бар. Анда йортлар урамның бер ягында гына урнашкан (Авылның бу өлеше дә шактый зур булган – 1937-1939 елгы хуҗалык кенәгәләрендә Тау башында да, Тау астында да 37-шәр хуҗалык язылган – А.М.). Тагын бер аркылы урам Чишмә башы дип йөртелә. Кече урамнан башланып, ул Олы чишмәгә илтә. Эчә торган суны бөтен халык, ерак булса да, шушы чишмәдән алып кайта. Чишмәдән суны күбрәк кызлар ташый (8-10 яшьтән алып); олы кызлар өчен

ул өйдән чыгып китәргә сәбәп тә, дус кызлары белән күрешү-серләшү урыны да иде.

Барлык урамнар да тыкрыклар белән кварталларга бүленгән. Алар урамнардан таррак булсалар да, йөкле ат узарлык иде. Һәрбер тыкрыкта диярлек бер-ике йорт та урнашкан. Тыкрыклар шул йортларның хуҗаларының исеме яки кушаматы белән йөртелә, шулай ук җәмгыять биналары исемен дә йөртә ала иде (Госман тыкрыгы, Чәрләй тыкрыгы, Мәчет тыкрыгы h.б.). Урамнардан аерым йортларга илтә торган тыкрыклар да бар. Мәсәлән, алар авылның Тау башы һәм Чишмә башы өлешләрендә күп иде. Безнең өйгә дә шундый тыкрыктан керә идек. Минем балачагымда җәен урамнар ямь-яшел чирәм белән каплана; без бу хәтфә паласларда ауный-ауный уйнап үстек.

Авылда барлык өйләр дә бер катлы итеп агачтан салынган. Бары тик Олы урамда асты таш, өсте агач ике катлы ике-өч йорт бар. Йортлар ике төрле: алты почмаклы өй - уртак стеналары белән бергә тоташкан ике бурадан торган йорт һәм дүрт почмаклы өй - бер бурадан гыйбарәт йорт. Өйалды беренче очракта я арткы өйгә алып керә, я ике бура арасында да була; икенче очракта ул өйнең дәвамы була. Өйалдына кушып, бер я ике чолан салынган була. Өйләрнең эчке, яши торган өлеше, гадәттә, аерым бүлмәләргә бүленмәгән була, ләкин аның аерым өлешләре чаршау белән бүленеп алынган була, кирәк чагында чаршау ябыла. Алты почмаклы өйнең алгы, урамга чыга торган ягы – ак өй – кунаклар кабул итә һәм хуҗалар йоклый торган урын булып санала. Көндәлек тормышның күп өлеше арткы якта уза иде.

Йортның шактый зур өлешен мич (алты почмаклы йортларда ике мич була) алып тора. Гадәти буларак, ул ишек каршына яны белән, стенадан бераз чигенеп салынган. Стена белән мич аралыгы, күрәсең, янгыннан саклану һәм мичнең җылысы өйгә күбрәк таралсын өчен ясалгандыр. Алгы өлеше (авызы) белән мич арткы тәрәзәләргә караган, аның стена ягында кечкенә учак өчен урын бар. Учакның өстенә ашау пешерер, су җылытыр өчен чуен (казан) сылап ябыштырылган; икенче ягында гөлбәч дип аталган уем ясалган. Гадәттә анда керосин лампасы, комган кебек әйберләр тора. Стена ягында мич башы бар, анда кыш көннәрендә урамнан туңып кергән балалар җылынырга ярата, савыт-саба, йорт кирәк-яраклары саклана.. Гомумән алганда, мичнең функцияләре бик күп – өйне җылыту, ипи һәм төрле бәлеш-бөккәннәр, гомумән, ашау пешерү, азык-төлек, кием-салым (бигрәк тә, балаларның итекләрен) киптерү h.б. Мич алды өлеше кухня ролен үти, гадәттә, ул чаршау белән бүленгән була. Кыш көннәрендә анда яңа туган мал өчен дә бүлентек ясала.

Йортның алгы зур өлешен сәке биләгән була. Сәке тәрәзә буйлап, якынча, ике метр озынлыгында, өйнең бар киңлегенә ясалган. Ул бар нәрсәне – урындык, карават, диван, хәтта өстәлне дә алмаштырган. Көндезләрен сәкенең бер почмагына урын-җир әйберләре җыелып куелган. Калган өлешендә балалар уйнаган, әбиләр намазларын укый. Шунда ук сәке уртасына ашъяулык җәелә, һәм аның тирәсенә утырып ашыйлар. Төнгә сәке

зур ятакка әйләнгән. Өйләрдә әле сәндерә дә булган. Гадәттә ул мич артындагы аралыкта түшәмгә 0,5-0,7 м биеклек кала ясалган. Сәндерәдә өй кирәк-яраклары, савыт-саба сакланган, кайчак бала-чага йоклаган.

Һәрбер йортта диярлек төрле зурлыктагы ак калай белән бизәлгән бер-ике сандык булган. Сандык өсләренә мендәр-юрганнар да өеп куела, балаларга йоклау урыны да була иде. Сандыкларда кием-салым, сөлгеләр һәм башка затлы әйберләр сакланган, кызлар үсеп җиткәндә, махсус сандыкларга алар үз куллары белән хәзерләгән бирнә җыя торган булганнар. Ә әбиләрнең сандыгында... Бәйрәм киемнәре, шәлъяулык, сөлге һәм үлемтеккә хәзерләгән әйберләрдән башка нәрсә генә булмый иде бу серле сандыкларда! Кечкенә, уч төбенә генә сыярлык төенчекләрдә без, балаларны бик тә кызыксындыра торган тәм-томнар – кипкән җиләк, җимеш, йөзем, чикләвек, тәмләткечләр, кәнфит-прәннек, клиндер дисеңме, хәтта бавырсакка кадәр була иде. Ә бу сандыктан аңкый торган нафталин белән кушылган тәм-том исе безнең бөтен гомеребезгә саклангандыр... Бу онытылмас искә карамастан, без, сугыш чоры сабыйлары, бәлки безгә дә берәр кәнфит яки җимеш эләгер дип, әбиләрнең серле сандыклары ачылганын дүрт күз белән көтеп ала идек.

Онытылмас күренеш: җәйге көн уртасы... Зурлар эштә, өйдә Алиса белән мин һәм әби генә. Менә әби, намазын укып бетереп, сандыгы янына килә. Ул хәзер аны ачачак (тыныч вакытларда, намаздан соң, әби аннан китап алып укый). Без, тын да алмыйча, карап торабыз. Әби озак кына кесәсендәге ачкычын эзли (аның өстендә берничә кат күлмәк, шуларның барысының да кесәсен капшап чыгарга кирәк). Ниһаять, ачкыч табыла, сандык ачыла, өйгә сөйләп бетерә алмаслык үзенчәлекле сандык исе күтәрелә. Мин урынымнан кымшанмыйм (ярамый), ә Алиса инде әби янында. Әби, догасын укуын дәвам итеп, төенчекләрен актара. Безнең Алиса – ябык кына, кечкенә генә, бөдрә чәчле 4-5 яшьлек кызчык (миңа әби аны фәрештәгә ошатырга тиеш кебек тоела иде). Аның түземе җитми, сорап куя: “Әби, ә бу нәрсә?”... Кайчак әби, коры гына булса да, җавап бирмичә калдыра алмый, төенчекләрнең берсеннән Алисаның учына нәрсәдер салып: “Бар кит, йөрмәгез монда”, - ди. Без үз почмагыбызга посабыз, я урамга чыгабыз. Алисаның учында өч-дүрт бөртек кипкән карлыган я шомырт була, без аны бүлешеп, бик озак суырабыз...

Безнең йортыбыз Кече урамнан инешкә таба кергән тыкрыкта урнашкан иде. Бу тыкрыкны авылның нәкъ уртасында – аны Олы юлның борылышыннан башланган Госман тыкрыгының дәвамы дип әйтеп була. Анда ике өй бар; урамнан кергән беренче кечкенә йортта өч баласы белән Камиләттәй тора иде. 1942 елның язында, кыш чыккан эскерт төпләреннән җыйган ашлыктан агуланып, Камиләттәй һәм ике баласы вафат булды, ә исән калган малаен балалар йортына озаттылар. 1943 елда бу йортка Бәхтегәрәевлар - Исмәгыйль абый, Хәмдиттәй һәм балалары Зәки абый белән Зафира апа күчеп килделәр. Ут күршеләребез турында мин алдарак берничә җирдә язган идем инде.

Тыкрык безнең капка белән тәмамлана. Ике хуҗалык арасыннан инешкә төшә торган сукмак бар. Зур, авыр капка артында безнең хуҗалык (аны утар

дип билгеләү дөресрәк булыр): чирәм белән каплангаи иркен ишегалды, капка каршысында зур алты почмаклы йорт, аның ике ягында да алмагач, карлыган, кура җиләге үсә торган бакча, төрле каралты-кура. Капканың уң ягында тимер ишекле таш келәт, аңа киң капкалы лапас тоташкан, алар өстендә такта түбә астында печәнлек бар; аннан аерым-аерым тора торган кар базы һәм мунча. Мунча янындагы кечкенә арткапкадан бәрәңге бакчасына һәм инешкә төшә торган сукмак. Арткапкадан чыккач та, табигать күренешләре белән хозурланасың. Таудан төшкәч тә, безнең бәрәңге бакчасы, аның кырыеннан ук ярлары таллыклы инеш ага. Безнең турда ук киң генә инеш үзәне җәелгән, анда кешеләрнең бәрәңге бакчалары. Каршы якта яссы-ялпак таулар, дөресрәге, калкулыклар чылбыры. Җәйләрен ямь-яшел хәтфә келәмнәр, кышларын күз камашырлык ап-ак җәймәләр белән каплана алар. Шуларның иң текәсендә мәктәп урнашкан...

Утарның көнчыгышында бер салам түбә астында хуҗалык корылмалары төзелгән – утынлык, ишегалды ягыннан ачык лапас һәм маллар өчен бүрәнәдән салынган ике җылы абзар. Олы капканың сул ягыннан безнең утарны урам буйлап салынган хуҗалыклардан тоташ койма аерып тора. Утарның төньяк өлешен йорт һәм бакчалар биләгән. Безнең өебез башка өйләрнең күпчелегеннән үзенең аерым урнашканлыгы белән генә түгел, эчке күренеше белән дә аерыла. Анда авылга хас булган сәке-сәндерәләр юк, аларны өстәл-урындыклар, карават-шкафлар алмаштырган. Гомумән алганда, безнең өйдә тормыш-көнкүреш “шәһәрчәрәк”, авылдашлар әйтмешли, “укытучыларча” корылган. Бездә пластинкалары белән патефон, аяклы тегү машинасы, велосипед бар, сугышка кадәр радиоалгыч та булган. Әниебез, кул эшләренә бик оста булгач, киемнәребезне дә шәһәрчә итеп тегә иде. Безнең сөйләм телебезгә дә әни игътибар итә, дөрес әдәби телдә сөйләшергә өйрәтә. Киемнәр һәм сөйләмебез үзгәрәк булса да, бүтән яктан без башка балалардан аерылмый идек.

Күршеләр турында. Безнең тыкрыктан чыкканда уң якта Ясәви абзыйлар яши, аларның өч малае бар – үсмер Нургали абый, миннән өч-дүрт яшькә олырак Сәетгали һәм Тимергали. Сул яктан Гайшә әбиләр йорты. Гайшә әби сугышка дүрт баласын да озаткан – Галиәхмәт, Хуҗахмәт, Минәхмәт абыйларны һәм Нәгыймә апаны. Алар Мәчтүрәттәй һәм Вафира апа белән өч буын хатын-кыз яшиләр. Аларга каршы якта Рәхиматтәй берүзе яши (энесе сугышта, балалар юк). Рәхиматтәйнең бакча почмагында җәйләрен безне бик кызыктыра торган зур шомырт агачы үсә, кайчак малайлар аны селкетеп шомыртын коялар (ә без аны җирдән җыеп ашыйбыз – авызлар камаша, иреннәр зәп-зәңгәр була...).

Аның белән рәттән дүрт баласы – Хәдичә апа, Фәйрүзә, Фәния, Шәрипҗан белән Гайшәттәй Кәримова яши. Кечкенә генә гәүдәле, ябык кына бу хатынның, ире Галиәхмәтне сугышка озатканда, олы кызы Хәдичә апа гына кул астына керә башлаган булгандыр. Фәйрүзә миннән, Фәния Алисадан берәр яшькә олырак иделәр. Улы Шәрипҗан исә әтисе сугышка киткәч дөньяга килгән. Гайшәттәй ирен күрү бәхетенә ирешә алмады – Галиәхмәт абзыйның Сталинград сугышында 1942-43 елларда һәлак булуы

хакында хәбәр килде. Шундый зур кайгыга карамастан, Гайшәттәй элеккечә кайгыртучан, гадел, шат күңелле булып калды, һәрвакыт сугыш чоры балаларының күңелен күтәрергә нәрсә булса да уйлап таба иде. Үз балаларына нәрсә ашатырга белмәгән иң авыр көннәрдә дә ул безне дә кайгыртырга өлгерә иде, балаларына нәрсә бирсә (бәрәңге кәлҗемәсеме ул, юа боткасымы, балтырган ашымы), шуны безгә дә бирергә тырыша иде. Дистәләгән башка күршеләрем-авылдашларымның исемнәре дә бүгенгедәй минем хәтеремдә саклана. Алар да иртәдән кичкә кадәр колхозда да, өйләрендә дә башларын күтәрми эшлиләр иде. Беренче карашка кырыс күренсәләр дә, алар үз балаларына гына түгел, безгә дә бетмәс-төкәнмәс эш арасында күз-колак булырга вакыт табалар иде.

Күрше йортларда балалар күп (гомумән, һәрбер йортта, иң кимендә, 2-3 бала үсә торган чор бу). Сугыш еллары һәм сугыштан соңгы ачлык-ялангачлыкка карамастан, без күп вакытыбызны урамда уйнап уздырабыз. Нинди генә уеннар юк иде безнең – җәй көннәрендә качышлы, куышлы, “чирталы” (классики), “саңгырау телефон”, кыш көне аларны тау шуу апмаштыра... Бу уеннарны уйнаганда, кайчак безгә малайлар да кушыла, ә гомумән алганда, малайлар үз уеннарын уйный, ә без, кызлар, үз уеннарыбызны уйныйбыз. Без, әлбәттә, җәй көннәрендә үзебезне бик рәхәт хис итәбез. Җәен урам һәм ишегалларын яшел чирәм каплый, урам уртасыннан гына арба эзе күренә. Гадәттә, без яланаяк, киемебез дә бик җиңел - күлмәк-ыштан гына. Җәй уртасына аяк-кулларыбыз чебиләнеп бетә иде. Мәктәптә укый башлаганчы, без үз тирәбездәге 5-10 кыз җыелып уйный идек. Аннан соң уеннар да кимеде, без дә үзгәрдек, дусларыбыз да артты.

Биш-алты гына яшьтә булсак та, безнең башкарырга тиешле бурычларыбыз да бар – ул хуҗалыктагы кош-кортларны карау (аларны ашатырга, каз-үрдәкләрне инешкә алып төшәргә-алып кайтырга кирәк), тау буена әни-апалар бәйләп киткән бозауларга су алып барып эчерү, көтү кайтканда малларны барлау h.б. Ләкин безгә йөкләнгән иң зур бурыч – ул эне-сеңелләрне карау. Безнең белән (барыбызның да диярлек) сеңелләребез дә йөри – минем белән Алиса, Фәйрүзәнең Фәниядән башка әле энесе Шәрифҗан да бар, Хәлимә һәм Сәлимә, Сажидә һәм Сания. Әлбәттә, безнең әни-апалар ясап биргән курчакларыбыз да бар. Тормышта нәрсә күрсәк, шуны да уен итеп уйныйбыз – кем әни, кем әби, кечкенәләрнең барысы да бәби була. Әтиләр сугышта, ә инде уен планы буенча әти я бабай кирәк булса, малайларны чакырабыз. Безгә уенчыклар да кирәкми – иске чабата чана я арбага әйләнә, савыт-саба ватыклары (керәч), әрекмән яфрагы затлы савыт була h.б. Ашавы да табыла –песи борчагы, кукы, кәҗә сакалы h.б. үләннәр (әни-апалар алып кайткан юа, кузгалак та ярап куя). Без һәрвакыт диярлек ач булсак та, ашау турында сөйләшмәскә тырышабыз – искә төшерсәң, ныграк ашыйсы килә...

Әтиләр сугышта, әниләр эштә, безнең арттан әбиләр күзәтә. Гомумән алганда, Бәзәкә халкы кырыс, балаларга артык иркәләү эләкми, ягымлы сүзләрне дә бик сирәк ишетә идек. Ләкин өлкәннәр балаларга карата гадел, игътибарлы: безне кирәкмәгәнгә ачуланмыйлар да. Урамда үссәк тә, “безнең

тәрбиячебез булмады” дип әйтеп булмый – без, балалар, авыл халкының күмәк тәрбиясендә идек. Авыл өчен “урам тәрбиясе” – уңай күренеш. Өлкәннәр безне сүз белән түгел, эш белән тәрбияли. Безнең иң зур тәрбиячебез – хезмәт; һәркемнең үз вазыйфалары бар, аларны яхшы һәм вакытында башкарырга кирәк. Болай эшләгәндә, безгә беркем дә начар сүз әйтми; шулай без кечкенәдән “яхшы-начар” төшенчәсен белеп үстек.

Менә бер күренеш. Җәй көнендә безгә Шәмсекамал әби кунакка килә. Аның белән күрешергә дип, көндез аның туганнары җыела – Чишмә башыннан Көдрә әби, Тау башыннан Сәрби әби, күршедән Гайшә әби керә (өйдә бер кем дә юк, әби безне дә өйдән озатырга тырыша; мин, ничек булса да, өстәл астына качып калырга тырышам). Алар хәл-әхвәл белешәләр, намаз укыйлар, чөкердәшеп чәй эчәләр. Минем өчен иң кызык вакыт җитә – мөнәҗәт-бәетләр әйтү башлана. Мин аларны йотлыгып тыңлыйм, кунакларны озаткач, әбигә ялына башлыйм: “Әби, теге “Сак-Сок” бәетен тагын җырла әле...”. Әби: “Ах, явыз, тагын качып калдыңмы?! Мин җырламыйм. Җырлау гөнаһ. Бәетне җырламыйлар, әйтәләр”. Мин: “Ярар инде, әби, шул бәетне әйт инде, менә шунысын гына кабатла инде...”. Әби: “Юк. Бар, югал күземнән, ана, Алиса нинди акыллы бала, бар әйткәнне үти, ә син, киребеткән, гел үзеңчә эшлисең...”. Шуннан соң инде мин Гайшә әби янына китәм...

Үз әбиебезнең безгә карата җылылыгы җитмәгәч, без аны күрше Гайшә әбидән эзли идек. Гайшә әбинең үз оныклары булмагангамы, миңа калса, ул безнең белән бик теләп аралаша иде. Кайчак ул безгә әкият-риваятьләр сөйли, бәет-мөнәҗәтләр көйли. Бу хәлләр еш булмый. Менә Гайшә әби, өйдәге эшләрен бетереп, капка төбенә ял итәргә чыгып утыра. Без шуны гына көтәбез: аның тирәсенә җыелабыз, безгә берәр нәрсә сөйләү-көйләвен сорыйбыз. Мин, бигрәк тә, аның мөнәҗәт-бәет әйтүләрен ярата идем – “Сак-Сок бәете”, “Алабуга бәете”, “Әхмәдиша бәете”, “Таһир-Зөһрә”, “Бәдәвам” һәм башкаларны Гайшә әби нечкә генә тавыш белән безгә көйли, аннан соң аларның эчтәлеген дә аңлата, безне “тәрбияли” иде.

Бу урында мин кечкенә чагымда Гайшә әбидән отып калган бик озын “Әхмәдиша бәете”ннән бер өзек китерәм.

Әхмәдиша бәете.

Базардан алган атымны кулым туя җикмәдем,
Елашмагыз, туганнарым, урлап Себер китмәдем.
Быел чәчкән богъдаемны кибән итеп кем куйган?
Беребез - солдат, беребез – Себер, безнең кебек кем булган?!
Бәнем исмем сорасагыз – Бәзәкәдән Әхмәдиша,
Биздапруса Себер киттек, белә микән падиша?
Әхмәдиша Себер китте Алабуга каладан,
Дин хәсрәтен күрер өчен туган икән анадан.
Без өйләрдән чыкканда өстәл тулы аш калды,
Шәмсениса, балаларның күзе тулы яшь калды.

Бәет шулай дәвам итә, Әхмәдиша һәм аның энесе Дәүләтшаның күргәннәрен, аларның авылда калган балаларының авыр язмышын

тасвирлый. Бик кызганыч җирләрдә без борыннарыбызны тарта башлыйбыз... Гайшә әби бәетне үз әбисеннән ишеткәнлеген, ә бәеттәге хәлләрнең безнең авылда булуын әйтә иде. Мин, әлбәттә, гадәттәгечә, “биздапруса”ның нәрсә икәнен белергә тырышып карадым, ләкин Гайшә әби аңлата алмады, ә әни миңа, “бәйләнмә әле” дип, кулын гына селтәде. Мине кызыксындыра торган башка нәрсәләр дә дөньяда җитәрлек иде, шуңа күрә бәет үзе дә, аңлашылмаган җире дә хәтеремнең бер почмагына кереп качты. Менә хәзер, хәтеремне яңартканда, мин бу бәетне (дөресерәге аңа охшашны) фольклорчы галим Марсель Бакиров китабында очраттым. Марсель әфәнде бәетне Тәтеш төбәгендә язып алган; аның исеме дә үзгә – “Мөхәмәтша бәете”, башка исемнәр дә икенче төрле, ләкин эчтәлеге бертөрлерәк булып чыкты. Мине аптырашта калдырган “биздапруса” да, дөрес язылгач, гап-гади “без допроса” икән ич! Шулай итеп, безнең “надан” әбиләребез (алар безнеңчә укый белмәсәләр дә, үз китап-дәфтәрләрен бик яхшы укыйлар иде) безне бай татар әдәбияты белән кечкенәдән таныштырып, бездә яхшы сыйфатлар – гаделлек, игелек, бер-береңә ярдәм итү, дуслыкка омтылыш тәрбияләгәннәр икән.

Әби-апалардан без төрле санамыш, табышмак, сынамыш, такмак-такмазалар да өйрәнә идек. Мәсәлән, мине чуан чыгып аптыратуы хакында язган идем. Ә Бәнат апа, минем чуаннарымны эшкәрткәндә: “Чуан, бет, бет, багана башы, шешеп кит”, - дип берничә тапкыр кабатлый иде. Мин бу сүзләргә чыннан да ышанып, аларны үзем дә кабатлый башладым, хәтта буем җиткән арткапка баганасын берничә тапкыр, шешмәде микән дип, тотып-тотып та карадым. Әллә шуңа бик ышанганга, әллә вакыты җиткәнгә, 1942 елның көзенә мин чуаннардан котылдым. Без кулланган бик күп санамышлар арасыннан мин Шоңкар абзыйдан өйрәнгәнне монда да китерергә булдым:

“Әби, кая барасың?
Минзәләгә барамын.
Минзәләдә ниең бар?
Оча торган кошым бар.
Очты, китте дәрьяга,
Дәрья буе калага.
Дәрья суы чистадыр,
Балыклары астадыр.
Кәнәпикә, кәпикә,
Татарески пулк.
Агырчык, багырчык,
Бар син, йөгереп чык”.

Мин үзем 4,5-5 яшьләр тирәсендә әни Казанда алып биргән хәрефле шакмаклар буенча укырга өйрәндем. Башта өйдә булган китапларны укыдым (дөрес алар күп түгел иде, әни, гадәттә, укыган китапларны китапханәгә илтеп бирә иде), аннан миңа да әни һәм Нәҗия апа (ул мәктәп китапханәсендә эшли) китапханәдән китаплар алып кайта башладылар. Авылдагы китапханәне без “избач” дип әйтә идек (“изба-читальня”нең кыскартылган варианты). Ул Олы урамда, бездән ерак түгел урнашкан. Минем, зурлар кебек, китапханәдән китапларны үзем барып аласым килә,

ләкин мине анда мәктәптә укый башлагач кына язачакларын аңлаттылар. Нинди китаплар укыдым соң мин ул вакытта? Әлбәттә, иң беренче чиратта, әкиятләр һәм шигырьләрне әйтергә кирәк. Мин аларны бик тиз укып чыгам. Ә шигырьләр, бер укуда диярлек, истә дә кала. Габдулла Тукайның балалар өчен язылган шигырьләрен, “Шүрәле”сен, Һади Такташның “Мокамай” һәм тагын күп кенә шигырьләрен яттан беләм. Һади Такташның “Җир уллары” поэмасы бик нык тетрәндергәнен хәтерлим. Укыган китаплар арасында сугыш турында кечкенә генә китапчыклар да бар иде. Бу юка гына китапчыкларда безнең солдатларның батырлыгы, партизаннарның каһарманлыгы, фашистларның ерткычлыклары хакында язылган була...

Үзем укыганнарны мин башкаларга сөйләргә яратам. Бу, әлбәттә, минем яшьтәш дус кызларым. Уйнап аргач, без берәр капка төбендәге бүрәнә я скамьягә барып утырабыз да, мин сөйли башлыйм. Кызлар мине дә, Гайшә әбине тыңлаган кебек, игътибар белән тыңлыйлар. Шуңа күрә, отышлы уеннарда мин оттырсам, кызлар миңа шигырь-хикәя сөйләргә кушалар. Кайчак минем тыңлаучыларыма әби-апалар да килеп кушыла. Алар да, балалар кебек үк, мин сөйләгән геройларны үзләренә таныш булган тере кеше итеп кабул итәләр, аларның кайгы-хәсрәтләрен уртаклашалар, елап та алалар, җиңү-батырлыклар турында сөйләгәндә, сөенәләр. Бу хәлләр бигрәк тә сугыш турында сөйләгәндә була. Кич-кырын булса, кызларның эштән кайткан әни-апалары да, бераз булса да, туктап тыңлыйлар иде...

Миңа алты-җиде яшь булгандыр, чолан идәне астында мин очраклы рәвештә пөхтә генә итеп капчыкка төрелгән ике китапка тап булдым. Ләкин мин аларны укый алмыйм булып чыкты, чөнки күп кенә хәрефләрне танымый идем. Бер китапны тотып, Зафира апа янына кереп киттем. Һәрвакыттагы кебек, ул миңа ярдәмгә килде: бу китапның “Яңалиф” дигән латин алфавитында басылганлыгын аңлатты, басма хәрефләр белән бу алфавитны язып бирде. Мин китапларны кирәклеге беткәнгә алып куйганнардыр дип уйладым, чөнки Зафира апа “Яңалиф”не рус хәрефләренә алмаштырылганлыгын да аңлатты. Мин шактый тиз арада бу хәрефләрне таный башладым. Беренче китап Кәрим Тинчуринның пьесалары җыентыгы иде. Мин аны тулысынча укып чыктым. Иң мөһиме – миңа пьесалар уку бик охшады – алар, “калын” китапларның озын җөмләләренә караганда, җиңелрәк аңлашыла һәм кызыграк та тоелды. Шушы вакыттан мин драматургиягә гашыйк булдым дип әйтергә ярыйдыр.

Икенче китап – Галимҗан Ибраһимовның “Безнең көннәр” романы булып чыкты. Ансы минем өчен бик катлаулы – күп нәрсә аңлашылмый. Катлаулы сорауларга әни генә җавап бирә ала дип уйлап, мин әнине көтеп алырга булдым. Әни бу чорда яңадан көне-төне эштә була иде. Йокламыйча әнине көтеп алып, китаптагы миңа аңлашылмаган урыннарны аңлатуын сорадым. Ләкин әни, китапны күргәч, агарынып китте, һәм, аңлату урынына үзе миннән сораштыра башлады – “китапны каян таптың, кемнәр күрде” h.б.; аннан соң, китапларны миннән алып, алар хакында онытырга, беркемгә бер сүз дә сөйләмәскә, сорашмаска кушты. Менә шулай тормыш безне “артык сораулар” бирмәскә, сакланырга өйрәтә иде. Ә Кәрим Тинчурин, Галимҗан

Ибраһимовларның “халык дошманы” дип гаепләнеп, нахакка атылулары турында мин алар аклангач кына белдем. Әни дә шул чагында гына аңлатты: укытучыларга үзләрендә булган “халык дошманнары” китапларын яндырырга кушканнар икән, аның бу эшкә кулы бармаган; ә аларны тапкан очракта әнинең төрмәгә эләгүе дә бик мөмкин булган...

Мәктәптә укый башлагач, минем аралаша торган даирәм киңәйде. Ул минем классташларым һәм яраткан укытучыларым Рәхилә апа һәм Әминә апа иде. Кабатлау булса да, әйтим: беренче класстан соң әни мине, икенче класста укытмыйча гына, өченче класска “сикертергә” уйлаган, чөнки мин белемне бик тиз үзләштерә идем. Өченче классны Әминә апа укыта иде. Ул мине хисаптан икенче класс программасы буенча тикшереп карады. Мин барлык биремнәрне дә дөрес эшләп чыктым. Шулай итеп, 1945/1946 уку елын мин өченче класста, аннан соң дүртенче класста да Әминә апада укыдым. Безнең классыбыз бердәм, дус иде. Ярым ач, ярым ялангач булсак та, без белемгә омтылабыз, яраткан укытучыбызның һәрбер сүзен йотлыгып тыңлыйбыз, ул кушканны рәхәтләнеп үтәргә тырышабыз. Әминә апа дәресләрдә генә түгел, дәрестән соң да безнең белән шактый күп вакытын уздыра.

Мәсәлән, ул безгә төрле экскурсияләр оештыра иде. Өченче классны тәмамлаганда, ул безне авылдан 1,5-2 чакрым ераклыкта булган колхоз умарталыгына алып барды. Безнең үзебезнең өйдә дә умарта булса да, мин кортлар турында бик аз белгәнмен икән. Умартачы бабай безгә кортлар турында бик кызык нәрсәләр сөйләде, төрле формадагы умарталарны күрсәтте, хәтта безне бал белән дә сыйлады (укучыларның күбесе ул көнне бал тәмен беренче тапкыр белгәннәрдер дип уйлыйм). Ә дүртенче классны тәмамлаганда, без инеш буйлап аның башланган җирен эзләп киттек. Дөрес, инеш башланган җиргә үк барып җитмәдек (Әминә апа аның бик ераклыкта булуын аңлатты). Бер 3-4 чакрым инеш буйлап менгәч, Әминә апа безне инешкә кушылган тагын да кечкенәрәк агымсу буйлап алып китте һәм аның башланган җирендә җир астыннан бәреп чыккан чишмәне күрсәтеп, бөтен инешләр дә, елгалар да шулай башланганлыгын аңлатты...

1946 елда игеннәр уңмады, кытлык елы булды.1946-1947 елның кышы минем хәтеремә безнең гаиләдә дә иң авыр елларның берсе булып кереп калды. Беренчедән, әти бик нык чирләде. Икенчедән, сугыш тәмамланса да, бу кыш та, сугыш елларындагы кебек, халык ачтан интекте. Хәтта безнең өйдә дә әни ипине арыш онына кырган бәрәңге өстәп пешерә башлады. Мин бәрәңгеле ипине ашый алмадым (аның исеннән үк минем күңелем болгана иде). Бу кышны мин, нигәдер, тиздән үләм дип уйлый башладым. Белмим, әтинең авыруымы моңа сәбәп булган, берәр кешенең үлемеме (ә үлемнәр күп булды), әллә укыган китапмы, ләкин мин, чынлап та, ун яшемне тутырмыйча ук үләчәгемә ышана идем. Һәм мин өйдәгеләргә: “Барлы-юклы гомеремдә (ун яшемә кадәр җитәмме, юкмы) мин бу ипине ашамыйм”, - дип белдердем. Әлбәттә, барысы да моны минем уйдырма, каприз дип кабул итте.

Әни генә, минем сүзләрне чынга алып, миңа чиста арыш оныннан аерым кечкенә генә ипи сала башлады. Соңыннан белгәнемчә, бу бигрәк тә әтинең ачуын китергән (әсирлектә аңа нәрсә генә ашарга туры килмәгән):

бала бер нәрсә дә аңламый, ә син аны узындырасың дип, әнине гаепләгән, һәм бер үк камырдан миңа да кечкенә ипи пешерергә кушкан. Мин, әлбәттә, моны белмәдем, ләкин яңа пешкән ипине кулыма алып кисә башлауга, исеннән күңелем болганып, урамга йөгердем. Бәрәңгеле ипине генә түгел, әни кайчак пешерә торган бәрәңгеле коймакны да минем ашказаным кабул итмәде (күршеләр пешерә торган кәлҗемә-көлчәләрне әйтеп тә тормыйм инде). Ә менә Алисага бәрәңге кәлҗемәсе бик ошый (аны кайчак дусты Фәниянең әнисе Гайшәттәй сыйлый иде), һәм ул әнидән дә шундый кәлҗемә пешерүен сорый иде. Әни, яхшы бәрәңгене күршеләрдән өшегән бәрәңгегә алмаштырып, Алисаның “заказын” үтәде. “Яңа ризык” белән Алиса гына түгел, миннән башка барысы да берничә тапкыр сыйландылар. Бу хәлләрне мин әнинең безнең белән санлашуын, безнең теләкләребезне игътибарсыз калдырмавын күрсәтер өчен яздым.

1947 елның җәендә мине Бондюг заводы эшчеләренең балалары өчен булган Озын Таудан ерак булмаган Кама буенда нарат урманында урнашкан пионерлагерьга җибәрделәр. Лагерьдан берничә факт истә калган. Иң мөһиме, мөгаен, ашау җитмәве булгандыр. Азык-төлек карточкалары кулланылган бу вакытта, башкалар белән бергә ашатсалар да, миңа ипи тиеш түгел иде. Шуңа күрә әни пешергән ипине атна саен миңа Нажия апа алып килде (ул авыл советы секретаре, районга төрле отчетлар белән еш йөрде). Икенче истә калган нәрсә – көн саен иртәнге аштан соң безне урманга гөмбә җыярга алып китәләр. Без җыйган гөмбәне кухняга илтәбез. Көн саен безне гөмбәле ризык белән сыйлыйлар (гөмбәле аш, кыздырган яки томалап пешерелгән гөмбә, гөмбә бөккәне һ.б.). Минем өчен гөмбә таныш ризык түгел (сугыш һәм ачлык вакытында да бәзәкәлеләр гөмбә ашамады) – мин аны ашарга өйрәнә алмадым (ашның шулпасың, бөккәннең камырын гына ашадым). Бу походларның бердәнбер файдасы – мин гөмбәләрне танырга өйрәндем һәм урманда гөмбә эзләү, җыю процессын бик яраттым (гөмбәне мин хәзер дә ашамыйм)...

Үз эшен яратып башкарган әнием миңа үземне белә башлаганнан бирле үрнәк булды. Укытучы булырга теләгем барлыгын белгәч, аның, мине хуплап: “Безнең җиде буын бабаларыбыз балалар укыткан. Укытучы эшеннән дә хөрмәтлерәк, балаларны тәрбияләү, аларга белем бирүдән дә кирәклерәк эш дөньяда бар микән?” - дип әйткәне күңелемә уелып кереп калды (миңа ул вакытта җиде яшь иде). Әлбәттә, кызыксынучан бала буларак, мин әнинең җиде буын бабасы хакында сораша башладым. Ләкин, күпме генә белергә теләсәм дә, ул чагында әни алар хакында бер нәрсә дә сөйләмәде. Без үскән заманда туган-тумача, гомумән, шәхси тормышка кагылган мәсьәләләр хакында сорашу ярамый, кызыксынуыбызны туктатырга ике сүз җитә иде - “Үскәч белерсең”.

Чыннан да, үскәч белдем. Тарих 1917 елдан гына башлана, аңа кадәр караңгылык, наданлык хөкем сөргән гади халык тормышының бер кызыгы да булмаган, дип формалашкан кеше, үсеп җиткәндә, үз нәселебез тарихы белән кызыксынмаска өйрәнгән идем инде. Җиде буын бабаларыбыз тарихы белән дә мин бик соң, олыгайгач кына, кызыксына башладым. Әнием нәселе

хакында шул белемнәремнең сөземтәсен монда да бирергә булдым. Әнинең шәҗәрәсе: *Тәкәш - Ирәй - Сыбай - Мостафа - Гомәр - Мөхәммәдәмин - Сәгъдетдин - Вәлиәхмәт - Рөкыя - Альта.*

Миңа бабамнар белән үсү насыйп булмады. Әтиемнең әтисе Ибраһимов Мәхмүт бабай 1921 елда ук тифтан вафат булган. Әниемнең әтисе, Субаев Вәлиәхмәт Сәгъдетдин углын (1870-1949) – Вәлиәхмәт бабамны берничә тапкыр гына күреп калдым. Чөнки ул Алабугада яши иде һәм, ул вафат булганда, мин 12 яшемдә генә идем. Шулай да мин бабамны яхшы хәтерлим. Минем хәтердә ул чандыр буйлы, юка гәүдәле, бик пөхтә киенүчән, ап-пак чәч-сакаллы, ягымлы карашлы, йомшак мөгамәләле бабам булып саклана. Бабай тәртип ярата, аның көндәлек режимы төгәл үтәлә торган кагыйдәләрдән гыйбарәт: бишвакыт намаз, иртән берничә коймак белән чәй, өйдәге бар кешене дә өстәл артына җыя торган кичке аш. Бабай бер вакытта да тавышын күтәрмәс, кычкырып сөйләшмәс. Бабамның сөйләм теле бик матур иде. Бераз сизелгән мишәр акценты белән, төрле мәкальләр, шигъри өзекләр кушып сөйли иде ул. Аның үзеннән тирә-юньгә ниндидер җылылык, яктылык, нур, чын зыялылык сирпелеп тора иде кебек. Хәтта хәзер дә, бабам исемә төшкәндә, мин ирексездән елмаям, аның әйткән сүзләре, миңа биргән “сабак”лары хәтергә килә.

Тормышымдагы үзгәрешләр

Балачакта бары да ерак була:
Ерак иде басу капкасы,
Әллә кайда иде күрше авыл,
Ничек кенә урап кайтасы!
Үсеп җитеп булмас кебек иде...
Харрас Әюп

1947-1948 уку елында без, Әминә ападан китеп, бишенче класста укуыбызны дәвам иттек. Монда безне берничә укытучы укыта башлады. Уку миңа элеккечә җиңел бирелде, һәм әни белән әти миңа өстәмә эш таптылар. Алар мине киләсе уку елында Бондюгтагы рус мәктәбенә укырга бирергә уйлаганнар булып чыкты. Ә моның өчен мин рус телендә аралашырга өйрәнергә тиеш идем. Әни Бәзәкәгә эшкә килгән яшь рус теле укытучысы Наталья Николаевна белән сөйләште, һәм мин аның җитәкчелегендә рус телен өйрәнә башладым. Наталья Николаевна, ихтимал, мин белгән чорда Бәзәкәдә даими яши башлаган беренче рус кешесе булгандыр. Аның белән русча аралаша башлаганда, мин рус телендә бер җөмләне дә дөрес итеп төзи белми идем. Әлбәттә, безнең Әминә апа алып барган рус теле дәресләре булды; күпмедер дәрәҗәдә сүз запасы да барлыкка килгән иде, ләкин минем бер кем белән дә русча тулы бер әңгәмә алып барганым булмады. Рус сөйләмен без клубта була торган киноларда гына ишетә алдык (гомумән, ул чагында телевизор-интернет кебек нәрсәләр юк иде). Хәтта радиоалгыч та 1947 елда гына алынды, ләкин аннан без Казаннан татар телендәге

тапшыруларны гына тыңлаганбыздыр дип уйлыйм. Наталья Николаевна мине нәкъ менә русча аралашырга, рус сөйләм теленә өйрәтте.

Русча сөйләшкән балалар белән таныштырыр өчен Алиса белән мине Бондюгка Метшиннар гаиләсенә чыршы бәйрәменә дә алып бардылар. Ильяс абый Метшин һәм аның хатыны Зәкия апа Валеева ВКП(б)ның Бондюг райкомында эшлиләр иде. Аларның ике баласы янына тагын берничә бала чакырганнар. Өйләрендә татарча сөйләшсәләр дә, бәйрәм күбрәк рус телендә булды, чөнки балалар русча җырладылар, русча шигырьләр сөйләделәр. Әни кушуы буенча мин дә Н.А.Некрасовның “Мужичок-с-ноготок” дигән шигырен сөйләдем. Бу вакытка сәхнәдән шигырьләр сөйләргә өйрәнеп беткән булсам да, чыгыш миңа бик авыр бирелде (рус телендә укыгангамы, чит кешеләр алдында булгангамы, белмим). Оялуымны, читенсенүемне җиңеп, балалар белән дә бераз аралаштым.

1948 елның 1 сентябреннән минем өчен бөтенләй үзгә тормыш башланды - мин Бондюгта беренче номерлы мәктәпнең 5-а классында укый башладым. Бишенче класс программасы Бәзәкәдә үтелгән булгач, рус телен өйрәнүгә игътибарны күбрәк биреп булыр дип уйлагандыр әни. Шулай итеп, унбер яшемдә мин туган йортымнан, туган авылымнан читтә, чит-ят кешеләр арасында, үзгә шартларда яши башладым. Дөрес, әтинең сеңлесе Нурнидә апа ике улы һәм әби белән Бондюгта яшиләр, ләкин аларның өе мин укый торган мәктәптән ерак, Камаш дип йөртелә торган җирдә урнашкан. Шуңа күрә мине мәктәпкә күрше йортта ике баласы белән яши торган Мәймүнә апаларга фатирга урнаштырдылар. Мин анда ике ай тирәсе яшәдем.

Менә минем өчен бер елга тиң булган яңа җирдәге беренче атна-ун көнем узып китте. Җомга көнне әти эш белән Бондюгка килгән иде, миңа ашау әйберләре алып килгән. Якшәмбе көнне әби янына, Нурнидә апаларга барырга кушып, киләсе атнага килеп аласын әйтеп, ул кайтып китте. Шимбә җитте. Без икенче сменада укый идек. Дәресләр тәмамланды. Урамда якты. Мин тоттым да, аны-моны уйламыйча, авылга кайтырга булдым. Ул елларда авыллар арасында автобус түгел, йөк машиналары да юк, ат белән дә кеше бик сирәк йөри, ә кичкә таба алар бөтенләй булмый иде. Бәзәкәгә Бондюгтан ике юл илтә – берсе өстән, ачык җирдән, икенчесе астан, әрәмә аша. Мин өске юлдан кайтырга булдым – ул озынрак булса да, ачык, үргә менгәч тә, авыл да күренә башлаячак. Көн җылы, әбиләр чуагы, күктә кояш та бар. Юлда беркем дә юк, мин бер үзем. Мин шат – өйгә кайтам, әнине, Алисаны күрәм; әнинең, мине күргәч, шаккатачагын да, сөенәчәген дә күз алдыма китерәм. Үргә менә торган ике чакрым чамасы юлны мин бик тиз уздым кебек, ләкин, миннән дә тизрәк кояш баеды, караңгы төшә башлады. Шулай да мин авылны күреп өлгердем, кайтып җитәрмен дип уйладым.

Дөм караңгыда (сәгать тугызлар булгандыр) Сәйтәккә килеп җиттем. Мин бик арыган идем инде. Миңа ни эшләргә? Куркыныч булса да, берәрсенә төн кунарга керергәме? Кемгә керергә? Сәйтәктә керәшеннәр яши, бәзәкәлеләр алар белән аралашмый иде. Алар безнең өчен бөтенләй чит кешеләр, тормышлары да безгә ят, икенче дөнья. Әти янына килгәли торган Җәгур дәдәй бар инде барын, ләкин мин аның өен белмим. Ә өйгә кадәр

калган өч чакрымны узу тагын да куркынычрак – алда ике чокыр (Тарлау һәм Зират чокырлары) һәм зиратны узарга кирәк... Караңгы, тәрәзәләрдә ут та күренми (электр уты юк, кешеләр иртә яталар). Шулай да мин, берәр тәрәзәдә ут күрсәм, тәвәкәлләп, шакырга булдым: монда барысы да әтине белергә тиешләр (ул уполминзаг булып эшли).

Минем бәхеткә, кырыйдагы бер өйдә пыскып кына торган ут күренде. Һәм мин, кыймар-кыймас, тәрәзәне шакыдым. Ишекне ачкан апа, шаккатып: “И-и, бала, син каян килеп чыктың?” – дип, аптырап калды. Мин үземнең Бәзәкәдән, Мәхмүт Хаҗиеның кызы икәнемне, Бондюгта укуымны, ялга авылга кайтуымны әйтеп, кунып чыгарга рөхсәт сорадым. Юраганым юш килде, ул әтине белә иде. Нәрсәдер такмаклый-такмаклый, ул мине, өйләренә алып кереп, берничә кеше йоклый торган сәкегә яткырды. Иртән мине уятканда, барысы да торганнар иде инде. Мин, апага рәхмәт әйтеп, юлымны дәвам иттем. Ике чокыр арасында колхозчылар каен утырталар иде. Алар арасында булган Зафира апа, мине күргәч, аптырап калды. Әти белән әни дә, мин ишектән килеп кергәч, сүзсез калдылар. Алай да, артык ачуланмадылар. Мин үзем дә инде дөрес эшләмәгәнемне аңлаган идем, башка үзем генә юлга чыкмаска сүз бирдем. Минем беренче тапкыр үзлегемнән Бондюгтан Бәзәкәгә кайтуым шулай тәмамланды. Әлбәттә, Бондюгта укыган өч ел эчендә миңа бу араны кешеләр белән дә, үземә генә дә атна саен диярлек узарга туры килде.

Башта, беренче атналарда, әти шимбә көнне үзе велосипедта мине алырга килеп йөрде. Рамга утырып кайту бик җайлы булмаса да, барыбер, җәяү йөрү түгел инде. Яңгырлар башлангач, тагын җәяү йөри башладык. Кышка кергәндә, әти миңа юлдаш та тапты. Ул Бондюгта эшләп, шимбәләрен авылга кайтучы Гөлҗиян апа иде. Аның белән без астан, әрәмә аркылы йөрдек. Бондюгка мин дүшәмбе көн иртән китәм. Гадәттә, әти миңа кичтән юлдаш табып куя, еш кына ул районга эш белән ат җигеп баручылар була иде. Мин үземнең “башка Бондюгка бармыйм” дип киреләнгәнемне хәтерләмим, ихтимал, атка утырып китү миңа өйдәгеләр белән аерылышуны җиңеләйткәндер (әле бит аның “кирәк” дигән сүзе дә бар).

Класста мин бердәнбер татар кызы идем. Хәер, әгәр дә мин русча дөрес сөйләшсәм, моңа беркем дә игътибар да итмәгән булыр иде (ул чорда милләт мәсьәләсе, гомумән, телгә алынмады). Классташлар мине, бик тиз булмаса да, үз араларына кабул иттеләр, малайлар гына башта, минем ялгышларымны кабатлап, үртәделәр. Һичшиксез, классташ-яшьтәшләре арасында алгы планда булырга күнеккән горур һәм үпкәчел кызга бу шартларда бер дә җиңел булмагандыр. Мин, әлбәттә, читсенә, ояла идем; үз эчемә бикләндем, ләкин кире авылга кайтаруны сорамадым. Тизрәк русча дөрес сөйләшергә өйрәнергә кирәк. Миңа классташ кызлар да булыштылар (малайлардан да якладылар, ярдәм дә иттеләр). Мин укуга “чумдым” – хәзер инде русча китапларны күп укый башладым. Китапларны мин Зәкия апалардан да алдым, классташ кызлар да үзләрендә булган китапларын бирделәр. Хәтеремә Галя Куликованың өйләрендәге зур китапханә булуы кереп калган

(китапка булган мәхәббәт Галя белән мине соңрак, 6-7 классларда, дуслаштырды да).

Класстагы кызларның миңа карата мөнәсәбәтләре начар булмады. Ә Вера Денисова иң якын дустым булып китте. Ул класста иң яхшы укучы, отличница. Белмим, бәлки баштарак аңа миңа ярдәм итәргә кушылган булгандыр – без аның белән бер йортта яшәдек, ерак йөрисе дә түгел. Вера бик ярдәмчел, йомшак күңелле, тыныч характерлы, төпле кыз иде. Без тиз дуслашып киттек, җиденче классны тәмамлаганчы, бик якын дуслар булдык. Җиденче класстан соң безнең юллар аерылды – Вера Чиләбе өлкәсе Миасс шәһәрендәге тау техникумына, ә мин Алабуга педучилищесенә укырга кердек.

Беренче чирекне мин өч “бишле” (математика, география һәм немец теле) һәм өч “икеле” (рус теле, әдәбият һәм тарих – барысы да сөйләм теленә бәйле) белән тәмамладым. Шуннан соң әти-әниләр мине, Мәймүнә апа өендәге татар мохитеннән аерып, икенче фатирга күчерергә булдылар. Аны Зәкия апа тапты. Ул, үзенең күршесендә яшәгән бабушка Сорокина белән сөйләшеп, аның ризалыгын алган булып чыкты. Мине шунда торырга күчерделәр. Бабушка Сорокина заводта эшләүче кызы Поля белән яши. Мәктәпкә якын, ике өй аркылы гына, Зәкия апалар да күршедә генә, Вераларга да якын. Минем өчен бик уңай вариант.

Кызганыч, ләкин мин, бабушка Сорокиналарда өч елга якын яшәсәм дә, аның исемен белмәдем. Ул миңа үзенә бабушка дип кенә эндәшергә кушты, ә минем русча белемем аның исемнәрен төпченерлек булмаган, күрәсең. Бабушка, беренче карашка, бик кырыс, аз сүзле кеше иде, шуңа күрә кыюлыгым да җитмәгәндер. Аны олысы-кечесе “бабушка Сорокина” дип атый, аннан барысы да шүрли, аның күзенә чалынырга омтылып тормый. Чынлыкта ул бик гадел, яхшы күңелле, миңа карата хәтта ягымлы да иде. Ул чын күңеленнән Аллага ышана, Пасха бәйрәменә Бондюгтан 50 чакрымдагы Алабуга районы Костенеево авылындагы чиркәүгә барып, төнге догаларны укыганнан соң икенче көнне әйләнеп кайта. Шуннан чыгып, мин аның яше бик зур булмагандыр - 50-55 яшьләр тирәсе булгандыр дип уйлыйм. Бабушка мине гел кайгыртып торды – ашавымны да, киемнәремне дә тикшерә, үзе укый-яза белмәсә дә, минем сөйләм телемнең дөреслеген күзәтә, өйрәтә иде. Тетя Поля минем өй эшләремне тикшерә, гомумән, алар миңа беренче көннән үк бик игътибарлы, мәрхәмәтле булдылар. Өч елымны да мин аларда үземне якын кешеләрдә яшәгән кебек бик уңай хис иттем.

Икенче чирекне мин инде “икеле”ләрсез тәмамладым, классташларым да миңа күнектеләр (хәтта малайлар да үртәми башлады). Шулай да мәктәпкә күнегеп бетә алмадым. Хәзер мин бу уңайсызлыкларны рус теле укытучысының укучыларына булган мөнәсәбәте белән аңлатам. Тәҗрибәсе булмавы, ә бәлки үз эшен яратмавы аркасындадыр, аның дәресләрендә киеренкелек хөкем сөрә. Дәресләре дә кызык түгел, бик коры, формаль рәвештә үтә, укучыларның һәрбер ялгыш җавабына аның ачуы чыга. Моны Бәзәкә укытучыларының йомшак мөнәсәбәтенә, гаделлегенә күнеккән мин генә түгел, башкалар да сизә иде. Безнең бәхеткә, укытучыбыз яңа елдан

декрет ялына китте. Бәлки аның бу халәте дәресләргә һәм безгә карата булган мөнәсәбәтенә йогынты ясагандыр, белмим. Ләкин аны икенче укытучы алыштырачагын белгәч, без барыбыз да бик нык сөенгәнебезне хәтерлим.

Өченче чирек башыннан рус теле һәм әдәбияты дәресләрен моңа кадәр пенсиядә булган өлкән яшьтәге укытучы Мария Михайловна алып бара башлады. Беренче дәрестән үк ул безнең күңелләребезне яулап алды, чөнки аның дәресләре бик кызыклы уза, дәрес узып киткәнен дә сизми кала идек. Миңа карата да аның мөнәсәбәте бөтенләй үзгә – әгәр дә беренче укытучы минем белән бөтенләй кызыксынмаса, тиешле эшләрне тикшергәндә дә мине читләтергә тырышса, Мария Михайловна, киресенчә, миңа бирем артыннан бирем табып кына тора, мактарга да онытмый, мине канатландыра иде. Ул безнең белән дәрестән тыш эшләр дә алып барды, безнең өчен әдәбият һәм рус теле түгәрәге оештырды. Яхшы укучы классташлар белән бертигез дәрәҗәдә мин дә рефератлар язам, үзем язган докладларны сөйлим. Укытучыбыз безгә төрле китаплар укырга куша, ул китаплар буенча конференцияләр уздыра, иншалар яздыра. Я без төрле әйтемнәр, табышмаклар, сынамышлар, тизәйткечләр җыябыз, я кроссвордлар төзибез һәм чишәбез, я башы бирелгән әкиятнең азагын язып килергә тиеш булабыз, я инсценировкалар куябыз... Мария Михайловна минем Бондюг мәктәбендәге иң яраткан укытучым булып китте. Әлбәттә, минем белемем арткан саен, билгеләрем дә үзгәрде – өченче чирекне мин “дүртле-бишле” билгеләренә генә тәмамладым, ә ел ахырына рус теле, әдәбият, тарихтан “бишле” билгеләре генә ала башладым. Туган телемнең байлыгын, аның матурлыгын миңа әнием ачты. Минем уйлавымча, рус телен яратуым һәм яхшы дип әйтерлек дәрәҗәдә белүем белән мин, һичшиксез, Мария Михайловнага бурычлы – ул миңа рус теленең байлыгын һәм матурлыгын күрсәтте, рус әдәбиятына мәхәббәт уятты.

Алтынчы-җиденче классларда укыганда, мин инде үземнең бу мөстәкыйль тормышыма ияләшеп җиткән идем. Бабушкада яши башлагач, минем ашау-көнкүреш хәлләрем дә уңайлашты. Әти көздән үк бәрәңге китереп куя, башка азык-төлекне (сөт, май, ит) аз-азлап мин үзем дә алып киләм, әти дә китергәли (ул заманда, гомумән, тормыш та кысан, суыткычлар да юк). Минем кечкенә генә чуеным бар, мәктәпкә киткәнче, мин шуңа бәрәңге әрчеп калдырам, калганын бабушка хәстәрли – булса, итен-маен-ярмасын салып, булмаса, бәрәңгене үзен генә, мичне яккач, пешерергә куя. Кайтуга мине әзер җылы ашау көтеп тора. Бу тормышны, бүгенге күзлектән караганда, мул яки тук тормыш дип бәяләп тә булмыйдыр, ләкин бөтенләй ачлыктан да интекмәдем.

Миңа атна саен күпмедер акча да бирәләр, әмма кибетләрдә алып ашарлык бернәрсә дә юк, ипигә дә зур чиратлар була. Ә менә кара уылдык бар иде. Минем аны ашаганым булмаса да, кыздырган яки ашта пешкән балыкларның уылдыгын яратып ашый идем. Бер тапкыр мин, башка ашау әйберсе күренмәгәч, шул кара уылдыкны алдым. Аны зур мичкәдән алып, калын кәгазьгә төреп бирделәр - йөз грамм чамасы булгандыр. Ләкин ул бик тозлы, иписез-нисез ашарлык түгел булып чыкты. Шулай да, мин аны

портфелемнең кечкенә кесәсенә салып куйдым һәм, бик ашыйсы килгәндә, бер-ике бөртеген генә кабып суыра идем. Шулай итеп, бу деликатес миңа бик озакка җитте, ә портфелемдәге балык исе бик озакка җитте. Бондюгка әти килгән көн минем өчен бәйрәмгә әйләнә, чөнки ул мине завод ашханәсенә пилмән ашарга алып бара. Өйдә әни дә минем кайтуга нинди булса да тәмле нәрсә пешереп куя, ләкин минем иң яраткан ризыгым – мичкә тәгәрәткән бәрәңге иде. Өстәлгә нәрсә генә килмәсен (хәтта бәлеш, өчпочмак булганда да), минем соравым бер: “Ә тәгәрәткән бәрәңге бармы?”. Бер-ике бәрәңге ашагач кына башка ризыкка күчә идем.

Шулай өч ел узып китте. Аерым яшәү психологик яктан минем өчен шактый катлаулы булды. Шимбә кич өйгә кайтып, таныш шартларда мин бөтен җаным-тәнем белән рәхәткә чумам, ләкин ял итәргә дә өлгермим, тагын чит-ят мохиткә китәргә кирәк була. Гамәлдә миңа ике төрле тормыш белән яшәргә туры килде – берсе күнегелгән татар авылы тормышы, икенчесе – рус мохите. Миңа ул шул кадәр авыр бирелә иде, авылга кайткач, минем өйдән чыгасым да килми. Шулай, акрынлап, авылдагы дус кызларымнан читләшү башланды. Каникул, бәйрәмнәр вакытында гына миңа алар белән иркенләп аралашу мөмкинлеге була. Шулай, алтынчымы, җиденчеме класста укыганда, 1-Май бәйрәменә кайткач, карга боткасына баруыбыз хәтеремә кереп калган. Тагын шунсы да бар бит әле: авыл балалары тизрәк өлгерә: мин Бәзәкәдән киткәндә 13-14 яшьлек булган үсмер кызлар (минем классташларым миннән олырак булуларын язган идем) бу өч ел эчендә җиткән кызларга әйләнде, ә мин әле һаман бала булып кала бирдем. Мин алтынчы классны бетергәндә, алар җидееллык мәктәпне тәмамлап, зурлар рәтенә күчте. Зурлар төркеменә күчкән кызларның эшләре дә, уй-фикерләре дә үзгәргән иде инде.

Бондюгтагы классташларым белән дә мин бик күп аралаша алмадым. Сәбәбе шул ук – аларның уеннарында катнашырга минем вакытым җитми – уку көннәрендә мин уку белән мәшгуль, шимбә җиттеме – авылга кайтып китәм. Шуңа күрә мин ике-өч кыз белән генә дуслаштым. Вера белән Галядан башка, әтиләре белән Украинадан кайтып, безнең белән алтынчы класста укый башлаган Роза Гильмутдинованы гына әйтә алам. Безне, күрәсең, икебезнең дә завод кызларына ят булуыбыз берләштергәндер (Роза, татарча белмәсә дә, украин акценты белән сөйләшә иде). Алтынчы-җиденче классларда мин яхшы укуымны дәвам иттем; җиденче класстан соң алган таныклыгымда ике генә “дүртле” булды (геометрия һәм физкультурадан).

1951 елның җәендә әтиләр өйне күчереп салырга ниятләделәр. Беренчедән, 1920 елда Мәхмүт бабай салган йорт инде шактый искергән һәм зур ремонт таләп итә иде. Икенче сәбәбе дә бар – безнең хуҗалыкны урамнан аерып торган урын бушады. Анда яшәгән Гәрәевләр, бик искергән өйләрен сүтеп, Олы урамга күченделәр. Шушы бушаган урынга әтиләр безнең йортны һәм каралты-кураларны күчереп салырга булдылар. Шулай итеп, бу җәй һәм көз бик мәшәкатьле булды.

Мәшәкатьләрнең икенче төре дә бар иде. Мин бу җәйне җиденче классны тәмамладым. Барыбыз бергә киңәшеп, миңа укуымны Алабуга

педучилищесендә дәвам итәргә кирәк дигән фикергә килдек. Бу фикер безнең уртак фикер иде: мин җиде яшемнән, үскәч, укытучы булачагымны белә идем, ә әти-әни (икесенең дә сәламәтлеге нык түгел) олы кызларының (Нажия апа һәм Рәмзия апа үз гаиләләре белән яши) кулына ышанычлы һөнәр бирергә булдылар, чөнки минем артта тагын ике кыз – унбер яшьлек Алиса һәм ике яшьлек Әнисә бар. Алабугада таяныр нокта да бар – анда Сара әби һәм гаиләсе белән әнинең абыйсы Шаһвәли яши. Мине әби карамагына тапшырдылар – аның белән мин педучилищегә документларны илтеп тапшырдым, керү имтиханнарын биреп, укырга да кердем. Ә Алиса минем юлымны кабатлады – аны да бишенче класска Бондюгка рус мәктәбенә укырга бирделәр. Шулай итеп, яңа өйдә әти белән әни һәм ике яшьлек Әнисә генә яшәп калдылар. Әтинең зур гаилә булып яшәү хыялы бу вакытка чәлпәрәмә килгән иде инде: Шәриф абый гаиләсе белән Карелиядә (ул сугыштан соң армиядә хезмәт итүен дәвам итте); Нажия апа авылда (ул 1947 елны Нәсифуллин Гәрәйгә кияүгә чыкты); Рәмзия апа Березняк шәһәрендә кияүдә (ул анда 1947 елда ук киткән иде), мин Алабугада, Алиса Бондюгта.

Минем тормышымда Алабуга дәвере башланды. 1951-1955 еллар – минем үсмер чорым – яшеллеккә күмелгән борынгы кечкенә шәһәрдә үтте. Ул чор Алабуга шәһәре авылдан артык аерылмый - хәтта көтү дә чыга иде. Хәзер мин авылда тагын да сирәгрәк була башладым. Алабуга – ул инде Бондюг кына түгел, авылдан 35 чакрым, аннан җәяү генә кайтып җитеп булмый. Дөрес, хәзер юлда йөк машиналары ешрак күренә. Шулай да башта Алабугадан чыга торган юл чатында сәгатьләр буена безнең якка бара торган машина көтәргә кирәк. Ул Можгага (Монай авылы янында төшеп каласы) я Бондюгның үзенә кадәр була. Машина әржәсендә йөк өстендә кайту үзе бер маҗара булса, аннан соң да әле 10-15 чакрымны җәяү кайтырга кирәк. Өйгә кайтып җитмисең – кире җыена башлыйсың. Моннан тыш көзен сентябрь аен һәм барлык якшәмбеләрне без педучилищегә шефлыкка бирелгән Сарайлы (Бехтерево) авылы колхозында эштә уздырабыз (анда да Алабугадан бару-кайту – җәяү). Шуңа күрә авылга бәйрәмнәрдә һәм каникулларда гына кайтыла иде. Җәйге каникуллар да кыскарды – июньдә без әле имтиханнар тапшырабыз, бер айны Сарайлыда колхозда эшлибез. Димәк, инде педучилищедә укыган елларда ук мин авылдан аерылып беттем дип әйтеп була торгандыр.

1955 елда педучилищены тәмамлап, мин башлангыч класслар укытучысы дипломы алдым. Безнең чыгарылыш соңгы булды – Алабугада педучилище бетерелде. Әти белән әни минем укуымны институтта дәвам итүемне теләделәр. Педучилище белән бер үк бинада урнашкан укытучылар институты 1953 елда ике факультетлы педагогия институты итеп үзгәртелгән иде, ягъни ерак китәсе түгел, ике факультетның берсендә укып, югары белем алу мөмкинлеге бар. Ләкин минем башта укытып карыйсым килде. Әти-әниләр, озак кына бәхәсләшкәннән соң, миңа юл бирергә мәҗбүр булдылар (бу бәхәс аркасында мин кызлар белән бергә Урта Азиягә китмичә калдым). Нәтиҗәдә 1955 елның 15 августыннан мин Казан мәктәпләренең берсенә 1 класс укытучысы итеп билгеләндем.

Шуннан соңгы гомерем Казанда үтте. Монда мин ун ел мәктәптә укыттым, 1965 елда читтән торып Казан университеты тарих-филология факультетының тарих бүлеген тәмамладым. Шул ук елны СССР тарихы кафедрасы каршындагы аспирантурага кабул ителдем. 1967 елдан 2010 елга кадәр университетта эшләдем (ассистент, өлкән укытучы, доцент). 1971 елда "Татарларда хатын-кызларны дөньяви укыту өчен көрәш (1861-1917 еллар)" дигән темага кандидатлык диссертациясен якладым. Берничә фәнни һәм фәнни-популяр китапларым, төрле журнал һәм җыентыкларда күпсанлы мәкаләләрем басылды. Хәзер пенсиядә. Бәзәкәдән киткәнемә инде алты дистә елдан артык гомер узса да, авылга ел саен, берничә көнгә генә булса да, кайтмыйча калганым булмады. Табигый ки, авылга кайткач, күпмедер дәрәҗәдә әтиләргә җәйге эшләрдә – утын-печән әзерләүдә булыша, әни урынына укытучыларга җәй саен мәҗбүри булган субботник-воскресникларда катнаша идем һ.б. Әлбәттә, авыл тормышы, Бәзәкәдәге үзгәрешләр белән дә мин гел кызыксынып тордым, ә ул үзгәрешләр XX гасырның икенче яртысында аз булмады...

Авылдагы үзгәрешләр

Бөтенесен чынлап без күрдекме? –
Бер гомердә күпме үзгәрешләр!
Сискәндереп куя бүгенгесе,
Истән чыкмый йөри узган эшләр.

Харрас Әюп

1946-1947 елларда сугыштан кайтучылар шактый күп булды. Ләкин анда да барлык фронтовиклар да кайтып бетте дип әйтеп булмыйдыр, чөнки 1944-1945 елларда армияга алынганнар сугыштан соң да армия хезмәтен дәвам итте. Аларны исәпкә алмаганда (алар хезмәт вакытын тутырып кайтачаклар әле), 1948 елга кайтасы солдатлар кайтып беткән дип санарга була торгандыр. Минем кулда 1948 елның 1 январенә авыл советы тарафыннан төзелгән хуҗалыклар һәм аларда яшәгән бәзәкәлеләр саны турында белешмә бар. Шул мәгълүматка игътибар итик әле. Бәзәкә авыл советында 1948 елның 1 январенә барлыгы 386 колхозчы хуҗалыгы теркәлгән булган; алар эчендә 31 бушап калган хуҗалык та бар. Калган 355 хуҗалыкта барлыгы 1437 кеше яшәгән, 51 кеше читтә дип күрсәтелгән. Бу саннарны сугышка кадәрге саннар белән чагыштырыйк. 1940 елда Сталин колхозында 447 хуҗалыкта 1839 кеше саналган. Димәк, шушы вакыт эчендә колхозчы хуҗалыклары саны 92 гә, яки 20,6% ка, ә халык саны 402 гә, яки 21,9% ка кимегән.

Бәзәкәдә, колхозчылар гына түгел, укытучылар һәм башка хезмәткәрләр, кооперациягә берләшкән һөнәрчеләр һәм эшчеләр дә яшәгән. Андый хуҗалыклар 42 булган: тугызы кешесез, калган 33 хуҗалыкта 109 кеше саналган, 28 кеше авылда булмаган. Алты аерым хуҗалык булган (13 кеше); дүрт хуҗалыкта вакытлыча яшәүче 15 кеше күрсәтелгән. 1948 елның 1

январенә авылда барлыгы 438 (392 кеше яшәүче һәм 42 буш) хуҗалыкта 1571 авылдагы һәм 83 читтәге кеше теркәлгән.

Бу 1571 кешедән 647 ир-ат һәм 924 хатын-кыз булган. Аларны туган еллары буенча төркемнәргә бүлеп карыйк.

Таблица № 15

1948 елның 1 январенә Бәзәкә халкының составы

Туган еллары	Ирләр		Хатын-кызлар		Барлыгы
	Абс.	%	Абс.	%	
1938-1947	150	48.5	159	51.5	309
1928-1937	241	49.6	245	50.4	486
1927-1918	54	30.5	123	69.5	177
1917-1908	49	29	120	71	169
1907-1898	54	34.6	102	65.4	156
1897-1893	21	48.8	22	51.2	43
1892-1888	34	38.6	54	61.4	88
1888 елга кадәр туганнар	44	30.8	99	69.2	143
Барлыгы	647	41.2	924	58.8	1571

Һичшиксез, авылдан юкка чыккан егерме процентта артык кеше арасында фронтта һәлак булучылар гына түгел, ачлыктан һәм төрле авырулардан үлүчеләр дә күп булуын онытмаска кирәк. Шулай ук мобилизация белән завод-фабрикаларга киткәннәрнең бер өлеше дә кире әйләнеп кайтмаган, кайбер солдатлар да башка төбәкләрдә төпләнеп калган. Сугышта катнашмаган иң яшь ике төркемне алсак, аларда ир-ат һәм хатын-кыз саны якынча тигез булган: 150:159, 241:245. Алтынчы төркемдәге ирләр, призывка эләксәләр дә, күбрәк тыл хезмәтендә һәм обозда булганнар, тәжрибәләре дә күбрәк булган, шуңа күрә бу төркемдә шулай ук аермалыклар юк дәрәҗәсендә. Ә инде соңгы ике төркемдә ирләрнең хатыннарга караганда күпкә аз булуы, минемчә, хатын-кызларның тормыш авырлыкларына чыдамрак булуын күрсәтә торган факт.

Сугышка катнашкан өч төркемдә исә нәтиҗә үзгә: ир-атлар монда 29% - 34,6% кына тәшкил итә. Хатын-кызлар, 65.4 - 71% булып, бу төркемнәрдәге кешеләрнең ике өлешен тәшкил иткән, ягъни бу төркемнәрдәге хатыннарның һәр икенчесе ирсез – я тол, я булачак кияүләре сугыш кырында ятып калган кызлар булып чыга. Гомумән алганда, бу төркемнәрдәге хатын-кызлар, минем фикеремчә, сугыш чорында иң зур корбан китергән, иң рәнҗетелгән төркем. Сугыш еллары авырлыкларын барлык хатын-кызлар бер дәрәҗәдә күтәрсәләр дә, ирләре, уллары сугыштан исән кайткан хатын-кызлар аларны күрү, тормышларын бергә дәвам итү бәхетенә иреште. Гарипләнеп кайтсалар да, сугыштан соң озак яши алмасалар да, аларның ирләре исән, җиңүче булып кайтты. Ә толлар? Ярый ла, “фәлән җирдә, фәлән сугышта һәлак булды” дигән кәгазе килгән булса (зур кайгы булса да, үлгән, күмелгән җире билгеле). Ә күпме хатын, күпме ана, күпме бала, бер хәбәр дә ала алмыйча, кайгы-хәсрәтләргә, кимсетү-рәнҗетелүләргә дучар булды...

Сугышта хәбәрсез югалганнар (әсирлеккә эләккән солдатлармы алар, сугыш кырында һәлак булып, күмелмичә ятып калганнармы) ул елларда бернинди дәлилсез илгә хыянәт итүдә гаепләнде, һәм бу аларның туганнары язмышына да зур йогынты ясады. Уйлап куям: сугышны аннан соңгы ике дистә ел дәвамында онытырга тырышу - бәлки исән калганнарның үлгәннәр һәм аларның туганнары алдында үзләрен уңайсыз сизүдән дә булгандыр?!?.. Мин бу юлларны язып куюга “бизяки.рф” сайтында Рәшит Кәлимуллин тарафыннан куелган яңа материалга тап булдым. Ул Бондюг райвоенкоматы 1947 елның 13 гыйнварында төзегән хәбәрсез югалган 107 бәзәкәленең исемлеге. Военкомат аны аларның гаиләләренә ярдәм итү максатыннан чыгып төземәгәнен дә ассызыкларга кирәк. Исемлектән күренгәнчә, аларның берничәсенең язмышы сугыштан соңгы елларда ачыкланган (әле хәзер дә, бик сирәк булса да, андый ачышлар булгалый). Шулай да бер авылдан гына да йөзгә якын кешенең хәбәрсез югалуы Бөек Ватан сугышының күпме фажига китерүе хакында кабат-кабат уйландыра...

Сугыштан соңгы еллар, сугыш еллары кебек үк, бөтен ил, барлык кеше өчен бик катлаулы еллар булды. Сугыш елларында материаль-техник базасы эштән чыгып бетә язган колхозларга бик күп нәрсә җитми иде шул: чәчү өчен орлык, атлар һәм кул көче дисеңме, зур ремонт таләп итә торган каралты-куралар дисеңме, трактор һәм машиналар дисеңме h.б., h.б.. 1942 елда кертелгән хезмәт көне минимумы сугыштан соң да сакланып калган иде әле. Ә минимумны үтәмәгән өчен колхозчыларга гаиләне ачтан үтермәс өчен куллана торган йорт янындагы җирләреннән мәхрүм итү я төрмәгә утырту янаганын да искәртим. Сугыштан соң хезмәт көненең хакы да, сугышка кадәрге чор белән чагыштырганда, кискен кимегән булып чыкты. Нәкъ менә сугыштан соң хезмәт көнен “таяк” дип атау халык арасына кереп китте. Коллхозчыларга хезмәт көннәренә күпмедер “түләү” эләккән очракта да, ул колхоз тулысынча дәүләт белән расчет ясагач кына мөмкин була иде.

Сугыш тәмамланганнан соң халык дәүләттән тормыш шартларын җиңеләйтерлек карарлар кабул ителүен көтте. Андый карарлар да булмады түгел. 1947 ел азагында карточка системасы бетерелде, акча реформасы узды. Һәр ел яз башында дәүләт масштабында азык-төлеккә бәяләр киметелә башлады. Бу көн килеп җиткәнен бар халык түземсезлек белән көтеп ала иде. Ләкин бу чараларның халык тормышына йогынтысы бик сизелмәде, чөнки, бер яктан, дәүләт халыкка ниндидер төшермәләр ясаса, икенче яктан, сизелерлек дәрәҗәдә җыеп та ала иде. Беренче чиратта, сүз дәүләт тарафыннан чыгарылган һәм халыкка мәҗбүри таратылган заемнар турында бара. Авыл хуҗалыгы налогы шулай ук сугыштан соң да кимемәде.

1948 елдан авылдан читтә яши башлап, мин Бәзәкә хәлләрен өстен-өстен генә, әти-әниләр сөйләшүеннән генә белә башладым. Шулай да, бу авырлыклар безнең авыл халкы өчен дә бер дә җиңел булмавын белеп тордым. Бу елларда авыл советы һәм колхоз рәисләре еш алмашынып торды. Мин белгәннәрдән, шактый озак вакыт, сугыштан соңгы иң авыр 1946-1954 елларны, Гыйлфанов Нуриәхмәт абый колхоз председателе булды. 1946-1947 елгы ачлыкка 1948-1949 еллардагы корылык килеп кушылгач, колхоз да,

халык та бөтенләй бөлгенлеккә төште. Ә дәүләт салымнарын һәм заемнарын барыбер вакытында түләргә кирәк иде; димәк, гаиләне саклар өчен азык-төлек табу гына түгел, төрле салымнарны түләү өчен дә халыкка өстәмә керем кирәк булды. Бу шул ук Бондюг заводы өчен кәрзин үрү, әрәмәдә гөлҗимеш-балан җыю (ярый әле, бәзәкәлеләрне һәрдаим коткара торган әрәмә бар иде) булды. Авыл халкы, гаиләсе авызыннан тартып алып, Бондюг базарына сөтен-маен, катыгын-эремчеген, йомыркасын да ташыды.

Иртәдән кичкә кадәр дәүләткә түләүсез диярлек эшләргә мәҗбүр булган колхозчылар сугыштан соң да көндәлек тормышларында озак еллар ачлык-мохтаҗлыктан арына алмадылар. Бәзәкәлеләр, башка авыл халкы кебек үк, элеккечә үз шәхси хуҗалыкларында җитештерелгән продукция хисабына гына тормыш көтте. Ләкин монда да дәүләт шәхси хуҗалыкларның мөмкинлекләрен чикләү юлын сайлаган булып чыкты – колхозчыларның сугыш вакытында өләшкән басудагы кишәрлекләре тартып алынды. Йорт янындагы җирләр өчен түләнә торган салымнар, колхоз базарларында азык-төлек һәм башка һөнәрчелек товарлары саткан өчен җыела торган җыемнар кискен арттырылды. Мондый чаралар шәхси хуҗалыкларда алына торган керемнең кимүенә китерде. Ә аның тискәре йогынтысы, үз чиратында, шәһәр-бистәләрдә дә сизелде, чөнки авыллардан шәһәр базарларына килә торган продукция кимеде.

Үзе җитештергән продукция белән колхоз базарларында сату итү крестьяннарга хуҗалыкларына төшкән азык-төлек салымы тулысынча түләнгәч кенә рөхсәт ителә иде. Минем әти авыл хуҗалыгы продукциясен хәзерләү буенча агент иде, һәм мин, үсә барган саен, аңа хисап эшләрендә ярдәм итә килдем. Шуңа күрә авылдашлар җилкәсенә төшкән авырлыкларны белеп үстем. Һәр хуҗалык ел саен дәүләткә билгеле бер күләмдә сөт, ит, май, йомырка, сарык йоны тапшырырга тиеш иде (хәтта ниндидер төр продукция аларның хуҗалыгында җитештерелмәгән очракта да).

Ачлык-мохтаҗлыктан интеккән кайбер бәзәкәлеләр авыр крестьян язмышыннан котылыр өчен һәрбер мөмкинлектән файдаланырга тырышалар иде. Ләкин авылдан читкә чыгып китү мөмкинлекләре юк дәрәҗәсендә - крестьяннарга элеккечә паспорт бирелми, ә ансыз бер кая да китеп булмый. Аларның ярым крепостнойлар хәлендә булуларын дәлилләү өчен шул да җитәдер. Авылдан китү мөмкинлеген авыл халкы арасында бу чорда даими уза торган “оргнабор”лар (завод-фабрикаларга, төзелешләргә, Камчатка-Сахалинда балык тотуга, Донбасс шахталарына килешү нигезендә китү), урта һәм югары уку йортларына, ФЗУларга укырга керү һәм армия хезмәтенә алыну гына мөмкинлек бирә иде.

Авыл халкының авыр тормышы Сталин вафатыннан соң уңай якка таба бераз үзгәрә башласа да, бу үзгәрешләр тыныч кына килмәде. 50-еллар азагы – 60-еллар башы – илдә авыл хуҗалыгын оештыру өлкәсендә очы-кырые булмаган үзгәртүләр чоры – аерым авыл хуҗалыгы районнарын, өлкәләрен оештыру, вакыт-вакыт уздырылган колхозларны эреләндерү-кечеләндерү, h.б., h.б.. Табигый, бу яңалыклардан бер авыл, бер колхоз да, шул исәптән, Бәзәкә дә, читтә кала алмый иде. 1954 елда үз авылында эшне яхшы гына

җайга сала башлаган Гыйлфанов Нуриәхмәт абыйны Азин исемендәге совхозга директор итеп күчерделәр. Сталин ис. колхоз председателе итеп авыл советы рәисе булып эшләүче Шакиров Галимҗан абый (1954-1957), аннан соң Баһаветдинов Касыйм абый сайланды. Бер елдан соң аны өстән җибәрелгән Әхмәрев Баян Вәли улы алмаштырды. 1958 елда Сталин колхозы да эреләндерелде. Аның составына Бәзәкәдән башка күрше дүрт авыл колхозы керде – “Труженик” (Ык Тамагы), “Игенче” (Сәйтәк), “Беренче май” (Татар Тәкәше) һәм “Кызыл Октябрь” (Мари Тәкәше).

Бу чорны тасвирлауга күчкәнче, халык тормышына турыдын-туры кагылган “Хрущев реформалары” хакында да әйтергә кирәк. 1954-1958 елларда авыл хуҗалыгы продукциясен хәзерләү һәм сатып алу бәяләре күтәрелде, мәҗбүри рәвештә тапшырылырга тиеш булган нормалар киметелде. Колхозларның сугыш чорыннан ук җыелып килгән бурычлары юкка чыгарылды. Ел саен мәҗбүри таратыла торган заемнар, урта һәм югары мәктәпләрдә укучылардан укыган өчен җыела торган түләүләр бетерелде. Барлык бу чаралар нәтиҗәсендә халык, шул исәптән бәзәкәлеләр дә, үзләрен иркенрәк сизә башлады. Моны кешеләрнең киеменнән, йортларның тышкы күренешеннән үк күреп була иде.

50-еллар – безнең төбәктә нефть һәм газ чыгару киң колач җәеп киткән чор. Бәзәкә тирәсендә беренче нефть эзләүчеләр – бурильщиклар күренүгә күп вакыт та үтмәде, Сәйтәк авылы янындагы 15 номерлы скважинадан 1955 елның 20 маенда беренче нефть фонтаны аттырды. Бу скважинадан соң башкалары да нефть бирә башлады. Шулай Бондюг нефть чыганагы ачылды. Нефть белән бергә өскә чыга торган иярчен газ ул вакытта яндырыла гына иде, шуңа күрә тиз арада Бәзәкә тирәсе факелларга күмелде. Алар бигрәк тә төнлә бик якты яна, еракларга күренә иде. Шул факелларны санап, без тагын ничә скважина нефть бирә башлаганын белә идек. Озакламый “Прикамнефть” дигән нефть – газ чыгару идарәсе эшләп китте. Яшь нефть промыселы үзе чыгарган беренче 6600 тонна нефтьне баржа белән Кама буйлап 1958 елның сентябрендә озатты.

Нефть белән бергә безнең төбәккә зур масштабта электр энергиясе килде. Бәзәкәдән көнбатышка таба ике чакрым ераклыкта нефть җыю пункты ясалды. Бу нефть саклагычыннан Кама елгасы аша Бондюг – Әлмәт нефть үткәргече төзелде. Ул 1961 елда эшли башлады. Нефть сәнәгатенең интенсив үсеше күп кенә бәзәкәлеләрне (беренче чиратта, ир-егетләрне) үзенә тартты. Ә бу колхозда болай да кискен торган кадрлар проблемасын тагын да кискенләштерде. Нефть-газ чыгару табигатькә зарарсыз да булмады: сулыклар пычрануга, колхозның чәчүлек җирләре кимүгә китерде – ул җирләр нефть-газ корылмалары өчен колхоздан алынды. Шул ук вакытта нефтьчеләр белән бергә авылга зур уңайлыклар да килде.

Беренче чиратта, 1961 елда авылга электричество килүен күрсәтергә кирәк. Йортларга электр утын кертү бик гади эшләнде – урамдагы баганадан өйләргә тимер чыбык уздырылды, түшәмгә бер лампа һәм стенага бер выключатель куелды. Калганын йорт хуҗалары үзләре кайгыртырга тиеш иде (ниндидер куркынычсызлык техникасы турында сүз дә юк). Мәсәлән,

безнең алты почмаклы өйгә, иң кимендә, тагын өч-дүрт лампочка, шул кадәр үк выключатель һәм розетка куярга кирәк иде. Белгеч-электромонтерлар авылда юк. Берничә үзбелдегеннән маташучы егетнең зур авылда эше муеннан. Мин Казаннан ялга кайтканда, әти, атна-ун көн монтер эзләп, аяктан калган иде. Аптыраганнан, әти миңа: “Альта, син эшлисеңме әллә?” – диде. Мин, әлбәттә, катгый рәвештә баш тарттым. Ләкин әтигә әни дә кушылгач, яшьлек җүләрлеге белән ризалаштым. Башта мин кемнәндер (физика укытучысы Фоат абыйдан, бугай) белешмә китаплары алып кайтып, теорияне өйрәндем, аннан, тәвәккәлләп, бу акылга сыймаслык эшкә тотындым. Хәзергә кадәр, исемә төшкәндә, үземә үзем ышана алмыйм: мин бу эшне башкарып чыктым – арткы өйгә һәм өйалды-чоланга электр уты уздырдым (үзем дә исән калдым, пожар да чыкмады). Мин уздырган чыбыклар әле дистә еллар безгә хезмәт итте...

1958 елның февралендә Сталин исемендәге колхоз председателе итеп Әхмәрев Баян Вәли улы (1914-1992) сайланды. “Татар энциклопедиясе”ндә аның хакында түбәндәге белешмә урын алган: хәзерге Актаныш районы Күҗәкәй авылында дөньяга килгән; “Менделеев районының “Кама” колхозы рәисе (1958-1983). Минзәлә укытучылар әзерләү мәктәбен тәмамлый (1930). 1930-1940 елларда укытучы, мәктәп директоры, халык мәгарифенең район бүлеге инспекторы булып эшли. 1940-1957 дә Совет Армиясендә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ул җитәкчелек иткән елларда колхоз алдынгы хуҗалыкка әверелә. 1980 еллар башында бөртеклеләрнең уңышы 1 гектардан 20 центнерга, 1 сыердан савым 3000 килограммга җитә. Җитештерүнең барлык тармакларында заманча материаль-техник база булдырыла, социаль-көнкүреш объектлары төзелә. Әхмәрев Октябрь революциясе, 2-дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, “Почет билгесе” орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә”. Әйтергә кирәк, илдә Сталин культы фаш ителгәч тә, колхоз әле озак еллар күнегелгән исемен йөртте; 70-еллар азагында гына аның исеме “Кама” булып китте.

Б.В. Әхмәрев, 17 ел тормышын армиягә биргәннән соң, партия тарафыннан авыл хуҗалыгын күтәрергә җибәрелгән “утызмеңчеләр”нең берсе иде. Халкы бер дә читләргә буйсынырга яратмаган Бәзәкәдә ул үзен оста оештыручы, үзенә һәм башка хезмәткәрләргә карата үтә таләпчән, кирәк булганда, бик кырыс, хәтта катгый җитәкче итеп танытты. Тәҗрибәле тәрбияче буларак, ул җитәкче кадрлар коллективын булдыруга, беренче чиратта, колхоз идарәсенә эшлекле кешеләрне туплауга, шулай ук механизатор һәм терлекчелек өлкәсе белгечләрен тәрбияләүгә күп көч куйды. Мәсәлән, ирләр күпләп нефть-газ өлкәсенә китә башлагач, 1971 елда колхоздан 12 хатын-кыз трактористлар курсын тәмамлап, хатын-кызлардан гына торган тракторчылар бригадасы оештырылуын ассызыклап әйтергә була (Әхмәтҗанова Фәйрүзә, Зиннәтуллина Мөгаллимә, Сәлимуллина Минеямал, Сәлимуллина Фатыйма, Хәбибуллина Сажидә, Шәймәрданова Газзәбикә, Шәрәфетдинова Наталья, Шәяхмәтева Нәҗибә, Ганиева Мәүгыйдә h.б.). Күп кенә уңышларга ирешкән бу бригададан сигез кеше 1975 елда Мәскәүдә авыл хуҗалыгы алдынгылары слетында катнашты, алар хакында

радио-телевидение тапшырулары оештырылды, газета-журналларда мәкаләләр басылды.

Б.В. Әхмәрев рәис булып килгәндә, Сталин колхозында 3 трактор, 3 йөк машинасы, 3 комбайн, фермаларда 325 баш эре мөгезле терлек, 574 сарык, 315 дуңгыз булган. Авылны электрлаштыру колхозның барлык тармакларының заманча материаль-техник базасын булдыруга нигез булды. 60-70 елларда барлык җитештерү процессларын механизацияләштерү һәм автоматизацияләштерү каралган зур терлекчелек комплекслары төзелде. Катлаулы техника белән җиһазландырылган зур машина хуҗалыгы барлыкка килде. Кырларда минераль ашлама куллану кискен артты. Нәтиҗәдә, дип яза "Яңа Кама" газеты 1977 ел 7 ноябрь санында, "20 елдан соң колхозның 4800 гектар чәчү җирлеге, 1800 гектар болыны, 20 гусеницалы тракторы, 20 тәгәрмәчле тракторы, 17 "Колос" һәм "Сибиряк" комбайннары, 13 автомашинасы бар. Фермаларда 1850 баш эре мөгезле терлек, 1100 сарык, 700 дуңгыз, 3500 кролик. Колхоз 1976 елда 171400 сумлык продукция җиткерде, 451000 сум капитал кертелде, акча кереме 1014000 сум булды".

60-елларда Бәзәкә басуларында яңа культура – кукуруза күренә башлады. Бәзәкәлеләр бу культураны үзләштерүдә зур уңышларга иреште. Менә "Яңа Кама" газетасында басылган "Сталин исемендәге колхозның кукуруз басуыннан репортаж"дан бер-ике өзек: "Үз хезмәтеңнең татлы җимешләрен күрү күңелле дә, рәхәт тә. Колхоз председателе Баян иптәш Әхмеров та шундый хис кичерә. Ул кукуруз басуына чыгып баскан да, үзен күмәрдәй булып торган яшел үсемлекләр арасыннан "ныграк тырышсак, әле без мондый гына уңыш үстермәс идек" дигән кебек җитди генә карап тора. Күрәсең, әле ирешелгәннәр белән председатель һич тә канәгать түгел".

Бу сүзләрдән соң репортаж авторы газетада бирелгән фоторәсемнәр аркылы кукуруз игүдәге алдынгылар белән таныштыра: алар һәр гектардан 400-500 центнер яшел масса алучылар - Ык Тамагы бригадасы бригадиры Ермолина, кукуруз игү остасы Миңнәхмәт Халиков, звено җитәкчесе Фәрит Сәлахетдиновлар. "Дөресен әйтергә кирәк, Сталин исемендәге артельдә кукуруз үстерүгә елдан-ел күбрәк игътибар бирелә. Биредә мул уңыш кына үстереп калмыйлар, аны саклау турында да чын хуҗаларча кайгырталар. Колхозда кукуруз урып-җыюга керешкәнче үк инде силослау урыннары яхшылап хәзерләнеп куелган иде. Моның өстенә яңа траншеялар да казылды. Автомашиналар бирегә берөзлексез яшел масса ташып торалар, - дип күрсәткән автор. – Кукуруз уруда катнашучы механизаторлар да звено членнарының тырыш хезмәтен нык истә тотып эшлиләр. Алар һәркөнне 6-7 гектар кукуруз уралар. 75 гектар кукуруз силосланды инде". Чыннан да, ул басулар минем дә хәтеремдә: ерактан ук күренеп торган ямь-яшел кукуруз кырлары, якынлашканда, куе урманны хәтерләтә, биеклекләре ике – ике ярым метрга җиткән мәһабәт үсемлекләр стенасы янында ирексездән туктап кала идек.

Әлбәттә, барлык бу эшләрне сәләтле оештыручы исеме беән генә бәйләү дөрес булмас иде. Чирек гасыр дәвамында (1958-1983 еллар) Б.В. Әхмәрев колхоз председателе булган дәверне илдә барган зур үзгәрешләр

чоры дип атап була. Бу чорда илдәге хуҗалык һәм социаль реформалар нәтиҗәсендә авыл-шәһәрләрдә шактый актив иҗтимагый-икътисадый үсеш башланды. Ул эзлекле булмаса да, дәүләт хуҗалыгының барлык өлкәләренә кагылды. Шәхес үзен эштә күрсәтә алсын өчен күп кенә шартлар бергә туры килергә тиеш. Бу очракта шулай туры килде.

Авыл хуҗалыгында җитешкән уңышлар, нефть тармагында эшли башлаган бәзәкәлеләрнең керемнәре арту халык тормышына да зур үзгәрешләр кертте. Йорт-җирләре тузып-искереп барган һәм ремонтка яки яңа төзелешкә мөмкинлекләре бик чикле булган бәзәкәлеләр, беренче чиратта, өйләрен сипләү-ремонтлауга, ә мулрак тормышта яшәгәннәре яңа йортлар салырга кереште. Бу елларда шулай ук социаль-көнкүреш объектлары да төзелде. 1951 елның 1 сентябреннән яңадан урта мәктәп статусын кайтарган Бәзәкә мәктәбе бик тыгыз шартларда яшәргә мәҗбүр иде. Биналары искергән мәктәпкә алмашка 1961 елда авылга Бондюгтан килгән юлның уң ягында яңа бина салына башлады. Финанслау бик саран булганга төзелеш эшләре озакка сузылды. Ниһаять, 1967 елның 1 сентябрендә тантаналы рәвештә яңа мәктәп үзенең ишекләрен ачты. Шул ук елның 2 октябрендә яңа Мәдәният йорты эшли башлады. 1967-1968 елларда Бәзәкә урамнарында беренче су колонкалары куелды, авыл халкы артезиан скважинасыннан алынган су белән тәэмин ителде. Бәзәкәлеләр өйләрендә сыекландырылган газдан файдалана башлады. Ә авылны газификацияләү соңрак, 1978-1979 елларда башланды, 1979 елда Олы урамда асфальт юл салынды.

Барлык бу яңалыклар Бәзәкәгә нефть һәм электр уты белән килде дип тә әйтеп була торгандыр. Гомумән, электр уты авылга тормышны яңача кору мөмкинлеген ачты. 1961 елдан авыл тормыш-көнкүрешендә яңа чор башланды. Һәм бәзәкәлеләр үзләренең көндәлек тормышларына да, үз мөмкинлекләренән чыгып, яңалыклар кертергә тотындылар. Ләкин ул чорда мөмкинлекләр бик аз иде әле. Авыл хезмәтчәннәренең керемнәре җитәрлек булмау бу юлда зур киртә булып торды. Ул елларда илдәге иң зур социаль казаныш итеп, мөгаен, дәүләт пенсиясе белән колхозчыларны тәэмин итүне атап буладыр. СССР Югары Советы 1964 елның 15 июлендә “Колхозчыларга пенсия һәм пособиеләр турында” закон кабул итте. Бу көннәрдә мин авылда ялда идем һәм әти-әни янына дистәләгән өлкән яшьтәге авылдашлар килүе исемдә калган: кемдер киңәш, аңлату сорап килә, кемгәдер Собеска гариза язып бирергә, кемгәдер эш стажын расларга кирәк. Һәм алар барысы да әти-әнидән ярдәм таптылар.

Тулаем алганда, нәкъ менә Б.В. Әхмәрев Бәзәкә колхозын җитәкләгән чорны, бер яктан, авылның үсеш еллары дип атап булса, икенче яктан, ул чорның авыл тарала башлаган еллар булуын да инкарь итеп булмый. Әйе, бу елларда авыл тормышы тамырдан үзгәрде. Халык мулрак тормыш белән яши башлады. Яңа салынган йортлар шәһәрчә җиһазландырылды. Сәке-сәндерәләрне өстәл-урындыклар, карават-диваннар, шкафлар, көзгеләр алыштырды. Электр уты белән бергә халык көнкүрешенә радиоалгыч-магнитофоннар, телевизорлар керә башлады. Кар базлары урынына

суыткычлар кулланышка керде. Киемнәр үзгәрде. Урта белем алган яшьләр институт-университетларга китте. Хәтта клубта оештырыла торган кичәләр дә үзгәреш кичерде – “өчле”, “бишле”, “сигезле” кебек күмәк уеннарны “шәһәр биюләре” – вальс, фокстрот, танго, твист, шейк кебек көнбатыш биюләре алыштырды. Бу елларда кичләрен урам буйлап гармун тотып җырлап йөрүче егетләр дә азайды. 60-елларда шәһәрдән кайткан егетләр кичләрен, магнитофоннан килгән чит ил музыкасын дөбердәтеп, урамнарны әйләнә иде инде. 50-елларда егетләр велосипедта “элдерсәләр”, 60-елларда – “матай” (мотоцикл) модага кереп китте.

60-80 елларның икенче ягы – авыл тарала башлады дидем. Чыннан да. Бу елларда безнең төбәктә башланган зур төзелешләргә эш көчләре кирәк булды. Әгәр дә 50-60 елларда нефтьче булып киткән бәзәкәлеләр авылда яшәүләрен дәвам итсә, Түбән Кама, Чаллы төзелешләре яшьләрне тамыры белән йолкып ала башлады. Урта белем алуга ук егет-кызларның күбесе техник училищеләргә ашыга, белгечлек алып, заводларда эшли, тулай торакларда яши башлады. Институт-университетларны тәмамлаган бәзәкәлеләр дә төрле төбәкләргә эшкә җибәрелә торды. Моңа өстәп, Түбән Кама, Чаллы, Алабугада 70-80 елларда йортлар төзелешенең киң колач алуын, күпләгән бәзәкәлеләрнең, эшләгән җирләреннән фатирлар алып, яшь шәһәрләргә күчүен дә әйтергә кирәк. Аларның авылда яшәп калган ата-аналары, олыгаеп, авыл хуҗалыгы эшеннән читләшеп кенә калмады, үз мал-туарын да бетерә барды. XX1 гасыр башына Бәзәкә халкының күбесен балалары шәһәрләргә китеп беткән карт-корылар гына тәшкил итсә дә, йорт-җирләре төзек, пөхтә саклана безнең авылда. Дөрес, җәйләрен, оныклар күпләп кайткан чакта, Бәзәкә яртылаш урыслаша диярлек...

Бу хакта күп сөйләп тормыйча, “Татар энциклопедиясе”ндә Бәзәкә халкы хакында бирелгән берничә санны гына китерәм. 1920 елда Бәзәкәдә 2708 кеше яшәгән; 1926 елда – 2179 кеше, 1938 дә – 2248, 1949 да -1611, 1958 дә – 1533, 1970 тә – 1656, 1979 да – 1222, 1989 да – 781 кеше калган. Бәзәкә авыл советыннан алынган соңгы мәгълүматлар: 2016 елның 1 гыйнварына авылдагы 291 хуҗалыкта 752 кеше яшәве теркәлгән (алардан 628 кеше авыл прописскасында, 124 кеше прописскасызлар, ягъни авылдагы йортларын дача урынына кулланучылар тәшкил итә).

Менә шушы урында үземнең тарихи эзләнү-хатирәләремә нокта куеп, мин Харрас Әюпның “Авыл җаны” поэмасыннан тагын бер өзек белән тәмамлыйм:

Авыл җаны...
Каян белик ди без
Гади авылның да җаны барын?
Ул турыда кемнәр уйлап торсын
Ташлап киткән чакта авылларын?
Үзебезнең җан кайгысы иде...

***

Бәзәкәдә үткән 50-70 еллар хакында сеңлем Мәхмүтова Әнисәнең дә истәлекләре бар. Шуларны да укучыларга тәкдим итәм.

ИҢ КАДЕРЛЕ ЕЛЛАРЫМ...

Ташлап китте дип рәнҗемә,
Сагынуларым үзем беләм.
Авылкаем, хәсрәтләрең,
Шатлыкларың минем белән.
Мансур Шиһапов

Һәр кешенең тормышында иң матур, иң күнелле, йөрәгенең иң түрендә уелып калган вакытлары буладыр, мөгаен. Кемнеңдер бала чагы, кемнеңдер мәктәп еллары, кемнеңдер югары уку йортында үткәргән вакыты һәм башкалар. Әгәр миннән сорасалар: “Шундый мизгелләрең кайчан?” - дип, мин ике минут та уйлап тормыйча: “Авылда узган гомерем,” - дип җавап бирер идем. Әти-әнием исән-сау, үзем яшь, сәламәт, көч күп...

Әни әйтә торган иде: “Ике кызымның да балалык чоры тормышның иң авыр чагына – сугыш елларына туры килде. Шуны уйлап йөрәкләрем өзгәләнә. Сугыш бетеп, дөньялар рәтләнә башлагач, тагын бер бала табып, конфет кына ашатып үстерәсем килде. Менә шуңа күрә син тудың да инде”. Әнигә 37, әтигә 49 яшьтә мин беренче авазымны салганмын. Ничек курыкмыйча тудырасы булганнардыр, белмим. Әти сугыш елларында күргән газапларыннан соң ярым гарип булып кайткан, әни үлеп терелгән, яшьләре дә байтак – ничек шундый адым ясый алганнардыр!!! Ничек кенә булмасын, мин туганмын. Бераз үсә төшкәч, авыл апалары: “Син бит бутылка чаклы гына тудың. Без сине исән калмассың дип уйлаган идек. Тәки кеше булып үсәсең бит,”- диләр иде. Ходай тормыш биргәч, әле дә яшим. Миңа әни Альбина исемен кушарга булган, бар исемнәр дә А дан башлансын, имеш. Әтигә кабат-кабат әйткән дә, әйттергән дә. Авыл буйлап, бөтен очраган кеше белән сөйләшеп, авыл советына барып җиткәнче әти моңарчы колак ишетмәгән исемне оныткан. “Нинди исем куштырасыз?”- дип сорагач, әти аптырашта калган. Бөтенесе А хәрефеннән башланган исемнәрне әйтәләр, берсе дә ул түгел. Аптырагач, әти:”Әйдә, Әнисә булсын, барыбер А”,- дигән. Әтиемә шул исемне биргәненә мин гомер буе рәхмәтлемен.

Кендек әбисе Миньямал әбине мин зур үскәнчегә кадәр минем әбием дип уйлый идем. Әни, берәр камыр ашы пешерсә, тизрәк шуны әбигә суынганчы илтеп бирергә куша иде. Өйләре кечкенәрәк, түрдә сәке, һәрвакыт чиста, бөтенесе тәртиптә. Әби ачык чырай белән олысын-кечесен улым-кызым дип каршы ала, чәй эчермичә җибәрми. Ул үз гомерендә бик күп Бәзәкә кешесенә дөньяга туарга ярдәм иткән кеше, барысы да аны, зурлыйлар, бик ихтирам итәләр иде.

Үземне белә башлаганда әти районда фининспектор булып зшли иде. Ул авылларда йөри, иртә таңда мин уянганчы китә, кич соң кайта. Бер якшәмбе көнне генә күрәм. Әни мәктәптә укытучы булып эшли. Иртән җидедә эшкә китә, кич сәгать унберләрдә кайта. Дәрестән соң әллә нинди

җыелышлар, өстәмә эшләр – һич бетәрлек түгел. Менә шундый вакытта күршеләр ярдәмгә килә. Бигрәк тә Газзә әби истә. Ул каршыда гына тора. Берүзе яши. Улы Фоат абый армияда булды, ахрысы. Мәктәптән кайтам. Өй салкын. Әни әзерләп калдырган ашау да суынган. Ул чагында җылытып ашарга газ да, электр да юк. Берүземә лампа да яндырып торасым килми. Мин башлангыч сыйныфта укыйм. Дәресләрне әзерлим дә, караңгылана башлагач, Газзә әбигә кереп китәм. Аның өе җылы, изрәп утырам. Газзә әби: “Ипи белән шикәр булса, чәй эчәр идек, минем бик тәмле гөлҗимеш чәем бар,”- ди. Мин аның ни әйтергә теләгәнен беләм. Ул Хрущев заманы иде. Укытучыларга кеше башына көненә ярты буханка ипи, бер айга бер кило шикәр я конфет саталар. Аларны мин алырга тиеш. Кибет хәзерге Хузяхметов Әнвәр абыйларның беренче катында урнашкан. Аның эче халык белән шыплап тулган. Исемлек буенча алып бетергәнне көтеп торалар. Мин этә-төртә керә башлауга: “Хаҗи абыйның кызын кертегез,”- дип мине эчкә этәләр. Алуын аласың, әле кире чыгасы да бар бит... Ипине авылда пешерәләр иде. Ул хәзерге буханкаларның икесенә тора. Кабарып пешкән ак ипинең тәме әле дә булса хәтердә. Андый тәм хәзер юк инде. Газзә әбинең сүзен тыңлап, тиз генә өйгә чыгам да, теге ипидән икебезгә ике зур гына кисәк кисеп алам, ике зур кисәк шикәр дә эләктерәм дә күршегә кереп китәм. Анда тәмле гөлҗимеш чәе әзер. Икәүләп тәмләп аны эчәбез. Тамак тук, өй җылы, йокы килә башлый. Газзә әби кешегә палас суга иде. Шул яңа суккан җәймәләрне тимер мич белән стена арасына сала, ә мин шунда ятып, изрәп йокыга китәм. Бераздан Газзә әби мине уята: “Әниең кайтты, ут кабызды, бар, өеңә чык,”- ди. Мин, күзне яртылаш кына ачып, юл аркылы чыгып, капкадан керәм, өй ишеген ачам да туп-туры караватка авам. Әни ашарга чакыра, ә минем тамак тук, йокы тәмлерәк. Әни никадәр генә тырышмасын, мин йокыдан аерыла алмыйм. Төнлә күземне ачсам, әни әле ятмаган, мичкә яга, ашау пешерә, дәфтәр тикшерә, дәресләргә план яза... Кайчан яткан да, кайчан торган – анысы билгесез. Иртән яңадан аяк өстендә, мине ашарга уята... Бергәләп мәктәпкә китәбез.

Газзә әбинең улы Фоат абый армиядән кайтты, эшкә урнашты. Ул бик озак өйләнми йөрде. Көннәрдән беркөнне килен төшә дигән хәбәр ишетелде. Мин йөгереп урамга чыктым. Озак та үтми алар каршына арбалы ат килеп туктады. Яшь килен Шәмсия апа бирнәсе белән арбада утыра. Фоат абый бик олы гәүдәле иде. Булачак хатынын җәһәт кенә кулына күтәреп җиргә бастырды. Аның янында Шәмсия апа бик кечкенә булып күренде. Арбада бирнә белән тутырылган олы гына сандык, көянтә-чиләк һ.б. Капканы зур итеп ачып, атны ишек алдына кертеп, капканы ябып куйдылар. Килен бик әйбәт, йомшак күңелле, эшчән булды. Орчык кадәр генә булса да, бөтен өйне тотты. Өч уллары туды. Газзә әби дә, олы яшьтә булуына карамастан, балалар үстерергә булышты – кайчан керсәң дә бишек янында, йоклый-йоклый булса да шуны тирбәтеп утыра иде. Шәмсия апа кайнанасын бик кадерләп карады һәм соңгы юлга озатты.

Җәен хатын-кыз җиләккә йөрергә тырыша. Ләкин бу бик авырлык белән башкарыла, чөнки бу вакытта колхозда да эш бик күп. Мин дә Шәмсия

апага иярен җиләккә барам. Ул мине алдан ук кисәтеп куя: “Мин әйткәнне тыңла, миңа гына карап тор”,- ди. Мыштым гына инешкә таба китәбез, күперне чыгып, таулар арасына кереп югалабыз. Ул арада тау өстендә атка атланган бригадир күренә. Без чокыр эченә кереп, тын алырга да куркып, качып ятабыз. Бригадир күрсә, ачуланып, куып авылга кайтара, эшкә чыгарга мәҗбүр итә. Ә зур апалардан башка мин берүзем, кечкенә генә кызчык, җиләккә бара алмый калам. Колхоз эше бетмичә, колхозчылар үзләренә җиләк-җимеш җыярга да, утын-печән әзерләргә дә, бәрәңге казып алырга да тиеш түгелләр иде – бөтенесен дә кача-поса эшләргә мәҗбүр булдылар, барысын да үз вакытында эшләп калырга кирәк бит.

Бездән сул якта Ясәви бабай гаиләсе белән тора. Аның карчыгы сукыр, шуңа күрә суны үзе ташый. Биш яшьтән мин аның белән суга йөри башладым. Чишмәгә нинди юл бар, мин аның белән бөтенесеннән дә йөреп чыктым. Кышкы буранларда, көрттән чыга алмыйча газапланганда, ул мине тартып чыгара иде. Язларда чишмә кар суы белән капланганда, көянтә башына чиләк тагып, бик оста гына итеп аны суга чумдырып тутырырга һәм тартып чыгарырга өйрәтте. Җәйләрдә чишмәнең суы кимеп, болганчыклана башлагач, инеш буйлап җир астыннан бәреп чыккан суны чүмеч белән җыярга булышты. Ясәви бабайның өч улы бар иде. Иң олысы Нургали абый өйләнеп, башка чыкты. Икенче улы Сәетгали абый атаклы көрәшче иде. Сабантуйларда бик озак батырлыкны бирмәде. Ул әле бик матур итеп җырлый да иде. Тавышы моңлы, йомшак. Кече уллары Тимергалинең тифтан акылына зәгыйфлек килгән булган. Аннан күбесе курка иде, чөнки алдагы минутта аның ни эшләсен беркем дә белми. Ә мин аның күршесендә генә яшим. Миңа дус кызлар да килергә курка. Ул көннәр буе капка төбендә утыра. Аның өстенә безнең каршыда һәрвакыт су, әмәтәй дип йөртә торган баткаклык. Ул беркайчан да диярлек кипми иде. Аның аркылы чыгарлык түгел. Аңа ташлар салып, атлап чыгарлык итәргә өлгермиләр, алар тагын баткаклыкка кереп югала.

Ясәви бабайның сул ягында Мәчтүрәттәй (безнең якта түтәй сүзен шулай кыскартып исемгә кушалар) тора иде. Ул мине бишенче класста укыганда беренче тапкыр каз өмәсенә чакырды. Үземне зур итеп хис иттем, ышанып тапшырган бөтен эшне җиренә җиткереп башкарырга тырыштым. Анда өйрәнгән һөнәрләрем тормышта бик кирәк булып чыкты.

Уң якта Башаровлар. Гаилә башлыгы Шоңкар бабай. Мин аннан шүрли идем. Ул бик аз сөйләшә, минем ише бала-чагага игътибар да итми. Бөтен гаиләсен тәртиптә тота. Карчыгы Бәдәрттәй бик шук, күңелле, һәрвакыт эштә. Инде карт булуына карамастан, күзлексез энә саплый, тегә, тешләре ап-ак, тезелеп тора. Аларның улы Мирсәет абый, хатыны Тәскирә апа, өч уллары бар. Тәскирә апа чын килен: күп сөйләшми, гел эштә, барлык гаиләне ашата-эчертә, юа, чистарта. Мин аның кычкырып сөйләшкәнен дә ишетмәдем. Иртә таңнан җигелеп эшли. Ник бер каршы сүз әйтсен! Шул кадәр чыдам булса булыр икән!

Мирсәет абый мине биш яшемдә үлемнән коткарды дип әйтсәм дә була. Әни мине, ныгысын диптер инде, бик кечкенәдән биергә өйрәтеп,

концертларга катнаштырырга тырыша иде. Ничек курыкмыйча биш яшемнән авыл яшьләре белән шундый чараларга җибәргәндер! Бервакыт шулай авыл үзешчәннәре күрше Тәкәш авылына концерт белән барырга җыендылар, мине дә чакыра килделәр. Укытучы-баянчы Аликин абыйга ышандырып, әни мине, 5-6 яшьлек баланы, алар белән җибәрде. Кыш, февраль ае. Өч чанага төялеп киттек. Концертны куеп, кайтыр юлга чыкканчы төн уртасы җиткән. Артистлар кызган, Аликин абыйның миндә хәбәре дә юк. Букчамны күтәреп, уртадагы атның чанасының иң артына кысылып кына утырдым. Кузгалып киттек. Кайсы җырлый, кайсы көлешә, кайсы йокымсырый... Берзаман арттан килә торган ат пошкыра-пошкыра безнең өскә килә, чанага басардай бара, башы минем баш өстендә үк, менә тешләр-менә тешләр кебек. Кычкырып карыйм – берсе дә игътибар итми. Куркуымнан букчамны кысып тоттым да чанадан тәгәрәп төшеп калдым. Атлар чыр-чу килгән яшьләр белән авылга таба элдерттеләр. Ник берсе сизсен, күрсен. Ай яктысында кар җем-җем итә. Ни Тәкәш, ни Бәзәкә – бер авыл да күренми. Әкрен генә атлар киткән юлдан атлыйм. Ничектер күңелдә курку да, борчылу да юк. Яшем зуррак булса бу җүләрлекне эшләмәгән булыр идем. Кайтам шулай әкрен генә. Алай да күңелгә бераз курку керә башлады, бүре я эт килеп чыксса нишләрмен дип уйлыйм. Бервакыт арттан тарантаслы ат килеп җитте. Мин бата-чума юл кырыена чыктым. Минем янга килеп җиткәч, тарантаста утырган ир-ат атын туктатты. Мине күтәреп алып кырыена утыртты. Шунда гына аның безнең күрше Мирсәет абый икәнен белдем. “Төнге бердә нишлисең бу кыр уртасында?”- ди, аптыравы йөзенә чыккан. Авылга кайтып, әнигә тапшырды. Әнинең исе китте, ни дип әйтергә дә белми. Ничек йөрәге түзгәндер! Икенче көнне Аликин абый белән ничек аңлашканнардыр, белмим. Ул бит: “Үз кулым белән алып кайтып тапшырам,”- дигән иде. Шулай итеп, Мирсәет абый булмаса, бу вакыйга ничек беткән булыр иде микән?

Шоңкар бабайлар кырыенда Разия апаның өе. Аның белән бергә Бәдәр исемле апасы тора. Ул йөрми иде. Ул чагында пенсия-мазар булмаган бит инде. Кайчан керсәң дә Бәдәрттәй сәкедә ята, кулында энә белән җеп – сатарга үбәл бәйли, шулай Разия апага тормыш алып барырга булышуы булгандыр, күрәсең.

Бездән ерак та түгел Гайшәттәй яши. Аның өч кызы, бер улы бар. Бу бәләкәй генә карчык, авыр тормышта яшәсә дә, шат күңелле иде: җырлап та ала, биеп тә җибәрә. Мин аның күңелсез, кайгырып-елап утырганын күрмәдем, һәрвакыт шук, тормыш җанлы булды. Мин кияүгә чыгып, беренче баламны тапкач, Алабугага китәргә җыендым. Бик күңелсез, барыбыз да югалып калдык. Машина килгән, чыгып утырырга кирәк. Шулвакыт елмаеп Гайшәттәй килеп керде, баланы кулына алды, дога укый-укый аны төрде. Сүзләрен дә тапты, тыныч ландырды, урамга алып чыгып, бисмиллаларын әйтеп, машинага утыртты, яхшы теләкләр тели-тели озатып калды. Бүген дә аның елмаеп торган йөзе, кечкенә генә гәүдәсе күз алдымда тора.

Минем мәктәп елларым Хрущев заманына туры килде. Аның планы буенча без тиз арада Америкаиы куып җитеп, узып китәргә һәм коммунизмда яшәргә тиеш кешеләр идек. Колхозчылар өйдә, мал-туар тотып, интегеп

ятарга тиеш түгел, ә кибеткә барып, кирәкле әйберен алырга тиеш. Шуңа күрә мөгезле эре терлекне колхозга илтеп тапшырырга мәҗбүр иттеләр. Безнең сыер Маньканы да шул язмыш көтә иде. Аны ишек алдыннан алып чыгып киткәндә мин елап калдым. Аның урынына кәҗә алып куйдылар – сөтсез булмый бит. Ә кибеттә сөт юк. Икенче бер яңалык: кешеләр өйләрендә ашау-эчү әзерләргә тиеш түгелләр, ашханәгә барып әзер ашау гына ашарга тиешләр. Безнең дә авыл уртасына ашханә салып куйдылар.

Безнең әти-әни сирәк кенә булса да туганнарга икәүләп кунакка баргалыйлар иде. Әтинең бер кызык гадәте бар. Һәр җәйдә безнең өй кунаклардан арынып тормады. Әни ничек түзгәндер! Аларны ашатырга да кирәк бит. Көндезге ашны утырып ашар өчен ишек алдында зууур өстәл, тактадан ясалган утыргыч. Кайбер чагында икешәр смена утырып ашый идек. Кунакларны әти бик теләп көтә, каршы ала. Беренче-икенче көнне яннарыннан да китми, өченче көнгә әти күбрәк юк-бар эш белән шөгыльләнә башлый, дүртенче көнне юк сәбәпне бар итеп юкка да чыга башлый. Аның җавабы бер: “Кунак өч көн була ул!” Үзе дә, кая гына бармасын, өч көннән кайтып җитә. Бервакыт әни белән икесе, бик нык җыенып, Сортовала шәһәренә киттеләр. Ул Финляндия чигендә урнашкан. Анда Шәриф абый хезмәт итә иде. Атна-ун көннән кайтып та җиттеләр. Поездда бөтен ил буйлап барасы-кайтасы да бар бит әле! Әни әйтә: “Барып җиткәннең өченче көнендә әтиегез кайтырга җыена башлады. Бөтенесенең исе китте, җибәрмиләр. Ә ул үзенекен сөйли, дүртенче көндә кайтырга җыенып чыгып та утырган. Шулай кайтып киттек инде”.

Шулай итеп, алар каядыр кунакка киттеләр. Миңа бераз акча калдырып: “Теләсәң, ашханәгә да барып ашарсың”,- диделәр. Анда утырып ашарга читенсенгәнмендер инде. Савыт-саба алып, шунда киттем. Ерактан ук авыз суларын китереп тәмле исләр чыгып тора. Татар авылында күбесенчә токмачлы аш бит инде. Ә монда щи-борщ та пешерәләр. Шул аш янына гуляш белән бәрәңге боламыгын да алып, тутый кош тоткандай, өйгә йөгереп кайтып, утырып, тәмләп ашыйсың. Аны әле көне буена җиткерәсең. Ул ашларның тәме әле дә исемдә. Шул ук вакытта авылда роддом да ачтылар. Шәмсия апа белән Шура апа акушеркалар булып киттеләр.

Хрущевның кукурузасының шаукымы безнең авылга да килеп җитте. Мәктәптә производство бригадасын оештырдылар. Орлыгын утыртудан алып кукуруз чәкәне үсеп җиткәнче карап үстереп, хөкүмәткә тапшыру белән җәй буе мәш килә идек. Чебиләр карап үстерү дә, куяннар да калмады. Кош-корт тизәге, көл җыю дисеңме, көз буе бәрәңге казып алу дисеңме, кул белән ашлама сибү дисеңме – барысын да эшләдек. Зуррак үскәч, безнең колхозга кергән Ык-Тамагы авылына бәрәңге алырга җибәрәләр. Ул рус авылы, анда карт-корылар гына яши, яшьләр якын-тирә шәһәрләргә күчеп киткәннәр. Безне квартирларга тараталар. Бәрәңге эше беткәнче шунда яшибез. Ял көннәрендә юынырга, өс киемнәрен алмаштырырга авылга кайтып киләбез. Нинди генә эш кушмасыннар, бөтен эшне дә авыр итеп кабул итмәдек, һәрберсеннән кызык таба идек. Мәктәптә буфет эшли, анда Шәмсекамал апа ашау сата. Озын тәнәфестә аның кырыена укучылар җыела, талаша-талаша

калын көрән кәгазьгә салынган кильки белән бер телем кара ипи, я булмаса мичкәдә тозлаган яшел помидор белән шул ук бер телем кара ипине 5 тиенгә алып тәмләп ашыйбыз.

Мин 6-сыйныфта укыганда булган тагын бер вакыйга күңелгә уелып калган. Көз, яхшы гына дәресләр башланып китте. Икенчеме-өченчеме дәрестән соң барыбызны да залга җыйдылар. Американың безгә каршы сугыш башлавы-башламавы хәл ителә дип аңлаттылар. Бөтенебез кайгыда, кайберләре елый ук башлады. Ул чагында ук атом сугышы турында сөйлиләр иде. Хиросима, Нагасаки турында белә идек. Безгә бик озак тоелган вакыттан соң йөзләренә елмаю чыккан укытучылар сугыш булмый дигәннән соң ни булганы әле дә хәтеремдә: китте кочаклашу, сикерү, бию... Яңадан дәресләр башланды. Укытучыларга безне тынычландыру бик авыр булгандыр.

Көннәрдән беркөнне бездә нефть эзлиләр икән дигән сүз ишетелде. Зыярат кырыена зур гына вышка китереп куйдылар. Эш аннан арыга узмады. Күпмедер торганнан соң, аны сүтеп, берничә зур-зур тракторларга төяп, каядыр алып та киттеләр. Авыл тынычланып калды. Безнең авыл янында нефть юк дигән карарга килсәләр дә, күпмедер вакыт узгач, район буйлап әле анда, әле монда вышкалар күтәрелеп чыга башлады. Кырларда кара алтынны чыгара торган качалкалар бер күтәрелә, бер төшә. Факелларның ниндие генә юк – олысы дисеңме, кечесе дисеңме, һәрберсеннән күкләргә тиярдәй булып ут телләре күтәрелә. Кичләрен һәм төннәрен шул кадәр якты була иде, хәзерге электр баганаларың бер якта торсын. Ә без һаман элеккечә тал чыбыгын ягып, аннары күмер модага кереп китте – шуны интегә-интегә кабызып җибәреп (аның да үз җае бар), өй җылытабыз, ашау пешерәбез. Авылга газ кергәнче ничә еллар үтте микән? Аңарчы да бит әле башта газ баллоннарыннан файдаландык. Ә кырлар бик озак яктыда, җылыда булдылар.

Берзаман Бәзәкә су астында кала икән дигән хәбәр таралды. Чит кешеләр килеп, инеш буйларын ниндидер ят приборлар белән тикшереп йөри башладылар. Чишмәгә төшә торган юлда, бер урам булып, байтак кына өйләр тора иде. Аларга авылның өске ягына күчәргә туры килде. Ул җиргә барыбер су килеп җитмәде, яхшы гына яшәп яткан кешеләрне, туган-үскән җирләреннән аерып, урыннарыннан кузгатасы да түгел иде. Гасырлар буе бәзәкәлеләрне ашатып торган, печәнен, утынын биргән болыннар, күлләр, әрәмәләр су астында калды. Суы коенырлык булса да хәтерең калмас иде. Ә болай сазлык булды да калды.

Атнага бер тапкыр пәнҗешәмбе көнне мәктәптә, безнеңчә әйтсәк, танцылар була иде. Анда я җиденче сыйныфтан, я бишенче сыйныфтан йөрергә була иде. Ул гел үзгәреп тора. Бу үзенә күрә бер бәйрәм иде. Ара ерак, салкын, бозлавык, саз дип тормый идек, йөгерә-йөгерә тау башына – мәктәпкә ашкынабыз. Бервакыт, 8-9 сыйныфта укыган вакыт булгандыр, матур май аенда танцы булырга тиеш көнне мәктәпкә җыелдык, ә ул бикле. Биисе килә. Малайлар, күп уйлап тормыйча, форточкадан кереп, магнитофон алып чыктылар, ничек электр тогына тоташтырганнардыр, белмим, музыка уйный башлады. Туйганчы биеп, магнитофонны урынына куеп, кайтып

киттек. Үзебез куркабыз. Икенче көнне линейкага җыйдылар, бик нык итеп ачуландылар – алай озакка сузмадылар тагын.

Шулай итеп, мәктәп еллары үтеп тә китте. Ул елны ике 10, бер 11-сыйныф чыгарылышы иде. Экзаменнар уңышлы гына үтте. Бөтенебез чыгарылыш кичәсен көтәбез. Бигрәк тә кызлар әзерләнә. Менә көткән көн килеп тә җитте. Киенеп-ясанып, сөенә-сөенә клубка киттек. Безне котладылар, аттестатларны тапшырдылар да таралышырга куштылар. Каршы килеп караган идек тә, файдасы булмады. Өстән шундый фәрман килгән, имеш. Танцы урынына кайсыбыз кая таралыштык.

Безнең Бәзәкә мәктәбе бөтен яктан да алдынгы санала иде Шуңа күрәдер инде ул елны югары уку йортларына бик күп укучы керде. Минем дә язмышымны хәл итәргә дип гаилә советы җыелды. Күптәнге хыялым, Казан университетын бетереп, юрист булу. Аңа әни дә, апалар да каршы түгел иде. Әти: “Алты баланың берсенә генә хакым бардыр. Әнисәне ераккa җибәрмибез. Әнә Алабуга институты, шунда керә,”- дип әнигә усал итеп карады да чыгып та китте. Әни дә моңа каршы бер сүз дә әйтмәде. Андый сүзләрдән һәм караштан соң елап утыруның файдасыз булуын мин аңлый идем. Ә менә әтинең алты бала турындагы сүзе күптән түгел генә башыма барып җитте. Әни гомер буе балалар русча белсен, белем алсыннар, кеше булсыннар дип яшәгән: Шәриф абыйны Алабугага педучилищега җибәргән, Альта апа белән Алиса апаны кече яшьтән үк Бондюгка озаткан, Нажия апа да: “Оркыя әнәй аркасында гына Алабугага, бер авыз сүз русча белмәсәм дә, укырга барып кердем. Ул мине, укы, кеше булырсың, дип, җибәрергә тырышты,”- ди торган иде. Рәмзия апа, укырга теләмичә, Березнякка китеп барган. Шулай итеп, әти мине – алты баладан берсен генә булса да үз янындарак калдырырга тырышкандыр, күрәсең.

Рус теленнән безне Рәшит абый Башаров укыткан иде. Соңгы ике елны, директор итеп куйганга, аның дәресләрен кыскарттылар. Ул безнең классларны алмады. Без аңа шулчаклы үпкәләдек, хәттә озак кына сөйләшмичә дә йөрдек. Ул безгә аңлатып та карады, тик безнең аңа үпкәләвебез кимемәде. Менә шул Рәшит абый биргән ныклы белем белән институтка да кердек. Ә тарихтан Гаян апа Әюпова укытты. Ул шундый итеп дәресне аңлата, көчкә өчкә укыган, бүтән фәннәрдән, күренмәсәм ярар иде дип, партага сеңеп утырган балалар да кул күтәреп җавап бирергә тырышалар иде. Институтка кергәндә тарихтан экзаменны атаклы Насибуллинга бирергә туры килде. Барлык өч сорауга да җавап биргәннән соң тотынды бу даталар буеча куарга... Коридорда Альта апа көтеп тора иде. “Әллә бирә алмадыңмы?”- ди. “Нигә?”- мин әйтәм. “Бик озак тордың. Бар, көзгедән үзеңне кара,”- ди. Карасам, битем каушауданмы, куркуданмы, тимгел-тимгел булып, кызарган, зәңгәрләнгән. “Бишле”, - дим, ниләр булганын сөйләп бирдем. Экзамен алдыннан даталар буенча апам үзе әзерләгән иде бит. Шуннан соң биш ел буе Насибулин, кайда гына күрмәсен, көчле тавышы белән: “Как дела, Махмутова (или бизякинская)?”- дип сәламли иде. Гаян апа биргән белем белән институтта тарихтан җиңел бардым.

Студент еллары күп кешенең хәтерендә иң күңелле еллар булып саклана торгандыр. Ә минем хәтеремдә уку атнасы тизрәк үтсен дә тизрәк өйгә кайту теләге булу калган. Икенче көнне, беренче пар булмаса, төнгә каршы булса да авылга кайтып китә идем. Ә иртән сәгать 3-4тә торып, җәяү ТХУга чаклы барасың, берәр машинага утырып, яңадан Алабугага китәсең. Шулай авылны, әти-әнине, җылы өйне сагынып, ике арада йөреп, биш ел үтеп тә китте. Институтта күңелсез булды дип әйтә алмас идем мин. Күңелле итеп концертлар да куя идек, танцыга да йөрдек, бәйрәмнәр дә була иде. Ләкин болар берсе дә авыл җылысын бирмәде.

Институт бетереп, мин авылга кайттым. Мин дә кайчандыр әни кебек яшь укытучы булып мәктәптә эшләячәкмен. Әти-әни пенсиядә инде, картлар. 16 августта эшкә чыктым. Бу инде мин укыган тау башандагы мәктәп түгел, яңасын салып, шунда укыта башлаганнар иде. Мине укыткан укытучылар белән эшли башлавы куркытты, әлбәттә. Нажия апага 4А, миңа 4Б классын бирделәр. Класста балалар күп. Уку елы башында ук күрше Сәйтәк авылында мәктәпләре янды. Безне җыеп, балаларны якты йөз белән каршы алырга, бөтен сорауларына да җавап бирергә, ярдәм итәргә һәм тизрәк танышып китсеннәр өчен ике авыл баласын аралаштырып утыртырга куштылар. Автобуста алып килделәр укучыларны, ике дүртенче класска унар бала бүлеп бирделәр. Алып киттем боларны балалар белән таныштырырга. Анда укучылар белән сөйләшеп куйдым, урыннар да әзерләнгән. Барысы да берсүзсез барып утырдылар. Павел дигән малаем: “Мин анда утырмыем, - ди. “Нигә?”- дим. “Мин татар белән утырмыем,”- ди. Сәйтәктә керәшеннәр яши. Моңарчы милләтләр арасында каршылыкка очраган булмагач, башыма таяк белән китереп суккандай булды – исем китте. Алай дип тә карыйм, болай итеп тә карыйм – көйгә килми генә бит. “Ярар, - мин әйтәм, - монда бер буш парта бар, шунда утыр”. Аңа риза булды.

Мәктәпкә АДПИдан рус теленнән практикантлар килделәр. Миңа да ирле-хатынлы ике студентны бирделәр. Мин Хәй абый янына йөгердем – ул завуч иде. “Мин үзем дә практикант бит әле,”- дим. Хәй абый көлә генә, йомшак тавышы белән әкрен генә тыныч ландырып чыгарып җибәрде. Ни белән керсәм, шуның белән чыгып киттем.

